
ISSN 0206—4189

# Казан утлары

4.2002



# «КАЗАН УТЛАРЫ»НА 80 ЕЛ




1933 ел башыннан журнал **«Совет әдәбияты»** исеме белән чыга башлый. Аның беренче саны (**Г. Нигъмәти** редакциясендә) «әдәбият, сәнгать һәм тәнкыйть журналы» итеп тәкъдим ителә. Икенче саннан журналның җаваплы редакторы— **Кави Нәҗми** (1933—1934). Шул ук саннан «әдәбият, сәнгать һәм тәнкыйть журналы» дигән билгеләмәгә «публицистика» дигән сүз өстәлә.

Утызынчы еллар... Сталинның шәхес культы тарафыннан зыялыларның юк ителүе, эзәрлекләнүе шартларында, редакторлары бик еш алмашынып торса да, журнал үзенең яшәвен дәвам итә.

Бөек Ватан сугышы елларында кайбер газета-журналлар ябылса да, «Совет әдәбияты» чыгудан туктамый. Ул фронтовик язучылар белән элемтәдә тора, укучыларын аларның әсәрләре белән таныштырып бара.

Сугыш тәмамлангач язучылар дәһшәтле еллар турында зур күләмле әсәрләр иҗат итәләр. Г. Әпсәләмовның «Ак төннәр» (1947), «Алтын йолдыз» (1949), «Газинур» (1951) романнары, М. Җәлилнең «Моабит дәфтәре» циклына кергән шигырьләре (1953), Н. Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» (1957), Ш. Маннурның «Муса» (1965) әсәрләре, С. Хәким, З. Нури һ.б. поэмалары журналда дөнья күрә.

Илне төзекләндерү чорында татар халкының күркәм мораль сыйфатларын, аның тарихи үткәнен, хезмәт сөючәнлеген чагылдырган яңа әсәрләр туа. Г.Бәшировның «Намус» (1948), К. Нәҗминең «Язгы җилләр» (1948), И. Газиның «Онытылмас еллар» (1949), М. Әмирнең «Ялантау кешеләре» (1953), «Саф күңел» (1959), Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» (1959), Ф. Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы» (1961), Г. Гобәйнең «Без үскәндә» (1963), Ә. Еникинең «Йөрәк сере» (1958), «Рәшә» (1963), Г. Ахуновның «Хәзинә» (1962), А. Расихның «Ике буйдак» (1964) әсәрләре, Х. Вахит пьесалары, Х. Туфан, Н. Арсланов, С. Хәким поэмалары һәм шигырьләре әнә шундыйлардан.

Журнал 1939 елга кадәр латин имласында, аннан соң кириллицада 1965 елның 5 санына кадәр «Совет әдәбияты» исеме белән чыга.

**Казан утлары**

**Qazan utları**

*2002*

# 4

**(954)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## *Бу санда*

ШИГЪРИ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР


Факил САФИН. Саташып аткан таң. *Роман (Икенче китап)* ..... 5
Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Яңа шигырьләр ..... 82
Ләбибә ИХСАНОВА. Күңел күзе күргәндә. *Парчалар* ..... 91
Рөстәм МИНГАЛИМ. Онытылмас хатирәләр. *Шигырьләр* ..... 98
Нур ӘХМӘДИЕВ. Дөньяларны гаярь ир бизәр... *Шигырьләр* ..... 102
Рәниф ШӘРИПОВ. Ил эчендә — ил. *Шигырьләр* ..... 128


ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ


Данил САЛИХОВ. Мөгезле Мәүлихан. *Комедия* ..... 106


"КАЗАН УТЛАРЫ"НА 80 ЕЛ


Нәзиф МИРИХАНОВ. Саллы сүз мөнбәре ..... 32
Васил ГАЙФУЛЛИН. Милләт бөтенлеген кайгыртучы журнал ..... 116
Владимир ИВАНОВ. Рухи терәгебез ..... 134
Шамил ЗАКИРОВ. Хәзинә таптым! ..... 160
Солтан ГЫЙЛЕМХАНОВ. Ул мине гомер буе озата килде ..... 178


ТАРИХ


Солтан ШӘМСИ. Низаглы йортта ..... 131


ЯҢА ИСЕМНӘР


Хәмит ЛАТЫЙПОВ. Өшегән йолдызлар яктысы. *Шигырьләр (Р. Гаташның кереш сүзе белән)* ..... 136


ПУБЛИЦИСТИКА


Әгъдәс БОРҺАНОВ. Дөнья көзгесендә — урыс гамәле ..... 139


КОРЫЛТАЙ АЛДЫННАН УЙЛАНУЛАР


Рифат СВЕРИГИН. Гасырлар чатында ..... 145
Ризван ХӘМИД. Татар драматургиясе миллиме? ..... 155
Мөдәррис ВӘЛИЕВ. Сөенсеннәр әле сабыйлар! ..... 164


ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ


Равил РАХМАНИ. Кыйблабызга тугрылык ..... 170


ЮМОР-САТИРА


Маннур САТТАР. Такмаклар ..... 185
Укучы сүзе ..... 187
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 189

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": Ф. САФИН. Роман "Мнимый рассвет" (книга вторая); рассказы Л. ИХСАНОВОЙ; стихи Р. ФАЙЗУЛЛИНА, Р. МИНГАЛИМОВА, Н. АХМАДИЕВА, Р. ШАРИПОВА.
"К 80-летию журнала": «"Казан утлары" в моей жизни»—воспоминания Н. МИРИХАНОВА, В. ГАЙФУЛЛИНА, В. ИВАНОВА, Ш. ЗАКИРОВА, С. ГИЛЕМХАНОВА.
"Драматургия": комедия Д. САЛИХОВА "Рогатый Маулихан".
"История": С. ШАМСИ. "В скандальном доме" (страницы истории Золотой Орды).
"Новые имена": стихи Х. ЛАТЫПОВА (с предисловием Р. Гаташа).
"Публицистика": А. БУРГАНОВ. "Русский вопрос в зеркале мировой истории".
"Навстречу съезду писателей": Р. СВЕРИГИН. "На рубеже веков"; Р. ХАМИД. "Татарская драматургия—национальна ли она?"; Мударрис ВАЛИЕВ. "Пусть радуются дети",
"Литературная критика": Р. РАХМАНИ. "Преданность".
"Юмор-сатира": частушки М. САТТАРА.
Наш календарь.
Слово читателя.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: "Половодье"—фотоэтюд; поэтесса Ф. Тарханова.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and poetry": F. SAFIN'S novel «The seeming dawn» (the second book); L. IKHSANOVA'S stories; the verses of R.FAIZULLIN, R.MINGALIMOV, N.AKHMADIEV, R.SHARIPOV.
"Commemorating of 80th anniversary of «Kazan utrary» magazine": «Kazan utrary in my life» - reminiscences of N.MIRIKHANOV, V.GAIFULLA, V.IVANOV, Sh.ZAKIROV, S.GILEMKHANOV.
"Dramatics": D.Salikhov's COMEDY «HORNED MAULIKHAN».
"History": S. SHAMSI "In scandalous house" (the history pages of Gold Orda).
"New names": Kh.LATIPOV'S verses (with R.Gatash's preface)
"Journalism": A.BOURGANOV. "Russian question at the world history mirror"
Reflections about coming congress of writes: R.SVERIGIN "On the boundary of century". R.KHAMID "Is tatar dramatics national?"
M.VALIEV. "Let chilolren be glad."
"Literary criticism": R.RAKHMANI "The loyalty"
"Humor and satira": sung couplets of M.STTAR.
Our calendar.
Reader's word.
The diary of social and cultural life.
In our covers: "The high water"; poet F.TARKHANOVA.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 26.03.2002 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 9134. Заказ Б—165
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2002 ел.



## Факил Сафин

# САТАШЫП АТКАН ТАҢ

ИКЕНЧЕ КИТАП*

РОМАН

I

...1930 елның салкын гыйнвар иртәсе...

Чулман өсләп сыек рәшә сыман томан күтәрелә. Яңа ел башына кадәр ишле карлар явып, көннәр буранлап торды да, кинәт кенә жылытып, җепшетеп җибәрде. Атна чамасы шулай булды. Карлар чын-чынлап эри башлады дигәндә, кыш үзенең бар ихтыярын, бар гайрәтен үз кулына алды, ахры, сансызланып маташкан идегез, менә күрегез инде алайса дигәндәй, янә буран котырды, аннан чатнама суыклар башланды.

Чаллыдан чыкканга чирек сәгать вакыт үтмәде, туры айгырның сырты ак бәскә төренеп өлгерде. Юл бозлы, шуңа күрә олаучы, кашсыз бүрек кигән олы яшьләрдәге чандыр гәүдәле агай, атын бик куаламаска тырыша—ат хөкүмәтнеке, кантон кәнүшниеннән бирелгән, аяк-тоягын имгәтеп кайтсаң, көт тә тор, мәхкәмәсез-нисез Минзәлә төрмәсендә ике-өч ай яткырып, сохари кимертеп чыгарырлар. Яңа блачның талканы коры. Казан кунагына ике дөнья бер моржа, чыптага төренеп, печәнгә күмелеп утырган да, дәшми-тынмый, үз уйларына йомылып тик бара. Керпе кебек. Болай үзе, кала кешесе булса да, кышкы юлга чыкканын белгән тагын, калын киенгән, аягында да шәп олтанлы киез итек. Казаннан килгән вәкилләрне күргәне бар агайның, кайберсе бигрәк юка киенеп килә: әллә кышкы юлга чыккан, әллә сәхрәгә сәйрангә җыенган. Чанага менеп утыруга тотына тынгысызланырга, тотына боргаланырга—шул арада моңа суык бабай ике куллап чытырдап ябышырга да өлгергән димәк ки... Бичара мосафир чәнчеп-чәнчеп ямчыга да карап ала. Әйтерсең, аны юлга җыйнап-төйнәп ул чыгарып җибәргән. Андый чакта ямчы кая

---

Факил САФИН (1954)—*прозаик, шагыйрь, публицист. "Соңгы күз", "Тузганак чәчәге", "Гәлҗиһан" һ. б. китаплар авторы.*

*Романның беренче китабы журналның 2001 елгы 8-9 саннарында басылып чыккан иде.

керер тишек тапмый, үзен карасынмы, олауны кайгыртсынмы, әллә вәкилне катырып үтермәс өчен чара күрсенме—валлаһи, якты дөньяга бүген туган сабый шикелле көйләтмәкче үзләрен кайбер вәкил дигәннәре. Эшең ямчылык кылу булгач, берни эшләр хәл юк, һәммәсен дә кайгыртырга туры килә. Атына утырткансың икән, адәм баласын исән-имин тиешле урынга илтеп җиткерү өчен ул, ямчы җавап бирә бит. Кыюлык та, тәвәккәллек тә, осталык та кирәк әлеге эштә. Үткән дәвердә ямчы аты куганнар өчен какшамас канун булган әлеге хакыйкать бүген дә үзгәрмәгән, киләчәктә дә үзгәрергә тиеш түгел. Агай иркенрәк тын алды, бу егет, болай яшь күренсә дә, җитди кешегә охшаган, көйләтеп, юкка-барга чәпчеп җанны җәфаламас шикелле.

Кичә, кояш баер алдыннан, Чаллы кантуны каршына килеп туктап, ис җыярга өлгермәде, каршысында шушы егет пәйда булды. Минзәләдән үзен алырга килгән ямчы икәнен белгәч, елмаеп, ике куллап күрешә дә, төнне Чаллыда үткәрергә туры киләсен әйтеп, эш-мәшәкать дилбегәсен үз кулына алды: агайның атын-тунын кантун кәнүшниендә калдырып, үзен кунакханәгә урнаштырып мәш килде. Йокы бүсәргә һәвәс түгел икән, агай уянырга өлгермәде, егет иртүк агай артыннан килеп тә җитте, бергәләп чәйләп алдылар, аннан инде сәфәргә җыена башладылар: атны идарә каршына туктатып, чана башына китаптыр-мазардыр төяп азапландылар. Болай булса, чанада үзләренә урын да калмас, Минзәләгә кадәр алмашлап җәяү кайтырга туры килмәгәе дип курка да башлаган иде, бәхетенә, Казан кунагының йөге төялеп беттеме, әллә ямчының уйларын аңлап, төяү эшләрен үзе үк туктаттымы—җинелчә агач чемодан тотып, канткомның ярым түгәрәк ишегеннән үзе килеп чыкты, ямчы аты белән мәшәләнгән чакта, урын көйләштереп, чанага менеп тә утырды.

Юлга иртүк кузгалу ярый ул, кичкә, Ходай юлны уң кылсын, кайтып та керерләр өяз каласына. Ямчы, олыгаеп килүче агай, электән ишеткәләгәне булса да, һич кенә дә "кантун" дигән сүзгә күнегә алмый, ияләнгән "өяз" сүзе янына ничектер якын сыман тоела иде. Егерменче елны бугай, Татарстан җөмһүрияте төзелгәч, өяз сүзен кантунга алыштырдылар да куйдылар. Хәер, элекке өязне дә чәчкәләп, таратып бетерделәр. Мәскәү кушкан диделәр. Ул күп йөрде, күп күрде, күп ишетте, акны карадан әйбәт аера, әмма шунсын гына аңлап җиткермәде агай—хөррият алдык дип и шапырындылар, и кабарындылар заманында Минзәләдә яңа блачның хуҗалары булып алган Сәгыйдуллин кебек елгыр бәлшәвикләр. Үзебезнең дәүләтебез булды дип лаф ордылар, үзебезгә үзебез хуҗа дип тә җибәрәләр иде. Митинглар оештырып, башны күп әйләндерделәр инде. Шул бер "өяз" сүзен дә калдыра алмагач нинди хуҗа син илгә?.. Һә, бик хуҗа булырыең да, кулында көч—гаскәр юк бит синең, ие бит. Сәгыйдуллин кулында да юк иде, Байчурин да буш кул белән килеп, буш кул белән китте. Дөнья йөзендә гаскәре булмаган нинди дәүләт, нинди җөмһүрият бар ди?! Болай үзләре шәп егетләр иде болай. Тик тел белән тегермән тартып хөррият яулап булмый шул. Күп теленә салынсаң да килешми, Ижау ягыннан егерме мылтыклы солдат килсә, беттең диген инде, һавага бер гөрселдәтсәләр, минут эчендә дәүләтең дә юк, җөмһүриятең дә юк, телең дә кыскарып калыр... Шул мылтыклы егерме солдат блач була да куячак бөтен өязеңә. Мәскәүнең сүзе Минзәлә өчен дә, Казан өчен дә канун. Күп шыбырдый алмассың, иеме, вәкил иптәш? Кычкырып сорарга тел кычыта да, килешеп бетмәс шул, килешеп бетмәс. Кайтып кергәч ГПУ га җиткерсә... Ул ГПУ дигән нәмәрсә туры Мәскәүгә карый ди бит. Әле каршы әйтмәсәң дә... советка каршы элемент, дип, авылы-авылы белән төяп китерәләр халыкны Минзәлә төрмәсенә. Кайберәүләрен шунда ук чыгарып аталар да икән. Инна лиллаһи вә инна иләйһи ражигун... Бичараларның ни гаепләре булгандыр яна блач каршында. Юкса, үтә череп чыккан байлар Колчакка ияреп әллә кайчан бу яклардан эзләрен суыттылар. Хәер, бай кеше, акчалы кеше беркайчан, бер җирдә аптырамас ул. Ямчы агаең да чегән

арбасыннан төшеп калган дегет чиләге түгел, егеткәем, күрмәде түгел, күрде—бу дөньяда акыл алдан йөрми, акча алдыра, ул башлап сүз әйтә... Шулай да байлар белән сөйләшү, эш йөртү җинелрәк иде. Менә шулар хакында рәхәтләнеп гәпләшеп кайтасы иде дә. Юл кыскарыр иде ичмаса. Ярап бетмәс шул Казан вәкиленә ташыган уйларынны чыгарып түгү, килештермәс...

Атның бер җайга юыртуына ияләшкән Әхмәтсафа Дәүләтьяров исә үз уйлары белән мәшгуль. Әле ул Минзәләдә ниләр эшләргә тиешлеген чамалап та бетерми. Декабрь урталарында Татар коммунистик университетының соңгы курсында укучы студентларны җыеп алдылар да, үзләренен ел башыннан урыннарда һаман да ныгып житә алмаган совет хакимиятенә булышлык күрсәтү өчен егерме бишменчеләр сыйфатында кантоннарга китәчәкләре турында әйттеләр. Студентларнын бу эшкә теләге бармы, юкмы—анысын сорап торыш юк. Өлкә комитетының чәнчә бармак очы кайда төртеп күрсәтсә, коммунистның арты шунда барып чүмәшергә тиеш. Бәхәскә урын кала димени?.. Университетта белем эстәүче яшь балалы хатыннарга кадәр "ирекләләр" исемлегенә кертелгәннәр иде. Бер-ике хатын, әлеге карарга каршы төшмәкче булып, чәпчеп тә маташкан иде, кая ул, икенче көнне үк партия ячейкасы җыелышы җыеп, пешерделәр генә үзләрен. Теге хатыннар ник бала табуларына үкенә башладылар ахырда. Шулай булмый соң, илдә социализм тулысынча җиңми торып, ни йөзең белән имчәк баласын сылтау итеп гомумпартия эшеннән читтә калырга мөмкин булсын ди?!. Сөйләшү каты булды, теге тавыш күтәрергә батырчылык иткән бичәкәйләр социализм тулысынча җиңми торып, яңадан бала тапмаска ант иткәч тә әле тынычлана алмады ячейка җыелышындагылар. Тагын да нәрсәдер житеп бетми иде тулы ышаныч өчен. Коммунистик тәрбиянен алымнары үтемле шул анын. Балалар, башлыча, "ирекле мәхәббәттән" туган яшь совет гражданнары иделәр, каты сөйләшүдән соң "аң" кергән әниләре, артык авырыксынмыйча, һәрхәлдә фиркадашларына шулай тоелды, кантоннарга киткәндә нарасыйларын балалар йортына тапшырачаклары хакында язмача раслама бирделәр. Шуннан соң гына җыелыш җинел сулап куйды: гаять мөһим мәсьәлә иң дөрес чишелеш тапты тәки. Монын шулай икәненә имчәк баласы булган яшь совет гражданнарыннан башка һәммәсе дә аңлаганнар иде. Яшь гражданнарның аң керәсе еллары алда әле, аларның авылда барган күмәкләшү эшендә кайгылары юк.

Партия ячейкасы бюросы әгъзасы буларак, Әхмәтсафа әлеге эшләрнең уртасында кайнады, студентларны кантоннарга бүлгәндә Казан тирәсендә калырга жае бар иде—исемлекне үз куллары белән төзеде, әмма иң ерак кантонга—"Минзәләгә",—дип язып куйды Дәүләтьяров фамилиясе турысына. Ул мизгелдә күңелендә бер генә уй тулганып алды, укуны тәмамлап, диплом алырга ярты еллап вакыт калып бара, бераз гына сабыр итсәләр булыр иде югарыда утыручы түрәләргә, югары белемле һөнәрмән булып эшкә башлау кулайрак та булыр иде гамәли якны исәпләгәндә, әмма сәяси вәзгыять шуны таләп иткәч, нишлисен?..

## II

Сталин күзен кыса төшеп дача тәрәзәсеннән бакчага карап торды. Нәрсә тота аны тәрәзә каршында болай озаклап, һич кенә дә аңлый алмый. Югыйсә, сәркатип кертеп биргән почтаның әле чирегеп дә карап чыга алмады. Көн инде кичкә авыша башлаган, хәл итәргә тиешле көндәлек мәшәкатьләр хәттин ашкан.

Татарстаннан килгән телеграмманы укыгач, дәрте сүрелде анын. Беренче карашка, өлкә комитеты сәркәтибе Разумовның телеграммасына ул сөенергә генә тиеш иде—Разумов республиканың барлык кантоннарында да егермебишменчеләрнең ныклап эшкә керешүләрен хәбәр итеп, даһи юлбашчы Сталин дөрес һәм гадел күрсәткәнчә, быелгы язны Татарстанның

йөз процент кумәкләшкән хәлдә каршы алачагына катгый ышандыра. Телеграммадагы: "Сталинның, партиянең установкасын тулысынча үтәү—өлкә комитетының намус эше һәм бу мәсьәләдә беренче чигенү дә булмас!"—дигән сүзләрне нигәдер ошатмады ул. Соңгы вакытта аңа кумәкләштерү эшендәге бөгелешләр хакында да хәбәрләр килеп ирешә башлады. Сталин үзенә килеп ирешкән хәбәрләрнең никадәр нечкә иләктән иләнгәнен аңламаслык хәлдә түгел. Инде кумәкләшү урындагы надан, күрәкараучы җитәкчеләр аркасында гарип форма алган икән, нишләп бу эш Сталин исеме белән бәйләнә? Шул ук Татарстан партия оешмасы кылган гамәлләрнең барысы да ал да гөлме? Ә бит һәр эш юлбашчы исеменнән башкарыла: Сталин күрсәткәнчә, Сталин установкасы... Бер гөрәнкә унышлан да башлары әйләнгән бу наданнарның телен тешләтәсе иде... Тулысынча җиңү булгач кына дөреслек, гаделлек дип авыз чайкарга мөмкин булачак. Ниндидер хәстәрлек күрмичә ярамый, һәрнәрсәдә өлгерлек күрсәтү кирәк. Разумовның телеграммасы шундый зирәк фикергә китерде: тиз арада "Правда"га мәкалә хәзерләп бирергә кирәк. Исеме дә шәп: "Унышлардан баш әйләнү." Разумов та, башкалар да дөрес эш алып баралар: йөз процент кумәкләштерү мәҗбүри. Тик акцентларны үзгәртә төшеп...

Аның йөзендә сизелер-сизелмәс яктылык уйнап алды. Бакча түрендәге миләш агачы һаман кызыл җимешләре белән тулышып тора. Гадәттә, бу вакытта җимешләрдән җилләр искән була, игътибар иткәне бар—декабрь башларындагы дымык бер иртәдә каяндыр көтүе белән миләш чыпчыгы килеп чыга да, кып-кызыл җимеш сырып алган агачны минут эчендә "чишендереп" тә куялар. Сталин "төн кошы", иртәләрен йоклап үткәрә, ә менә нәкъ шушы көнне иртүк аяк өстендә була һәм иң сәерешушы әрсез, талымсыз кошлар өеренең бакчада минутлык вәйран чигүенә аерым ләззәтләнү белән карап тора. Ни өчен икәнен үзе дә аңлата алмый. Быел исә нигәдер соңладылар кошлар. Әллә исәпләре бөтенләй килмәскәме? Гыйнвар үтеп бара түгелме соң инде? Ул шулай уйлап бетермәде, миләш агачын кызыл түшле кош чиргә сырып та алды...

Аңа нигәдер җиңел булып китте. Юк, дөнья күчәренең әйләнешен үзгәртер көч юк җир йөзендә. Һәр пешкән җимеш өзеп алынырга тиеш, хәтта вакыт үтә төшсә дә. Җәмгыять үсешендә, иҗтимагый фикердә "кумәкләшү" дигән татлы җимеш күпләрнең күзен кыздыргандыр кыздыруын, әмма бу җимешнең өлгерүен көткән менләгән әрсез өер, йолкыш чиру барлыгын бер генә минутка да онытырга ярамый шул. Күз ачып йомганчы иләнне туздырып атачак бу өер. Ил белән үзенне дә. Тир түкмичә бәхеткә, муллыкка ирешү хыялыннан да мәгънәсез омтылыш юк. Менә шушы куркынычка юл куймаска кирәк, өерләрне ачыкларга, әйдәүчеләрен эзләп табарга һәм берәм-берәм мәйданнан алып атарга кирәк. Ерактан балкып торган миләш җимеше кебек—бар иде, мизгел эчендә юкка чыксын. Иң мөһиме шунда, моны беркем дә белми дә калсын. Аның үзеннән башка...

Разумовны Татарстанга җибәреп дөрес эшләде ул. Татарлар хәтәр халык. Акыллы, еракка карап эш йөртүчән, бер-берсенә юл куймый торган үзсүзле, үҗәт халык. Шушы сыйфатлары аркасында Милләт эшләре халык комиссариатын җитәкләгәндә аның канына аз тоз салмады бу кавем кешеләре. Күз алдына үз-үзләренә гаҗәеп ышанган Солтангалиев, Вахитов сурәте пәйда булды. Җанын туктаусыз нидер кимергән кыяфәттә йөрүче Ибраһимовның үртәгеч карашын янә тоеп, тәненә салкын йөгерде. Тагын бер егет истә калган—аңысы мөселман полклары төзим дип хыяллана иде. Тиктормас, революция идеаллары белән тәмам адарынган егет иде ул. Әмма ул чакта ук Сталин сизеп алды, егет шулай ук еракка карап эш йөртә иде бит—әгәр Ленин, ахмак Троцкий коткысына бирелеп, татарлардан гына торган мөселман гаскәрләре төзергә ирек бирсә, ни белән тәгәлләнер иде микән революция дигәннәре! Ярый әле бу хәлне вакытында туктатып кала алды Сталин, аның тарафыннан Ленинга тиешле сирәк

рәхмәтләрнен берсе дә шуның өчен иде: Усмановның, менә бит ничек, хәтта фамилиясе хәтердән китми нәләт егетнең, нинди ният белән йөрүен аңлатып биргәч, Ленин үзе дә урыныннан сикереп торып, зыр килеп бүлмәсен әйләнеп чыкты. Татарларга үз кулларын белән гаскәр төзеп бир, дәүләт бир. Аннан нәрсә?.. Шул сәгатьтә үк төзелә башлаган мөселман полкын фронтка җибәрүне таләп итеп Фрунзега телеграмма сукты һәм шуның белән идеягә нокта куелды. Әйе, татарлар белән тезген һәрчак кыска булырга тиеш. Ул чакта да шулай фикер йөртте Сталин, хәзер исә бигрәк тә. Көчле халык, рухи тамыры сәламәт сакланган халык. Сәләтлеләрне тарих мәйданына ыргытып кына тора. Чүпләп кенә өлгер–күзне, зиһенне алдап янып торган ачы җимешләрне.

...Егерменче еллар дәвамында Татарстан хөкүмәте җитәкчелеге Мәскәү басымына каршы кискен көрәш алып барды. Бу көрәш ни белән тәмамланыр иде, фараз итүе авыр, әмма Мәскәү өчен шунысы әһәмиятле иде–җитәкчеләрнең үзләре арасында да фикер каршылыгы чыга торды, төркемнәр барлыкка килде. Һәр төркем каршы якны фаш итеп, Мәскәүгә хат артыннан хат юллады. Сталин татарларның абруй алдында гына баш иеп, "и"гә килә торган халык икәнлеген аңлаган иде инде, Татарстанда барган фикер көрәше, үчегү-бәхәсләр, әгәр дә ки ул үз куллары белән Солтангалиевне юлдан алып ташламаса, булмас та иде, чөнки Мирсәет көчле шәхес, акыллы һәм зирәк, абруйлы җитәкче, татарлар ана һичшиксез буйсыначак, хәтта күзенә генә карап торырлар иде. Мона бәлки Сталинның артык исе дә китмәс иде. Совет властеның тәүге елларында милли республикалардагы тынычлык Мәскәү өчен үтә мөһим нәрсә иде. Әмма иң куркынычы да шунда–Солтангалиевнең күзенә карап торучы бер татарлар гына түгел шул... Милли сәясәт өлкәсендә илдәге төрки халыклар алдында Солтангалиевнен абруе шулкадәр үсте, хәтта берзаман Сталин үзен дә ул халыклар алдында Солтангалиевнең күләгәсе сыман гына хис итә башлады. Мона юл кую–дилбегәне кулдан ычкындыруга бәрабәр һәм ул, бар зиһенен җыеп, Мирсәеткә каршы җәтмә үрә башлады, җаен китереп, фирка исеме белән Солтангалиевне юлдан чөеп ыргытуга ирешә дә. Авыр булды Мирсәеткә каршы көрәшкә чыгу, әмма фирка, халыклар, ил алдында сәяси яктан гына түгел, хәтта җисмән яктан да үзенне саклап калуның башка юлын күрмәде ул. Сталин көрәшнең иң хәйләкәр әмәлләрен эзләп тапты, тозакның иң шәпләрен ташлады Солтангалиев юлына һәм тегесе, татарларга хас ышанучан зат, килеп капты да. Мирсәетне үз абруен үстерү өчен йөз процентка файдаландым дип исәпли ул, шуна эчтән генә сөенә. Татарстанга исә Белорусиядән сыналган большевик Мендель Маркович Хатаевичны җибәрде. Хәйләкәр яһүд эшкә авырыксынып керешсә дә татарларны тиз кулга алды, куандырганы шул–Солтангалиевкә каршы куя алды ул татар коммунистларын. Сталин ялгышмады, Хатаевичның абруе тәэсирле булды, өлкә комитетында тора-бара чагыштырмача тынычлык урнашты, милләтчелек учагы сүрелде. Үзәк комитетка яла, әләкләрнен Татарстаннан аз килә башлавы шуна ишарә идә. Татарлар сәер халык, берсе чак кына өскә үрмәли башласа, хәзер буза куптаралар. Теге бәхетсезне урыныннан тартып төшереп, тизәктә аунатмыйча тынычланмыйлар, монын өчен вакыт та, көч тә кызганмыйлар. Татарның иң яраткан эше–әләк язу. Мәскәү гомер гомергә бу халыкның тар күнелле булуыннан файдаланып эш йөртте. Итәк астыннан ут йөгертү өчен иң кулай мохит–татарның акыллы башлары арасында. Татарның булдыклы егетләре бер-берсен таптый, изә. Үзләре үк бумаклап үтергән улларын күз яшьләре белән юып ләхеткә индерә... Ахырдан югалган кавемдәшләрен кызганып нәгърәләр ора, аһ итә, чәчен йолкыйлар... Татарның акылы төштән соң. Сталин менә шундый халыкта асыл егетләр–зирәк сәясәтчеләр, икътисадчылар, язучы-каләм осталары үсеп чыга алуына чынлап аптырый иде. Ул үзе Татарстанда булып үткән һәр нәрсәне җентекләп күзәтеп

барды, кирәк тапса, кичекмәстән юнәлеш бирә килде.

1927 елны ноябрь аенда партиянең унөченче өлкә конференциясе "буржуаз милләтчеләргә һәм группаларга каршы көрәш" шигаре астында үтеп, әлегәчә милли хисләр йогынтысыннан арына алмаган татар зыяларын янә беркат туздырып атты. Күпчелегеен илдән үк сөрделәр. Рәхимсез кыландылар татарлар. Татар дөньясы умарта оясыдай гөжләп алды да, тынып калды. Сталинның күнеленә шик йөгерде. Шикне раслап, Казан ягыннан янә әләкләр ява башлады. Ныклап барлый башлагач, шул билгеле булды—революциягә кадәр җитлеккән татар зыялыларының зур күпчелеге исән-имин генә яшәп яталар икән. Куылганнар, туздырылганнар, таптал-ганнар, изелгәннәр, әмма исәннәр! Идел буенда, Уралда, Себердә, Урта Азиядә генә түгел, Мәскәү, Ленинградта да җитәрлек иде алар. Нинди яшәүчән халык!.. Шулар баш күтәреп, тирә-юньгә күз салганнар да, бераз өскә калка башлаган кавемдәшләрен батыру эшенә керешеп киләләр икән. Димәк, тамырлар исән, куркыныч үтмәгән, әле катылык, тәвәкәллек җитми... Сталин мондый мәсьәләдә башлаган эшне ярты юлда калдыра торганнардан түгел, хәйләкәррәк һәм сакланыбрак эш йөрткән Хатаевичны Самарага күчереп, аның урынына Казанга Михаил Осипович Разумовны җибәрде. Эшчеләр арасында чарланып өлгергән, дуамал холыклы, бераз кылтык та, әмма ВКП(б) үзәк комитеты алдында гаять абруйлы Разумовның, Сталин алдында йөзен җиргә бәрмәс өчен барысын да эшләргә хәзер икәнлегенә иманы камил иде юлбашчының.

## III

Вәзгыятьтән чыгып, дөресен әйтик, Хатаевичның Татарстанга килүенең файдасы булмады түгел—ызгышып ятудан туктап, киләчәк хакында уйлый башлау кирәк, татарлар өчен бирәү дә килеп эшләмәс, оҗмах төзеп бирмәс, дигән карашны җирле җитәкчеләргә яхшылап сеңдереп өлгерде ул. Татарлар торган саен яңа тормыш йөген ныграк тарталар, элекке кебек, юк кына эш өчен дә Мәскәүдән ярдәм сорап, шаулап, чаң сугып йөрмиләр, һәр нәрсәне урында хәл итәргә омтылалар. Иң мөһиме—үзара бугазлашып ятудан башканы белмәгән, күпчелеге революциядә, гражданнар сугышында катнашып, ат өстендә кылыч болгап йөргән чакта кылган каһарманлыклары һәм, шулар өстенә, кайбер оештыру сыйфатлары чагылып киткән өчен генә җитәкчелеккә үрмәләгән дистәләрчә надан коммунистлар урынына яңа чорда тәрбияләнгән, белемле кадрлар хәзерләү эше юлга салынды. Казан—югары уку йортларына кытлык кичерми, аларда татар студентларының саны сизелерлек артты, техникумнар, һөнәри-техник белем бирү мәктәпләре ачылды. Төрле өлкәләрдә сибелеп көн күргән өметле татар яшьләре Казанга тартыла башлады, хәзерлекле татарларны җитәкчелек эшенә яки тагын да алга табан белем эстәргә чакырып китерү колач җәйде.

Шушы әйбәт шаукымга Әхмәтсафа Дәүләтьяров та килеп эләкте, партиянең Хорезм өлкә комитетында җаваплы инструктор булып эшләгән егерме бер яшьлек егетне, үз гаризасы нигезендә, Казанга, Татар коммунистик университетына чакырып кайтардылар.

...Әхмәтсафа уйларыннан аерылып, йөзен чытып куйды. Көтмәгәндә, көйле генә барган уку өзелеп куйсын инде, ә?.. Пошмас җирдән пошар эчен...

Әмма партия карарын санга сукмаска хакы юк аның. Яшь кадрларны авылларга җибәреп, сыйнфый көрәш шартларында чыныктырып алу турындагы фикер яңа булмаса да, бөтен кискенлеге белән ВКП(б)ның унбишенче съездында көн тәртибенә килеп басканын яхшы белә ул, әлбәттә.

1927 елның декабрендә Мәскәүдә үткән бу съезд илнең крестьян

тормышын тамырдан үзгәртүгә нигез салды. Сьездда аерым хуҗалыкларны бетереп, кулакны сыйныф буларак юкка чыгару, авыл хуҗалыгын коллективлаштыру турында карарлар кабул ителде һәм шул карарларны үтәү йөзеннән авылларда нинди генә гамәлләр кылынмый да, нинди генә хикмәтләр эшләнми шушы ике ел эчендә. Әхмәтсафа ишетеп тора–бу гамәлләр арасында хилафлары да житәрлек иде. Ямчы агайның ара-тирә авыр сулап алуының сәбәбе нәкъ шушы сәяси хәлләр аркасында түгел микән? Ялыкты авыл туктаусыз куалау-ашыктырулардан. Бу хакта университетта Разумовский, Ишков кебек профессорлар да әйткән иде. Артык каударлану беркайчан да җүнлегә китерми китерүен дә. Разумов һаман риза түгел, эшне кызу тотарга куша, утызынчы елның язын авыл тоташ коллективлашкан хәлдә каршы алырга тиеш дип ашыктыра һәм һәр чыгышында моның партия, Сталин установкасы икәнлеген искәртеп, үзенең бу хакта юлбашчыга партия вәгъдәсе бирүен дә әйтеп, чигенергә юл юклыгын да сиздереп куя.

1929 елның көзендә ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты кантоннардагы партия һәм совет органнарының җитәкчеләрен җыйнап махсус киңәшмә үткәрде. Киңәшмә барышында ике сүзнең берендә урыннарда кадрлар мәсьәләсенең катлаулы булуы телгә алынды. ВКП(б) үзәк комитетының ноябрь пленумы карары нигезендә авылларга шәһәр эшчеләре, интеллигенция арасыннан "егермебишменче"ләр җибәрүнең мәҗбүриләнгән искә алып, утызынчы елның башында ук Татарстан авылларына дүрт йөзләп кеше җибәрергә тиеш дип табылды. Әхмәтсафаның шушы "егермебишменче" нең берсе сыйфатында Минзәләгә барышы да инде.

–Менә бусы Әҗмәкәй дигән авыл була инде...–диде ямчы агай, зур гына авылның урамына барып кергәч.

Әхмәтсафа, уйларыннан арынып, читәннәрен кар көртләре күмеп китә язган тар урамга күз ташлады. Ике атлы кара-каршы килсә ничек юл сабыша торгандыр, анысын олаучылар үзләре генә белә. Кар көрте аша да сизелеп тора: өйләр нинди дер шомлы хәл буласын көтеп торгандай куырылып, җиргә сенеп үк утыралар. Салам түбә, түбәне тишеп чыккан морҗа башларына төпсез балчык чүлмәк кигертелгән, морҗалардан сүрән генә аксыл төтен саркыла. Тешкә сылаша торган төче төтен. Яшереп торасы юк, җанга тансык ис анкый төтеннән. Әхмәтсафа туып-үскән моннан ерак-еракта гы Оренбур ягындагы Каргалы авылында да шундый ук ис тарала иде дөньяга–кизәк, салам яккан якларда шундый ис була.

–Авылда әле һаман тормыш көтүләре җинелдән түгел бугай...–диде көттереп кенә Әхмәтсафа.–Мин бу якларда беренче мәртәбә. Танышлыгым юк, шулай да чамаларга була. Үзем дә сала малае...

Ямчы рәнҗегән төсле, теш арасыннан берничә сүз сыгып чыгарды:

–Хәерче, алама инде безнең яклар, туган.–Аннан күнелдәгесен нигә яшереп торам соң әле дигәндәй, тавышын күтәрә төшеп, тезеп китте.–Яңа тормыш дигән булалар... Яңасы кайчан төзелер, белгән юк, әлегә булганын җимерү дә туздыру. Яшь чагында никрутлар: "Ват, җимер коймасын, юл өстендә тормасын" дип җырлыйлар иде. Яшь җилкенчәк ни җырламас, чынга алучы юк ие аларның сүзләрен. Ә бу хөкүмәт чынлап тотынды туздырырга, ни кыланганын аңлап бетереп булмый, туган.–Ямчы агайның буәсе ерылды, зарланыпмы зарлана.–Азап чигә халык, бә-әк интегеп җан асырый. Чистый, киямал йөрәккә төштеләр, һаман тынгылык юк халыкка...

–Кантунда ни хәлләр бар соң? Нигә тыныч түгел халык?

Ямчы, әллә айдан егылып төштеңме дигәндәй, сәер генә Әхмәтсафага карап алды. Чынлап сорый, ахрысы, чыраенда төчеләнеп маташу билгесе юк.

–Ни бит, туганкай, әйтсән–сүз, тортсән–күз дигәндәй, хөкүмәт иман тоткасы булган хәзрәтләргә юл бирми башлады. Халыкны диннән, иманнан яздырып нәрсә күрмәкчеләрдер... Инде зур хәзрәтләрне җыеп бетерделәр, хәзер мәчет картларына тотындылар. Халык бә-әк рәнҗи

моңа, апай.—Минзәлә ягында үзләреннән кече кешегә “апай” дип дәшкәннәрен ишеткәне бар иде Әхмәтсафаның. Ул көлемсерәп куйды. Әмма агайның сүзе житди нәрсә хакында бара иде.—Ә бит сәвит үзе урлашырга, таларга өйрәтә халыкны, шуңа юл куя. Мал-мөлкәтле бәндәләрне жыеп төрмәгә ябалар да куялар. Милке кая китә аларның? Совет тирәсенә елышкан жыен әтрәк-әләм йома малны. Хәзрәт үзе төрмәдә, гаиләсен өйдән куып чыгарып, ихатасына аркылыны торкылы салырга иренгән хөрәсәннәр кереп оялый аның тәзек йортына. Шул да булдымы дөреслек?

—Халык белән киңәшләшеп эшләнмимени болар? Партия бит башбаштаклыкка юл куймаска куша.

—Бер дә рәт чыгардай түгел синнән—китап сүзләре сөйләргә һәвәс икәнсең, туганкай. Нинди партия кайгысы булсын ул хәчтрүшләрдә, кулга гомердә күрмәгән мал килеп эләккәч соң... Халыкны кем искә ала хәзер? Элек тә искә алу юк ие анысы. Аңлап житкермисең, яшь шул әле син. Башыңа төшмәсен мондый бәла, балакай. Һай кылана хөкүмәт кыланчыклары, күрсәтә дә соң халыкка. Афәт ишелде өскә, афәт...—Ямчы кызып китте—Ленин бабай үлеп барганда, Сталин сорый икән: “Иптәш Ленин, инде жан тәслим кыласың, син үлгәч, илне ничек алып барыйк?“—дип әйткән, күз яшьләрен агызып. Ленин, авызын чалшайтып: “Аннан-моннан, ялган-молган...“—дигән дә, үлеп тә киткән. Менә шул Ленин кушканча алып бара да инде Сталин. Хәер-фатыйхасы шул булган. Шундый илдә угрылык булмыйча, нәрсә булсын, ачуым бер килмәгәе. Сталин үзе дә урлашып, келәт басып, төрмәләрдә яткан ди бит.

Агай чаманы онытып жибәрде.

—Саграк, абзый. Юлбашчыга тел тидерү ярамас,—диде Әхмәтсафа, тәмам кызып, бар куәтенә кычкырып сөйләнеп барган ямчыны тыярга теләп. Урамда кеше-фәлән күренми күренүен... Шулай да абзыйның бу кадәр ачыктан-ачык үзе төптән белмәгән, аңлап бетермәгән нәрсәләр хакында теленә ни килсә, шуны такылдап баруын өнәмәде. Ни әйтсәң дә, ул бит әле өлкәдән килгән вәкил, халыкны агартырга, урыннарда надан халыкка агымдагы хәлне фирка күзлегеннән чыгып аңлату өчен жибәрелгән кеше.

Ямчы көтелмәгән үжәтлек күрсәтте: Казаннан килүче мосафирдан шикләнмәскә мөмкин икәнлеген, аның кеше сатмаячагын абайлап өлгергән иде булса кирәк, үз туксаны туксан:

—Йөрәк яна шул,—диде ул ачынып.—Минем куркыр чаклар үткән инде. Уемдагы—телемдә. Баткан аяк чылана дигәндәй, ярты сүз әйтмәс борын авызны томаларга ашыкма, апай. Үзең халыктан сорарга дисең...—Әхмәтсафа чамалап алганча, агай һич тә надан бер сала мажигы түгел иде.—Минзәлә кантунына караган Иркәнәш дигән авылдан мин үзем. Узган атнада туганнарымны жыеп алдылар да, “кулак“ дип, төрмәгә китереп япканнар. Мине Алла саклады, олауда калдым. Авылга кайтырга да шикләндерә, кайтып керсәм, ни булыр тагын... Нинди кулак булыйк без? Һәркайсыбыз үз хужалыгында үз көче белән көн күрәбез, житеш тормышта яши идек. Шул гына... Имеш, күмхужга каршы без. Кем “күмхуж” дип йөри? Жыен суыгаяк, сәлкәү, ялкау. Алар кереп оялады сәвиткә. Без тир түгәргә тиеш, тегеләр ашарга. Ашамый торсыннар әле, иеме, бахбай...—Ямчы нәрсәдәндер өркеп, читкә каерырга маташкан атына дилбегә кагып алды.—На-а, малкай, үтеп барабыз Әжмәкәен дә...

—Бу авыл миңа таныш,—диде Әхмәтсафа, нидер исенә төшеп.

—Безнең якларда булганым юк, дисең үзең...

—Булганым юк, анысы хак сүз. Татарстанда гражданнар сугышы тарихын өйрәнгәндә укыган идем. Бу авыл тирәсендә зур сугышлар булган акларга каршы.

—Китапка язалардыр инде. Безгә анысы карангы,—диде ямчы теләмичә генә.

—Алда тагын нинди авыллар бар?

—Калмыя, Малтабар, Күзкәй, Югары Байлар...—дип тезеп китте

ямчы.

—Кызык исемнәр. Мин туып-үскән Оренбур ягында да авылларның исеме матур: Биккол, Нәүрүз, Йөзекәй, Мостафа, Сакмар... Һәр егерме-егерме биш чакрым саен татар авыллары. Тезеп чыккан кебек. Үзем—Каргалыдан,—дип, туган авылын янә бер мәртәбә искә аласы итте.

—Ишеткәнем бар. Ямчы авыллары. Яшь чагында күп йөрелде, сезнең якка да барып чыктым. Бохарасына кадәр барып життем. Кызыл мал ташыдым мин Фәттах байга. Якын тирәдә бер бай иде. Ул да юкка чыкты. Туздырды сәвит, туздырды тормышны.

Әхмәтсафа дәшмәде, "Бохара" сүзен ишеткәч, нигәдер ямансулап, үз уйларына йотылып бара бирде. Уйлары аны еракка-еракка алып киттеләр.

***

Революциядән соң сугыш китергән бәла-казадан, җимерекләрдән, буталыш һәм ачлыктан тәмам хәлсезләнгән халыкның исән калуда бердәнбер һәм соңгы өмете—Урта Азиягә барып урнашу иде. Ташкент, Бохара яклары телдән дә төшмәде ул чакта.. "Ташкент—икмәкле шәһәр!" Әлеге сүзләрне иң беренче кем әйткән, кайда әйткән, кайчан әйткән—анысын уйлап торыш юк, Ташкент каласы күпләрне ымсындыра, үзенә тарта иде. Агылды татар ул якка, агылды. Агыла торды, күбесе, комга сеңгән су сыман, хәбәрсез югала торды. "Ачы дәверне шәүкәтсез елларын шул якларда үткәрдем, заманага төс иңгәч, кире туган-үскән якларга кайттым әле," дип сөйләнгән кешене Әхмәтсафаның ишеткәне дә булмады диярлек. Күпмесе юлда кырылган киткән халыкның, күпмесе анда юкка чыккан, күпмесе исән калып, шунда гомер кичерә—кем санап баккан аны...

Алар гына җитмәгәндер, яна хөкүмәт тә аз тырышмады: партия куша дип, татарның аңлы, фәһемле яшьләрен куды Урта Азиягә. Әхмәтсафа шундый "бәхетле"ләрнең берсе иде. Әүвәл аның кебек йөзләгән яшьләрне Бохарага җыйдылар, аннан тиешле кәгазьләр, мандатлар, юлламалар тоттырып, төрле вилаятләргә җибәрә тордылар. Бөтен эш хәрбиләр кулында, һәрнәрсә хәрбиләрчә ярым-йорты, ашыгыч эшләнгәнгә, Әхмәтсафа Бохарада үткән ике-өч көн эчендә юньләп ни шәһәрне, ни мондагы тормышны карый-күзәтә дә алмады. Шунсы сәер—Урта Азиягә сәяси-хуҗалык эшләрендә ярдәм итәргә җибәрелгән яшьләр төркеме белән аралашкан түрәләрнең зур күпчелеге янә дә татарлар булып чыктылар. Җирле халыктан булган түрәләр исә юк дәрәҗәсендә аз иде. Әхмәтсафада шундый тойгы уянды—төрле яктан җыелган, белемнәре, тормыш тәҗрибәләре төрле булган шушы килмешәк кавем үз туган җирендә кайчандыр бөек мәмләкәтләр төзегән, дөньяга мәшһүр галимнәр бүләк иткән үзбәк халкына ожмах төзеп бирә алырмы?.. Үзбәкләр көчкә-коралга каршы торып-торып та баскынчылар чирүеннән котыла алмагач, барысына кул селтәп, ни майтарсагыз майтарыгыз инде, анда безнең эшебез, гамебез юк дигәндәй, читтән генә күзәтеп торалар сыман.

Бохарада юлламага мөһер, тамга җыеп, чабулап йөргәндә, көтмәгәндә Заһидәгә, ТИНО да укыган үткен-чая сабакташ кызга тап булды Әхмәтсафа. Мондый чакта күзгә ак-кара күренми, тар, ярым караңгы коридорда аң бер хатын-кыз заты нык кына бәрелеп үтте, әмма каршысына болай әрсез төстә килгән үтә арык, эсседә, җилдә янып кара чүтырга әйләнгән хатын-кыз затына күз дә салмаган иде. Ике-өч адым үткәч, үрсәләгән тавыш ишетеп, үзе дә өнсез калды:

—Әхмәтсафа?! Син түгелме соң, малайкаччаем?.. Әстәгем...

Әхмәтсафа шып туктап калды, артка әйләнеп карарга өлгермәде, кыз аның муенына килеп тә сарылды:

—Син бит бу Әхмәтсафа! Син... син...

Кайчандыр җаныннан артык күргән кешенең таныш чалымнарын

шәйләп алуга, Әхмәтсафаның тез буыннары йомшарып китте.

—Заһидә!.. Каян килеп чыктың?—диде ул, кипшенгән телен көч-хәл белән әйләндереп.

Кыз үз кыланмышыннан оялыпмы, егеттән читкәрәк тайпылды, балчык сылап шомарткан коридор стенасына сөялде һәм арыган тавыш белән:

—Таныдың тагын...—дип, мышкылдап елап җибәрде.

Шулкадәр газиз, тансык һәм кызганыч тоелды кыз. Егет чарасыз хәлдә, Заһидәнең җинелчә калтыранган иңсәсенә сак кына кагылып алды.

—Тынычлан, йә инде...—Үзенең дә тавышы калтыранып чыга иде.—Тау белән тау гына очрашмый диләр... Әле дә исемә килә алмыйм.—Кабат сорамыйча булдыра алмады.—Каян килеп чыктың син бу җәһәннәмгә?

—Оҗмах юллап инде, оҗмах эзләп...—диде Заһидә сулкылдавын басып.—Мин, ятимә кызга кайда булсын инде оҗмах...—диде ул, әрнеп.

Әхмәтсафа ТИНОда укыганда көн дә очрашып, аралашып яшәгән сабакташының тормыш хәлләрен бөтенләй белмәвенә аптырап, кайтарып сорады:

—Ятимә? Әти-әниең юк идеме синең?..

—Мин Ташкентка киткәч, ачлыктан, тифтән үлеп беткәннәр. Беркемем дә калмады минем.—Кызның тавышы еракта, тау-ташлар артыннан иңрәп чыккан сыман тоелды.

—Хәлләр шулай диген...—Әхмәтсафа көтелмәгән очрашудан кузгалган дулкынлануны, хисләр өермәсен басарга теләп, үзенең монда җәйге ял чорында эшләргә, үзбәк дусларга совет хакимияте төзүдә булышлык күрсәтергә җибәрелгәнен сөйләп алды.

Заһидә сүрән генә елмайды.

—Һи-и, җүләркәем, ике-өч ай каникул чорында ни кырмакчы буласың? Монда килгән һәркем шулай инде. Башта, ике айга дип җибәрәләр, аннан өч-дүрт айга калырга кыстый башлыйлар. Шулай йөри торгач, айлар, еллар үткәне дә сизелми кала. Син дә ике-өч елсыз ис-акыл җыя алмассың, үтә дә китә ул вакыт дигәнең.

Сораша торгач, егет Заһидә хакында шактый күп нәрсә белеп өлгерде. Ташкентта медсестралар хәзерли торган курсларны тәмамлап, Бохара янындагы бер вилаяттә эшләгән икән. Инде ике ел, ди.

—Мондагы халыкны күрсәң, Әхмәтсафа,—диде ул, бик зур яналык әйткәндәй тавышын әкренәйтеп.—Ничек үлеп бетмиләр алар, ике ел араларында яшәп, тәки аңлый алмадым. Дөньясын бет баскан. Корчаңгы, бизгәк, трахома—бу нәмәкәйләргә шулкадәр ияләшеп беткәннәр, аларны авыру дип тә белмиләр. Туктаусыз бала табалар, исәбен-санын алучы юк, туа торалар, үлә баралар, бала җанын чебен урынына да күрмиләр. "Ходай бирде, Ходай алды" дип, бит сыпырып куялар да, вәссәләм. Исән калганы үсә инде. Алары—таш та тимер. Салкын да алмый, кызу да сукмый. Кислотага ташласаң, аннан да исән-сау чыгарлар. Вәт халык дисәң дә халык!

—Табигый сайланыш хикмәте,—диде Әхмәтсафа, көлемсерәп.

—Нинди сайланыштыр, чуртым белсен,—диде Заһидә битараф тавыш белән. Хәзер инде аның килеш-килбәте ТИНОда укыган чактагыга охшап калды. Шушы ярым караңгы коридорда кызны танымыйча үтә алырына Әхмәтсафа ышанмас та иде хәтта.

—Син кая билгеләнден?—дип сорады Заһидә, күзләрен зур итеп ачып.—Башың ике булмаса, ычкын, кач син. Ни калган монда, әнә үзбәкләр үзләре төзесен үзләренә кирәк тормышны. Мин—гарык, җитәр, Казанга китәргә йөрим менә...—диде көтелмәгән ныклык белән. Бу инде Заһидә, холкы бер генә мыскал да үзгәрмәгән Заһидә иде.

—Казанга? Ничек?..—Егет тәмам аптырашта калган иде.—Мин Үргәнечкә китәм. Шунда билгеләндем...

—Иртәрәк килмәден бит,—дип, көлеп куйды Заһидә. Егетнең шулай

үрсәләнеп алуы аңа охшап китте бугай.—Бергә-бергә күнеллерәк тә булыр иде. Әйтәм бит, монда килеп эләккәч, син теләгәнчә, ансат кына китү юк ул, егетем. Өермәгә килеп капкан кебек инде син. Тиз генә ычкына алмыйсың... Мине дә өч кенә айга, практикага дип җибәргәннәр иде. Курсларда аз-маз укытып, укол кадарга, җәрәхәт бәйләргә өйрәттеләр дә, әнә бара торган юлын диделәр. Нинди генә авыруларны дәваларга туры килмәде. Хирург та үзем, терапевт та, акушер да, балалар табибы да булырга туры килде вакыты белән.—Әхмәтсафа ул санап киткән нәрсәләрдән, дөресен әйткәндә, бернәрсә дә аңышмады. Аңа калса, ак халат киеп, хастаханәдә йөргән һәркем табиб. Заһидә мактанып та алды.—Яшерен-батырын түгел, үкенмим,—диде бераз һавалы тавыш белән.—Мәскәүдән, тагын әллә кайлардан килгән зур табиплар кул астында да эшләдем. Алар биргән белемне мина бер институтта бирә алмас иде. Барысын да җибәрәләр инде Урта Азиягә, барысының да ярдәм итәсе килә мондагы халыкка, һәммәсе бу халыкны агартырга тырыша. Үзбәкләрнең генә исләре дә китми. Ничек яшәгән, шулай яшиләр. Алар үзләре безне кара халыкка, аңгыра ишәккә чутлыйлар әле. Егылып үләрсең, үзләренең ике каш арасында бетләр чабышып йөри, урамнан үткәндә безне мыскыл итеп, теләсә нәмә кычкырып калалар. Шундый монда хәлләр...

Бая Әхмәтсафа әйткән сүзләр исенә килеп, егеткә акыл бирергә тотынды.

—Үргәнече дә шул, башкасы да шул. Сак йөр, теләсә кая илтеп тыкма башыңны. Кышлакларда халык бик әйбәт күренә болай, тик белер-белмәс көе араларына кереп, теленә ни килсә, шуны сөйли башласаң, хәзер тукмап ташларлар. Алай гына булса... Ленинны яраталар, "безнең кебек диһкан булган," дип кенә җибәрәләр. Башкаларын белмиләр дә, беләселәре дә килми. Басмачылар, фәлән-фәсмәтән дип авызыңны да ачма. Алар өчен басмачылар—без, ягъни совет хакимиятенә эшләүче теләсә каян җыелган халык.—Заһидә үгет-нәсихәтем күпкә китте диптер инде, шаяра төшеп, Әхмәтсафаның җиңеннән тартып куйды,—Сүз бозау имезә. Мина поездга өлгерергә кирәк. Әйберләрем иптәш кызымда... Аларны алам да поездга йөгерәм,—дип, хушлаша башлады.

Әхмәтсафа, баштагы соравына җавап ишетмәгәч, янә сүз кузгатты:

—Казанга дисең... Уйлап сөйлисеңме, уйнапмы? Кем көтеп тора сине анда?

Заһидә ачылып китте.

—Ә-ә...—диде сузып кына,—әйтмәдеммени соң әле. Рабфакка укырга керергә гариза язып җибәргән идем. Чакыру килде. Укырга дисәң, монда бик карыша алмыйлар. Әйтәм бит, ярты ел җибәрүләрен сорап йөрдем. Һич кенә хәлгә кермиләр, баш катырып тик йөрттеләр шунда. Үзем дә бирешмәдем тагын. Әткәй, мәрхүм, әйтә торгание, син, кызым, лэтчә белән бер, дип. Лэтчәсе нәрсәдер, күргәнем юк, тычкан тота торган бер җәнлек бугай шунда.—Заһидә сер әйткәндәй, янә тавышын басты.—Мин бит Гайшә белән хат алышып тордым. Оренбурдагы хәлләрнең барысын-барысын да беләм.—Күзләрен елтыратып, бертын Әхмәтсафага карап торды.—Синең дә, егеткәем, кызың бар икә-ән инде. Ниһаять, үзеңә тиңне тапкансың... Рабига исемле, бик матур, итагатьле кыз, дип язды Гайшә. Гайшә кадәр Гайшәгә дә охшагач, безнең ише генә түгел инде..—Йөзенә уфтану билгеләре сибелде.—Минем булмады инде тиңем, табалмадым,—диде ул кулын селтәп.—Кем кирәктер мина, нәрсәгә ашкынамдыр—үзем дә белмим. Тиңеңне табу—бәхет бит ул, Әхмәтсафа. Меңнәр арасыннан үз тиңеңне сайлап алу җиңел түгел шул. Хисләр акылны томалый да куя, каһәр. Оренбурны искә төшереп, елап чыккан төннәрем аз булмады. Үткәннәрне кире кайтарып булса икән...

Әхмәтсафа кызарганын тойды, маңгаена тир бәреп чыкты шикелле, ирексездән, битен кул аркасы белән сөртеп, сөйләнеп алды:

—Әле кая сиңа болай сөйләшергә. Япь-яшь башың белән, дим...

Егетләрең күләгәдәй тагылып йөри торгандыр артыннан.

—Синнән башка бер күләгәм булмады,—дип ярып салды Зәһидә. Шулай ачыктан-ачык әйтүенә бераз кыенсынып, тотлыгып куйды.—Син... син... әй, барып чыкмады инде,—диде ул, янә кулы белән җилләнеп.—Язмагандыр, әйеме, Әхмәтсафа, малайкаччаем...—Ул сөйләшүне һаман да шаярту рәвешендә алып бармакчы иде дә, үзе дә сизми калды, күзләреннән яшь атылып чыкты.

—Такташ...—дип, уйламастан, кызның йөрәк ярасына тоз салды Әхмәтсафа.

—Такташын әйтерием...—диде ачу белән Зәһидә.—Тотарсың аның койрыгын. Ә шулай да мин аны Ташкентта эзләп таптым,—дип җанланып китте кыз. Зәһидәнең күзләрендә очкын уйнап алуын шәйләп алды егет. Шулай сәер янып-елтырап торган күзләрне беренче мәртәбә күрүе иде егетнең, бер мәлгә мәзәксенеп куйды. Зәһидә исә, поездга ашыгуын да онытып, такылдый бирә.—Яшьләр клубында чыгыш ясый дип ишеткәч, соңгы акчама чәчәкләр сатып алдым да, очтым шунда. Такташның сәхнәгә чыгып басуы булды, атылып мендем дә бирдем бер кочак чәчәкне. Үзем каушый-каушый пышылдаган булам: “Мин—Зәһидә... Оренбург... ТИНО...”—дим. Тезәм инде шунда, болгатам. Сәхнәдән куып төшергәнче дип ашыгу. Шунда, Әхмәтсафакаем, ышансаң ышан, ышанмасаң юк—бөтен залга кычкырып әйтте Такташ: “Таныйм, мин сине кызый, исемдә...—ди, җанкисәкәем. Менә бу шиырьне синең өчен укыйм,—дип, “Пәри кызы“ дигән шигырен укыды. Теге чакта ТИНО сәхнәсендә Гөлсемгә укыган шигырьне... Мин, бу якты дөньяда иң бәхетсез кеше, Такташның үземә багышлап шигырь укыган мәлдә нинди бәхет диңгезендә йөзгәнемне белсәң... Мәңге онытасым юк. Чума-чума йөздем, чумырып-чумырып эчтем бәхетне шул чакта. Шулкадәрле яшисем килде дөньяда, шулкадәрле көч алдым, кичәдән соң өч көн ач йөрдем, акча юк, таныш-белешләр дә юк җүнле-башлы. Курсларга килеп эләгеп кенә ач үлемнән котылып калдым. Үзем ач йөрим, үзем көлеп-елмаеп туймыйм. Мәхәббәттән исерү дигәннәре хак икән. Бәхет шулай була икән ул, Әхмәтсафа...

Егет, исе китеп, Зәһидәнең якты хатирәләрен тыңлап тора иде. Зәһидә бер мәл шулай күктә йөзеп алды да, шапылдап җиргә төште. Бераз кыланчыкланып, тавышына ясалма кырыслык чаткылары өстәп:

—Рабиганны шундый бәхет диңгезендә йөздер, егет булсаң—диде.—Хәер, сине күргән саен үзен бәхетле тоя торгандыр ул кызый. Минем кебек күктәге торнага ышанып, кулдагы чыпчыкны ычкындырган тилемиле түгел инде ул алайса... Үзең чибәр, үзең акыллы. Монда да ни житте кешеләрне җибәрмиләр, өмет бар синдә, сиңа ышаналар, егеткәем,—дип, Әхмәтсафаны кысып кочаклап алды. Кызның тыгыз күкрәкләрен тоюдан егетнең тәннәре чымырдап куйды, сизмәстән, арткарак тайпылды Кыз аны кочагыннан ычкындыру турында уйламый да иде, көлеп сөйләнүен дәвам итте.—Йә инде, оялма! Беркем дә күрмәде кочаклавымны...—Аннан кулларын җибәреп, яшьле күзләрен Әхмәтсафага текәде:

—Хуш, сабакташ, исән-имин бул, сак йөре,—дип, җавап та көтмәстән, йөгерә-атлый китеп барды.

Бу очрашу төштәгедәй тоелса да, Зәһидәнең әйткәннәре артыгы белән расланды. Ике-өч айга дип килгән Әхмәтсафа Урта Азиядә ике елдан артык гомер кичерде. Зәһидәнең киңәшләре дә ярап куйды тагын. Ул аларны һәрчак истә тотты.

* * *

Үргәнеч аны салкын йөз белән каршы алды. Язның соңгы ае, ихата саен бакча, агачларның шау чәчәктә чагы артта калган, алар җимешләнеп килаләр иде. Ул шәһәргә килеп төшкән көнне ком бураны котырды. Зәһидәнең: “Өермәгә килеп эләксәң...” —дигән сүзләрен каткат исенә алды ул.

Партиянең өяз комитетында да аны төксе кыяфәт белән каршы алдылар. Табигатьнең кешегә тәэсир итүеме бу—һәркайда чытык йөзле, үтә житди кешеләр генә очрады беренче мәлдә. Заһидә дөрес әйткән, килсәң сөенүче юк, китсәң елап калучы булмаячак.

Иң тәүдә кадрлар бүлеге башлыгы Ниязов хозурына керде ул. Тулы гәүдәле, кара тут йөзле бүлек мөдире вәкарь кыяфәт белән жентекләп Әхмәтсафага Оренбург губкомыннан, Бохарадан биргән язуларны караштырды, ашыкмыйча гына тәмәке төтәтеп алган булды. Тәмәке суырган арада күзләрен кысып, сынап-сынап каршысында утырган егеткә карап ала, төтенне исә нигәдер аска иелә төшеп, юан ботлары арасыннан коңгырт япмалы өстәл астына өрә. Табигый ки, төтен өстәл астына сыеша алмый, өскә бәреп чыга; өстәл, Ниязов үзе дүрт яклап күксел төтен камалышында калган сыман. Күрешкәндә үк бүлек мөдире үзен: "уртак Ниязов" дип таныштырган иде. Уртак—үзбәкчә иптәш дигән сүз икән, Бохарада ишеткән иде инде—совет-фирка хезмәтендәгеләргә "юлдаш" дип тә эндәшәләр, казахчалап "жолдас" диючеләр дә бар. Үзбәкстан күп шивәле, күп милләтле ил булып чыкты. Төшенеп өлгерде Әхмәтсафа—шушы Үргәнечтә генә дә үзбәк, казах, төрекмән, каракалпаклар яши. Кая барып чыксаң да татарны очратасың, аларны жирле халык нугай дип йөртә, тажиклар да аз түгел.

—Тагын бер нугай баласын эшкә өйрәтәсе икән...—дип сузды Ниязов, егетнең кәгазьләрен әйләндерүдән әллә арып, әллә туеп туктагач. Кесәсеннән бер бәйләм ачкыч чыгарып, ян якта боегып утырган сейфны шалтыр-шолтыр китереп ачып жибәрде, өстә яткан калын гына кенәгәне тартып чыгарды һәм һәр сүзенә бик зур мәгънә салгандай, күзен кыса төшеп, авыз эченнән сөйләнгәндәй, ләкин егеткә ачык ишетелерлек итеп берничә кәлимә сүз ыргытты.—Монда сезнең якташлар аз имәс, анча-күп булдылар алар. Менә бу кенәгәгә һәркайсы теркәлеп куелган, иренмичә актарып чыксаң, кемнәр генә килеп, кемнәр генә китмәгән... Кем килеп чыкса да кадрлар бүлеге аша үтә. Эшкә өйрәтеп кенә өлгер,—дип көрсенеп алган булды. Ниязов авыр сулап, кемнәндер, нәрсәдәндер чирканган кыяфәт белән йөзен чыта төшеп, телефон трубкасына үрелде, кемгәдер Әхмәтсафа Дәүләтъяров исемле нугайның үзләренә эшкә жибәрелүен озаклап, тәфсилләп аңлатып маташты, аны нindirәк эшкә тыгарга, нindirәк урындыкка утырту хакында киңәште. Шушы сөйләшүдән соң да байтак вакыт тагын ниндидер кәгазьләр актаргалап утырды. Бүлек мөдиренең акрын кыймылдавының сәбәбе—аның шактый тулы гәүдәсе, юан корсагы иде, ахры. Болай карап кына Ниязовның нинди милләттән икәнлеген аерып әйтү кыен булса да, үз-үзенең дәрәжәсен белүеннән аның шушы якларда туып үскән, яки инде монда озак еллар яшәгән, мондагы хәл-әхвәлләрне биш бармагы сыман белүче кеше икәнлеге хакында сөйли иде. Тагын шунысына игътибар итте Әхмәтсафа: Ниязов үзбәкчә сүзләрнең кайберсен татарчалап та кабатлап куя, әйткән сүзләре егеткә аңлаешлы булсын өчен тырышкан кебек.

Ниязов янә телефонга үрелде, трубканы колагына куеп, кемгә, ни дип шылтыратырга тиешлеген онытып, жәфаланып утырган эшем ияседәй күзләрен кысып бер тын түшәмгә текәп торды, янә авыр сулап өстәл астына бүрек кадәрле аксыл төтен бөркеде, аннан салкын гына:

—Фиркалымы?—дип сорады.

Сорау урынсыз иде, егетнең юлламасына барысын да ачык итеп язып куйганнар иде. Шулай да Әхмәтсафа сорауга тыныч кына жавап кайтарды:

—Кандидат... Егерме дүртенче елның октябреннән,—диде. Шушы минутларда алдагы язмышы хәл ителгәнен тоеп, тынын кыса төште.

—Массалар арасында эшләгәнең бармы?—Әхмәтсафаның аптырабрак калуын күргәч, Ниязов сүзләренә ачыклык кертәсе итте.—Михнәткә—хезмәт иясенә, кәмбәгал—ярлы халыкка, диһкан—игенчегә сәяси мәсьәләләр хакында аңлата алырсыңмы? Ил, мәркәз, өяздәге хәлләр белән

таныштыруны йөкләсәк тарта алырсынмы?—Сорауны бирде дә, җавап та көтмәстән, әйтеп салды.—Сине агитация-пропаганда бүлегенә билгелибез. Әлегә вазифаң—агымдагы вәзгыятькә карап, аерым йомышларны үтәү булыр, атап әйткәндә, инструктор йөген тартырсын. Үзенне сәяси яктан ышанычлы, белемле, тырыш-уҗәт итеп күрсәтә алсаң, күтәрербез. Бездә нугайлар эш башына тиз менеп утыралар,—дип тә өстәде. Ниязов, иң ахырдан, дустанә елмаеп, Әхмәтсафага кулын сузды.—Мин дә Оренбур якларыннан. Ярым казах, ярым нугай булам. Ата-ананы, туган җирне, якташларны сайлап алмыйлар, ничек бар—шулай инде,—дип, Әхмәтсафага бик үк аңлашылып җитмәгән фәлсәфә дә куертып алды.

Әхмәтсафа кебек "берничә айга" дип кенә җибәрелүче егет-кызлар өяздә унлап җыелды. Башта аларга элекке хәрби казармалардан—тулай торактан урын-җир бирделәр, аннан атна-ун көн нык кына эшкә өйрәттеләр. Шәһәр эчендә корал белән йөрү мәҗбүри түгел, әмма кышлакларга чыкканда коралны алу лазем икән. Инкыйлаптан соң совет хакимияте өчен Үргәнеч, Хива якларында хәлләр артык кискен булмаса да (1920 нче елда, төбәккә кызыл гаскәрләр килеп җитүгә үк Хивада милли ихтилалчылар тарафыннан ханлыкны бәреп төшереп, советлар төзелә. Үргәнечтә—Хивадан утыз биш-кырык чакрымдагы шәһәрдә дә совет хакимияте җирле ихтилалчылар ярдәмендә урнаштырылган), монда бик үк тыныч та дип әйтеп булмый. Шуларны истә тотып булса кирәк, хакимияткә эшкә җибәрелгән яшьләрне берничә көн корал тотарга, атта йөрергә, җирле халыкның гореф-гадәтләренә өйрәттеләр. Өйрәтүчеләр кызыл гаскәриләр иде, алар кат-кат искә төшереп тордылар: хәрби хәзерлек мәсьәләсенә игътибар итмәү аркасында, беренче нәүбәттә, яна килгән совет хезмәткәрләре күп кенә фаҗигале хәлләргә юлыкканнар. Алар да менә Әхмәтсафа, аның иптәшләре кебек, игелекле ният белән—җирле халыкны яңа, матур тормышка чыгарабыз дип җилкенеп килгән булганнар, тик үзбәкләр тарафыннан аларны "ләббәйкә" дип кабул итүче генә булмаган... "Ярдәм" итү нияте белән килүчеләрнең шактые ком чүлләрендә юкка чыккан. Нинди җил, өермә, сил йоткан аларны?.. Кем дә белми—чүлнең хәтере мәңгелек булса да, аның теле юк, ул эндәшми...

Урта Азиядә сәяси хәл чагыштырмача тотрыклана төшкәч, узган ел гына Олы Төрекстанны кисәкләргә таркатырга керешкәннәр—ул Үзбәкстан, Төрекмәнстан, Таджикстан кебек республикаларга бүлгәләнгән. Галәмәт зур мәйданнарны биләгән өлкә идарә итү өчен җыйнакланган. Хәзер инде урындагы хакимиятне белемле кадрлар белән тәэмин итү, халыкның хакимияткә ышанычын арттыру, халык белән хезмәттәшлекне ныгыту бурычы тора. Әхмәтсафа шушы эшләрнең үзәгендә кайнарга тиеш иде.

Үргәнеч үзе борынгы шәһәр, ике өлештән—Яңа кала һәм Иске каладан тора. Иске каладан дистә чакрымлап читтәрәк борынгы ханлык истәлеге—төрбәләр, мәчет, башка элгәрге корылмаларның җимерелгән калдыклары, анда халык изге урынга йөргән кебек табынырга йөри, Яңа калада исә көндәлек тормыш ыгы-зыгысы. Халыкның ни-нәрсә белән мәшгуль булуын әйтеп бетереп булмый. Шәһәрдә мамык чистарту, мамык мае эшләп чыгара торган заводлар бар, сабын кайнаталар (хәзерге чисталык фронтында бу иң әһәмиятле участок дип аңлаттылар), тегү фабрикасы эшли. Борынгылык һәркайда күзгә чалына. Урамнар—тар, тыкрык-кучәләр шактый биек һәм шыксыз, әллә балчык, әллә ком-таштан өелгән дуван-коймалар белән әйләндереп алынган, алар эчендә нинди хәлләр бар—анысын бер Ходай гына белә. Һәр мәхәлләнең үз чалымы, үз тормышы. Базарлар, НЭП сәясәте нәтиҗәседер инде, тернәкләнеп килә, монысы да яңа хакимиятнең олы казанышы сыйфатында телгә алына. Базарсыз халык—беткән халык, базар бар, димәк, халык яши. Соңгы чорда халыкка җәдитче-ихтилалчыларның йогынтысы зур булуын да искәрттеләр.

Җәдитчеләрнең ныклап сәяси мәйданга килүе Бохара белән бәйле. "Яшь бохарачылар" күп михнәтләр чигеп, Бохара әмиренә каршы көрәш

җәелдергәннәр, кызыл гаскәрләр—татар-мөселман бригадалары булышлыгы белән, әлбәттә, әмирне куып, хакимиятне кулга алганнар. Аннан Рәсәй белән каршылыкка кереп, инглиз, башка чиктәш мөселман дәүләтләре белән элемтәдә, бер сүздә булып, хакимлеккә советларны уткәрмәү нияте белән, тагын көрәшкә күтәрелгәннәр. Аяусыз көрәш була бу. Куйбышев, Фрунзе, Кәрим Хәкимов кебек большевистик рухлы рәхимсез коммунистлар кулы белән җәдитчеләр җинелә, Совет хакимияте ныгып кала. Бу көрәшләр Хива, Үргәнечне читләтеп үтмәсәләр дә, төп вакыйгалар Бохараның үзендә, кышлак-вилаятләрдә булганлыктан, монда хәл шактый тотрыклы дип исәпләнелә, Әхмәтсафа шикелле бу төбәккә яңа килеп, эшкә керешүчеләр, уяулыкны югалту аркасында, еш кына четерекле хәлләргә дә тарыйлар иде. Татар-нугайларга, (алар монда шактый күп санлы булып чыктылар), совет хакимияте урнаштырган чакта күрсәткән рәхимсезлекләре нисбәтле, җирле халыкның карашы, тышка бәреп чыкмаса да, эчкә яшеренгән үчлекле караш иде. Нугайга урыска сатылган, муенына тавык тәпие аскан нәмәкәй дип карау нык сизелә, туры килсә үчне тышка чыгарудан да тайчанып тормый үзбәк халкы. Шуларны исәпкә алып, алны-артны чамалап йөрергә туры киләчәк иде.

Җирле халык белән аралашып, аларның уй-гамәлләрен өйрәнеп бетергәнче өч ай да үтеп китте. Инде көзгә керергә җыена табигать, җәйге каникул үтеп бара, Әхмәтсафа, документларын алып, кире Оренбурга, укуын дәвам итәргә кайтып китәргә дип килсә... егетнең гозерен тыңлап утырган Ниязовның керфеге дә селкенми. Ул янә өстәл астына төтен өреп, өзек-төтек рәвештә, хәзерге вәзгыять хакында сафсата куерта башлады.

—Һәй нугай баласы,—диде ул, үз итеп елмайган булып, әмма бу елмаю күбрәк мәсхәрәле, егетнең теләге белән бөтенләй санлашмый торган елмаю иде.—Киләп-сарып йөрдем дә хәзер кайтып китәм дисеңме? Чынлапмы бу?.. Оялмыйча, бармак башы кадәр эш күрсәтми, кайтып китмәкче буласыңмы? Уйла, егет! Без сиңа өч ай дәвамында хезмәт хакы-айлык түләп тордык, ашханәдә тамак туклыгы иттердек, әнә чыраең бак—тазарып, матураеп, йомрыланып киттең, күз тимәсен... Корал тотарга өйрәттек, атка атланып кайларга гына йөрмәдең.—Әхматсафаның нидер әйтергә теләвен сизеп, кулын күтәреп, егетнең дәшми торуын үтенгән хәрәкәт ясады.—Беләм, беләм, нугай баласы, әйбәт эшләвеңне дә беләм, кайда барсаң да кәмбәгалга гүзәл гәптәш булдың, массаларга сәясәтне дөрес ирештердең, телгә алырлык хаталарың булмады, абруең бар өяз комитетында. Синең кебек кадрларны югалту кыен. Сине Хивага, округ комитетына сорап запрос килде. Яшермим, тартышып карадым, ләкин фиркага, мәркәзгә мин каршы килә алмыйм. Документларың Хивада, анда кирәк син, сине анда көтәләр юлдашлар.—Ниязов урыныннан кузгалып, егет янына килде, итләч кулын егетнең сөякчел инсәсенә салып, үгетләп-юмалап сүзен дәвам итте.—Укуың бүгенге вәзгыять өчен житеп ашкан, Дәүләтьяров. Ничек диләр әле, укып мулла булмассың, чукып карга булмассың, диләрме? Нугайлар төртмә телле халык, ничек әйтергә беләләр, һех-һех.—Ниязов көчәнеп көлеп алды.—Син дә ташлап кит, башкалар да китсен, монда яңа тормышны кем төзер? Валлаһи, чүлдә янтак-үлән эзләп таралган куй сыман, таю ягын гына карый хәзерге яшьләр. Булачак көрәшчеләр, имеш... Кем монда хакимиятне ныгытыр? Үзбәк халкы советны кайчан үз итәр, кайчан аңа йөз белән борылыр? Уйлап караганың бармы?

Әхмәтсафа эндәшмәде. Ниязовның үгетләве кирәк түгел аңа, төбәктәге халыкның совет хөкүмәтенә карашын яхшы белә. Монда аңа да, башкаларга да эш житәрлек. Ул өч ай түгел, өч ел эшләргә дә риза. Тик... аны Оренбурда Рабигасы көтә. Ул бит өч айдан кайтам дип, сүз биреп китте. Вәгъдә—иман... Кызый әлеге сөйләшүне ишетсә, ни дияр иде икән? Ни хәл итәргә?

Ниязов исә үзенекен тукый:

—Документларынны карап чыктым. Кандидатлык вакытың үтеп бара. Фиркага Хивада, округ комитетында керсәң, һич тә зыян итмәс. Әле синең яшисе бар, совет хезмәтендә чарлана-чарлана үсәсең бар. Чын совет хезмәткәре булып житешеп кенә килгәндә, "каникул бетте" дип, тот та китеп бар. Акылга сыймый. Фирка эшендә каникул юк, егет! Башланган эш—беткән эш, иелгән башны кылыч кисми, карышма, кал әле Хивада. Үзең үк рәхмәт әйтерсең. Бераз вакыт үтсен. Акча ягың да рәтләнер, өстең бөтәер. Егет кешегә кирәк ул. Ниязов юк-бар сүз такылдап утыручы түгел, минем сүзләр әле исеңә төшәр!..—дип, бүлек мөдире өстәл өстеннән алдан ук әзерләп куйган юлламаны алып, Әхмәтсафага сузды.

Икенче көнне Әхмәтсафа Хивага килеп төште...

* * *

—Аңлыйм, аңлыйм,—диде округ партия комитетының оештыру бүлеге мөдире Рәҗәпов каршысында утырган Әхмәтсафаның һичшиксез Оренбурга кайтып, укуын тәмамларга кирәклеге хакында кайнарланып сөйләвен тыңлаганнан соң.—Миннән генә торса, ике куллап җибәрер идем, иптәш Дәүләтъяров. Калган эшкә кар ява, диләр нугайлар. Дөрес сүзләрең, бик дөрес әйтәсең...—Ул кесәсеннән тәмәке чыгарып Әхмәтсафага сузды.—Күп сүз бозау имезә ди, берне көйрәтеп җибәрик.

—Рәхмәт, тартмыйм,—диде Әхмәтсафа үртәлеп.—Үзегез кадрлар белән янача эшләү кирәклеге хакында гәпәрдегез, үзегез кешеләрне төрлечә алдап эшкә калдырмакчы. Дөрес юл димәс идем, иптәш Рәҗәпов.

Рәҗәпов көлеп җибәрде. Тәмәкесенә ут элеп тәрәзә янына килеп басты һәм нәкъ Ниязов шикелле башын чөнкәйтеп тәмәкесен тирән итеп суырды да, төтенен тәрәз пәрдәсе артына өреп җибәрде. Тәрәз өлгеләренә сыеша алмый зәһәрләнеп-дулап зәңгәр төтен чабыша башлады.

—Син инде ничә мәртәбә алдау, алдашу дигән сүз ычкындырдың. Яңадан әйтмә бу сүзеңне. Фиркадашларча түгеллеген искәртәм, шул гына. Монда инкыйлапны асылда нугай-татарлардан торган мөселман батальоннары ясады. Җәдитче яшь көчләр нугайлар килеп житкәнче үк Хивада, Бохарада хакимиятне үз кулларына алырга теләп кузгалыш оештырдылар оештыруын, тик уңышка Хивада гына ирештеләр. Ул чакта мин дә җәдитчеләр сафында идем. Бохарада түгелгән кан дәрья булгандыр. Катлаулы чор иде. Хивада хакимлекне алдык, аны бит тотып торырга көч-белем кирәк. Монсын да булдырыр идек тыштан тыкшыну булмаса. Бер яктан—Рәсәй, икенче яктан —башка илләр... Кайсыдыр якка авышырга кирәк иде, шунсыз котылу юк. Без Рәсәйне сайладык. Ул дәверне сөйләп китсәң... Күрде бу яклар. Аксак Тимердән соң инкыйлапка кадәр моның ише хикмәтләр булмагандыр. Зәки Вәлиди дә үтте моннан үзенең үгет-нәсихәтләре белән. Әнвәр-патша килеп яу оештырып йөрде. Үзебезнең Фәйзуллаев, Ходжаевлар да шактый эш майтарып ташладылар. Мирсәет Солтангалиевнең бергәлек идеясе якын иде күңелгә. Әмма... әмма... Мәскәү төркиләрнең берләшүгә омтылышын җиңел генә хәл итте дә куйды. Олы Төркестанны бүлгәләп-таратып бетерде. Безнең Хива республикасы җирләре хәзер Үзбәкстан, Төрекмәнстан, Каракалпак дәүләтләре эчендә. Бүлгәлә һәм хакимлек ит!.. Сәясәт аңлашыла торгандыр. Ә син алдашу дисең...

Рәҗәпов янә өстәл артына килеп утырды. Әхмәтсафа әлеге сәяси агартуның үзе өчен үткәрелүен яхшы аңласа да, Рәҗәповның тел төбен аңлап житкерми иде әле. Моны Рәҗәпов үзе дә сизенде булса кирәк, сүзен дәвам итте.

—Мирсәет әкәнең башын ашадылар. Минем Мәскәүдә рабфакта укып йөргән чак, ул хәлләрне яхшы беләм. Күргәненчә, мине дә Мәскәүдә озак тотмадылар, "Үзбәкстанга җирле кадрлар кирәк,"—дип, кайтарып җибәрделәр. Кадрлар житми, кадрлар,—диде ул ачынып.—Мәскәүдә укыган

елларда минем карашлар да шактый үзгәреш кичерде. Рәсәйгә үчләшеп, әллә-ни майтарып булмаячак. Шушы вәзгыятьне үзбәк халкына мөмкин кадәр отышлырак итеп файдаланып калу кирәк. Безнең башка чара юк әлегә... Әүвәлге елларда бөгелешләр күпкәрәк киткән. Җәдитчеләр, кемнен кем булуына карамастан, өерләре белән фиркага кергәннәр. Аларнын күпчелеге Солтангалиев идеяләре белән сугарылган иде һәм бу омтылыш фирка тарафыннан яклау да тапкан иде. Хәзер исә, киресенчә, кем Мирсәет әкәнең идеясенә ябышып ята, андыйларны Мәскәү күрсәтмәсе буенча өерләре белән фиркадан чыгарып аттык. Мин, әйткәнемчә, Мирсәет әкәне ихтирам итәм, әмма фирка линиясе тармаклы була алмый. Фиркадан чыгарылганнарның күбесе үзләрен үзбәк ихтилалынын әттәләре дип санаучылар иде, биләгән урыннарын югалтуны авыр кичерделәр. Тартышу озаккарак китте шул. Эшкә аяк чалулары бер хәл, аларнын халык алдында абруйлары бар, аларга ышана халык, безгә түгел. Тез астына ин нык сукканы–кешеләр җитми, уртак Дәүләтьяров, кешеләр кирәк. Янында ышанычлы кешеләр булмаса, бер эшне дә башкарып чыга алмыйсын. Хива, Бохара кадрлар белән ярыйсы гына тәэмин ителгән анысы. Кешеләрне шәһәрдә калдыру җинелрәк–шәһәр һавасы барыбер үзен сиздерә. Бер якта–Караком, икенче якта Кызылком сахралары булса да, тимер юл якын, дарья, шөкер, кул сузымы гына. Ә эчкәре вилаятләргә кем барыр? Анда эшне кем белән, ничек оештырырга? Хакимлекне ничек кулда тотарга? Властьны кулдан ычкындырсан–беттен, тагын кан коеш, суеш башланачак. Бу НЭП дигәннәре, ярый, сәүдәгә иркенлек биреп, дихканнар күзләрен бераз ачты әлегә, артык мамыкларын сата алалар. Базар да тернәкләнеп килә. Тик сәүдә тирәсендә болганган халык–ин ышанычсыз халык ул. Бүген болайга борыла, иртәгә тегеләйгә. Сатуга күнеккән кеше акча керемен генә уйлый. Әҗере тиярдәй булса, барысын да сата. Хәтта хатынын да. Кызын сатып җибәрергә әзер. Шундый хәлләр... Менә шушы халыкны мен ел дәвамында чарланган гадәтләреннән аерып кара син!.. Кадрларны табып алабыз алуын, эшкә дә өйрәтәбез, инде кул арасына керерлек кеше булды дигәндә, мәркәздән директива килеп төшә–Үзбәкстаннын башка өлкәләре–Наманган, Сәмәрканд, Фирганә якларына кешеләр сорыйлар, таләп итәләр, тыңламасаң–яныйлар. Җибәрми нишлисен? Шәп егетләрне кулдан ычкындырдык, шунсы җәл. Сез нугайларда өмет, уртак Дәүләтьяров, сезгә өмет баглыйбыз. Әмирлекне пыр туздырып, хакимлекне алып бирдегез, инде кулда тотарга булышыгыз. Башка чара юк. Синен кебек урысча белгән егет урамда аунап ятмый. Фиркага алырбыз, кандидатлык вакыты үткәнен көтеп тормабыз. Нәкъ шундый егет кирәк безгә. Миндә уртак Ниязов язган холыкнамәң бар. Яхшы яктан күрсәтә. Эшлик, фирка шигарендә әйтелгәнчә, чүлдән гөлбакча ясыйк!

Әхмәтсафа уртак Рәҗәповны тыңлый да, тыңламый да кебек. Ул бит әле август башында гына Рабигага хат язып җибәргән иде. “Озакламый кайтып җитәм, көт,”–диде... Ул хат, һичшиксез, инде Рабигасы, төшләренә кереп йөдәтүче сөйкемлесе кулына эләккәндер, чөнки Рабига аны вокзалга озата төшкәч, бу җәйгә корган ниятләре белән уртаклашкан иде. “Атбасарга–туган шәһәремә кайтып киләм дә, анда озак юанмам, җәйге каникулда Оренбурдагы берәр балалар йортына тәрбияче булып урнашырмын, аз булса да акча, яшәргә мая булыр,”–дип сөйләнгән иде. Кыз күптән Оренбурда инде, аның кайтуын көтә torгандыр...

Рабига бер тын эчендә күнел капчыгын бушатып бетерүчеләрдән түгел. Танышып, инде егеткә ияләшкәннән сон, бер кичне урамга йөрергә чыккач, бераз чишелеп, үзенең тормыш хәлләрен дә сөйләштереп алган иде. Әхмәтсафанын белгән кадәресе шул–Атбасарда яшәүче әтисе, Мөхәммәтҗан исемле үзбәк–диндар, кадими кеше, кызларынын, әле анын Бибиҗамал исемле апасы да бар икән, янача яшәүгә омтылуларын һич тә хупламый, шунын өчен әнисен–татар хатыны Хәлимә апаны бик тә рәнҗетә, кечкенә ике улын ияртеп, куып җибәрү белән яный, кыскасы,

кызлары үчен анасыннан ала, шуны бик авыр кичерә иде Рабига. Атасының яшь хатыны да бар икән, ике дә уйламый куып чыгарыр әнине дип, тәмам аптырашта да калгалый иде ул. Инде үзе дә укуын өзеп, кайтып китә алмый, әтисе–үзбәк карты тәртипләренә күнә алмаячак ул, мәнге түзеп тормаячак. Әнисе кызганыч, шул үзәкне өзә. Куып чыгарса, әни энеләрем белән кая барыр, кемгә сыенып, дип өзгәләнгәч, сөеклесен бер мәлне Әхмәтсафа юатып та маташты:

–Кайгырма, Рабига, укып кына бетерик, барысы да җайланыр. Әниеңне–Хәлимә апайны да йолып алырбыз.

–Кемнән?–дип гаҗәпләнеп сорады Рабига.

–Әтиеңнән!–диде егет, инде барысы да хәл ителгән кебек.–Кыерсыта икән, моңа һаман да юл куярга ярамый.

Кыз күз яшьләрен сөртеп, елмайгандай итте:.

–Әй, Әхмәтсафа, Әхмәтсафа... Кайсы хатын-кызның гомер иткән иреннән язып, ялгыз каласы килсен. Гаиләдә өйне тотучы хатын-кыз булса да, туйдыручы–ир кеше бит. Минем әнием тегү-чигү эшенә оста, өй эшләренә бик һәвәс, йомшак күнелле, басынкы кеше. Әти исә ямчы, гомер буе юлда, диндар, каты куллы карт, өйдә аның сүзе генә сүз. Гомер бакый шундый тәртип булуын теләде. Башта Җамал апа чыкты әти сүзеннән. Ул өяздә хатын-кыз хәрәкәтен оештыручыларның иң тәүгесе иде. Аннан мең бәла белән мине озатты апам укырга. Әти ризалыгыннан башка. Әни, бичара, ул чакта әтинең талавына ничек түзгәндер... Әле бит энеләр дә бар. Гадәт буенча, апам белән мине тугач ук әти үзенең ямчы дус-аркадашларының улларына ярәшеп куйган. Шулай итеп, без инде ярәшелгән кызлар, колаклар тешләнгән дип, хәсрәтле көлеп алган иде Рабига.

–Ярәшелгән дип...–Әхмәтсафа кызны кирегә үгетләгәндәй, сөйләнеп алды.–Ул бит инде искелек касәфәте. Моңа хәзер кем ышансын?..

–Безнең әти кадими кеше,–диде Рабига, бу юлы тагын да житдирәк иде тавышы.–Сүзеннән чыкан өчен безне кичерә алмый. “Ил-көн алдына чыгарлыгым калмады, кызларымны марҗа иттең,” –дип әнигә көн-төн бәйләнә, җәберли. И-и, түзсә дә түзә икән золымга татар хатыны...

Рабига башын түбән иеп, тын гына атлый бирде. Бу сөйләшү Әхмәтсафаның Бохарага китәр алдыннан булган иде. Соңгы хатында егет Рабигасын тынычландырырга тырышып, “әгәр әниең Оренбурга, синең янга килеп урнашырга теләсә, мин китәр алдыннан Гомәр абый белән сөйләшкән идем, һич аптырамасыннар, Хәлимә апай белән энекәшләрең бездә торыр. Алда ничек яшәрбез, тормыш ничек булыр,– анысын мин кайтып, укулар тәмамлангач, карарбыз...“ дип тә өстәгән иде.

Бәлки язылганнарның төп асылын Рабига төшенеп тә җитмәс, ләкин егет инде үзе чамалый, аның күңеленә бу дөньяда Рабигадан башка беркем дә якын түгел; шушы җыйнак кына гәүдәле, ягымлы карашлы, тыйнак кыз җанына кереп утырды да, кузгалып та карамый, егетне иләсләндереп тик йөри. Төшкә керми калган төне юк, кайту көннәре якынлашкан саен сагыну-юксыну хисләре отыры көчәя бара иде, менә сина мә, дөя урынына ишәк дигәндәй, үзбәк дуслар аны кайтарып җибәрү турында уйлап та карамыйлар, “Килгәнсең икән, яңа тормыш төзеп бетермичә киту юк!”–дип, авыз ерып тик торалар. Ана кеше итеп карау юк, үз сүзеңне тәкрарларга маташсан, фирка исеме белән авызынны томалап кына куялар. Капты егет капкынга, фирка муеныннан эләктереп алган да җибәрми генә бит, кана. Каршы килсән, укыган җиренә, губерна комитетына холыкнамә җибәрәбез дип шүрләтәләр. Егетнең яхшы якларын санап, күрсәткән игелекләрен язып түгел инде. Гомеренең тәүге эш елларында ук начар холыкнамә җыясы килми, әлбәттә. Фиркага кергәндә: “Яңа тормыш төзүчеләрнең иң алгы сафында буласым килә, фирка өчен гомерем дә җәл түгел?”–дип кат-кат әйттерделәр аннан өлкән иптәшләр. Яңа тормыш төзүдә катнашасы

жирнең адресы күрсәтелмәгән иде. Ул җир Үзбәкстанда булып чыкты менә, әлегә аннан гомерен бирүне таләп иткән кеше юк. Җанында каршылыклы уйлар кайнашса да, риза булды, тагын бер елга калырга килеште.

Рәҗәпов егетнең йөзендәге чарасызлык чаткыларын күрмәмешкә салышып, аңа йомшак кулын сузды.

—Менә бу егетләрчә! Нугай егете сынатмас дигән идем, дөрес уйлаганмын. Аннан бая Әхмәтсафаның "тәмәке тартмыйм" дигән сүзләре исенә төшепме, аңа дустанә тавыш белән, киңәш бирәсе итте.—Тартмыйча дөрес эшләмисең, уртак Дәүләтьяров! Егет кеше икәнсең, тәмәке тарт, һич тә булмаса насбай булсын авызыңда. Борын астында мыек та булу шарт. Шунсыз үзбәкләр сине егет кешегә, ир-ат халкына санамас. Тәмәке тартмаган, әфьюн, насбай кулланмаган, сакал-мыексыз егетләрне хатын-кыз урынына кулланалар монда, белеп тор. Монда тәртип шулай.

Әхмәтсафа, әлеге ятышсыз сүзләргә каршы ни әйтергә белми тора иде, Рәҗәпов, үзе ачыклык кертте:

—Элек ханнар, байлар хатыннары өстенә уйнаш өчен гарем—кызлар белән бергә ак тәнле малайларны да тота торган булганнар. Кызлар кебек үк файдаланганнар малайларны. Бу якта киң таралган нәрсә ул. Шуңа күрә йөзенә карау белән синең ир-ат халкы булуыңны аңлап алсыннар. Абруйга шик-мазар төшәрлек булмасын... Аңлагансыңдыр?

Әхмәтсафа, Рәҗәповны җирәнеп тыңласа да, аның сүзләре тәэсирле булды, шул ук көнне инде кесәсендә папирос, шырпы пәйда булды. Ай үтмәгәндер, округ комитетының статистика-хәбәр бүлеге мөдиренең борын астында җыйнак кына мыек та үсеп чыкты. Инде хәзер һәр яктан ярарлык булды: фиркага да каршы төшмәде, абруйга зыян килерлек түгел иде. Үзенең тиз генә әйләнеп кайта алмавы хакында Рабигага язып җибәргән иде, озак та үтмәде, кыздан хат килеп төште. Кыз Әхмәтсафаның хәленә керергә тырышып язган иде, борчылмаска кушкан, көтәм дип, вәгъдә дә биреп куйган. Егетнең кәефе күтәрелде, үзе килгәнче бөтенләй таркалып бетә язган бүлектә эшне тәртипкә салу өчен, җиң сызганып вазыйфага кереште.

* * *

Эшенә дә, кешеләренә дә ияләшеп килгәндә генә Әхмәтсафага яңа хезмәт урыны тәкъдим иттеләр: Хорезм округ комитетының җаваплы инструкторы итеп билгеләнде ул. Егет каршы килмәде. Һәр хезмәт урынында ул эш сөючәнлеге, акыллы булуы, тынгысызлыгы, кешеләр белән тиз уртак тел таба белүе белән аерылып тора иде. Өстәвенә, башкалар белән чагыштырганда шактый белемле икәнлеге дә ярылып ята. Аңа хөрмәт артты, ни дисәң дә, фирка комитеты чыгарган карарларның үтәлешен тәэмин итү аңа йөкләнгән, карар язу эше, аны кабул итү үзе артык күп көч сорамаса да, фирка чыгарган карарларны үтәү өчен меңнәрнең көче, тир түгүе сорала. Үтәлешне тәэмин итим дисәң, ихтыяр, теләк тә, сабырлык һәм белем дә кирәк. Әхмәтсафаның эшенә ул яктан да тел-теш тидерерлек түгел иде.

Эш белән онытылып, көннәрнең бер-бер артлы йотыла баруын да тоймый калды, инде 1926 елның җәе дә үтеп бара икән. Шактый бертөрлегә әйләнеп беткән көннәрен җанландырган бер вакыйганы искә ала да, Әхмәтсафа шаклар ката—бу дөнья, бер карасаң, шул кадәрле киң, зур сыман. Шушы Хива якларын гына ал. Һәр ике якта диңгез сыман ком сахрасы җәйрап ята. Чүл барысын да йотып кына барган кебек. Аерым бер кешегә ни сан—сәфәргә кузгалган зур-зур кәрваннар да кибәнгә төшкән инә сыман гына монда. Бер офыкка кереп күмелгәч, кемнең кайда йөргәнен дә белмәле түгел. Атналар буе хәбәр көтәсең, эзсез-нисез юкка чыккан кебек алар. Мәңге табарлык түгел сыман. Айлар үтә, шулай да бер җай табып, исәнлекләрен белдереп куялар тагын. Чүл чүл инде, аңлашыла да. Хәтәр юл, хәвефле як. Әхмәтсафа шуны уйлый да,

үзе яшәгән Оренбур якларын искә төшерә–күрше авылда гына яшәп яткан яхшы танышыңны, йәисә якын туганыңны дистә еллар күрми яшисең. Кайберсе белән элемтә бөтенләй өзелеп, кайда гомер сөргәнен дә онытa башлыйсың. Әхмәтсафа да Саттарның эзен югалтты менә. Аның белән Бохарада аерылышкан иде. Рабиганың хатлары буенча, дустының шактый дәрәҗәле хезмәт башкаруын белә һәм шуның белән вәссәлам. Күрешкәне, очрашканы юк. Хивада елдан артык яшәп, ныклап танышып, дуслашып киткән кешесе дә юк. Барысы да үзләрен вакытлыча килгән кешегә генә саныйлар. Кайсы көзгә чаклы дип гомер үткәрә, кемдер ел башыннан каядыр китмәкче. Барысы да моннан тизрәк китү уе белән яналар. Сүз сөрешләрендә мантыйк юк түгел–монда шактый җаваплы урыннарны биләгән кешегә Урал, Идел буйларына кайтып төшсәләр, һичшиксез игътибар итми калмаслар дип, ышаналар алар. Утны-суны кичеп кайткан фирка солдатлары бит алар. Бәлки кемдер Мәскәү тирәсендә дә эш таба алыр. Һәрвакыт ишетеп торалар ич–кадрларны чәчеп үстермиләр. Менә шушындый җәһәннәм түрләрендә житешә алар иң кыйммәтле кадрлар! Вакытында күреп алулары гына кирәк, өстәгеләр сиңа игътибар иткәнче үк үзеңне күрсәтеп өлгерсәң бигрәк тә яхшы. Кыек-мыек сөйләп торасы юк, Әхмәтсафага очраган килмешәк түрәчекләрнең күбесе үзләрен кыйммәтле, белекле кадрларга саныйлар, шуңа чын күңелдән ышаналар, башкаларның да үзләре хакында шулай уйлауларын телиләр иде. Күп кенә яшь хезмәткәрләр Урта Азия республикаларына килеп эләгеп, артык көч, тир түкмичә һәм, дөресен әйтик, белем дәрәҗәсен исәпкә алып та тормастан, тиз генә шактый дәрәҗәле урыннар биләп алдылар. Моны алар, алдан әйтеп киткәнчә, очраклылык, язмыш бүләге дип түгел, бәлки үзләренең эшкә сәләтле, гайрәтле булулары белән аңлатырга азапланалар иде. Шул рәвешле, фирканың "жылы кулы" белән, дәрәҗә яраткан, әмма чын эшкә килгәндә шактый булдыксыз һәм надан яңа совет бюрократиясе туды. Мондый түрәләр янына белемле, эшне алып барырлык "йөк атлары," яки, үзләре эчтән көлеп, мыскыл итеп атаганча "совет ишәкләре" кирәк иде. Ниязов, Рәҗәпов кебекләр уенча, Әхмәтсафа Дәүләтъяров та шундый "ишәк"ләрнең берсенә әверелергә тиешле егет иде. Әмма бу хакта үзе әле бик уйлап бетерми, ул яңа тормыш кору идеясе белән яна, аны яшьлек романтикасы алга әйдәкли, ни кылса да бары ил өчен, халык өчен дип исәпли, якты киләчәкнең бик еракта булмавына, үзе кебек чын йөрәктән, җаны-тәне белән эшкә бирелгән миллионнарның хезмәте бушка китмәсенә инанып, рухланып яши иде. Фирка директиваларында күрсәтелгәнчә, әгәр дә Урта Азиядә совет хакимиятенең күзгә күренерлек уңышлары була икән, үзбәк-сартлар тиз арада совет ягына авышып бетәчәк. Ул чагында барлык халыклар ашкынган бәхетле киләчәккә–социализмга, аннан инде коммунизмга да ерак та калмас. Килеп житәр ул бәхетле тормыш, һичшиксез килеп житәр, кул кушырып көтеп кенә утырмаска кирәк, дип уйлый иде егет. Менә үзбәкләргә яңа тормыш төзеп бирсеннәр дә...

Шундый уйлар белән илһамланып, янып-пешеп эшләп йөргәндә, көтмәгәндә, округ комитеты урнашкан ике катлы бина алдында Фәтхулланы очратты Әхмәтсафа. Хәер, ул аңа игътибар да итмичә үтеп бара иде. Бу көнне педагогия техникумының яңа уку елына хәзерлеген тикшереп матавыкланды. Кәефе шәптән түгел иде. Алдагы көнне үк техникумга килəсен хәбәр иттереп куйса да, анда аяк атлап кергәч, ни мөдирнең, ни мөгаллимнәрнең берсенең дә эш урынында булмавын күреп, тәмам ярсып чыккан иде. Анысы бер хәл, әгәр эшенне шәп башкарасың икән, окружкомнан түгел, әллә каян килгән вәкилне дә санга сукма ди, монда бит иң кенче мәсьәлә–бина эче ташландык бер корылманы хәтерләтә иде, жәй буена адәм аягы басмаган монда. Бүгениртәгә уку елы башлана дип йөр син менә. Техникумның яңа уку елына хәзер булмавына җаны кыйналып, жилләнеп кайтып килгәндә, кемдер

артыннан куып житеп, жиненнән тартып туктатты:

—Уртак... Әхмәтсафа, син түгелме соң, авызына төкерим?!

Әхмәтсафа барган жирдән кисәк туктап, аптырау катыш куанулы тавыш иясенә борылды—каршысында милиция киемле, зур гәүдәле, төскә чибәр генә кеше басып тора иде һәм ул, егеттән ниндидер күнеленә ятыш сүз ишетергә теләгәндәй, балкып-елмаеп читкәрәк тартылды—мә, күр, янәсе, танырсыңмы абзаңны! Әхмәтсафа һушын жыеп өлгергән иде инде, каршысындагы бу бик тә мөлаем милиция вәкилен дә төсмерләп, танып та алды. Үзе дә сизмәстән:

—Фәтхулла абый!—дип, теге кешенең кочагына ташланды.

Әлеге очрашудан Фәтхулла телгә килә алмыйча азапланды. Егетне кысып кочаклап алды да, бер тын жибәрми торды, аннан гына өтә-төтә сөйләшә башлады:

—Карыйм, бер чибәр егет килеп ята. Башка күсәк белән ордылар диярсең, Әхмәтсафа бит бу, мин әйтәм, авызына төкерим. Үзгәргәнсең болай, нәчәлник кыяфәте кергән, шулай да танодым...

Әхмәтсафаның авыз ачуын көтмәстән, күнеленә килгән беренче сорауны бирергә ашыкты:

—Нишләп йөрисең монда?

—Тире жыеп, күн эшлим,—дип шаяртып жавап кайтырды Әхмәтсафа.

—Һи-и Каеш, монда нинди тире булсын, чүл бүреләренең тиресен генә жыймасаң...—дип, шаяртуны эләктереп алды Фәтхулла.

Әхмәтсафа, артык озакка сузмыйча, үзенең инде елдан артык бу якларда эшләп йөрүен сөйләп биргәннән соң, Фәтхуллага сораулар яудырырга керешге:

—Син... Фәтхулла абзый, ничек әле монда? Милиция дисәм... Кайда эшлисең димме соң? Кайчан килден Хивага?—Егет Каргалыда ук Фәтхулланың бу якларга чыгып китәргә жыенганын абзыйның үз авызыннан ишеткән иде.—Менә сиңа, нинди очрашу!—дигән булды.

Алар шулай ишек катында шаулашып-гөрләшеп торалар иде, кемдер, үтеп барышлый шелтәләгәндәй итеп:

—Юлдашлар, болай тору яхшы имәс, кешегә үтеп китәргә юл юк, читкәрәк китеп гәпәрегез,—диде.

Әхмәтсафа, исенә килеп, Фәтхулланы үзенең бүлмәсенә алып кереп китте. Бәхеткә, бүлмәдәшләре инде төшке ялга таралып беткәннәр иде, Әхмәтсафа зур калай чәйнек тотып чыгып китте дә, тиз генә әйләнеп тә керде:

—Шунысы әйбәт, кизү бүлмәсендә һәрвакыт кайнар су була, ашыкканда йөгертеп кенә алып киләбез дә бер чәйнек шаулап торган суны, эч күпкәнче яшел чәй эчәбез,—дип көлә-көлә, калай кружкага чәй салып, Фәтхуллага сузды. Ул инде хужа кыяфәтенә кереп алган иде, кунагы алдына хәлвә, аз-маз тәм-том китереп куйды. Егетнең бар байлыгы шул иде. Үзе Фәтхулланың каршысына утырып, бер йотым чәй уртлап куйды, мин сөйләдем, инде чират сиңа дигәндәй, сораулы-сынаулы карашын Фәтхуллага текәде.

Моны Фәтхулла да сизде. Нигәдер кашын жыерып, кружкасын өстәл уртасына таба этәрде һәм тавышын баса төшеп:

—Аптырадыңмы?—дип сорады.

—Ни дип әйтим... Киемең генә...

—Ат карагы милиция булгач, аптырасаң да сүз юк,—дип көлемсерәде Фәтхулла.

—Мин анысын әйтмим лә.—Ләкин Әхмәтсафа нәкъ шул турында уйлап алган иде, шулай да аны авылдашына сиздермәскә тырышты.—Бу дөньяда кем башыннан ни узмас. Язмыш бәндә башыннан йөри, агач башыннан түгел.

Егетнең күпне кичергән өлкәннәр кебек сөйләшүе Фәтхулланың күнеленә хуш килде бугай, ачылып китте.

—Шулай туганкай... Менә Хивага килеп төштем. Монда күптәнге

танышлар, авылдашлар шактый иде минем. Тик дөньялар үзгәреп киткән, кирәкле дигәннәрен инде таба да алмадым. Эшкә урнашырга кирәк, хәтерлисең булыр, теге чакта ат урлау турында авыз сулары корытып сөйләсәм дә, мин ул эшне кәсеп үк итеп бетерә алмадым. Сезгә юлыккан төндә мин арадашчы гына булдым, кемнәрдер китерделәр, мин авылдан өч-дүрт чакрым ераклыкта каршы алдым, атны абзарга кертеп җибәрдем һәм... ул атның кайда киткәнен дә, кемнәр алып киткәнен дә белмәдем. Сөйләшү шулай иде. Сез аптырадыгыз инде, әйеме, кая аткарды микән бахбайны дип. Миңа нәрсә. Китәргә акча кирәк иде, нигәдер Каргалыга кайткач, күңелем ятмады авылга. Шәмсия апаң да гел китү ягын каерды. Хәзер сагынам дип елый. Хатын-кыз шулай икән ул, энекәш. Баш әйләндерергә маһир алар, авызларына төкерим.

—Шәмсия апай?—дип, кабат кайтарып сорады Әхмәтсафа.

—Минем белән инде. Ал тәгәрмәч кай тарафка тәгәри, арткысы да шунда иярә. Ачка үлеп булмый, киттем эш эзләп. Бер танышым ОГПУ да эшли икән, аңа тап булдым, ул инде тезгенне шундук үз кулына алды. Гражданнар сугышында бергә ниләр генә күрмәдек аның белән бергә, баштан ниләр генә кичмәде, әмма бер-беребезне ташламадык ул чорда. Шушы иптәшем, авызына төкерим, мине милициягә китереп кертте. Башта курслар үттем, хәзер җинаятьчеләрне эзләү бүлегендә.

—Алайса эш җитәрлектер инде?

—Дөресен әйткәндә, башка калалар белән чагыштырганда, "тфү-тфү," әйтмәгәнем булсын, тынычлык әлегә шәһәрдә. Электән эшләүчеләрнең әйтүләренә караганда, күп кан коелган бу җирдә. Кан-яшь түгеп төзелгән хөкүмәт... Хәзер инде халык ризалашкан кебек язмышына. Тотрыклы тормышта җинаятьчелек тә кими дип өйрәттеләр безне. Әгәрен ки дәүләттә тәртип юк икән, югарыдагылар үзләре "шухыр-мухыр"га һәвәс дигән сүз. Моны борынга дәвердә яшәгән бер гыйлем иясе әйтеп калдырган. Шулай да шәһәрдән читтә, кышлак-вилаятьләрдә хәлләр четерекле. Әле яңа хөкүмәтнең буыны сыек, ныгып бетә алмый.

—Уку бушка китмәгән синең, Фәтхулла абый.

Фәтхулла егетнең шаяртуына игътибар итмәстән сөйләвен белде.

—Яңа икътисадый сәясәт нәтиҗәсендә, халыкка кот кунды, базар тернәкләнеп килә. Базар тирәсендә шпана, вак-төяк караклык җитәрлек инде. Эш арта, күп вакытны шулар белән куышып үткәрәбез.—Фәтхулла, ашыгыч бер эше исенә төшкәндәй, кинәт урыныннан кубарылды.—Син кайда яшисең?—диде ул, башына йолдызлы кәпәчен киеп. Әхмәтсафа каршысында гаярь кыяфәтле хәрби киемле кеше пәйда булды кебек. Соравы да кырыс яңгырады.

—Тулай торакта ауныйбыз. "Совет хезмәткәрләре йорты"нда.

—Кит инде,—дип сузды Фәтхулла, карашында чагылган кырыслыгы, кул белән юып алгандай, юкка чыгарга да өлгерде.—Әйдә безгә, Шәмсия апаң белән дә күрешерсең. Сагынуы басылыр үз малаен күргәч,—дип дустанә елмайды.—Сезне телдән дә төшерми, үз балалары сыман сагына. Ул Бибкәйне инде әйткән дә юк. Гел бергә иделәр авылда. Киткән чакта көч-хәл белән аерылыштылар, картлар әйтмешли, йон-май түктеләр. Үзебез белән алып китик дигән идем, Гомәрхан каршы төште. Миңа бер йорттан өч бүлмә бирделәр, шактый зур йорт ул, берничә милиция хезмәткәре гаиләсе белән яши. Безгә шулай кулайрак. Ни дисәң дә, беребез өйдә булмасак, икенчебез өйдә була. Корал бар, андый-мондый хәл булса дим. Дөньяны онытып йөри торган җир түгел, ни булмас дисең...

—Миңа да револьвер бирделәр.—Әхмәтсафа өстәл астыннан корал тартып чыгарды.

—Корал бирүләре әйбәт, анысы. Тик нишләп анда ята соң ул?

—Ә мин аның белән нишлим? Халык арасына чыкканда корал алып булмый. Безнең төп коралыбыз—сүз.

—Ай-һай, егеткәй, корал биргәннәр икән, юкка түгел инде бу, авызыңа төкерим...—дип, шелтәләгәндәй итте Фәтхулла.—Бүген тыныч

булыр, иртәгә әллә нинди хикмәтләргә юлыгырсын.

Әхмәтсафа револьверны тиз генә кире өстәл тартмасына салып куйды. Уйламаганда, көтмәгәндә мактанып ала торган гадәте бар инде аның. Шушы гадәте өчен ул үзен битәрләп бетерә алмый. Менә хәзер дә Фәтхулла абзый алдында кыен хәлгә тарыды. Нигә күрсәтергә инде ана револьверын. Мактана, имеш...

—Ана калса инде... Атып та караган юк соңгы араларда...—дип, аклагандай сөйләнде.

...Алар абыйлы-энеле кебек, күнелле сөйләшә-сөйләшә Фәтхулла йортына китеп барганда көн кичкә авышкан иде инде. Ике-өч көн үтмәде, Әхмәтсафа бу йортка күченеп үк килде. Үги әнисе Шәмсия исә Әхмәтсафаны үз улыдай кабул итте. И дөнья! Кемнәр белән кавыштырмый, кемнәрне нинди хәлгә төшерми бу яшәү дигәннәре. Дөнья киң түгел икән. Бик тар ул дөнья дигәннәре. Шулай булмаса, әллә кайда, шайтан олаккан җирдә, Фәтхулла абзый белән Шәмсия апайга юлыгыр идемени ул?...

* * *

Мөселманның ял көне—җомга. Якшәмбе—урыс көне. Һәр мөселман баласы намазга баскан көннән башлап белә торган гап-гади нәрсә инде бу. Әлмисактан ук килгән һәм бәхәс-мазарларга бөтенләй урын булырга тиеш кебек түгел дә... Әмма шушы ял көне мәсьәләсендә дә кайбер аңлашылмаучылыклар килеп чыга башлады соңгы вакытта.

Округ комитетыннан җибәрелгән циркуляр буенча, ул "үтә яшерен" дип тамгаланган иде, Хивадагы хөкүмәт карамагындагы завод-фабрикаларда ял көне итеп якшәмбе көн билгеләнгән, ә җомганың эш көне итеп үзгәртелүе хакында әйтелеп, бу хакта эшчеләр арасында ныклы аңлату, үгет-нәсихәт алып бару зарурлыгы ассызыкланган иде. Сәбәбе дә күрсәтелгән: Үзбәкстан—СССР составындагы республика, үз-башка кануннар белән яшәргә тиеш түгел. Бөтен Совет иле бер төрле канун белән яшәгәндә, Үзбәкстанның, аерым утрау хәлендә, һаман шәригать кануннарына чат ябышып ятуы кискен тәнкыйть ителгән. Төп гаеп—җирле фирка оешмаларының акрын кыймылдавында диелгән иде циркулярда. Мәскәү, ана кушылып фирканың Үзбәкстан мәркәз комитеты милли мөхтариятларда монын ише вак-төяк тайпылышларны тиз арада "төзәтергә", моңарчы бу төбәктә яшәешне көйләп торган шәригать кануннарыннан тиз арада ваз кичеп, гомумсовет кануннары белән тормыш итә башлауны таләп итә иде. "Гомуми нормаларга китерү" дип әйтүе генә ансат, хәл күпкә катлаулырак иде шул.

Мәркәздән күрсәтмә-фәрманнар агылып кына тора, аларның дөрес яки хата булуын тикшерү урындагы фирка комитетының эше түгел. Боерык бар икән, аны үтәргә кирәк. Нинди күрсәтмә бирелсә дә!.. Фирка шулай гына яши ала. Шуңа күрә "ял көне" мәсьәләсен хәл итүгә дә җиң сызганып кереште округ комитеты. Әлеге гаять мөһим мәсьәләне "контрольдә тоту" Әхмәтсафа Дәүләтьяровка тапшырылды.

Мәскәү ерак, юлбашчылар Үзбәкстандагы хәлләрне бөтенләй белми торгандыр дип әйтә алмый Әхмәтсафа. Белә торганнардыр. Әмма ни дәрәҗәдә белә?.. Бу сорау аның күңелендә юктан гына тумады һәм ана төгәл җавап табу мөһим булыр иде. Әхмәтсафа фирканың үз эчендә эшне оештыруда зур чатаклыклар булуын сизенә башлаган иде. Шикләнергә, шөбһәләнергә сәбәпләр җитәрлек.

...Әле Хивага килеп, статистика-хәбәр бүлегендә эшли башлагач ук, аның белән Рәҗәпов арасында кискен сөйләшү булып алган иде. Ул сөйләшү хакында ни Әхмәтсафа, ни Рәҗәпов бер-берсенең исләренә төшереп тормасалар да, нәкъ шуның аркасында, егетнең бүлектә эшли башлавына өч ай дигәндә, аны икенче урынга күчереп утырттылар. Яңа урын әүвәлгесеннән югарырак һәм үтә җаваплы булса да, егетнең

күнелендә яра булып калды бу күчеш.

Әхмәтсафа статистика бүлегенә ел ахырында килгәнгә, еллык исәп-хисап ясап, бөтен мәгълүматларны мәркәзгә җибәрү дә аның өстенә өелде. Монарчы җүнле-башлы исәп-хисап алып барылмаган бүлекнең эшен яңа баштан оештыру, ел дәвамында өзек-төтек җыелган статистик хисапларны барлап чыгу, аларны чагыштыру өчен кабаттан вилаятьләрдән мәгълүматлар китертү, якынча гына булса да еллык эшне дөрес итеп күзаллауга ирешү ниятен тормышка ашыру шактый көч һәм вакыт сарыф итүне сорады. Алсыз-ялсыз эшләү авырга туры килсә дә, ахыргы нәтиҗә сөенечле булды. "Тырышкан табар, ташка кадак кагар,"—ди иде әтисе мәрхүм, дөрес икән. Көне-төне шушы кәгазь боткасы белән әвәрә килеп үткәрсә үткәрде гомерен, әмма һәр тармак буенча, һәр нәрсәгә кагышлы дөрес һәм төгәл мәгълүмат туплауга ирешә бит, ә! Яңа хакимият урнашканнан соң беренче мәртәбә округ җитәкчеләре өстәленә шундый төгәл, җентекләп хәстәрләнгән мәгълүматлар килеп ятсын әле! "Әфәрин, егет икәнсең, Дәүләтьяров!"—дип, үзен мактый-мактый, билгеләнгән вакытта җавап тоту өчен Рәҗәпов янына юнәлде ул.

—Йә, уртак Дәүләтьяров, хәлләр ничек бүлектә? Төшенденме эшкә? Күреп тордык. Баш күтәрми эшләдең, мәгәрәдә яткан акыл иясеннән ким кыланмадың,—дип, үсендергән шикелле кабул итте аны Рәҗәпов һәм егетнең култык астындагы калын кенәгәгә күз салып, хәйләкәр генә каш сикертеп алды.—Чуар тышлы китап ни сөйли анда? Башка округ, өлкәләр алдында ничегрәк күрсәтә микән безнең хәлләрне?..

Әхмәтсафаның әле Урта Азиягә килгәненнән бирле үз эшеннән шулай канәгать хәлдә йөргәне юк иде. Шаяртуга шаяртып җавап бирде:

—Китап нәкъ китап кушканча сөйләргә әзерләнде, уртак Рәҗәпов. Акка кара белән язылган, һәр саны мең дә бер кат тикшерелгән, һәр бите тамгаланган, мөһер сугып мәркәзгә җибәргәнне генә көтә.—Үзе әйткәнне дә көтеп тормыйча, Рәҗәпов каршысына утырып, хисап тотарга әзерләнде ул. Тирән тын алып:

—Ел дәвамында округта... дип, авыз ачып, сүз әйтергә өлгермәде, аны Рәҗәпов кисәк кенә бүлдереп тә куйды:

—Тү-тү-тү, уртак Дәүләтьяров, кая ашыгасың, шаулап аккан арыкка төшкән өрек кабыгы шикелле. Каударланма әле син.—Рәҗәповның калын кашы җыерылган, йөзе кызарып чыккан, нигәдер тынычсызланган иде ул. Тиз генә барып бүлмә ишеген бикләп килде, аннан бераз тынычланып, акыл биргән сурәттә сөйләнә-сөйләнә кенәгәне битараф кыяфәт белән актаргалагандай итте.—Эш җаен белмәс көйгә мамык кәшәнкәсенә үрелгәч ни булганын беләсеңме? Кулсыз каласың, егеткәем! Исәп-хисап эшендә дә шулай, кулсыз гына түгел, башсыз калуың да ихтимал. Ашыгу пылау ашаганда гына әйбәт, инде эш эшләнгән, языласы язылган, сызыласы сызылган дигәндәй, тыныч кына сөйләшик әле. Мин синең хисап белән узган елгы күрсәткечләрне чагыштырып карадым. Күзгә чалынган икеөч санга игътибар итүгә, йөрәк жу-у итеп китте, менә... Башсыз калабыз, уртак Дәүләтьяров, икәүләп башсыз калабыз болай булгач... Бер дә дөрес эшләмәгәнсен, кенәгәне кинәшләшми-нитми тутырып та куйгансың. Карап кына тормалы инде—чиста, пөхтә, бүген үк Мәскәүнең үзенә җибәр, иеме?..—Рәҗәпов чыраен сытып, урындыгыннан күтәрелде.—Әүвәл каралмада гына эшләргә иде, аннан уйлашыр идек. Ашыккансың, уртак, ашыккансың...

—Монда барысы да дөрес!—дип, кайнарланып, Рәҗәпов алдындагы еллык хисапны тартып алды егет. Гарьлегеннән нишләргә белмичә, җәһәт-җәһәт кенәгә битләрен актара башлады.—Һәр сан үз урынында, әйтәм бит, тикшерелмәгән бер сан юк дип. Һич тә борчылмагыз, уртак Рәҗәпов!—Ул ашыгып тәмәкесенә ут элде.

—Фирка комитеты раславын үтми торып, бер генә сан да дөрес була алмый, Дәүләтьяров. Төшенеп бетмәгән сабый кебек син. Дөрес сүзне фәкать фирка гына әйтә, дөрес санны да фирка гына белә, фирка

гына юл күрсәтә. Без ул кушканны үтәүче генә. Син уйлаган дөреслек белән, фирка фараз иткән дөреслек арасында зур аерма барлыгын исеңнән чыгарма. Хәзер үк күнелгә корт керде, менә син бу елда фәлән кадәр мамык җыелды дип күрсәтәсең...

—Мин күрсәтмим. Санны тикшереп, язып кына куйдым, чөнки чыны шул...

—Вәт, вәт!.. Кем язды соң ул саннарны? Син! Шулай бит. Димәк, әле бу диһканнарның эссе кояш астында тир түгеп, кул чиләрен чыгарып үстергән уныш күләме түгел, ә син язган коры саннар гына. Конкрет саннар исә бөтенләй башка нәрсә хакында сөйли, болай дип әйтә алар...— Анын юан бармагы өстәлдә яткан таушалып беткән кәгазь буйлап китте.— Узган ел тырыш диһканнарыбыз моның кадәр мамык унышы җыеп алганнар. Салым-налог хисабына хөкүмәткә менә моның кадәр тапшырылган.—Рәҗәпов әйткән һәр санны авыз эченә йомып бара иде.—Ирекле бәядән дәүләткә фәлән кадәр сатканнар. Шулай, шулай... Башка күрсәткечләр ни сөйли анда?.. Каракүл тиресе шунын кадәр әзерләнгән, тәк, тәк... болары сатылган, дәүләткә тапшырылган. Ә синең кенәгә, үткән ел белән чагыштырып карасаң, капма-каршысын сөйли. Имеш, кайсын алма, быел нәкь ике мәртәбә ким житештергәнбез. Барысын да! Нәрсә, ел буе ефәк күбәләге куып йөримени округ комитеты?.. Бер нәрсә эшләмәгән, бернәрсәгә житәкчелек итмәгән, карамаган, күрмәгән, белмәгән диген сүзме? Әллә собатаж ясап, советка каршы эш маташтырып яткынбызмы? Җавап бир, иптәш Дәүләтьяров, мин төшенмәдем...

—Мин ... кабатлап әйтәм, иптәш Рәҗәпов...

Рәҗәпов җилләнеп урынынннан торды, аннан шап итеп янә урындыкка менеп кунаклады.

—Син шул, син! Син генә монда, башка кешене күз чалымына да китермисең. Көн-төн халык мәнфәгатен кайгырткан округ комитеты да, безнең тамакны туйдырган диһканнар да, безне киендергән эшчеләр дә юк? Син бар менә, иеме?!. Каян килә ул яшьләрдә шулкадәрле эгоизм?.. "Без" дип сөйләшәсе урынга, һаман "мин" дип тәкрарлый бит. Өлгермәгән йөземне җилпуч белән алга китереп утырттын да, инде хәзер, "мәйлен, ашаныз, иптәш Рәҗәпов, дип торасыңмы? Миннән эш төште, калганын үзең кара, теләсә ни эшлә," дисеңме? Алай булмый егеткәй. Ул саннарны кенәгәгә язганчы уйлар идең, башың булса. Алдагы елда бу диһканнар ничек яшәр, совет тарафыннан аларга нинди ярдәм күрсәтелер? Уйладыңмы бу хакта? Юк шул, кешенеке кештәктә, диһкан кайгысы юк синдә, иеме? Менә бит ул ничек. Быелгы унышка карап диһканга яренгә ашлама алырга мөмкинлек бирелә, сугару өчен ташлама ясала, кызыксындыру чаралары карала. Уныш юк икән, бичара диһканга да бернәрсә дә юк, шымытыр башы тотып калачак. Төшенәсеңме, зирәк баш. Ә каракүл тирегә килсәк, ул—чүл алтыны, аны ким итеп күрсәтсән, мал карауччыларыбыз, чабаннар ни хәлгә төшәчәк? Күз явын алырлык бәрән тиреләре бездә генә, чыра яндырып дөнья буйлап китсәң дә, башка андый затлы каракүл тирене таба алмассын. Ким итеп күрсәтсәң, малчыларга да шымытыр башы, дөньяны өстерәргә рәт калмый диген сүз. Күрсәткечләрдән чыгып, аларга хөкүмәт ярдәм күрсәтә бит. Ә ярдәмгә ин мохтаж кешеләребез—нәкь менә чүл алтыны—каракүл бәрәннәре тәрбияләп үстерүче фидакарьләребез. Сүзем тәмам, инде хәзер ни уйлыйсын? Син биргән саннарны җибәрсәк, ярлы-ябагайны кыен хәлгә куябыз, иптәш Дәүләтьяров, төшенгәнсендер?..

—Тел төбегезне аңладым кебек. Тик бер генә нәрсәне төшенмим—еллар буе шул рәвешле "уныш арттырып", күрсәткечләрне купайтып килгәнсез. Беренче игътибар иткән мәлдә, белдексезлек касафате дип кенә уйлаган идем. Хикмәт тирәндәрәк икән. Булмаган нәрсәне бар дип күрсәтүдән кем ота? Үзбәкстанмы, әллә, тулаем алганда, совет иленә бирәр файда киләме? Әгәр бөтен ил күләмендә шундый купайтып күрсәтү чире башланса?

Рәҗәпов көлемсерәп куйды, тик дәшмәде.

—Моннан диһканнарга, чабаннарга да зур өлеш чыгар сыман түгел,— дип, дәвам итте Әхмәтсафа.—Мин аларга күрсәтелгән ярдәм, ташламалар хакында да берничә еллык белешмә тупладым. Ләкин үсеш-үзгәреш сизелми. Кем елгыррак, кемнең округ комитетында таныш-белеше бар, шулар ярдәмне чумырып ала. Чыннан да, мохтаҗларга мыскаллап кына тәти совет ярдәме. Аннары дәүләткә, сәүдәгә озатылган һәр нәрсә чутсыз түгел ич. Без генә исәпләшмибез чынбарлык белән. Ялган барыбер ачылачак.

—Әй, Ходай бәндәсе,—диде ачынып Рәҗәпов.—Аларын кем санап-җыеп бетерсен, ди. Син болай язып җибәрәсен, Бохарада тегеләй төзәтәләр, Ташкентта алай, әле Мәскәүдә дә тере үзбәкне күрмәгән бер бәндә, Үзбәкстандагы хәлләр хакында җавап биреп утырадыр. Анын да диһкан әзерләп тапшырган мамыкка "кул тыгасы" килә торгандыр. А как же, җаваплы түрә бит ул! Ул да үзенчә төзәтеп утыра торгандыр. Һәммәсенә эш күрсәтү кирәк бит. Бәлки безнең "күрсәткечләр" әллә кайчан хәзерләнеп беткәндер, уртак Сталинның, йәисә Бухаринның өстәле өстендә әллә кайчан ятадыр инде. Безгә эш тә калмагандыр.

—Алайса нигә баш катырып утырабыз?

—Кызма, уртак Дәүләтьяров. Өлгермәгән йөзем ашап, эче киткән сабый кызганыч та, көлке дә. Шундый хәлдә калмыйк. Без Мәскәү өчен дә эшләмибез, башкасы өчен дә тире җыртмыйбыз. Үзебез өчен кирәк ул. Күсәткечләрнең һәркайсысы узган елгыга караганда ун-унбиш процентка артык булырга тиеш. Округ комитеты шуны таләп итә. Дөресен белүчеләр бармак белән генә санарлык: син беләсең, мин, тагын Мөхәммәтәмин дигәндәй...

Әхмәтсафаның бирешәсе килмәде.

—Чынлыкта күрсәткечләр, соңгы ике елда, нәкь сез әйткән кадәрле кими барган, еллык исәп-хисапта артым күрсәтелгән. Бу алдауның кайчан да булса "исе" чыгачак бит.

—Нәкь өстенә бастың! Кайчан да булса... Иртәгә өчен ишәк кайгырган, уртак Дәүләтьяров. Без, конкрет алганда, бүген эшлибез, иртәгәге көн хакында да онытмыйбыз. Без күрсәткән саннар алар-алдагы көннәр өчен ният-план булып торалар, изге ният ул. Төшенденме? Без шул күрсәткечләргә йөз тотып эшләргә, диһканнарны, михнәткәшләрне-хезмәт ияләрен шуңа әйдәкләргә тиешбез. Башка округ, өяз, өлкәләр алдында йөзебезне җиргә орырга да тиеш түгелбез. Алардан ким эшләмибез, буй-сыннарыбыз да, акыл-фигыльләребез дә башкаларныкыннан ким түгел. Димәк, исәп-хисапны үзгәртеп, икенче кенәгә тутырырга туры килер. Менә сиңа үткән елгы саннар, күрсәткечләр, ә монсын миңа бир, өйрәнеп чыгыйм, кем әйтмешли, белми белмәүгә караганда, белеп белмәү яхшырак. Ә синең алдашу, дип, денең каткан... Алдашу түгел, эш тәртибе бу, илнең яшәү рәвеше... Ил матур ниятләр белән, алга карап яши безнең. Халыкны шулай гына алга әйдәкләп була, беләсең килсә. Аң бул, уртак Дәүләтъяров, синең кулда көчле корал-каләм бар. Каләм үгез тарта алмаган йөкне дә тарта, белеп кенә куллану кирәк...

...Үзгәртеп эшләнгән еллык исәп-хисапны округ комитетында зур күтәренкелек белән расладылар. Әхмәтсафа җир тишегенә кереп китәрдәй булып утырды. Бигрәк тә чыгыш ясаучы җаваплы хезмәткәрләрнең бер-берсенең күзенә туры карап, ялган саннар китерә-китерә нотык тотуларын авыр кичерде ул. Барысы да һәммәсен белеп торалар, саннарның "түшәмнән" алынганына һәммәсе хәбәрдар, әмма алдашалар, берсеннән-берсе уздырып күзгә төтен җибәрәләр. Анын күз алдына әле өстәл астына көлтә-көлтә төтен җибәреп утыручы тук кыяфәтле Ниязов, әле тәрәз пәрдәсе артына зәңгәр төтен бөркүдән ниндидер сәер ләззәт кичерүче вәкарь Рәҗәпов килеп басты.

Рәҗәпов бу мәҗелестә шундый кәнагать рәвештә утыра иде,

әйтерсең, ниндидер кодрәт беләҥ чүл өстенә ике көннән берендә шаулатып янгыр явып торган да, монарчы ком бураны уйнап торган сахралар гөлбакчага әйләнгән дә куйган. Сәер халык, сәер ил, сәер дөнья...

Мәҗлестән алган авыр тәэсирләрдән арынып бетерә алмый, эш бүлмәсендә уйланып, кул астындагы кәгазьләр белән әвәрә килеп утыра иде, коридорда ниндидер җанлылык, ашыгып сөйләшкән тавышлар ишетелеп алды, ул арада Җәмигъ мәчетенең имамы—Хиванын абруйлы хәзрәте, аның белән ике-өч дин әһеле килеп керделәр.

Имамнар керә-керешкә гозерләрен сөйли башламакчы иде, Әхмәтсафаны күргәч, бөтенләй күнелсезләнеп калдылар шикелле.

—Шушы ять-яшь нугай баласы белән ни генә гәпәребез икән инде, ә җәмәгать?—Моны алдан кергән баш имам әйтте. Башкалар авыр сулап аны җөпләгән булдылар.

—Болар кулына динебез язмышын тапшырсаң...—диде галәмәт олы чалмалы имам.—Читтән килгән байгыш башына кунса, сәмруг кош булыр. Килмешәк этне җиде мәхәлләдән куалар, аларга иркенлек бирсәң, ни буласын бүгенге хәлемездән чамала инде.

—Гыйлем—болак, акыл—чырак. Чеп-чи надан нугай имәстер күк...

—Наданнын шунсы куркыныч—ул һәр нәрсәне беләм, ни эшкә тотынсам, шуны булдырып чыгам дип уйлый, бахыр. Җиде йортнын телен бел, җитмеш төрле белем бел, дигән гыйлем иәләре. Каян табасын хәзер андый белекле затларны? Бәс, дин-шәригать эшләренә казыйлык итүне шушы балага тапшырганнар икән, акыл казаны бөтенләй үк буш имәстер, берни эшләр хәл юк, гәпәрергә туры килер инде,—диде баш имам. Ул бу сүзләрне ничарадан бичара гына әйтте кебек.

Әхмәтсафа, ишек катында торган имамнарнын үзенә юллап атылган утлы сүзләренә артык игътибар итмәгән сурәттә, урынынан кузгалып, һәркайсы белән ике куллап күрешеп, аларга урын тәкъдим итте, бергәләп озаклап дога кылдылар. Һәр хәлдә үзенә төбәп әйтелгән сүзләр анын мин-минлегенә нык кына кагылып үткән иде, ләкин вазифа дигән нәрсә дә бар бит әле, кем дә булса тынларга тиеш имамнарны. Юкны бушка аударып йөрүчеләр түгел алар.

Нугай егетенең үзләре белән үк бөтен шартын китереп дога кылуын күргәч, баш имам яктыра төште һәм округ комитетына килү сәбәбен тәфсирләп бирде:

—Балам, мөселманнар кимсенә бит. Изге җомга көнендә хөкүмәт эшенә килергә куша икән сәвит. Бу ни хәл, каян чыккан, кем чыгарган мондый канунны? Нинди иблис котырта мөселман әһеленә каршы сезләрне?—Имам күзен чепиләндереп, зәһәр генә Әхмәтсафага карап куйды.—Син үзең мөселманмы, әллә урысларга сатылып, шайтан аздыруы аркасында юлыннан язган бер нәмәрсәме?..

Әхмәтсафа, имамнын сүзләрен килештермәгән кебек, маңгаен җыерып куйса да, җитди итеп җавап бирде:

—Мөселман, хәзрәт, мөселман булам мин. Сез керер алдыннан гына динебезгә кагылышлы бер кәгазь укып утыра идем әле. Менә Татарстаннан бер документ бар.

Имам, башкаларга аңлаткандай итте:

—"Татарстан" дигәне нугай иле була инде.

Калган икесе шаулашып алды.

—Аларга бер ышаныч та юк. Урысларга сатылып беткән адәмнәре.

—Аларнын мөселманлыгын әйтерием инде...

—Алай димәгез, мөхтәрәм имамнар,—диде Әхмәтсафа, бәхәскә керергә тайчанмыйча.—Татарстанда, милли республика буларак үз йөзен саклап калу, беренче чиратта, шәригать кануннары буенча яшәргә омтылу көчле. Менә бу документта да, РСФСР конституциясе белән шәригать кануннары чагыштырылып күрсәтелә, һәм, асылда, алар бер-берсенә каршы килмиләр икән. Сүз шул хакта бара. "Мөселманнар башка халыклар белән каршылыкка кермичә, үз тормышлары белән, шәригать кануннарына

таянып яши алалар,"—дип, раслыйлар әлеге документны хәзерләгән галимнәр. Шушы фикерне ныгыту максатыннан шактый күп мисаллар китерелә. Мәскәү моңа каршы килер сыман түгел, башка мөселман республикаларына да шундый яшәеш өлгесе тәкъдим ителә. Мәскәү хуплавы белән, әлбәттә. Димәк, хәлләр бөтенләй өметсез түгел, сез әйткәнчә. Совет хөкүмәте бу хакта уйлана...

—Бәрәкалла, бәрәкалла, бирсен Ходай,—диде имамнарның берсе.—Аны кем язган, кем чыгарган соң. Ленин тамгасы салынганмы, мөһере бармы?

—Турысын әйтим, бу документ ике-өч ел элек килгән округ комитетына. Нигәдер ана тиешле игътибар бирүче булмаган сыман. Югыйсә, документны өйрәнеп, тәкъдимнәрне Мәскәүгә җибәрергә тиеш булганнар. Төгәл әйтә алмыйм, тик белгәнемчә ул тикшерелмәгән, фикерләр Мәскәүгә дә җибәрелмәгән, ахры. Урындагы юлдашлар шулай диделәр. Ленин вафатыннан соң, аның васыятьләренә туры китереп эшләнгән ул. Шәхсән үзем, мөселманнарны пошындырган җомга көн мәсьәләсе хәл иткәндә шушы документка таяначакмын.

...Асылда хәл җитди икәнен яхшы белә иде Әхмәтсафа. Хивада урыслар аз санда булсалар да, алар округ комитетында булсын, башка өлкәдә эшләүчеләрме—һәркайсы мөһим урын биләп торалар. Соңгы вакытта: "Ял көне җомга булырга тиеш түгел, совет илендәгечә—ял көне якшәмбе булсын!"—дип гауга чыгаручылар, җомга көнне эшкә килгән булып, якшәмбе көнне исә, ял итәбез дигән сылтау белән эшкә килмичә, хезмәт урыннарында ыгы-зыгы тудыручылар күренә башлады. Сәере—аларга башка милләт кешеләре, шул исәптән татар коммунистлары да кушылып, бер карауга, әһәмиятсез дип күренгән хәрәкәт, шактый тамырлана бара иде. Бу шаукымнан хатын-кызлар да читтә калмый, әле күптән түгел генә окружкомга мәркәз вәкиле

## «КАЗАН УТЛАРЫ»НА 80 ЕЛ
## «QAZAN UTLARI»NA 80 YIL

### Нәзиф Мириханов,

*Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге тулы хокуклы вәкиле*

## САЛЛЫ СҮЗ МӨНБӘРЕ



*«Казан утлары» журналы минем тормышымда, бигрәк тә совет заманында, бөтен ил халкы өчен «Роман-газета» билгән урында булды. Журналыбызның абруе бүген дә зур.*

*Соңгы вакытта барыбыз да информация ташкынына кереп баттык. Әдәбият та саеккан сыман тоела, язучыларыбыз исә конъюнктурага бирелеп, күбрәк детектив, азгын мәхәббәт, җинаятьчелек турында яза башладылар. Әдәби журналдан тормышның мәгънәсе, кешенең бу дөньядагы урыны турында фәлсәфи әсәрләр укыйсы килә.*

*Үземә килгәндә, соңгы елларда нигездә тарихи әсәрләр, тюркология һәм этнология белән мавыга башладым. Бу темаларга язмаларны «Казан утлары»нда да еш очратам. Афәрин! Татарча латин графикасында язылган шигырьләрне дә ин беренче журналда укый башладым.*

*Гомумән, «Казан утлары» заман катаклизмнарына карамастан, кайбер басмалар шикелле уңга-сулга авышмыйча, бер читтән икенче читкә ташланмыйча, тоткан кыйбласына, мәсләгенә, халыкка хезмәт итү юлына тугры калды. Әдәпле әдәби журнал булып яши бирә.*

*80 еллык юбилее уңае белән «Казан утлары»на татар халкын саклап калу юлларын яктырту эшендә зур уңышлар, саллы сүз мөнбәре булып калуын телим, редакция хезмәткәрләренә исә сәламәтлек, бәхетле тормыш юллаш булсын!*

булып Жамал исемле бер яшь кенә чая хатын килеп, зур жыелыш үткәреп китте. Үзе Коканд өлкә комитетында эшли икән. Бик ялкынланып, үтемле итеп сөйли. Аны тыңлаганда әлеге яшь-яшь хатынның кыюлыгына, тапкырлыгына хәйраннар калып утырды Әхмәтсафа.

—Житте! Башны күтәрергә вакыт!—дип сөрән салды Жамал чыгыш ясаганда.—Мин Казахстан баласы, Атбасар-Акмулла якларында беренчеләрдән булып пәрәнжәне йолкып атып ялан баш йөри башладым! Монда үзбәк хатыннарын, кызларын бәладән йолу өчен килдем. Салыгыз хатыннар пәрәнжәләрегезне! Кызлар, якты кояш астына чыгыгыз! Күрсеннәр мөселман хатыннарының нурлы күзләрен, күрсеннәр гүзәл кызларыбызның йөзләрен. Шәригать безне күп изде инде, бетсен—изү! Көчләү хурлыгы төрмә хурлыгыннан да яман. Безне мең еллар дәвамында шәригать исеме белән көчләделәр. Жаныбыз корыды, бәгырьләр кипте. Без шәригатькә түгел, шәригать кешелеккә хезмәт итсен! Шигарь шул булырга тиеш. Беренче адым—ял көнен якшәмбегә күчереп, жомга көнен—эш көне дип игълан итик. Якшәмбе—хезмәт ияләренең хезмәт бәйрәме булсын!—Яшь хатын күкрәк киереп, иләмсез тавыш белән,—ташлагыз пәрәнжәне, Хива хатыннары!—дип кычкырганда, зур залда ялт-йолт яшен уйнап торган сыман тоелды. Бу кадәр тәвәккәллектән, кыюлыктан хәтта таш диварлар шаккатып калды, бина үзе чүгеп куйгандай булды.

Жамал Сарымсакованы шәһәр буйлап Әхмәтсафа озатып йөрде. Сарымсакова дигән саен, күңеленә аның Рабигасы килеп баса, ул да Сарымсакова фамилияле, ул да Атбасар ягыннан бит... Әмма бу янып торган карашлы, тыелгысыз рәвештә алга омтылган, ашкынулы адымлы хатын белән тыйнак, сабыр табигатьле, оялчан Рабига арасында нинди дә булса уртаклык күрмәде ул. Чибәрлек ягына килгәндә, әйе, Жамал төскә Рабигадан калышмый, бер тутырып карасаң, күзне алып булмый үзеннән, каһәр... Әхмәтсафа, тәвәккәлләп, Рабига хакында Жамалның үзенә сүз катмакчы иде, аның янып торган күзләренә карап алгач, кире уйлады, юк, аның Рабигасы әлеге мәркәз вәкиле белән беркайчан да туган була алмыйдыр. Холык башка, гамәл башка боларның.

Монарчы да шәһәрдә хатын-кызлар хәрәкәте оештырганнар иде. Аны оештыручылар, билгеле, читтән ярдәмгә жибәрелгән коммунистлар, ир-ат халкы булды. "Ана" жәмгыятен дә ирләр оештырып, дилбегәне хатын-кызлар кулына тапшырдылар. Тик, өмет иткәнчә, Хивада бу хәрәкәтләр дөрләп кабынып китмәде. Бүген сүнәм, иртәгә сүнәм дип, пыскып кына азапланган хатын-кызлар хәрәкәтенә, Жамал килеп киткәч, май сиптеләрмени, шәһәрдә пәрәнжәгә каршы төркемнәр төзелеп, инде урамда пәрәнжәгә ябынмаган мөселман хатын-кызлары да күзгә ташлана башлады. Онытырлык түгел иде аны.

...Имамнар исә, Әхмәтсафаның сүзләреннән жилкенеп киттеләр, һаман гәп куерталар.

—Барлык милләтләр дә ил-көн алдында тигез булырга, үзе теләгәнчә көн итәргә тиеш! Ленин шуны гәпәрде. Без моны аңлыйбыз. Ә менә нигә дип мөселманга каныга бу урыс, һич төшенмибез, нугай баласы ничек уйлыйсың, ә? Инде әмирдән яздык, халыкны зар елатып, хәкәрә китереп, дәүләтебезне таркаттылар, мәчетләребез изге гамәл—садака-зәкәт алудан мәхрүм калып баралар. Һәр нәрсәдә тикшерү, һәр тиенгә ун тиен арттырып салым салына, кая бара бу дөнья? Әнә урыс теләсә нишләсен чиркәвендә, носариларда безнең эшебез юк. Аларның якшәмбесе—ял, безнең газиз жомгабыз—ял булсын. Аннан ял көне дип, мөселман беркайчан да кул кушырып утырмады, жомга көнендә фарыз гамәлләрне кылгач, ижтиһат итәргә тотына ул. Носарилар дуңгыз урынына эчеп ауный ул көнне. Сез, балам, мөселманны шушы носарилар хөкеменә төшермәкче буласызмы? Бер динне күтәреп, икенчесен юкка чыгарырга маташкан дәүләттән риза имәс без. Акылыгызга килегез, алар коткысына ияреп кагылмагыз мәчеткә, хатын-кызларыбызны хурламагыз йөзләрен ачтырып.

Нәмәхрәм эшкә өндәмәгез... Урыслар мәҗбүр итми бит безне бу эшләргә, үзләрен мөселман дип санаучы, асылда, көфергә сатылган адәмнәр мәҗбүр итәләр. Әйт әле, нугай баласы, коммунистның мөселманы, носарие, динсез-имансыз иблисе буламы?

Әхмәтсафа аптырап калды.

Имам моны сизеп, "һөҗүмгә" күчте:

—Син үзең мөселманмы, балакай?

—Мөселман дидем шикелле.

—Фиркалыдамы?

—Фирка әгъзасы...

—Димәк ки, син мөселман коммунисты?

—Шулай булып чыга. Үземне денсез-имансыз кешегә санамыйм.

—Мәчеткә йөрмисең, намазга басмыйсың, фарызларны үтәмисең, нинди иман турында сүз алып барасың, төшенмим...—Имамның тавышы ачулы иде.

—Без, коммунистлар, иман калебтә дип саныйбыз, ә мәчеткә бару, намазга басу мәсьәләсенә килгәндә, дөрес, коммунист буларак, бу эшләрне фарызга санамыйм.

—Урыс коммунисты чиркәүгә барамы?

—Дингә барлык коммунистларның да карашы бер төрле. Мин уйлаганча...

—Юк, балам, син уйлаганча уйламый ул носари коммунисты. Үзенең сүзе дөрес, синеке хак түгел дип уйлый ул. Син иблис-шайтан коткысына бирелеп, башыңны урыс куенына тыккансың. Ходай сине зиһеннән айерган. Әгәр урыс дәүләтенең кануннары шәригать кануннары белән яраша икән, кемнән куркып ятасың, ник мәчеткә йөрмисең?..

—Бу хакта әйттем инде...

—Телең шәп сөйли дә, күңелең каралыгын каплый алмый шул. Тагын бер кат уйла әле, менә син фирка тыя дип, җомга көн ял итмисең, димәк тәмам динсезгә әйләнеп беткән мөселман коммунисты буласың әйеме. Носари коммунисты исә, үз дине өндәгәнчә, якшәмбе көнне, ягъни воскресенье көнендә, Гайсә пәйгамбәрнең кабат терелгән көне дип ял алып, тыштан күрсәтмәсә дә, эчтән, калебе кушканча, диндәшләре белән бәйрәм итә. Хәзер инде шуңа башка диндәге кешеләрне дә өнди, көчли, мәҗбүр итә. Димәк ки, шул рәвешле мөселман калебенә дә носарилык иңә, ул шул канунга буйсынып яши башлый дигән сүз. Хаклыкмы бу? Ленин юлы шулмы?

—Уйлашырбыз, уйлашырбыз... мөхтәрәм имамнар,—дип кенә җавап кайтара алды Әхмәтсафа.

—Ай-һай,—диде көрсенеп баш имам, урыныннан кузгалган көйгә.— Сиңа, нугай баласы, уйларга калдырдылар микән инде носари-коммунистлары. Чегән арбасына таккан дегет чиләге шикелле, ияреп кенә йөрүчеләр түгел микән сез, балакайлар... Адашуыгызны үзегез дә төшенмисез, ахры...

Әхмәтсафа кулына төшкән документны тотып шактый йөрде. Тик аның сүзләренә колак салучы булмады. Барысы да округ комитеты циркулярына буйсынып эш итүне хуп күрделәр. Ял көне итеп якшәмбе көн игълан ителде. Ә РСФСР конституциясен шәригать кануннары белән туры килүен раслап Казанда хәзерләнгән документка килсәк, Мәскәү аннан күптәннән ваз кичкән иде инде—Ленин вафатыннан соң ук. Моны, әлбәттә, Әхмәтсафа белми иде әле...

* * *

Мондый рәхәт, җайлы тормышта яшәүне Әхмәтсафа онытып бара иде инде. Бирәм дисәң колына, чыгарып куяр юлына. Шәмсиягә нәкъ Каргалыда дәшкәнчә, "инәй" дип дәшә ул. Үги әнисенең күңеленә хуш килә торган сүз булып чыкты ул әнкәй, инәй дигән сүзләр. Инәй сүзен ишеткән саен яктыра, канатланып, очынып китә. Хатынындагы әлеге

үзгәрешне Фәтхулла да сизә һәм Әхмәтсафаны үзләренә яшәргә алып кайтуына сөенеп бетә алмый. Ул гомерен эштә үткәрә, өйгә кайтып ризык җыеп китә алса хуш, кайчакта кайтып керергә өлгерми, артыннан килеп тә җитәләр. Әхмәтсафа исә төшке ашка да өйгә ашыга, үги инәй хәстәрләгән ризыкларны авыз итеп, хәл алып китәргә гадәтләнде. Кич, эшләре соң гына тәмамланган чаклар да, якындагы тулай торакка кереп кунарга мөмкинлеге булса да, шәһәрнең аулак почмагындагы Фәтхулла фатирына кунарга кайта. Бу хәлгә Шәмсия бигрәк сөенә–Фәтхулла өйдә булмаган төннәрне үткәрү кыен аңа. Куркып, шомланып чыга төнне. Әхмәтсафа бер дигән иптәш–басынкы, тыйнак холыклы. Андый-мондый көтелмәгән хәл килеп чыкса, Шәмсия күреп калды–егетнең мендәре астында револьверы бар, бер дә җибәп төшәргә ошамаган, Шәмсияне дә, үзен дә яклый алыр, боерган булса.

Шәмсия, ни хәл итсен, Ходай бәби алып кайтудан мәхрүм иткән хатын, гел Мостафа агайның балаларын–үзенең үги улларын, теп-тере зәңгәр күзле Бибкәйне сөйләп, истәлекләр белән юанып гомер үткәрә монда. Ике сүзнең берендә Каргалыны, анда үткән тормышын сагынып телгә ала. Югыйсә, сагынырлык тормыш кичердеме ул анда, җә?.. Туып-үскән яклар сагындыра икән шул. Анда күргән авырлыклар онытыла, тигәнәге гөл булып күренә башлый.

> Ефәк тә генә билбау чите ука,
> Чишәсем лә килми билемнән.
> Туып-үскән илләр алтын бишек,
> Никләр генә киттем илемнән?..

Ялгыз калса, күрше-күләнгә ишетелмәс итеп, гел шушы җырны суза ул.

Әхмәтсафаның Хивага килеп, истә-уста юкта үзләрендә яши башлавына сөенде ул. Мостафа вафатыннан бирле, хатынның күңелендә авыр таш ята. Мостафаның үз-үзенә кул салуында хатын үзен гаепле санап яши, шул чаклар исенә төшә дә үзен каһәрли, битәрли башлый, күпме генә акланырлык сәбәпләр эзләсә дә, андый сәбәпләр юк, була да алмый: ул, никахлы, ире Мостафага хыянәт итте, шул хыянәт аркасында Мостафа балаларын калдырып, элмәккә менде. Белгәндер, сизгәндер хыянәтен. Мостафаның күңеле бик нечкә, үтә сизгер кеше иде ул. Урыны җәннәттә булсын дип тә тынычлана торган гына түгел, китап мордар киткән кешене яратмый бит. Аңлашырга дисә, эч серен кемгә сөйли ала, кемгә нәрсә дип аклана ала соң ул? Ялгыз калган чакларда бу хакта еш уйлана Шәмсия. Кабат үткәннәргә әйләнеп кайта.

Фәтхулланың үлү хәбәрен алгач, бәгырьләре өзелеп төшкән сыман булды, хәсрәтен таратмак булып, белгән догаларын укып көннәр үткәрде. Кайгысы таралмады. Ятим-җилпеләргә хәерләр өләште. Хәсрәт уты һаман күкрәген яндырды. Ялгызлык бәгырен телгәли иде, кан-яшь түкте, газапланды, тик үзенә юаныч таба алмады. Шәмсиянең җанын саташтырган нәрсә тагын шул иде–көн-таң атса турларында Вәлкәй хаҗи чуала башлады. Кара-каршы очрашкан чаклары да булды. Вәлкәй хаҗиның әйткән һәр сүзендә ниндидер киная ята, һич кенә дә ихлас кайгыру, яшь хатынның хәсрәтен догалар белән җиңеләйтү түгел, киресенчә, бу дөньяда ялгыз гомер итүнең авырлыгын сөйләп күңелгә вәсвәсә артыннан вәсвәсә салды, тол хатынга ирсез яшәүнең харам икәнен, бу хәлне китапның бер дә мактамавын тезепме-тезә торды. Үзенең күзләре очкынланып китә, хатынга күтәрелеп караган саен хаҗиның авызына сулар килә. Вәлкәйнең майлы карашын сизгән саен, Шәмсия үзен төпсез упкынга очкан сыман хис итә. Әйе, бу зур дөньяда ул япа-ялгыз, ни яклаучы, ни хәлкәйләрен аңлаучы булмаячак иде аның. Ә яшәргә кирәк. Ул әле ять-яшь хатын, кулы белмәгән һөнәр юк, кем белер кадеренне

дә, кемнәр сине юатыр, иркәләр?.. Әчтән хәсрәт кимерә. Башның зиһенсез чагы. Дөнья гаме калмады, алар Фәтхулланың үлү хәбәре белән очып-тузгып юкка чыгып беттеләр. Вәлкәй хажи, әрсезләнеп, өйгә үк кереп йөри башлады. Аны уйлаган ниятеннән тотып торырлык бер көч тә югын чамалый иде инде хажи. Хатын зиһене уянып, яшь түгә-түгә менә шулар хакында уйлады. Вәлкәй хажи аның саен нәфсесен яшь хатынга сузды, жай чыккан саен, тол бичә янына кагылып, аның күнелен жәрәхәтләп чыга торган булды. Һаман ялгыз яшәүнең кыенлыгын, тол яшәүнең читенлеген тәкърарлый, бу хәлне дошманына да күрсәтмәсен дип, дымлы иреннәрен ялмап куя. Ялгыз хатыннарга шайтан ияләшә икән, житмәсә. Тол хатын, үзе дә сизмәстән, куенына иблис ияләштереп, янадан ир-ат дигән сүзне ишетәсе дә килми башлый икән. Һи-и, жүләркәй, иблис-шайтан тол бичәләрне эзләп кенә йөри, тол хатын булса, аларга бернәрсә дә кирәкми. Шулар белән женләнеп тик ята ул андый хатын. Дөнья гамен оныта, сүзенең тәме бетә. Монысы инде Шәмсиянең Вәлкәй хажига ачылып китеп дәшмәвенә, сый хөрмәт күрсәтмәвенә ишара иде. Вәлкәй, берзаман, авызларын чыпылдата-чыпылдата Шәмсияне үзенә яшь хатынлыкка димли башлады, өрмәгән жиргә дә утыртмаска вәгъдәләр яудыра, балда-майда гына йөздерермен, дип ант эчә иде. Шәмсиянең, беренче мәлдә, башы әйләнеп китеп, чарасызлыктан ни хәлләр кылырга белми йөрсә дә, аңына килеп, Вәлкәйнең азгынланып, тәненә үрелүенә хурланып, әрнүле-каргышлы жаваплар кайтара башлады. Берсендә, аны табагач белән төрткәләп үк өеннән куып чыгарды. Үзенә йөз тотып, табагач күтәреп, ажгырып килүче хатынны күреп, эшнең житди икәнен аңлаган Вәлкәй, хәзер үк чыгып китмәсә, бу таза, мул күкрәкле хатын кулындагы табагачтан жан тәслим кыласын сизеп, ишеккә атылды. Бу мәлдә аны башына ураган жыйнак чалмасы гына коткарып кала алмавы көн кебк ачык иде. Жил капкадан чыгып югалганчы Вәлкәй һаман бер сүзне тукыды: "Иблис коткысы, шайтан кергән моның куенына. Беткән бу хатын, тәмамсы эздән чыккан, Ходаем үзең сакла!" Вәлкәй хажиның болай йөрүе, туктаусыз иблис, шайтан, коткы дип сөйләнүләре хатынның тынычлыгын алган иде инде. Эш белән көн үтә, кич житеп, жиргә караңгылык инә, йончып бетеп йокларга ята, салкын түшәгенә баш төртүенә, колагына ят тавышлар керә башлый: жил әле тәрәз капкачына кагылып китә, әле түбә камышлары белән шаярып ала, әле урам капкасы белән әвәрә килә. Колак төбендә—Вәлкәйнең жангa вәсвәсә, шом салып өлгергән иблис, шайтан дигән сүзләре... Ихатада кемдер йөргән кебек, болдырда нәрсәдер кыштырдагандай тоела. Шулай ята-ята ул хыялланыр дәрәжәгә житә, болай ялгыз башы яшәп булмавын ачыктан-ачык тоя. Нидер эшләргә кирәк. Башын бу бәладән ничекләр итеп коткарырга кирәклеген уйлап, көч-хәл белән төнне үткәрә. Таң сызылгач кына черем итеп ала, яктыра башлауга инде аяк өстендә. Тол хатынга дөньяны алып бару өчен икеләтә көч сарыф итәргә кирәк шул...

Вәлкәй берничә көн тынычлыкта калдырса да уй-ниятеннән кайтмаган иде, көн саен диярлек Шәмсия бусагасын яучы карчык таптый башлады. Бу эшкә шомарып беткән карчык Шәмсиянең башын шундый әйләндереп ташлады, яшь хатынлыкка китмәс өчен бер чара да калмагандай тоела иде инде аңа. Вәлкәйгә чыгар дәрәжәгә өлгереп килгәндә, урамда Мостафаны күреп, әлеге күз буулардан айнып китте сыман. Хатыны вафатыннан соң бөтенләй басынкыланып, төсен ташлап йөри иде ир. Ходай шушы мәлдә аның юлына тикмәгә каршы төшермәгәндер Мостафаны. Ирнең дә үзе кебек үк ялгыз жәфа чигүен уйларга гына өлгерде ул. Һәм... иләсләнгән зиһене уйнап алды, башында көтелмәгән ният туды.

Нигә соң әле ул шул Вәлкәйнең эзәрлекләвенә түзеп, дәшмитынмый елан авызына кереп бара ул? Вәлкәйдән ул ун өлеш артык кеше—Мостафа аңа күз салмаслыкмы?!. Яшь аермасы дип тә ут йотасы юк, Вәлкәй Мостафага караганда өлкәнрәк яшькә, гәүдәгә аннан

мәртәбәлерәк булса да, төскә-биткә Мостафа янында бер сасы кәжә тәкәсе сыман гына бит, ачуым да бер килмәгәе. Ялгыз ирнең тормышы житеш, балалары үсеп килә. Шәмсияне афәттән йомып калырдай бердәнбер чара—үзенә Мостафадан яучы жибәртергә ирешү. Тик ничек итеп? Ярты көн шул уйны бөтерчәләп йөри торгач, әмәлен тапты—Тайфә түти!.. Менә кем аны аңлар, менә кем ана булышыр...

...Тик Мостафа нигәдер ана күнелен сала алмады. Болай караганда бар да хатын теләгәнчә булды: яучы да жибәрде, йолага туры китереп өйләренә алып та кайтты. Әмма ирнең басынкы, боек табигате үзгәрмәде. Нәрсәдәндер тартына идеме, әллә беренче, вафат булган хатынын оныта алмадымы, була бит жырдагыча, гомерлеккә бердәнбер ярга гашыйк булып, нинди генә хәлләргә тарса да шуны мәнге оныта алмыйча яшәүче изге жаннар. Мостафаның үзенә карата читенсенүле самими мөнәсәбәтен яшь хатын шулай гына аңлата ала иде. Югыйсә, балаларны да үз итте, Бибкәйне бөтенләй үз кызы сыман якын күреп, куеныннан да чыгармады. Йорт эшләренә чат кулы ябышып тора, өйгә нур инде Шәмсия бусаганы атлап кергәч, әмма икесе дә көткән жан жылылыгы, бер-берсен үз итү була алмады.

Бу хәлне Шәмсиягә караганда, Мостафа авыррак кичерде сыман. Хатын сизеп тора, ир үзе дә әлеге салкынлыкның сәбәпләрен эзли. Бәргәләнә, үз-үзен эчтән ашый иде. Өзгәләнүен сиздерергә теләмичә, жүнләп өйгә кайтып кермәве дә шул сәбәптән иде булса кирәк. Жаны тартмаган хатын яшәгән йортка кайсы ирнең кайтып керәсе килсен?... Ул мең хәйлә, сәбәп таба, өйдән чыгып китү жаен гына карый иде. Олы уллары Госманны Оренбурга, Гомәр абыйсына кибет-сәүдә эшләренә өйрәтергә бирде, Гомәрханны үзе белән казах далаларына тире-яры жыярга алып чыгып китә... Шәмсия исә өч бала—Әхмәтсафа, Әхмәтхан, Бибкәй белән айлар буе Мостафаның кайтуын көтеп, хужалыкны алып барырга тырыша. Әхмәтсафа бөтен күнелен укуга салган малай, итагатьле, ярдәмчел булса да, күп вакыты сабакка китә. Йорт эшләрендә булышырга вакыты юк диярлек—көне буе мәктәптә, кич кайтса, дәрес хәзерләргә тотына. Сабактан туймас бала булса да булыр икән. Бикләгән-ятлаган шигырьләр, бәетләр укып, Шәмсиянең күнелен күреп тә ала, әмма ялгызлыктан төксегән күңелгә бу гына житми шул. Әхмәтхан белән Бибкәй кечкенәләр. Аларга тамак тук булсын да, уйнарга булсын. Кич эшләр беткәч, балалар кече өйдә йокларга яталар. Шәмсия ак өйдә берүзе, салкын түшәк кочаклап ята.

Бер кайтуында, Шәмсия Мостафага зарларын түгә. Йорт эшләре күп, аның өстенә мал-туарны карап өлгер—ялгыз башын ничек житешмәк кирәк?.. Хатынының елар дәрәжәгә житеп чәпчегәнен тыңлап торды-торды да, дәшми-тынмый чыгып китте Мостафа. Өйлә намазына дип мәчеткә киткән жирдән, үзе белән яшь егет ияртеп кайтты. Ул Тайфә түтинең улы—житкән егет Хәлфи иде. Шул көннән йортта хезмәтче булып эшли башлады егет.

Мостафа тагын сәфәргә чыгып китте. Ни эшләсә дә үз-үзенә зарланып йөрүдән туймаган бу чибәр һәм көче ташып торган егет белән Шәмсиянең аралары, көтмәгәнчә, якынаеп китте. Бөтен эшне диярлек бергә башкаргaнлыктан, егеткә тиз ияләнде Шәмсия. Көннәр буе икесе бергә, ике яшь жан бер-берсенә тартылды, бер-берсен ярты сүздән аңлый башладылар. Еш кына карашлар очраша, очрашкан мизгел арасында күзләр бер-берсенә иң матур, иң ягымлы хисләр озатып өлгерәләр, кыскасы, яшь аермасы өч-дүрт елдан артмаган бу ике мәхлукның йөрәкләрендә чынлап мәхәббәт уты кабынып өлгерде. Гыйшык-мыйшык уеннары уйнап өлгерделәрме, юкмы, Шәмсия сизми дә калды, эшләр инде "кыйшык"та иде. Фәтхулласына бәби алып кайта алмады хатын, Мостафадан да балага узмады, күпме чуалып, Хәлфетдиннән дә йөкле булмады. Әмма ире өстенә хыянәт итеп яшәп булмавын аңлап, Шәмсия аерылу хакында уйлап йөри башлаган иде. Хәлфетдин, үзе дә күп ирләргә

хас булганча, көймә комга терәлгәнче, ягъни, кеше теленә кереп хур булганчы, авылдан чыгып олагу хакында уйга кергән иде, нәкъ шул чагында Шәмсия куркып калды кебек, эшне тиз генә хәл итә алмый азапланды. Ул арада дөньясы болганып китте. Егет үзенчә котылу чарасын тапты—кызылларга ияреп китмәкче булды. Шактый тәвәккәлли алмыйча йөрде. Акларга иярергә күңеле тартмады, кызылларның командиры Хәйбри усал иде шул. юлында очраган егет-җиләнне сөзәктереп ала да, "дезертир" дип, таш келәткә ябып куя. Каршы сүз әйтүче булса, Сакмар буена чыгарып солдатларына аттыра. Аннан Усманов дигән ягымлы комиссар пәйда булды. Ул килгәч, Хәлфине Шәмсия үзе үк кызылларга кушылырга күндерергә дип, егет яшеренеп яткан төшкә—сәндерәгә китте. Аларның өстенә шунда килеп чыкты инде Әхмәтсафа... Аңынчы да Госман белән бәрелеш булып алган икән, бу хакта аңа өстән-өстән генә әйтеп өлгерде Хәлфи. Бүтән чара юк иде, ике егет бергә Усмановка ияреп китеп бардылар. Менә бит тормыш ничек ул. Госман да кайтмады, Хәлфетдиннән дә хәбәр килмәде. Имеш, кайсыдыр якта аклар белән бәрелештә һәлак булган диделәр диюен. Тик Фәтхулла белән булган хәлдән соң андый сүзләргә ышанмый иде инде.

Шул көннән соң Шәмсия Әхмәтсафаның күзенә туры карый алмыйча йөрде. Болай озак яшәп булмый, Мостафа белән аерылышу хакында ныклы карарга килгән иде ул. Ләкин сүз башларга һич җай чыгара алмый интекте. Шулай бәргәләнеп, җаны кибеп көннәр үтә торды. Тора-бара, Әхмәтсафаның авызыннан бер сер дә чыкмавына ышаныпмы, Шәмсия тынычлана төште, үз хәленә күнекте, аерылу хакында сирәк уйлый башлады. Аңа барыбер инде, яшәүнең яме киткән иде. Хәлфетдингә дә күңеле суына башлаган кебек булды. Җитмәсә, киткәннән бирле хәбәр бирми, җүнсез.

Көннәрнең берендә... Фәтхулла кайтып төште. Җен арбасы. Ничә еллар тилмереп көтте аны Шәмсия, ул бер хәбәр салмады. Үлде хәбәрен ишеткәч, аның рухына күпме дога кылынды, бер шәкерткә мул гына акча биреп, Фәтхулла солдат рухына Коръән чыгарды хәтта. Ә ул исән-имин, әллә кайларда совет власте урнаштырып йөргән, имеш.

Ирнең кайтуын ишетү белән, ничек шулай булгандыр, алдын-артын уйламыйча, Шәмсия аның янына йөгерде. Елый-елый үзенең нинди хәлгә төшкәнен сөйләп бирде. Соңыннан Фәтхулланың "үлемен" Вәлкәй хаҗи оештырганлыгы билгеле булды. Фәтхулла бу хәлләрдән аптырап, алга табан ничек яшәргә дип уйланып, хыялланып йөргәндә Мостафа үлеп китте. Фәтхулла бер авыр сүз әйтмәде, хатынның яралы бәгыренә тоз сипмәде, Шәмсияне кире өенә алып кайтты, никах яңартып яши башладылар. Шул ук вакытта Мостафаның балаларына да каты кагылмады. Бибкәйне үз кызыдай яратты ул, Әхмәтсафа белән Әхмәтханны да какмады. Әгәр ачлык елны Фәтхулла булмаса, бу сабыйлар исән кала алган булырлар идеме икән, Шәмсия ачык кына җавап бирә алмый... Миһербанлы, игелекле, шул ук вакытта курку белмәс кеше шул Фәтхулла.

Шулай да хатын Мостафаның үлемен авыр кичерде. Шушы көнгә кадәр ирексездән, үзен гаепле сизеп, күңелендә каты төер йөртә...

...Әхмәтсафа да әтисенең үлемендә үзен гаепле итеп яши. Яшьлек җүләрлеге дип атаргамы аны, олылар әйтмешли, әткәсенең башына ашкынуы микән, Гает көннәрендә узынып алдылар шул ул елны. Кич яшьләр уены үткәрделәр. Яшь-җилкенчәккә нәрсә, кайда яңалык, кайда кызык—алар шунда. Ул кичне каравыл өе яшьләр белән тулы иде. Шәһәрнең якынлыгы, анда кайнаган мәдәни тормышның сулышы Каргалыга да килеп ирешә, яшьләрне җилкендереп, үзенә тартып тора иде. Халык мондый үзгәрешләрдән бөтенләй үк бихәбәр түгел иде, комсомолларның кыланышына артык чәүчәләкләп йөрүче дә булмады кебек. Волкомнан килгән вәкил кайнарланып яшьләрне Гаеткә бармаска үгетләде, егетләр риза булып, соң гына өйләренә таралыштылар.

Иртән шул билгеле булды—ниндидер бәндәләр мәчет ишекләрен

аркылы такталар белән кадаклап чыкканнар. Югыйсә, барысы да белеп торалар: гаеткә каршы төндә мәхәлләнең иң диндар картлары мәчеттә төн уздыралар, тәһлил әйтәләр, китап кушкан йолаларны үтиләр. Әлеге көферлекне яшьләргә, аларны оештырган Саттар, Әхмәтсафа, Рәхимгә сылтадылар. Яшьләр үзләре аптырашта иде, бу эшне кемматаштырганын бик беләселәре килде килүен, тик очына чыга алмадылар. Артык зурга җибәрмәскә тырышып, эзләп-шаулап йөрүдән авыл түрәләре үзләре үк тыйды яшьләрне. Зариф абзый аны, "провакация", кешеләрне советка каршы кую өчен махсус оештырылган эш дип атады. Тик бу эшләрнең барысы өчен дә дин кардәшләре алдында нигәдер Мостафага—Әхмәтсафаның әткәсенә җавап тотарга туры килде. Вәлкәй хаҗи аны каргый-каргый мәчеттән куып чыгарды, бичара әтисе, икенче мәхәллә мәчетенә барып Гает намазы укып кайтты. Әле шушы хәлдә дә Әхмәтсафага күтәре-леп бәрелмәде. Улына каты-каты карап алуыннан, бүген булмаса, иртәгә, әмма нык кына сөйләшү булачагын аңлап алган иде егет. Эчке киеренкелек белән шул сөйләшүне көтеп йөргән чакта, үлем килде алар өенә... Моны егет авыр кичерде, чөнки Вәлкәй хаҗи, ачыктан-ачык, халык алдында: "Мостафаны коммун малае харап итте,"—дип кычкырып йөрде.

...Әйе, уртак кайгылар, уртак кичерешләр һәм хәтта... уртак серләр берләштерә иде Шәмсия белән Әхмәтсафаны. Әхмәтсафа үзләрендә яши башлау белән үги әнисе сеңлесе Бибкәйне дә үз яннарына алдыру хакында сүз кузгатты. Моны Фәтхулла күтәреп алды.

—Хивада кызлар мәктәбе бар. Аны тәмамлагач, кызлар гына укый торган педагогия училищесына бирербез.—Һәм инде хәл ителгәнгә санап, кистереп әйтте.—Баланы җай чыгу белән алып киләбез. Йөрмәсен ятим булып, каңгырап...

Җай чыгарга тора—Әхмәтсафа инде ел ярымнан артык ялсыз эшли иде, ана отпуск бирергә булдылар. "Отпуск" дигән сүзне беренче мәртәбә ишетүе булганга, башта Әхмәтсафа аптырабрак торган иде, вакытлыча гына килгән кешегә дә мондый ял биреләме, янәсе, ана тиз төшендерделәр, сине монда вакытлыча килгән кешегә бирәү дә чутламый. Син инде зур кеше, округта фирка җитәкчеләренең берсе, басылып кына эшләргә вакыт сиңа, канса да канис!.. Вакытлыча түгел дип саныйлар икән, анысы аларның эше, әмма Әхмәтсафаның күңеле Каргалыда—туганнары һәм, әлбәттә, Оренбурда калган кара күзле сөеклесе Рабига янында. Ул монда мәңгелеккә килмәде, үзе дә сагынудан кибә башлады, аны да сагынып көтеп торучы кеше бар, аның җаны шунда ашкына, күңеле шунда талпына иде.

Ә Бибкәйне алып килергә кирәк. Фатхулла абзый дөрес әйтә. Укытырга, кеше итәргә кирәк бердәнбер сеңелләрен.

* * *

...Каргалыга кайтып килгәч, Әхмәтсафа шактый вакыт кадерле истәлекләр, хисләр эчендә йөзде. Шунысы әйбәт—ул август ахырларында гына кайтып җиткәнлектән, Рабига белән очрашып, сөйләшеп, вәгъдәләрне янә бер мәртәбә ныгытырга өлгерде. Чөнки Бибкәйне алып китәргә кирәк, шуңа Каргалыда озак юана алмый иде ул. Бибкәйгә укый башларга вакыт, болай да яңа ил, яңа иптәшләр, яңа вәзгыятькә өйрәнү кыенга килер. Әгәр укуга соңга калып, иптәшләреннән артта калса, тагын да авыр булачак.

Рабига Әхмәтсафаның ашыгуын дөрес кабул итте. Тик егет шуны тойды: егерме яшькә җитеп килгән, бүген-иртәгә педагогия техникумын тәмамларга йөргән сылу кыз, билгеле, әллә кайда, үзбәк дусларга совет хакимияте ныгытуда ярдәм итеп йөргән егетне көтеп ятмас, әгәр алдагы елга кайтып, кызны әләктереп калу, үзенеке итү мәсьәләсендә тәвәккәллек

күрсәтмәсә, көт тә тор, Рабигадан коры калачак Әхмәтсафа. Рабига тирәсендә чуалырга маташкан шактый абруйлы егетләр барын ишеттереп өлгерделәр инде. Кызның оялчан гына үзенә карап, күз сирпеп алуларында да бу хакта ачык ишарә сизде ул.

Дус-ишләре инде шактый үзгәргәннәр, алар Әхмәтсафаны житди егеткә санныйлар. Санарсың да. Элекке мутлыклар кимегән, сүзен үлчәп кенә сөйли, һәр вакыттагыча, һәр нәрсәгә үз карашы, үз бәясе бар, түрә булырга да өйрәнеп килә, ахрысы. Шулай да үзенекен генә тукып тормый, башкаларны тыңлый белә, аннан соң гына сүз әйтеп куярга ярата. Иптәшләренен үзенә карата хөрмәт белән карауларын тоеп, ул бераз кыенсына да иде. Дуслары да төшеп калган түгел ич: Муса Жәлил губернада күренекле шагыйрь, яшьләр житәкчесе, аны белмәгән, чыгышларын тыңламаган кеше юктыр якын-тирә төбәкләрдә. Муса һәрвакыт уку, үсү хакында сөйли. Гайшә Мөхәммәдова Мусага шактый ачуланып хат язган, ул шуңа бераз үпкәләп тә йөри бугай. Аңлашыла сыман да. Муса Казанда чакта Гайшәне үз янына чакырган: "Кил, укуыңны монда дәвам ит, бергә-бергә күңелле булыр, мин инде Казанда танылган шагыйрь, абруй бар, исем бар,"—дип кызның башын әйләндереп бетергән. Гайшә ТИНОны тәмамлау белән, ике дә уйламый, Казанга чыгып киткән. Муса исә, юллама буенча, Оренбур губкомы карамагына кайтып төшкән. Хәер, икеөч ел туган якларында эшләп, авыл хужалыгын өйрәнергә ниятләве хакында ул Гайшәгә язып торды, башкалар да белә иде. Тик нигәдер Гайшә белән юллары аерылды да куйды шул. Муса Әхмәтсафага туп-турысын әйтте: Казанда белем алырга, укырга була, әмма эш ягына килсәң... Аны юкка гына Такташ: "Казан—фәхиш шәһәр,"—дип язмаган инде.

Казан—көнчелек, бер-берсен күрә алмау, иң якын дуслары дип йөргән кешеләрне сату оясы. Төркемчелек бик көчле. Төркемнәр үзара дөмбәсләшә, бер төркемдәгеләр дә бер-берсенә ышанып бетмиләр. "Казанда авыр атмосфера, авыр,"—дип көрсенеп кабатларга ярата яшь шагыйрь. Саттар Ишбулдин Үзбәкстанда икән, аның белән дә күрешеп өлгерде Әхмәтсафа. Саттар мәркәздә эшли. Дәрәжәсен белеп сөйләшә һәм эшеннән бик канәгать иде, ахрысы, алдагы ният-хыяллары хакында ләм-мим, гел үзенең эше, иптәшләре турында сөйли, тиздән өйләнеп тә жибәрү икән исәбе.

Рабиганың үз кайгысы. Әтисе, дуамалланып, әнкәсе белән энесен өеннән куып чыгарган. Кызларының уку йортларында белем алуларына һич риза түгел, ата-баба йоласын, гореф-гадәтләрне аяк астына салып таптауларына әнисен—Хәлимә абыстайны гаепли икән. Быел жәйге ялы ял булмаган Рабиганың, йортсыз-жирсез калган әнисен юатып, жан асрарлык куыш табып, аз-маз кул эшләре белән утырып, теккән-чиккән, аларны базарда сатып акча эшләгән, әниләренә ярдәм итеп, булышып килгән. Инде алар өчен борчыла, алар өчен кайгыра. Әхмәтсафа кызның сыктауларын артык тыңлап тормады, үз сүзен өзеп әйтте:

—Әнкәнне, иң элек Каргалыга китерик, Гомәрхан белән сөйләштем, торырга куыш булыр, абый кешенең өе иркен, эше дә табылыр, һәрхәлдә, тамаклары ач, өсләре ялангач булмас. Калганын мин кайткач хәл кылырбыз,—диде.

Рабига егетнең сүзләренә куанып, беренче мәртәбә аның күкрәгенә сыенды.

—Нишләргә белми аптырап беткән идем шул,—диде ул, күз яшьләрен егеткә күрсәтүдән кыенсынып йөзен читкә борды.—Киңәшим дисәм, апам Жамал Урта Азиядә... Безнең янга кайчан кайтасын үзе дә белми.

"Жамал" исемен ишеткәч, Әхмәтсафа Хивага килеп киткән мут, чая хатынны искә төшерде. Рабигадан сорамакчы иде. Нәкъ Хивадагы кебек үк күңеленнән Жамал белән Рабиганы чагыштырып карады да, ачкан авызын кире япты. Ничек барысын да сөйләп торасын инде. Рабига әллә ни уйлар тагын. Жамал ачыктан-ачык егет белән кызыксынды бит. Форсат чыккан саен хатынның үзенә утлы караш ташлап алуын,

егетне астыртын эзэрлеклэвен хэтерендэ янартты да, юк, Рабига белэн Жамал һич кенэ дэ апалы-сенелле, бертуганнар була алмый, дигэн нэтижэгэ килде. Шулай булгач, хатын-кыз хакында сөйлэп, кызның күнелене вэсвэсэ салуның кемгэ хажэте бар? Мондый эшкэ Муса һэвэс, ул сөйлэргэ ярата хатын-кыз хакында. Рабиганың исэ күнеле болай да китек, хэле уеннан үткэн. Яшерен-батырын түгел, Муса Рабигага күз атып, сүз кушып караган каравын, эмма кыз кырт кискэн: "Эхмэтсафага әйтэм, һаман-һаман тирэмдэ тулгануыннан туктамасан, үзенэ үпкэлэ!"— дип, тегене бераз шүрлэтеп тэ куйган. Муса, Эхмэтсафа исемен ишеткэч, сүзне шунда ук сэяси яссылыкка күчергэн, имеш, аны кыз аңлап житкермэгэн, сүз бит яшьлэрне губком тирэсенэ туплау, актив комсомолкалар белэн элемтэлэр урнаштыру хакында гына бара, ул Рабига, мондый эшлэрдэн читтэ тормаска тиеш, активлашырга, үзен күрсэтергэ тиеш. Килэчэк өчен мөһим нэрсэ ул. Эхмэтсафа эле рэхмэт кенэ эйтер, Рабиганың шундый кызыклы, актив тормыш белэн яшэвенэ. Кыскасы, боларны Рабига көлэ-көлэ сөйлэде, эмма егетнең йөрэгенэ ут капты. Муса—хэйлэкэр, күнеленэ ятышлы кыз очраса, кармак салып карамый үтми инде, менэ Ченэкэй өйрэтте аны. "Кызлар алар күлдэге балык, кармак салмый үтмэ,—ди иде ул мэхэббэт турында гэп куерта башласалар.— Элэксэ—икелэнеп тормый, тартып чыгар, элэкмэсэ—жебеп утырма, кармакларыңны ал да, икенче күлгэ кит. Бер дэ борчылма. Бер күлдэ элэкмэсэ, икенчесендэ элэгер. Ниятенэ кергэч, "балык" тотмый кайткан "балыкчы"ны очратканым юк, һэрхэлдэ, кайсы күлдэ балык булуы хакында хэбэрдар йөри ул шэп "балыкчы", кармак салырга жай гына көтэ,"— дип, шырык-шырык көлэ иде.

Рабига—күлдэге балык, кемнэр генэ кармак ташлап карамас, озакка сузмаска кирэк. Эхмэтсафа менэ кыз күнеленэ шик-шөбһэ салмыйм дип, уйлап кына сөйлэгэн була, э кыз исэ, киресенчэ, Мусаның үзе тирэсендэ бөтерелүен эйтеп, егетне бөтенлэй аяктан екты. Ah, усал кыз! Карап торуга оялчан гына, тартынып кына сөйлэшэ. Кирэк чагында үтэ кыю да була белэ икэн, турысын эйтеп, сиздереп куйды: "Чит ят жирлэрдэ күп йөрсэң, колак кагып калуың да бар миннэн. Азамат егет булсаң кыю бул, сирэк-мирэк килгэн хатларыңдагы мэхэббэт сүзлэренэ эреп, вэгъдэ янартып утыру озакка сузылмаска да мөмкин. Кыз кеше—очар кош, вакыты житкэч, оча да китэ. Ходай шулай яраткан безне. Килэсе елга ни дэ булса хэл кыл, тилмертмэ яшь йөрэкне?"

Эхмэтсафа кызның тел төбен яхшы аңлады. Хивага да жилкенеп, очынып, изге ният белэн кайтып китте: килэсе елның язынннан да калмыйча Каргалыга эйлэнеп кайтырга, укырга керүне хэл итэргэ һэм Рабиганың билгесезлек утында януына чик куярга!

...Бу юлы да ул уйлаганча гына барып чыкмады. Кыш та үтте, яз да үтте, Эхмэтсафа инде Рэжэпов янына ун гына кергэндер, тик аны эштэн жибэрү хакында гына һич кенэ дэ уйламый тегесе. Бэхетенэ, Рабигадан хат килеп төште. Кыз үзлэре белэн ТИНОда укыган берничэ кешенең быел көздэн Казанда, Татар коммунистик университетында укый башлаячаклары хакында эйтеп язган иде. Ходай биргэн зирэклеге кушканмы, хат белэн элеге уку йортының адресын жибэргэн иде. Эхмэтсафа күп уйламый, ТКУ житэкчесе исеменэ укырга телэге барлыгын, мөмкин булса чакыру жибэрүлэрен сорап хат юллады. Округ комитетында эшлэп, мондый нечкэлеклэргэ өйрэнэ башлаган иде инде ул. Июль башларында чакыру килде, инде, билгелэнгэн тэртип буенча, аны укырга китүдэн беркем дэ тыя алмый иде.

Моны Рэжэпов та яхшы аңлый иде. Ул Эхмэтсафага бертуктаусыз эш өя, шелтэлэп алырга да күп сорамый, аны хэтта ялкаулыкта, эшне белмэүдэ гаеплэүдэн дэ тартынмый, кыскасы, ничек тэ егетнен укуга карата күнелен суытырга тырыша. Тисэ тиякка, тимэсэ ботакка, ди бит. Ике сүзнең берендэ: "Сине Казанда көтеп торучы кеше юк, фиркага

җүнле-башлы файдасы тимәгән кешенең Казанга да керәге юк. Йөрмә, барма. Казанда сине укырга алмаячаклар,"—дип, егетнен күнелен төшереп азаплана иде. Әхмәтсафа боларның үзенә басым ясау икәнлеген яхшы аңлый иде, үзенең хак юлда икәнлегенә ышанычын какшатмады, укырга китү ниятеннән ваз кичү башына да кереп чыкмады, сабыр итте, түзде, чөнки белә, үзенең вазифалары ул яхшы башкара, мәркәзгә җибәрә торган кәгазьләрне фәкать ул гына җиренә җиткереп яза, әле аның кулы аша үткән, бер генә документ, язу өчен дә мәркәздән шелтә-мазар алганнары юк. Рәҗәпов нәкъ менә шуның өчен дә Әхмәтсафаны җибәрәсе килми. Егеткә талпан сыман кадалды. Кемдер әйткән бит, акылың булса, яхшы эшләвең өчен мактау, рәхмәт сүзләре көтмә. Зирәклегең, белеп эшләвең үз башыңа тимер чөй генә ул. Яхшы эшләүче чүлдә гөлбакча үстергән диһкан кебек—тир түгә, гөлбакча үстерә, аны көннәрдән бер көнне сарык көтүе таптый да чыга. Кемне гаеплиләр дисеңме? Көтүчене түгел, әлбәттә, диһканны сүгәчәкләр, җүнле-башлы сакламадың, дип.

Инде Рәҗәпов, Әхмәтсафа Дәүләтьяровны тотып булмасын аңлап, бераз йомшарган булды.

—Ярый, мәйлең, Казан икән, Казан булсын,—диде ул бер көнне егетне үз янына чакырып.—Без сине тотарга хакыбыз юк. Укуга теләгең көчле икәнлегенне расладың, җитди кеше син, бушка вакыт үткәрмәссең. Укырсың, белем тупларсың, бәлки әле кире әйләнеп кайтырсың. Өйрәнгән яу сугышмага яхшы. Көтәбез, кайт. Син бездә җитлеккән кадр.

—Әлбәттә, әлбәттә, иптәш Рәҗәпов,—диде Әхмәтсафа куанып. Юкка ызгышып, җаны телгәләнүен бер дә өнәми ул.

—Менә килештек тә,—диде Рәҗәпов елмаеп.—Әйбәт кешеләр белән эшләве дә күңелле.—Ул бераз тын торгач, тәрәз янына килеп басты, гадәтенчә, авызына папирос кабып, ут элде, тирән итеп эчкә суырды һәм тәмәке төтенен, нәкъ Ниязовча, пәрдә артына өреп җибәрде һәм көйле генә сүзен дәвам итте.—Бер эш килеп чыкты әле. Сиңа соңгы үтенеч тә дип аңла, фирка фәрманы дисәң дә була, Дүрткүл вилаятенә, Каштау кышлагына барып кайтырга кирәк. Яңа икътисади сәясәт диһканнарга зур мөмкинлекләр ача. Алар дәүләт алып барган сәясәткә ышанып карыйлар хәзер. Безгә шул мөмкинлектән файдаланып калырга кирәк. Диһканнарны аерым яшәүдән йолып алырга кирәк, кооперативлар төзү мәсьәләсен кабыргасы белән кую лазем. Дәүләт хуҗалыклары—совхозлар төзү буенча да әйбәт эшлибез дип әйтә алмыйм. Диһканның зиһененә барып җитәрлек итеп сөйли, үгетли алмыйбыз. Фирка карарларын синнән дә оста аңлатучы булмас дип уйлыйм. Бер кышлакта эш башласаң, калганнарын "и"гә китерү җиңел булыр. Кураның берсенә генә ут элеп җибәр, башкаларына тиз үрли ул.

—Моңа диһканнар ничек карый соң? Алар телиләрме мондый берләшүне? Совхозларга ышаныч юк диләр бит алар. Җирдән аерыласы килми диһканның.

—Фирка тели, фирканың ихтыяры бар,—диде Рәҗәпов мәсьәлә хәл ителгәндәй.—Башка өяз, округларда хәлләрне ишетеп белсеңдер. Инде совхозлар оешканга биш быелтыр, колхозларга берләшү бара. Ә Хорезм аксый. Ике аякка да аксый. Диһканнар белән эшләү ташка үлчим, хатын-кызлар һаман искегә ябышып яталар. Кирәк булса, мисал бар: бер яшь кенә бичә иренә икенче хатын алып кайтырга рөхсәт сорап, тупсаны төшермәде. Бер хатын белән генә яшәү, аның ире өчен хурлык булса, хатыны өчен иң зур кимсетелү икән. Менә аларның совет кануннарын аңлау дәрәҗәсе. Без яңа тормыш төзү хакында лаф орабыз... Уйлап бак, иптәш Дәүләтьяров, Казанда, сабакташларыңа нәрсә дип сөйләрсең, Урта Азиягә ничек килдем, шулай киттем, бер үзгәреш тә булмады, үзем дә булышлык күрсәтә алмадым, дипме?

—Үзгәрешләр шактый, иптәш Рәҗәпов. Күрә белергә кирәк, иң мөһиме, халык тынычланып килә, хезмәткә кайта. Советка шактый ышанып карый, әмма ордым-бәрдем кыланып, бу ышанычны бик тиз

какшатырга мөмкин. Арттан берәү дә кумый, без коммунистик җәмгыятьне мең еллар өчен төзибез. Уйлап, һәр адымны саклык белән атларга кирәктер. Юкса, бер кулыбыз белән төзегәнне, икенче кулыбыз белән җимерергә дә мөмкин ич.

—Сакланып дисең инде син. Саклану—куркаклык билгесе ул.

—Чынлап уйласаң, бернәрсәдән дә курыкмаган кеше үзе куркыныч ул... Андый кешенең җаны үз ихтыярында түгелдер кебек.

—Юкны сөйләп торма инде, Дәүләтьяров. Акыл сатарга оста икәнлегеңне беләм. Шуны анла, мондый акыл фиркага бер тиенгә дә кирәкми. Киресенчә булса, ул аны синең ише акыл иясеннән потлап сатып алыр иде. Алмый бит, димәк, кирәге юк. Демогогия—бар эшне харап иткән иң явыз, мәкерле дошман! Мең еллар буе сенгән дикан күңеленә милекчелек, шуны мең ел буе куып чыгарыйкмы инде? Мең ел түгел, йөз ел эчендә дә әллә нәрсәләр булып бетә бу дөньяда. Тимерне кызуында сугу кирәк. Төшендеңме?

—Сезнең тел төбен төшендем. Тик мантыйкка сыймый, башлаган зур эшебезгә—яңа тормыш кору эшенең мәңгелек икәнлегенә ышанмыйча, ничек яшәргә кирәк, ди?

Рәҗәповның йөзендә нәфрәт дулкыны уйнап алганын күреп, Әхмәтсафа бәхәскә нокта куйды. Аның соңгы көннәрдә генә бу адәм белән нык ачуланышасы килми иде.

—Кайчан китәргә тиеш мин Каштауга? Кемнәр белән юлга чыгам?..— Округ комитеты хезмәткәрләренә вилаятләргә ялгыз чыгу тыела иде, Әхмәтсафа шушы хакта Рәҗәповка искәртте.

Рәҗәпов бераз уйланып торды.

—Башкарма комитеттан иптәк Хуҗаев ике сакчы белән барырга тиеш. Әмма ул ниндидер эшләр белән тоткарлана. Сиңа, күрәсең, үзеңә барырга туры килер. Дүрткүл белән сөйләштем, Каштауда диһканнар комитеты көчле дип ышандырдылар. Комитет рәисе Зәйнетдин әкә. Күргәнең дә бардыр, диһканнар мәҗлесләрендә бик төпле чыгышлар ясый торган адәм. Ышанычлы кеше. Заманында Әнвәр-пашага каршы кулына корал тотып көрәшкән кызыл яугир.

Әхмәтсафа күп сүз куертмыйча, фатирга кайтып, сәфәргә җыена башлады.

Шәмсия, Әхмәтсафаның бер ялгызы җәһәннәм артындагы кышлакка җыенуын белгәч, чак елап җибәрмәде.

—Кая барганыңны чамалыйсыңмы, җүләркәй? Ялгызыңны кем җибәрә? Кемнең нинди үче бар синдә?.. Аяк та атлама, Фәтхулла абыең кайтсын, ул бер җаен тапмый калмас,—дип, өтәләнде сөмсере коелган үги әнисе.

—Бармыйча ярамый, инәй.—Әхмәтсафа, Шәмсияне тынычландыру өчен күтәренке тавыш белән сөйләште.—Өч көннән мәркәзгә хисап тотарга тиешбез. Һавадан алып язып булмый, барырга, күрергә кирәк. Соңгы вакытларда вилаят-кышлакларга чыкмадым диярлек, гел өстәл артында кәгазь язып вакыт үткәрдем. Юлдан кайтып кермәгән кешеләр дә бар, алардан кыен...

—Белмим, белмим,—диде хафаланып Шәмсия.—Өйләдән соң кем юлга чыксын, ди?..

—Минем өчен шулай булуы әйбәт тә. Атым яхшы, монда килгәннән бирле бер ат. Холкы әйбәт, ияләнеп беттек бер-беребезгә. Әллә нинди хәлләрдә дә юл саташтырмый торган зиһенле җан. Затлы мал. Бүген Дүрткүлдә кунам, вилаяттәге эшләр белән танышырмын, аннан иртүк Каштауга кузгалам. Ирәвәнләмә генә барып җитәргә кирәк. Минем бурыч—Каштауда җыен үткәрү, диһканнар белән сөйләшү, халыкның хәлләтен белү. Шул гына, эш син уйлаганча катлаулы түгел, инәй. Иртәгә башка иптәшләр дә килеп җитәргә тиеш, бергә кайтырбыз.

...Сәфәр исә ул уйлаганга караганда да уңай башланды. Елкылдап торган туры атка, байтактан ерак сәфәргә чыкмавына рәнҗеп аранда

гомер үткәргән яшь айгырга шул гына кирәк иде, юлга чыгып Дүрткүл ягына борылуга, такыр юлдан алга томырылды. Ике сәгать вакыт үтсә үткәндер, Әхмәтсафа инде вилаяттә, үзен көтеп торган Зәйнетдин әкә белән иртәгә булачак җыен хакында гәпәреп утыра иде.

...Һәр якның үз матурлыгы. Каштауга атларны кызулатмый гына барган чакта, Әхмәтсафа, бәлки Хива якларына килгәч, беренче мәртәбәдер, игътибар белән тирә-юньгә күз ташлап, хозуранә хисләр кичерде. Ара-тирә битләрне җиләс һава уйнаклавын тоясың. Бу якта сирәк бәхет—йөзне фирүзә җил иркәләп үтә. Бу—төш түгел, өн; бу—Амударья сулышы. Җиһанга ямь биреп, яшәүне ләззәтле иткән ике генә нәрсә бар—берсе кояш, берсе—су. Һәрхәлдә, чүлдә гомер кичергән кавемнәр шулай уйлый. Тик чүлдә кояшы хәттин ашкан, суга исә мәңгелек кытлык. Ходайга бәндәләрен болай тилмертү, сынау нигә кирәк булгандыр, үзе генә белә. Хәер, кай якка барып чыкма, шул хәлдер: бер җирдә халык суыктан интегә, кар-бураннардан җәфа чигә, икенче җирдә туктаусыз җил-зилзилә, су басулар, өченче җирдә халык сусызлыктан әлсери, кояшның рәхимсез нурлары астында тилмерә. Яшәү дигәннәре тоташ бәйрәмгә әйләнмәсен дип тырыша торгандыр инде Ходай. Гомер кичү тоташ бәйрәм түгел шул. Ел фасылы алышынып торган кебек, кичергән хисләр дә бертөрле генә түгел. Кеше күнелендә мәңгелек шатлык булмаган кебек, гел хәсрәт-ут йотып кына да яшәми адәм баласы. Чиктән ашып сөенмә, чиктән ашып көенмә. Яшәү кануны урталыкны сайларга куша. Менә Рәҗәпов үзенчә Әхмәтсафага бер этлек эшләп алды, бүген-иртәгә туган ягына кайтып китәсе кешене ерак сәфәргә чыгарып җибәрде. Мондый хәлдә нишләргә тиеш ул? Акылы сәламәт бәндә борчылырга, чәпчергә тиеш инде. Тик, егет үзен тынычландырды: әгәр юлга чыкмаган булса, шушы хозурлыкны күрер идеме ул? Юк. Аның өчен Хива яклары матур яктан ачылмый калыр иде. Димәк, Рәҗәповка төшәсе рәнҗү хисен сөенеч, канәгатьләнү хисе алыштырырга тиеш.

Иртүк юлга кузгалсалар да, кояш алардан өлгеррәк булып чыкты, бераз күтәрелеп, тирә-юньгә күз ташлады да, галәмдә үзенә тиң таба алмавына галәмәт үртәлгән кебек, җирне рәхимсез кыздыра башлады. Баш өстендә—кучкыллы зәңгәр күк. Җирдәге һәр җан иясенә, һәр нәрсәгә битараф һәм гамьсез карый ул. Баягы куанычлар чигә төште. Әхмәтсафаның тойганы булмаган икән—башын күтәреп, күк түрләрен карашы белән айкап алган иде, хәйран калды—югарыдан аңа өметсез бушлык текәлгән. Җанны ут ялмап алды кинәт. Табигатьнең бу халәте адәм балаларының бер-берсенә мөнәсәбәтенә охшаш иде. Кайбер адәмнәр югарыга менгән саен түбәндәгеләрне оныталар бит. Түбәндәгеләрнең эш-гамәлләренә, сөенеч-шатлыкларына, кайгы-хәсрәтләренә тома битараф була башлыйлар.

Гомумән, Әхмәтсафа яшьтәшләренә караганда иртәрәк өлгерде сыман. Әле ТИНОда укыганда ук, өлкәнрәк яшьтәге сыйныфташлары акыллы сүз, күнелгә ятышлы кинәш өмет итеп аңа киләләр иде. Кинәшкә бару—ата-бабадан калган йола. Әмма кинәш-табыш итәрлек кешеләр сирәк була. Авылда, әйтик, андый бер-ике кеше табылса табыла. Кинәшкә барырлык олпат заты булмаган авыл үз йөзен югалта, ул саланың кешеләренә сан булмый, авыл халкында бердәмлек югала, таркаулыктан иза чигә. Кинәш-табыш итүче сүз йөртми, гайбәт-ваклыклардан өстен була. Ул кабаланмый, кешене тынлый белә, каударланып, ашыгып нәтиҗә чыгармый, бөтенне өлешкә дөрес итеп тарката белгән кебек, өлешләрдән бөтенне дә оста оештыра. Шундый затка гына киләләр кинәшкә һәм сабакташлары Әхмәтсафаны шундый ышанычлы кешегә санийлар, ул әйткәнне кире кагарга ашыкмыйлар, сүзенә колак салалар иде. Хорезм округ комитетында да шундый ук ышаныч яулады егет. Аңа үз яшеннән чыгып түгел, хезмәт вазифасын төгәл башкаруы, акылына карап бәя бирделәр. Әхмәтсафа, гадәтенчә, ир уртасы булган адәмнәр белән дә тигез сөйләште. Үзен башкалар алдында кечерәйтеп азапланмаган кебек,

эшләмәгәнне эшләдем дип күрсәтү, булмаганны бар дип шапырыну аның өчен ят иде. Бәлки нәкъ шушы сыйфатлары аркасында аны хөрмәт иткәннәрдер дә. Хивада үткән еллар эзсез калмады, һәркем күз алдында ул ун-унбиш яшькә өлкәнәеп китте. Тагын шунысы бар, ана сер сыя. Дөнья булгач төрле хәлләргә тарый адәм баласы, ана үз итеп кенә нидер сөйләп ташлыйлар икән, белеп торалар, сер инде йозак астында. Әхмәтсафа бу хакта төпченеп, кабат исләренә төшермәячәк. Кыскасы, жиргә күммәс, жилгә сипмәс. Жиргә күмсә—кайчан да булса шытып, жилгә сипсә—илкөнгә таралып, кемнәрнең генә башлары хур булып бетмәс иде. Әхмәтсафа иптәшләре алдында үзе дә бераз серле, ниндидер илаһи көчкә ия кеше сыман күренә башлады.

...Уйланып бара торгач, тиз агышлы елгага життеләр. Елганың ике яры чаукалык, яшь таллар сырып алган. Эчтә эрерәк агачлар да күзгә ташлана. Монысы Сакмарның урманга күмелгән сул як ярын хәтерләтә. Чаукалыкта кошлар сайрый, ишеткәне бар, имеш жәй уртасы үткәч, кошлар сайраудан туктыйлар икән. Туктый ди сиңа, бер генә тын торыгыз әле, нинди генә кошлар сайрамый да, нинди генә авазлар ишетелми монда. Хәер әлеге гүзәллеккә тап булсаң, үзең үк сайрый башларсың. Әхмәтсафаның күнелен ашкынулы хисләр биләп алды. Төбе әкәмәт тигез итеп ташлар белән түшәлгән шушы елга буенда, толымнарын алкын суга салып, рәхәтлеккә оеп утырган яшь таллар арасында качыша-качыша уйныйсы иде. Кем белән дисезме, әлбәттә, сөйгәне, Рабигасы белән инде. Хыялдан шәп нәрсә юк, баш миенең иң серле гамәле дә хыялдыр. Әхмәтсафа мизгел эчендә хыялы белән Рабиганы үз янына алып килде, бергәләп ат өстендә йөрделәр, елганың боздай салкын суында битләрен юдылар, арган тәннәренә дәрман алдылар, су чәчрәтеп уйнадылар, озаклап чаукалыкта уйнап-шаярып, сабый балалардай чыр-чу килештеләр. Рабиганы күр син, оялчанлыгын, кыюсызлыгын шушы елга суына агызып жибәрде, ахры, бөтенләй тартынусыз Әхмәтсафага килеп сыена, егетнең чәчләреннән сыйпый, иркәли. Ә үзе конгырт матур күзләрен каядыр биеккә, күккә төби. Әхмәтсафа исә, моны килештермәгән кебек, бераз көйсезләнеп: "Миңа гына кара, күзләреңне миннән алма, бәгърем,"—дип үрсәләнә. Егетнең зәңгәр күзләреннән сагыш, шөбһә түгелә. Күңеленә хуш килмәгән битараф, төпсез күккә каратасы килми ул аны. Ниндидер гамьсез өермә уйнап алыр да, Рабигасын кулыннан йолкып алып, әллә кайларга илтеп ташлар кебек... Шуның өчен китердеме ул аны шушы гүзәл елга буена?.. Рабига исә аны ирештереп: "Нигә карамыйм, ди, тиле егет!—дип чыркылдап көлеп жибәрә.—Жир безнеке, күкләр дә безнеке. Жиһан, галәм безнеке! Ә мин син—минеке, минеке генә!"—дип, егетнең муенына сарылып, кысып кочаклап ала. Әхмәтсафа ашкынып: "Ә син—минеке!"—дип, кызны күкрәгенә кыса...

Шундый ләззәтле уйлар эчендә йөзгәндә, аны Зәйнетдин әкәнең кычкырып әйткән сүзләре айнытып жибәрде:

—Алдагы таулыкка күтәрелеп төшкәч, безнең кышлак инде, уртак Дәүләтьяров. Ходай уң кылгач, менә килеп тә житәбез.

Татлы уйларыннан аерганы өчен Зәйнетдин әкәне рәхәтләнеп бер тиргәргә иде дә, "уртак Дәүләтьяров" дигәнне ишетеп, Әхмәтсафа елмаеп куйды. Уртак Дәүләтьяровның нинди хыяллар эчендә гизгәнен белсә, ике дә уйламый: "И сабый, сабый, син карый булып житкәнче..."—дияр иде әкә...

Каштау диһканнарына алдан әйтеп куйганнар булса кирәк, зур гына амбар сыман жиргә шактый кеше жыелган иде. Каштауга килеп житкәч, озак юанмадылар, Зәйнетдин әкә комитетның берничә актив әгъзасына ниндидер әмер биреп каядыр озаткач, Әхмәтсафага кышлак хәлләрен сөйләде. Болай тыныч кына яшәп ятучы кышлак икән ул. Өчдүрт еллар элек хәлләр мөшкел булган. Диһканнар авырлыклар кичергәннәр. Озын жәй буе тир түгеп үстергән мамыкны дәүләт талап

диярлек алган. Бәяләр арзан; мамыкны бирми, көтеп торырга уйлаган диһканның өенә гаскәриләр кергән... Алар инде буш кул белән чыкмаганнар. Игенне дә талап алу гадәткә кергән. Шушы хәл диһканнарны яңа хөкүмәткә каршы куйган. Күпчелеге элекке әмирлек чорын сагына башлаган. "Гөнаһысына кирәкми, әмир диһканга яшәргә мөмкинлек бирә иде,"—дип уфтанып куйды Зәйнетдин әкә. Шөкер, соңгы елларда мондый талау сәясәте йомшара төшкән, халык белән киңәшләшеп, килешеп эшләргә өстенлек бирелә башлаган. Шулай да диһканнар комитеты һәр нәрсәне үзенчә хәл итә алмый икән әле.

—Электән үк кышлакта үз сүзен сөйләтә, үз җыруын җырлата торган адәмнәр бар иде. Хәзер дә бар алар, халыкны хакимияткә каршы котырталар,—диде Зәйнетдин әкә Әхмәтсафаның чокырына чәй коеп.

—Ниндирәк дәлилләр белән коралланган соң алар?

—"Советлар, алдап, төрле хәйлә кулланып үзбәкләрне басым астында тотмакчы булалар, денсезлеккә өндиләр,"—дип сафсата саталар. Имеш тә ки, советка хезмәткә керүчеләр ата-баба йоласын җиргә салып таптыйлар, гореф-гадәтләрне санга сукмыйлар. Моннан берничә ел элек кышлакка бер мулла килеп төпләнгән иде. Зәһәр нәрсә, сүзен бирмәс өчен әллә ни кылырга да әзер. Гыйлемлеге дә бар, инкаръ итеп булмый. Нугай адәме. Халык әүвәлге елларда аның авызына гына карап торды,—дип, дәвам итте Зәйнетдин әкә.—Урысча да шәп белә. Телендә нугай, казах сүзләре күп. Бик үҗәт кеше, диндар болай карап торуга. Эчтән ничектер, анысын Ходай белә. Чи итне чыгарды ул безнең. Диһканнар комитеты башлаган һәр эшкә аркылы төшә, кем әйтмешли, авызыңны ачып торсаң, чылтырап агып яткан арык юлын бикли дә куя.

—Каян килеп чыкты соң ул?—дип кызыксынды Әхмәтсафа.—Шулай тиз генә кышлакны үз кулына ничек ала алды ?

—Кызыл нугайлар безнең муллабызны—ишан хәзрәтне атып киттеләр. Әнвәр паша кешеләре белән элемтә дә булып, советларга каршы эш алып барган дип. Озак та үтмәде, сәүдә белән киткән кешеләребез чалма-чапанлы, үткен бер адәмне ияртеп кайттылар. "Шушы кеше муллабыз булыр!"—диделәр. Кем каршы төшсен? Мулласыз, шәригатьсез яшәп булмый.

Зәйнетдин әкәнең алдан сөйләп куюы мәҗлес-җыен вакытында ярады тагын. Әхмәтсафа чәйханә алдына җыелган халыкка үзенең килү сәбәбен аңлатып, алга табан ничегрәк тормыш итү хакында округ комитетының уй-ниятләрен бәян итеп, шулар хакында диһканнар белән киңәш сурәтендә әңгәмә кора башлаган иде, арадан берсе алгарак чыгып, бу хакта артык җәелергә бирмәде:

—Хивадан килгән кунак мөһим эш белән йөри, үзе дә каршы имәстер, дип уйлыйм, мондый зур сөйләшү-гәпне, әүвәл Коръән-кәрим аятьләре белән башласак яхшы булыр,—диде.—Ходайдан узып кылган гамәлдән хикмәт чыкмас. Бисмилласыз башланган сүз зиһенгә барып житми, аны шайтан эләктереп ала да, анда буталыш тудыра. Бераз гына сабыр кылыйк, муллабыз килеп житсен, мәҗлесне башларга фәтва бирсен. Хивадан килгән вәкилне ул да тыңласын. Кунакның тел төбен аңладык, диһканнарны берләштерергә, җирләрне бергәләп эшкәртергә, арыклардан күмәкләп файдаланырга өнди. Инде безне тыңласын. Бу әле сүзгә керешү түгел, болай гына... Уйларга җирлек бар, әйтик, Фәйзулланың җире кештәктә, Насретдинныкы гарештә, Бикмәтнеке мәгърибтә, Алимныкы мәшриктә. Мөмкинлеге булганнар, үз җирләрен үзләре хәл кыла. Катлаулы, четерекле мәсьәлә бу. Бер җыенда гына хәл кылып булырмы? Муллабызга безнең исемнән сөйләргә вәкаләт бирик. Без аңлап җитмәгән нәрсәләрне ул төшендерер. Сәвит кешеләре белән сөйләшүләр алып барырга булышлык күрсәтсә, начар имәс. Безнең файдага гәп кылды монарчы, Ходай ана савапларын бирсен.

Ул да булмады, ишектә чалма-чапанлы дүрт-биш адәм пәйда булды. Халык арасында:

—Мулла килде, юл бирегез, үткәрегез,—дигән сүзләр ишетелде.

Җыйнак гәүдәле, зур чапанлы кешенең мулла булуында шик юк иде. Беркемгә дә күз салмый, гаять иркен рәвештә халык арасыннан алга табан үтүе, үзе өчен махсус җәелгән киезгә илтифатсыз кыяфәттә аякларын бөкләп утыруы (кунаклавы дисән дә дөрес булыр, чөнки ул моны бик тә җәһәт һәм гадәти башкарды), халыкның Хива вәкилен дә онытып, ана күз текәп, тын калуы мулланың чыннан да абруе зур икәнен сөйли иде. Үзбәкләр мулла дип, дин әһелен генә түгел, абруйлы һәм белекле, күп нәрсәләрдән хәбәрдар, белгәннәрен уныш белән гамәлдә кулланучыларны да атап йөрткәнгә, Әхмәтсафа кызыксынып каршысында утырган кешегә күз салган иде, күкләр ишелдемени, җир чайкалып, беразга башы әйләнеп, зиһенен җыя алмый торды, аның каршында бәбәкләрен аска текәп, иманга оеган төстә утырган адәм—кайчандыр Каргалыдан эзсез-нисез юкка чыккан Вәлкәй хажи иде...

Ул чорда илдә дин әһелләрен, шул исәптән мулла-хәзрәтләрне эзәрлекләү башланган иде. Вәлкәй хажинен кисәк кенә юкка чыгуына хафаланган кеше дә булмады бугай. Шулай да нинди-дер хәбәрләр килеп ирешә тагын. Кемдер азанчы хәзрәт Төркия ягына чыгып сызган дип сөйләде, кемдер хажиның Зәки Вәлиди янына, Стәрлетамак якларына китеп эзен чуалтуы хакында хәбәр ирештерде. Әмма ул чактагы болганчык дәвердә бу сүзләргә берәүнең дә исе китмәде. Әхмәтсафаларның ул көннәрдә бигрәк тә борчулы көннәре иде. Әтисе Мостафаның аянычлы үлеме һушсыз иткән иде, хажи кайгысы булмады анда. Вәлкәй исә нәкъ менә әтисе үлгән көнне юкка чыкты бит...

Әхмәтсафа үзен кулга алырга тырышып, Зәйнетдин әкәгә:

—Әйдәгез, әкә, дәвам итик,—дип дәшкән иде, Зәйнетдин ашыкма дигәнне белдереп, Әхмәтсафаның беләгенә сак кына кагылып алды.

Егет үзен табага куырырга салган ясмыктай хис итте. Иң кыены—кечкенә өстәл артыннан җәһәт кенә сикереп торып, Вәлкәй хажиның—Каргалының карагруһ, миһербансыз кешесе, авылда чакта мөәзинлектән үтә алмаган, шуның өчен мәчет тирәсендә ел саен тавыш чыгарып мәш килүче үчлекле бер адәме, үз сүзен сүз итү өчен теләсә нинди нәҗеслеккә бара торган затсыз бәндә икәнен дә әйтә алмый. Вәлкәй хажи мондагы халыкның гадәтләрен, холык-халәтен яхшы өйрәнгән, Әхмәтсафаның бер сүзенә, ун сүз белән җавап кайтарачак, житмәсә, борын-борыннан диһканнарның үтә нык дини рухта булуыннан файдаланып, һәр сүзен Коръән аятьләре, хәдисләр белән ныгытып барачак. Әхмәтсафаның бу мәсьәләдә, сүз дә юк, белеме дә, тәҗрибәсе дә бәләкәй. Ул күбрәк фирка сүзе сөйләп чарланды. Җәдәлләшергә оста иде Вәлкәй хажи, һай, оста иде. Каргалыдагы һәр төрле ызгышның үзегендә—ул, мәхәллә имамнары арасында бакый барган каршылыклардан оста файдаланып, дин-мәчет эшләрендә үз сүзен үткәрүгә ирешмәктә иде. Күрәсең, әлеге сыйфатлары Каштауда ана ифрат файда китергән, халык әнә ничек табынып, интизар булып, хәзрәт белән бергәләп озаклап дога кыла. Әхмәтсафа да башкалардан калышмаска тырышып, шартына житкереп дога кылды, әмма Вәлкәй хажи һәммәсеннән дә озаграк укыды. Хәзрәт эргәсендәгеләр берничә мәртәбә хәзрәтнен тартылып куюын күреп, бит сыпырырга ният дип анлап, кушырылган кулларын йөзенә якын китерделәр. Әмма хажи ашыкмады, бирелеп дога укыгандагы сыман иреннәрен кыймылдата бирде. Вәлкәй хажиның астыртын күземсерәп, иреннәрен чалыш-молыш китереп утыруыннан анлап алды егет—хажи халык белән, шул исәптән каршында утырган Хива вәкиле белән дә мәчеле-тычканлы уйнаган шикелле итә иде.

Шунысын да тотып алды Әхмәтсафа, Вәлкәй хажи догага оеп кына утырмый инде, вәкил булып килгән егеткә күз ташлаган унайга нигәдер кисәк алга тартылып куйды, янә берничә мәртәбә егеткә сынап-сынап карады, йөзе күм-күмгәк булып чыкты, аннан үзен иманга оерга мәҗбүр итте шикелле, бераз дога укып утыргач, тынычлана төштеме,

авыз читендә сәер елмаю хасил булды. Шактый тулыланган битеннән дога укылып беткәнче китмәде ул елмаю.

Догадан соң, Вәлкәй хажи, Зәйнетдин әкәгә баш кагып, жыенны дәвам итәргә рөхсәт бирде.

Зәйнетдин әкә озаклап кышлак хәлләре, Дүрткүлдә ишеткән-күргәннәре хакында ялыктыргыч нотык сөйләргә тотынды. Вәлкәй хажи исә, бер тын алга иелә төшеп, уйлагандай итеп утырды да, янәшесендәге табак битле чалмалы адәмнең колагына нидер пышылдарга, бер караганда ашыга төшеп, икенче караганда тыенкы һәм тәфсилле рәвештә аңа нәрсә хакындадыр аңлатырга, төшендерергә тотынды. Теге адәм башта тутырып Әхмәтсафага агулы караш ташлады, аннан Вәлкәй хажиның сүзләреннән үтә сөенгәндәй, бөтен йөзе белән елмайгандай итте. Әмма әлеге елмаю зәһәр һәм шулкадәр нәфрәтле иде, Әхмәтсафаның, ирексез, йөрәге кагып алды. Икеләнерлек урын юк, Вәлкәй хажи үзенең каршысында утырган егетнең авылдашы Мостафа малае икәнен танып алган иде.

Соңгы елларда ул Мостафа агайга, аның балаларына шулкадәр үчлекле булды, хәтта өзәрлекләргә үк тотынды дисән дә ярый: вафат булыры алдыннан әтисен шушы Вәлкәй хажи котыртуы буенча куштаннар ничек кенә мәсхәрә кылмадылар да, ничек кенә рәнжетмәделәр. Гажәбе шул, кай якларга килеп чыкса да Вәлкәй ишеләр үзләренә куштан табалар икән, башларында туктаусыз бөтерелгән мәкерле ниятләрен алар аша тормышка ашыралар. Менә хәзер дә, иманы камил, Вәлкәй хажи үзенең куштаннарына Әхмәтсафа хакында яман нәрсә сөйләп, аларны егеткә каршы өстереп, котыртып утырадыр. Вәлкәй хажине яхшы белгәнгә, башкача булуы мөмкин түгеллеген шулай ук тиз төшенеп алды Әхмәтсафа.

Башында уйлар чабыша иде егетнең. Вәлкәй хажи ни эшләргә жыена? Әхмәтсафага сөйләргә ирек бирерме аның куштаннары, юкмы? Сөйләгәндә каршы төшеп, бүлдереп, фикерен бутап бетерсәләр? Ничек хәлдән чыгарга?.. Мантыйк буенча китсән, күрәсең, ул Хивадан килгән вәкилне, кем булуына карамастан, тыңларга тиеш. Чөнки округка кайтуга ук, советка каршы үгет-нәсихәт алып баручы Каштау мулласы хакында сүз кузгатачак, вәкилгә каршы килү—Зәйнетдин әкәнең кылган эшләренә астыртын аяк чалып, халыкка коткы таратып яту гына түгел, тиз эзенә төшәчәкләр. Бүгенге жыенда ул ачыктан ачык каршы сүз сөйләмәс, ә менә Әхмәтсафага каршы нинди дер астыртын гамәл кылмый, ай-һай, жибәрер микән? Жыен бетүгә Әхмәтсафаның исәбе—Каштауда озак юанмау иде. Дүрткүлгә, атны артык куаламыйча да, өч сәгать чамасында барып әлгәшә ул. Бүген Дүрткүлдә кунып, иртәгәсен, бик каударланмыйча гына Хивага кайтып керәчәк. Төштән соң шушы сәфәре хакында хисап язып тапшырырга да, шуның белән вәссәләм, эшне тапшырып, атна-ун көннән Каргалыга карап юл чыгарга булыр кебек. Насыйп булса, август урталарында ул инде Каргалыда, тагын берничә көннән соң Казанга кузгалыр. Кулында укырга чакыру кәгазе булган хәлдә, Хивада аны бераү дә көчләп тота алмый. Үзбәкстанда совет хакимиятен үзбәк дуслар үзләре, жаннары теләгәнчә урнаштырсыннар, Әхмәтсафа булдыра алганча тырышты, кем әйтмешли, һаман да карусыз малай хәлендә йөрүне күз алдына да китерә алмый. Ярый әле, үжәтлек күрсәтеп, Казанга язып жибәрде, юаш булсан—басарлар, баш бирмәсән—асарлар, дисәләр дә, бу дөньяда үзен өчен көрәшмәсән дә булмый икән. Әхмәтсафа шуны төшенде, фирка исеме белән теләсә нинди әшәкелекләр эшләргә мөмкин хәзерге вәзгыятьттә. Житәкчелеккә дә зирәклеге, эшкә сәләте буенча түгел, уйнаш кыларга яратучылар жыела бара. Егетнең бөтен күнеле әлеге хәл белән килешми, болай булмаска тиеш дип уйлый, әмма шушы сәясәткә каршы чыгу юлларын да белми. Эчтән көеп йөрүдән башка чарасы юк иде...

Зәйнетдин әкә сөйләгәндә Вәлкәй хажидан башланган уй, аны бөтенләй ерак алып кереп китте, ул онытыла язган икән—алга күз ташласа, егылып китә язды, анда инде Вәлкәй хажи юк иде. Ике куштаны белән,

әллә тагын, жир убылып, аска төшеп киткәннәр, эзләре суынып өлгергән бугай инде. Халык бер дә исе китмәгән сыман, һаман Зәйнетдин әкәне тынлый, мулла килеп бер авыз сүз әйтмәсә дә, шушы дәшмәве, кинәт урыныннан торып, мәжлесне ташлап китеп баруы белән үк нинен ни икәнен төшендереп куйды инде, хәзер ни сөйләсәгез, шуны тынлыйбыз, диләр микән?.. Вәлкәй хажиның жыенда калган теге табак битле куштаны гына һаман егеттән күзен алмый, балкып утыра иде. Егет хәлнен бик үк гади булмавын төшенгән иде. Эчен янә нидер яндырып үтте...

Әхмәтсафага сүз бирелгәч, ул тез буыннары калтыравын басарга омтылып, бар осталыгын җыеп, сүзен башлады.

—Дикканнар!—диде ул, тыныч булырга тырышып,—сүз дә юк, бүген сөйләштек тә, барысы да хәл ителде дип булмый. Күп өлкәләрдә, вилаятләрдә колхозлар төзелә, совхозлар тернәкләнеп килә. Хәбәрләргә караганда, халык мәнфәгатен искә алып эшләгәндә, диһканнар хуплыйлар мондый үзгәрешне. Яна тормыш төзибез дибез икән, искечә яшәп булмый инде. Һәрьяклап үзгәрергә тиеш булабыз. Дөньясы үзгәрде, дәвер башка. Уртак Ленин бу хакта бер генә мәртәбә әйтмәгәндер, бердәм булсак кына, дөрес юлдан тайпылмасак кына хәерчелектән котылырбыз, мул тормышта яши башларбыз, ди ул. Инде сез совет хөкүмәтенен диһканнар өчен кайбер яхшылыклар эшләгәнен күрдегез. Сонгы елларда яна икътисадый сәясәт үткәрелеп, мамыкны, каракүлне ирекле бәяләр белән сатарга хокук алдыгыз.

—Халык тәмам бөлеп, эштән чыккач,—дип, нәфрәтле сүз ыргытты арадан берәү:

—Кызганычка каршы, сез хак әйтәсез... Хәзер хәлне тизләтү өчен чаралар күрелә. Дөрес юлга тизрәк бассак иде...

—Дөрес юл кайда соң ул?—диде теге табак чырайлы адәм.—Кая алып барып чыгармакчы буласыз халыкны?

—Нәкъ бая әйтелгәнчә,—дип, тавышын күтәрә төште Әхмәтсафа,—диһканнарны бөлдерә торган сәясәт ялгыш, аларнын тормышын яхшы якка үзгәртә торган сәясәтне дөрес юл дип табам. Ин элек, үзегез уйлашыгыз, сезнен өчен кайсы юл әйбәт: һаман шулай аерым-аерым чыкмакчы буласызмы бөлгенлектән, әллә бергәләшеп чыгарга ният кылсагыз, отарсызмы? Илдә берләшү шәкеле өскә чыкты. Мәркәз күмәк тормыш корып эшләүчеләргә ярдәм кулы сузарга хәзер. Аерым тормыш алып барган диһканнарга инде уйларга туры килер, бар кешегә дә ярдәм итеп бетереп булмас...

—Ленин бит алай димәгән!—дип, калкына төште тәү башлап сүзгә кушылган диһкан.—Барлык кешеләрне тигез күрәбез, һәммәсе дус, туган, дигән. Ә сез ни сөйлисез? Берләшсәгез, ярдәм итәрбез, аерым калсагыз, мәйлен, үзегезне үзегез карагыз, димәктә сүз алып барасыз. Дөресме бу? Юк, дөрес имәс!

—Мин сезгә бу мәсьәләгә карата мәркәз сәясәтен житкердем,—диде Әхмәтсафа.

Сүз көрәштерүнен үз файдасына түгелен белә иде инде ул. Бу хакта чыгыш ясый башласа, һәммә жирдә шундый бәхәс куба. Сорауларга бер төрле генә жавапны бирү һич мөмкин түгел. Мәжбүриләп халыкны ожмахка өстерәп кертмәкче була фирка. Тик һәр кылган гамәле халыкка каршы килеп чыга. Моны мәркәздәгеләр дә сизә, башкалар да жүләр түгел, шуна күрә туры сорауларга туры жавап бирә башласан, жавабында үзен үк бутала башларга мөмкин. Җыенга килгән кешеләр арасында күпчелек сонгы еллардагы тәртипсез талау сәясәтеннән зур зыяннар күргән диһканнар, инде бу кадәр хәерчелектән, бөлгенлектән аерым-аерым чыга алуларына ышанычын югалтып бетереп баралар. Әхмәтсафа ашыкмый гына берләшү файдасына дәлилләр китерә башлады, аларны мисаллар белән оста итеп ныгытып та куя.

Халык тынычлана төште, арада анын сүзләрен хуплаучылар да табылды кебек, ахырда, мәсьәләне өйрәнеп, алдын-артын исәпкә алып,

кҮмәкләшү эшен башларга дигән карар чыгарып, мәҗлесне тараттылар. Зәйнетдин әкә, озакка сузмый, якын көннәрдә эшкә тотынырбыз дип вәгъдә дә бирде халык алдында. Җыен таралып беткәндә, табак битле адәм, Әхмәтсафа янына килеп, аның белән ачылып сөйләшә башлады, Хива хәлләрен төпченеп маташты. Урамга кадәр аңа тагылып чыкты. Сүз унаенда гына:

—Юлдаш Дәүләтьяров, шундый зур җирдән вәкил килүенә без бик шатбыз. Сөйләшәсе, киңәшәсе сүзләр күп җыелган. Бүген сезнең ниятләр ничек?—дип, егетнең күзенә карап тора башлады.—Бәлки, кычкырып янә гәпәреп алырбыз.

—Ай-һай, вакыт табып булыр микән?..

Әхмәтсафа инде үзен кулга алган, салкын акыл белән эш итә башлаган иде. Бу сорау юкка гына бирелмәгәнен дә белә, берни булмагандай, Зәйнетдин әкәгә төбәлде:

—Бераз кышлакта ял итеп алам да,—диде ул, чын күңелдән сөйләгән кыяфәт белән.—Кичкә табан менә Зәйнетдин әкә белән күрше кышлакка барып кайтырга исәп. Кышлакның исеме онытылды, аты коргыры...—дип, Каштау артында еракта гы офык артында шәйләнгән каралтылар ягына күрсәтте.—Хивадан килеп, бер генә кышлакта булу килешеп бетмәс. Кайткач ни дип хисап бирермен?—диде ул, көлемсерәп һәм исе китмәгәндәй тәмәке чыгарып, авызына капты. Зәйнетдин әкә вәкилнең әле тагын бер кышлакка барырга ниятләвен белеп алгач, аны ашыктыра-кабаландыра чәйханәдә генә калдырмыйча, үзләренә чәй уртларга алып китте. Вәкилнең күрше кышлакка барасы килүен алдан әйтеп куймавына кәефе кырылса да, үзенә сиздермәскә тырышты.

Юлга чыкканчы, дөрестән дә бераз ял итеп алырга кирәк шул, бу ашыктыруны һәркем, шул исәптән табак битле адәм дә аңлый иде. Өч сәгатьләп ял иткәч, юлга кузгалачакларын да белгәч, кош тоткандай китте вәкил белән Зәйнетдин әкә яныннан.

Кызыл комлы тар урамнан барганда да, балчык дувал-койма белән әйләндереп алынган ихатага килеп кергәч тә, җәйге йортта чәй эчкәндә дә Әхмәтсафа үзенең уй-нияте белән хуҗаны таныштырырга ашыкмады. Тыштан сабыр булырга тырыша-тырышуын, ләкин йөрәге урынынnan купкан, ана кышлакта бер генә сәгатькә дә калырга ярамаганлыгы көн кебек ачык. Әле ул кечкенә чакта Оренбурга, Гомәр абзыйларга кунакка барганнар иде. Әткәсе белән сөйләшеп утырганда абзый малай һич төшенә алмаган, әмма бик көлке сүзләр әйтеп ташлаган иде. Шул хәтереннән чыкмый, менә тагын исенә килеп төште. Әткәсенең алып килгән тире-ярыларын икенче көнне иртән генә тире-күн заводына тапшырырга ниятләвен белгәч, Гомәр абзый күтәрелми-бәрелми генә: "Төн чыкканчы, җон чыккан, Мостафа туган, без бу йөкне бүген үк урнаштырыйк,"—диде. Сүз җебен әткәсе эләктереп алып, көлемсери төшеп: "Анда кич-кырын безне кем көтеп торыр микән соң? Исәп-хисап ясаучы табылырмы? Нашатырь да сип, җон да чыксын,"—дип, абзыйга каршы килде. Әлеге җаваптан җитди кыяфәтле Гомәр абзый ихлас рәвештә көлеп җибәргән иде. "Шулай дисеңме, туганкай, йә, ярый алайсам, Ходайдан узып, эш булмас, иртәнге эш хәерле булыр, йөкне ишек алдына кертеп куйыйк,"—диде һәм җил-җил атлап өйдән чыгып киткән иде. Бу вакыйга ни өчендер Әхмәтсафаның күңелендә кадерле хатирә булып саклана, ике өлкән кешенең сүз әйтешкән чичәннәр кебек, бер-берсен йөремсәк мәзәкләрдән йолкып алынган мәкаль-әйтемнәр белән сыйлавы малайның хәтер түренә үк үтеп кергән иде. Гомәр абзый әйткән "төн чыкканчы, җон чыккан" дигән сүзләрен бүген бик урынлы кулланып булыр иде. Ашыгырга кирәк. Әйе, Вәлкәй хаҗи юкка гына мәҗлесне ташлап китмәгәндер. Табак битле куштаны да вәкилнең уй-ниятләре белән тикмәгә кызыксынмады. Вәлкәй хаҗи егетне тануын белдереп, керфек тә кагып азапланмады, әмма Әхмәтсафа сизеп торды—авылдашы аны таныды... Тик Вәлкәй хаҗи хакында ул Зәйнетдин әкәгә бер сүз дә дәшмәүне хуп күрде. Иң яхшысы, Дүрткүлгә

кайткач, андагы җаваплы кешеләр белән кинәш-табыш итәргә кирәк. Каян килеп чыккан ул монда, ни өчен Зәйнетдин әкә, инде үтенә тиеп бетсә дә, түзеп тора ана? Куштаннары кемнәр? Кыскасы, сораулар күп иде. Зәйнетдин әкәгә әйтсә, сүз иярә сүз чыгып, ул бу хакта тагын кемгәдер ычкындырса, Вәлкәй хаҗи эзен тиз югалтыр. Әхмәтсафаны ул танып алды, ә менә егет аны таныды микән? Бу хакта Вәлкәй анык белеп бетерми, "таныдымы-юкмы?" дип, баш ватадыр. Шиксез, куштаны алып килгән хәбәр җирлегендә нәрсә дә булса эш кылмакчы була торгандыр. Әхмәтсафага карата берәр явызлык кылмаса, Вәлкәй хаҗи була ди ул, тот капчыгыңны, кем әйтмешли.

Чәй эчеп бетергәч, дога кылып, Әхмәтсафа аты бәйләп куелган киртә янына килде, атның муеннарын сыйпап, аны юмалап алды. Ат ашаган, эчкән, ял иткән иде. Әлегә эшләр ул уйлаганча бара, артык яшереп азапланасы юк, телгә килде Әхмәтсафа:

—Рәхмәт яусын, Зәйнетдин әкә. Мондагы хәл-әхвәлне белдем, диһканнарның холык-халәте һич тә берләшүгә каршы түгел икән. Кайбер оештыру чаралары күрәсе, аңлату эшләрен юлга саласы бар. Боларны белү мина да, фирканың округ комитетына да бик мөһим иде. Кайтышлай Дүрткүлгә дә кереп, фикерләрне җиткереп чыгармын.

Вәкилнең болай, кисәк кенә, саубуллашкан сыман сөйләнүенә Зәйнетдин әкә аптырап калды.

—Чәй уртлагач, уртак Дәүләтьяров, ял итеп алыйк, әле кояшның рәхимсез чагы. Аннан күрше кышлакка озатып куярмын, боерган булса.

—Хәзер үк юлга чыгам,—диде Әхмәтсафа хуҗаны шаккатырып.— Озатып мәшәкатьләнмәгез, юлны беләм. Мина тоткарланырга һич тә ярамый,—дип, атының тезгенен чишеп, аны капка ягына әйдәкләде.— Бахбайны да әйбәтләп ял иттергәнсез. Рәхмәтләр яусын үзегезгә, үз игелегегез үзегезгә кайтсын...—Якын итеп, Зәйнетдин әкәгә саубуллашырга ике кулын сузды.

—Һай, уртак Дәүләтьяров, яхшы имәс, яхшы имәс,—дип икеләнә төшеп кенә кулын бирде Зәйнетдин әкә.—Бер сүз гәпәреп, икенчесен эшлиләрме инде? Булмаганны...—диде ул һаман ризалашмый.—Күршеләргә икәүләп барабыз диден ич...

—Без шундый заманда яшибез шул, Зәйнетдин әкә. Иртән әйткән, кичкә ярамый. "Төн чыкканчы, җон чыга" дип тә өстәмәкче иде, шаяртуның урынсыз икәнен аңлап, тыелып калды.

—Мәйлен инде, уртак Дәүләтьяров. Юлда уңга-сулга карап барыгыз. Сезнең сыман ялгыз юлчыга кем очрамас та, кем ни кылмас,—дип, борчылган кыяфәттә, Зәйнетдин әкә Әхмәтсафаны озатып калды.

Кышлакны чыккач та егет атын күрше кышлак ягына түгел, кире якка, ягъни килгән юлга борды. Юл дисәң, хәтерен калыр, бу якларның холык-фигыле шул, әле ике-өч сәгать элек үткән эзне ком күмә дә китә. Бәхеткә каршы, Каштаудан Дүрткүлгә алып кайтучы юл шактый өметле икән, эзләр дә сакланган, аннан бу якларда йөреп өйрәнгән атларның табигате шундый, алар кайту ягын искәреп алсалар, юнәлешне тиз тотып алалар, эз булмаса да, юлны саташтырмый, җайдакны исән-имин алып кайтып җиткерәләр. Әхмәтсафа шуңа исәп тота да инде.

Егет атын мөмкин кадәр куарга тырышты. Әмма чаманы да югалтмаска кирәк, атың янып эштән чыкса, үлем белән бер. Юлда кое фәлән очрамады, көмештәй елтырап яткан елгага кадәр дә ерак. Аның уйлавынча, Вәлкәй хаҗиның ниятендә егеткә каршы яманлык кылу булса, ул аны, һичшиксез, күрше кышлакка барганда, яки аннан кайткан чакта кыларга хәзерләнәдер. Әгәр кышлакта куна калса, аннан исән-имин чыгу икеле иде. Вәлкәй хаҗиныкылар Әхмәтсафага яманлык кылып кына калмаслар, Зәйнетдин әкәнең ишле гаиләсе дә каза күрүе бар. Һич булмаса, атына зыян салачаклар иде алар. Вәлкәй хаҗиның ат караклары белән бәйләнештә торуы хакында сөйлиләр иде авылда. Ышанганы ышанды, ышанмаганы юк, әмма әткәсе Мостафа, Вәлкәй хаҗи турында сүз чыкса, теш арасыннан гына: "Ат

буры!“—дип ычкындыргалый иде. Димәк, Әхмәтсафа Каштауда төн үткәрә алмый, юлга чыгуы һәр яктан аклана. Чүл буйлап дулап чапкан атының муенына ята төшеп егет шуларны уйлап алды. Ярты сәгать чамасы вакыт үтте, артта шикле нәрсә күрмәде, тоймады ул. Курыкканга куш, икесе бергә биш, юкка шыр җибәрде бугай ла...

Атын тыя төште, тәмам тынычланып килгәндә, артка борылып караган иде, йөрәге “жу“ итеп китте, үзен куып томырылып чабып килүче ике җайдакны шәйләп алды. Ат өстендә кемнәр икәнен чамалавы кыен, әмма аларның Хивадан килгән вәкилне куа чыгучылар икәнлегенә дә шик юк. Аңлашыла. Шулай булмаса, эссе кояш астында шулкадәрле ашыгырлык ни эш бар? Әхмәтсафаның аты да төшеп калган түгел, шактый элдереп өлгерде кышлактан чыккач. Димәк аны куалар... Егет үзенең ялгышмавын аңлап, атының касыгына үкчәсе белән нык кына төртеп алды. Туры айгыр алга омтылды... Арттан куучы җайдакларның (инде алар аермачык күренә башлады) атлары шәбрәк, елдамрак иде, ахрысы, ара торган саен якыная бара. Әхмәтсафа, өйдә онытылып калган револьверын исенә төшереп, ачынып, сызланып ыңгырашкандай итте. “Их!..“ дигән әрнүле тавыштан хәтта ат та тигезлеген югалтып, бер мәл чабу эзенә төшә алмый азапланды кебек. Аны коткарса бер генә нәрсә коткара ала—калкулыкка менеп, сөзәк араны үткәч, тау төшәсе, аннан елгага килеп чыгасың, теге ярда исә чаукалык, агачлар, таллар, чытырманлык... Шунда качып калса гына инде. Аермачык ишетелә, җайдаклар әллә һавага, әллә үзенә төбәп шарт-шорт мылтыктан ата башладылар. Ара ерак калмый, димәк. Әмма артка борылып карарга форсат юк. Куркудан бөтен тәне калтыраган шикелле тоела, ул үз-үзен белештерми, атына кычкыра, аны куалый башлады.

Калкулыкка менеп, бераз чапкач, еракта елтырап яткан елга күренде. Егетнең күңелендә өмет канат җәя, аты да аны аңлый кебек, тагын да ашкынып җилдерә башлады. “Әйдә, бахбай, әйдә!” Егет күңеленнән генә дәшкән сыман булса да, шактый кычкырып әйтә иде бугай сүзләрне, ат соңгы көченә җитеп чаба иде инде елгага табан. Арттагыларга борылып та карамый Әхмәтсафа, ике-өч пуля колак янынннан гына сыздырып үтте. “Әйе, каптың, егет, Вәлкәй хаҗиның кара тозагына!”—дип, ачынып уйлап кына алды. Күрше кышлак хакында сөйләнгән булып, эзне саташтырып, үзенә күрә тапкырлык күрсәтеп маташмаса, эш ни белән беткән булыр иде? Кем кемне?!. Сизенүе дөрес булган, әгәр Зәйнетдин әкәдә чәйләп тормаса, бәлки бу тозакка эләгеп тә азапланмас иде. Эш узгач кына акыллы булып кыланасың шул. Терсәк якын да... Хәер, кая монда терсәк кайгысы!

Елгага килеп тә җиттеләр. Аты суга очып кына килеп төште кебек. Ат аяклары астында су кайный сыман, егетнең өстенә су тамчылары бөркелә, тагын дүрт-биш ыргым, һәм ул инде агачлар арасына кереп китә ала. Баш очында зәһәр чиелдәп пулялар оча. “Әйдә, бахбай, әйдә!”—дип, шашынып пышылдый Әхмәтсафа. Көтмәгәндә, аты нәрсәгәдер абынды, кисәк башын суга чумдырып алган сыман итте. Су эчәргә маташа түгелме соң бу хәерсез. Шундый мизгелдә, инде котылдым дигәндә атның шулай баш бирми маташуына җен ачуы чыгып, атының касыгына типте. Кара туры тагын бер ыргым ясады, аннан тизлеген югалтып, сәер урхылдап, башын янә суга чумдырды. Егет кычкыра, атын һаман куалый, ат исә хуҗасын ишетмәгән дә кебек, бөтенләй туктап калды, буыннары йомшарып, шаулап аккан суга гөрс итеп чүкте дә, агым уртасына сузылып ук ятты. Әхмәтсафа тезгенен ычкындырмаган килеш, суга барып төшкән мәлдә, аяк өсләренә басып, атын тарткалап маташканда, атның сырты буйлап ургылып-ургылып аккан канны күреп, үрсәләнеп кычкырып җибәрде:

—Бәдбәхетләр, атка ... атка төзәп аттылар бит!..

Куа килүчеләр дә елгага атылып килеп керделәр. Әхмәтсафа нишләгәнен белмичә, атының муенына ташланды, җаны чыгып бетмәгән малкайны кысып кочаклады да күзен йомды. Тозактан ычкынып булмасын аңлаган иде инде ул.

...Егетнең баш өстендә пулялар яңгыры... Ниндидер могҗиза аркасында ана әлегә бер ук та тими. Терелай алмакчылар, күрәсең... Куып килгән җайдаклар килеп җитеп, аның эшен бетерер вакыт үтте, һаман ату, ниндидер сәер тавышлар. "Шашыналар, бәдбәхетләр, бәйрәм итәләр үзләренчә. Вәлкәй өскә чыкты, сөенерлеге бар. Их револьвер булса..." Шулай уйлап бетермәде, баш очында гына яңгыраган тавышка сискәнеп, ирексездән, аяк өстенә басты. Тавыш исә таныш, һич тә ачулы түгел иде:

—Әхмәтсафа, син исәнме?

Билдән суда килеш шәлперәеп торган егет, ат өстендәге җайдакка күтәрелеп карагач, имәнеп китте, үз итеп, шул ук вакытта житди дә тавыш белән хәлен сорашучы кеше—Фәтхулла иде... Егетнең исән-имин икәнлегенә инанып, бары тик әлеге мәхшәрдән һушын җыя алмый торганын абайлап, Фәтхулла ике уйлап тормый суга, Әхмәтсафа янына ук сикереп төште.

—Ярый әле өлгердек, беткән идең, парин,—диде ул һәм егетне тизрәк һушка китерергә тырышып, җилкәсенә үз итеп кулын салды.—Тәки өлгердек ...

—Атны үтерделәр...

Әхмәтсафа һаман Фәтхулладан башка кешене күрми, үзен кемнәр куып килгәнен белергә теләп, артка борылып карарга да җөрьәт итми.

Яннарына су чәчрәтә-чәчрәтә янә бер җайдак чаптырып килде.

—Берсе яраланган, берсен дөмектердек, уртак Галиев.—Фәтхуллага дәшүе иде аның.

—Ярлысына беренче ярдәм күрсәтегез, ничек тә исән-имин сакларга тырышыгыз анысын. Кайбер нәрсәләр хакында сорашасым бар, хәзер килеп җитәм.

—Каштауда Вәлкәй хаҗине күрдем. Мина һөҗүмне ул оештырды булса кирәк,—диде Әхмәтсафа, ниһаять ис җыеп.—Сизенгән идем, үзенә күрә хәйлә дә корып маташтым, барыбер арттан куып тоттылар.

—Кышлактан чыгасың калмаган. Килеп җитә идек бит.

—Кем белгән бит...—диде Әхмәтсафа. Суда яткан туры айгырның үле гәүдәсенә карап, үкенгән тавыш белән өстәп куйды.—Аттан яздым мәнә. Кызганыч, малкай.

—Үзең исән калгансың, шуңа сөен. Шулай итеп, Вәлкәй хаҗине күрдем дисең инде Каштауда. Ялгышмадыңмы? Сөйләштегезме?.. Ниләр сайрый, чалмалы кош?

—Анда, минѐ күргәч, сайрау кайгысы булмады бугай. Танымаган сыман кыланды. Сизми калдым, җыен барган җирдән чыгып киткән. Шулай сәер генә юкка чыккач, күрше кышлакка, бөтенләй кире якка барам дип, үземчә эзне саташтырып, Дүрткүлгә киттем кайтып. Күрәсең, алар мине башта кышлакка бару юлында көтеп торганнар инде. Аннан хәбәр килеп, арттан куып, эзгә бастылар. Ә сез ничек? Монда каян килеп чыктыгыз соң әле?—дип, каударланып Фәтхулладан сораша башлады.—Йомышыгыз төштеме бу якларда? Хәер, эшегез булмаса...

—Кичә төнлә, кизүдән кайтып керсәм, Шәмсия әнкәң елардай булып утыра. "Күнелем сизә, бер-бер хәл булмасын Әхмәтсафага. Черем итеп алганыем, әллә нинди төшләр күреп бетердем,"—ди. Кыскасы, мина йокы бирмәде, үземне дә эчтән корт кимерә, коралсыз-нисез чыгып киткәнеңне белгәч, тыңгы тәмам бетте, иртүк егетләрне алдым да, каршыңа киттем. Хатын-кыз күңеле сизә бит ул. Тап өстенә баскан. Гаҗәп инде, чирек чакрым юл үтәрлек вакыт соңга калсак, ни булыр иде, ә, егет?!.

—Ни булсын, "чүкеп" китәрләр иде инде. Алар сөйләшә-сөйләшә яралы эзбасар янына килделәр. Ярдагы чирәм өстендә аһ-үһ килеп шыңшып яткан табак битле таныш йөзне күреп, Әхмәтсафаның шыбыр су аркасына кайнар тир бәреп чыкты. Табак битле адәм ярасы авыртуын онытып, ачу белән Әхмәтсафага карап торды да:

—Исән икәнсең, нугай баласы. Газраилең без имәс, без—кушканны

үтәүче генә, —диде һәм, авыртуга түзә алмыйча, ыңгырашып, күзләрен йомды.

...Фәтхулла Хивага ике көннән соң гына кайтып керде. Арыпталчыккан йөзенә карап, ниндидер мөһим эш башкарып чыкканын аңлап алдылар өйдәгеләр. Хәер, ашап-эчкәч, йорт хуҗасы үзе дә ялындырып тормады, шушы ике көндә күргәннәрен сөйләп бирде. Башка вакытта үзенең эше хакында өйдәгеләргә ләм-мим дәшми йөргән Фәтхулланың кинәт сүзчәнләнеп китүенә Шәмсия исе китеп утырды.

Каштауга Фәтхулла төркеме кергәндә, Вәлкәй хаҗиның эзе әллә кайчан суынган булган инде. Әмма яралы эзбасардан хаҗиның һәм яраннарының алдан әзерләнгән яшерен урыннарын әйттерә алганнар. Әйтмәсә, ярдәмсезнисез үләсен белгәч, барысын да сөйләп биргән ул. "Иске кое" дигән җирдә, чабаннардан калган куышта тотып алганнар Вәлкәй хаҗины. Өсләренә милиция килер дип башларына да китермә-гәннәр, Әхмәтсафаның җанын кыярга киткән ике эзбасарны көтеп ятулары икән. Коралсыз-нисез бер малайны юк итүне эшкә дә санамаганнар инде алар. И өтәләнгән Вәлкәй хаҗи килеп эләккәч, и өзгәләнгән. Гөнаһсыз сабый сыман, әүлия шикелле тоткан үзен кулга алгач. Тикшерү-чегә барысы да билгеле икәнен аңлагач, хөкемгә тартылудан котыла алмаячагын төшенгәч, чөнки Әнвәр паша оештырган гаскәрләр сафында сугышып йөрергә дә өлгергән икән, ул чакта кылган явызлыклары да фаш ителгәч, Фәтхулла белән очраштыруларын үтенгән.

—Тикшерүче янында очраштык,—диде уйчан гына Фәтхулла абзый.— Бер нәрсәне дә онытмыйм, төшереп калдырмыйм дигәндәй, Вәлкәй хаҗи ашыгып-кабаланып сөйләп бирде. Сиңа, Шәмсия, китергән золымнарын да әйтте, иң аянычлысы шул, моны Әхмәтсафага әйтәсе дә килми, белсә яхшырак булыр, әткәсе Мостафаны, үч алу нияте белән, Вәлкәй хаҗи үтерткән икән. Каргалы очындагы Абдулла белән бер шәкертен котыркан... Иртән лапаска килеп керүгә, "эһ" тә итә алмый калган, элмәк салынган муенына... Синең исән калуыңны белгәч, әшәке итеп сүгенде, ис-акылларым китте, гомере буе дин дип авыз суын корыткан адәм, Ходайга яман сүз тигерде. Ышан син аңа...

Бу хәбәрдән Әхмәтсафа өнсез калган иде. Ярый, Вәлкәй хаҗи үчләшеп, шундый явызлык эшләсен дә, ди. Соң бит Абдулла абзый ачык белә, үзе дә, улы Кәрим дә янгын чыккан көнне фәкать әтисе Мостафаның яклавы аркасында гына исән калдылар. Әле дә күз алдында Әхмәтсафаның, котырынган ирләр икесен дә эләктереп алып, башта малае Кәримне, аннан абзыйның үзен утка атабыз дип, гайрәт чәчкәндә, әткәсе ирләр арасына кереп, үзенә төшкән йодрыкларга, каргыш-каһәрләүләргә игътибар итмәстән, ике мәхлукны ярсыган ирләр хөкемен-нән йолып калган иде. Ул чакта әткәсенә Саттарның әтисе нык каршы килеп, берара дошманлашып та йөрделәр хәтта. Шул Апуш үзен яклап калган изге җанга кул салсын инде. Адәм әйтсә, адәм ышанмас. Акчага сатылган дисәң генә инде. Аңламассың бу дөньяны, аңламассың. Игелек эшләсәң, җәзасы сонламас диюләре хак икән...

...Берничә көннән Әхмәтсафа округ комитетында эшен тапшырып, Каргалыга юл тотты. Хивадан аны якын кешеләре—Фәтхулла абзый, Шәмсия әңкәсе һәм сеңлесе Бибкәй озатып калдылар. Хивада үткән гомерен ул файдасыз, әрәмгә үтте дип әйтә алмый. Шулай да күңелендә авыр истәлекләр генә калдырды бу яклар. Әткәсе язмышы хакында уйлап, ул бер нәрсә төшенде, кешегә игелек күрсәтеп, аннан рәхмәт өмет итү, аянычка каршы, бу дөньяда иң зур тилелек бугай...

## IV

Минзәләгә кичке карангылык ингәч, соң гына килеп керделәр. Бөтен шәһәрне кар күмеп киткән кебек. Тәрәзәләрдән төшкән сүрән ут яктысында оеп кына утырган шәһәр. Әхмәтсафа сонга калуларына пошынып, шулай да шаяра төшеп, ямчы агайдан:

—Мине кайда бушатасыз инде? —дип сораган булды. Агайның күңел

кылларын чиртеп, үзенең алдагы тормышын бераз күз алдына китерергә омтылуы иде. Тулай торакта яшәргә тиешме, фатир-мазар әзерләп куйганнармы? Көтеп торучы бармы аны, әллә төнне һәр кантон үзәгендә булган "крестьян йортын"да үткәрерме? Әхмәтсафа яңа урынына, моңарчы ят булган кешеләргә авыр ияләшә. Бер ияләшсә, аерылып китә алмый җәфалана. Була бит кайберәүләр—бүген монда, иртәгә Кәҗә авылында—исе дә китми, бүген Гыйзди белән кочаклашып йөри, иртәгә Иван белән үбешә—"минем душа киң бит ул, дингезләргә тиң бит ул!" дип, үз-үзеннән дә, кылган гамәленнән дә канәгать булып яши бирә. Әхмәтсафа исә алай булдыра алмый. Билгеле, аның да җилкәсен нужа каешы аз кисмәде. Шөкер, яшь кенә гомерендә күп нәрсә күреп өлгерде. Кыенлыкларны ашап-ашап та сыгылмаган кешегә аерым бер караш яши. Андыйларны "тормыш тәҗрибәсе туплаган" дип, аерым хөрмәт белән караучылар да бар, әлбәттә. Тик сирәкләр генә шулай уйлый. Берәүләр ышаныч күрсәтсә, икенчеләре андый кешене әрсез алабайга чутлый, өченчеләре үзе өчен генә яшәүче хәйләкәр, шома бер затка санап сүз йөртә. Сындырып-сындырып та сынмаганны өнәмәүчеләр күбрәк. Тагын да сәеррәге—ышаналар, әмма һәр кылган гамәлен шик астына алалар. Андый кешегә иң авыр, җаваплы эшләрне тапшыралар, теге бичара, начар эшли белмәү сәбәпле, көн-төн чабып, ал-ял белми эшне җайга сала, шуна куанып, тагын да дәртләнебрәк уй-ниятләр кора, эш күзгә күренеп алга китә. Менә шунда аны туктаталар инде. Бу эшкә бөтенләй катнашы юк сыман карый башлыйлар аңа, үзен читкә этәрәләр, карышып азапланса, гөрләп барган эшне туздыру чарасына керешә хәсрәт түрәләр. Түрәне кыздырып, котыртып торучы хөсет җанлы бәндәләр табыла. Эшенең күзгә күренеп тарала башлавын күреп, ниһаять, түрәләрнең үзенә булган мәсхәрәле карашын чамалап, эшне саклап калу хакына, анда тир түгүче эшләүче—хезмәткәрләр мәнфәгатен яклау бәрабәренә эштән китәргә мәҗбүр була теге бичара фидакарь. Китмәсә, үзенә үпкәли... Аның урынына, дөнья буйлап юри эзләп тапкан шикелле, бер затсыз, белексез кешене утыртып та куялар. Җайга салынган эш ярты ел чамасы таралмаска теләп җан тартыша әле. Әмма бирешә төзек машина, чыгымчылый башлый. Эшнең көе китүен кемнән күрәләр, кемне гаеплиләр дисезме? Киткән җитәкчедән, әлбәттә. Барысы өчен дә ул гаепле... Совет илендә кеше язмышына, кеше хезмәтенә шундый караш шәкелләшеп килә. Бәндә түрәлек баскычыннан югарырак менгән саен акыллыга "әйләнә". Ул хаталардан хали зат. Һәрвакыт аныкы дөрес, ул ялгышмый, гаеп эш булса, сәбәпчесен тиз табалар. Һәм ул гаепле адәми затны һәрвакыт түбәннән табып алалар, эштән башканы белмәүче мәхлук була инде ул... Моны Әхмәтсафа күңеленең кайсыдыр чите белән тойган кебек, ләкин аңлаудан ерак әле. Вакытлы күренеш, ил тотрыклы хәрәкәткә килсә, вак-төяк житешсезлекләр тиз төзәтелер сыман иде. Надан түрәләр арткан саен югарыда уйнаш кылу, фәхешлек арта. Бу нәжеслек һәр гамәлдә, һәр адымында сизелеп тора. Әхмәтсафаның кешеләргә ышанычы зур. Алар белән сөйләшкәндә ачык, үзеннән ихласлык, җегәр, хәтта чаялык та бөркелеп тора. Әмма болар барысы да тиз яралanучан җанын, холкындагы гадилекне, җанында актарылган мең дә бер төрле уйларны башкаларга сиздермәс өчен бөркәлгән ялма хезмәтен үтиләр, кайгы-хәсрәтен, шик-шөбһәләләрен, әрнүләрен ул яшерә ала, ә менә шатлык-сөенеч булса, монда инде бернәрсә дә ярдәм итми, хәзер йөзенә бәреп чыга, хәер, йөзләре генә түгел, буй-сыны дөньяга ямь, җылы тарата башлый, күзләреннән нур чәчелә. Шатлыкны кемнән һәм ни өчен яшерәсең, ди?! Шуның өчен дә иптәшләре аны вафасыз, уенчак табигатьле, хәсрәт-борчулардан азат бер затка саныйлар. Үзләре башкарган эш һәрвакыт авыр һәм җаваплы тоела, Әхмәтсафаның эше җинелдер сыман—ул алар кебек үк интекми, көчәнми, ни кылса да үзеннән-үзе генә килеп чыккан кебек. Хәтта ки егетнең бер катнашы да юктыр шикелле.

Ямчы агай, байтак барды өлкәдән килгән вәкилгә җавап кайтармый,

шуннан соң гына, исе китмәгән төслерәк җавап кайтарды:

—Минзәләгә кадәр исән-имин китереп җиткергәч, бушатыр урынын табарбыз анысы. Монау (Монау—менә *җирле сөйләшү*.), килеп тә җиттек, кем, вәкил иптәш,—дип, чаттан борылып, шактый яктырып утырган ике катлы бина алдына китереп туктатты атын.—Башлыклар, хуҗалар, түрәләр-барысы да шушында җыелып ята инде. Төне буе йокламыйлар, көне буе тынгылык юк—кая карама алар, әле җыелыш, әле таралыш. Ничек чыдый торганнардыр. Бер нәрсәне авызларына алсалар, чәйниләр дә чәйниләр, ачуым килмәгәе, чүбек чәйнәп май чыкмый диләр, болар чыгара, туган, әллә нәрсәләр чыгара... Син, вәкил иптәш, аякларынны яза тор, мин кизүгә кереп, "йөк"не исән-имин алып кайтканга язу алып чыгыйм, аннан, боерган булса, кәнүшнигә атны туарырбыз да, җәяүләп Иркәнәшкә теркелдәрбез, әйе бит, бахбай,—дип сөйләнә-сөйләнә кантком бинасына кереп китте.

Озак та үтмәде, ишектән йөгерә-атлап чыгып килүче милиция киемендәге кеше күренде. Ул чыга-чыгышка Әхмәтсафага эндәште:

—Иптәш Дәүләтьяровмы?..

Күшеккән иреннәрен җинелчәрәк кыймылдатырга тырышып, җавап кайтарды:

—Үзе булам, Казаннан...

Милиционер күп сүз куертып тору кирәкмәс дигәндәй, юлчыны ашыктыра башлады:

—Иптәш Филиппов белән иптәш Солтанов волком җитәкчеләре белән кинәшмә үткәрәләр, сезне иптәш Мусин бүлмәсенә керә торырга куштылар.

Югарыда телгә алынган баштагы ике кешенең кантонда фирканең җаваплы сәркәтибе һәм башкарма комитет рәисе, Мусинның—агитация-пропаганда бүлеге мөдире икәнен Әхмәтсафа белә иде инде.

Мусин—эре сөякле, талчыккан йөзле кеше, Әхмәтсафа килеп керүгә, түрдәге өстәл артыннан авыр гына күтәрелеп, аңа каршы чыкты, күрешергә кулларын сузды:

—Иптәш Дәүләтьяров?.. Юлга чыгып китүегез турында хәбәр иткәннәр иде инде. Егермебишменче, значиться? Ноябрь пленумы карарларын безнең белән бергәләп тормышка ашырабыз дисез инде?

—Шулай булып чыга, ахры. Чанада Чаллыдан биреп җибәргән китаплар, плакаты-башкасы бар, бушатасы иде бит.

—Шәп, шәп. Безгә китапны олавы белән ташысаң да, артык булмас.—Мусин зарланган сыман, өстәп куйды.—Каранты яклар бит, иптәш Дәүләтьяров. Бүлектә ике-өч кеше элекке бөтен бер өязне агартып яткан булабыз. Ничек өлгермәк кирәк? Шуңа күрә Казаннан "егермебишменче" килә диюгә, житмәсә ТКУда белем җыйган кеше, Филипповка ультиматум куйдым: "Мина бирәсез!"—дидем. Мин бит ике сөйләшмим, дәвер шулай куша. Иптәш Филиппов янына башка бүлекләрдән дә кереп чыш-пыш килеп йөрүчеләр булды, ну минем холыкны беләләр, күп сөйләшкән кешенең муенына уч кырые белән генә тартам. Кылычтан ким түгел. Хе-хе... Кәк же, гражданнар сугышында илне кылыч белән аркылыга-буйга айкап чыккан кеше бит мин! Әле кичәге кинәшмәдә, Филиппов: "Вәкил юлга чыккан"—дип әйтүгә, боргалана башлаганнар иде, урындыкка кадаклап кына куйды теге кыбырсыкларны. Филиппов күзен алартып бер карады да: "Мусин, синең бүлеккә килә яна иптәш,"—дип ярып салды. Менә шулай, значиться, иптәш Дәүләтьяров. Кадрлар житми, халык арасында агарту эшен тиешле югарылыкка куясы бар. Менә хәбәрләр йөри, имеш Чаллыны шәһәр итеп, үз башка аерып чыгарасы икәннәр. Ишетмәденме андый хәбәр?—Әхмәтсафа юк дигәнне белдереп, башын чайкап куйды.—Итсеннәр, сүзем юк,—диде Мусин вәкарь генә,—ичмасам файдасы булмасмы бераз...

...Минзәләгә китәр алдыннан үзе сыман "егермебишменче"ләрне Разумов өлкә комитетына чакырып, озак кына коллективлаштыруның

әһәмияте, коллектив хужалыклар төзүгә аяк чалучы корткыч-дошманнар турында сөйләгән иде. Залда утырган районнарга китәргә тиешле дүрт йөз "егермебишменче"нең һәркайсының аңына сеңдерерлек итеп әйтте:

—Авылларда колхоз төзү эшенә аяк чалучы бер генә кулак та, аларның ялчылары да калырга тиеш түгел. Аларны шау-шусыз тиз арада җыеп алырга, тиешле урыннарга озатырга. Бүгенге көндә совет хөкүмәтенә каршы нәсихәт үзәгенә әверелгән мәчетләрне ябарга, бу эшкә каршы муллаларны, аеруча диндар мәчет картларын барлап, колхозга өндәргә, "и"гә килмәсәләр, шулай ук ГПУ кулына тапшырырга. Церемониться не будем! Яңа 1930 елның язгы чәчүен йөз процент коллектив хужалык булып каршы алырга тиеш авыл. Бу—партия куйган таләп һәм без аны, ышанам, сезнең ярдәм белән һичшиксез үтәп чыгарбыз!

Әхмәтсафаның мондый зур түрә белән беренче мәртәбә очрашуы булмаса да, үзендә ниндидер гайре җаваплылык сизеп, аның һәр сүзен хәтеренә сеңдерергә тырышты. Аннан Разумов өлкә комитетында, Казанда зыялылар арасында булып алган ун һәм сул тайпылышлар, түрәләр арасында төркемчелекнең һич тә тамырдан ук бетерелмәве, мондый чатаклыклар юк-юк та үзен сиздереп куюы, аеруча кантоннарда төркемчелек вируслары оста яшеренеп, сакланып калуы хакында нотык тотты.

—Солтангалиев сабагын тиз онытты татарлар!—дип, сөрән салды ул, залдагыларның аркалары чымырдарлык ачы тавыш белән.—Солтангалиев, аның гарип идеяләрен юк-юк та күтәреп чыгучылар табыла. Уйлап кына карагыз, утызынчы елга кереп барабыз, һаман бер балык башы чәйнибез. Никадәр тирән кереп калган солтангалиевчелек кайбер тинтәк башларга.—Разумов, көтмәгәндә, Татар коммунистик университетына ябышты.—Мин аеруча ТКУ дан килгән иптәшләргә мөрәҗәгать итәм: "Җитте!—дим. ТКУ ректоры Вольфовичның үзенә, студентларына соңгы кисәтү! Партия канаты астына сыенып инде ничә еллар Бухарин чәчкән зарарлы орлыкларны үстереп, җыеп, таратып маташалар. Оят юк, намус юк! Монарчы партия үзәк комитеты, иптәш Сталин шәхси үзе дә Бухарин, Томский, Рыков кебек партиягә кереп оялаган фәхишләргә түзеп тордылар. Төзәлмәсләрме, аңнарына килмәсләрме дип уйлау бар иде. Хәзер андый икеләнүләргә нокта куелды. Ноябрь пленумы аларның чын йөзен тулысынча ачты. Чигенү юк. Бухарин теше-тырнагы белән каршы булган авыл хужалыгын тоташ коллективлаштыру мәсьәләсе—хәлиткеч бурыч. Партия куйган барлык сроклар да үтәлергә тиеш. Тир түгеп үтәрбез, кирәк булса—кан да түгелер. Тик чигенмәбез. ТКУ дан бухаринчылар эзе суынырга тиеш, бу уку йорты шайтан оясы булудан кайчан туктый? Партиянең күрсәтмәсе ни өчен өтеренә кадәр үтәлми? Бухаринчыларның астыртын, мәкерле идеяләре шундый татлы ки, заманында үзем дә аз буталып йөрмәдем алар арасында. Вольфовичка бер генә юл—тиз арада ТКУ да эшне яңача оештырып корырга! Бүген без "егермебишменче" сафына ТКУ студентларын алганбыз икән, бер теләк белән эшләнде бу эш: студентлар тормыш белән якыннан танышсыннар, Бухарин алларына ятып сәҗдә кылган кулакның кем икәнен үз күзләре белән күрсеннәр һәм, ахыр чиктә, миләренә сеңгән черек идеяләрне сыгып чыгарсыннар!—Разумов бер тын дәшми торып, сүзләренең тыңлаучыларга ни дәрәҗәдә барып җитүен күзәтте. "Әйбәт, йотып куйдылар бу өлешен" дигән уйдан битенә алсулык җәелде. Ул татар зыялыларына әйләнеп кайтты.—Интеллигенция, зыялылар, гомумән, кызык халык. Ленин юкка гына аларны милләтнең тизәге дип атамаган. Бу кавемгә тәмам ышанычын югалткач әйткән. Татарлар белән эш тагын да катлаулырак. Болай караганда һәммәсе ярыйсы гына кеше инде менә. Акыллы, белемле, тәрбияле кебек. Һич тартынусыз, теләсә нинди катлаулы мәсьәлә хакында сөйләшеп утырырга ярый үзләре белән. Ну шуннан ары юк, чукынып кит. Тотыналар бер-берсе өстенә пычрак өяргә. Әләк, гайбәт—колаклар кызарып чыга. Кем сораган алардан моны, кемгә кирәк, һич аңлашылмый. Үзләре генә чиста, алар гына дөрес, алар гына туры.

Татар интеллигенты үз шәхесе белән генә мавыга. Башка кешене тыңламыйлар, ишетмиләр. Эч пошыр-гыч. Татар—тәкәббер, татар—куштан, татар—хөсет. Чак кына акылыгызга килегез инде, Алла коллары, ташлагыз бу яман гадәтләрне, мин моны коммунист буларак, сезнең арада яшәүче бер иптәш буларак әйтәм...—Ул авыр сулап, урынына утырды. Татарлар хакында әйтелгән әлеге сүзләрне тыңлап утыруы авыр иде Әхмәтсафага. Артык күпертә Разумов, татарга кырын каравын үзенчә акларга маташа дип, эчтән генә уйлап та куйды.

"Егермебишменче"ләр алдында Татарстан АССР халык комиссарлары советы рәисе Кәримулла Исмаев, ноябрь пленумыннан соң җир эшләре халык комиссары итеп сайланган Габдрахман Искәндәров һәм ТАССР Үзәк башкарма комитеты рәисе Байчурин чыгыш ясады.

Гомәр Байчурин чыгышын Әхмәтсафа аеруча игътибар белән тыңлады. Байчурин берничә ел Минзәлә кантонында эшләгән. Андагы уң тайпылышларга каршы оештырган көрәше хакында озаклап сөйләде. Бигрәк тә, егерменче елларда Минзәлә кантонында эшләп киткән Мингә-рәй Сагыйдуллинга каты эләкте. Ул чәчеп калдырган солтангалиевчелек орлыклары, милләтчелек тәгълиматы белән көрәшүнең никадәр авыр һәм мәшәкатьле булуы, шулай да кантонда сагидуллинчылыкның бер генә шөребе, винтигы да калмавын искәртеп, инде Минзәләдә тамырланган "бухаринчылык"ны бетерү кирәклегенә басым ясады. Болар турыдан-туры Әхмәтсафа Дәүләтьяровка төбәп әйтелгән сыман яңгырады ул чакта. Менә хәзер ул Минзәләдә, Разумов әйткәнчә, үз-үзенә галәмәт ышанган тәкәббер татар түрәсе каршында тора.

Мусин бүлмәсендә салкынча иде. Әхмәтсафа кергән уңайга кызуланып, өстендәге озын шинелен салып куйган иде, ул аның Саескан базарында берничә айлык стипендия акчасына сатып алган иде, кире иңбашына элде һәм, әңгәмәдәшенең аңа урын тәкъдим иткәнен дә көтмәстән, күн аркалы урындыкка утырды. Арылган, берничә көн юлда булу тәмам йончыткан иде.

—Хәзер инде озаклап сөйләшергә вакыт та юк,—диде Мусин урыныннан күтәрелә башлап.—Киңәшмәгә кереп тормассыз, мин иптәш Филипповка тиешенчә җиткерермен.—Ул елмая төшеп Әхмәтсафага өлкә комитетыннан биргән юлламаны кулында әйләндерде.—Юлламаны алып калам, хәзер сине кизү бүлегеннән берәр милиционер фатирга илтеп куяр. Иртән иртүк килеп җитегез. Безнең монда төн-көн юк. Ноябрь пленумы карарларын үтәү, ай-һай, җиңел бирелми. Инде нигездә бөтен волостьлар колхоз төзү турында рапорт бирәләр. Әмма кулаклар аяк чала-а!..—дип сузды ул әрнү белән.—Һич акылга китереп булмый үзләрен. Бүгенге көндә авылларны кулаклардан чистарту бара. Мулла-мәзиннәрне җыябыз. Мәчет картлары белән Минзәлә төрмәсе тулды. Ә күпме авылга кул да тимәгән әле?!. Иртәгә сине ерактагы авылларның берсенә—Әмәкәйгә җибәрәм. Зур авыл, базарлы-ярминкәле авыл. Үҗәт халык яши. Борынгыдан волость үзәге булгач, теләсә нинди килмешәк килеп тулган. Сәүдәгәрләрен, кулак, муллаларын җыеп алып кайтабыз. Син вәкил булып барасың. Борчылма, Әмәкәйдә ышанычлы иптәшләр эшли, әллә кайчан исемлек төзеп куйганнар. "Кайчан җыеп, алып китәсез!"—дип, бәгырьгә төштеләр инде. ГПУ дан кешеләр бара. Олаулар белән авыл үзе тәэмин итә. Анысы да хәл ителгән дип хәбәр итәләр. Утызлап кешене төрмәгә китереп ябасы була. Аларны исән-имин китереп җиткерүсинең җаваплылыкта!

Әхмәтсафаның йөзе бозылды. Моны Мусин да күреп алды, вәкил иптәшне тынычландырырга ашыкты:

—Аңлыйм, аңлыйм иптәш Дәүләтьяров. Күңелле эш түгел. Ләкин башкача мөмкинлек юк. Авылларны кулаклардан, башка корткыч элементлардан чистартмый торып, без колхозлар төзи алмыйбыз. Төзеп карадык инде—бер генә хәлле кеше дә колхозга аяк басмый. Җыен

хәерче, жирсез, суыгаяклар кереп тулды менә. Алар белән нишләп булсын? Кулак сөенә, эчтән генә көлеп йөри. Аңа колхоз нигә? Атлары шәп, жирләре әйбәт, көч бар, кирәк булса яллап та эшләтә. Әнә хәбәрләр килеп тора: бер хәерче байгыш колхозга кергән, үзе кулакка ялланып ашлык суга икән. "Ул кумхужның нәмәсе бар соң? Менә мин эшләгән фәлән абзый кебек ныгысын башта, аннан килермен кумхужга эшләргә,"—ди икән. Менә йөр син аны колхоз әгъзасы дип. Дөрестән дә, кеше түгел, әгъза гына инде ул. Бер генә юл кала—кулаклардан ашлыкны, машинаны, каралтыны тартып алып, колхоз милке итәргә.

—Ә үзләре ни эшли инде ?

—Кемнәр?—дип сорады, Мусин аптырый төшеп.

—Хәлле крестьяннар диюем. Алардан башка күмәк хужалык төзү көлке бит. Кем эшләр колхозда?

—Бухаринчы!—диде зәһәрләнеп Мусин.—Син генә житмәгән иден монда! Энекәш, андый уй белән килсәң, дүрт ягын кыйбла, юлларына ак жәймә. Синнән башка да баш буталып беткән. Колхозда кем эшләр, дисең. Әле аны башта чынлап төзергә кирәк. Эшләүчеләр табылыр. Татар хатыны ике елга өч бала таба. Жиде яшьтән кулына урак тота башлый татар баласы, утауга чыга. Беренче адымны ясау кыен, аннан майлаган коймак булачак эшләр. Кулакларны гына себереп түгик менә. Күрерсең, иптәш Дәүләтьяров, партия сүзе өскә чыгачак!

Әхмәтсафа саксыз сүз ычкындырып, Мусинны кыздырып жибәрүен аңлап, телен тешләгән иде инде. Чак кына онытылып китте егет, ТКУ да күнегелгәнчә, бәхәс урыны түгел бу. Чыннан да, әгәр аның фикерен элэктереп алып, күпертеп-купайтып, Казанга житкерсәләр, икеләнмичә, үзен дә төркемчелектә гаепли башлаячаклар, ул инде өлгереп житкән кеше, гаиләсе бар, саграк кыланса да ярыйдыр. Рабигасы белән кавышып, иң матур көннәрен кичергән чор, һич кенә әллә нинди хикмәтләргә буталып кереп китәсе килми иде.

—Мин болай гына... —диде Әхмәтсафа Мусинның сүрелә төшүен күреп.—Сезнең фикерне белергә теләгән идем. Иң мөһиме—әңгәмәдәшнең нинди мәсләктә торуын ачыклау бит, сынап карау димме. Килешәм, кулакка күмәк хужалык кирәкми. Партия тулысынча коллективлаштыру бурычын куйган икән, ул үтәлергә тиеш, ничек булса да үтәлергә тиеш...—Ул Разумовның "тир түгеп, кан белән" дигән сүзләрен исенә төшерде. Бу эшнең никадәр авыр һәм каршылыклы булуын аңлап бетерә микән фирка житәкчесе үзе?.. "Дөнья хәлен белеп булмый, үз башына төшмәсә," диләр, инде үзенә турыдан-туры шушы аңлаешсыз көрәшкә кушылып китәргә язган икән. Китаптан укыган бернәрсә, ә гамәл икенче нәрсә шул.—Шулай да, бераз аңлатып, сөйләп-күрсәтеп жибәрерсез инде. Болай гына чыгып китеп...

—Сөйләрбез дә, күрсәтербез дә, иптәш Дәүләтьяров. Моннан соң иптәшләрне сынап жәфаланма, без барыбыз да кат-кат сыналган. Бусы дусларча киңәш. Утлар-сулар кичкән иптәшләр. ТКУ да укымасак та, "Минзәлә мәктәбе" диләр моны, бу мәктәпне үткән иптәшләрне Казан үзенә жыя тора. Сагыйдуллины да алды Казан, Байчуринны да, башкаларны да...

—Сагыйдуллинга төрлечә карыйлар Казанда.

Мусин көчәнеп көлеп жибәрде. Инде саксыз сүзне ул ычкындырган иде.

—Бусы сине сынау өчен, дускай. Сагыйдуллин турында болай гына сүз кузгаттым... Үжәт кеше ул, арты белән киртә жимерергә маһир. Әйдә, киенә тор, хәзер үк кизү милиционерны чакыртам, озатып куяр фатирыңа...—дип, Мусин ишектән башын тыгып, үтеп баручы адәмгә кычкырды:

—Кизүне жибәр әле монда, Хәбибуллин. Эш бар!

* * *

Юл йөрүгә күнегеп киләме, сәфәргә Әхмәтсафа авырыксынмый кузгалды. Алда нинди эшләр торганын да чамалап бетерми, Мусин белән булган кичәге сөйләшүдән мәгънә тапмады әллә-ни. Яна көн туарга өлгермәде, ул инде кантон бинасында иде. Башкарма комитет рәисе Солтанов ГПУ дан әлеге эшкә җаваплы итеп билгеләнгән Шәмтиев дигән кешегә жентекләп Әмәкәйгә ничек барырга икәнлеген, иң беренче кемгә мөрәҗәгать итү, җыелган халыкны ничегрәк тынычландыру, кулак-муллаларын алдап-йолдап чанага төяп, авылдан чыгып таю серләрен аңлатуын тыңлап утырды. Шунда гына нindирәк эшкә килеп капканын чынлап аңлады. Филиппов бүлмәсендә дә булып чыкты, ана чыннан да Мусин кул астында эшләргә туры киләчәк. Агитация-пропаганда бүлегендә исә кулына культпроп мөдире итеп билгеләнүе хакында язу тоттырдылар.

Ат менгән гаскәриләр—ГПУ кешеләре озатуында ике кашовка, Минзәләдән чыгып, "Әби-патша күпере" дип аталган дугалы тимер күперне үтеп, калын урманга килеп керделәр. Алдагы кашовкада Шәмтиев белән башкарма комитеттан кулга алынган кешеләрнең йорт-малларын конфискацияләргә тиешле хезмәткәр бара, Әхмәтсафа янына хәрби комиссариаттан нindидер йомыш белән юл өстендәге бер авылда төшеп калырга тиешле Шәйхенур исемле утыз яшьләр тирәсендәге ир-егет утырды. Кашовкалар да ГПУдан булып, кучерлары аркаларына винтовка аскан гаскәриләр иде.

—Ул винтовкаларынны салып, рәхәтләнеп барсаң ни була инде?—дип сүз башлаган иде Шәйхенур, гаскәри кырыс кына җавап кайтарды:

—Утыруынны бел, синнән сорамыйлар!

Шәйхенур тыйнак егет булып чыкты, юкка-барга кысылып баруына кыенсынган сыман, шактый дәшми барды. Бары Минзәлә күперен чыкканда гына телгә килде:

—"Әби-патша күпере" дип йөртәләр моны,—диде ул, толыпка (шулай ук ГПУ милке дип бирделәр) төренеп утырган Әхмәтсафага табан борылып,—кем әйткәндер бу сүзне, әле моннан егерме еллар элек кенә, бәләкәй чак минем, әткәй Минзәләгә алып барган иде, ярминкәгә, пыр тузып шушы күперне төзеп яталар иде. Ис-акыллар китеп карап торганым хәтердә. Бакчи, кем уйлап чыгарган диген, "Әби-патша күпере," имеш. Хан заманындагы әби-патша каян килеп чыксын, ди эт олаккан җиргә? Кызык инде, уйласаң.

—Әби-патша—Екатерина икенче чыннан да бу яклардан үткән,—Әхмәтсафа, юлдашына тарихтан хәбәрдар икәнлеген сиздереп алды.

—Кит әле?—диде Шәйхенур, көтмәгәнчә, гаҗәпләнеп.—Ни калган аңа монда? Пайтәхетендә генә утырса ни булган инде, чыдамый адәм баласы рәхәткә. Күрмәгәннең күрәсе, күргәннең качасы килә, хак сүз. Мин үзем герман сугышында яралангач, пайтәхеттә госпитальдә яттым. Инкыйлаб көннәрендә урамнарында йөрдем, Ленинның чыгышын тыңладым. Питер—зур шәһәр, Минзәләне шәһәр дип йөргән булалар, Ходаем. Питер янында адәм көлкесе генә бит ул. Ә шулай да Әби-патша ник килгән соң монда?

—Себергә барышлый үтеп киткән. Ул чакта осталар үзләренчә матурлап-сырлап агачтан төзеп куйганнар Минзәлә елгасы аша күперне. Әби-патша күз дә салып тормаган диләр осталар айлар буе тырышып корган күпергә.

—Салган, ди! Патшага нәмәгә синең күперең? Питердә күпер күрмәгәнмени ул? Андагы бер-бер күпергә ике урамы белән безнең Чүплек авылы кереп кенә утыра.

—Чүплек? Шундый исемле авыл бармы?

—Беренче мәртәбә ишеткән кешеләр шулай аптырыйлар инде,—диде Шәйхенур бу сорау биреләсен алдан белгән шикелле.—Авыл исеме инде. Ык буенда, бик матур урында ул безнең Чүплек авылы. Бабайлар авылга исем эзләп озак баш ватканнар, нигез корган җирдә Чүплек елгасы ага икән, шуннан тотканнар да авылга шул исемне чәпеп куйганнар. Әткәй

минем бә-әк укымышлы кеше, чүп—үлән дигән сүз, ди ул, димәк, үлән каплап алган елга дигәнне аңлаткан Чүплек елгасы.

—Чүп сүзе казакъларда да үлән дигәнне аңлата бит. Ишеткәнем бар казакъ арасында йөргәндә.

—Йөрмәгән жирең калмаган икән. Казакъча булса да шаклар катасы юк, безнең якта үзенә башка халык яши. Кыска буйлы, нык бәдәнле, кәкре аяклы. Шул якка тартымрак. Көчле кешеләр. Мин үзем дә күп йөрдем татар-мөселман арасында. Бездә башкарак халык, икенче төрлерәк...

Әхмәтсафа төпченүен дәвам итте.

—Еракмы соң әле авылыгыз?

—Аюны чыккач, Кәжә авылы. Сез шунда ял итәргә, атларны ашатып алырга туктыйсыз. Мин җәяүләп кенә Ык өсләтеп Чүплеккә элдерәм. Күп калмый—дүрт-биш чакрым гына.

—Безгә бит Матвеевка авылына житмичә, ялга туктау юк дигәннәр иде...

—Шул Кәжә авылы инде ул. Матвеевка дип йөртәләр урыслар.

—Моның да тарихы бардыр инде.

—Тарих дип... Әткәйдән ишеткәннәрдән чыгып әйтсәм генә. Бу якларда борынгыдан татар ыру-ыру оешып утырган авыл төзеп. Аю ыруы, Кәжә ыруы, Бурсык ыруы, Әтәс, Куян, Колын, Елан ырулары... Безнең як халкы бер дә тынгы белмәгән бит. Патшага каршы чыгып, яу чаба торган булганнар. Тикмәгә түгел инде, патша боларның жир-суларын тартып алып, үзләрен чукындырырга маташканга. Чукынмаса—күтәрә алмаслык салым. Патша гаскәр белән килеп авылларны тамыры-ние белән яндырып китә, тагын тернәкләнә халык, тагын баш күтәрә. Нинди генә яугирлар булмаган безнең якларда!—Шәйхенурның үзенең дә каны уйнап алды булса кирәк, урынында тыныч кына утыра алмыйча, кыбырсый башлады, карга күмелеп, тын гына оеп утырган агачларга карап, монсу тавыш белән өстәп куйды.—Һи-и, бу урман йоткан һәммә серне дөньяга чыгарсаң... Батырша дигән каһарман, Теләкәй, Алдар, Күчем, Акай, Килмәк батырлар... Булган безнең курку белмәс бабайлар!.. Барысы да шушы якларда яу корып йөргәннәр. Шуннан соң урыслар мөселманнарны җирләреннән кубарып, Ык аръягына куып чыгарганнар. Исән калган авыл йортларына урыслар кереп утырган. Менә шулай Кәжә ыруы үзенең авылын югалткан. Матвеев исемле урыска, патша кешесенә бүләп биргәннәр Кәжә авылы жирләрен. Менә сиңа тарих... Синең Әмәкәйдә дә булганың юктыр инде?

—Әйтәм ич, бу якларны беренче күрүем...

—Инкыйлап чорында аклар белән сугышлар булган тирәләр инде. Бәете дә бар иде. Хәтердән чыкмаса, әйтеп бирәм.—Шәйхенур бәетне исенә төшерергә азапланып булса кирәк, тын калды. Озак үтмәде, бер жайга көйләбрәк бәет әйтә башлады:

Тарих мен дә тугыз йөз дә
Унсигезенче елларда;
Акларга каршы бардык без
Совет властен якларга.
Киткән чакта, сау бул, диде,
Ятим карчык—әнекәй дә.
Бомба белән бәреп ектык
Теләнчинне Әмәкәйдә.
Әмәкәйне алганнан соң,
Барып кердек Бакалыга,
Бездән һич тә тынычлык юк
Андагы ак якалыга...

Шәйхенур, нигәдер көрсенеп, бәет укуыннан туктап, сүзгә керешге.

—Озын бәет инде. Туган туганның канын койды ул чакта. Син яшьрәк булгансыңдыр, исеңдә бар микән?

—Булмыйча! Безнең Оренбур якларында да булды инде хәлләр...

—Шундыйрак авыл инде ул Әмәкәй. Кызыллык көчле булды нигәдер... Бәете дә "Кызыл көрәшчеләр бәете" дип атала.

...Матвеевкада ял итеп алганнан соң, тагын юлга кузгалдылар. Шәйхенур җәяүләп үз авылларына китеп барды. Юлдашыннан аерылып, ялгыз, сөйләшми баруның бер ягы яхшы булды—иркенләп үз уйларында йөзәргә җай чыга. Ык елгасын кичеп, атлар Әтрәкле дигән авылга йөз тотып юырта башлагач, Әхмәтсафа уйлар диңгезенә чумды.

...Хивадан кайтып, Каргалыда озак тормады ул. Рабига белән очрашкан-кавышкан татлы минутларны искә алмаганда, хәтердә яңартыр-лык тагын ни булды икән? Әйе, Рабиганың башка чарасы калмаган, әнисе белән энесен, качырып диярлек, үзе белән алып килгән иде. Алдан хат язып, килешкәнчә, Атбасар качаклары вакытлыча Каргалыда, Әхмәтсафаларның өенә урнаштылар. Әнисе, кечкенә буйлы, бөтерчек кебек Хәлимә апай белән танышып, бер-берсен бик тә үз иттеләр. Эре сөякле үсмер Шираз—Рабиганың энесе белән дә тиз дуслаштылар алар. Шираз һәр нәрсәдән кызык табып, кәмит ясарга һәвәс икән, аеруча кеше булып кыланырга ярата. Әхмәтсафа ана "әртист" дигән кушамат та тагып куйган иде, Ширазга гына ошап житмәде:

—Артист булмыйм ла мин...—диде ул уенны чынга алып.

—Кем буласың килә?—дип сорады Әхмәтсафа, үсмернең кинәт житдиләнеп китүен күреп.

—Кавалерист!—диде горур рәвештә күкрәген алга чыгарып Шираз.—Буденный кебек ат өстендә, кылыч белән менә шулай, менә болай акларны кырасың гына...—дип, ат өстендәге кызыл җайдак кыяфәтенә кереп, ишек алдында килештереп сугыш уены да күрсәтеп алды.

Малайның минут эчендә шундый үзгәреш кичерә алуына сокланып, Әхмәтсафа кулын Ширазның шактый нык җилкәсенә салды:

—Кылыч селтәп чабардай кавалеристлар күп булыр ул, кайнеш. Ә менә артист һөнәре алсан...

Рабига, бер читтән аларның сөйләшкәннәрен тыңлап тора иде, "кайнеш" дигән сүзне ишеткәч, комачтай кызарып, тизрәк өй ягына атылды. Әле һаман, бер-берсен сөйсәләр дә, вәгъдәләр бирешүдән узмый мөнәсәбәтләре. Әхмәтсафа янә Казанга укырга китәргә җыена, Рабига исә, ТИНО ны тәмамлап, быел көздән Каргалыда укыта башлый. Казанда ни булып бетәр, Әхмәтсафа юлына кемнәр очрар, егетнең берәр чибәркәйне күреп, башы әйләнеп китмәсме?.. Уйлый башласаң...Кызның күңеле тулы шөбһә. Ул Әхмәтсафага бик тә ышана. Шулай да... Инде яше дә бара бит. Егерме яшьтән үткән кызларны "сазаган" дип үртәргә дә күп сорамыйлар аны.

Хәлимә апайның исә үз хәсрәте, үз борчуы. Карты Мөхәммәтҗан кызларының сәвит яклы булып китүен, гореф-гадәтне бозарга җөрьәт итүләрен күтәрә алмады. Сырхауга сабышты башта. Исенә килгәч, Хәлимәне җәберли башлады, түзәр әмәл калмады, ул да булмады, ир кеше яшь бичә алып кайтты. Әле бусына түзәргә буласы икән. Көндәш белән яшәү бер Хәлимәдән генә калмаган. Мөхәммәтҗан торган саен холыксызлана бара. Бигрәк тә Җамалның ялан баш йөрүенә үчекте. Кызның ирдәүкәләнеп йөрүен, бары тик хатыннан гына күреп, Хәлимәне төпчек улы Шираз белән өеннән үк куып чыгаргач, дөньялар җимерелеп төшкән кебек булды. Кешедән кешегә йөреп, тамак ялына йорт эшләрендә булышып, кайда туры килсә, шунда куныл йөргәндә, бәхетенә, Рабига кызы кайтып төште. Өйдән куып чыгарса да, Хәлимә моны аерылышу дип уйламый, ире бер акылына килеп, өйләренә кайтарып кертер дип өметләнә иде. Рабига катылык күрсәтте, икенче көнне үк, ай-ваена карамыйча, Каргалыга алып китте үзләрен. Әүвәл Оренбурда, Рабига янында тулай торакта көн күреп азапландылар. Әхмәтсафага рәхмәт, һич тә авырыксынмый өйләренә алып кайтты, Гомәрхан абыйсы белән сөйләшеп, аларны өйдәш итеп урнаштырды. Гомәрханы да ипле булды. Алар киләсе елны Оренбурда тракторчылар мәктәбендә укып, авылга беренче тракторны алып кайткан ир-егет ул! Инде яздан бирле Зариф белән колхоз

тәзибез дип женләнеп йөриләр икән. Күмәкләшеп язгы чәчү үткәргәннәр менә. Игеннәре матур булып өлгереп, башаклары тулышып килә. Гомәрхан сабантуенда өйләнеп җибәрде, хәзер үз тормышы. Һаман-һаман кеше өстендә торуы кыен бит. Бу хакта сүз кузгаткан иде, Әхмәтсафа килештереп бетермәде:

—Хәлимә апай,—диде ул, кулын йөрәге турысына куеп.—Мин бит сезгә чит-ят кеше түгел. Рабига минем булачак кәләшем. Казанга барып урнашыйм, бераз унны-сулны карарга кирәк, аннан инде Рабигага эш белешермен. Бер дә борчылмагыз, мин сезне үзем белән алып китәм Казанга.

Хәлимә апайның күзләренә яшь тыгылды. Бердән, шулай бөтенләй чарасыз хәлдә, кешегә мәшәкать тудыру өчен өзгәләнсә, икенчедән, Әхмәтсафаның миһербанлы, игелекле булып, алар өчен борчылуын күреп, күңеле йомшарып китте.

Күзеннән яшь килмәс ди. Казан дигән шәһәр хакында күпме ишетте ул, ә менә үзе дә шунда барып, көн итәчәге төшенә дә кермәде. Казанга китү дигәнне ишетсә, йөрәге әллә нишли, бик ымсындырса да, күңеле борчыла, һич кенә дә аягы тартмый иде шунда. Ерак, ят шәһәр, күз күргән җирләр түгел. Үзе гомер кичергән Атбасарын сагынып яши, хәтта холыксыз, дуамал ире Мөхәммәтжанга да бер ачуы да юк сыман. Исенә төшсә, үзәкләре өзелә—үз сүзле картына Каргалыга килеп житкәч тә хәбәр салганнар иде, җавап җибәргәне юк. Шулай аралары тәмам өзелер, килеп хәлләрен дә белмәс микәнни?.. Ни дип әйтәсең, яшь бичәсе белән чөкердәшеп тик ята торгандыр инде, Хәлимәдә, балаларда кайгысы юк. Казан дигәндә. Шунысы бар бит әле, Хәлимәнең бабалары шушы яктан, казан татарлары, күптән инде Атбасар якларына килеп чыгып, төпләнеп калганнар. Казанга бару түгел, Казанга кайту булып чыгар иде, Әхмәтсафаның нияте барып чыкса...

* * *

Казанга сентябрь ахырларында килеп төште Әхмәтсафа. Казан—Оренбур түгел, Хива—Бохараларны телгә дә аласы юк, Европа шәһәренә тартым.

Татар коммунистик университететында инде укулар башланган. Тиешле эшләрне үтәп, кәгазьләрне тәртипкә китереп, тулай торакка урнашканчы октябрь ае да житте.

Оренбурда озак тоткарлануының сәбәбе—әйтсән-әйтмәсән дә Мусага, аның яшьлек дустына барып тоташа иде. Муса июль аенда ук Мәскәүгә китеп барган. Әхмәтсафа аның белән сирәк булса да хат алыша иде, соңгы хатында Муса: "Мин Оренбурда август ахырына кадәр булам, мина кагылмыйча калма, Казанга бергә китәрбез,"—дип язган иде. Ул инде Казанда рабфакта укып, язучы-шагыйрьләр белән аралашып чарланырга өлгергән. Сүз иясез, имеш-мимешләргә караганда, Казанда әллә өйләнергә ниятләп йөргән, әллә өйләнеп тә караганмы, һәрхәлдә, танышлары әйтүе буенча, мәхәббәт мәсьәләсендә Мусаның күңеле киң, йөрәгенә атна саен бер гүзәл кереп утырырга мөмкин, ди, бәлки шул сүзләр раска чыгып, "гөнаһлары" артып ашкан да, егет Казанга бару уеннан кире кайтканмы, әллә үзенә хас булганча, "асылынсаң асылын—агачның асылына" дипме, ул Мәскәү университетына укырга керергә ниятләп китеп барган булып чыкты. Әлеге хәбәрне ишеткәч, Әхмәтсафага кыен булып китте, Муса дустына ышанып, ярык тагарак янында утырып кала язуы дөрес. Каргалыга кайтып кергәч тә, озаграк юанды, шундук Мусаны эзләп калага юл чыгасы калган да... Артык ышанды шул. Хәзер инде таныш булмаган шәһәргә ялгызы чыгып китәргә туры киләчәк. Хәер, артык катлаулы эш булмас анысы, егет илләр гизеп кайткан кеше бит. Муса булса, аны Оренбурда тоткарлап маташмаслар иде, шул гына.

Губкомда Әхмәтсафаны көктән ингән бәхет дип кабул иттеләр. Комсомолның губком секретаре, Әхмәтсафаның Казанга укырга китәргә җыенып, документлар хәстәрләп йөрүен белгәч, сөмсере коелып, кырт кисте:

—Бернинди Казан юк, иптәш Дәүләтъяров. Һәркайсыгыз жә Казан,

жә Мәскәү дип хыяллана. Губернада кем эшләр? Мәнди анасымы?– Әхмәтсафаның ана каршы төшәргә маташуын күргәч, бөтенләй кызып китте.–Юк булгач, юк! Рөхсәт итә алмыйм? Әнә Муса урыны буш, хәзер үк вазифанны кабул итеп ал да, эшкә тотын. Сине Казанда беркем дә көтеп тормый, беркемгә кирәгең дә юк. Барыгыз да интеллигент булмакчы. Беләсенме, Совет иле сезнең ише интеллигентиклардан гарык инде, аларны корабларга төяп, чит мәмләкәтләргә юкка гына озатмыйбыз! Кирәге юк аларның. Безгә башы юк-бар акыл белән тулып, диңкеп, сөрсеп бетмәгән, кыю эшче-крестьян яшьләре кирәк. Хезмәт урыннарында тормыш университетын үткән, коммунистик аңга ия булган бер кешене институт тәмамлап, диплом алган ун белгеч тә алыштыра алмый. Аңлашылдымы, иптәш Дәүләтьяров? Аңлашыла, әмма төшенеп житмисең. Сиңа бер генә юл–губком үзенә эшкә чакырып торганда, сөенә-сөенә кил, сузып йөрсәң, мондый урыннан бөтенләй колак кагып куюың да мөмкин.–Губком секретаре сүзен тәмамлап, мәсьәлә хәл ителгән чамасында егетне бүлмәсеннән чыгарып жибәрде. Ишекне япканда аның:–Кадрлар бүлеге уңнан өченче ишек, гариза яз да... –дигән сүзләре генә ишетелеп калды.

Губком бинасыннан чыккач, Әхмәтсафа исәңгерәгән кыяфәттә шактый басып торды. Кесәсендә инде жәй башында ук килгән чакыру кәгазе. Ирексездән, шул язуны капшап карады, фирка билеты белән ни эш кылырга? Исәпкә басмый ярамый. Фирка дисциплинасы каттый. Исәпкә бассаң да харап, кире исәптән төшеп йөргәнче ярты ел үтәчәк. Ярый, исәпкә басып тормадың, ди... Анысын Казанда хәл итәр ул. Тагын бер кыенлык бар–аның эш кәгазьләренә: "Әхмәтсафа Дәүләтьяров Оренбур губерна комитеты карамагына жибәрелә,"–дип язылган. Моны Рәжәпов–Хорезмдагы түрә белеп эшләгәнме, әллә чыннан да тәртип буенча, кеше юллама белән кайдан килгән, шунда кайтарып жибәрелергә тиешме, егет уйлап-нитеп тормаган иде ул чакта. Шуның аркасында тоткарлык та була язды менә. Кат-кат сызланды егет: их Муса булса-а! Моның ише хәлләргә төшеп, айдан артык вакытын сарыф итмәс иде лә ул... Йөреп-йөреп тә губкомнан кирәкле язу ала алмый, юлга чыгып китте.

Казанга килгәч, бәласен аз татымады. "Оренбур губкомыннан рөхсәт язуың юк,"–дип, тулай торактан урын бирми азапладылар. Бәхеткә каршы, ТКУ директоры, үзе дә күптән түгел генә Мәскәүдән жибәрелгән илле яшьләр тирәсендәге хәрәкәтчән яһүд адәме–Алексей Абрамович Вольфович егетнең кангырып йөрүен күреп алып, тулай торакка урнаштырып ук куйды..

...Яшьләр булган һәр жирдәге кебек үк университет та гөрләп тора. Әхмәтсафа монда үзенең элекке сабакташы Фатыйх Сәгыйтовны очратты. Ул инде сүзгә, фаразларга, коткы салырга оста, Әхмәтсафаның ТКУга керүен белеп алгач, астыртын гына чеметеп тә өлгерде:

–Оренбур сәүдәгәрләре Казанга жыелып бетә болай булгач...

–Мин сәүдәгәр түгел,–диде Әхмәтсафа, каты итеп. Әлеге сүзнең үзенең башына бәла булып төшәчәген сизенгән сыман.–Үз тамагын үзе туйдырган крестьян баласы булам мин! Әйләндермә юкка кеше башын.

–Алайса тыныч бул. Нигә соң бу тиклем өректең? –дип, көлгән булды Фатыйх.–Мин бит болай гына, электән үк белгән кеше буларак кына...–Бөтенләй көтмәгәндә сорау бирде:–Үзең кайсы якта соң син? Кем тарафдары?

Әхмәтсафа сәерсенеп китте.

–Ничек кайсы якта? Белүемчә, без барыбыз да бер якта–совет ягында, совет тарафдарлары.

–Һә-һә...–Фатыйх, мыскыл иткәндәй чыркылдап алды.–Ялгышасың егет. Бу бит Казан! Казан ул бер генә минут та кайнамый тормый. Самовар сыман пар бөрки, әче төтен тузгыта-тузгыта кайный ул Казан. "Ун"нар да бар, "сул"лар да житәрлек. Солтангалиевчеләр үз якларына тарталар, Троцкийчылар үз якларына, инде Хатаевич, өлкә комитеты секретаре: "Туйдым бу татарларның бер-берсен чәйнәүләреннән, китәм, минем урынга башка кеше табыгыз!"–дип, Сталинның үзенә үк барып житкән, ди.

—Син тамчы да үзгәрмәгәнсен, һаман элекке Фатыйх. Белмәгәнен юк.

—Дөнья өйрәтә ул,—диде Фатыйх, мактанган сыман. Ачылып китеп, акыл да сатып алды.—Белсән-белмәсән барысына кысылган бул, сүз әйтеп кал, бу кешенен үз фикере бар, дип уйласыннар. Шулай булмаса, ни пычагыма сон ул уку дигәннәре? Кесәдә кәгазь йөртү өченме? Хәзердән үк үзенне күрсәтергә өйрән, күрсеннәр, исләрендә калдырсыннар. Укуны тәмамлагач, эшкә биш куллап кабул итәрләр. Минем караш шулай. Бәхәстә—хаклык!

—Белсән-белмәсән кычкырып, нинди хаклыкка ирешмәкче буласын?

—Ә син белеп кычкыр. Мин үземчә барам.

Әхмәтсафа бәхәсне күпертеп җибәрмәскә тырышып, Фатыйхтан Оренбурда укыган таныšлары хакында сораша башлады. Фатыйх һәр сабакташын атаганда ничектер борынын җыерып ала. Саный башлады:

—Муса инде зур кеше булып маташа. Ул, имеш, шагыйрь. Һи-и, монда анын ише шагыйрьләр буа буарлык. Мыж килеп тора. Аны чәйнәп кенә төкерәләр мондагы шагыйрьләр. Шуна Мәскәүгә качты ул.—Фатыйх кисәк кенә Әхмәтсафага төртеп куйды.—Гайшәнен башын әйләндереп йөргән иде, коры калды кыздан. Хәзер Гайшә медицина институтында укый. Профессорларга күз кысып йөри инде ул анда, белмәгән Гайшә түгел. ТИНО да гел мөгаллимнәр тирәсендә әйләнде. Беркөн очраган идем, җүнләп сөйләшмәгән була, хар-рап инде... Мусанын монда әллә ничә "Гайшә"се булган ди, дөрес булса, берсенә бәби "бүләк" итеп киткән бугай. Шулай булгач, чамала. Муса тиз генә Казанга аяк баса алмый ул. "Гайшә"ләре чәченә ябышыр дип тә курка. Фатыйх Исхаков та Мәскәүдә. Нургали ага Надиев—гыйльми үзәктә. Мина салкын карый ул кеше, мин ана нәрсә эшләгән? Зиннәт, Саттарларны, үзен беләсен, Казан шулпасын чөмерәләр—һәркайсы белем алабыз дип, тилмереп йөри. Ин кызыгы—Кәрим, шул Каргалы борчасы да Казанга килеп, каядыр укырга кергән, дип ишеттем. Күзгә-башка күренми. Ул—астыртын егет, чәчрәп чыкмый, безнен сыман җүләр түгел.

Кәрим исемен ишеткәч, Әхмәтсафанын кәефе төште. Вәлкәй хаҗинын сүзләрен әле ул Гомәрханга да әйтми торган иде. Тел сөяксез, ни сөйләмәс, үзем ныклап эзенә төшәрмен дип уйлап та йөргән иде. Каргалыда шуны белде, Абдулла гаиләсен алып авылдан китеп тә барган икән. Җаек шәһәре тирәсенә дигән сүзләр генә ишетә алды. Кәримне күреп, белешсән, начар булмас иде...

Инде, китәм дигәндә, Фатыйх, янә Әхмәтсафанын касыгына төртеп алды.—Карале, беркөнне Заһидәне күрдем. Хәтерлисенме, ТИНОда... артыннан чабып маташкан иден. Ул сине Бохарада очратканын сөйләп бирде. Шәп кыз, башкалар кебек борынын өскә чөйми. Теге вакыттагы саташулары беткән, житди кызга әйләнгән. Хәзер медицина институтында укый икән. "Такташ белән хыялланасынмы?"—дигән идем, көлә, "җүләр чаклар үтте инде" ди. Шәп кыз, күзен төшеп йөри иден, боткагыз пешмәде, ахрысы. Хәзер ничек сон, янабаштан гыйшык-мыйшык уенына керешмисенме?

—Минем ярәшкән кызым бар.—Йөрәге кысылып куюын сиздермәскә тырышкандай, йөзен читкә борды. Заһидәгә исемен ишетү түгел, искә генә килеп китсә дә, битараф кала алмый ул. Күз алдына килә дә баса. Югыйсә, инде күнеленнән сызып атканга биш былтыр кебек, искә төшсә, үзәге өзелә куя, каһәр. Кызнын Казанда икәнлеген белә Әхмәтсафа. Очрамаса гына ярар иде... Рабигасы бар анын. Кинәт ике ут арасында калгандай хис итте үзен.

Фатыйхнын йөзендә көнләшү галәмәте чагылды.

—Ну, парин, кая ашыгасын син? Бөтен көймәнен койрыгын берьюлы тотмакчы буласын. Ярәшеп, вәгъдә бирешеп йөрмәсән, кызлар беткәнме Казанда?

...Укулар башлангач, Әхмәтсафа башаягы белән дәресләкләргә чумды.

Аның тырыш, укуга сәләтле икәнен Александр Айхенвальд—политэкономия укытучысы күреп алды һәм егетне студентлар түгәрәгенә тартты. Ул үзе Мәскәүдә Кызыл профессорлар институтын тәмамлаган, Бухаринны якыннан күреп белгән, аның идеяләре белән янып, илһамланып яшәүче галим иде.

Фирка житәкчеләре арасында фикер аерымлыклары барлыгын Әхмәтсафа аңлый, Айхенвальд түгәрәгендә бу хакта еш кына бәхәсләр дә килеп чыга, остазы кебек үк, бәхәстә табылган хакыйкатьне генә хакыйкатькә саный, тыныч тормыш төзүгә йөз тоткан илдә бәхәс—тартыш-даулардан битәр, ил үсешен тизләтүче мөһим бер чара. Бәхәстә иң кирәклесе—башкаларны да тыңлый белү. Менә монысы житми тек житми инде студентларга. Яшь әтәчләрдән ким кыланмыйлар. Айхенвальдка аларны тынычландыру өчен шактый тир түгәргә туры килә. Әхмәтсафа Татпрофсовет каршында пролетстуд бюросында эшләгәнлектән, Мәскәүдәге фирка житәкчелегенең фикер көрәшен игътибар белән күзәтеп бара иде. "Уңнар" юлбашчысы Бухарин яклы профсоюз башлыгы Томский карашлары да аңа якын иде. Күреп тора, "сул" Троцкий белән Бухарин яклыларның бәхәсе, тора-бара чикләрне үтеп, ярсулы тартышуга әйләнеп бара, бусын егет өнәп бетерми, гел үзеңнекен генә хак дип раслау, башкаларның фикеренә колак салмау куркыныч юлга да алып кереп китәргә мөмкин бит. Сталин исә бәхәсләргә бик катышмый, ара-тирә кызган табага май салган кебек, каршы якның әле берсен куатләп, әле икенчесен үсендереп, тартышны тагын да кискенләштереп кенә жибәргән кебек. ТКУның үзендә дә тыныч түгел. Вольфович белән Айхенвальд арасында ачыктан-ачык бәхәс купты. Акылы, йөрәге белән Айхенвальд яклы иде егет. Вольфович —тарихчы, Татарстанда гражданнар сугышы тарихын өйрәнә. Күрәсең, Татарстанда яшәгән кыска гына арада шактый мәгълүмат туплап өлгергән, кызыклы, мавыктыргыч итеп сөйли. Татарстан Республикасы төзелү чорында "уңнар"—Мохтаров, Шамил Усманов кебекләрнең Казанга Солтангалиевне кайтарырга омтылышын кискен гаепләп чыга. "Сулларның" Сәхипгәрәй Саидгалиевне яклап тартышуларын, ахыр чиктә, Сталин фикеренә таянып, Үзәк "сулларны" алга чыгаруын, Тат. Республика башына Саидгалиев куелуын дөрес гамәлгә санап, бу хәлне хакыйкатьнең жиңүе итеп, мисал рәвешендә китерә иде. Әйе, кызык дәверләр булган. Әхмәтсафа бераз гына соңрак туган шул, әлеге дауда катнаша алмавына офтанып та куя. Вольфович егетне хыялланып утыруыннан жиргә төшерә, ул инде Грасис, Шәмгунов кебек коммунистларның тетмәсен тетүгә керешкән. Болар, гомумән, милли республикалар төзүгә каршы төшкән ахмаклар, милли сәясәттә чеп-чи наданнар... Вольфович белән килешми булмый, дөрес әйтә, милли мәсьәләдә сай йөзгән бәндәнең сәясәттә эзе булмаска тиеш!

Бу кешеләр арасында Әхмәтсафага азмы-күпме таныш ике кеше бар. Беренчесе—комиссар Шамил Усманов булса, икенчесе—Оренбур большевигы Гали Шәмгунов иде.

Шамил Усмановны солтангалиевче буларак, 1920 елда ук Казаннан жибәргәннәр икән. Ул Урта Азиядә Көнчыгыш фронт карамагында була, аннан янә Мәскәүгә килеп төпләнмәкче була. Тынгысыз татар комиссарының мәркәздә яшәвен өнәмәгән фирка житәкчеләре Усмановны тагын Казанга озату чарасына керешкәннәр дигән хәбәрләр йөри. Студентлар арасында легендар комиссарның абруе зур, күпләрнен, шул исәптән Әхмәтсафаның да комиссар белән күрешәсе, сөйләшәсе килә.

Гали Шәмгуновның исеме Оренбурда инкыйлапның жиңеп чыгуы белән аерылгысыз. 1918 елдагы хәлләр дә тарихка кереп калган. Февраль аеннан апрель башларына кадәр Оренбур төрмәсендә яткан Зәки Вәлидине "ликвидировать" итәргә рөхсәт сорап Үзәккә мөрәжәгать иткән үжәт бер коммунист ул Шәмгунов, килешмәүчән большевик. Сталин бу мәсьәләгә сак карап, Шәмгуновка ашыкмаска киңәш бирә, чаманы онытып жибәргән коммунистны шелтәләп, арт белән киртә жимерүен хупламавын белдерә. Зәки Вәлидидә үжәтлек житәрлек. Ул "өченче юл" тарафдары. Шигаре—

“Без большевиклар да түгел, меньшевиклар да түгел, без–башкортлар!“ Андагы көч, дәрткә сокланып карый иде Әхмәтсафа. Тәки барлык каршылыкларны үтеп, Рәсәйдә беренче милли республика–Башкортстан төзүгә ирешә, аның беренче илбашы була. Шәмгунов тырнагыннан исән калдырганы өченме, Зәки Вәлиди Сталинны милли проблемаларны иң яхшы белүче дип саный, аңа ышанып, кызыллар ягына чыга. Әмма соныннан бу гамәленә үкенә дә. Кызыллар ягына күчкән чакта коралсыз башкортларга күрсәткән җәбер-золымны мәңге онытырлык түгел шул. Сталинның ике йөзле җан булуына тәмам инанып, бу кешедән өмете киселеп, ел ярымнан соң, 1920 елның июнендә Бакуга, аннан Урта Азиягә китә Зәки. Әхмәтсафа Хивада эшләгәндә әле үзбәкләр арасында Вәлидигә хөрмәт зур иде. Вәлиди хакында андагы укымышлы кешеләр авызыннан күп тапкырлар ишеткәне булды. Аның Ленинга атап язган хатындагы: “Сак булыгыз! Милли сәясәтнең барлык ялгышлары башында Сез үзегез торасыз булса кирәк,“–дигән сүзләрен хәтеренә салып куйган иде. Вәлидиләр буыны нык холыклы, иманлы буын булган шул, дип уфтанып куя кайчак Әхмәтсафа. Хәзер аумакайлык, ярарга тырышу тамырланып килә яшьләр арасында. Вәлиди әнә үзен Сталинның кат-кат Мәскәүгә чакыруын да санламый. 1923 елда ук Советлар иленнән киткән кеше буларак, аны ил, милли сәясәткә хыянәт иткән кеше буларак телгә алалар. Әхмәтсафа да акламый аның кыланышларын, әмма хөрмәткә лаек бу шәхес, монысы аның өчен бәхәссез иде.

Боларны искә алу да шуның өчен: әгәр Татарстан Республикасы төзелгәндә Шамил Усманов кебек якташлары җан атып, тартышып йөргән икән, аңа да Казан бөтенләй үк чит-ят түгел, димәк. Казан–бөтен татарның мәркәзе, бөтен татарны җыеп торучы шәһәр. Шушы уй аның күңелен җылытып җибәрә, укуга дәртен тагын да арттыра иде.

...Утсыз төтен чыкмый, диләр. Каршы килер сүзләр түгел икән. Озак та үтмәде Казанга күченеп кайткан Шамил Усманов үзе ТКУга килеп керде, студентлар алдында чыгыш ясап китте. Студентлар клубында булды әлеге очрашу. Берничә укытучы озатуында (алар арасыннан Гомәр Шаһиәхмәтовны, ягъни Толымбай тәхәллүсле мөгаллим-язучыны гына белә Әхмәтсафа) җил-җил атлап килүче нык, ыспай гәүдәле коңгырт чәчле яшь кешене тамашачылар кул чабып каршы алдылар. Комиссар Усмановның яшьләр арасында абруе зур иде һәм моңа сәбәпләр дә бар. Ул–гражданнар сугышының башыннан ахырына кадәр кичеп чыккан гаярь комиссар. Казанда әле 1922 елларда ук радио мәсьәләсе буенча чыгышлар ясап йөргән кеше, 1924 елда бөтен шәһәр халкы катнашында диярлек, исәпсез-сансыз гаскәрләр белән гаҗәеп тамашалар үткәреп, Казанның дүрт көнгә йокысын алган шәхес. Китаплары чыга, сәхнәдә аның спектакльләре уйнала. Инде менә тамаша предприятиеләре идарәсе һәм ерак дулкында тапшырулар алып баручы радиостанция төзелеше җитәкчесе итеп билгеләнгән. Бөтен Казанны дер селкеткән могҗиза–җиденче ноябрь көнне беренче мәртәбә Татарстан башкаласында радиотапшырулар да оештырып җибәргән кеше ул. Күп кенә студентлар аның аэродинамика клубын оештыру өчен җилкенеп йөрүләрен дә онытмаганнр икән. Кыскасы, Шамил Усманов барысына да якын, һәркемгә таныш, билгеле шәхес, шуңа студентлар аны котырып кул чабып каршы алдылар да инде.

Усмановны күреп алган уңайга Әхмәтсафаның йөрәге кысылып куйды. Бер карасаң, һич тә үзгәрмәгән сыман комиссар, икенче карасаң, тагын да җитдиләнгән, олпатланган.

Очрашуны Гомәр Толымбай ачты. Усманов, үзенә сүз бирелүгә, җәһәт кенә трибуна артына килеп басты һәм өстенә кигән өр-яңа костюмына җай гына ишарә ясап, көлемсерәп, сүз башлады :

–Ун елдан артык хәрби киемнән йөрергә туры килде. Гади кәчтүмгә һичияләшеп булмый. Сүз сөйләргә чыксаң, нәрсәдер җитми, тотып торыр көч юк шикелле.

Зал күңелле генә гөжләп алды.

Усманов, мона артык игътибар итмәгәндәй кыланып, күзен бер мәл түшәмгә төбәп торды, ул морадына ирешкән иде инде—тамашачылар белән үзе арасында элемтә урнашуын тоеп, төп сүзгә күчте.

—Соңгы айларда булып үткән вакыйгалардан тетрәнгән күңелем һаман үз урынына утыра алмый әле,—диде ул, дәһшәтле хисләр кичергән тавыш белән. Аның чыгышын Әхмәтсафа Каргалыда ук ишеткәне бар. Аерма бар иде бу ике чыгыш арасында. Ул чакта артык көчле булмаган тавышы ныгыган хәзер, һәр сүзе күңел түренә үтеп керә. Анда кабалану юк, хәтта тыңлаучыларны шул беренче җөмләдән үк авызына карата алуына ниндидер канәгать хисләре дә кичерә сыман.—Август ахырларында Нью-Йоркта Сакко белән Ванцеттиның үтерелүе турында хәбәр килеп иреште. Җаным елады ул көннәрне. Радио. Траур маршы. Күз алдыма үзем кичкән гражданнар сугышы еллары килде. Утлы, давыллы еллар. Революция өчен һәлак булган көрәштәшләр. Ком бураны, күз карашын, сулышны буа торган ком бураны... Өермә. Пәри туе. Яктылыкны капларга тырыша, күзне томаларга азаплана бу өермә. Аннан ком бураны тына, көн яктыра, тирә-юньдә тынлык, өермә-мәхшәр булмаган да кебек. Барысын да онытасы килә шушы минутларда. Юк, онытырга ярамый. Нью-Йоркта булган хәлләр якын киләчәктә капитал белән бәрелешнең неизбежностьлыгын күрсәтә. Сез, татар студентлары, сәясәт мәйданы сулышын, җилнең кайсы тарафка исүен, кайсы агачның кайсы яфрагы нәрсә дип кыштырдавын ачык белергә, аңлап торырга тиешсез. Әле партиядә дискуссия бетте дип тынычланырга иртә. Тормышның һәр почмагында восстановительный процесс—төзү пульсының көчле тибүе сизелә. Татарстанда группалар тынмыйлар, кайчандыр мин араларында йөргән "уң"нар хәзер көннән-көн физиономия-чырайларын ача барып, татар буржуазиясенең төп яклаучысына әйләнгәнлеген күрсәтәләр. Сезнең кебек үк мина да политэкономия, сыйныфлар көрәше тарихы фәннәрен тирәнтен өйрәнергә туры килә. Алар миң күп нәрсәне танырга ярдәм итте, күземне ачты.

Зал тын да алмый Усмановны тыңлый, Гомәр Толымбай янәшәсендә утырган икенче бер кунакның колагына нидер пышылдап, тыенкы гына көлеп куйды. Тегесе ризасызлык белдереп, җилкәсен сикертеп алды. Моны Усманов сизеп алды һәм аптыраулы күзләрен тутырып Толымбайга караш ташлады. Гомәр Толымбай үзе дә сизмәстән урындыкка сеңә төште. Уңайсызланып, башын түбән иде. Усмановның әлеге хәлдән кәефе килепме, күтәренке тавыш белән сүзен дәвам итте:

—Әйе, революция вакыйгалары искә төшә дә, ирексездән хәтирәләр өермәсе чолганышында каласың. Хәтирәләр белән генә юанып яшәргә иртәрәк әле безгә. Көрәш туктап тормый, иптәшләр. Хәзер төп көрәш—латинга күчү мәсьәләсе тирәсендә бара. Череп беткән искелек тарафдары Гимад Нугайбәк, аның иярченнәре тарих тегерменәнә таяк тыгып, вакыт агышын акрынайтмакчы булалар. Иске язуны сипләштереп кенә татарны яңа тормышка өстерәп алып кереп булмый ул! Барып чыкмас! Гыйльми Үзәктә Галимҗан Ибраһимов яңалифкә күчүне ашыктырмый. Аның тарафдарлары—Җамал Вәлиди, Галимҗан Шәрәф кебек шәкерт-агайлар гәрәп хәрефе койрыгына ябышып, социализмга килеп чыкмакчы булалар...

Шул чагында залда Фатыйх Сәгыйтов, ут капкан кебек, урыныннан сикереп торды һәм ярсулы тавыш белән:

—Куарга аларны Казаннан!—дип кычкырды.—Эзләре булмасын! Газетага мөрәҗәгать белән чыгыйк. Җитте татарның башын бутарга!—диде дә, ничек чәчрәп торса, шулай ук шып туктап, урынына чүкте.

Усмановның битенә кызыллык йөгерде. Ул сүз җебен чуалткандай, бераз тын торды да, сүзен әкрен генә дәвам итте:

—Куып кына мәсьәлә хәл ителми, иптәшләр. Без һәр кешене, фикер аерымлыгына карап, илдән куа башласак... Андыйларга иң көчле удар—массаларның җавабы. Әгәр масса, ягъни татар халкы тулаем яңалифне яклый икән, монарчы су болгатып яткан күгәргән мәдрәсә хәлфәләренә

ни кала? Әйе, тончыгачаклар алар үз кулләрендә. Безгә менә шушы юлдан бару кирәк. Иң мөһиме—безне яшьләр якласын. Газеталарда минем чыгышларны укый торгансыздыр, Шәрәф Борһан, Сәләх Атнагулов иптәшләр тырышлыгын да искә алырга кирәк—барысы да яналифне яклыйлар. Тагын шунсы да бар—латинчага күчү мәсьәләсенә урыслар да битараф түгел. Кириллица, әйтүләре буенча, аларны да канәгатьләндерми икән. Луначарский, Яковлев кебек галимнәрнең фикерен ишеткән, укыганыгыз бардыр инде. Урыслар безгә караганда да өлгеррәк булып чыктылар, аларның ныклап хәзерләнгән өч проекты бар латинчага күчү буенча. Шулай итеп, киләчәк—латин файдасына хәл ителәсе көн кебек ачык.

Әхмәтсафа өчен бусы яналык иде. Димәк, латин мәсьәләсе, уйлаганга караганда да тамырлырак булып чыга, болай булгач.

Усманов кызып сүзен дәвам итте:

—Яналиф—көн таләбе. Гарәпчә язу дигән булып, балаларның телен бозудан туктарга вакыт. Мин гарәпчәләп язуның хилаф яклары хакында йөзләгән мисаллар китереп, чыгышлар ясадым. Кабатлап тормыйм. Шунсы кызганыч, әлегәчә өлкә комитеты шул хәлфәләрне яклап маташа...—Усманов бераз гына дәшми торды.

Әхмәтсафаның күз алдына "чулак" кушаматлы Хатаевич—өлкә комитеты секретаре килеп басты. Яналиф хакында бәхәсләрнең кызган чагы. Алардан студентлар да читтә кала алмый. Инде яналифка күчүнең унай якларын тукый-тукый күпме чыгышлар ясалгандыр соңгы айларда. Исең китәр, Хатаевич ашыкмый, шушы ук фикерне ТАССР Халык Комиссарлары Советы рәисе Хажи Габидуллин да яклый.

Усманов, залда утырган студентларга түгел, нәкь менә шушы житәкчеләргә төбәп, бәхәсләшкән сыман, кайнарланып дәвам итте.

—Күпме котәргә була? Инде гасыр башында ук әзәрбайжаннар күтәреп чыкты бу мәсьәләне. Ишеткәнегез бардыр, Мирза Ахундов ничә еллар элек милләтне саклау хакына, гарәп язуыннан ваз кичәргә чакырып чыкты. Әзәрбәйжаннарның әдәбият башында торган кеше ул. Ни сөйләгәнен, ни язганын яхшы белә. Язу—ул милләт сакчысы, халыкның рухын саклый. Казанда латинчылар хәрәкәте егерменче еллар башыннан ук яшәп килә. Моннан өч еллар элек үк, 1924 елның октябрендә латин хакында доклад ясап, беренче латинчылар ячейкасы төзелгән иде. Ул инде шактый күп эшләр башкарып өлгерде. Мөһиме—халыкта фикер туды. "Кирәк!"—ди, акыллы татар. Үзегез уйлап карагыз. Кабатлап әйтәм, иптәш Луначарский хәтта урыс алфавитын латинчага күчерүне күтәреп, бу эшне дәлилләп чыкты. Әрмәннәр белән грузиннар дә бу мәсьәләне өйрәнәләр. Иң алда, барыбызга да үрнәк булып, әлбәттә, әзәрбайжаннар бара. Хәзәриләр чорыннан калган тәвәккәллек, янага омтылу һич сүрелми бу халыкта. Аларның Агамалы Оглы дигән галимнәре бар. Әзәрбәйжан үзәк башкарма комитеты рәисе, дәүләт житәкчесе ул. Әле егерменче еллар башында ук иптәш Ленин ана: "Латинизация—Көнчыгыш өчен Октябрь ул!"—дип белдергән. Безнең өчен дә канат түгелмени бу сүзләр? Канат, әлбәттә!

Толымбай кул чаба башлады. Ана башкалар кушылды. Усманов, рәхмәт дигәнне белдереп, Толымбайга баш иеп алгандай итте.

—Ә Ибраһимов белән Шәрәф нишлиләр?—дип, залга сораулы караш ташлады ул. Үзе үк жавап та бирде.—Гарәп алфавитына үзгәртүләр кертеп, аны ямаулы ыштан хәленә китереп, халыкка такмакчы булалар. Ул гына да түгел, шушы сөрсегән карашны яклап РКП(б) үзәк комитеты секретариаты алдында чыгыш ясыйлар. Хәтта язу машинкасы өлгесен дә эшләп маташканнар. Әйтерсең, алар 1926 елда Бакуда, тюркологларның беренче съездында яналифкә күчү хакында карарга килүне бөтенләй белмиләр. Быел Бакуда бөтен төрек-татарлар өчен уртак алфавит кабул ителде. Бөек адым! Менә кайда ул бәйрәм!.. Ә Татарстан һаман ашыкмый. 1926 елда Мәскәүдә РСФСР Халык комиссарлары совет рәисе урынбасары Рыскулов Хажи Габдуллинны пыр туздырып ташлады. "Казан яналифне кертүдә акрын

кыймылдый,"—дип, кистереп әйтте. Сегә дөресен әйтергә кирәк, моның сәяси-идеологик ягы да бар. Латинга каршылык дингә каршы көрәшне тоткарлый, муллалар тегерменәнә су коя...

Усманов дин мәсьәләсенә килеп кагылгач, залда утыруын онытып, шактый уйланып утырды Әхмәтсафа.

Димәк, әлифба мәсьәләсе, иң беренче чиратта, дингә каршы юнәлдерелгән чара булып чыга түгелме соң? Халыкның нинди хәреф белән язуы сәяси гамәлгә әйләнә икән бит. Язу—аерым бер сәяси вәзгыятьтә халыкның анын, фикер юнәлешен билгели булып чыга. Мондый эштә уйламый адым ясау төзәлмәс хаталарга китермәсме? Күрәсең, Галимҗан Ибраһимов моны анлап эш йөртә. "Хата ясап, аны төзәткәгә караганда, аны алдан күрү хәерле,"—ди иде Оренбурда Гомәр агасы. Гел сакланып, ул-бу булмасын дип, алны-артны карап кына яшәп тә булмый ич! Иске белән көрәшми, аны тәмам тар-мар итми торып яңага ирешеп булмаячак икәнен дә яхшы анлый ул. Усмановка ышана ул, яңалифкә каршы килүне урынсыз дип саный. Әхмәтсафаның яшьлеге инкыйлапка туры килде, аның хәзер өлгереп килгән чагы, аң-зиһене, дөньяга карашы революция җилләре алып килгән өермәле яңгыр астында бөреләнде, чәчәк атты, инде менә җимеш бирер вакытлар җитеп килә. Һәр нәрсәгә аның үз карашы булырга тиешле чор бу, үзе дөрес дип тапкан фикер-мәсләккә икеләнмичә кушылырга тиеш дип саный, шул мәсләк өчен көрәшергә дә туры килүе мөмкин. Бу яктан Усмановка сокланып карый ул, менә кеше ичмаса, һәр нәрсәдә эше бар аның, һәр нәрсәгә үз фикере өлгереп җиткән, үз юлының дөреслеген раслап, ал-ялны белми көрәшкә дә ташланаган әнә... Менә шундый көрәшчеләрдән үрнәк алып яшәргә кирәк тормышта. Әхмәтсафа уйларыннан айнып, чыгыш ясаучыга текәлде.

Усманов исә, күкнең җиденче катында талпына. Яңалифкә күчүне дөнья пролетариаты башлап җибәргән революцион көрәштә тәүге адымнарның берсенә санап, шушы күчеш белән генә тукталып калмыйча, һаман алга табан баруның зарурлыгын исбатларга кереште. Киләчәктә тагын бер кирәкле адым ясау мөһим булачак—ул да булса эсперантога күчү. Бөтен дөнья күләмендә. Усманов ялкынланып эсперанто турында нотык тота башлады. Көтмәгәндә, тамашачыларга карап:

—Чу ви пороляс эсперантэ?—диде. Аның күзеннән шаян чаткылар чәчелде.

Әхмәтсафа моны анламаса да, эсперантода ниндидер сорау бирелгәнен анлый иде, янәшәдә утырган кемдер:

—Нэ, ми нэ пароляс эспирантэ,—дип, җавап та кайтарырга өлгерде.

Усманов чын күңелдән көлеп җибәрде.

—Анлагансыз бит. Мин: "Сез эсперантода сөйләшә беләсезме?"—дип сорадым. "Юк, без эсперантода сөйләшә белмибез,"—дигән җавап ишеттем.—Аннан ул янә җитдиләнде.—Белергә кирәк. Үзлегемнән немецча өйрәндем, эсперанто буенча дәреслек язып бастырдым. Тора-бара җир шарындагы барлык халыклар эсперантода сөйләшә башлаячаклар. Шунсыз бөтендөнья халкы арасында нинди туганлык, үзара аңлашып яшәү булсын ди. Бөтендөнья пролетариаты—эсперантога!

Студентлар гөрләтеп кул чаптылар.

Усманов, кулын күтәрә төшеп, гөжли башлаган залны тынычланырга чакырды:

—Минем килү яңалифне мактау өчен генә түгел иде. Бу инде хәл ителгән мәсьәлә дип анларга кирәк. Вакытны сузуга эч пошып кына сөйлим. Күңелне тырнап торган бернәрсә бар—гарәпчелекне яклаучылар, берләшеп, үзәк комитетка, иптәш Сталинга хат язганнар. Төркем актив эшли, хәзер галимнәр, язучылар, студентлардан имза җыю бара. Аң булыгыз, әгәр шундый кешеләргә тап булсагыз, провокацияләргә бирелмәгез, имза куймаска чакырам.

—Б... пумала белән куып чыгарабыз,—дип әтәчләнде Фатыйх Сәгыйтов.

Ул арада студентлар Усмановка сораулар яудырырга тотындылар. Сүз нигәдер, яналифне урап үтеп, әдәбият тирәсендә куерды.

—Соңгы вакытта нинди әсәрләр яздыгыз?—дип сорады бер кыз.

—“Памирдан радио...”—диде, мәгънәле итеп кенә Усманов.

Әлеге әсәрне студентлар да яхшы белә иделәр бугай, кул чаптылар.

—Әкият бит ул...—дип, мыгырданганы ишетелде Фатыйх Сәгыйтовның.—Әкиятнең чын әдәбиятка ни катнашы бар?

Әле генә үзен яклап, күтәрелеп бәрелгән егетнең кинәт үзенә үк каршы төшүенә аптырап, Фатыйхка сынаулы караш төшереп алганнан соң, Усманов әдәбият хакындагы уйлары белән уртаклаша башлады.

—Әдәбият мәйданы—көрәш ул. Тинсез көрәш ул. Мине татар әдәбиятында бердәнбер пролетариат язучысы дип әйтергә дә ярый торгандыр. Мона Гомәр иптәш Толымбай да каршы килмәс дип уйлыйм.—Ул нигәдер муенын боргалап алган Толымбайга дустанә карап алды.—Ләкин мондый “беренчелек“ мине шатландырмый. Артка борылып карыйм да, кашларымны җыерам. Юк, арттан ияреп килүче яшь көчләр күренми. Алмаш күрмим. Шул борчый мине. Син, яшь иптәш, әкият дисең... Бәлки сәламәтлегем түзеп мин алдагы көрәшләргә җитәрмен, тагын да гамьле, тагын да җанлы вакыйгалар кичерермен. Бәлки күз алдымда җиңгән пролетариат Европасын күреп, коммунизм төзүдә катнашырмын... Ни булса булыр, әмма ул еллар, бүгенге көрәш сафлары, беренче ашкынулар тәкърарланмаслар. Аларны күздән югалтмас өчен эшкә тотындым, язам да язам. Каләм житкән кадәр ул минутлардан күзгә чагылган, күнелдә калганнарын суырып алып, яшь буынга укытыр өчен мәйданга чыгарам. Киләчәк буын унҗиденче ел коммунистларының тормышын белсен, дим...

Бу сүзләрдән соң нигәдер монсу булып китте. Әхмәтсафа үзе дә сизмәстән, урыннан сикереп торды.

—Шамил абый!..—Олы язучыга, сугыш батырына шулай үз итеп эндәшүеннән кыенсынып, төртелеп калды. Үзен кулга алып:—Иптәш Усманов,—дип, рәсмирәк тонга күчте.—Сез мине онытkансыздыр инде. Унтугызынчы елда Хәйбри дигән командир Каргалы авылында дуамал кылана башлагач, мин Оренбурга, сезнең штабка килеп хәбәр иткән идем...

Усманов, гаҗәпләнә төшеп, алдагы рәттә басып торган Әхмәтсафага бераз карап торды да, елмаеп, ана каршы килде, нык кына итеп, кулын кысып, җилкәсеннән кочаклаган хәлдә, йөзе белән тамашачыларга борылды:

—Исемә төште. Бу егет элемтәче булды ул көнне,—диде.—Әгәр вакытында килеп җитә алмаса, Каргалыда хәлләр була иде... Хәйбри дуамал иде шул. Шул дуамаллыгы аркасында Тозтүбә тирәсендәге сугышларда башын салды да. Сагынам мин аны... Ул елларны сагынам... Рәхмәт, егет, искә төшерүең өчен рәхмәт. Әйе, ул еллар онытылмый, истән чыкмый. Йөрәккә уелган хәлләр бар...

—Безне сөендереп, күнелләргә үтеп керерлек итеп, яна әсәрләр языгыз,—диде Әхмәтсафа, халык алдында басып торуын яна гына абайлап алгандай.—Соңгы елларда Урта Азиядә булып, әдәбият яналыкларыннан артта калдым. Куып җитәрмен дип ышандырам...

—Әйе...—диде, Усманов трибуна артына кире барып баскан иде инде һәм сүзен дәвам итте.—Язарга кирәк, язучы бит ул кулы кычытканга язмый, кирәк булганга, тиеш булганга яза. Мин әдәбиятны матурлык сөйгәнлектән сөймим, әгәр дә әдәбият революциягә корал була алмаслык булса, мин аңарга тотынмаган булыр идем кебек... Мин художникмы, әллә мастермы? Художникның элекке мәгънәсе белән алганда, матурлык өчен рухланып язучыга санаганда, мин—түгел. Мин аерым тойгылар, мәхәббәт, башка сыйфатлар белән генә хисаплашып, аларны тикшерергә уйлыйм. Миңа инсаният, коллектив дигәннең тәкъдире кирәк. Аның кайгысы, шатлыгы, тойгылары миңа азык. Шуларны язарга уйлыйм...

Очрашу бетеп, кул чабулар тынып бетмәс борын, Усманов янә Әхмәтсафа янына килеп басты.

—Исемеңне онытканмын, энекәш...—диде ул, үзен гаепле хис иткәндәй.—Һич хәтергә төшми.

—Әхмәтсафа мин, Дәүләтьяров булам.

—Таныш фамилия. Дәүләтьяровларны Оренбурда укымышлы кешеләр дип беләм. Шулар нәселеннәндер бит.

—Гомәр агай безгә туган тиешле.

—Шулайдыр, шулайдыр. Менә бит, тау белән тау гына очрашмый. Кайларда йөреп, жирләр-илләр кичеп Казанга килеп чыккансың, бу очрашуга чынлап сөенәм мин.

Усмановны башка студентлар да урап алган иде, ул ашыга төшеп, Әхмәтсафага кулын сузды.

—Югалма күздән. Концертларга йөрисеңме? Асия Измайлова концертларын калдырма. Искиткеч жырчы!—дип, чыгу ягына кузгалды. Ишек төбенә кадәр студентлар камалышында барды ул.

—Ну, егет, моменттан файдалана беләсең!—Фатыйх Сәгыйтовның күгәрек тавышы Әхмәтсафаны сискәндереп жибәрде. Фатыйхның төртмәле сүзләренә жавап кайтарып тормастан, сыйныфташ егетләре янына атлады. Сүз дә юк, аның абруе бу минутларда иптәшләре каршында, чыннан да, кисәк үсеп киткән иде.

* * *

—Кеше яхшысын да, яманын да тиз онытучан. Хәтер дигән нәрсә хикмәтле нәстәкәй инде ул. Хәтерсезлектән мескенлеккә—бер адым. Онытучаш миенең иң әһәмиятле һәм мөһим үзенчәлеге. Әгәр күргән-белгәннәребез хәтергә теркәлеп бармаса һәм кайсыдыр вәзгыять кысасында кирәкле хәбәр хәтердә терелеп, кабат искә килеп төшми икән—кеше өчен фажигагә тиң тормыш башлана. Тиз онытабыз, хәтерне эшкә жигәргә яратмыйбыз. Шулай әйбәт була дип уйлыйбыз, искегә тисәң—исең китәр дип, кайбер вакыйгаларга кагылмыйча, булганны юк дип яшибез. Чын тарихчы болай эшләргә тиеш түгел.—Айхенвальд политэкономия буенча гыйльми түгәрәккә килүчеләргә каш астыннан сөзеп карап алды. Карашы Әхмәтсафага төртелде.—Беренче итеп, үземне борчыган нәрсәләр хакында сөйләшеп аласы килә... Әйтегез әле, һич аңлый алмыйм, әгәр политэкономия дигән фән бар икән, социализмда аның асылын тәшкил иткән акча—товар—акча дигән нәрсә барлыгын кире какмыйбыз икән, без төзи торган жәмгыять нинди юл белән үсәргә тиеш соң? Дәүләтьяров, сез инде дөнья күргән кеше, бу хакта ни уйлыйсыз?

Дәүләтьяров урыныннан күтәрелә башлаган иде, Айхенвальд, үзе дә әле чагыштырмача яшь кеше, аны кире утырырга мәжбүр итте.

—Утырган килеш кенә жавап бирегез. Аяк өсте хаклыкны яклап булмый диләр бит...

Кемдер тел шомартып алды:

—Утырырга өлгерербез әле, иптәш Айхенвальд. Утырган хәлдә якларга туры килмәсен хаклыкны.

Айхенвальд, шаяртуны аңламаганга сабышып, жилкәсен жыерып куйды.

—Ну-у, сөйләшүне андый яссылыкка күчермик инде. Дәүләтьяровны тыңлыйбыз.

—Хужалык эшчәнлеге белән ныклап шөгыльләнгәнем юк,—диде Әхмәтсафа, башында бөтерелгән фикерләрне тәртипкә китерергә тырышып.—Урта Азиядә чагында шуңа игътибар иттем, әгәр икътисад өлкәсендәге сәясәт халыкка аңлаешлы икән, ана диһкан каршы килми. Житештергән продукциясен тиешле күләмдә дәүләткә тапшыра, салымнарны түләп бетергәч, продукциянең арткан өлешен хужалыгына файда китерерлек итеп сатып жибәрә. Сәүдә итә алса—аның хужалыгы бара, әгәр үстергән мамыгын мәжбүр итеп дәүләткә тапшырталар икән, житмәсә, аның өчен

бернинди түләү дә булмаса, диһканга афәт килә–ачлык-ялангачлыктан иза чигә башлый, хужалык таркала, хәерчелек янында, белгәнегезчә, үлем йөри. Андый хәлләр булды Хивада. Фәкать яна икътисадый сәясәт нәтиҗәсендә генә диһканнар бераз хужалыкларын ныгыта алдылар. Югыйсә, эшләр мөшкел иде. Ә болай дөрес кебек, товар–акча–товар формуласы яна җәмгыятькә батмый. Өстәмә табышка юл ачылмый икән, җәмгыять икътисадый үсә алмый.

–Димәк, сезнеңчә, хакимият икътисадый сәясәтне ордым-бәрдем түгел, ә крестьян хужалыгының мөмкинлекләрен исәпкә алып үткәрергә тиеш. Дөрес аңладыммы?

–Шулай, житештергән продукция хужалыкны ныгыту өчен эшләми икән, алдагы елларда, хәтта крестьян үзе теләсә дә, ул инде хужалыгын тарта алмаячак. Салым сәясәте хезмәт кешесен бөлдерүгә юнәлергә тиеш түгел дип саныйм. Товар житештергән хужалык–илнең тоткасы ул. Без социализмны эшче-крестьян кулы белән төзибез, революция идеясен алар тормышка ашыра. Маркс сүзләрен хәтердән чыгармаска иде: идеяне тормышка ашыручы мәнфәгатьләрен санга сукмыйбыз икән, ул идея беркайчан да чынга ашмас.

Айхенвальд җаваптан канәгать калып, аудитория алдында ике кулын артка кушырып әрле-бирле йөри башлады.

–Болар бит шундый гади нәрсәләр. Моның өчен югары уку йортларын да тәмамлау кирәк түгелдер. Хәер, без хәзер массаларны укытуга нык әһәмият бирәбез. Укыйбыз, ачышлар ясыйбыз, ә хужалыкны һич кенә дә кирәгенчә алып бара алмыйбыз. Уйлап куям, барыбызда да югары белем бар, ә башлангыч белем юк. Башлангыч белем–нигез. Менә нәрсә житми. Крестьян-эшчедә булган гади тормыш зирәклеге юк бездә. Аларда бар ул башлангыч белем дигәнең... Әле генә Вольфович белән бәхәскә кереп алдым. Бер төркем галим жин сызганып Татарстанда революция, гражданнар сугышы тарихын язалар. Хәзерге пролетариат диктатурасы чорындаТатарстандагы хәлләрне ал да гөл итеп тасвирлаганнар. Әйтерсен, һәм иктисадта, һәм сәясәттә ялгышлардан хали без һәм аларны төзәтергә дә кирәкми. Куркыныч юл. Ялгышларны исәпкә алмасаң, бик тә гыйбрәтле үзенчәлеге бар–алар кабатлана. Без әлегә беркатлы сәясәт алып барабыз–массаларның аңында борылыш ясарга кирәк дип лаф орабыз, үзебез исә хужалык итүдә бертуктаусыз ялгышлар жибәрәбез. Ин үкенечлесе–алар кабатлана тора. Шулай булгач, масса аңында үзгәреш буламы? Юк, булмый. Адәм баласы ялгышлардан сабак алырга тиеш. Борынгы Кытай фәлсәфәчесе: акыллы кеше башкаларның ялгышыннан гыйбрәт ала, ахмаклар үз ялгышларыннан сабак ала,–дип язып калдырган. Ә без ни башкаларның хаталарын өйрәнмибез, ни үзебез ясап ташлаган хаталардан сабак алмыйбыз. Аптыраш, нинди җәмгыять төзибез, кая бармакчы булабыз?..

Аудиториядә авыр тынлык урнашты. Айхенвальд йөрүеннән туктап, уйлана төшеп сөйләнүен дәвам итте.

–Әле яңа дәрескә материаллар эзләп утырганда, үзем өчен коточкыч яңалык ачтым. Бу хакта уйлана идем, сәбәпләре дә билгеле иде кебек, әмма кулда конкрет дәлилләр юк иде.–Айхенвальд өстәл өстендә чәчелеп яткан кәгазьләр арасыннан тиз-тиз үзенә кирәклесен эзләп тапты. Маңгаена күзлек менеп кунаклады, әрнүле тавыш белән тезеп китте:

–Егерменче еллар башында Идел-Урал якларындагы ачлык хакында уйланганыгыз бармы?

–Бар...–диде Абдулла Юсупов.–Туганнарым ачлык елны кырылып беттеләр минем. Коточкыч вакыт иде...

–Сәбәп нәрсәдә дип уйлыйсыз?

–Корылык инде... Ике ел рәттән корылык булды.

–Корылык–игенченең баш өстендә мең еллар буенча асылынып торган ялангач кылыч ул. Ачлыктан котылуның бер генә чарасы бар: игенче һәрчак алдагы елларга мая калдырып килгән. Ин авыр чакларда да

кагылмаган ул ана. Мая—киләчәк, мая—яшәү дигән сүз. Ә егерменче елда, игенче өстенә ач үлем ябырылып килгәндә хөкүмәт нишли?—Айхенвальд соравына җавап та бирде.—1920 елда Урта Идел төбәкләреннән кырык миллион пот ашлык хәзерләнә... Яшермичә әйтсәк, крестьяннан тартып, талап алынган ашлык. Тарих икән тарих булсын, ачыктан ачык язарга кирәк. Алдагы еллар өчен сабак булыр. Илгә, нәкъ шул төбәктә яшәгән халык өстенә ябырылып ачлык килгән көннәрдә Татарстанга ун миллион йөз егерме мең пот продразверстка җиткерелә. Сахибгәрәй Саидгалиев моны унбиш миллион дүр йөз мең потка җиткереп үти. Инде көз көне ук республика ишегенә ачлык шакый башлый. Җитәкчеләр һаман продразверстка "үтәп" мәш киләләр. Кашаф Мохтаров—Халык комиссарлары советы рәисе дөнья революциясе хакында лаф ора. Губчека рәисе Денисов халыктан мәҗбүри рәвештә, талап җылы киемнәр җыю хакында фәрман бирә. Республикада мең биш йөз вәкил халыкның соңгы икмәген талап җыю белән шөгыльләнә, берничә ревтрибунал эшләп тора. Һәр авылга разверстка планы җиткерелә һәм планның үтәлеше өчен авыл коллектив рәвештә җавап бирә, план үтәлмәгән очракта авылга продотряд, халык телендәгечә "обжор команда" кертелә. Халык каршы килә, әмма мондый чуалышларны хәрби частьлар ярдәме белән рәхимсез бастырыла. Вольфович бу фактларны читләтеп үтмәкче була...

—Ни өчен?—дип үзе дә сизмәстән сорап куйды Әхмәтсафа.—Чирен яшергән —үлгән. Җан өшетерлек нәрсәләр ич болар.

—Мине дә шушы сорау борчый—ни өчен яшереп маташырга? 1920 елның 30 сентябрендә Халык комиссарлары советының беренче утырышында "продразверстка үтәү хакында Татреспублика халкына мөрәҗәгать" кабул итү мәсьәләсе күтәрелә,—дип, үзендә булган мәгълүматларны тыңлаучыларга "түгә" бирде Айхенвальд. "Үз халкымны талыйсым юк,"—дип мөрәҗәгатькә Шамил Усманов кул куймый. Җир эшләре буенча халык комиссары Юныс Вәлиди "Мәскәү куштаннары, милләтне сатучылар" белән хезмәттәшлек итәргә җыенмавын белдерә. 1921 елның кыш айларында ук ачлыктан меңәрләп кырыла халык. Адәм ашау фактлары күзәтелә, мәче, эт, кумак ашау инде беркемне дә гаҗәпләндерми.

—Республикага күрә торып ачлык китергән җитәкчеләр җавап тоткандыр бит Мәскәү каршысында?—диде Абдулла Юсупов. Ул инде ачлык хәлләрен үз башында кичергән кеше, монда сөйләнгән һәр нәрсәне йөрәге аша үткәреп, әрнеп утыра иде.

—Җитәкчеләргә ни булсын? Алар судан коры чыгалар. Саидгалиевне азык-төлек хәзерләүдәге "уңышлары" өчен Мәскәү алтын сәгать белән бүләкли һәм ачлык котырынган 1921 елда ул Казаннан чыгып ычкына. Мәскәүдән килгән азык-төлек халык комиссары Алексей Изюмов та 1921 елда республикадан сыза—банк-сәүдә хезмәткәре булып Мәскәүдә эшли башлый. Фәкать 1921 елның җәй айларында гына, халык авыллап-авыллап кырыла башлагач кына совет хөкүмәте Татарстанга аз-маз ярдәм күрсәтә башлый.

—Әгәр чит илләр ярдәм итмәсә беткән идек инде,—дип куйды Абдулла.—Җәл, иртәрәк булмады ул ярдәм.

—Әйе, бәхеткә каршы чит илләрдән ярдәм шактый сизелерлек була. Шунсыз бүгенге Татреспубликаданиләр булып бетәр иде—билгесез,—дип, сүзен тәмамлады Айхенвальд.

Түгәрәк әгъзалары үткән дәвердәге авырлыкларны җаннары аша кичереп утырганда, Фатыйх Сәгыйтовның шыксыз тавышы тынлыкны бозды:

—Иптәш Айхенвальд, сез дөрес юлдан бармыйсыз!—диде ул урыныннан сикереп торып.—1920 елгы ачлык—ил өстенә төшкән авыр сынау, афәт иде. Корылык булмаса, ачлык та булмас иде. Бөтен гаепне Татарстанның партия, совет җитәкчелегенә өеп калдырмакчы буласыз. Ә бу сарык бәрәннәре сез сөйләгәннәрдән зур ачыш ясап утыралар менә. Шундый

житәкчеләр булмаса, ачлыктын котылып калган булыр идек, дип уйлап утыралар инде үзләренчә. Сезнең максат—Татарстан житәкчеләренә яла ягу һәм мондый сарыклар өере алдында максатыгызга ирешәсез дә! Чынын әйткәндә, Татарстанның яңа тарихын язуда үзегезне катнаштырмаган галимнәрдән үч алмакчы буласыз. Дөрес эшләгәннәр!—дип, дуамалланып аудиториядән чыгып китте.

—Сәгыйтов үз сүзен әйткән уңайга хаклыкка ирештем дип уйлый. Минем фикер белән килешмәве өчен аны гаепли алмыйм, әмма бүтәннәрне тыңларга теләмәвен һич төшенмим,—диде Айхенвальд шулай ук яшьләрчә жилкенеп.—Полемикадан качмыйбыз, безнең Вольфович белән бәхәсләргә дә шаһит сез, әмма бәхәстә каршы якны мыскыл итү, аның дәлилләрен тыңламау, яки төгәл әйткән фикерне кире ягы белән әйләндереп, аны имгәтү, гарипләндерү һич дөрес түгел. Кызганычка каршы, Сәгыйтов шул юлдан бара. Аны күзәтеп торам да, хәйран калам, ТКУ күләмендә нинди бәхәс кабынса, ул шунда, һәрнәрсәдә үзен белгеч дип хис итә һәм ахыргы хакыйкатьне ул гына әйтергә тиеш дип уйлый. Илгә яңа кадрлар, янача фикер йөртә алырлык гыйлем ияләре әзерлибез дип мактанабыз. Асылда, еш кына, Сәгыйтов ишеләрне әвәләп бирәбез. Алар киләчәктә ни кылырлар, ни күрсәтерләр—уйлавы да куркыныч. Бәхәс турында фән бар—эриэстика дип атала. Моназара кылу сәнгате. Бәхәстә күтәргән тавыш белән түгел, акыл, зиһен һәм белем белән жиңәргә кирәк.

—Акыллы егет ул Сәгыйтов,—диде Абдулла, нигәдер Фатыйхны яклыйсы килеп.—Кызып китәргә һәвәслеге дә булмаса...

—Кемдер әйткән: акыллы булу белемле булу дигән сүз түгел әле. Бүгенге вәзгыятьтә наданлык һәр жирдә чабудан килеп тота.—Айхенвальд Мәскәүдә кызыл профессорлар институтында укыганда еш кузгалган бәхәскә килеп тукталды.—Ил белән революционерлар идарә итәргә тиешме, әллә дилбегәне белемле, хуҗалык эшләрендә тәҗрибә туплаган кешеләр кулына тапшыру кирәкме?—диде ул һәм, башкаларга сорау барып житкәнче, җавап та биреп өлгерде.—Әлбәттә, революцион романтизм чоры үтә дә китә, ә идарә итү, хуҗалык эшләре—мәңгелек. Белемле кешегә кимсетеп карау, ышанмаучылык Рәсәйнең гомерлек чире. Бу чир революцион романтикларга, һәр төрле энтузиазмга да хас. Әлеге авыру бик тиз совет җәмгыятенә дә үтеп керде. Белемнең кирәк икәнлеген исбат итүгә киткән көч—исрафка сарыф ителгән җегәр, энергия ул. Шунсы кызганыч. Белексезлек, ягъни компетентсызлык харап итәчәк безне.—Айхенвальд Сәгыйтов ярым ачык калдырган ишекне барып япты. Сүзен дәвам итте.—Мин сезгә Татреспубликадагы ачлык һәм аның сәбәпләре хакында сөйлим икән, анда уйлап чыгарылган бер генә нәрсә дә юк. Сез—булачак житәкчеләр, ил белән идарә итү, әлбәттә, киләчәктә сезнең кулда булачак. Әгәр совет җәмгыяте төзелешендәге кайбер хаталарны, ә бу очракта сүз сабак алу мәжбүри булган хәл—миллионлаган совет гражданнарын теге дөньяга алып киткән ачлык сәбәпләрен ачыклау хакында барды, искә алмыйбыз, санга сукмыйбыз икән—киләчәк аяныч булачак. Тарих кабатлана диләр. Мондый тарих исә кабатланырга тиеш түгел.

* * *

Кайнарланып үткән түгәрәк утырышларына тиздән нокта куелыр дип беркем дә уйламый иде. Сүз ирегә, фикер хөрлегә ашәгән Айхенвальд түгәрәгә үтәсе көнне Әхмәтсафа аерым бер җилкенү белән көтеп ала. Монда үз сүзенне ишеттерергә мөмкин, кирәк икән бәхәс куертып та җибәрергә була. Яшьләрнең очынуы Айхенвальдка да охшый, ул аларны кыздырып җибәрергә җай гына эзли. Бер кызып китсәләр, студентларның авызын тиз генә томалармын димә.

Менә бүген дә бәхәс куерып килә.

Фатыйх Сәгыйтов теге көнне ишекне шапылдатып ябып чыгып

китүен онытып, бүгенге утырышка беренчеләрдән булып килде. Совет хакимиятенең икътисадый нигезләрен барлаганда, кәтмәгәндә, яңа икътисад сәясәтенең хуҗалык итәргә кулай булмавын расларга тотынды.

—НЭП елларында совет хуҗалыгы тәмам йончыды, эздән чыкты,—дип сөйли башлады ул үзенә хас катгыйлык белән.—Уйлап кына карагыз, тигезлек, җир, ирек шигарьләре белән революция ясаган илдә, биш-алты ел үтмәде, крестьян ни хәлдә калды? Күтәрәмгә калдырды илне НЭП! Тигезләндек тә кебек, ирек тә алдык, җир күпме кирәк бездә, ә иктисадый бөтенләй юк. НЭП касәфәте инде.

—Яңа икътисад сәясәте аркасында гына авылга җан инде,—дип аңа каршы төште Әхмәтсафа. Үткән елгы түгәрәкләрдә Сәгыйтов чәчрәп чыгып НЭПның бүгенге авыл өчен никадәр әһәмиятле һәм вакытлы чара булуы турында нотыклар сөйләгән иде. Моны Фатыйхның үзенә дә искәртәсе итте ул.—Бу хакта син үзең дә яхшы беләсең һәм НЭПны яклый да идең, һич аңлашылмый, ни өчен болай тиз үзгәрде фикерең?

Фатыйх сабакташының сүз башлавын көтеп кенә торган диярсең, тагын да дәртләнеп китте.

—Син, Дәүләтъяров, өстәл артында Бухаринның эткә ташласаң эт иснәмәс китапка охшаган нәмәләренә борының белән кадалып утырганда, мин бераз гына башны күтәреп, әйләнә-тирәгә күз салдым. Илдә барган үзгәрешләрне аңлау өчен монда, ТКУ да диюем, хөкүмәт икмәген черетеп яту кирәкми, болай да күренеп тора, монарчы Бухарин калыплаган идеяләрнең көле күккә очты. Партиянең унбишенче съезды карарларын өйрәнсәң зыян итмәс иде. Син һаман Хива-Бохара якларыннан эләктереп кайткан диһкан акылы белән яшәргә маташасың. Крестьяннарның ирегеи кысма имеш. Салым сәясәте дә фәлән-фәсмәтән имеш, крестьян сәүдәгә тартылсын имеш... Хәер, сәүдәгәр малаеннан ни көтмәк кирәк?

Аудитория беразга тынып калды. Соңгы чорда кайбер студентларны “сәүдәгәр, мулла малае“ дип гаепләүләр ешайды. Бу—гаеп ташланган яшьләргә алга табан совет уку йортларында белем алуның мөмкин булмаганлыгын аңлатучы “дәлил” иде. Шушындый гаепләү белән соңгы вакытта шактый студентны укудан чыгарып җибәрделәр. Аларның кайяшь түгеп, кире укуга кайтырга тырышып йөрүләренә Әхмәтсафа үз дә шаһит. Сәгыйтовның дәлилсез-нисез аны сәүдәгәр малае дип атавы астында нинди мәкер ятканын яхшы аңлый. Оренбурда, әле ТИНОда укыган чагында да ишетте ул сүзне аннан. Көнләшү галәмәте генә дисәң... ТКУда Фатыйхның һәрнәрсәдә беренче буласы килә. Башкалар аның авызына гына карап торырга тиеш. Ул шулай уйлый. Әмма дорфалыгы, тәкәбберлеге аркасында зиһен һәм зирәклектән бөтенләй үк мәхрүм булмаган егеттән күп кеше аңлы рәвештә читләшә. Үч саклый торган егет, шуңа күрә аның белән бәхәскә кермәскә тырышалар. Бәхәскә керүдән тайчанмый торган бердәнбер үҗәт булып Әхмәтсафа калып бара иде. Әле кичә кич соң гына тулай торакка кайтып: “Яшьләр клубында Хәсән Туфан белән Гадел Кутуйның иҗат кичәсен ясап маташканнар иде. Бетләрен туздырдым! “Без—шагыйрь!“—дип, борыннарын күтәреп йөрмәсеннәр. Пролетариат белән крестьянга нинди шигырьләр кирәк икәнлеген сөйләп бирдем үзләренә, ул шагыйрь кисәкләрен яңадан сәхнәгә менмәслек иттем!”—дип әтәчләнеп йөргән Фатыйхка, бүген тагын кемдер каршы килеп маташсын инде, җә?! Җитмәсә, укытучылар алдында. Үҗәт Дәүләтъяровка ни җитми? Үҗәтлек чикне үтсә, чиргә әйләнә, дөрес инде. Моңа ничек түзсен дә Сәгыйтов, нервысы ничек чыдасын?..

—Шулай, сәүдәгәр малае дигәч, тиз шиңде Дәүләтъяров,—дип һаваланды Сәгыйтов, бәхәскә нокта куйгандай.—Бу сиңа кеше талап мал җыю түгел, без икътисадның какшамас социалистик кануннары хакында сөйлибез, ә син кем тегермәненә су коеп маташасың? Икътисад иҗтимагый җитештерүнең объектив кануннарына буйсына, НЭПның кисә канунына түгел.

Надир Әбдершин, Әхмәтсафаның күптәнге дусты һәм авылдашы, түзмәде урыныннан сикереп торды:

—Әхмәтсафа сәүдәгәр малае түгел!—диде кайнарланып.—Ул ятим үсте, үзенең тырышлыгы, зирәклеге аркасында гына алга юл ярып бара. Әтисе Мостафа агай авылның иң ярлы игенчеләреннән иде. Гаиләсен туйдыра алмаганга, балаларын байларга көнлекче итеп бирде, үзе айлар буе өенә кайтып керми, казакъ арасында тире-яры белән эш итеп йөрде. Хәтәр эш ул, куркыныч, авыр хезмәт. Алай да мантый алмады, яшь балаларын үги әни кулына калдырып, үлеп китте. Әхмәтсафа ятим үсте,—дип кабатлады Надир.—Нинди сәүдәгәр нәселе булсын, ди. Әкият сатма инде, Фатыйх, үзең дә яхшы беләсең...

Фатыйх бу сүзләргә керфеген дә селкетмәде.

—Үзең үк әйтеп торасың тагын. Тире-яры белән эш иткән кеше сәүдәгәр булмый, кем булсын инде?—дип, авызын жырды ул.—Вак сәүдәгәр, байлар белән эш йөрткән кеше, нигә яклап маташасың?

—Байлар белән эш йөртмәгән кеше юк иде ул чакта,—диде Надир, Фатыйхның белә торып Әхмәтсафага яла ягуына рәнжеп.—Ана калса, син үзең дә мулла малае.

Фатыйхны жен алыштырдымыни! Ул, атылып урыныннан торды, Надир янына килеп басты, аның якасыннан эләктереп алып төкерекләрен чәчә башлады:

—Тагын бер мәртәбә кабатласаң, телеңне тартып өзәм! Мин инде әллә кайчан мулла атайдан баш тартуым хакында хәбәр иттем. Моны бөтен кеше белә. Ә син... син... бетле күркә, күрәләтә алдашу юлы белән, съезд тарафыннан ныгытылган фикерләремнән ваз кичтермәкче буласыңмы? Минем юлым—партия юлы, мәсләгем—партия мәсләге. Синең ише сәүдәгәр, кулак кебекләр белән уртаклыгым юк!—Фатыйхның иреннәреннән ак күбек ургылып чыкты. Ул калтыранып, урынына килеп утырды, үзе һаман тынычлана алмый.—Сәүдәгәр, кулак калдыклары кереп тулган, авыз ачып сүз әйтергә дә бирмиләр, паразитлар, идән асты кыргаяклары,—дип зәһәрен чәчә иде

Әхмәтсафа түзмәде, урыныннан күтәрелде.

—Сәгыйтовның төкерек чәчүеннән шыр жибәреп утырыр чаклар үтте,—диде ул, тыныч, әмма беренче сүзләреннән үк башкаларны җәлеп итәрлек нык тавыш белән.—Мин аның кебек сәяси флюгер була алмыйм. Партия карарларын ничек теләсәм шулай, бозып аңлата да алмыйм. Әйе, соңгы чорда партиядә бәхәсләр берьяклырак була башлады. Бухаринчылар дигән сүз кирәгеннән артык куертыла. Ә бит иптәш Сталин Бухаринны "социализм төзелешенең прорабы" дип атады. Әле үткән елларда гына фикер аерымлыгы да сизелми иде. Партия сафларының ныклыгына сокланып яши идек.

—Сәяси сукыр!—дип жикеренде Сәгыйтов.—Надан сүз сөйләп, тавык көлдермә, ичмаса. Партиядә бернинди бәхәс, аерымлану да юк. Сүз—тиз арада коллективлаштыруны төгәлләү, промышленность үсешен тиешле дәрәжәгә житкерү хакында бара. Солтангалиевче икәнлегеңне беләбез, кирегә сукалап торма, яме.

—Солтангалиев мәсьәләсенә килгәндә, кызганычка каршы, мин аның белән таныш түгел, карашларын да ныклап белеп бетермим, аны партия гафу иткән иде инде...

—Бүре баласын бүрегә салсаң да, урманга карый, Дәүләтьяров. Үзең кебек инде. Сезнең ишеләргә тел белән аңлатып була торганмы? Солтангалиевне дә күпме иркәләделәр, башыннан сыйпап кына йөрттеләр. Нәтиҗәсе—Солтангалиев йөрде-йөрде дә, һаман шул милләтчелек сазлыгына кереп чумды. Аның иярченнәре Мидхәт Борындыков белән Мәхмүт Бөдәйлине бик дөрес кулга алдылар. Аларны таш ваттырып кына акылга утыртып була.

—Газеталарда "Утызтугызның хаты" басылып чыкты. Житди сүзләр

бар анда. Солтангалиевне аклауны сорыйлар безнең зыялыларыбыз,—дип, бәхәскә кушыласы итте Абдулла Юсупов. Ул мондый бәхәсләрдән читтәрәк торырга ярата, шулай да бәхәсне кыздырып җибәрергә ана куш, каян чамалап ала, инде сүз көрәштерү басыла башлый дигәндә, ике-өч сүз ыргытырга өлгерә, сүз янә куерып китә.

—Һе, надан,—диде, ачы тавыш белән Сәгыйтов. Ул "утызтугыз" дигәнең ничәгә калгандыр. Хатка кул куйган сәяси куштаннар инде үзләре үк бу эшләреннән баш тарталар—комиссар Шамил Усманов беренче булып Солтангалиевеннән ваз кичте. Башкалары да озакламас...

Айхенвальд, сүзнең аерым шәхесләр тирәсендә әйләнә башлавын күреп, түзмәде, шәкертләре чуалтып бетергән җеп очын эләктереп алмак булды:

—Ну, егетләр, гайбәт сатарга гына булсын сезгә. Бу сүзләр бит, ачуыгыз килмәсен, гайбәт югарылыгында гына. Башта бер-берегезне пычратып азапландыгыз, хәзер милли зыялыларыгызга ябыштыгыз. Сезнең өчен абруй да, табынган кешеләрегез дә юк. Сүзгә керешсәгез, барысын рәттән буярга кирәк. Каян өйрәндегез бу һөнәргә?

—Табынган кешебез—иптәш Сталин, аның сүзе иң дөресе. "Большевиклар ала алмаган крепостьлар юк!" Мин үземне большевик дип саныйм, шуңа күрә вак буржуаз тәгълиматка, мещанлыкка, һәр төрле аумакайлыкка рәхимсез сугыш ачам?—дип жилкенде Сәгыйтов.

—Ярый, шулай да булсын, без иптәш Дәүләтьяровны тыңлыйк әле. Карап-карап торам да, тагын бер карап алам дигәндәй, бу мәсьәлә белән ике кеше—ул һәм Сәгыйтов кына кызыксына кебек.

Бу сүзләргә Сәгыйтовның үтә дә кәефе килеп, түшләрен киереп, як-ягына масаюлы караш ташлап алды.

Әхмәтсафа, алдында яткан конспектка күз дә салмый сүзен дәвам итте:

—Ачыклап китим, 1927 елның декабрендә үткән унбишенче съезд коллективизацияне бердәнбер һәм иң дөрес юл дип тапмады бит. Барлык төр кооперацияләрне дә хуплаган карар кабул итте. Аннан соң елдан артык вакыт үтте, дөресен әйтәм, мин үзем дә коллективлаштыруның мөһимлеген таныйм. Яна техника үсешендә могҗиза булган электрофикация аша коллективлаштыруга йөз тоту—төп юлларның берсе шул. Шунсын да таныйм, аерым бер кооперация төренә өстенлек бирелмәде. Съезд Бухарин, Рыков иптәшләр алга сөргән һәм нәкъ соңгы чорда зур бәхәс куптарган нәрсә—индустриализация белән авыл хуҗалыгы үсешенә финанс өлеше кертүнең дөрес бүленешен яклады. Мона иптәш Сталин үзе дә каршы килмәде. Җитмәсә, 1927 елда барлык крестьяннарның өчтән бере инде кооперацияләргә берләшкән иде. Димәк, авылда бердәмләшеп эшләүгә, яшәүгә каршы түгел халык. Халык шушы юлга тартыла икән, санлашмый булмый.

Сәгыйтов тагын түзмәде.

—Ташла инде халыкны изгеләштереп, аннан әүлия ясаудан! Халык бүген болай, иртәгә тегеләй. Ана дөрес установка бирү кирәк һәм вәссәләм.

Айхенвальд килешмәгәнен белдереп, башын чайкап куйды.

—Беркөнне Дәүләтьяров Маркснын акыллы сүзләрен хәтердә янартты. Кабатлау зыян итмәс: әгәр без идеяне тормышка ашыручыларның мәнфәгатьләрен санга сукмыйбыз икән, ул идея беркайчан да чынга ашмаячак.

Әхмәтсафа алдында яткан кәгазьләренә күз салып алган булды. Студентларның аны ышанып, бирелеп тыңлауларын чамалап алган иде инде ул. Тыңлаучыларның барысы да диярлек авыл балалары, авылга кагылышлы һәр сүз аларның җаннары аша үтә, Әхмәтсафаның сүзләре йөрәкләренә сары май булып ята.

—Авылда куллану кооперациясе үсеш юлында иде, кустарь-промышленность кооперациясе дә җанланып килә. Һәркайсыбызның күз

алдында, авыл белән шәһәр арасында бәйләнеш ныгый бара. Шуна күрә мин иптәш Бухаринның: "Индустриализацияне гамәлгә ашырганда крестьяннарның мәнфәгатьләрен һәрдаим истә тотарга кирәк"—дигән сүзләрен яклап киләм. Бу һич тә сәяси сукырлык, йәки кирелек түгел.

—Син сәяси күрә караучыга әйләнеп барасың!—дип, аны бүлдерде Сәгыйтов.—Мең тугыз йөз егерме жиденче-егерме сигезенче елларда икмәк хәзерләү кампаниясе нинди хәлгә төште? Авыл үз мәнфәгатен кайгыртып, шәһәрне ачлык ягасына китереп терәде. Ә син, бәйләнеш ныгый дип, кеше башын катырасың!

Сәгыйтовка жавап кайтарып торуны кирәк санамады Әхмәтсафа.

—Ә кулакларга мөнәсәбәтегез?—дип сораган булды Айхенвальд чыгыш ясаучыдан.

—Кырып себерергә!—диде Сәгыйтов.

—Монда эш катлаулырак,—диде Әхмәтсафа, нигәдер тавышын баса төшеп.—Унбишенче съезд карарларында ачыктан-ачык күренә—анда сүз кулакны физик юк итү турында бармый. Икътисадый ысуллар кулланып, аларның эксплуататорлык мөмкинлекләрен чикләүне тормышка ашыру күз уңында тотылды. Кулакны талап, хәерче хәленә төшерү аяныч нәтижәгә китерә .

—Син, димәк, иптәш Молотов кул куйган 1928 елның беренче март хатын вакытсызрак дип табасың? Анда бит сүз нәкъ менә кулакны тамырдан юк итү хакында бара.

—Партия житәкчелегенә каршы килә алмыйм...

—Килеп кара!

Моны Сәгыйтов әйтте.

—Иптәш Молотовның "Урындагы партия оешмаларында чәчүлек жирләрен арттыру һәм крестьян хужалыкларын коллективлаштыруны тизләтү" турындагы хатында: "партия, совет органнарының эше коллективлаштыру нәтижәләре нигезендә бәяләнә" диелгән. Бу съезд карарларына каршы килә, минем фикерем шундый.

—Әт-тә-тә, акыллы баш табылды!—Сәгыйтов янә урыныннан кузгалды.—Ни өчен мондый каршылык килеп чыга дип уйламадыңмы, миеңне самауыр күгәреге баскан нәстәкәй?! Синдә булган кәгазьләр миндә дә бар ул!—диде ул эре генә.—Менә тыңлап кара. Син яклап маташкан кулакларның "тырышлыгы" белән үткән елда икмәк хәзерләү кампаниясе өзелде. Ил ачлык куркынычы алдында басып калды. Син, Дәүләтьяров, иптәш Сталинның: "Бездә эчке дошманнар бар, бездә тышкы дошманнар бар. Бу хакта бер генә минутка да онытмаска кирәк!"—дигән даһи сүзләрен санга сукмыйсың.

—Бу бит конкрет сөйләшү түгел...

—Нәрсә? Юлбашчының сүзләре конкрет түгелме?—дип, күзләрен акайтты Сәгыйтов.

—Иптәш Сталин бик дөрес күрсәтә. Яңа жәмгыять төзегәндә, ана каршы көчләр табыла. Куелган сорауга конкрет жавап бирмәдең дип кенә әйтәсем килде.—Әхмәтсафа үзен сәяси сукырлыкта гаепләүләрен теләми иде. Әмма, моңарчы илдә хөкем сөргән, соңгы чорда "бухаринчылык" дип мөһер сугылган карашларыннан тиз генә ваз да кичә алмый. Аның инануынча, ул идеяләр дөрес иде. Соңгы чорда ниндидер аңлашылмаучылык булды, партия сәясәте үзгәреп, үткән чорда көч, акыл сарыф итми анга сеңдерелгән идеяләрне, бер селтәнүдә кире кага башлау аңлашылып житми иде, ягъни бу гамәлдән үзе утырган ботакка балта чабу шикеллерәк бер нәрсә килеп чыккан иде.—Икмәк хәзерләүдә ел саен бер кыенлык килеп чыга тора. Шулай да егерме беренче елдагы ачлык сәбәпләрен искә алып эш итү нәтижәсендә, фажига кабатланмады. Узган ел авыл икмәкне башка елларга караганда аз жыйнап алды. Хәлле крестьян шушы хәлдән файдаланып калырга маташты. Илдә икмәк аз булган саен, аңа бәя арта бара. Кулакның исәбе гади иде. Илне ачлык чигенә житкереп, шуннан

байтак керем алырга жыенган кулакның гамәлен мин дә хупламыйм.

—Техник культуралар яхшы уңыш бирде,—дип сүз кыстырып алды Айхенвальд.

—Әйе, икмәге булганнар хөкүмәтнең сатып алу бәяләрен арттырганын көтеп, сатуны кичектерә килделәр. Техник культура хисабына яшәргә була иде бераз. Хәлсез хуҗалыклар исә, икмәкләрен көз көне үк хөкүмәткә арзан бәягә сатып бетерде һәм яз көне өч бәя артык түләп чәчүлек орлыгы сатып алырга мәҗбүр булды.

—Терлекчелек артуга йөз тотты. Еллык артым биш процент,—дип Айхенвальд шәкертенең дәлилләрен раславын сиздереп куйды.

—Дөрес әйтәсез, терлекләргә дә азык кирәк. Ләкин хөкүмәт шушы хәлдә дә индустриализация темпларын киметү ягын карамады. Бөтен авырлык авыл өстенә ишелде, ягъни, үзе дә ярым ач хәлдә, ул зур төзелеш мәйданына әверелгән илне тартып барырга мәҗбүр булды. Нишләргә кала? Бер генә юл—крестьяннардан икмәкне тартып ала башладылар. Мәхкәмәгә эш артты. РСФСР җинаять кодексының 58—10 статьясы, ягъни контреволюцион агитацияләүдә гаепләп кулга алулар ешайды. НЭП ка, фактик яктан килгәндә, нокта куелды.

—Синең үзеңә 58—10 статьясын кулланырга кирәк,—дип ысылдады Сәгыйтов.—Җанын-тәнең белән уң аппортунистларны яклыйсың. Тиреңң жыртылып чыкмаса ярар иде дип куркып утырам менә.

—Бүгенге вәзгыять хакында фикер йөртеп, Ленинның социализм һәм кооперация төзү планыннан тайпылышлар булуын гына күрсәттем.

Айхенвальд янә сүзгә кушылып алды.

—Дәүләтьяров үз фикерен иптәш Бухаринның "Икътыйсади язмалары"на нигезләп шәрехләде. Дөрес эшләде дип уйлыйм. Чынбарлыкка дөрес бәя бирелде. Синең шикелле Сәгыйтов, кемнәрнеңдер ниндидер гаепләрен санап утырып кына социализм төзеп булмый.

—Киләчәктә сугылачак кирпечләр белән бүген үк фабрика төзи башлап булмый. Әүвәл кирпечне сугып, төзелеш мәйданына китерергә кирәк, аннан гына төзи башларга була. Беренче бишьеллык планын тормышка ашырганда мондый кимчелекләр исәпкә алынса иде дигән исәптән генә чыгып сөйлим.—Әхмәтсафа сүзе беткәнгә санап, урынына утырмакчы булды.

—Елап та җибәр инде, ышанырлар,—диде Сәгыйтов, яшерен тантана белән.—Статья дип сүз кузгаткач, Дәүләтьяров ничек шинде! Аферист Бухарин астыртын ният белән "Правда" газетасында "Сәяси васыять" дигән нәмәрсә бастырган әнә. Ленин үзе язган имеш. Бөтен газетаны пычратып бетергән. Бик телең кычыткач, шуны да яттан сөйләп чык инде, алай булгач. Декламация сөйләргә оста бит син.

—Илнең җитәкчеләре арасындагы каршылыкларга кысыласым килми. Минем эшем түгел бу. Фикеремне кабатлап кына әйтәм—авылда дөрес сәясәт үткәрелмәсә, хәлләр аяныч булырга мөмкин...

Әлеге бәхәс түгәрәкнең соңгы утырышы булды. Вольфовичка кемдер әләкләгәнме, әллә үзе шундый фикергә килгәнме, инде ВКП(б) тарафыннан тар-мар ителгән Бухарин идеяләре нигезендә Айхенвальдның һаман бәхәсләр оештырып ятуын өнәмичә, ул түгәрәк эшен тыйды...

...Әхмәтсафа уйларыннан айнып, әрнү катыш көлемсерәп куйды. Дөнья куласа, бер әйләнә, бер баса ди, инде хәзер үзе авылда совет тәртипләре урнаштып йөри менә. Һәрхәлдә, шушы эшне йөкләде ана кантком. Үзе яклаган хәлле крестьян хуҗалыгын туздырырга бара. Йорт хуҗасын кулга алгач, ул нигездән ни каласы билгеле инде. Әтисе вафатыннан соң үзләренең нигезе бөтенләй юкка чыга язды. Ярый әле Гомәрхан исән-имин кайтты сугыштан. Хәлле крестьяннарга кантком ике генә гамәл белә: кулга алырга, мөлкәтен туздырырга. Кая монда крестьян мәнфәгате, кая монда Бухарин идеяләре. Юлга чыгып китәр алдыннан

Филиппов кулакларны физик юк итү хакында мен тугыз йөз егерме тугызынчы елның җәй аенда җирле партия оешмаларына җибәрелгән Молотов хатын кат-кат исләренә төшереп алды:

—Сез авыллардан җыеп китерәчәк кулаклар өч төркемгә, ягъни категориягә бүленә,—диде ул белдекле кыяфәт белән. Сүзнең мөһимлеген искәрткәндәй, мангаена бәреп чыккан тирне кул аркасы белән сөртеп алды. Соңгы вакытларда җүнле-башлы йокы күрмәгәнгә, аның йөзе агарып, сулып калган иде. Таң алдыннан гына канком утырышы бетүгә карамастан, иртүк, Әмәкәй авылына китүче төркемне озатырга килеп җиткән, аларга инструкция биреп, өйрәтеп җибәрүне үзенең бурычы итеп санаган иде.— Беренче категория—контрреволюцион актив, советка, колхозга каршы чыгышлар оештырган, йәки турыдан-туры катнашкан кулаклар һәм аларның куштаннары. Соңгы вакытта күреп-ишетеп беләсез, Әлмәт, Буа кантоннарында кулаклар коткысы белән коралы бәрелешләр булып алды. Кулакларны җир йөзеннән себереп түкмичә торып, "коллективлаштыруны—йөз процент!" дигән социалистик йөкләмәбезне үти, иптәш Сталинның "Бөек борылышлар елы" дигән мәкаләсенә лаеклы җавап бирә алмаячакбыз. Иптәш Сталинның шушы мәкаләсенә җавап итү йөзеннән генә дә мин бөтен кулакларны җир йөзеннән себереп түгәр идем. Тамырлары корырга тиеш аларның! Тә-әк... Беренче категория—гаиләләре белән Себергә сөреләчәк,—дип, мәгънәле караш ташлады Филиппов Шәмтиев ягына.— Иптәш Шәмтиев, аңлашылдымы!

—Сөрәчәкбез, иптәш Филиппов, этләре-песиләре дә калмас, нигезләрен туздырачакбыз.

—Дөрес әйтмәден, Шәмтиев. Бернәрсәне дә туздырмагыз. Әйберләрен конфисковать итеп, колхозга тапшырырга. Йортларын совет учреждениеләре итәргә, ярлы колхозчыларга бүлеп бирергә. Аңлашылдымы?

—Ялгышлык китте, иптәш Филиппов, ялгыш ычкындырдым. Сез әйткәнчә эшләрбез... Туздырмабыз, башкаларга өләшербез.

Филиппов җаваптан канәгатьләнеп, аңлатуын дәвам итте:

—Эре кулакларны, күмәкләшүне өнәмәүчеләрне, эшкә аяк чалучыларны кулга алып, гаиләләре белән ерак районнарга сөрү каралган. Болары икенче категориягә керәләр. Тә-әк... Өченче категория дигәннәре—вак кулак, кулак тегерменнәренә су коючылар була инде. Шушы өч төркемгә кергән контрреволюцион элементларны кулга алып Минзәлә төрмәсенә китереп ябу эше йөкләнә сезгә. Авыл активистларына да эш житәрлек. ОГПУ ярдәме белән кулак гаиләләрен өч көн вакыт эчендә авылдан сөреп, әйберләренә кадәр конфисковать итәргә. Җаваплы—Шәмтиев.

—Эшләрбез, иптәш Филиппов, инә-төймәләренә кадәр конфисковать итәрбез. Үзләрен кулга алып...

—Житте, Шәмтиев, кайткач сөйләрсең. Хәзер юлга! Сак булыгыз, каршылык очраса, ике дә уйлап тормый, корал кулланыгыз.

Сүзгә ОГПУ башлыгы да кушылды:

—Кулга алынганнар нидер сизенеп, тавыш-мазар күтәрергә тиеш түгел. Минзәләгә барып, бер кәгазьгә кул куеп кына кайтасыз диярга кирәк булыр. Әмәкәй зур авыл, ярминкәле, базарлы авыл. Төрле яктан җыелган әтрәк-әләм күп булыр. Тирә-як авылларга хәбәр салып өлгермәсеннәр...

...Кайчан гына Матвеевкада җылынып чыкканнар иде. Аякларга суык үрмәли башлады. Бигрәк тә ат өстендәге җайдакларга кыен. Шуңа күрәдерме, төркем башлыгы Әтрәкле дигән авылга җиткәч тукталыш ясарга боерды.

Әтрәкледән караңгы төшә башлагач кына кузгалып, Әмәкәй дигән ерак авылга төн уртасында гына килеп керделәр. Колакта исә Филипповның каты тавышы:

—Контроль саннар... Үтәлергә тиеш. Арттырып үтәрбез...

*Ахыры киләсе санда*



## Равил Фәйзуллин

### ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

Диңгез булган җирдә таулар булыр.
Таулы җирдә кыя-таш булыр.
Чыбык төртсәң, тарантас үскән
җылы кояш җирдә аш булыр.

Судан чыгып, ташка баскан ир зат
күкләр белән бертоташ булыр.
Сулы, ташлы, ашлы, рухлы халык
үз җирендә үзе баш булыр.

### Фараз һәм чынлык

*«Егерме елдан коммунизм була!»*
(Н. Хрущев)
*«Егерме елдан соң татар теле бетәчәк ул...»*
(Ф. Табеев. Язучылар белән очрашудагы чыгышыннан)

Егерме ел үтте. Күбрәк тә үтте...
Коммунизм килмәде... Килде—СПИД.
Әфьюнчылык атты чәчәк...

Шулай да,
шагыйрьләребез туган телдә шигырьләр яза.
Эшләп килә татарча гимназияләр.
Чын тарих ачылып килә чак-чак...
Ни әйтер киләчәк?..

---

Равил ФӘЙЗУЛЛИН (1943)—*Татарстанның халык шагыйре (1999). Төрле телләрдә басылган кырыктан артык китап, шулардан—биш томлык «Сайланма әсәрләр» (1992—2001) авторы. Казанда яши.*

*

*«Милләтләр әкренләп бетәчәк,*
*бердәм совет халкы калачак.»*
(КПСС программасыннан)

**Кырык еллап үтте. Хәтта күбрәк...**
**СССР таркалды. Аерылып ишәйде дәүләтләр.**
**Көчәйде җинаять.**
**Җәмгыять бүленде: байга, ярлыга.**

**Шулай да,**
**азанлы манаралар күккә ашты.**
**Намазга баскан сабыйлар ничаклы.**
**Йа Хода,**
**без гөнаһлыларны ярлыка!**

*

*Ай заман! Вай заман!..*

**Күл өстендә черки аулый**
**энә карагы.**
**Шәхси вертолетта оча**
**казна карагы.**

**Энә бурын улым япкан**
**капка, «шап!» итеп...**
**Казна бурын сайлаганнар**
**депутат итеп.**

*

**Талантын да, буй-сынын да**
**җәлләмичә ишеп биргән.**
**Ефәктән түгел, каештан**
**Язмышын да ишеп биргән.**
**...Бәхет дигән кульяулыктан**
**бер чеметем кисеп биргән.**

## Күпсенмә, Ходаем!..

*Иҗатым бар, балаларым үсә!..*
*Бәйрәм түгелмени бу тормыш!*
*Бәхет түгелмени бу яшәү!*

**Җуймадым әле—**
**Аш тәмен,**
**Эш тәмен,**
**Тән тәмен!**

Яшим тоеп
Дөньяның
күп гамен,
күп ямен...

Өстәвенә—
яна Каләмем!

Кирәкми
Язмышның
бүтәне!

## Татарник

*«Хаҗимөрат» кыйссасында*
*Толстой герое ул!*

«Шайтан таягы», яки
«Татарник» диләр.
Идерә алмый аны
давыллы җилләр!

Татар үзе шыңшый:
шул ук «Зиләйлүк...»
Сөялгәнсең чатта...»
Әллә илең юк?..

## Килде бу көн...

*Килер бер көн—*
*хәерчеләр йөрер төркем-төркем.*

Килер бер көн
мөтәгалим-"академиклар" йөрер төркем-төркем.
Гамәлләрен аңламас беркем.

Милләтнең күбәер "ата-аналар"ы.
Туган телдә сөйләшмәс балалары.

Идарәгә менәр угрылар -
алдап җыйган малга тугрылар.

Закон өстендә законнар булыр, Указ өстенә указлар,
берсен-берсе бетерешеп бугазларлар.

Зур галимнәр акчага ялланырлар.
Клонлаштырмакчылар Алланы да.

Җиһандагы вакханалия-хаоска
шаккатыр иде Нострадамус та!

...Ахырзаман килеп барсы килер вәйран.
Кояш кадәр кояш калыр хәйран.

## Ак төш

Күктә—акчарлак.
Суда—ак чабак.
Дулкын өстендә—
күбектә ак ат!

Каршыма минем
томырылып килә!
Җайдак соң үзе
күренми нигә?

Җилфер ялларда
әллә ак хәбәр?
Ут—тоякларда
әллә ят хәбәр?

Җаным, тынычлан,
янма ул кадәр!

...Сүзем хак булды,
төшем ак булды!
Каршыма килгән—
хыялымдагы
акбүз ат булды!

Күктә ак болыт.
Җирдә—ак канат.
Сабый чагыма
кайтылды кабат.

## Иртәнге махмыр

Шешә төбендә
«ак» калган.
Идәндә гөлләр
тапталган...

Кичә кем кемгә
ят калган...
Җанда ниндидер
тап калган...

Димәк, әле бераз
оят калган.

*

Беренче саф хисне
булмас та яңартып,
шулай да мендәрне
иплә әле кабартып!

Әйдә, кемдер йөрсен
гайбәтләр таратып...
Саулыкта сөелү -
байлыктан мең артык!

Тырышсаң, буладыр
караны агартып.
Кояшны, Сөюне
булмый ул каралтып!

## Берәүгә

Тузган кош оясын жәлләп
язган ул инша.
Күздән яшьләр китерерлек,
әгәр укысаң.

Үз гаиләсен ташлап качкан.
Сабыйлары—юксыл...
Гаҗәпләнмим, бисмилла әйтеп,
әгәр чукынса.

## Бер нәрсә юк...

«Җир йөзендә бер нәрсә юк
Яшьлектән кадерлерәк!»

Гомерлеккә сөйгәнеңнең
иреннән тәмлерәк!

Сабыеңның күзеңә карап
көлүеннән ямьлерәк!

## Р. истәлегенә

*Әллә ничек сәер генә*
*үтте-китте бу гомер!..*

Бу юл(ы) юньләп яшәлмәде...
Яшәрбез киләсендә!
Беләм, минем бу сүзләрдән
кемнеңдер көләсен дә.

Кем-нәрсә булырмын икән
киләсе яшәүләрдә?
Бәлки, әйләнермен чыкка,
ә, бәлки, рәшәләргә...

Бәлки, мильон еллар үткәч
әйләнермен металлга?
Йә бер кош булып сайрармын
канат кагып бер талда?..

...Ходай язмасын йөрергә
бер имгәктә сыр булып.
Ә хәзергә яшик әле
берәр йөз ел җыр булып!

## Дүртьюллыклар

Алтын кайчы ал кисә.
Көмеш кайчы гөл кисә.
Кылны ярып җил искәндә
угъры патша Ил кисә...

Канунсызлык канун икән—
булмас Кеше кадере.
Исереклек—фетнә башы.
Аракы—ил кабере.

Ыргыла агымга каршы
уылдык чәчәргә балыклар.

...Вакыт агымында коела
тарихи картайган халыклар.

*Яшьлек—тиз үтәр «чир».*

Алма битләрдән артык көнләшмә.
Хөкемдар Вакыт үз эшен белә!
Матурлык хакын кайтару көне—
бүген килмәсә, иртәгә килә.

*Раздели и властвуй!*

Атомны таркаткан кебек,
Татарны таркаталар...
...Стратегик чимал кирәк
«Русь» дигән «ракета»га.

### Аңлашыла...

*Тартария—*
*Татария—*
*Татарстан*

«Стан» өчен генә китте
күпме халык җегәре!
«Мөстәкыйль Татар Иле»нә—
күпме желек кирәге...!

**Керфекләр тирәли**
**картлыгың рәшәсе...**

**Бирсен сиңа ходай**
**толлык дәрәҗәсен.**

**«Хатын-кыз кем? Елан? Алиһә?**
**Тик... Кеше түгел!»**
**диде берәү.**
**Сагайды күңел.**

**«Без—бар! Без—мәңгелек!» Тавышымның**
**яңгыравы кайта: «Юк!..»**

**... Төпсез тәхеттән—«Ә мин бар!» дип**
**көлеп тора КартАю.**

**Беләсеңдер, җил шәп иссә—**
**яфрак күбрәк коелганын.**
**Сүз мулрак булган саен,**
**гөнаһ күбрәк җыелганын.**

*Бюджеттан аракы исе килә.*

**Дәүләткә—эчсеннәр генә...**
**Табышын шуңа корган.**
**Халык—сәрхүш. Ил—махмырда.**
**Саулыкка—«тишек юрган»...**

*Каргавың карга башына.*
*Карга синең башыңда!*

**Кем белә бит, кара кайгыларның**
**кайчан килеп җанны айкасын...**
**Кайнар сумалалы канат булып,**
**каргышларың үзеңә кайтмасын!**

Күпме генә казганса да,
һәр теләгән Алып булмас.
Җанда ялкын көчәйсә дә,
янган кадәр яньш булмас...

Төкереп бир кемсәләрнең
өерелеп өрүенә!
Тормый алар сабыеңның
бер ертык көлүенә!

Уртаклашкан кайгы—ярты кайгы.
Уртаклашкан шатлык—ике шатлык.
Кайгы-хәсрәтне үрчетмәсеңгә
шатлык чәчмәк булып угълан таптык.

## Идиллия

Куй өстендә тургай күкәй сала.
Дөньяның бар солдаты җыйнаулашып корал сүтә.
Бодай көшелләре өстендә
мәтәлчекләр ата сабыйлар.

Каркылдый карга ашыкмый гына...
Очына күбәләк оныгылып!
...Үлеп киткән йөрәге тотып
утыз яшьлек геронтолог*.

## Бер үк көнне

«Армия көне—бәйрәм!» дип
ир-атларны тәбрик итте.
...Улын солдаттан йолсынга
бер түрәгә ришвәт илтте.

* Геронтолог-кеше гомерен озынайту фәне буенча белгеч.

*

Ага су. Әйләнә чарык.
Тегермән тарта тора.

Бабай акылы чыга тора,
оныкның—арта тора.

*

Сары йортта «Наполеон»нар,
«Ленин»нар нотык тота!
«Мин—Тукай!» дип йөрүчеләр
очрыйлар Шигырь-Йортта...

*

*Шахта өсләрен каплаган*
*күзге сары яфрак.*
*Өстә микән, аста микән*
*безгә язган туфрак?*

(Шахтер жырларыннан)

Күмер базларында күмелеп калган
күпме татар моңы, күпме сүз!..
...Күгең булса гына җирдә казган.
Күккә күмелгәннәр генә үлемсез!



## Ләбибә Ихсанова

# КҮҢЕЛ КҮЗЕ КҮРГӘНДӘ

ПАРЧАЛАР

*Шулай килеп чыкты, бу язма исемендәге сүзләр бер үк хәрефтән башланды. Һәм ул мина күптәнге бер вакыйганы искә төшерде.*

*1957 елның җәе. Мәскәүдә шаулап-гөрләп татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы бара. Без—татар язучылары Ясная Полянага Лев Толстойның тормышына бәйле истәлекләр белән танышырга һәм бөек әдипнең каберенә баш ияргә дип юлга чыктык. Кояшлы тымызык көн. Юл буендагы агачлар, күргәнебез бар инде сезнең ишеләрне, дигәндәй яфракларын да селкетмичә тын гына утыралар.*

*Якын ара түгел. Бер автобус тулы язучы арасында сүзнен житдие дә, шаяны да була. Бара торгач яңа уен да уйлап таптык. Кайсыдыр ки, язучыга хас сыйфатларны бер жөмлә белән әйтергә, жөмләнен һәр сүзе язучының исеме, я фамилиясе башланган хәрефтән булсын.*

*—Гази гомерлек газаптан гарык,—дип, уенны Салих Баттал башлап жибәрде.*

*—Кайсы Гази? Монда алар икәү,—диештеләр.*

*—Ибрай Гази турында сүз бара.*

*—Ижат газабыннандыр инде.*

*—Икенче Газины да онытмагыз,—дип, йомшак тавыш белән Бари Рәхмәт сүзгә кушылды. Сөйкемле дустыбызның бер тәүлек гомере калганын бу сәгатьләрдә башыбызга да китерә алмый идек әле. Бари аганын тәкъдимен Гали Хужи күтәреп алды.*

*—Кашшафның каләменә кире каһарман капкан,—диде ул, үз сүзеннән үзе оялган кебек кызарынып.*

*Театр тәнкыйтьчесе Гази Кашшаф мондый бәяләмә белән канәгать иле. Нәрсәдер әйтергә теләп авызын ачканда аны бүлдерделәр.*

*—Мәхмүт мәдәният мәйданында маташа,—диде кемдер.*

*Шагыйрь Мәхмүт Хәсәен кайбер концертларда конферансье булып катнашамы, маташамы, анысын сәнгать белгечләре әйтер, хәзер исә безгә көләргә генә булсын. Язучыларның байтагына шулай берәм-берәм өлеш тигәч, союз житәкчесе Афзал Шамовка чират житте. Теленә шайтан төкергән Зәки Нури шунда:*

*—Шамов шалашта шаяра,—дип куймасынмы.*

---

Ләбибә ИХСАНОВА (1923)—*прозаик. «Көмеш елга», «Нияз», «Тал бөгеләә», «Саралан малайлары», «Очкын», «Гөлләр кояшка карый», «Наил һәм Фаил» повестьлары авторы. Утыздан артык китабы бар. Казанда яши.*

*–Бу мыскыл иту,–диде Афзал ага үпкәләп.*

*Чыннан да, тормышта гаять тотнаклы, әдәпле җитәкчебезгә мондый бәяләмә һич туры килми иде. Уенның кызыгы китте. Барыбыз да җитдиләндек, берара сөйләшмичә бардык.*

*Уйнап сөйләсәң дә уйлап сөйлә дигәннәре дөрес шул.*

*Шушы кечкенә генә истәлектән соң «Күнел күзе күргәндә» дигән язмамны башлап карыйм әле. Халыкта күнел күзе күрмәсә маңгай күзе ботак тишеге, дигән сүз бар. Ямьсезрәк чагыштыру булса да дөреслеккә туры килә. Чөнки күргән бар нәрсә дә хәтердә калмый. Ә менә кай ягы беләндер күңелгә сеңгәне озак еллар онытылмый саклана.*

## Биеклек

Багана башындагы электр утларына карап утырам. Элек алар тәбәнәгрәк иде, яктысы да күп җиргә төшми иде. Монтерлар килделәр дә лампочкаларны күтәртеп куйдылар. Хәзер ишек алды якты. Биеклектә икән шул хикмәт. Кояш та бит иң биек ноктасына җиткәч, җылысын да, яктысын да мулрак бирә.

Ә кайбер кешеләргә биеклек килешми, биеклектән башы әйләнүчән була. Үзенә күрә бер чирдер инде ул. Дәрәҗәгә күтәрелсәләр мәрхәмәтле, ярдәмчел, киң күңелле була алмыйлар. Андыйларның акыллары түгел, борыннары гына югары чөелә. Элек кул биреп күрешкәннәре дә баш кагып кына үтә. Йомышын төшеп янына керсәң ачык йөз белән каршы ала үзе, ә елмаюы январь кояшы кебек якты булса да салкын. Артыннан ишек ябылуга дөньяда барлыгыңны да онытачак.

Шулай да биеклекне Ходай биргән бүләк итеп түгел, олы бурыч кебек тойган кешеләр дә була дөньяда. Шундыйларның берсен, иң югары дәрәҗәле кешене студент чагымда күргән идем.

Кырыгынчы еллар. Илдә сугыш бара. Ә без–күбебез кызлар, тиздән җиңү буласына өметләнеп, ачлы-туклы көе, тырышып укып йөрибез. Лекцияләрнең барысын да университетның төп бинасында тыңласак та геология буенча лекцияне Кремль янындагы «Бегемот» дип йөртелгән бинада тыңлыйбыз. Ун-унбиш минут эчендә анда булырга кирәк. Ленин урамыннан ашыга-йөгерә барганда һәрвакыт бер кеше очрап, бик ягымлы тавыш белән, «Исәнме, кызым», дип үтеп китә. Олы яшьтәге бу кешенең эшләгән җиреннән төшке ашка кайтып йөргән чагы булгандыр дип уйлыйм. Кара драп пальтодан, шундый ук драп кепкадан йөргән урта буйлы, базык гәүдәле агайның кемлеген еллар үткәч кенә белдем. Татарстан Югары Советы председателе Гали ага Динмөхәммәтов булган икән ул. Илленче еллар ахырына хәтле, инде үзе ялга чыккач та, аны хөрмәт белән искә алуларын хәтерлим әле мин. Ә теге вакытта, безнең татар кызы да университетта белем ала, дип, сөенеп исәнләшүе булгандыр аның.

Чыннан да, дәрәҗә кешене түгел, ә кеше дәрәҗәне бизи, дигәннәре хак шул.

## Байлык

Татар язучыларының кайсыдыр бер съездында Киевтан килгән кунак язучы үзенең сүзен: «Мин барган бер җиремдә халыкның ничек яшәвен белер өчен шәһәр базарына чыгам»,–дип башлаган иде. Шул исемдә калган. Ә мин берәр танышыма килсәм игътибарымны китап шүрлеге ала–хуҗаның зәвыгы ниндирәк, нинди әсәрләргә өстенлек биргән? Шунда сүзлекләр, белешмә китаплар, энциклопедия томнары, төрле кинәш җыентыклары да күрсәм танышыма ихтирамым көчәя. Матди байлыктан бигрәк рухи байлыгы сөйләп тора аның кемлеген.

## Үсентеләр

Халыкның бер катлавында ваемсызлык белән бергә чарасызлык күренешләре сизелә башлады. Бүген көн үтсә алдагысын ишәк кайгыртсын, дип яшәүчеләр бар. Арган–талган, киләчәккә ышанычын югалткан андый кешеләрне эче куыш хәлдә дә яфрак ярып, төптән үсентеләр җибәреп азапланган карт агачка охшатам. Ләкин бу үсентеләр бик зәгыйфь, үзләрен саклау көче аларга бирелмәгән, җәмгыятьтәге чирләргә каршы тора алмыйлар. Эчүчелек, наркомания, караклык, бандитлык шундый яшьләрне бөтереп ала да инде. Изге урын буш тормый шул. Корый барган карт агачлар аларны саклый да алмый, көч бирерлек тә хәлләре юк. Таза, нык үсентеләр сәламәт агач тамырыннан гына үсеп чыга.

## Чык тамчысы

Чыклы иртәдәге сафлык, яктылык, күкрәкне тутырып суларлык хуш исле һава йөрәккә дәрт, кулга көч бирә, күнелдә гөнаһлы уйларга әз генә дә урын юк. Бу бәхетле мизгелләрне мин бишектәге яшь баланың ике бөртек тешен җемелдәтеп, ялтаеп яткан чагына охшатам.

Ләкин алда эшле, мәшәкатьле көн бар бит әле. Чык тамчысы кояш нурына бер елмаеп ала да үлән тамырына төшеп ята. Тик шунысы бар: үләндә чык булганда гына көн якты, бәрәкәтле, күнел тыныч була. Чык тамчысына сөенә белгән кешенең дә күнелендә изгелек тулып ята.

## Чаткы

Бүген төшемдә шигырь чыгардым. Уянып китүгә язып та куйдым.

Син анда ялгызың  
Ут йотып яшисең,  
Ә үзен күрешкәч  
Берни дә дәшмисең.  
Шулмыни хисләрнең  
Ялкынлап януы,  
Мәхәббәт утының  
Йөрәккә кабуы.

Язып куйдым да инде аптырап утырам. Каян килеп керә андый төшләр. Шушы яшькә житкәч. Нәрсә соң инде бу, яшьлектә сарыф ителеп бетмәгән хисләрнең уянуымы, назга сусаган сөеп, сөелеп туймаган еллар авазымы? Алмадай чакларын сугыш уты көйдергән кызның җан газабымы, ут эченнән кайтмый калган ярны сагынумы? Күнел картаймый дигәннәре шулдыр күрәсең.

Кайчагында сүнеп, суынып беткән учакта да көл астыннан елтырап бер чаткы җемелдәп куя. Ни үкенеч, «чаткыдан ялкын кабынып» чаклар үткән шул инде.

## Бүләк

Бала-чага таптамаган, кеше аяк басмаган бер кишәрлек җир бар безнең ишек алдында. Бигрәк тә яз башында соклангыч матур була ул. Ямь-яшел үлән өстендә сап-сары тузганак чәчәкләр җемелдәп утыра. Аларның вакыты үтүгә бирегә сары ромашкалар, казаяк чәчәкләре хуҗа була. Яшел белән сары төс бер-беренә шул хәтле килешә, бер-берсен шундый да тулыландырып, карап туймаслык гармония хасил итә. Күзгә ташланып, чекрәеп тә тормый бу матурлык. Сабыр, тыйнак гүзәллек үзеннән-үзе игътибарны ала. Табигать матурлыкны кирәк урында, кирәк кадәр генә бирә белгән.

Кешеләргә карыйсың, төсе-бите белән аерылып та тормый берәү,

әллә кай ягы белән күңелгә кереп утыра да күргән саен күрәсе килә үзен. Нәкъ менә җырдагыча:

Күрер күзгә берни түгел,
Сөйкемлеге сөйдерә.

Сөйкемлелек—үзе бер бәхет.

## Бердәмлек

Безнең йорт янында зур гына күл бар. Шәһәр уртасындагы биек таш пулатлар арасында ничек сакланып калгандыр да яз саен әйләнеп кайткан кыр үрдәкләре ничек эзләп табадыр бу күлне.

Яз башында артык зур хәрәкәт булмый әле күл өстендә. Яшькелт-зәңгәр башларын горур тотып, күкрәкләрен киереп, ата үрдәкләр генә йөзеп йөри. Камышлар арасында ояда утырган парларның тынычлыгын саклавы инде бу кошларның. Менә бер көнне күл өсте кинәт җанланып китә. Ана һәм ата үрдәкләр, йодрык хәтле генә бәбкәләрен ияртеп, оя-оя йөзеп йөриләр. Алар янына Идел акчарлаклары очып төшә. Читтән караганда малайларның кәгазьдән ясап суга җибәргән «кораблары» кебек күренгән бу кошлар үзләре бер матурлык өстиләр. Оныкларын житәкләгән әбиләр дә су буенда ешрак күренә. Сабыйлар кошларны җим белән сыйлыйлар, күмәч кисәкләренә ашыга-ашыга йөзеп килгән үрдәкләргә шатланалар.

Ә бер чыгуымда күз яшьләре белән елап торган нәни кызны күреп:
—Кем тиде бу матур кызга?—дип сорадым.
—Күлдән үрдәкләр киткән, шунар кәефе бозылды,—диде әбисе, оныгының күз яшен сөртеп.

Игътибар итмәгәнмен икән, ул иртәдә су өстендә бер генә үрдәк тә юк иде. Шулай каядыр очып барып кайткалыйлар иде алар. Исәя барган бәбкәләрен очарга өйрәтүләре, канат ныгытулары күрәсең. Шулай булмыйни, сиздермичә генә көз якынлаша бит. Ерак сәфәргә җыенып вакытлар да житә. Безнең күлгә башка җирләрдән дә үрдәкләр очып төшә башлады. Бер иртәне утызлап пар үрдәк санадым. Алар шулай юлга чыгар алдыннан җыелып, үзләренчә киңәш-табыш итәләрдер кебек.

Элегрәк елларда адәм балалары да бердәмлектә көч, таяныч тапканнар. Хәзер җәмгыятьтә, кешеләр дә, туганнар да бер-берләреннән аерылып беттеләр. Берәүләр меннәр өчен, меннәр берәү өчен дигәнне «кеше кайгысы төштән соң» алыштырды. Башыңа бәла төшкәндә кычкырып еласаң да, кул сузучы аз булыр. Борынгыларның бүленгәнне бүре ашар, дигән сүзләре хак. Шундый чакта кошлардан көнләшерлек, билләһи.

## Алдашу

Тагын төш күрдем. Мәскәүнең балалар әдәбияты нәшриятында милли әдәбиятлар бүлеге мөдире булган Галия ханым Кәримовага хикәя укыйм икән. Ә ул тынлап та бетермәде, Илдар Юзеев сюжетын алгансың, диде. Эчем пошып китте. Хикәям алдашу турында иде бит. Болай булгач, үзем дә алдакчы булып калам түгелме соң? Ә хикәянең ахыры болай тәмамлана иде: «...Бу җирләргә каны тамган кешеләрнең каберләренә чәчәкләр куярга кирәклеген әйткән идек аларга.順ныбыздан урап узарга тырышуларын күрсәк тә, кулларында чәчәкләр булгач, тынычланган идек. Ләкин ул чәчәкләр кәгазьдән ясалган, төссез чәчәкләр икән. Атлаган саен кыштыр-кыштыр киләләр.»

Төштә генә түгел, өндә дә шулай ясалма чәчәкләр кебек буш сүзләргә, ялган вәгъдәләргә алданып күпме кешеләрнең өметләре киселә, бәгырьләреката, яхшылыкка ышанычлары югала. Оҗмахтан куылган шайтан ару гына кешеләрнең күңеленә килеп керсә, «Алдала, алдала, алдала» дип

котыртып тора. Югыйсә Хода бәндәләре бер-берсенә тау хәтле яхшылыклар эшли ала бит.

## Ут белән су

Үзгәртеп кору чире башлангач, сыйнфый көрәшне юкка чыгарырга маташучылар күбәйде: бай да әйбәт, ярлы да әйбәт. Хәтта «Килешү көне» дигән нәрсә дә уйлап маташтылар. Килешүчеләр генә күренми. Һәркем үз бәхетен, үз рәхәтен үзе табарга тиеш дигән караш хөкем сөргәндә бу каршылык көчәя генә төште. Ә бит сыйнфый көрәш сәясәтчеләр уйлап тапкан нәрсә түгел. Ул бик борынгыдан, Чыңгыз хан вакытыннан ук (ә бәлки аннан да элегәрәктер) билгеле булган.

Тимучинның (Чыңгыз хан) бала вакытыннан бергә уйнап үскән Җәмуха исемле дусты булган. Үсеп буйга житкәч, бергә яу чапканнар, ыругларының язмышын яклап, иңгә-иң куеп сугышканнар. Тора-бара аларның юллары аерылган. Җәмуха гади халыкның бер вәкиле буларак, аларның ихтыяҗын өстен күргән, ә Тимучин байлар (атлы кешеләр) ягында булган. Элекке дуслар арасындагы каршылык нык кискенләшкән. Тимучин Җәмуханы дошман күрә башлаган. Инде алар бер булып түгел, бер-беренә каршы корал күтәргәннәр.

Матди байлыкка хуҗа булган кешеләр беркайчан да үзләренә хезмәт итүчеләр белән дуслаша алмыйлар. Хуҗалар һәм хезмәтчеләр ут белән су кебек. Мәңге бергә, мәңге аерым.

## Өлеш

Әнием казанга аш салганда берничә чүмеч суны:
—Монысы үзебез өчен,—дип сала.
Тагын берне өстәп:
—Монысы парга әйләнү өчен,—дип куя.
Иң ахырдан тагын бер чүмеч салып:
—Монысы килгән кеше өлеше,—ди.

Ул моны күнеленнән генә уйлап та, йә өйрәнелгән гадәте белән дә эшләгән булыр иде. Белеп торам, минем колагыма керсен, мин өйрәнә торсын дип әйтә ул аларны. Безнең өйдә бер пешкән ашны ике утырып ашау да, ризыкны исраф итү дә юк. Шуңа күрә әниемнең чама белән эшләвенә исем китми. Ә менә анын килмәгән, киләсе дә билгеле булмаган кеше өчен өлеш салуы гажәбрәк.

Кешеләр, чыннан да, күп килә иде үзе. Йомыш белән дә, йомышсыз да кереп утыралар. Әтием белән әниемнең ерак юлдан килеп төшкән танышлары да була. Барысының да урыны түрдән. Татарның килгән кешене өстәл янына чакыра торган гадәтен бәләкәйдән күреп, өйрәнеп үстем.

Шул турыда сүз чыккач, Шәрәфнең (сүз Ләбибә Ихсанованың тормыш иптәше—шагыйрь Шәрәф Мөдәррис хакында бара, *ред.иск.*) сөйләгәне истә калган. Германиянең Штеттен шәһәрендә ул яшәгән фатир хуҗалары ашап-эчеп утыралар икән. Күршеләре килеп кергән.
—Сез ашадыгызмы әле?—дип сораган хуҗа.
—Өлгермәдек әле.
—Без дә янарак кына утырдык,—булган шуңар каршы җавап.

Һәр халыкның йоласы, үз гадәте. Гаеп итеш юк. Ә безнең татар, күрше хакы алла хакы, дип яши һәм бик дөрес эшли. Мин шуның белән горурланам.

## Күнелләге җыр

Нажар Нәжминең вафатын ишетү авыр булды. Әледән-әле күрешеп, хатлар алышып, китаплар бүләк итешеп яшәгән еллар искә төште. Хатларын яңадан алып укыдым. Һәр сүзеннән, җөмләсеннән аның тавышы килгән кебек. Күңелдә аның җыры, аның моңы. Ягымлы баритон тавыш, киң күкрәктән чыккан иркен сулыш, сагышлы моң. Беренче тапкыр

мин аны Агыйдел буенда ишеткән идем. Бу жыр мине студент чакларымда йөргән Урал тауларына алып менде дә янадан гөнаһлы жир өстенә кайтарып куйды.

Кешеләрне жырлаткан да, елаткан да шушы газиз жир бит. Шагыйрь шул жирне саклап утка керде, шул жирне яклап жырлады. Туган жиренен сөекле улы булып яшәде. Менә инде ул жылы жир куенында мәнгелеккә күзен йомды. Әмма анын жырлары калды. Моны, сагышы, янып-көеп әйткән сүзләре, шатлыктан эчкерсез шаркылдап көлүе калды.

Шагыйрь гомере яшәгән еллар белән түгел, калдырган хезмәте белән санала.

## Чыршы

Ап-ак мендәрдә йоклап яткан сабыйны искә төшерә иде ул–ак кар өстенә яшел итәген жәеп тын гына утырган нәни чыршы. Яныннан чабып үткән кыска койрык–озын колакка да исе китмәде, шакылдавык саесканга да селкенмәде. Янындагы карт чыршы яман күзләрдән саклап тора иде аны. Тик саклап кына бетерә алмады.

Салкын корычнын үткен йөзе йомшак тәненә батып кергәч, яшь чыршы сискәнеп китте. Берара аңышмыйча торды һәм әкрен генә жиргә ауды. Балта йөзенә анын күз яше сыланып калды.

Жылы, матур бүлмәгә алып керделәр аны. Ялтыравык тәтиләр, аллыгөлле утлар белән бизәделәр. Күнелен ачарга теләп, жырладылар, биеделәр, бәллүр бокаллар чынлаттылар. Нәни чыршы туган урманын сагынып, почмакта боегып утырды. Матур бизәкләр анын күнелен ача алмады, көннән-көн саргаеп, кибеп бетте.

Шуннан сон бу чыршыны салкын кар өстенә чыгарып ташладылар. Хәзер инде ул мәсхәрәләнгән яшь кызны хәтерләтә иде. Үсеп кенә килгәндә туганнарыннан аерып алдылар да күнелләре булганчы уйнадылар. Туйгач, аяк эзләреннән каралып беткәнпычрак кар өстенә чыгарып аттылар, оныттылар.

## Үкенү

Мондый да мәшәкатьле дөньяда үкенүләр күп була анысы. Вакытында йөрәкне чеметеп алгандай итә дә онытыла тагын. Бер борчу икенчесен баса. Шулай да гомерен буена жаныңны борчып торганы да була икән анын. Яшәгән саен ачысы көчәеп, тирәнәеп, төзәтеп булмаслыгын белгән саен әрнетеп торганы үзен белән бергә китәдер бу дөньядан. Күп кешеләрнен шулай әкрен генә сызлап торган төзәлмәс ярасы бардыр ул.

Әтиемнен вафатыннан сон парын югалткан ялгыз аккош сыман сагышлап йөрде-йөрде дә әниебез, мәрхүмнен ел ашын үткәрүгә, урын өстенә ятты. Безнен башка авыр көннәр тагын килде. Газизебезнен тормыш жебе өзелер чакны кан калтырап сизеп торабыз. Ул үзе инде барлык вөжүде белән әтиебез янында бугай. Салкын сулы савыттагы дәү кулларынын вакыт-вакыт калтырап куюыннан гына дөнья белән хушлашырга өлгерməвен анлыйбыз. Суны алыштырыгыз, дигән ишарәсе була ул анын. Ут янган учларынын салкын суда гына бераз тынычланганын белгәнгә тизрәк анын теләген үтәргә ашыгабыз.

Зәнгәр тамырлары бүртеп, как сөяккә калган кулларны әкрен генә сөлге өстенә куям да, сулы савытны алып ванна бүлмәсенә керәм. Нинди дер кодрәт белән тыелып торган яшьләремә шунда ирек бирәм. Ике битемне яндырып тәгәриләр дә тәгәриләр.

Әниебезнен эштән бушый белмәгән куллары гомере буе тынуны белмәде. Январь суыкларында да кулына кимәде ул. Инешкә төшеп, бәкедәге агым суда кер чайкавын дер калтырап карап торганым бар. Бу кулларнын күпме балаларнын башыннан сыйпап сөеп үткәнен дә күргәнем бар. Кырык елдан артык балалар укыткан әнием кичләрен дәфтәрләренә билге куйганда укучыларынын язмышы турынданиләр уйлаганын үзе генә белгәндер мөгаен. Эшен төгәлләп ял итәргә утырганда да анын

кулында йә чигү, йә челтәр бәйләү энәсе булыр иде. Ул бәйләгән челтәрле мендәр тышлары, сөлге башлары, карават кашагалары күбрәк сенлем белән минем өчен дигән бирнәгә салып куела иде. Без кечкенә чакта тегеп кигерткән матур күлмәк өлгеләрен, энеләремнең якасы чигүле күлмәк үрнәкләрен кемнәр генә күчереп алмагандыр безнең авылда.

Хәзер менә шул кулларның кыймылдарлык та хәле юк. Минем аларны учларыма аласым, битләремә куеп торасым, бармакларын берәм-берәм үбеп чыгасым килә. Ләкин кыюлыгым житми, моны эшләргә нидер комачаулый, хисләремне богаулап, тыеп тора.

Хәзер уйлап утырам: үскән чагыбызда әниебезнең кулларына бераз ял бирик дигән уй башыбызга килдеме икән? Әни, утырып тор, үзебез эшләрбез, дип әйтә белдекме икән? Әллә кушканны гына эшләп йөрдекме? Әйтә белмәгәнбездер мөгаен. Үсмер чак—ваемсыз чак шул. Менә хәзер йөрәкне шунысы әрнетә, шунысы үкендерә. Әти-әниебезгә бурычлы булып калу намусны борчый.

## Чәчәкләр

Грузиннарда матур гадәт бар дип әйтәләр. Хужаның берәр әйберен бик яратып, чын күңелдән мактасаң, ул аны сиңа бүләк итә ди. Бу кытлык заманда андый гадәт сакланамы, юкмы—белмим. Әмма бер көнне үземнең шундый хәлгә калганым булды.

Дачадагы күршем чәчәкләр үстерергә ярата. Иртә яздан кара көзгә хәтле гөл бакчасыннан күзенне алырлык түгел. Андагы примулаларга, пионнарга, флоксларга, глодиолусларга, кашкарыйларга сокланып туя алмыйм. Бер көнне дөньямны онытып карап торуымны күргән дә күршем, кичкә таба чәчәкләр күтәреп кергән.

—Көзен тамырларын алып бирермен, әлегә чәчәкләрен рәхим ит,—диде.

Шатлыгымнан ни әйтергә дә белмәдем. Үземнең дә шундый гөлләр үстерәсем килеп йөри иде. Күршемнән сорарга гына кыюлыгым житми торды. Тамырларын бирермен дигән вәгъдәсе чәчәкләрдән дә битәр сөендерде.

Ә кызымның башы күккә тигәндәй булды. Төрле-төрле букетлар ясап кич буе мәш килде. Иртәгесен ике ак, бер кызыл глодиолусны эшенә алып китте.

—Бүген Мәрьям апаның туган көне, килүенә өстәленә куям әле,—диде.

Мәрьям апалары минем кызым кебек бик күпләрне эшкә өйрәткән, инде пенсиягә жыенып йөргән игелекле жан өстәлдәге чәчәкләрне күргәч:

—Инде күптән миңа шундый чәчәкләр бүләк итүче юк иде,—дигән.

—Беләсеңме, әнием, аның күзләре яшьләнде шул чагында,—диде кызым.

Ләкин бу кадерле бүләкне өенә кайтарып житкерә алмаган ул. Тыны бетеп, артыннан бер яшь егет куып житкән дә:

—Әйтегез әле, ханым, бу чәчәкләрне кайдан алдыгыз?—дигән.

—Бу миңа бүләк,—дигән Мәрьям ханым, горурланып, һәм егетнең күңелсезләнүен күргәч,—Сезгә бик кирәк идемени?—дип сораган.

—Кәләшем янына бара идем, чәчәкләр таба алмадым,—дигән егет.

—Алыгыз соң бу чәчәкләрне,—дигән ханым,—алыгыз, ал. Чәчәксез барырга ярамый сезгә.

Кызым шуларны сөйләгәч:

—Менә күрәсеңме, Нажия апаң ничә кешене сөендерде,—дип әйтмичә түзә алмадым.

Грузиннардагыча гына булып чыкмады бит әле бу. Бакча күршем мине генә түгел, кызымны да, Мәрьям ханымны да, кәләше янына ашыккан кияү егетен дә бәхетле итте.

—Бер алманы бишкә бүләек,—дип жырлыйсы гына калды.



## Рөстәм Мингалим

### ОНЫТЫЛМАС ХАТИРӘЛӘР

### Күрәсебез бар икән

*(Алар һәм болар
яки гөлләр турында)*

Алар башка буын иде,
ә болар—башка буын.
... И язлар кабатлануы—
гөлләрнең ачылуы!

Чын төс иде, чын ис иде
калын толымнарында.
Тезләнеп торыр идем лә
узасы юлларында...
Алар шул бик үз иделәр,
болар да бик чит түгел.
Шулай да һаман аларны
юксынып куя күңел.
Чын сүз иде телләрендә,
күз яшьләре чын иде.
—Гафу итә күрегез?—дип,
әйтергә дә соң инде.
Алар калган бакчаларда
хәзерниләр бар икән?
Анда микән әле алар,
анда да—болар микән?

---

Рөстәм МИНГАЛИМ (1937)—*шагыйрь, драматург; егермедән артык лирика, балалар өчен шигырь китаплары авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

Исе башка, төсе шашкан,
дөньясы—бүген бүтән.
Алар кыяк-кыяк иде,
болар бит түтәл-түтәл.

Озын-озын түтәлләрнең
аралары тар икән.
Бинибая матур гөлләр
күрәсебез бар икән!

## Ялгыш яраттым

*(Шаяру түгел)*

«Тиле яшьлек!»—иске әйтем,
тик яшьлеген кичкән һәркем
уза аны яңартып:
мин дә
тиле яшьлегемдә
бер тилене яраттым.
Туң җаннарның боз колагын
эретерлек кызчык ул.
Күкрәгенә кунып сайрый
тулай торак кошчыгы!
Яз түгел бу, көз дә түгел,
чатнап торган кыш ае.
Сайраштык та саташтык бит,
очты... маржа-тургаем.
Барып кагам бүлмәсен дә,
түңам тәрәз катында.
Уты янмый, йоклаганмы,
иртән генә кайтырмы?
Өмет яна—сары башны
табалырмын шикелле:
сөяп түрем почмагына,
табынырмын шикелле!
Шулай ялгыш яраттым шул,
авызкае—бөрмәле...
Күрәм бермәл ачылганын
мин какмаган бүлмәнең.
Күз шар булды,
өнсез торам—
әйтерсең лә бер карак...
... Ә ишектән елмаючы—
маржалардан маржарак!
Бүлмәсе җәйләрдән җылы,
йә Раббым, ни ояты—
Картлыгымда керә төшкә
тиле яшьлегем юлына
аркылы яткан хатын:
—«Таныйсыңмы,
мин исән!—ди,—
тилемсәм!»—ди;
моңландыра, уйландыра,
чукындырып китәр иде,
комачаулый таң ату.

## Ходай сиңа күп биргән

*(Казанда яшәүче танышым Мария Васильевнага)*

Күлмәгең тар, түшең киң,
иреннәрең—ут кына.
Куркыта да, суыра да
күзләреңнән упкыны.
Синең зәңгәр упкының
йөз әбиең мирасы:
сизәсеңдер—исемнәре
бер шигырьгә сыймасын.
Упкыныңда—морзалар,
татар арба-атлары...
Милли ярыш мәйданының
сез тиңдәшсез затлары.
... Әнә берәү—мәйданда:
—Мин татар!—дип очына.
Мүкәләп ул төнлә килер
синең аяк очына...
Рус иленең көче—сез,
кабыгымы, төшме сез?
Күрше илләр өстенә дә
бер менсәгез—төшмисез!

Ах, Мария, Мария—
Мария Васильевна!
Мин сиңа асылынмыйм ла,
син миңа асылынма...
... Ак кәбестә—артларың,
үкчәләрең—кадактыр:
Бикбулатка, Хәйруллага,
Зәйнуллага кадап тор.
Малаена төртеп ал,
яше чыкса—сөртеп ал.
Аннан төпсез упкыныңа
чумганнарын карап кал.
Чуммаучылар очраса—
чукын да бер ярлыка—
гыйбрәт өчен кирәк әле
алар минем халыкка.

Ходай сиңа күп биргән,
өеп биргән—азсынма.
Ах, Мария, вах, Мария!
Мария Васильевна!
Күлмәгең тар, түшең киң,
иреннәрең—ут кына.
Куркыта да, суыра да
күзләреңнән упкыны.

## Сүзләрең гел истә торды

*(Актаныштан Яна Кормаш*
*кызы Илүсәр Вәлиевага)*

**Ну начар да язгансың, дип**
**әйтүче дә син булдың.**
**Моны язма—янарсың, дип**
**әйтүчем дә син булдың.**

**Бер җилкәмдә ике баш та**
**түгел иде югыйсә.**
**Бар язганым—җан һәм кеше,**
**күңел иде югыйсә.**

**... Язылды шул—**
**бер башлагач,**
**хут белән дә уйналды.**
**Хут белән уйнаган шәйгә**
**ут белән дә уйналды.**

**Сүзләрең гел истә торды—**
**шулай да азгаладым:**
**шигырьдән җәяү качканнар**
**өчен дә язгаладым...**

*1999—2001.*



# Нур Әхмәдиев

## ДӨНЬЯЛАРНЫ ГАЯРЬ ИР БИЗӘР...

### Июль уртасы

**Печәнчеләр яныл печән чаба,**
**Һәр болытка карый шик белән.**
**Кигәвеннәр ярсып корбан эзли,**
**Сулыш каба хәтта кич белән.**

**Тәңкәләрен саф алтыннан койган**
**Көнбагышлар нурда коена.**
**Басуларның симез башаклары**
**Хәзерләнә соңгы туена.**

### Җаны белән кеше Одиссейдыр

**Сәяхәттә гел йөрмәдем түгел,**
**Холык-фигыль минем—илгизәр.**
**Бакчаларны гүзәл гөл бизәр дә,**
**Дөньяларны гаярь ир бизәр.**

**Чит җирләрдә, бәлки, дан да килер,**
**Зур-зур эшләр ирләр майтарыр.**
**Бер көн килеп Алып батырны да**
**Туган җире дәшеп кайтарыр.**

**Җаны белән кеше Одиссейдыр,**
**Җаны белән кеше—илгизәр.**
**Туган җирне оныта калсаң әгәр,**
**Йөз чөерер авыл, ил бизәр.**

### Бәхет турында

**Артык бәхет—үзе бәхетсезлек,—**
**Башкаларның кайный саруы.**
**Әҗәлнең дә даруы бар диләр,**
**Көнчелектән бармы даруы?**

---

Нур ӘХМӘДИЕВ (1946)—*шагыйрь, «Аһән», «Бал янгыры», «Чакматаш» һ. б. китаплар авторы. Проза әсәрләре дә яза. Әлмәттә яши.*

## Ялагайлар

Алласыз да калдык яши торгач,
Ә Иблис әрсез.
Аздырырга гына тора
Мактап әйткән һәр сүз.

Тәнкыйтенә түзә алган бу җан
Ник мактауга эри?
Шуны сизгән шакал кебек, янда
Ялагайлар йөри.

## Таныш зиратларда

Әчем пошса, керәм зиратларга,
Җан тартамы, әллә кан тарта.
Үлемнәр дә яшәүнең бер төре,
Шуңа серле, булмый аңлап та.

Күпме дуслар күчте мәңгелеккә,
Кайсыбызның хәзер чираты?
Кочагына кабул итәр өчен
Әзер тора шәһәр зираты.

Күпме дуслар күчте мәңгелеккә,
Саный китсәң, тел дә сөрлегә.
Без яшибез җирдә парлы-парлы,
Ә гомер бит, гомер бер генә!

Дусларымның барлыйм каберләрен,
Әрвахлары белән сөйләшеп.
Исәннәрне алар кызганамы,
Яталармы әллә көнләшеп?

Торып әйтер иде, мөмкин түгел,
Ул дөньяда гайбәт сатмыйлар.
Җирдәгеләр кемгә кем кирәктер,
Мәрхүмнәрне
Фәрештәләр анда саклыйлар.

Уйлар узып тора башкаемнан,
Шом сала шул, сала зиратлар.
Ахыр чиктә кем дә шунда бара,
Бозылмасын иде чиратлар.

*

Арабызга җил дә керми иде,
Усал телләр гайбәт тараткан.
Шомырт чәчәгедәй ак сөюгә
Кырау төшә төрле тарафтан.

Арабызга җил дә керми иде,
Хәзер шаулый давыл, ураган.
Кояш сүнде, алган яктым бары
Пыскып торган юеш чырадан.

Арабызга җил дә керми иде,
Хәзер атлы арба узарлык.
Иртәгесен бәлки түзеп булыр,
Сабырлык бир бүген чыдарлык.

* * *

Атылырга гына торам,
Эчемдә, гүя, вулкан.
Вулкан юкка кузгалмый ул,
Ә мин ник кызам юктан?

Кайчак уйланам соңыннан:
Ә хаклы булдым микән?
Хаксызлыгымны танысам,
Үземне тетәм, сүтәм.

Ни файда?
Хәзер соң инде:
Җил искән, кораб киткән...

## Йола

Киләчәккә бара-бара,
Үткәнне сагынабыз.
Хыялда—һаман яшьлекнең
Канатлы таңында без.
Шыбырдап еллар коела,
Күзләргә тузан тула.
Туганнан кабергә кадәр
Озата безне йола.
Бул дөньяның иң даһие,
Укыганы, йә надан,
Әйтегезче, патшалар соң
Өстенмени йоладан?
Йолаларга элгәрләрнең
Зирәк акылы кергән.
Саклыйсызмы, диеп алар
Күзәтә кебек гүрдән.
И йола,
Каршы аласың,
Туып, аваз биргәндә.
Һәм дә озатып каласың
Ләхеткә иңдергәндә.

* * *

Яшәмим алай бүтән,
Җанымны шигырь итәм.
Кулдан чыпчыкны очырып,
Һавадан аккош көтәм.

Кулыма каләм алуга,
Айрылды җаннан бу тән...

## Намус турында

Намусыңны яшьтән сакла, диләр,
Онытабыз, әллә аң җитми.
Җан сакларга кайчак кан да җитә,
Намус өчен—хәтта җан җитми.

## Мантыйк

Гашыйк булу—теләп әсир төшү,
Әсир булу—ул бит онтылу.
Коллыгыңны аңлау—баш күтәрү,
Димәк, азатлыкка омтылу.

Чигәргә риза газап,
Сөюдән итмә азат.

## Беләм

Беләм мин сагыш газабын,
Ни икәнен көтүнең:
Яктылык елыннан озын
Синсез үткән бер төнем.

## Күз

Кичә генә әле яшел иде
Тәрәз каршындагы каеным.
Кояш байый,
Кояш баюлары—
Бер мизгеле гомер баюның.

Каеннарда кайдан бу сорылык?—
Соңаргандыр җылытыр сүзләр.
Урам әте кебек әрсез инде
Йөрәкләргә үтәр бу күзләр...

Күзгә моңга манган сагышларым
Торналарга барып сарылган.
Әгәр рәхәт булса, бу торналар
Китмәс иде туган ягыннан.

Кошлар китә, дуслар, без калабыз,
Кош язмышы түгел кешедә.
Тулган күңелемә сагыш өстәп,
Каеннардан яфрак ишелә.
Сары яфрак...

## Беләм мин

Беләм мин ул көн киләсен,
Кем качалсын Үлемнән.
Ышан син: Үлем каршында
Каушап калмам, җебемәм.

Тормышта аз сынамадым
Фигылең, гадәтеңне.
Ничек җиңеләйтергә соң
Ул көнгә халәтеңне?

Ул көн, беләм, синең өчен
Кыяматкә тиң булыр.
Елмаеп сиңа багучы
Ике күзем ким булыр.

Беләм мин: көнен, төннәрен
Исеңә аласыңны;
Кояшның алсу нурларын
Күз яшькә манасыңны.

Җаныңның җиде тамырын
Үкенү хисе кыйнар.
Хәлләреңне белә калса,
Таш булып таш та елар.

Хәтереңнең тәрәзәсен
Чиртермен, кагармын мин.
Онытылмас җырың булып
Җаныңда калырмын мин.



## Данил Салихов

# МӨГЕЗЛЕ МӘҮЛИХАН

КОМЕДИЯ ИКЕ ПӘРДӘДӘ

Катнашалар:

М и р в ә л и—амбар каравылчысы
З а һ и д ә—Мирвәлинең хатыны
Г ө л д а н и я—авыл хатыны
Н у р г а л и—кәнүшни каравылчысы
М ә ү л и х а н Х а н о в и ч—колхоз рәисе
Ф ә с х е т д и н—мулла
М ө з ә й ә н ә—кортка

## Беренче пәрдә

Пәрдә ачылганда төн. Багана башындагы фонарь каравыл йортының бер як бүрәнә стенасын яктырта. Стенага терәтеп эскәмия куелган. Эскәмиядә Мирвәли. Башында бүрек, өстендә каешланган бишмәт, аягында хатын-кыз оегы кигертелгән чучинкә. Стенага сөяп күсәген куйган. Җырлый-җырлый, тәмәке пыскытып утыра.

Бардым күлгә, салдым кармак,
Безгә балык эләкми шул.
Йөгереп китәрдәй булам ла,
Кайтып житәрдәй булам.
Күзгә ачы җилләрдә ләй,
Туган-үскән илләргә.

(*Карангылыктан аяк тавышы ишетелә. Кинәт җырлавыннан туктап кала.*) Стой! (*Таягын мылтык итеп карангылыкка төзи.*) Пароль?!

Н у р г а л и. Пошел ты... знаешь куда?!

М и р в ә л и. Знаю, на... баню.

Н у р г а л и (*килеп чыга. Кулын биреп исәнләшә*). Нихәл, кордаш?

М и р в ә л и. Ат мөгезе кебек. Ике ел постта торам, дип әйтте ди армиядәге бер чукча. Ике елга бер генә тапкыр да парольне үзгәрткәннәре юк. Пошел ты да пошел ты, дип күрсәнде ди мескен. Әйдә, чүмәш. Пыскытып җибәр.

Н у р г а л и (*тәмәке кабыза*). Тынычлыкмы?

М и р в ә л и. Кабер тынлыгы.

Н у р г а л и. Тыныч булмыйча. Буш амбарга карак киләме.

М и р в ә л и. Сөйлисе юк. Элегрәк күселәр чыйнашканын тыңлап юана иде күңел, икмәк беткәч алары да качышып беттеләр.

Н у р г а л и. Шулай инде. Бер яклап Мәүлихан Ханович; икенче яклап син ыштан балагына тутырып бөтен

Данил САЛИХОВ (1958)—*драматург, дистәдән артык сәхнә әсәрләре авторы. Казанда яши.*

колхоз икмәген ташып бетердегез.

М и р в ә л и. Сөйләмә, колхозның инәсенә дә тигәнем юк. Мәүлихан Ханович түгел, Мәүлихан Хамович ташып бетерде аны, машиналап...

Н у р г а л и. Хи-хи. Сөйләмә, кордаш. Чалбар балагына салкын икмәк тутырып ташып харап булган кеше бит син.

М и р в ә л и. Хатын гаепле. Заһидә. Юри эшләделәр. Мәүлихан белән бердәм булып. Кем инде чалбар балагы бәйләргә капрон жеп биреп жибәрә. Кызның башына бәйли торган бантигын биреп жибәргән бит. Колхоз правлениесенә генә килеп житкән идем, сүтелде китте, каһәр. Өстәвенә, бөтен дөньяны яктыртып, багана башында лампочка яна. Шуны гына көтеп торган Хам килеп тә чыкты, милициягә алып та китте. Синең ничек анда, кәнүшнидә?

Н у р г а л и. Озакламый тынычлап калам. Атлар бетә колхозда. Өч ат бар иде, аның да кичә төнлә берсе тирескә батып жан тәслим кылган.

М и р в ә л и. Да... Буш амбар саклаганчы, хатынны кайтып сакласаң, әйбәт булыр иде ул, ә, ахир?

Н у р г а л и. Утырма күзле бүкән кебек. Кайт та рәхәтләнеп йокы симерт.

М и р в ә л и. Симертерсен, бар. Кайтып кына кара. Мәүлихан жиденче бабанны исенә төшерер.

Н у р г а л и. Ә син ана күренмә. Ул югары очтан, ә син түбәннән. Ул түбәннән, ә син югары очтан.

М и р в ә л и. Югарыдан, түбәннән... Юк шул. Ул өстән йөрергә ярата. Күренмә, имеш. Беләсең ич инде. Минем каравылга киткәнне көтеп кенә тора. Бакча артлатып кына минем хатынның, Заһидәнең куенына йөгерә.

Н у р г а л и. Әй кордаш, кордаш. Мин сине берни дә белми бу дип йөрим, ә син...

М и р в ә л и. Белеп нишлисен?! Бар, кайтып кара. Чалбар балагы чишелеп харап булдым бит. Алты айга мәжбүри эшкә илтеп тыкты. Хәзер чәбәләнеп кара.

Н у р г а л и. Асылын да үл.

М и р в ә л и. Өченче көн кайткан идем. Өйдән Хам килеп чыкмасынмы? «Нишләп йөрисең монда», - диган идем, «сине тикшерергә килдем», ди. - Син әле шулай эш ташлап, өеңдә йоклап йөрисеңмени?! Мин сине бөтенләйгә рәшәткә арасына яшерәм бит», ди.

Н у р г а л и. Син шушы хәлгә түзеп яшисеңме?

М и р в ә л и. Яшәми нишлисен?

Н у р г а л и. Асылын да үл.

М и р в ә л и. Түзәргә туры килә, ахир. Өтермәгә кирәсе дә, үләсе дә килми. Аннары, ояты кемгә?

Н у р г а л и. Кемгә?

М и р в ә л и. Хатынга, Заһидәгә. Мин үләрмен дә котылырмын. Ә бит әле аның авыл халкы белән яшисе бар.

Н у р г а л и. Тинтәк! Син шул Хамга бер сүз дә әйтмәденме?

М и р в ә л и. Нишләп әйтмим, әйттем. Син мине ул кадәр жебегәнгә санама инде. Фонаремны оныткан мын, бик авыр булмаса, алып чыгып кына бирмәссеңме, дидем.

Н у р г а л и. Ярый әле, баш очларында да фонарь күтәреп басып торырга кушмаганнар.

М и р в ә л и. Анысы булмас. Фонарьның керосины юк иде.

Н у р г а л и. Асылын да үл.

М и р в ә л и. Керосинсыз лампа-фонарь тоттырып, озатып калды. Менә хәзер өйгә кайтырга куркып утырам.

Н у р г а л и. Әйттем бит мин сина, кордаш, чалбарга салкын бодай тутыру ир-ат өчен зарарлы дип. Тынламадың. Да, асылын да үл!

М и р в ә л и. Ярый, түзәм. Мин күрәсен кеше күрмәс. Бер йомырка маяда да чери.

Н у р г а л и. Да, асылын да үл!

М и р в ә л и. Ходай бар, Ходай барысын да күрә.

Н у р г а л и. Асылын да үл!

М и р в ә л и. Син нәрсә сон, асылын да үл, асылын да үл! Бик рәхәт булса үзен үл!

Н у р г а л и. Син алай димә әле, кордаш...

М и р в ә л и. Теге чакта бер ярты алып киләм дип акчамны алдап алып качкан идең, шуннан котылырмын дип уйлыйсыңдыр.

Н у р г а л и. Син алай димә әле, кордаш. Син асылынып үлсәң, гомергә рәхәттә яшәячәксен.

М и р в ә л и. Дивана, үлгәч яшәп була димени?

Н у р г а л и. Үлгәч инде ул рәхәтләнеп яшисен, ожмахта.

М и р в ә л и. Яшәрсен, бар. Ожмахка безне кем кертсен. Анда да акча түләп керештер әле ул. Әнә, безнен авылның мулласы Фәсхетдин акча жыймас иде.

Н у р г а л и. Каян беләсен?

М и р в ә л и. Әнә бит, Пыски Фәсхетдинне әйтәм, башта сәвит чагында

парторг, аннары сельсовет председателе булып колхозны талады, хәзер мулла булып, карт-корыны, авыл халкын талый. Оҗмах алар өчен инде ул.

Н у р г а л и. Юк. Оҗмах синең өчен ул. Бар, берәрне алып кил, оҗмахка керәсең килсә.

М и р в ә л и. Бар, алып кил! Каян килгән фәрештә!

Н у р г а л и. Ярый алайса. Оҗмахта яши башлагач, бер ярты урынына бер ящик куярсың!

М и р в ә л и. Әбиең сызгыра беләме?

Н у р г а л и. Тыңла. Хәзер син асылынасың.

М и р в ә л и. Таптый-таптый күмәр идегез бугай. Бөтен авылыгыз белән җыелып.

Н у р г а л и. Җүләр син, кордаш. Син асылынып үлсәң, икебез дә рәхәттә яшәячәкбез.

М и р в ә л и. Йә, сөйләп кара. Мине үтереп ничегрәк рәхәттә яшәрбез икән?

Н у р г а л и. Син хәзер әнә теге сарайга керәсең дә, муеныңа элмәк салып, телеңне чыгарып ятасың.

М и р в ә л и. Шуннан?

Н у р г а л и. Шуннан соң мин авылга чаң кагам. Кешеләрне уятам. Синең өеңә чабам.

М и р в ә л и. Нигә?

Н у р г а л и. Атаң башына! Мирвәли кордаш асылынып үлгән, әле генә баудан кисеп төшердем, әйдәгез тизрәк димен.

М и р в ә л и. Аннары мине тереләй таптый-таптый күмеп куясызмы? Күмеп куясыз да, син, хәер акчасына бер ярты алып саласыңмы? Кит, иблис! Син бит, ярты өчен, тудырган анаңны сатасың.

Н у р г а л и. Кем күмсен сине? Кемгә кирәк син?

М и р в ә л и. Күмми, җир өстендә калдырмассыз бит инде.

Н у р г а л и. Тыңлап бетер. Калганы минем эш.

М и р в ә л и. Калганы минем эш. Юк, син аңлатып сөйлә.

Н у р г а л и. Сине күтәреп алып кайтабыз, җыелышып юабыз.

М и р в ә л и. Юарга син оста...

Н у р г а л и. Кәфенгә урыйбыз, зыяратка алып китәбез дигәндә...

М и р в ә л и. Аңладым. Мин торып утырам.

Н у р г а л и. Нигә?

М и р в ә л и. Авыл халкы белән саубуллашырга.

Н у р г а л и. Тинтәк! Зыяратка алып китәбез дигәндә, мин хәйлә табып, синең янга җыелган халыкны урамга чакырып чыгарам. Син кәфенлектән чыгасың да, үзең урыныңа мендәрме, ягъни берәр иске чикмәнме саласың.

М и р в ә л и. Ә үземне кая куям?

Н у р г а л и. Син әллә *(үз чигәсенә төртеп)*, мондыйрак инде? Үзең чоланнан абзарга качасың.

М и р в ә л и. Аннары йорт иясе, бичура кебек, лапаста, абзарда сарыклар арасында яшиммe? Мин бит печән ашап яши алмыйм.

Н у р г а л и *(халыкка, тамашачыга карап)*. Кешеләр арасында сарык булып яшәгәнче, үз ишләрең арасында яшәвең хәерлерәк. (Мирвәлигә) Юк инде. Караңгы төшкәч, минем мунчага күчәсең. Берәр ай шунда яшәп, сакалмыек үстереп, башка киемнәр киеп, көннәрдән бер көнне мосафир, алла кешесе, йә булмаса җен булып авылга кайтып төшәсең.

М и р в ә л и. Кызык бит бу, ахир. Ә мине танысалар?

Н у р г а л и. Кем танысын. Үлгән кеше кайтамыни, тинтәк?

М и р в ә л и. Тавышымны бераз үзгәртермен.

Н у р г а л и. Кирәкми. Нигә үзгәртергә. Соңыннан уен узгач, мин чын Мирвәли дисәң дә авыл халкын ышандыралмый азапланырсың әле.

М и р в ә л и. Кызык, кызык. Ә ялгышып, чынлап күмеп куйсалар?!

Н у р г а л и. Кем күмсен, аңлатып торам ләбаса.

М и р в ә л и. Әгәр чынлап күмә башласалар, сикерәм дә торам! Шулай бит, ахир?

Н у р г а л и. Анысы кирәкмәс.

М и р в ә л и. Нигә, бигрәк кызык була.

Н у р г а л и. Булыр кызык. Синең аркада бөтен җыелган халыкны күмәргә туры килер.

М и р в ә л и. Мәүлиханның йөрәге шартлар иде, ә? Ха-ха-ха...! Мин риза!

Н у р г а л и. Риза булгач, билендәге бавыңны муеныңа сал да, теге келәткә чап. Ә мин авылга...

М и р в ә л и. Тукта әле, ахир. Син бит мине юабыз дидең?! Юганга кытыгым килмәс микән?

Н у р г а л и. Килмәс. Оҗмахта яшисең килсә, түзәрсең!

М и р в ә л и. Түзәрсен?! Заһидә минем кайсы җирдән кытыгым килгәнен белә ул. Ярый алайса, мине

юганда Заһидәне кертмәгез.

Н у р г а л и. Ярый, кертмәбез.

М и р в ә л и. Тукта әле, Нургали туган. Әллә нигә күнел тулып, жылыйсы килеп китте. Үлгәндә ямансу була икән. Кара әле, ахир, әгәр мине ялгышып күмеп куйсалар, теге аракыга дип алган бурычынны Заһидәгә кертеп бирерсен, йәме?!

Н у р г а л и. Ярар, ярар, кертермен!

М и р в ә л и. Хәзер аракы кыйммәтләнде, хәзерге бәясе белән кертерсен, йәме?

Н у р г а л и. Ярар, ярар, хәзерге бәясе белән кертермен.

М и р в ә л и. Онытa күрмә, ярыймы?

Н у р г а л и. Ярар инде, ярар. Үлгәч сина нәрсә, керттем ни дә, кертмәдем ни.

М и р в ә л и. Алай димә, кешедән аласым булса, тынычлап яталмыйм.

Н у р г а л и. Ярар, ярар, кертермен. *(Халыкка, тамашачыга.)* Бакыр акча корты!

М и р в ә л и. Карале кем, Нургали, тукта әле, ашыкма! Безнекеләрне саграк уят! Мәүлихан бажай, шатлыгыннан, эчке ыштаны белән йөгереп килмәсен, авыл халкы алдында оятлы итәр үземне.

Н у р г а л и. Ярый, саграк уятырмын. *(Чыгып йөгерә башлый.)*

М и р в ә л и. Туктале! Кеше күмәргә дигәндә бөтен дөньяны онытасын. Кабаланма! Заһидә апан хәернен артыгын бирмәс ул. Саранлыгы Аллага шөкер. Үземә охшамаган.

Н у р г а л и. Тагын нәрсә инде?!

М и р в ә л и. Мунчада очрашкач, хәер акчаларын үземә кайтарырсын, йәме?

Н у р г а л и. Да...

М и р в ә л и. Да түгел, Нургали кордый, Заһидә акчасы минем акча, минем акча Заһидә акчасы булыр ул. Килештек, алайса?!

Н у р г а л и. Килештек!

М и р в ә л и. Мә бишне! *(Кулын суза.)*

Н у р г а л и. Мә! *(кулын суза.)* Ун булсын!

М и р в ә л и, Н у р г а л и. - Эшләребез уң булсын!

*(Музыка астында ут сүнә.)*

Ут янганда Мирвәлиләрнен өй эче. Стенадагы сурәтләргә ак чүпрәк капланган. Сәгатьнең телен туктатканнар. Бүлмәнен уртасына башын кыйблага каратып Мирвәлине салганнар, анының өстендә юрган. Мирвәлине әйләндереп, Гөлдания, Нургали, Мәүлихан Ханович, Мөзәйнә әби, баш очындарак Фәсхетдин мулла утыра. Барысынын да кулында тәсбих. Хатын-кызлар башларына яулык, ирләр түбәтәй кигәннәр.

А в т о р д а н  и с к ә р м ә: Юрган астындагы Мирвәлинең кулында микрофон булу шарт.

М ә ү л и х а н  Х а н о в и ч. Әйбәт кеше иде мәрхүм. Урыны жәннәттә булсын. Нинди генә эшкә алынмасын, үз эшен намус белән башкара иде. Төннәрен колхоз каралтыларын барлап чыга торган гадәтем бар. Амбарга кайчан барма, арлы-бирле ул йөри торган иде.

М и р в ә л и *(жайлабрак ята).* Бигрәк катыга салдылар.

М ө з ә й н ә  ә б и. Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла, мәет селкенде түгелме?

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Жәмәгать, мәет хак сүзгә әйләнеп ятыр, ди китап.

М ө з ә й н ә  ә б и. Әстәгъфирулла, әллә картая башладым инде. Ходайнын рәхмәте, күпме мәетләр саклап, беренче тапкыр мондый хәлгә очравым.

Н у р г а л и. Йокламаунын галәмәте, Мөзәйнә әби. Яшен дә бар. Бар, чыгып башынны мендәргә төртеп тор.

М и р в ә л и. Минем янга ятып тор, Мөзәйнә әби. Монда иркен.

М ө з ә й н ә  ә б и *(арт санын урындыктан күтәреп, мәеткә сузыла).* Ә? Нәрсә дисен?

Н у р г а л и *(ана көлеп, уз мангаена ике бармагы белән мөгез ясап).* Мө! *(Халыкка)* Чукрак, ди!

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Нишлисен син энем, Нургали? Нишләп олы кешене тик торганда үртисен?

Н у р г а л и. Юк, үлгән кеше белән сөйләшеп утырам бит. Мине таный микән дип тикшереп карамакчы идем.

М ө з ә й н ә  ә б и. Игътибар итмә, Фәсхетдин. Нургали һәрвакыт шук булды инде ул.

М ә ү л и х а н  Х а н о в и ч. Үзе китте дә барды, колхозны ятим итте. Аны алмаштырырга кемне табарбыз?

М и р в ә л и. Сине! Репетиция ясый башладын бит инде. Утыр, утыр мине саклап, мин рәхәтләнеп йоклыйм. *(Селкенеп куя.)*

Н у р г а л и *(тамашачыга карап).* Мәлгунь Мирвәли, тик кенә ят! Башны бетерәсен!

М и р в ә л и. Табан асты кычыта, кашы әле?!

Н у р г а л и. Кара әле, мулла абзый, мәрхүмнең аягы жайсызрак яткан кебек, жайлап куйсаң ярыйдыр...?

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Ярый, ярый, кем, энем Нургали. Китап жайлап куйганга каршы түгел.

Н у р г а л и, *(Мирвәлинен аягын тегеләргә күрсәтмичә генә кашый. Аннары, пышылдап).* Булдымы?

М и р в ә л и. Уң аягымны кашы, имгәк!

М ө з ә й ә н ә  ә б и. Әләй, әләй, карагыз әле, мәет селкенә.

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Син нәрсә инде, Мөзәйәнә, алмашына башладыңмы әллә?!

М и р в ә л и. Алмашынырсың, 24 сәгатькә якын какъ тактада ятып кара.

М ө з ә й ә н ә  ә б и. Мин каты итеп чәй эчеп керим әле. *(Чыгып китә.)*

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Изге кешене юып кәфенгә салгач, жайлабрак ятыр, ди китап.

М и р в ә л и. Жайлабрак! Бик рәхәт булса, үзең ятып кара! Ястык салалар аны, Пыскый Фәсхетдин.

З а һ и д ә. Күпме яшәп, тырнагы белән дә чирткәне булмады мәрхүмнең. *(Елый.)*

Г ө л д а н и я. Берәр әйберем жимерелсә, гел шуна керә идем. Хәзер кемгә барырмын?

М и р в ә л и. Мактамагыз, хәзер жылап жибәрәм!

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Әләй, әләй, нишли ул? Селкенде түгелме?

Н у р г а л и. Син нәрсә инде мулла абзый?! Үзең Алла кешесе, Ходайга каршы килеп утырасың? Жаны чыгып очкандыр.

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Юк, кем, энем Нургали, аның жаны амбардагы келәттә үк гәүдәсеннән чыккан инде.

Н у р г а л и. Син беләсен инде, мулла абзый.

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Беләм, беләм, Нургали энем.

Н у р г а л и (тамашачыга). Беләсең әбиеннең келәсен!

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Хәзер аның жаны, гәүдәсе янында очып йөрер, ди китап. Кырык көнгә кадәр өйгә кайтып йөри ул жан.

Н у р г а л и. Менә бит нәрсәләр сөйли ул изге китап. Ишеттенме, Мәүлихан Ханович?! Кырык көнгә кадәр өенә кайтып йөрер диме?

М ә ү л и х а н  Х а н о в и ч. Кит аннан. Кырык көнгә кадәр диген, ә, мулла абзый?

М и р в ә л и. Кырык көннән сакалмыек үстереп, үзе кайтыр ди.

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Юк, үзе кайтмый. Үзе үлгән була бит инде.

М ә ү л и х а н  Х а н о в и ч. Син нәрсә инде, Фәсхетдин абзый, үзең белән үзең сөйләшеп утырасың. Соң без беребез дә ул кадәр дивана түгел, үлгән кешенең кайтмаганын гына беләбез.

Ф ә с х е т д и н  м у л л а *(аптырап).* Нигә, кайсыгыздыр сорады түгелме соң?

Н у р г а л и. Картаясың, олыгаясың, мулла абзый.

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Колагыма шулай ишетелде. Булмаса, һавага чыгып керим әле. *(Чыга башлый, Мирвәлинең аягы янына житкәч, Мирвәли аны тибеп жибәрә. Мулла - алдында утырган Гөлданияне кочаклап ала.)*

М и р в ә л и. Бар, карт ишәк, кеше алдап йөрмә!

Г ө л д а н и я. Нишләвең бу, Фәсхетдин абзый, килешмәгәнне. Үзең дин юлында йөргән буласың, үзең... Элек парторг чагында дояркаларның капшамаган жирен калдырмый торган идең, һаман да шул оятсызлыгыңны ташламагансың.

Ф ә с х е т д и н  м у л л а *(артка утырган Мәүлиханга озак кына карап тора да).* Дурак син, энем Мәүлихан. Олы кешене мыскыл итеп утырма!

М ә ү л и х а н  Х а н о в и ч. Кем әле сине мыскыл иткән?!

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Син! Именно менә син! Нигә тибәсең минем арт саныма?!

М ә ү л и х а н  Х а н о в и ч. Әллә котыра башладыңмы?!

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Син булмыйча, үлгән Мирвәли типкәндер шул!

М ә ү л и х а н  Х а н о в и ч. Хатын-кыз күргәч, кулларыңны тик тоталмаганыңны барыбыз да беләбез, мулла абзый.

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Сөйләп кенә торма, сине белмиләр! Син життең Мирвәлинең башына, Заһидәсе белән типтереп.

М ә ү л и х а н  Х а н о в и ч. Ә, шулаймыни?! Тоттыңмы?! Юк, син әйт, тоттыңмы?! Мин сине судка бирәм! Ах син, сволочь! *(Бугазыннан эләктереп ала.)*

Ф ә с х е т д и н  м у л л а *(таягы белән кизәнә).* Мин карап

торырмынмы? Менә бу таяк белән башынны тишәрмен!

Мирвәли. Нургали, мулла абзыйга хәер бир әле, тынычлана ул.

Нургали. Җәмәгать! Мәет өстендә тавыш күтәрүне китап яратмый.

Фәсхетдин мулла. Бирерсен син мине судка! Синен урлаганнарынны, кем-кем, мин белми идем. *(Чыгып киткәндә Мөзәйәнә белән ишек төбендә очраша.)*

Мөзәйәнә. Фәсхетдин, комганда җылы су бар. *(Җайлап кереп утыра.)* Кара әле, кызым Заһидә, Мирвәли мәрхүм сөннәтле идеме?

Заһидә. Анын сөннәте белән нишлисен? Кияүгә чыгарга уйламыйсындыр бит?!

Мөзәйәнә әби. Абау, нишләгәннәр болар?

Гөлдания. Сөннәтле иде, сөннәтле...

Заһидә *(Гөлданиягә карап).* Кит аннан! Каян беләсен?

Гөлдания. Нигә, Мирвәлинен каршысына утырып булмый иде бит. Юньле, рәтле ыштан кигәне булмады.

Фәсхетдин мулла *(килеп керә).* Нургали энем, бар, зиратка барып кил. Кабер әзер булса, ясин чыгарбыз да, мәрхүмне өйләгә кадәр җир куенына урнаштырырбыз.

Нургали. Хәзер, хәзер белешәм, мулла абзый. *(Чыгып китә.)*

Фәсхетдин мулла *(жайлап утыра, куен кесәсеннән китеп чыгара. Анын янына Мөзәйәнә әби якынаеп утыра).* Йәә сиин. Вәлкурьәнил хәкиим. Иннәкә ләминәл мурсәмин. Галәә сыйраатыйм мустәкыйм. Тәнзиләл газиизиррахим. Литунзира каумәм мәәәэ унзира зәбәәәьуһим фәһүм гаафилүүн. Ләкаду хәккаль каулу гәләә әксәриһим фәһум ләә йуьнинүүн. Иннәә җәгәлнәә фишин әгнәәкыйһим әгъләәлән фаһия иләл әзказни фәһум лукьмәхүүн.

Мөзәйәнә әби *(муллага төртеп ала, пышылдап).* Ялгыштын, мулла абзый, Фәсхетдин.

Фәсхетдин мулла *(пышылдап).* Тик тор, букән, хәере бутән. Иннәмәәәэ әмраһүүү изәәә әраадә шәйьән әййәкуулә ләһүү күн фәйәәкүү фәсубухәәнәлләзин биййдиһим мәләкүту кулли шәйьнү вә иләйһи тәрҗәгүүн. Амин!

Барысы бергә. Амин!

Фәсхетдин мулла. Ярый, мөәмин мөселман мөслим, мөслимәләр. Мәрхүмне калдырып торыйк. Мәрхүм янында якын туган тумачалары гына калсын. *(Мөзәйәнә әби, Фәсхетдин мулла, Нургали, Мәүлихан чыга башлыйлар.)*

Нургали. Нигә, син калмыйсынмыни, Мәүлихан Ханович?

Мәүлихан Ханович. Нигә калыйм. Мин бит анын туганы түгел. *(Чыгып китәләр.)*

Заһидә *(үксеп елый).* Әй, Мирвәликәем, Мирвәликәем, бәгырь кисәгем. Зинһар, рәнҗеп китмә. Хуш! Бәхил бул!

Мирвәли. Пока.

Гөлдания. Әйдә, әхир, үз-үзенне бетермә. Бер алкаш үлгәннән дөнья җимерелмәс. Дөньяда ирләр бетмәгән. Әнә, минем мәрхүмнен үләненә биш былтыр, бер ятып төшемә дә кергәне юк. Тегенен белән рәхәтләнеп яшәрсен. Бүген иртә белән, төялеп, хатыны китеп барды.

Мирвәли. Алла боерсанны онытма.

Гөлдания. Әйдә, әйдә чыгабыз. *(Чыгып китә.)*

Мәүлихан Ханович *(килеп керә).* Ярый, хуш, Мирвәли туган.

Мирвәли. Пока, бажай! Янадан очрашканга кадәр.

Мәүлихан Ханович *(Заһидәгә).* Әйдә, үз-үзенне бетермә, чыгабыз.

Заһидә. Жылаган булыйм инде. Авыл халкыннан яхшы түгел бит.

Мирвәли. Биегән чакларын да булыр әле.

Мәүлихан Ханович. Минем хатын китте. Кудым үзен. Кырыгы гына үтсен, бергә яши башлыйбыз.

Нургали *(ишектән башын тыгып).* Заһидә, Мәүлихан иптәш, чыгыгыз әле, мулла абзый чакыра. *(Икесе дә чыгып китәләр.)*

Мирвәли. Нургали, Нургали кордаш! Нургали мөртәт, чыгып беттеләрме әле?

Нургали *(ишектән башын тыга).* Беттеләр! Кабаланма! Тиз генә кермиләр. Мулла абзыйнын сәдакасы өй алды иданенен ярыгына төшеп китте. Шуны алалмый азаплана. *(Ишекне яба.)*

Мирвәли *(торып утыра).* Ирек бирсән, чын-чынлап күмеп куярлар. Валлаһи күмәләр. Ярый әле, үлеп карадым. Кайчан әле бу кадәр матур сүзләр ишетер идем. Үзем белмәгән яхшылыкларым да бар икән. Уф, суткадан артык какъ тактада ятып, үзем тактага әйләнә яздым. Өстәвенә арт

саным юеш. Бөтен кайгым - идәнгә акмаса ярар иде дип курыктым. *(Күзе стенадагы сәгатькә төшә.)* Вәт, Мирвәли туган, 1997 елның 7 нче январенда 13 сәгать 15 минут 13 секундта дөньядан китеп бардың. *(Тормакчы була.)* Әстәгъфирулла! Вәт сволочьлар, трусикка кадәр салдырганнар. Оятлы булуынны көт тә тор. *(Простыняга уранып торып баса. Үз урынына мендәр салмакчы була.)* Юк, мендәр җинел булыр. Тукта әле... *(Мич арасына кереп китә дә, аркасына капчык күтәреп чыга. Капчыкны үз урынына сала.)* Шикәре жалко. Ярты еллык хезмәт хакы өчен биргәннәр иде. *(Капчыкны әйбәтләп каплый да, мич арасына кереп югала. Бераздан булмәгә кешеләр керә.)*

Мәүлихан Ханович. Хөрмәтлебез Мирвәли туган. Син безнен колхозыбызның иң хөрмәтле кешесе иден.

Мирвәли *(мич артыннан)*. Рәхмәт!

Мәүлихан Ханович *(Фәсхетдин муллага)*. Хәер биргәч, рәхмәт әйтерсен!

Фәсхетдин мулла. Кем әле синнән хәер сорый?!

Мәүлихан Ханович. Синен колхозга керткән өлешең һәрвакыт колхозчыларыбыз күнелендә тирән сакланыр.

Мирвәли *(мич артыннан)*. Рәхмәт!

Нургали. Нишлисен, Миркәй, теленне тый!

Мирвәли. Мактыйлар бит, түзеп булмый.

Мәүлихан Ханович *(Фәсхетдин муллага)*. Життеме сина, юкмы? Чабата кайтарып торасын.

Фәсхетдин мулла. Нигә булышасын минем белән?

Заһидә, Гөлдания. Житте инде сина, Мәүлихан Ханович, рәнҗетмә инде өлкән кешене.

Мәүлихан Ханович. Сүз саен минем әйткәнне жөпләп бармасын. Рәхмәт тә рәхмәт, рәхмәт тә рәхмәт! Фикеремне чуалтма!

Фәсхетдин мулла. Мәетегезне ташлыйм да кайтып китәм! Теләсә нишләгез! Хәерегезне дә алып тормыйм!

Заһидә *(Фәсхетдин мулланың уч төбенә хәер сала)*. Мә, мулла абзый.

Фәсхетдин мулла. Бисмиллаһир-рәхмаанир-рахим! Вәссәләме галәйкүм вә рәхматулләһи вә бәрәкәтүү...

Мәүлихан Ханович. Нишлисен син?!

Фәсхетдин мулла. Нигә, син әйтеп бетермәденмени? Хәер бирә башладылар бит, укыйм.

Мәүлихан Ханович. Тинтәк! Авыр туфрагын җинел булсын, изге иптәшебез...

Фәсхетдин мулла. Минем өчен кайгырма. Үзеннеке жинел булсын!

Заһидә. Мирвәликәем, рәнжеп китмә, бәхил бул.

Мөзәйәнә әби. Мирвәли энем, Гәрафетдин бабана сәлам әйт.

Мирвәли. Әбиен утырмага киле, диярмен.

Фәсхетдин мулла. Ярый, мөслимәләр, сез чыгып торыгыз. *(Чыгып китәләр.)* Мәетне аягы белән ишектән чыгара башласак та ярыйдыр. *(Мирвәли мич арасыннан чыгып, ишеккә бармакчы була.)*

Нургали *(туктата)*. Кая барасың, имгәк!

Мирвәли. Нигә? Мулла абзый аягы белән чыксын диде бит.

Нургали. Сина әйтми бит ул, тинтәк! *(Төртеп мич арасына кертеп жибәрә. Җыелган халыкка)* Әйдәгез, җәмәгать! *(Мәүлихан Ханович, Нургали, Фәсхетдин мулла мәетне күтәрә башлыйлар, простыняга уранган Мирвәли мич арасыннан чыга да булыша башлый.)*

Нургали. Мирвәй дурак, нишләп йөрисен, дивана!

Мирвәли. Сезгә булышам! Үзегезгә генә авыр бит. Анда алагаем бер капчык шикәр!

Нургали. Күземнән югал, тинтәк!

Мирвәли. Ярый алайса, жайлабрак күтәрегез. Ялгыш төшереп жибәреп, муенымны сындырмагыз!

Фәсхетдин мулла *(Нургалигә)*. Кем иде ул синен янында?

Нургали. Кайда?

Фәсхетдин мулла. Синен янында, мәет янында?

Мәүлихан Ханович. Кем янында?

Фәсхетдин мулла. Нургали энекәш янында.

Мәүлихан Ханович. Менә ич мин. Мин аның янында басып торам. Әллә мине дә танымый башладынмы? Бу карт, кеше күмә-күмә тилерә, саташа башлаган ахрысы.

Нургали. Әйтәсе юк.

Фәсхетдин мулла. Кызык...

Бу мәетнең үлеме дә сәер, күмелүе дә сәер!

Мәүлихан Ханович. Әй, кем бар анда? *(Ишектән Гөлдания башын тыга.)* Чакырыгыз әле яшьләрне. Бу шәлперәйгән тиле-миле карт белән мәет күтәреп буламыни? *(Нургалигә озак кына карап торганнан соң.)* Әстәгъфирулла! Монысы алкоголик. Кулы белән бөтен гәүдәсе селкенә. Настоящий холодис.

Ут сүнә. Пәрдә ябыла. Бераздан, апак ыштаннан, яланаяк, чәче-башы тузган, күзе акайган, абына-сөртенә, ашыга-ашыга Мәүлихан Ханович пәрдә алдына килеп чыга.

Мәүлихан Ханович. Бармы бу авылда берәр кеше? Җәмәгать! Авылдашлар?! Каравыл! Үтерәләр, каравыл! Коткарыгыз, коткарыгыз! *(Тавышка Нургали килеп чыга.)*

Нургали. Нәрсә булды, Мәүлихан иптәш? Ник акырасың? Ут чыкмагандыр бит?

Мәүлихан Ханович. Ут чыгу ерунда. Дөньяда булмас хәл. *(Сәхнә алдына төрлесе-төрле яктан кешеләр чыга башлый.)*

Гөлдания. Нәрсә булган, кеше суялармы әллә?

Нургали. Юк, менә бит Мәүлихан иптәш.. Койрыгын капкага кыскан кәҗә тәкәсе кебек акыра.

Мәүлихан. Минем урынга үзегезне куеп карагыз?! Акыру гына түгел, акылдан шашарсыз.

Нургали. Кит инде, Мәүлихан иптәш, килешмәгәнне, председатель башың белән, урам уртасында бөтен авыл халкы алдында эчке ыштаннан..

Гөлдания. Нигә алай дисез, юрганы астына шөпшә кергәндер. Ха-ха-ха!

Заһидә *(мыскыллы)*. Теге чәчбие куып чыгаргандыр. Ул бит аннан уттан курыккандай курка.

Мәүлихан. Җыен дивана... Мирвәли кайткан!

Барысы бергә. Мирвәли кайткан? Ха-ха-ха! Мирвәли кайткан?

Фәсхетдин мулла *(тамашачыга карап)*. Өендә качып эчеп ятып, белая горячка башланган.

Нургали. Нәрсә, иптәш председатель, күзенә җеннәр күренә башладымы әллә?

Мәүлихан. Син үзең җен! Ышанмасагыз, әйдәгез, минем өйгә, күрмәгәнегезне күрерсез!

Мөзәйнә әби *(килеп керә)*. Нәстә булды? Әллә мина әйтмичә генә көтүче сайлыйсызмы? Быел чиратлап көтәбез. Узган ел да бер кәҗәмне суеп ашадыгыз.

Мәүлихан. Синдә көтүче кайгысы. Мирвәли теге дөньядан кайткан!

Мөзәйнә әби. Син, энем Мәүлихан, ычкына башлагансың түгелме соң? *(Мәүлихан янынарак килә дә)* Бисмилләһир-рахмәнир-рахим! *(Мирвәлинең йөзенә төкерә башлый.)*

Мәүлихан. Нишлисең, җен корткасы? Нигә мина төкерәсең!? *(Мөзәйнә әбине төртеп җибәрә.)*

Мөзәйнә әби. Абау, абау, котырган бит бу.

Мәүлихан. Син үзең котырган! Әйдәгез, ышанмасагыз үз күзегез белән күрерсез.

Фәсхетдин мулла. Мәүлихан энем, син безне авылыбыз белән диванага санама.

Мәүлихан. Ышанмыйсыз?!

Гөлдания. Тилермә, үлгән кеше кайта димени?

Мөзәйнә әби. Яшем сиксән өчтә, балалар. Шул яшемә житеп, берәүнең дә теге дөньядан кайтканын күргәнем юк әле.

Мәүлихан. Күрмәсәң күрерсең! Минем дә күргәнем юк иде.

Нургали. Туктале, Мәүлихан иптәш, нигә ул нәкъ сезгә кайткан?

Мәүлихан. Этем белсен. Каян белим мин.

Фәсхетдин мулла. Әйе! Нигә үз өенә, Заһидәсе янына кайтмаган?!

Мәүлихан. Каян белим.

Нургали. Чыннан да нигә именно сина кайткан? Мина да түгел, Фәсхетдин абзыйга да түгел, бүтәнгә дә кайтмаган, именно сина кайткан?! Син нәрсә, аның братымы? Син бит аңа ни брат, ни сват? Нәрсә, берәр бүлешәлмәгән әйберегез бар идемени?

Заһидә *(Мәүлиханга пышылдап)*. Бар инде, адәм көлдереп йөрмә, кайтып йокла. Женләнә башлагансың бит, дивана! *(Җыелган халыкка.)* Бүген генә, Мирвәликәемнең каберендә булдым. Кабере күпереп тора. *(Күз төпләрен сөртеп ала.)* Бармак төртерлек урыны юк, бал кортлары сырып алган.

Нургали. Бал корты?...

Фәсхетдин мулла. Изгеләр рәтендә булгандыр Мирвәли. Бал корты—оҗмах корты, ди китап.

Н у р г а л и. Булыр, булыр, мулла абзый. Синең китап әйтсә, хак әйтә инде ул. Бал корты кунса, балга куна да, шикәргә куна инде ул.

Ф ә с х е т д и н   м у л л а. Бар, энем Мәүлихан, кайт та бисмилланы әйтеп йокларга ят.

М ә ү л и х а н. Юк, мин ул өйгә кайтмыйм!

Г ө л д а н и я. Нигә кайтмыйсың?

М ә ү л и х а н. Куркам.

З а һ и д ә. Кемнән куркасың?

М ә ү л и х а н. Мирвәлидән!

Г ө л д а н и я. Нигә, хатының Сылу өйдә юкмыни?

Н у р г а л и. Мирвәли үлгән көнне үк куып җибәрде бит ул аны.

М ө з ә й ә н ә   ә б и. Бар, энем Мәүлихан, өенә кайт, тәһарәтеңне янарт, бисмилланы әйтеп, ятып йокла...

М ә ү л и х а н. Алла бәндәләре, кайтмыйм мин ул өйгә. Сез миңа ышанмыйсыз инде. Кая Корьәнегез, Корьән тотып ант итәм. Менә шушы күзләрем белән күрдем. Атам-анам рухы белән ант итәм.

Эштән кайттым, ишекне ачып кердем, юындым, ашадым-эчтем, урын җәйдем дә, ишекне бикләп, утны сүндереп йокларга яттым. Бераздан ишек шыгырдап ачыла башлады. Кем бар анда димен? Дәшми. Тыңлап ятам, аяк тавышы... Кем бар димен? Дәшми. Өстәл янындагы урындык шакылдады. Юрган астына кереп постым. Кемдер мыш-мыш килә. Курка-курка гына башымны юрган астыннан чыгардым да, баш очымдагы лампочканы яндырып җибәрүем булды, ни күзем белән күрим, өстәл артында Мирвәли утыра. Кулында мөгез!

Н у р г а л и. Мөгез?

М ә ү л и х а н. Әйе, мөгез! Син кем дип сорыйм. Мирвәли, ди. Мирвәли үлде, без аны күмдек, дим. Ә мин теге дөньядан кайттым, ди. Нигә?—мин әйтәм. Сина мөгез кайтардым, ди. Астым жылынып киткәндәй булды. Кулым белән астымны капшап карыйм, тәһарәтем бозылган. Урынымнан сикереп тормаммы? Башта тәрәзәгә атылдым, тәрәзәгә сыймагач, ишеккә. Ишек келәсе шартлап өзелде, ә мин урамга чыгып очтым. Аныма килсәм, бирелә басып торам. Менә ышанмасагыз тотып карагыз, тәһарәтем бозылган. Менә, менә, мулла абзый.

М ө з ә й ә н ә   ә б и. Гөлдания, тотып карагыз, юешме? Юеш!

Ф ә с х е т д и н   м у л л а. Туктале кем, Мәүлихан энем. Кайткач ишегеңне ачып кердеңме? Йозак бар идеме?

М ә ү л и х а н. Ат башы кадәр йозакны менә шушы кулларым белән ике тапкыр борып ачып кердем, Фәсхетдин абзый.

З а һ и д ә. Тәрәзәләрегез ачык түгел идеме?

М ә ү л и х а н. Ничек ачык булсын! Тәрәзәләр бит ике катлы, эчтәгеләре ачылмый.

М ө з ә й ә н ә   ә б и. Мич юшкәгезне карадыңмы? Ябык идеме?

Н у р г а л и. Син бигрәк инде Мөзәйәнә әби, Мирвәли мичтән керәлми торгандыр инде.

М ө з ә й ә н ә   ә б и. Ә бәлки ул Мирвәли түгел, Мирвәли кыяфәтендәге җендер!

Ф ә с х е т д и н   м у л л а. Энем Мәүлихан, ак белән кызылны бутамаган иденме?

М ә ү л и х а н. Ә нигә!

Ф ә с х е т д и н   м у л л а. Юк, болай гына...

Н у р г а л и. Үземнән чыгып әйтәм диген, Фәсхетдин абзый.

Ф ә с х е т д и н   м у л л а. Ходай тәгаләне оныттыгыз, балалар. Өйләрегезгә Корьән укытмыйсыз. Бозылды халык, бозылды...

М ө з ә й ә н ә   ә б и. Ата—улны, ана—кызны белми.

З а һ и д ә. Бар, бар, Мәүлихан, күзенә генә күренгәндер, кайт.

М ә ү л и х а н *(ыштанын тотып)*. Ә бу нәрсә? Ярый, минем күземә генә күренгән ди, ә бу нәрсә? Мә, тотып кара. Юешме? Юеш!

Н у р г а л и. Юеш кенә булса, бер хәл...

М ә ү л и х а н. Шулай булгач! Мирвәли юк ди. Ә тәһарәт кая киткән? Туктагыз? Шым! *(Барысы да тынып калалар.)*

Б а р ы с ы   б е р г ә. Фу...

Н у р г а л и. Вәт! Доказательство!

Г ө л д а н и я. Җәмәгать! Авылдашлар! Ни генә әйтсәгез дә, Мәүлихан Ханович авылыбызның дәрәҗәле кешесе, хуҗасы. Кызганырга кирәк үзен. Бергәләп озатып куярга кирәк.

М ә ү л и х а н. Юк, мин анда кайтмыйм. Әйтеп торам бит мин сезгә, куркам дип.

Н у р г а л и. Бәлки, Заһидәләргә кайтырсың? Ул ялгыз, өендә иркен.

З а һ и д ә. Әйе, тагын нәрсә?

М ә ү л и х а н. Сеңлем Заһидә,

кайтыйм сезгә генә?

З а һ и д ә *(пышылдап, Мәүлиханга).* Ап-ак ыштаннарыңны урам буйлап жилфердәтә-жилфердәтә, сасыган йомырка исләре чыгара-чыгара минем белән кайтыр иде бугай, юк. *(Җыелган халыкка.)* Юк, авылдашлар, булмый. Килешмәгәнне. Иремнең үлгәненә кырыгы тулмаган. Үз өендә күзенә Мирвәли күренгәнне, Мирвәли өендә аның күзенә Мирвәлинең җиденче бабасы күренәчәк. Чит ир ияртеп кайтырга сез мине кемгә саныйсыз, ходай кушмаганны?

М ә ү л и х а н. Фәсхетдин абзый, сезгә генә кайтыйм?

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Бик алып кайтыр идем дә, карчыгым сырхаулап тора шул.

Г ө л д а н и я *(Заһидәгә пышылдап).* Әллә соң үземә алып кайтыйммы, ахир?

З а һ и д ә *(пышылдап).* Җүләрләнмә, исе соң, исе...

Г ө л д а н и я *(Заһидәгә, пышылдап).* Нигә, таска салып юсаң, менә дигән ир була әле бу. *(Җыелган халыкка.)* Үземә генә алып кайтыр идем дә, тараканнар агулаган идем шул.

Н у р г а л и. Ялгышма, Гөлдания, ныклап уйла, мондый ир чүплектә аунап ятмый.

Г ө л д а н и я. Анысы шулаен шулай... Тик...

М ө з ә й ә н ә  ә б и. Бу инде килде-китте кәрәвник төзергә килгән әрмәннәр түгел.

З а һ и д ә. Акыл өйрәтмә, Мөзәйәнә әби. Бик акыллы булсаң, үзенә алып кайт.

М ө з ә й ә н ә  ә б и. Кара моны. Кара әле боларны. Элек, бөтен авыллары белән олы капкаларын ачып, кулларын сузып, авыз суларын киптереп, Мәүлихан Ханович, Мәүлихан Ханович безгә сугылыгыз, чәйләп алырбыз дип торган кешеләр, председательләре җүләрләнгәч, берсенә дә кирәкми. Минем белән, сиксән өч яшьлек кортка белән нишләсен ул. Минем өемә егерме биш ел ир-атның аяк басканы юк. Минем белән җенләнү генә түгел, котырып үлә ул.

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Соң алайса, җәмәгать, бергәләп үзен озатып куйыйк.

Г ө л д а н и я. Ерак ара түгел, озатыйк.

З а һ и д ә. Ни генә әйтсәгез дә үз сөягебез.

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Урам уртасында калдырып булмый бит инде.

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Әйдәгез, җәмәгать *(тезелешеп чыга башлыйлар. Иң алга Мәүлихан баса.).* Кара әле, кем, Мәүлихан. Син минем арттанрак бар әле.

Н у р г а л и. *(Мәүлиханны артка этә.)* Артка, артка! Иң артка.

М ә ү л и х а н. Нигә?

Н у р г а л и. Нигә, нигә? Күрмисеңмени, җил каршы исә.

*(Тезелешеп чыгып китәләр. Ут сүнә.)*

## Икенче пәрдә

Пәрдә ачылганда караңгылык. Тик Мәүлиханның өенә керә торган бизәкле баскыч кына яктыртылмаган. Сәхнәнең калган өлешендә, караңгылыкта Мәүлиханның бик иркен һәм бай җиһазландырылган өе эче. Өскә киң баскыч менеп киткән, ишек төбендә мич. Уртада өстәл. Алгы планда күпереп торган диван. Шомлы музыка. Нургали, Мөзәйәнә әби, Фәсхетдин мулла һәм калганнар тезелешеп баскыч янына чыгалар.

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Менә, кем энем Мәүлихан, кайтып та життек. Бар инде, бисмилланы әйтеп, уң аягың белән кереп кит.

М ә ү л и х а н. Юк, мулла абзый, үзем генә кермим. Куркам мин.

Н у р г а л и. Синең өенә мин кермәм бит инде.

З а һ и д ә. Мулла абзый, ни генә әйтсәң дә, син Ходай илчесе, Алла кешесе, җеннәрнең телен беләсең, булмаса үзең генә кер?!

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Бик керер идем дә, тәһарәтем бозылып китте шул.

М ө з ә й ә н ә  ә б и. Җен янына кергәндә тәһарәт нигә?

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Каршы сугылыр димен, кем кортка, тәһарәтсез йөрү кичләрен ярамый, ди китап. Керсәң син керерсең инде, Мөзәйәнә карчык. Безнең арабызда бердәнбер тәһарәтле кеше син.

М ө з ә й ә н ә  ә б и. Килешмәгәнне сөйләп торма әле, кем, мулла Фәсхетдин. Синнән узып керәмме соң, Алла сакласын. Гөнаһысын кая куярмын.

Фәсхетдин мулла. Юк, син ашын ашаган, яшен яшәгән, жылап калырлык яшь балаларың юк. Бар, бар, кер. Мин сина фатихамны бирәм.

Мөзәйәнә әби. Юк, хәзрәт, анда барырга ашыкмыйм әле. Синең фатихасыз да бу дөньяда калдырмаслар үземне. Аннары минем икеле-микеле күзләрем белән ул йортка кереп адашыргамы?!

Мәулихан. Нургали иптәш, безнең авылда синнән дә зирәк, синнән дә тәвәккәл кеше юк, куркак булсаң каравылда торалмас идең, бар, егетлегеңне күрсәт.

Заһидә. Мирвәлинең авылда ин якын иткән кешесе син идең, Нургали.

Нургали. Анысы шулай. Ул үзе дә мине көтеп арыгандыр инде.

Фәсхетдин мулла. Шулай булгач.

Нургали *(Тамашачыга карап).* Үләсе килми карт ишәкнең! *(Фәсхетдин муллага.)* Миңа гына риза булыр микән. Мин бит әле яшь. Аңа картрак кеше кирәктер инде ул.

Мөзәйәнә әби. Карт кеше..? Як-ягына төкер, энем.

Фәсхетдин мулла *(тамашачыга карап).* Тәһарәтсез иблис, мине кертеп котыласы килә боларның. *(Кесәсеннән кукиш күрсәтеп.)* Менә сезгә!

Гөлдания. Бар инде, бар, Нургали. Синнән дә кулай кеше юк.

Нургали. Мине зурлап, чиратсыз кертәсез инде.

Фәсхетдин мулла. Синең кайда, кайчан, нәрсәгә чират торганың бар. Син бит безнең авылда гел беренче.

Нургали. Беренче дисез инде. Бик керер идем дә, шүрләтә бит. Дус— дус инде ул. Дус, женгә өйләнгәч, дуслыкны онытып муен тамырына тартмас микән?

Мәулихан. Бар инде, катып үләм бит.

Нургали. Хәзер берәр стакан булсын иде, ике дә уйламас идем.

Мәулихан. Өйгә кергәч, бер литр итеп бирермен.

Нургали. Бер литр? Алдамыйсыңмы? Сүзеңдә торасыңмы?!

Мәулихан. Торам инде, торам!

Нургали. Ярый инде алайса, керәм!

Фәсхетдин мулла. Жылап калырга бала-чагаң юк.

Нургали. Анысы дөрес, Фәсхетдин абзый, менә шушы

**«КАЗАН УТЛАРЫ»НА 80 ЕЛ**

**«QAZAN UTLARI»NA 80 YIL**


## Васил Гайфуллин,

*Татар дәүләт гуманитар институты ректоры, академик*


## МИЛЛӘТ БӨТЕНЛЕГЕН КАЙГЫРТУЧЫ ЖУРНАЛ



*«Казан утлары» журналы белән мин (әле ул чагында «Совет әдәбияты») 1951 елда, Минзәлә педагогия училищесында укыган елларымда ук таныштым. Инде менә 40 елдан бирле яраткан журналымның бер генә санын да югалтмыйча, туплап-жыйнап барам. Әллә кайчан укылган саннарын да эзләп табып, кызыксынып, кайта-кайта укыйм.*

*Соңгы вакытта урыс сәясәтендә татар халкын бүлгәләргә, таркатырга тырышу сизелә. «Казан утлары»н татар «башкорт»ы да, Сергач мишәре дә, Питрәч керәшене дә, Себер татары да укый. Димәк, журнал аларда: «бербөтен милләт булып яшәгәндә генә бүгенгедәй буталчык заманда исән-имин калу мөмкин»,–дигән хисне ныгыта, үзара берләштерә. Чит төбәкләрдә, чит илләрдә яшәүче татарларыбыз турында, аларның көнкүреше, гореф-гадәтләре, яшәү рәвеше хакында да күләмле әсәрләр укыйсы килә. Бу жәһәттән, Себердә яшәп ижат итүче өлкән әдибебез Якуб Зәнкиевнең «Өтелгән мәхәббәт» романы миндә зур*

кыршылып беткән бишмәтемнән гайре бернәрсәм дә юк.

Ф ә с х е т д и н м у л л а. Шулай булгач...

Н у р г а л и. Сезнең кебек байлык кала дип куркасы юк. Бар тапканымны дуслар белән уртага салып яшәдем. Алай-болай булсам, жирләрсез инде?!

М ә ү л и х а н. Борчылма, колхоз чутыннан жирләрбез. *(Нургали баскычка менеп китә.)*

Ф ә с х е т д и н м у л л а. Бисмиллаһир-рахмәнир-рахим! Вәссәләме галәй...

Н у р г а л и. Кирәкми, мулла абзый, кирәкми. Бенең Мирвәли белән генә белә торган үз догабыз бар. *(Аягын бөкләп, намазлыктагы кебек, ике кулын ияк астына куеп баскычка утыра.)* Син Мирвәли, мин Нургали, сак бул, аң бул. Син Мирвәли, мин Нургали, синең хозурына мин керәм. Аң бул, сак бул! Бер гәләфиле фәкыйреңне кабул ит?! Йә Алла, үземнең язмышымны жан ахирәт дустым, кордашым Муллагали углы, Мирвәли кулына тапшырам. Шушы догам кабул булып, Мәүлиханның бер литрын кабул итеп, сина да, мина да төннәр буе жәннәттә яшәргә насыйп ит. Амин.

Б а р ы с ы д а. Амин.

Н у р г а л и. Тәвәккәллим. *(Кереп китә. Бераздан чыга.)* Керегез!

Барысы бергә. Ә Мирвәли?

Н у р г а л и. Мәрхүм Мирвәлигә Мәүлихан өендә шымытыр калсын димени?

Ф ә с х е т д и н м у л л а. Ха-ха-ха. Әйттем бит күзенә күренгән диеп. Әйдәгез, жәмәгать, керегез. *(Барысы да өйгә керәләр. Мирвәли мич артыннан кулын чыгарып, Мөзәйнә әбинең арт санын чеметеп ала.)*

М ө з ә й н ә ә б и. Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла, нишләвең бу, кем, мулла Фәсхетдин?

Ф ә с х е т д и н м у л л а. Нигә? Ни булды, Мөзәйнә?

М ө з ә й н ә ә б и. Ни булды, ни булды, жен булды! Минем арт санымны чеметкәнче, әнә яшьрәкләрнекен чемет!

Ф ә с х е т д и н м у л л а. Әллә котырасың инде. Як-ягыңа төкер, кем кортка. Бик кирәгең бар иде.

М ө з ә й н ә ә б и. Гомер буе хатын-кыз капшаудан туймасаң да туймассың икән, иблис!

Ф ә с х е т д и н м у л л а *(алга китә башлый. Мирвәли мич арасыннан чыга да, аны төртеп жибәрә. Фәсхетдин*

*кызыксыну уятты. Житди прозадан тыш, әдәби тәнкыйть мәкаләләрен көтеп алам. Соңгы вакытта юмор-сатираның кимүе генә бераз күңелгә тия. Югыйсә, журнал юморын уку бик күңелле эш.*

*Яңа төр мәктәпләр хакында да саллы мәкаләләр укыйсы килә. Журнал инициативасы белән төрле фәнни конференцияләр оештырылганда да шәп булыр иде.*

*«Казан утлары» бүген бик зур йөкне: ижтимагый, сәяси, әдәби, тарихи, мәдәни, фәлсәфи йөкне тартып бара торган колачлы матбага. Ул яшь әдипләр өчен дә үсеш-көрәш мәйданы булып тора.*

*Хәзер байтак кына татар мәктәпләре, гимназияләре, лицейлары ачыла. Аларның асылы нидән гыйбарәт, исеме жисеменә туры киләме-юкмы? Бүген татар телен мәктәпләргә кертү мәсьәләсенә үзеннән-үзе бара торган (алай гына түгел ул!) нәрсә дип караучылар күбәйде. Шул хакта да журналда үткен язмалар күрәсе килә.*

*«Казан утлары» –гасырга якын нәшер ителү дәверендә татар жәмәгатьчелегенең аерылгысыз бер мөһим институтына әверелде. Журнал белән танышу-өйрәнү гамәлен мәктәп программасына, хәтта кайбер югары уку йортлары программасына да кертәсе иде.*

*мулла башта алга сөрлегә, аннары борылып таягы белән Нургалинең сыртына менеп төшә).* Төртермен мин сиңа, алкаш. Ипи шүрлегенә менеп төшкәнне сизми дә калырсың.

Н у р г а л и. Нишлисең мулла абзый? Минмени ул? Ул бит Мирвәли!

Ф ә с х е т д и н м у л л а. Каравылда ята-ята җенләнеп беткәнсең. Нәрсә, эчә-эчә күзеңә Мирвәли күренә башладымени? Мә, тагын бирәрне! *(Таягы белән кизәнә.)*

Н у р г а л и. Җитте сиңа, Мирвәй, башны тиштерәсең бит.

Б а р ы с ы б е р г ә. Мирвәй? Ха-ха-ха! Мирвәй - Мирвәй диме?

Ф ә с х е т д и н м у л л а. Авылыгыз белән җенләнеп беткәнсез инде.

З а һ и д ә. Җитте инде сезгә. Уеныгыз уен түгел... Син йокларга яттым дигән идең, кая соң ул синең яткан урының?

М ә ү л и х а н. Менә. Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла, кемдер җыештырган...

Н у р г а л и. Мирвәли-җен җыештырып чыгып киткәндер.

М ө з ә й ә н ә ә б и. Җыештырыр сиңа җен. Җен өермәсен күргәнегез юкмыни? Юлындагы бар нәрсәне туздырып бетерә. Җенле өй болай булмый ул.

Ф ә с х е т д и н м у л л а. Дөрес, җен юлындагы бөтен нәрсәне туздырып үтә, ди китап.

М ә ү л и х а н. Туктагыз әле, җәмәгать! *(Дивандагы юрган астына кулын тыгып карый.)* Юеш! Менә юешме, юеш! Тотып кара, мулла абзый.

Ф ә с х е т д и н м у л л а. Юеш дип инде, энем, кем Мәүлихан, синең бәлки электән үк юешли торган гадәтең бардыр?

З а һ и д ә. Юк, юк, аның андый гадәте юк.

Н у р г а л и. Кит аннан, син каян беләсең?

З а һ и д ә. Юк, теге ни... Хатынының, Сылуның сөйләгәне бар иде.

Н у р г а л и. Шулайдыр. Син бит аның хатыны Сылу белән бик дуслар идегез. Күптән түгел генә кибет буенда чәчкә-чәч ябышып сабан туе үткәреп ята идегез бугай.

Ф ә с х е т д и н м у л л а. Эчүеңне киметергә кирәк, энем Мәүлихан, эчүеңне. Мирвәлине җирләгәндә үк шикләнгән идем мин синнән. Тик торганда үзенең атаңнан да өлкән кешенең арт санына китереп типтең бит син.

М ә ү л и х а н. Синең генә арт саныңа тибәләр дә, сине генә төртәләр. Мәчет салырга килгән үзбәкләрдән алып калган анашаңны азрак тартырга кирәк.

Ф ә с х е т д и н м у л л а. Син иблисне җәлләп, кызганып килгән булам. Эчкече. Хәсис. Котырып үл шушы клуб кадәрле өеңдә. Юньле булсаң хатының ташлап качмас иде сине. Колхоз малын сатып эчә-эчә, тилерә башлагансың. Сез диваналар белән олы башымны кече итеп вакытымны әрәм иткән мин дивана. Йөрим карт ишәк төсле, тәмле йокымны калдырып. Берсенә илле җитеп акыл кермәгән, ә икенчесенең кергән акылы да чыга башлаган. Чәнчелеп китегез сана! *(Чыгарга дип өстәл янына якыная, арттарак басып торган Мәүлихан, куркып, кинәт мулла өстенә сикерә.)*

Ф ә с х е т д и н м у л л а. Нишлисең, нишлисең, дивана! Тотыгыз, тотыгыз үзен. Үтерә! Үтерә! Коткарыгыз! Ычкына башлады бит. *(Икесе дә идәнгә егылалар. Фәсхетдин мулла таягы белән Мәүлиханны кыйный башлый.)*

М ә ү л и х а н. Мулла абзый, мулла абзый, гафу ит! Куркудан. *(Елап җибәрә.)* Мулла абзый, Фәсхетдин абзыкай, өстәлгә кара әле?! Нәрсә ул? *(Барысы да өстәлгә карыйлар, өстәл өстендә мөгез күреп, катып калалар.)*

Ф ә с х е т д и н м у л л а *(Саклык белән өстәлгә якыная. Таягы белән мөгезне әйләндереп карый. Гаҗәпләнеп).* Мөгез!?

Б а р ы с ы б е р г ә. Мөгез!?

Ф ә с х е т д и н м у л л а. Әйе, мөгез!

Б а р ы с ы б е р г ә. Нәрсә мөгезе?!

М ө з ә й ә н ә ә б и *(курка-курка гына мөгезгә якыная да, озак кына гаҗәпләнеп карап торганнан соң).* Тьфү, тьфү! Бисмиллаһир-рахманир-раһим. Бәрәкалла, бәрәкалла, бу мөгез, бу мөгез, ягъни мәсәлән, минем узган ел көтүдә югалган кәҗәмнең мөгезенә охшаган, фаразан!

Б а р ы с ы б е р г ә. Кәҗә мөгезе?

Н у р г а л и. Кәҗә мөгезе?! *(Кулына алып, әйләндереп карап тора да, мөгезне Мәүлиханның маңгаена куеп карый.)* Юк, җәмәгать, бу кәҗә мөгезенә охшамаган. Кәҗәнең мөгезе икәү була.

Ә бу бераү. Бу мөгезнең астында, ягъни мәсәлән, нинди дә булса хикмәт ята.

Фәсхетдин мулла *(тамашачыга).* Исән чакта кайтып котылырга кирәк. Минем чормадагы кәжә мөгезләре дә чыга башлады.

Мәүлихан. Әйтеп торам бит мин сезгә, Мирвәлине күрдем дип. Нишләп кайттың дигәч, сиңа мөгез куярга, диде.

Фәсхетдин мулла. Ярый, авылдашлар, мин кайтыйм әле. Карчыгым бик сырхау, үзе генә курка торгандыр.

Мөзәйәнә әби. Фәсхетдин, тукта, бергә кайтабыз. *(Мәүлиханга.)* Әй, оятсыз, оятсыз, жир бит! Кәжәмне суеп ашагансың да, мыскыл итәр өчен бөтен авылны җыеп мине мәсхәрә итәргә чакыргансың. Тамагыңа тыгылсын, бирән!

Фәсхетдин мулла. Шаштың син, егет! Карт-корының арт санына тибеп, колхоз малын сатуы гына житмәгән, хәзер авыл халкының малларына кул сала башладыңмы?! Үлгәч авыл зиратына да күмдермибез без сине, иблисне! *(Мөзәйәнә әби белән чыгып китәләр.)*

Заһидә *(тамашачыга).* Бу диваналар белән йөреп, күзгә мөгезләр күренә башлады. Исән чакта таярга кирәк.

Гөлдания. Әйдә, ахир, кайтыйк. Авыл халкы болай да үзебезгә әллә нинди нахак бәлаләр тагып бетерде, уйламасыннар, дүртәүләшеп уйнаш итеп яталар дип. *(Чыгып китәләр.)*

Нургали. Ярый. Мәүлихан Ханович, мин дә кузгалыйм инде.

Мәүлихан. Китмә, китмә, Нургали туган. Бу авылда синнән дә яхшы күңелле кеше юк.

Нургали. Эш бит, Мәүлихан әфәнде, эш! Каравыл! Болай да бик озакладым.

Мәүлихан. Чукынып кына китсен каравылың.

Нургали. Алай димә, председатель усал, прямо зверь! Күрмәгәнемне күрсәтер.

Мәүлихан. Китмә, жаным? Зинһар мине үземне генә ташлама?

Нургали. Булдыра алмыйм, Мәүлихан Ханович, намусым кушмый. Эш! Ничего не поделаешь, эш! Кая теге бер литрыңны монда тык та, гәләфи кигән военныйлар кебек, ике корчаңгы тайны сакларга постка китим. Ә син курыкма. Жен—жен инде ул, шушы бер литрга ияреп, минем белән китәр ул.

Мәүлихан. Әнә теге диван астыннан ал.

Нургали *(Диван астыннан бер литрны алып, чалбар кесәләренә тыга).* Менә гәләфиле дә булдык. Чин арта. Ә син курыкма. Жённәр алар тимертомырдан курка. Янына пычак сал, балта кертеп куй. Мин үзем баш очына арба күчәре, яныма кендек салам. Аннары жённәр—сүгенгәннән куркалар. Аты-юлы белән сүгенеп менеп ят, иртәнгә кадәр рәхәтләнеп изрәп йокларсың. Мин каравылда гел шулай эшлим.

Мәүлихан. Тукта алайса, бераз гына сабыр ит. *(Баскычтан өскә менеп китә.)*

Мирвәли *(мич арасыннан чыгып).* Ярый, мин кәнүшнигә элдертәм. *(Чыгып китә.)*

Мәүлихан *(килеп керә. Башына кастрюль кигән. Бер кулында пычак, икенчесендә балта, күкрәгенә кастрюль капкачы аскан).* Ярыймы?

Нургали. Настоящий рыцарь! Кәнүшнигә килсән, ат та бирәм. Хәзер йокла!

Мәүлихан. Юк, йокларга куркам. Йә төнлә белән йоклап киткәч, матчага асар.

Нургали. Ярый, иптәш председатель, мин теге флангың саклыйм, ә син бу флангыны сакла. *(Кесәсендәге шешәгә төртеп.)* Хәзер шартлатабыз жённәрне! *(Чыгып китә.)*

Мәүлихан бүлмә буйлап арлы-бирле йөри башлый. Музыка. Ут сүнә. Ут янганда таң сызылып килә. Мәүлихан өенең өске бүлмәсенә менә торган баскычында, балтасын кочаклап, йоклап утыра. Башында кастрюль.

Мирвәли *(килеп керә дә, йомшак кына басып Мәүлиханның кулындагы балтасын ала, кулы белән кастрюльгә шакый).* Можномы?

Мәүлихан *(сискәнеп уянып китә).* Жен! Үтерәләр! Жен, жен! Коткарыгыз!

Мирвәли. Акырма! Балта түтәсе белән маңгаеңа бер генә тартырмын, жилегең атылып чыгар!

Мәүлихан. Кем син?

Мирвәли. Күрмисеңмени, Мирвәли ич.

Мәүлихан. Юк, син Мирвәли түгел, Мирвәлине күмдек. Син—жен!

Мирвәли. Мин Мирвәли, теге

дөньядан командировкага кайттым.

М ә ү л и х а н. Командировкага!?

М и р в ә л и. Әйе, командировкага! Аллаһы Тәгаләнең приказы белән сиңа мөгез кайтардым.

М ә ү л и х а н. Миңа мөгез...?!

М и р в ә л и. Әйе, Сезнең ике күз арасына, менә монда, мангай уртасына *(бармагы белән төртеп)* мөгез куярбыз!

М ә ү л и х а н. Ни өчен именно миңа?

М и р в ә л и. Аллаһы Тәгалә галиҗәнапләренең әмере шундый. Бу авылга, Аллаһы Тәгалә тарафыннан бары бер мөгез бирелеп, һәм дә ки, ул мөгезне, Анабыз Һәувә, атабыз Адәмнән яралып, җиргә сынау шарты белән җибәрелгән мөэмин мөселман Минлехан, мөэмин мөслимә Бибигайшә углы, мөэмин мөселман Минлемәүлиханга җир йөзендә кылган гөнаһларын кичерү шарты белән, ул аны сезгә, ике аяклы хәйвани затка җибәрә. Һәм дә ки ул аны шушы елның 15 гыйнварында, шомырт чәчәк атканда, 13 сәгать 15 минут 13 секундта үз янына, оҗмахка кабул итә.

М ә ү л и х а н. Бөтенләйгәме?

М и р в ә л и. Сәвсимгә!

М ә ү л и х а н. Мөгез..? Кызык.. Нәрсә, мин теге дөньяда, оҗмахта кәҗә тәкәсе буламмыни?

М и р в ә л и. Юк! Кәҗә тәкәсе Ходай Тәгалә тарафыннан ике мөгезле итеп яратылган. Ә син бер мөгезле! Син урман сарыгы буласың!

М ә ү л и х а н. Нигә сине җибәрде соң ул, юньлерәк кеше тапмадымыни?

М и р в ә л и. Мөгезне мөгезле кеше генә куярга тиеш.

М ә ү л и х а н *(Тамашачыга)*. Кызык, мин бу бәндәдә мөгез күрмим! *(Мирвәлигә.)* Мин аңлап бетермәдем, сезнең исемегез һаман да Мирвәлиме соң? Сез анда нindирәк урын алып торасыз?

М и р в ә л и. Юк, мина оҗмахта Аллаһы Тәгалә яңа исем кушты. Мин хәзер Әбугали-Салимали-Миннегали-Гаптелкадый-Җаббарый-Шыттыргали, Аллаһы Тәгаләнең уң кулы, ягъни илчесе, мөгез министры булам!

М ә ү л и х а н. Ә... Али... мали... Гали... сали... Кем әле?

М и р в ә л и. Әбугали-Салимали-Миңнегали-Гаптелкадый-Җаббарый-Шыттыргали!

М ә ү л и х а н. Минем дә исемне үзгәртерләр микән?

М и р в ә л и. Үзгәртербез! Син Минлемөгезле-Хам-Мәүлихан булырсың!

М ә ү л и х а н. Шәп! Үзе озын, үзе матур, тагын кабатлагыз әле.

М и р в ә л и. Минлемөгезле-Хам-Мәүлихан!

М ә ү л и х а н. Хам... Мәүлихан... Менә шул хам дигәнен үзгәртеп булмасмы?

М и р в ә л и. Булмас! Хан—теге дөньяда Хам!

М ә ү л и х а н. Мин аңлап җиткермәдем, Ходай илчесе. Ничегрәк инде ул мөгез? Шул, сез өстәлдә калдырган мөгезме?

М и р в ә л и. Юк! Ул сиңа куеласы мөгезнең макеты!

М ә ү л и х а н. Ә шулаймыни? Аны ничегрәк куялар?

М и р в ә л и. Мөгезне куяр өчен, сезнең хәзерге вакытта дөньялыкта никах белән хәләл җефетегез булып саналган хатыныгыз, мөэмин мөселман Минлесадрый кызы Минсылуның ярдәме кирәк булачак.

М ә ү л и х а н. Анысы начаррак икән. Зәһидә белән генә куеп булмасмы?

М и р в ә л и. Булмас! Мөгезне бит сезгә куябыз!

М ә ү л и х а н. Карышып маташкан булыр әле ул, Сылу тәре!

М и р в ә л и. Анысы синең эш! Үзең өчен кирәк!

М ә ү л и х а н. Кайчанрак ясый башларсыз микән ул мөгезне?

М и р в ә л и. Ашыкмагыз, Аллаһы Тәгаләбез тарафыннан җиргә ике күзле, ике аяклы итеп яратылган хайваный зат, Минлемөгезле-Хам-Мәүлихан, мөгезсез калдырмам!

М ә ү л и х а н. Ходайның рәхмәте яусын үзенә, олуг вә киң күңелле Ходай илчесе! Куйганда бик авыртмас микән?

М и р в ә л и. Авыртмас! Куйганын белгәч, караңгы төндә, ай, йолдызларга карап, җир тырматып елатыр.

М ә ү л и х а н. Җәннәт дигәндә, анысына гына түзәрбез. Аннары мөгез дигәнегез күренеп, мангайны ямьсезләп тормасмы?

М и р в ә л и. Менә минем мөгез ничегрәк соң?!

М ә ү л и х а н. Ә мин сезнен маңгаегызда мөгез күрмим.

М и р в ә л и. Минем мөгез менә монда, йөрәктә!

М ә ү л и х а н. Кызык, йөрәккә дә мөгез куялар диген.

М и р в ә л и. Куялар! Үзенә куйгач

күрерсен. Мөгезне теләсә кем күрә алмый! Куйган кеше дә, сам Аллаһы Тәгалә генә күрә һәм белә. Аннары миннән әмер шул: бу киемнәренне салып, иске-москы киемнәр табып ки!

Мәүлихан. Нигә?

Мирвәли *(пышылдап, өскә түшәмгә төртеп күрсәтеп).* Байларны яратмый.

Мәүлихан. Байларны яратмый диген, ә? Яндырам, бөтен шифоньеры белән өеп яндырам.

Мирвәли. Яндырма! Авылыгыздагы берәр сәрхүшкә бир! Кисен! Ул барыбер ожмахка эләкмәячәк! Аның өчен бу дөнья ожмах.

Мәүлихан. Ха-ха-ха-ха! Нургали исерек башка бирәм. Рәхәтләнсен киеп, дивана баш, исерек тәре!

Мирвәли. Хәерчеме?

Мәүлихан. Кигән ыштаныннан, каткан бишмәтеннән гайре бернәрсәсе дә юк.

Мирвәли. Бик дөрес эшлисен!

Мәүлихан. Шулай итим әле. Яхшы киенеп, тәмугта янсын мәлгунь!

Мирвәли. Кара әле, мөгез дигәннән, бал, май, тәм-том кирәк булыр. Синен 150 мең акчаң бармы? Булса, бүген төнгә кибеттән шуларын алып куй!

Мәүлихан. Булмаган кая, менә моннан! Муеннан! Хәзер йөгерәм.

Мирвәли. Юк, сиңа өеңнән чыгарга ярамый. Берәрсен җибәр!

Мәүлихан. Кемне җибәрим микән? Заһидәне җибәрсәм генә инде.

Мирвәли. Хатын-кыз алган әйберләр мөгез ясарга ярамый! Мөгез ясар алдыннан сый-хөрмәтне ир кеше, ир-ат ала!

Мәүлихан. Кемне җибәрим икән?

Мирвәли. Нургалине җибәр!

Мәүлихан. Кит, дивана, кайтмый ул. Кулына акча керсә, көт Нургалине...

Мирвәли. Кайта. Ана мин боерачакмын, Ходай илчесе!

Мәүлихан. Ярый алайса, Нургалине җибәрәм.

Мирвәли. Бик дөрес эшлисен! Шуны җибәр! Онытканчы шуны әйтәм, берәр коньяк белән шампунь да алсын!

Мәүлихан. Нигә, мөгезгә шампунь да кушасызмыни? Сабын гына ярамыймыни?

Мирвәли. Шампуньнен исе тәмле була.

Мәүлихан. Әнә, әнә үзе үтеп бара Нургали. Чакырыймы?

Мирвәли. Чакыр!

Мәүлихан. Син кач!

Мирвәли. Ул мине күрми!

Мәүлихан. Ничек күрми?

Мирвәли. Мин синең генә күзенә күренәм.

Мәүлихан. Тавышынны да ишетмиме?

Мирвәли. Ишетми.

Мәүлихан. Кызык... *(Тәрәзә форточкасын ача да.)* Әй, Нургали, Нургали кер әле?

Нургали *(тавышы ишетелә).* Әллә бармы?

Мәүлихан. Кер әле, кер тизрәк!

Нургали *(килеп керә).* Нәрсә булды, әллә салып бирәсеңме?

Мәүлихан. Кибеткә барып кайт әле!

Нургали. Нигә?

Мәүлихан. Мөгез ясарга бал белән май алып кайт! Берәр коньяк белән шампунь да алырсын?

Нургали. Нинди мөгез?

Мәүлихан. Әнә күрәсенме? *(Мирвәлине төртеп күрсәтә.)*

Нургали. Нәрсәне?

Мәүлихан. Диванда утырган кешене?

Нургали. Диванда мендәрдән гайре бернәрсә дә, беркем дә юк ләбаса!

Мәүлихан. Алла илчесен, миңа мөгез куярга килгән Әбугали-Сәлимали-Гәптелкадый-Җаббарый-Шыттыргалине күрмисеңме?

Нургали. Кичә әллә артыграк салган иденме?

Мәүлихан. Нәрсә сөйләгән була, тәмуг кисәве.

Мирвәли. Әйтеп торам бит мин сиңа, ул мине күрми дә, ишетми дә диеп.

Нургали. Юк, мин диванда утырган кешене күрмим.

Мәүлихан. Сиңа тагын Алла илчесен күрергә. Мә 300 мең, здачасы кирәкми!

Нургали *(акчаны ала).* Карале, бер шампунь белән бер коньяк кына җитәр микән, уйлат ул башынны, кичә дә җитми калды, Мирвәй!

Мәүлихан. Кем белән сөйләшәсен син?

Нургали. Синең белән.

Мәүлихан. Мин Мирвәй түгел, надан!

Нургали. Беләм, син Мәүлихан.

Мәүлихан. Ничек кичә дә җитми калды?

Н у р г а л и. Колагыма ишетелде, әле дә колагым чыңлап тора.

М ә ү л и х а н. Ха-ха-ха. *(Бармагы белән түшәмгә күрсәтеп.)* Тегеннән минем өчен әмер бирәләр.

Н у р г а л и. Шулайдыр, өстәндер! *(Тамашачыга.)* Диваннан түгел микән, ахмак! *(Мәүлиханга.)* Ярый, мин киттем, Мәүлихан.

М ә ү л и х а н. Исемемне кыскартма! Мин хәзер, Миңлемөгезле-Хам-Мәүлихан.

Н у р г а л и. Кит аннан. Кайчан яңа исем куштың?

М ә ү л и х а н. Бүген.

Н у р г а л и. Элек «хан» идең, хәзер «хам»мыни?

М ә ү л и х а н. Син нәрсә аңлыйсың, надан? Салып ташла бу иске-москы киемнәренне. Мә, минем яңа киемнәремне ки. *(Шифоньердан өр-яңа костюм, яңа бүрек, пальто чыгара.)* Әле бер тапкыр да кигәнем юк боларны. Әнә биркалары да үзендә.

Н у р г а л и. Юк, алмыйм. Оят. Ничек инде алыйм, кеше киемен. Дивана дигәч тә, үзенә кирәк булыр әле.

М ә ү л и х а н. Кем дивана?

Н у р г а л и. Мин дивана, син акыллы.

М ә ү л и х а н. Каян беләсең?

Н у р г а л и. Беләм. Юк, мин кеше киеме кимим!

М и р в ә л и. Ал, ал, Нургали. Үз гомереңдә бер генә булса да кеше төсле кием киеп кара.

Н у р г а л и. Шулай дисеңме?

М и р в ә л и. Шулай димен.

М ә ү л и х а н. Кем белән сөйләшәсең син?

Н у р г а л и. Синең белән ич.

М и р в ә л и. Минем тавышны синеке дип уйлый ул, Миңлемөгезле-Хам-Мәүлихан.

Н у р г а л и. Ярый алайса, Мәүлихан туган, бик кыстагач, алырмын инде. *(Төенчеккә бәйләп киемнәрен ала да чыгып китә.)*

М ә ү л и х а н. Озак йөрмә! *(Ут сүнә, музыка.)*

Ут янганда Мәүлихан аякларын бөкләп, алама-сәләмә киемнән диванда утыра. Үзе мангаен уа. Бүлмәгә Заһидә белән Гөлдания килеп керәләр. Озак кына кызганулы карап торалар.

З а һ и д ә. Ни хәлләрең бар, Мәүлихан?

М ә ү л и х а н. Алланың биргәненә шөкер!

Г ө л д а н и я. Тереләсеңме инде?

М ә ү л и х а н. Мин бит чирләмим.

З а һ и д ә *(елап).* Белми инде, мескен. Үзенең алмашынганын белми.

М ә ү л и х а н. Беләм!

З а һ и д ә. Нинди ир идең бит син, Мәүлиханкаем, нинди ир идең!

Г ө л д а н и я. Сөйлисе юк, ахир. Типсә тимер өзәрдәй иде.

З а һ и д ә. Авырмыйм дигән була, мескенем.

Г ө л д а н и я. Кара син аның өс-башын гына. Каян табын бетергән бу иске-москыны?

З а һ и д ә. Мәүлиханкаем, әйдә өс-башыңны алыштырыйк? Синең бит әйбәт киемнәрең дә күп. Кая, тәти күлмәгеңне кидерим.

М ә ү л и х а н. Ярамый! Тәти күлмәкләр ярамый!

З а һ и д ә. Нигә?

М ә ү л и х а н *(өскә күрсәтеп).* Тегеләр кушмый!

З а һ и д ә. Кемнәр?

М ә ү л и х а н. Әбугали-Салимали-Гаптелкадый-Җаббарый-Шыттыргали!

Г ө л д а н и я. Күзенә күренә. Бозганнар моны, ахир, бозганнар.

З а һ и д ә. Кем бозсын аны?

Г ө л д а н и я. Кем булсын. Аның шаярган хатыннары буа буарлык. Син генә түгел.

З а һ и д ә. Шулай дисеңме?

Г ө л д а н и я. Бәлки Сылуы бозгандыр.

З а һ и д ә. Нишләп инде Сылу үз ирен үзе бозсын?!

Г ө л д а н и я. Ышанасың икән. Мина да, Заһидәгә дә булмасын дип.

З а һ и д ә. Нигә ышкыйсың ул мангаеңны, Мәүлихан?

М ә ү л и х а н. Йомшартырга.

Г ө л д а н и я. Кызартып бетергәнсең бит.

М ә ү л и х а н. Кызарсын! Йомшартырга кирәк!

З а һ и д ә. Йомшартырга?

М ә ү л и х а н. Тегеләр, өстәгеләр әйтте. Йомшак җиргә мөгез куярга җиңел була, диделәр.

М ө з ә й ә н ә ә б и *(килеп керә).* Исәнмесез, оланнар!

З а һ и д ә, Г ө л д а н и я. Безнең хәлләр, үзегез күргәнегезчә инде, Мөзәйәнә әби.

Г ө л д а н и я. Менә Мәүлиханыбыз нинди хәлгә төште.

З а һ и д ә. Күзгә күренеп бетә, күзгә күренеп. *(Елый.)*

М ө з ә й ә н ә  ә б и. Әйдәгез, бер дога. *(Өчесе дә утырып дога кылалар.)* Амин! Хәлләрең ничек, Мәүлихан энем?

М ә ү л и х а н. Ат мөгезе кебек.

М ө з ә й ә н ә  ә б и. Әстагъфирулла. Минем көнбагышларым арасына карачкы иттереп бастырып куйган иске жикетем югалган иде. Бу мескен алган икән. Хәерлегә булсын.

З а һ и д ә. Кичә көндез бакча уртасында бөтен яхшы киемнәрен өеп яндырган бит. Бөтен авылның балачагасы карап торган.

Г ө л д а н и я. Алла сакласын, өенә генә ут төртмәсен инде.

М ө з ә й ә н ә  ә б и. Башың шауламыйммы?

М ә ү л и х а н. Юк! Алланың биргәненә шөкер!

М ө з ә й ә н ә. Менә бит, җен нишләтми адәм баласын.

М ә ү л и х а н. Көнләшмәгез миннән! Үзегезгә мөгез эләкмәдемени?

Г ө л д а н и я. Бозганнар аны.

М ө з ә й ә н ә  ә б и. Үзем дә юл буена шуны уйлап килдем. Хатыны кайтмаганмы?

Г ө л д а н и я. Кайтыр! Ул бит аңа таза чагында гына, мал тапканда гына кирәк иде.

М ө з ә й ә н ә  ә б и. Тау хәтле дөнья бит, тау хәтле...

З а һ и д ә. Чукынып китсен дөньясы, нигезе каһәрле, аның белән торганчы, исерек Нургали белән торам мин дип әйтә ди Сылуы.

Г ө л д а н и я. Беренче очраган иргә тотам да кияүгә чыгам, дип әйтә, ди.

Ф ә с х е т д и н  м у л л а *(килеп керә).* Әссәламәгаләйкүм, авылдашлар!

Б а р ы с ы  б е р г ә. Вәгаләйкемәссәлам, мулла абзый!

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Йәгез, бер дога. (Барысы да кулларын йөзләренә күтәрәләр.) Агызибиллаһе имини шайтан бисмилләя иррахмаан иррәхиим. *(Пышылдап укыганнан соң)* Амин!

Б а р ы с ы  б е р г ә. Амин!

М ә ү л и х а н. Фәсхетдин абзый, укыма. Синең догаң барыбер Ходайга барып ирешми!

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Нигә ирешми?

М ә ү л и х а н. Патамушто, син иблис, кяфер, тәмуг кисәве!

Ф ә с х е т д и н  м у л л а *(тамашачыга).* Җүләр җүләрен дә, каян сизә диген. Бер йөз грамм гына тотып килгән идем. *(Мәүлиханга.)* Нишләп алай дисең кем, энем Мәүлихан?

М ә ү л и х а н. Кая маңгаеңдагы мөгезең?

М ө з ә й ә н ә  ә б и. Игътибар итмә кем, мулла, Фәсхетдин. Саташа.

Г ө л д а н и я. Күзенә күренә.

М ә ү л и х а н. Кәҗә урлап кына мөгезле булып булмый ул, мулла абзый. Мөгезне тегеннән, өстән җибәрәләр аны.

З а һ и д ә. Мулла абзый, әллә өшкереп карыйсыңмы соң?

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Игътибар итмәгез, җәмәгать, аның бер сүзе дә дөрес түгел, аны җеннәр сөйләштерә. Бөтен курыкканым, өендә ут чыгарып, мине генә яндырмасын инде. Бигрәк тәрләеп торабыз.

М ә ү л и х а н. Борчылма, Фәсхетдин абзый. Озакламый мин бөтенләйгә китәм. Курыкмыйча, рәхәтләнеп, бакча артында кәҗә суярсың.

Ф ә с х е т д и н  м у л л а *(тамашачыга).* Очлы күз! *(Мәүлиханга.)* Кая китәсең, Мәүлихан энем?

М ә ү л и х а н. Теге дөньяга, оҗмахка!

М ө з ә й ә н ә  ә б и. Китмисең әле, Мәүлихан энем, яшисең әле, яшисең.

М ә ү л и х а н. Китәм. Хәбәр китерделәр. Быелның 15 нче гыйнварында шомырт чәчәк атканда 13 сәгать 15 минут 13 секундта бөтенләйгә сезнең арагыздан китәм.

Г ө л д а н и я. Шомырт гыйнварда чәчәк атмый бит, Мәүлихан?

М ә ү л и х а н. Ата! Оҗмахта 15 нче гыйнварда ата.

М ө з ә й ә н ә  ә б и. Ходай сиздерә торгандыр.

З а һ и д ә. Мәүлиханкаем, безне, мине ташлап китәсеңмени?

М ә ү л и х а н. Кит, тәмуг кисәве, җылап утырма. Юньле булсаң Ходай илчесе Мирвәли өстеннән минем белән гулять итмәс идең син, себерке! Ярый әле вакытында Әбугали-Салимали-Гаптелкадый-Җаббарый-Шыттыргали кайтып үземне кисәтте. Синең белән тәмугта янасыларым булган икән.

Ф ә с х е т д и н *(тамашачыга).* Да, бирәүгә дә көн калмады. Асылын да ул! *(Җыелган халыкка.)* Нинди егет иде бит. Тирә-якта тиңнәр юк иде үзенә. Әле монда килгәндә Нургали кибеттән чыгып килә. Өстендә әр-яңа киемнәр,

кулында алагаем тулы ризык белән сумка. Үземә егерме биш мең хәер бирде.

М ө з ә й ә н ә ә б и. Сөйлисе юк. Көн аралаш миңа да ун мең дә, унбиш мең хәер кертә. Каян ала диген?

Г ө л д а н и я, З а һ и д ә. Айныган көне дә юк!

М ө з ә й ә н ә ә б и. Әллә мин әйтәм, кем... ни мулла Фәсхетдин, кыйнап карыйбызмы? Женнәрен кыйнап чыгарып булмас микән?

М ә ү л и х а н. Кыйнатырмын мин сезгә. Озакламый мөгез генә куйсыннар. Күрмәгәнегезне күрсәтәм әле мин сезнең. Мин сезгә элекеге председатель Мәүлихан түгел, мин озакламый мөгезле-Минлемөгезле-Хам-Мәүлихан булырмын!

Ф ә с х е т д и н м у л л а. Үзем дә шуны уйлап утырам. Нургалине чакырырга кирәк. Үзебезнен генә көч житмәс. Женле кешедә жен көче була, ди китап.

М ә ү л и х а н. Кагылып кына карагыз. Хәзер үк Әбугали-Салимали-Минлегали-Гаптелкадый-Жаббарый-Шыттыргали фәрештәне чакырам!

М ө з ә й ә н ә ә б и. Кызым, Заһидә, әллә син Нургалине чакырып киләсеңме?

З а һ и д ә (елый). Ничек Жәлләмичә кыйныйсың инде аны.

Г ө л д а н и я. Кеше ясыйм, женен куыйм дисән, жәлләп торып булмый инде, ахир! *(Кызу гына чыгып китә.)*

Ф ә с х е т д и н м у л л а. Карале, энем Мәүлихан, күзенә бирәр нәрсә күренәме?

М ә ү л и х а н. Күренә! Ә синекенә күренми. Нургалинекенә дә күренми!

Ф ә с х е т д и н м у л л а. Нәрсә күренә?

М ә ү л и х а н. Әбугали-Салимали-Минлегали-Гаптелкадый-Жаббарый-Шыттыргали күренә!

Ф ә с х е т д и н м у л л а. Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла, дилбегә буйлы исем. Ятлап бетерерлек түгел.

М ө з ә й ә н ә ә б и. Тагын нәрсәләр күренә?

М ә ү л и х а н. Үзе күренә—мөгезе күренми. *(Бүлмәгә Гөлдания белән купшы киенгән Нургали килеп керәләр.)*

Н у р г а л и. Исәнмесез авылдашлар! Заһидә, урындыкка өреп жибәр әле, тузаны булмасын. *(Бармагы белән урындыкны сыпырып карый.)* Сойдет! Әйдәгез, бер дога. *(Барысы да дога укыйлар.)*

Ф ә с х е т д и н м у л л а. Амин!

Б а р ы с ы б е р г ә. Амин!

Н у р г а л и. Мәүлихан чирлегә атап хәер өләшим әле.

Ф ә с х е т д и н м у л л а. Әле генә егерме биш мең хәер биргән идең бит, Минленургали.

Н у р г а л и. Алыгыз, ал! Әткәйнеке мал түгел, дусларныкы жәл түгел. *(Мөзәйәнә әбигә, аннары Заһидәгә, Мәүлиханга суза.)*

М ә ү л и х а н. Миңа кирәкми!

Н у р г а л и. Ал, ал! Үз көчтәнәченне ашасаң, озын гомерле булырсың! *(Аннары Гөлданиягә бирә.)*

Г ө л д а н и я. Кара әле, Нургали, тәмам күзгә күренеп баедың, малай. Каян табасың шул кадәр акчаны?

Н у р г а л и. Эшләп торам бит, күрше.

Г ө л д а н и я. Элек тә эшли идең инде.

Н у р г а л и. Элек йоклый идем мин. Менә Мирвәли үлгәч, ике кешелек кооператив ачып жибәрдек. Акча агып керә, күрше.

Г ө л д а н и я. Бүген кич кереп чык әле, үтүгем янган иде.

Н у р г а л и. Утүк ремонтлый белмим шул мин, Гөлдания. Үтүкләрне Мәүлихан әйбәт чинить итә торган иде.

Г ө л д а н и я. Әй, тиле-милегә ничек курыкмыйча үтүк ремонтлатасың инде.

Ф ә с х е т д и н м у л л а. Ярый, жәмәгать, үтүк-мүтүкләрегезне калдырып торыгыз. Менә бу баланы нишләтәбез? Әллә мин әйтәм, Нургали энем, кыйнап карыйбызмы?

Н у р г а л и. Тик торганда кешене кыйнарга мин палач түгел, миңа бер зыяны да тигәне юк, файдадан башка.

М ө з ә й ә н ә ә б и. Юк, кыйнап женнәрен куып булмас микән дибез.

Н у р г а л и. Жен?! Жен бар микән соң ул?

Ф ә с х е т д и н м у л л а. Аптыраганнан әйтәм инде.

М ө з ә й ә н ә ә б и. Нигә булмасын.

Н у р г а л и. Синен үзеннең жен күргәнең бармы соң, кем Мөзәйәнә әби?

М ө з ә й ә н ә ә б и. Күрмәсәм соң?

Н у р г а л и. Ә синең мулла абзый?

Ф ә с х е т д и н м у л л а. Юк, күргәнем юк.

Н у р г а л и. Күрмәгәч. Без үзебез җен түгел микән соң?

Ф ә с х е т д и н   м у л л а. Якгыңа төкер, энем, син нәрсә?

Н у р г а л и. Әйтегез, кайсыгызның җен күргәне бар?

Б а р ы с ы   б е р г ә. Юк, юк, күргән юк.

Н у р г а л и. Ә менә минем бар.

Ф ә с х е т д и н   м у л л а. Ха-ха-ха! Нургали энем. Алдарга синә куш инде.

Н у р г а л и. Алайса тыңлагыз. Сөйлим. Җен күргәнменме, әллә...

Г ө л д а н и я. Йә, сөйләп кара.

Н у р г а л и. Шулай бер тапкыр каравыл өендә ятам. Караңгы төшкән иде. Шыгырдап колхозның тегермән капкасы ачылып китмәсенме? Капкадан бер олы гына шәүлә дисән—шәүлә түгел, гәүдә дисән—гәүдә түгел, бер әрәк килеп чыкмасынмы?

М ө з ә й ә н ә   ә б и. Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла. Шуннан, шуннан,кем, энем Нургали?

Н у р г а л и. Аркасына алагаем зур, олы капчык аскан. Аптыраштa калдым. Кем булыр бу мин әйтәм? Күзәтә башладым. Ныклабрак карасам...

З а һ и д ә. Йә, шуннан, шуннан, ныклабрак карасаң..?

Н у р г а л и. Мулла абзый кыяфәтендәге җен!

Ф ә с х е т д и н   м у л л а. Тукта әле кем, ни, энем... Нургали, чама белән тәүлекнең кайсы вакыты инде бу?

Н у р г а л и. Чама белән кичке сигезләр тирәсе булгандыр. Нәрәт вакыты иде. Шунысын төгәл итеп әйтә алам, бөтен начальство нәрәттә иде.

Ф ә с х е т д и н   м у л л а. Булыр, булыр, энем. Әйтеп торам бит мин сезгә, җен төрле кеше кыяфәтенә керер дип. Минем нәкъ азан әйткән вакытыма туры килә, каһәр.

Н у р г а л и. Анын ин кызыгы да шунда шул, җәмәгать. Мулла абзый дисәм, мулла абзый азан сала, җендер бу, мин әйтәм. Сызгырып җибәрүем булды, җен капчыгын ыргытты да, кире якка йөгерә башлады. Капчык янына барсам...

Г ө л д а н и я. Шуннан, шуннан?

Н у р г а л и. Капчык янына барсам...

З а һ и д ә. Капчык юкка чыкканмы?

Н у р г а л и. Чыкмаган шул! Капчыкның тышында олы ике хәреф ярылып ята Х һәм Ф!

Г ө л д а н и я. Ханнанов...?!

З а һ и д ә. Фәсхетдин...?!

Ф ә с х е т д и н   м у л л а. Күрәсенме, җен адәм баласын ничек бутый. Караңгы төшкәч ферма тирәләрендә дә бик йөрергә тырышмагыз, китап шулай ди. Хәтта капчыкка да хәйлә, тамга салырга өлгергән.

М ө з ә й ә н ә   ә б и. Йә, шуннан нәрсә булып бетте?

Н у р г а л и. Җен артыннан йөгердем. Бераз барсам, сыңар галош аунап ята. Анын да эчендә Ф. Х тамгасы салынган. Менә шуннан җен юк дип кара.

М ө з ә й ә н ә   ә б и. Ә ул капчык белән галошны нишләттең?

Н у р г а л и. Күтәрдем дә туп-туры мулла абзый янына йөгердем.

Ф ә с х е т д и н   м у л л а. Туктагыз әле, туктагыз, Мәүлихан җеннәрен куыйк!

Г ө л д а н и я. Туктале, мулла абзый, тыңлап бетерик.

З а һ и д ә. Капчык дигәннән, Мирвәликәем үлгән көнне минем дә мич арасыннан бер капчык шикәрем югалды.

Н у р г а л и. Мәчеткә барсам, мәчет ишегендә ат башы кадәр йозак! Ә мөнбәрдән мулла абзыйның азан әйткән тавышы ишетелә.

М ә ү л и х а н. Йә, шуннан?

Н у р г а л и. Шуннан шул, мәчетнең баскычына утырдым. Мулла абзыйның азанын әйтеп бетерүе булды...

З а һ и д ә. Йә инде, йә, шуннан нәрсә булды?

Н у р г а л и. Илһам Шакировның «Сарман» көенә җырлап җибәрүе булды. Әле дә, бүгенгедәй хәтерлим. *(Җырлап җибәрә.)*

Сарман буйлары, ай, киң ялан,
Печәннәре җитәр бер заман шул.
Печәннәре җитәр бер заман.
Кавышулары, иркәм, бик күңелле,
Әмма аерылышу бик яман.

*(Фәсхетдин мулладан башкалар шаркылдап көләләр.)* Шушы хәлне авыл яшьләренә сөйләгән идем, чукынмышлар, яна җыр чыгарганнар. *(Җырлый.)*

Сарман буйларында ике күл бар,
Берсе Андыз, берсе Кандызлы.
Бу дөньяда ике кыенлык бар,
Берсе картлык, берсе ялгызлык.
Ферма буйларыннан кайткан чакта,
Очраттым мин авыл мулласын.
Авыл мулласы да шуны әйтте:
Чәлдереп кал фани дөньясын.

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Аның бит әле шунысы да бар, җәмәгать. Күп эчкән кешенең күзенә дә җеннәр күренүчән була. Ягъни мәсәлән, медицина теле белән әйтсәк, белая горячка! Вәт шулай, энем Нургали. Әзрәк эчәргә өйрән!

М ә ү л и х а н. Белмим, белмим. Ул мөнбәрдән кемнәр генә җырламады инде.

З а һ и д ә. Беттеме, Нургали?

Н у р г а л и. Юк шул әле, бетмәде шул әле, Заһидә! Баскычтан тордым да, озак кына уйланып торгач, саташам ахрысы дип сезнең очтан эшкә, кәнүшнигә менеп киттем. Карасам, тагын бер җен! Валлаһи, җен! Мәүлиханнарның арт капкаларыннан чыкты да, туп-туры, ап-ак ыштаннан, ак күлмәктән сезгә кереп китте. Аптырадым! Кем дип уйларга да белмәдем. Мәүлихан Ханович дисәм, төнлә сездә аңа ни калган? Җеннәр бу дип уйлап, каравыл өенә менеп киттем. Каршыма синең мәрхүм ирең, кордаш Мирвәли очрады. Күзләре яшьле, үзе ямансу иде. Күзләрен үз өенең тәрәзәсенә баккан да, дәшмитынмый, янып бетә язган тәмәкесен еш-еш суыра иде. Хәтта минем терәлеп узганымны да сизмәде. Шул төнне кордаш Мирвәлине теге җен мәңгелеккә амбар келәтенә асып китмәде микән дигән шик яши башлады үземдә.

М ә ү л и х а н. Әй, сез! *(Сикереп тора.)* Тәмуг кисәүләре! Минем өемнән, Минлемөгезле-Хам-Мәүлихан өеннән олтаннарыгызны күтәрегез! *(Кулына урындык алып кизәнмәкче була.)*

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Тотыгыз, тотыгыз үзен! Тизрәк бәйләп салыгыз. Кыйнарга кирәк аны, кыйнарга! Җеннәре котырта аны. Җеннәр, җен турында сөйләгәнне яратмый,—ди китап. *(Төрлесе төрле яклап килеп, Мәүлиханны кыйный башлыйлар.)*

Н у р г а л и *(китереп тибә.)* Монысы Мирвәли кордаш өчен! Монысы мине рәнҗеткәнең өчен!

Ф ә с х е т д и н  м у л л а *(йодрыгы белән корсагын төя).* Вакытсыз эштән куганың өчен. Очлы күз, күпне күргәнең өчен!

М ө з ә й ә н ә  ә б и. Кәҗәм, бәгырь кисәгем өчен! *(Чәчен йолкый.)*

З а һ и д ә *(битеннән сыйпый).* Тереләсең, бәгърем, мә берне! Тереләсең, алтыным, мә икене...

Г ө л д а н и я. Миңа карамыйча, Санияне яратканың өчен! *(Яңаклый.)* Миңа карамыйча, Заһидәне сөйгәнең өчен! *(Яңаклый.)*

М ә ү л и х а н. Үтерәләр, үтерәләр, коткарыгыз! Каравыл, үтерәләр! Син кая, Мирвәли туган, коткар, үтерәләр!

З а һ и д ә. Җәмәгать! Туктагыз, туктагыз, чыкты! *(Тынып калалар.)*

Г ө л д а н и я. Нәрсәсе чыкты?

З а һ и д ә. Җене чыкты.

Г ө л д а н и я. Кая?

З а һ и д ә. Әнә, мич авызыннан кереп китте дә, морҗадан чыгып качты!

М ө з ә й ә н ә  ә б и. Юшкә бикле бит?

Н у р г а л и. Чыкты, чыкты, җәмәгать! Үз күзләрем белән күрдем, ап-ак ыштаннан, ыштаны юеш иде. Чыкты да, мичкә кереп китте.

Ф ә с х е т д и н  м у л л а. Рәхмәт, авылдашлар, булдырдык! Хәзер үзен генә калдырыйк...

М ә ү л и х а н. Уф, ах, үләм... *(Өстерәлә-өстерәлә диванга менмәкче була, менә алмый.)* Мине җенле дигән булалар. Үзләре авыллары белән котырганнар! Тик торганда бер гөнаһсыз кешене кыйнап чыгып киттеләр. Уф, үләм! Алла, Алла, кабыргаларымны сындырдылар бугай. *(Музыка.)*

Ут сүнә. Мәүлихан аунап идәндә кала. Ут янганда Мәүлихан башын марля белән бәйләгән, күз төпләре каралып янган. Ыңгыраша-ыңгыраша арлы-бирле бүлмә буйлап йөри.

Кайчан тизрәк мөгезле булам да, кайчан гыйнварның унбише җитеп, шомырт чәчәк ата инде. Котылыр идем бу дөньялыктан. Юкса, шомырт чәчәге урынына, үземне чәчәк аттыралар болар! Тегесе дә кайтса кайтмады, мөгез кую бик катлаулы булды, ахрысы. Сылу, кире тәре, карышып ятадыр әле.

Н у р г а л и *(керә).* Нишләп йокламыйсың, сәгать иртәнге 4 кенә бит әле? Синең урында булсам, мин рәхәтләнеп йоклар идем.

М ә ү л и х а н. Йокларсың, бар. Бөтен тәнем ут яна.

Н у р г а л и. Янса! Өстенә ябынып ятасы юк. Йокла, дивана.

М ә ү л и х а н. Үзең йокла. Мин Әбугали-Салимали-Минлегали-Гаптелкадый-Җаббарый-Шыттыргалине көтәм.

Н у р г а л и. Кемне?

М ә ү л и х а н. Алла илчесен!

Н у р г а л и. Нигә?

М ә ү л и х а н. Мөгез куярга киткән иде.

Н у р г а л и. Аңгыра!

М ә ү л и х а н. Син үзең аңгыра, надан, мөгезсез шайтан!

Н у р г а л и. Мөгезле шайтан!

М ә ү л и х а н. Аллага шөкер! Тсс! Әнә үзе кайтты!

Н у р г а л и. Кем?

М ә ү л и х а н. Күзең чыкканмыни? Әнә бит үзе, Әбугали-Салимали-Миңлегали-Гаптелкадый-Җаббарый-Шыттыргали! *(Мирвәли килеп керә.)*

Н у р г а л и. Мин бит синең кебек тилермәгән. Минем күземә бернинди дә Сали-малилар күренми.

М ә ү л и х а н. Әнә ич ишектән керде. Ишек ачылганны да күрмисеңмени, дивана?

Н у р г а л и. Җил ачты ич аны.

М ә ү л и х а н. Әссәламәгаләйкем, Алла илчесе, Әбугали-Салимали-Миңлегали-Габтелкадый-Җаббарый-Шыттыргали? Ничегрәк, мөгез барып чыктымы?

М и р в ә л и. Таң алдыннан, көчхәл белән!

М ә ү л и х а н. Шулайдыр. Төне буе утыгыз булмады. Ике авыл арасын таптап аякларым суелып бетте, табан асларым уттай яна. Барам да тәрәзәгезне карыйм, барам да карыйм. Ишегегезне тартып карыйм, ишегегез эчтән бикле.

Н у р г а л и. Ишекләре эчтән бикле булгач, сөенеп кайтып китәсеңме?

М ә ү л и х а н. Сөенмичә. Синең өчен караңгыда, тирләп-пешеп, Алла илчесе эшләп ятсын инде, сөенмәс жирәннән сөенерсең.

М и р в ә л и. Хатыныгыз керерәк икән.

М ә ү л и х а н. Гомергә кире булды, бәдбәхет. Бер юньле эше булмады. Менә Заһидә булса...

М и р в ә л и. Кич белән үк кайта идем. Инде булды дигәндә, чәлпәрәмә китерә язды.

М ә ү л и х а н. Сылумы? Сукыр бит ул. Көн яктысында да күзлек белән көчкә күрә. Ут яндырып эшлисегез калган.

Н у р г а л и. Мөгез ясарга күз кирәкми, хис кирәк.

М ә ү л и х а н. Тик кенә утыр! Мөгез ясаган кеше кебек утырма, ахыр заман кисәве! Кара, минем мөгез үземә килешеп торамы?

Н у р г а л и. Бераз кыеграк булган.

М ә ү л и х а н. Кыек! Караңгыда үзең эшләп кара, алай бик оста булсаң! Рәхмәт сиңа, Алла илчесе! Мең, мең рәхмәт!

М и р в ә л и. Бераз гына кыеграк чыкты инде. Мөгез электр яктысыннан курка шул ул.

М ә ү л и х а н. Борчылма. Үзем гаепле! Үзем барып, керосин лампасы тотып, яктыртып торасым калган.

М и р в ә л и. Анысы ук миннән булмый инде, анысын син генә булдырасың! Ярый, әйберләремне җыям да китим.

М ә ү л и х а н. Кая? Аллаһы Тәгалә янынамы?

М и р в ә л и. Юк, синең хатының Сылу янына. Ошады ул миңа.

М ә ү л и х а н. Ә тегендә, җәннәткә кайчан кайтасың?

М и р в ә л и. Миңа мондагы җәннәт, Сылу җәннәте ныграк ошады.

Н у р г а л и. Нәрсә, Мирвәли, өйләнәсеңмени?

М и р в ә л и. Өйләнәм! Свидетелем булырсың!

Н у р г а л и. Ха-ха-ха! Димәк, туй!

М ә ү л и х а н. Нинди туй?

Н у р г а л и. Күрмисеңмени, Мирвәли Сылуга өйләнәм ди бит.

М ә ү л и х а н. Нинди Мирвәли?

Н у р г а л и. Каршыңда басып торган Мирвәли!

М ә ү л и х а н. Син аны күрәсеңме?

Н у р г а л и. Күрмичә, мин бит сукыр түгел.

М ә ү л и х а н *(Мирвәлигә)*. Син Сылу белән, миңа...

М и р в ә л и. Сиңа!

М ә ү л и х а н. Мөгез... Син бит мәет!

М и р в ә л и. Юк, мин тере!

М ә ү л и х а н. Син кабердә!

М и р в ә л и. Юк, мин бире дә!

М ә ү л и х а н. Ә кабердә?

М и р в ә л и. Капчык белән шикәр.

М ә ү л и х а н. Мич артындагымы?

М и р в ә л и. Мич артындагы.

М ә ү л и х а н. Бүген ничәсе?

М и р в ә л и. Гыйнварның унбише.

М ә ү л и х а н. Вакыт күпме?

М и р в ә л и. 13 сәгать 15 минут 13 секунд.

М ә ү л и х а н. Хушыгыз! *(Шапылдап егыла.)*

Музыка, пәрдә төшә.

1997.



## Рәниф Шәрипов

### ИЛ ЭЧЕНДӘ—ИЛ

### Өмет

Ишкәк сынгач, канлы куллар белән,
Ишәсе дә икән, ишәсе.
Ватты кяфер бәреп көймәләрне,
Югалды нур—кадер кичәсе.

Азгын, бозык дөнья бәндәләре—
Бата-калка әле йөзәбез.
«Кыйбла-яр» дип талпынабыз да бер,
Өметләрне тагын өзәбез.

Без өметсез түгел әле, Раббым,
Ярлыка син безне, якла, Син.
Әнә, кемдер, ишкәк бирәм диеп,
Суза безгә кабер тактасын...

### Такташ

Шулай, якташ,
Күп ул вак таш.
Күрәсеңме,
Олы, ак таш?
Бусы—Такташ.

Кемгәдер җан,
Кемгә гәүдә.
Мәхәббәт юк,
Бар тик сәүдә.
Бусы—«тәүбә».

---

*Рәниф ШӘРИПОВ (1950)—шагыйрь, «Тәрәзәдә ут», «Ян, учагым», «Йорт иясе», «Күк һәм Күнел йолдызлары» исемле китаплары дөнья күрде. Казанда яши.*

Кояшта да,
Ак ташта да
Бераз тап бар.
Шигъри җанны
Хыял саклар.
Бусы—«хатлар».

Дөнья—кара,
Шагыйрь—бала.
Мәхәббәт тә,
Киләчәк тә
Узып бара...
Такташ кала!

## Ил

Ил эчендә ил,
Җил себергән җир.
Җир астында ут.
Ярсып ала янар таулар—
Фәүзия, Зәки, Айдар...
Рәшит* кенә янып бетте,
Рәшит кенә инде юк.
Көле һаман да кайнар.

Көл суына, таулар тына.
Кайда сез, «яңа байлар»?
Борчымыймы сезне бер дә
Догасыз үткән айлар?

Каргыш иле,
Сагыш җире,
Кем үлә,
Кем уяна.
Көл суына...
Тик, онытма,—
Җир астында ут яна!...

## Хушлашу

Уза көннәр, уза айлар,
Гомер—газап, мизгел—алтын.
Чәчәк тоткан кулың кайнар,
Хәнҗәр тоткан кулың салкын.

Җиде тапкыр телгәләгәч,
Үз туксаның һаман туксан—
Бер генә кат үлчәр өчен,
Әзер түгел икән, юкса.

Шөкер диеп, тәүбә итеп,
Китеп барам. Җитәр инде.
Салкын кулың. Менә юлың.
Тотма мине, җибәр инде.

*Ф. Бәйрәмова, З. Зәйнуллин, А. Хәлим, Р. Әхмәтҗанов.

Тормыш кырыс. Ә син тырыш.
Карап торыйм соң ничек мин?
Сукыр белән чукрак кебек,
Син күрмисең, мин ишетмим.

Савабым юк, гаебем күп,
Үз кырыгым һаман кырык—
Мәхәббәтне кисеп була,
Ләкин булмый чагыштырып.

Шөкер итик, ирештең бит.
Китим инде. Җитәр инде.
Менә юлың, менә улың.
Тотма мине, җибәр инде.

Уза көннәр. Уза айлар.
Тормыш—газап. Мизгел—алтын.
Нинди язмыш безне сайлар?
Җан өшетеп кердә салкын...

## Яшьтәш дустым Фидәилгә

Шундый буладыр инде ул
Иллегә җиткән ир-ат—
Утырмадың кул кушырып,
Кемнәндер ярдәм сорап.

Ир белән ат яшәгәннәр
Гомер буе җигелеп.
«Ир-ат» сүзенең асылы—
Таяныч һәм игелек.

Шундый буладыр инде ул
Иллегә җиткән ир-ат,—
Укыдың, бала үстердең,
Төзедең нигез-торак.

Бакча утырттың җир сөреп,
Эштән эшкә җигелеп.
Раббым биргән һәр көнеңә
Шөкер иттең иң элек.

Җылы яңгыр, сау иминлек
Теләнеп түгел, сорап,
Калган барысын булдырдың,
Иллегә җиткән ир-ат.

Җиңелеп түгел, җигелеп,
Кылган эшең—игелек.
«Ир-ат» дисәк тә, син әле
Илле яшьлек ир-егет!

# Солтан Шәмси

# НИЗАГЛЫ ЙОРТТА

## АЛТЫН УРДА ДӘҮЛӘТЕНЕҢ ТАРКАЛУ ЧОРЫННАН СӘХИФӘЛӘР

### Сәмәрканд әмирендә

Туктамыш хан идарәсеннән канәгать булмаган төркемнең астыртын эшләре ачылу белән Идегәй мирза һәм аның тарафдарларының шактый кыен хәлдә калуын инде әйткән идек. Кызганычка күрә, бу хакта чыганакларда тулырак мәгълүматлар сакланмаган. Ләкин ул төркемдә Бикеш, Бикбулат, Тордычык-Бирде, Бахшы бәкләр, Даут мирза, Иса бәкләрнең булуы телгә алына. Әлбәттә, бу ыгы-зыгы вакытында аларның барысы да качып китми, бәлки моны кирәк тә санамаганнардыр. Арадан Идегәй мирзаның гына бик тиз эз югалтуын аның шушы эшләрне оештыручы төп фигура булуын сөйләмиме? Минемчә, нәкъ шулай. Ул юкка чыккач, Сарайда торып калган тарафдарларына хан алдында үзләрен аклар өчен бар гаепне качкан мирза өстенә аудару мөмкинлеге дә туа. Бу бит Идегәй мирзага барыбер зыян китерә алмый, чөнки ул хан кулы житә алмаслык жирдә—Сәмәрканд әмирендә.

Шулай итеп, Идегәй мирза жиһангир хозурында яши башлый. Бу хәл 1389 елда була.

Бу вакытта Сәмәрканд әмире инде, Мәвараэннәһердә үз хакимиятен күптән ныгытып, алай гына да түгел, тирә-юньдәге барлык өлкә-вилаятьләрне буйсындырып бетереп, эшчәнлегенең өченче дәверенә аяк баскан була. Икенче төрле итеп әйткәндә, бу дәвердә Тимер бәк талау максаты белән үзеннән ерак урнашкан илләрне басып алуга керешә. Идегәй аның хозурына менә шундый дәвердә килеп баса.

Дөресен әйтергә кирәк, жиһангир аны якты чырай һәм зур хөрмәт белән кабул итә. Ярдәм яки сыену урыны эзләп үз хозурына килүчеләрне ул гомере буе шулай кабул итә. Шулай ук алардан оста файдалана да белә. Бу очракта да Идегәй мирза кебек гаскәр башының дошмани мәмләкәт ханыннан качып китүе, ана килеп сыенуы аны бик нык сөендергәндер дип уйларга кирәк. Әлбәттә, ул Идегәй мирзага үз тирәсендә лаеклы урын бирә.

Лаеклы урын дигәннән, тарихчылар Тимер бәк үткәргән төрле киңәшмәләр, олуг жыеннар, корылтайлар вакытында чакырылган халыкның тәхет тирәсендә урнашу тәртибенә дә игътибар иткәннәр. Бу мәгълүматларны бергә тупласаң, шундыйрак картина күз алдына килеп баса.

Ин элек идарәнең диван дип аталган киңәшү органында туплануын билгеләп үтәргә кирәк. Бу органга атаклы руханилар, сәедләр, шәехләр, галим-голяма, олуг әмирләр, ыру-кабилә һәм гаскәр башлары, вәзирләр һ. б. күренекле кешеләр кергән. Сәркятибләр диванда тикшерелгән мәсьәләләрне, алар буенча әйтелгән фикерләрне, тәкъдимнәрне махсус дәфтәргә теркәп бара торган булганнар. Кабул ителгән карарлар, Тимер мирзаның фикерләре, тәкъдимнәре дә шунда теркәлгән.

---

Дәвамы. Башы 1—3 саннарда.

Ә урнашу тәртибе түбәндәгечә булган: тәхет тирәсенә ярымай рәвешендә, дәрәҗәсенә карап, Тимер бәкнен уллары, оныклары һәм башка туганнары урнашкан. Сәедләр, казыйлар, галим-голяма, дин әһелләре, атаклы шәехләр, түрәләр, эш башында торучы олуг затлар уң кулда урын алган. Гаскәр башлары, әмирләр сул кулда утырганнар. Диван башы, вәзирләр—тәхеткә каршы урнашкан, алар артында аерым олыс идарәчеләре урын алган.

Яуларда зур гайрәт күрсәткән баһадирлар һәм кыюлыгы, батырлыгы белән танылган яугирләр тәхет артында уң кулда, ә җинел гаскәр башлары сул кулда урнашкан. Маңгай чиру башы да (авангард) шулай ук тәхет каршында урын алган, ә сарай саклаучылар башы чатырның ишек төбендә торган.

Моннан тыш кинәшмә яисә корылтай вакытында берәр үтенеч белән мөрәҗәгать итәргә теләүчеләр яисә дөрес хөкем чыгаруны сораучылар тәхетнең як-ягына урнаша торган булганнар.

Махсус билгеләнгән дүрт кеше җыен барышында тәртипне күзәткән.

Чакырылучылар урнашып беткәннән соң төрледән-төрле сыйлардан 1000 табагы халыкка, 1000 табагы диван әгъзаларына, 500 табагы Тимер мирза исеменнән ыру һәм урда тоткан әмирләргә, гаскәр башларына җибәрелгән. Сыйларны тапшырганда хөрмәт йөзеннән һәрберсенең исеме кычкырып әйтелә торган булган.

Төркиләр белән монголларда хөкем сөргән мондый гадәтләргә XIX йөз тарихчысы, генерал М. И. Иванин да игътибар иткән. Нәтиҗә рәвешендә ул менә нинди сүзләр әйтә: «... подобный же церемониал наблюдался при курултаях, приеме посольств и других торжественных случаях и был общий во всех ханствах, управлявщихся потомками Чингиз хана. А от ханов Золотой Орды некоторые придворные обычаи перешли и ко двору московских князей» *(М. И. Иванин. О военном искусстве и завоеваниях монголо-татар и среднеазиатских народов при Чингиз хане и Тамерлане.—СПб.,—1875.—С. 129—237).*

Әйе, Сарай каласында да шундый ук йола, тәртипләр хөкем сөргән. Елдан-ел матурая, төзекләнә барган Тимер бәк мәмләкәте башкаласы Сәмәркандта да аларны тиешенчә үтәргә, дәүләтнең данын-шөһрәтен күтәрергә тырышканнар. Гомумән, Тимер бәк заманында калалар торгызуга, зиннәтле биналар салуга, җимеш бакчалары утыртуга, сугару каналлары төзүгә зур игътибар бирелгән. Ә инде уңышлы яулар китергән табыш һәм хәзинәләр, бер яктан, гаскәрне зурайту, тагын да яхшырак коралландыруга тотылса, икенче яктан, калаларны төзекләндерү, зиннәтле биналар, сарайлар төзүгә, кала диварларын ныгытуга киткән. Әлбәттә, яуларда талап алынган байлыкларның төп өлеше Тимер бәк сарае урнашкан Сәмәрканд шәһәренә алып кайтылган. Бу кала, җиһангир уенча, дөньяда беренче кала дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш булган. Шушы ниятен тормышка ашыру җәһәтеннән Тимер бәк башкала тирәсенә мөселман илләрендәге төп шәһәрләрнең исемен йөрткән бистәләр салдыра башлый—шулай Сәмәрканд тирәсендә Багдад, Димәшкъ, Мисыр, Шираз, Солтания кебек авыл-бистәләр үсеп чыга. Ә җиһангир сарае урнашкан гүзәл бакча, хуҗа үзе яуларда чакта, халыкның күңел ачу урынына әверелә.

Тимер бәкнен дин әһелләренә карата булган мөнәсәбәте үзе бер кызыклы мәсьәлә. Аның заманында яшәгән тарихчылар җиһангирнын дин әһелләрен, галим-голяманы, сәедләрне, шәехләрне бик хөрмәт итүен күрсәтеп үтәләр. Җитди мәсьәләләрне хәл иткәндә ул гел акыл ияләренең фикерен сорый торган булган. Ә инде кыен хәлдә калганда, гел Коръән Кәримне ачтырган, берәр карар кабул иткәндә килеп чыккан аятьнең мәгънәсенә колак салырга яраткан. Аның Автобиографиясендә дә без моны еш очратабыз. Гомумән, Тимер бәк сәясәт мәйданына чыккан көннәреннән үк сәедләр, дин әһелләре белән тыгыз элемтә урнаштырырга тырыша. Атасы Тарагай бәк үлгәннән соң мәрхүмгә якын булган шәех Шәмсетдин Күләл аның да якын киңәшчесенә әверелә, күп хаталардан саклап кала.

1370 елда, әмир Хөсәен белән барган көрәшнең иң кызган чагында, Тимер бәк янына ерак Мәккә шәһәреннән Бәрәкә исемле бер сәед килә. Бу әле Бәлх каласын басып алганчы ук була. Сәед аңа хакимият билгесе саналган барабан белән байрак тапшыра һәм алдагы тормышында бөек казанышлар вәгъдә итә. Шул көннән сәед Бәрәкә аның якын киңәшчесенә әверелә, гомере буе аның белән була. Сонрак Тимер бәк аңа Андхой каласын бүләк итә. Алар хәтта үлгәч тә бер-берсеннән аерылмыйлар—икесе дә Тимер бәк өчен махсус төзелгән Гүр әмир төрбәсендә күмелә. Дөрес булса, хәтта йөзләре дә бер-берсенә каратылган, имеш.

Хакимиятне үз кулына алганнан соң дөньяда Тимер бәк куркырлык бер генә кеше

дә калмаган, диләр. Тик бер зат барыбер калган икән—ул Зәйнетдин Абу-Бәкер Тайавади исемле дәрвиш булган, ди. Бервакыт Тимер бәк шушы дәрвиш яшәгән якларга килеп чыккан да аның белән очрашырга теләвен тегенә тапшырырга кушкан. Алла бәндәсенең мона бер дә исе китмәгән: «Минем ана эшем төшкәне юк, кирәк булса үзе килсен»,—дип кенә җавап биргән.

Нишләмәк кирәк, изге затның башын кистереп адәм хурына калып булмый. Тимер бәк үзе теге изге яшәгән тау куышына килергә мәҗбүр булган. Бу хакта ул үзе тарихчы Хафизи Абруга сөйләгән, аның аша хикәя безгә килеп ирешкән. «Дәрвишләр белән очрашканда, мин аларның күзендә гел курку күрә идем. Ә бу юлы дәрвиш түгел, үзем шундый бер хис кичердем»,—дип сөйләгән Тимер бәк. Зәйнетдин Абу-Бәкер Тайавадины ул тормышына йогынты ясаган, яуларында ярдәм иткән өч изге затның берсе дип атаган. Калган икесенең Шәмсетдин Күләл белән сәед Бәрәкә булганын инде әйткән идек.

Шулай итеп, Тимер бәк гомере буе дин әһелләре белән тату мөнәсәбәттә яшәгән. Мондый дуслыкта сәясәт тә күздә тотылганга охшый.

Дөньяви фәннәрдән Тимер бәк барыннан да бигрәк тарихны яраткан. Үзе укый-яза белмәсә дә, ул гаять мәгълүматлы кеше булган, янында махсус китап укучылар тоткан һәм буш вакытларында шуларны тыңларга яраткан. Шулай шактый зур белемгә ирешкән. Атаклы гарәп тарихчысы һәм философы Ибне Халдун, мәсәлән, Тимер бәк белән очрашып сөйләшкәннән соң аның киң карашлы, мәгълүматлы кеше булуын күреп хәтта гаҗәпкә дә кала.

Тимер бәкнең икенче яраткан шөгыле—шахмат уены була. Ә сәнгать өлкәсендә—архитектура яисә мимарлык. Шуңа күрә ул шәһәрләрне төзекләндерүгә, биналар бизәүгә зур игътибар биргән, бу традиция аның варислары заманында да дәвам иттерелгән.

Ләкин ана карап кына без бу тарихи шәхесне һич тә идеаллаштырырга тиеш түгелбез. Шик юк, Тимер бәк үз ватаны Мәвараэннәһер өчен зур эшләр башкарган, феодал низагларны туктаткан, илнең берләшүен тәэмин иткән, тынычлык урнаштырган. Ләкин ул төзегән дәүләт даими рәвештә күрше халыкларны талау, яулау, аларның матди байлыгын тартып алу белән шөгыльләнгән. Башкалардан тартып алынган ул хәзинәләр Мәвараэннәһер калаларына агылып торган һәм харам мал хисабына гүзәл биналар үсеп чыккан.

Шулай ук Тимер бәк яуларында күрсәтелгән вәхшилек, кансызлык үрнәкләрен дә искә төшерик. Яктылыкның икенче—күләгәле ягы да бар икән ләбаса! Анысына да күз салыйк. Гыйбрәт өчен!

Әйтик, 1387 елда Исфахан халкы аның гаскәренә каршы баш күтәрә. Фетнәне бастырганнан соң җиһангир 70 мең кешенең башын кистерә, бу башларны казаннарда кайнатырга куша, итеннән чистартып, ялтырап торган баш сөякләреннән манаралар төзетә. 70 мең баш сөягеннән манара! Мондый вәхшилек нигә кирәк булды икән?

Әйтик, Әфганстандагы Исфизар каласын алган чакта аның әмере белән 2 мең кеше кирпеч һәм балчык белән аралаштырып аркылы-торкылы салына да алардан башнялар төзелә. Чыннан да, Тимер бәк төзелеш эшләрен бик яраткан булса кирәк...

Әйтик, Кече Азиядәге Сивас каласын алганнан соң, 4 мең кеше тере килеш каберга күмелә.

Әйтик, Һиндстандагы Дәһли солтанатына каршы һөҗүм башлар алдыннан Тимер бәк мона хәтле әсирлеккә төшкән 100 мең кешене үтерергә боера. Ни өчен дисезме? Теге бичараларның йөзендә басып алучыларга карата нәфрәт чаткылары күренгән өчен!

Тимер бәкнең бөеклеге ничек кенә күкләргә чөеп сөйләнмәсен, аның эшчәнлегендәге бу хурлыклы вакыйгалар, вәхшилекләр дә кешелек хәтерендә саклана килә. Әйе, ул бөек җиһангир һәм дәүләт эшлеклесе булган. Моны берәү дә инкяр итәргә җыенмый. Тик эшчәнлегенең кара ягына да күз йомып калу мөмкин түгел. «Гений белән явызлык бергә сыеша алмый»,—дип язды Пушкин. Ай-һай, алай микән? Алай ук кистереп әйтү дөрес булырмы? Тарих еш кына моның капма-каршысын да күрсәткәли ләбаса. Егерменче гасыр да моны шактый күрсәтте: Гитлер, Сталин, Пол-пот...

Идегәй мирза менә шундый мохитка барып керә. Дөрес, ул Сәмәркандка качып килгәндә, Тимер бәк әле тышкы яулар дәверен башлап кына ята. Бу вакытта җиһангир әле тарихка кереп калачак гайрәтлекләрен дә, күп явызлыкларын да кылмаган була. Шулай да, алда әйтелгәннәрдән чыгып, укучы инде Идегәй мирзаның нинди шартларда, нинди шәхес белән аралашырга тиешлеген, максатына ирешү өчен нинди вәзгыятьтә

эш башлап жибәрергә тиеш булуын күзалдына китергәндер.

Әлбәттә, тар хокуклы килмешәк булып яшәү аңа җинел булмагандыр. Тик шуны онытмыйк, Идегәй мирза—гаҗәеп зирәк, сәләтле, булдыклы, кеше белән аралашырга оста, кирәк чакта йогынты да ясый белүче шәхес. Шуңа күрә Тимер бәк белән Идегәй арасында якын мөнәсәбәтләр урнаша һәм ул максатын тормышка ашыру өчен эш башлап җибәрә.

Ә максаты нидән гыйбарәт соң? Әлбәттә, кан дошманы Туктамыш ханнан үч алу, мөмкин булса, гомумән, аны тәхеттән бәреп төшерү һәм кабат Сарайга әйләнеп кайту. Тәхеткә Тимер Котлыкны утырту, шулай Алтын Урдага хуҗа булу.

Бу максатка ничек ирешергә мөмкин? Әлбәттә, Тимер бәк ярдәме белән. Башка юл юк. Туктамыш ханны тәхеттән очыру өчен зур көч кирәк, гаскәр кирәк, ә гаскәр-көч Тимер бәктә генә. Димәк, аны Сарайга, гомумән, Алтын Урдага яу йөрергә күндерергә, ничек тә шушы авантюрага тартырга кирәк. Моның өчен, дәлилләр китерә-китерә, бу фикерне аның колагына гел тукып тору, тәмам ышандыру кирәк.

Бүгенге көн биеклегеннән торып фикер йөрткән укучы: «Шәхси үчен кайтару өчен үз ватаны Идел-Йортка дошман алып килмәкчеме?»—дип сорау да куярга мөмкин. Бу очракта без: «Әйе, ул фәкать шуна керешкән, аның өчен шәхси мотивлар кайчакта зуррак әһәмияткә ия булган»,—дип әйтә алабыз. Урта гасырларда яшәгән ул затларның психологиясенә ватанпәрвәрлек хисе ят булган, күрәсең. Гомумән, без шәхеснең тарихтагы ролен киметеп күрсәтәбез шикелле. Ә бит күп вакыйгаларның үзәген фәкать шәхси мәнфәгатьләр тәшкил иткән, шуның аркасында үсеш теге яки бу юнәлештән киткән.

Идегәй мирзаның бу эшләре замандаш тарихчылар игътибарыннан да читтә калмаган. Димәк, Идегәй мирза үгетләүне чышын-пышын гына түгел, ә ачыктан-ачык алып барган. Бәлки әле зур җыеннарда да сүз алып бу хакта сөйләгәндер. Мәсәлән, Ибне Гарәбшаһ бу хакта менә нәрсә яза (русча чыганактан китерелә): «Он, Идику, не переставал подстрекать его к этому, возбуждать да окутывать Тимура».

Әйе, бу яуның һәр яктан отышлы һәм файдалы булачагын исбатлап, Идегәй мирза күп дәлилләр китерә, Сәмәрканд

## «КАЗАН УТЛАРЫ»НА 80 ЕЛ
## «QAZAN UTLARI»NA 80 YIL

**Владимир Иванов,**

*Татарстанның социологлар җәмгыяте рәисе, тарих фәннәре докторы, профессор*

### РУХИ ТЕРӘГЕБЕЗ



*"Казан утлары" журналы минем тормышымда һәм фәнни эшчәнлегемдә үзенчәлекле урын алып тора. Беренчедән, мин бу затлы журналны бик күптәннән, әле ул "Совет әдәбияты" дип аталган заманнардан бирле күзәтеп, даими укып барам. Анда бик күренекле әдипләребез, гуманитар белеменең төрле тармакларында эшләүче галимнәребез яхшы-күркәм хезмәтләрен бастыра киләләр. Шунысы тагын да куанычлы: журнал фән кешеләренә дә юл ачты. Редколлегия сафында озак еллар академик Рәфыйкъ Нәфыйковның булуы да күп нәрсәне аңлата. "Казан утлары"на мин фәнни басма итеп тә карыйм. Әле күптән түгел генә профессор Булат Солтанбәковка журналның быелгы беренче санында баш мөхәррирнең кереш мәкаләсен укырга киңәш иттем. Ул да бу мәкаләгә уңай бәя бирде. Димәк, журналны галимнәр дә укый. Алар автор буларак та журналда чыгыш ясыйлар. Мәсәлән, Миркасыйм Госманов һәм Хатыйп Миңнегуловның язмалары миндә зур кызыксыну уятты. Теләгем шул: мөхтәрәм басмабыз үзенең фәнни дәрәҗәсен, гуманитар статусын киләчәктә дә югары тотсын иде!*

әмирен күндерергә тырыша. Ул болай ди: «Ты устремляешься в страны дальние да в местности дикие и заброшенные, из-за этого подвергаешься опасностям, пересекаешь хребты и пустыни и перебираешь книги путешествий. А вот добыча холодная перед самими глазами твоими: ты добудешь ее легко и удобно, как тебе будет угодно и приятно, для чего же мешкать и дремать? Из-за чего медлить и отлагать? Поднимись с твердою решимостью, и я тебе порука в том, что нет крепости, которая тебя задержит, и нет преграды, которая тебя остановит; нет пресекателя (меча), который отгонит тебя... Там только сброд и сволочь. Богатства же там поддадутся угону и сокровища придут к тебе на своих ногах!» *(В. Г. Тизенгаузен. Сборник материалов...,—т1.— С. 459).*

Әгәр дә бу сүзләр дөрес булса, ә безнең аларга ышанмаска хакыбыз юк, Идегәй мирзаның үз ватаны Идел-Йортка нинди һәлакәт әзерләве коточкыч хәл булып күз алдына килеп баса. Чыннан да, катлаулы шәхес булган Идегәй мирза. Дастандагы Идегәй әле бу шәхеснең бер ягы гына, конкрет шәхес—тарихи Идегәй мирза да бар бит әле!

«Идегәй мирзаның үз ватаны Идел-Йортка...» дип күнегелгәнчә язып куйдым да уйга калдым. Идел-Йорт аның үз ватанымы соң? Ул бит Маңгышлак-Арал буе тумасы. Шунда туган, шунда житлеккән. Безнең өчен газиз ватан Идел-Йорт аның җанын сыкраткан мы? Ул бит Идел буена Туктамыш ханга ияреп кенә килә. Тәхет тирәсенә сырыша. Идел-йортны, аның халкын үз халкы дип санаган кеше: «Там только сброд и сволочь» дип әйтер иде микән? Монысы да зур сорау булып кала...

Тамчы ташны тишкәндәй, Идегәй мирзаның сүзләренә Сәмәрканд әмире тора-бара игътибар итә, колак сала башлаган, күрәсең. Ә тегесе күрешкән саен бу хакта сүз кузгаткан булса кирәк. Шулай Тимер бәк бу хакта чынлап торып уйлана, исәплəп-чамалап карый башлый. Һәм көннәрдән бер көнне Алтын Урдага яу йөрү фикере аның күңелендә тәмам ныгый, ул катгый карарга килә.

Шулай итеп, Идегәй мирза максатына якынаю өчен зур адым ясый—Тимер бәкне Дәшти Кыпчакка яу йөрергә күндерә.

*Дәвамы киләсе санда*

*Икенчедән, мин журналны укучы гына түгел, анда минем кайбер хезмәтләрем дә дөнья күрде. Берсе аеруча хәтердә калды һәм ул. Казаныбызның 1000 еллыгын каршы алыр алдыннан, бер истәлекле факт буларак та игътибарга лаек, дип исәплим. Сүз "Казан утлары"ның 1977 елгы 8 нче санындагы "Тасырлар аша карап" дигән мәкалә турында бара. Аның кечкенә генә сере-хикмәте дә бар. Нәкъ моннан чирек гасыр элек, 1977 елның февралендә мина һәм кайбер галимнәргә Казанның кайчан "тууы" хакында Мәскәүдә фәнни доклад ясарга туры килде. Мин докладны болай башладым: "Казанга мен ел чамасы, ләкин без рус елъязмаларына таянабыз, шуна күрә 800 еллыкны бәхәссез дип саныйм". Азагын исә болгар-татар чыганакларына таянып, болай: "Казан монголларга кадәр күп элгәре үк төзелгән" дип тәмамладым. Сонрак бу доклад журнал битләрендә саллы мәкаләгә әверелде. Мин мона бик рәхмәтле.*

*Өченчедән, «Казан утлары» журналы чын, асыл татар матбагасы буларак, милләтебезнен төрле кыйтгаларга таралган төркемнәрен берләштерә, аларга хәл кадәри игътибар юнәлтергә омтыла. Мин үзем, мәсәлән, керәшен татары буларак, заманлаш әдипләребез Гурий Тавлин, Егор Уткин, Гәрәй Рәхим, Ямаш Игәнәй кебек әдипләребезнен әсәрләре белән ин әүвәл «Казан утлары» аша таныштым. Олуг мәгърифәтчебез Яков Емельяновнын юбилеен да журнал зурдан билгеләп үтте. Киләчәктә дә яраткан журналыбыз милләтебезне бербөтен килеш саклап калуда эшен дәвам итәр дип ышанам.*

*Дүртенчедән, журналнын баш мөхәррирләре гел зур шәхесләр булдылар: Галимжан Ибраһимов, Галимжан Нигъмәти, Кави Нәжми, Зәки Нури, Гариф Ахунов, Ренат Харис, Равил Фәйзуллин. Алар күренекле язучылар гына түгел, милләт горурлыгы, анын асыл вәкилләре дә бит. Олпат журналыбыз киләчәктә дә рухи терәгебез булып калсын иде.*

## «ШИГЫРЬ ҖЕНЕ КАГЫЛГАН» РӘССАМ



*Хәмит Латыйпов (1949 елда туган) исемен әлегә журналыбыз укучылары очратмаганнардыр, шаять.*

*Тормышның ачысын-төчесен татыган милләттәшебез ул.*

*Һөнәре буенча—рәссам, агачка кисеп сурәт ясау остасы; графика һәм керамика төрләрендә дә эшли, сынлы сәнгать һәм скульптура белән дә мавыга—кыскасы, чын мәгънәсендә сәнгать кешесе. Әмма ул шагыйрь дә: күңеле белән, милли жаны белән генә түгел, инде кәгазьгә төшереп, төрле басмаларда («Аргамак», «Идел» журналларында һ. б.), көндәлек матбугатта күренеп килгән каләм иясе. «Жир һәм Күк» исемле китабы (1997 елда Башкортстанда—Туймазыда басылган) да дөнья күрдеана карата әдип Айдар Хәлим, хуплап, әтрафлы мәкалә дә язып чыкты. Хәзер Хәмит икенче китабын Казанда чыгарырга әзерли. Шигырьләрен (китапларын да!) үз рәсемнәре, эскиз-этюдлар белән дә бизәп күрсәтә ул. Журналыбызга тәкъдим ителгән дүртюллык шигырьләренә дә махсус декоратив агач тәлинкәләргә уеп эшләнгән сурәтләр эскизларын ясап китерде. Кыскасы, ул—рәссам-шагыйрь; төсләрне, буяуларны жанлы, афористик сүз, фикер белән кушып, бер яңа сәнгатьчә синтезга омтылган иҗат бу. Күз салыйк әле без аңа, яңа каләм иясенә, хөрмәтле укучыларыбыз!*

*Рәдиф Гаташ*

# Хәмит Латыйпов

## ӨШЕГӘН ЙОЛДЫЗЛАР ЯКТЫСЫ

**Күңелемдә—галәмнәр киңлеге,
Өшегән йолдызлар яктысы...
Ярсыган җилләрдә өметләр
Булыр күк—җанымның сакчысы...**

### Гаҗәпләнү

**Үзгәрүчән бу дөньяда яшим үзем.
Аңлый алмыйм һич кенә дә дөнья серен.
Гаҗәпләнеп гажиз калам һәр мизгелгә,
Шуңарданмы—нурлана күк күңел күзем.**

## Ара

Ак хыяллар... Ак аргамак җиктем,
Биек таулар—ерак арасы...
Офыкларны иңләп киңлек ята,
Сукыр томан аша барасы.

## Аваз

Җир авазы—чишмә агышында,
Чәчәкләрнең якты сагышында,
Былбыл, тургайларның тавышында...
Искән җилләр... яфрак кагышында!

## Капка

Кемнәр кергән, кемнәр чыккан бу капкадан.
Китеп читкә, кемнәр кайткан, кем кайтмаган...
Язмыш җиле хәбәр ташый чит яклардан—
Кемнәр тапкан бәхетләрен, кем тапмаган...

## Яра

Соңгы сулышында уйлагандыр
Үксез кала диеп балаларым:
Инде ничә еллар җанда сызлый
Әтиемнең сугыш яралары...

## Аһ, бу моңнар

Аһ, бу моңнар, аһ, бу көй-җырулар
Кузгаттылар тагын йөрәкне.
Кара төннән саркып борынгы җыр
Җанкаемны тагын көйрәтте!

## Теләк

Синнән башка үтте бу гомерләр,
Язмышларны үтте вакыт күмеп.
Үз көенчә калсын барысы да...
Тик өметләр бетмәсеннәр сүнеп.

## Балачак истәлеге

Авыл капкасыннан атлар узды,
Атлар белән китте абыйлар.
Читән башларыннан карап калды,
Кулын болгап, үксез сабыйлар.

Кар-бураннар аша алга таба
Атлап барам, үткән артта кала.
Адым саен җанда арта яра,
Мәңгелеккә ара—кими бара...

## Эзләнү

Бу дөньядан киткәч—калыр бер чак
Чыкка әйләнеп бу дөньяның яме.
Рух омтылган кадер почмакларын
Бу җан тагын-тагын эзләр әле.

## Ятимлек

Балачакның хыял чәчкәләре
Шарран күңелемә чәчелгән.
Ачы үксезлекне бәгыремә
Иртә килгән көзләр яшергән.

## Бер уч җылы

Алтын кебек көннәр үтә,
Сабый күк алданыпмы?
... Бер уч җылы биреп киттең,
Үзеңнән калганынмы?

## Ут капкан күк

Күк гөмбәзе утка күмелеп,
Кояш офык артына күчте.
Дөрләп янган кичке күкләрдән
Күңелемә очкын-моң төште.

## Хәтерләү

Гомер үткән инде, талган йөрәк—
Үткәннәрдән кайткан юлчыдай.
Күз алдымда шул вакытымны күрәм—
Үз нәкышен тоткан сынчыдай...

**Әгъдәс Борһанов**,
*тарих фәннәре докторы,
Россия дәүләт гуманитар
университеты профессоры*

# ДӨНЬЯ КӨЗГЕСЕНДӘ—УРЫС ГАМӘЛЕ

УРЫСНЫҢ акыллы башлары Россиянең ни өчен болай бәхетсез, кара язмышлы булуы хакында байтактан уйланалар, моның тамырын-сәбәпләрен эзлиләр. Эзли торгач ике сорау пәйда була: «Кем гаепле?» һәм «Нәрсә эшләргә?» Физиклар: «Мәсьәләнең 90 процент чишелешен аның ни дәрәҗәдә төгәл куелышы хәл итә»—дип раслый. Гуманитар фәндә исә, минемчә, мәсьәләнең 100 процент дөрес куелышы зарур. Чөнки бу өлкәдә, физиклардан аермалы буларак, теориянең хаклыгын раслау өчен тәҗрибә үткәрү мөмкин түгел. Әмма урыс сәясәтчеләре моның белән гомер-гомергә даими шөгыльләнәләр. Бигрәк тә коммунистлар бу җәһәттән зур «уңыш»ка иреште. «Максатка илтми торган кыек юнәлештән алга барабыз»—дип, әле теге заманнарда ук Чаадаев дөрес әйткән булган икән.

Октябрь түнтәрелешенә кадәрге һәм аннан соңгы совет әдәбияты «Кем гаепле?» соравына болай җавап бирде: «Самодержавие!». Бүгенге көндә исә халык өстенә ишелгән бәлаләрне демократларга (кайберәүләр: «дерьмократ»диләр) сылтыйлар. «Нәрсә эшләргә?» соравына җавап элекке заманда: «Патшаны бәреп төшерергә!» генә булса, хәзер исә күп төрле: «Яңа демократик җәмгыять, ягъни либераль капитализм төзергә кирәк»; «Юк, социализм!»...

Мөгаен, бүгенге вәзгыятьтә икенче сорауга өстәмә кертү таләп ителәдер. «Нәрсә эшләргә?» генә түгел, «Нәрсәне ничек эшләргә?» һәм «Кемгә эшләргә?» Совет чорында уздырылган бетмәс-төкәнмәс аянычлы тәҗрибәләрдән соң бу өстәмәләр бик тә актуаль ләбаса. Бу җәһәттән тарихи алшартларны янәшә куеп карау кызык. 1861 елда, ягъни крестьян реформасы алдыннан, патша хөкүмәтен халык мәнфәгатьләренә хезмәт иттерердәй көчләр юк иде. Моннан берничә ел элек тә халыкка файдалы реформаларны үз вакытында тиешенчә үткәрердәй көчләр табылмады. Нәтиҗәдә, дәүләт халыкны талады. Чөнки югары әзерлекле сәяси фиркаләр дә, лидерлар да юк иде. Ул хәзер дә юк. Бүгенге «элита» дигәнебез күп очракта «сәнәктән көрәк булган» һәм әле анда да коммунизм тиреслегендәге сәнәктән генә көрәк булган затлардан тора. Урысның Протопоп Аввакумы: «Фәхишә улы бүген атакай булып йөри»—дигән бит әле...

## 1. Кем гаепле?

РОССИЯДӘГЕ абсолютизм мәсьәләләрен өйрәнүче галимә Н. Демидова урыс бюрократиясенең туу тарихын XVI—XVIII гасырларга бәйләп карый. XVIII гасырның беренче чирегендә генә дә дәүләт хезмәткәрләренең саны ике мәртәбә арткан, канцеляриялярне асрау өчен исә дәүләт чыгымының уннан бер (!) өлеше бүлеп бирелгән. Әмма шуңа да карамастан, хезмәт урыныннан явызларча файдалану, ришвәтчелек, караклык чәчәк аткан һәм бу гадәти күренеш буларак кабул ителгән.

Николай I үз заманында әрнеп-гасабиланып болай дигән: «Россия белән 25 мең столоначальник идарә итә». Бу сүзләрне шул дәвердә ил буенча сәяхәт кылган француз Маркиз А. де Кюстин да үзенең «Николай Россиясе» китабында раслап куя: «Россия белән чиновниклар сыйныфы идарә итә... Үзләренең канцелярияләре түреннән торып, бу күзгә күренмәс залимнәр, бу пигмей-тираннар, һичбер җәзага тарымыйча, илне изәләр, җәберлиләр. Парадокс шунда ки, Россия патшасы үзенең чиксез кодрәтен үзе үк шик астына ала, әмма хакимлеге чикләнүен танудан курка. Бу чикне аңа алагаем зур хәтәр көч—бюрократия куя, чөнки хакимияттән явызларча файдалану Россиядә тәртипне ярату, дип атала. Императорның чикләнмәгән кодрәте түрәләрнең җәбер-золымына алышынуын күрәсең дә, административ система шау чәчәктә утырган бу илнең язмышы өчен калтыранып-чымырдап куясың...»

Кюстин үзе күргәнне төгәл тасвирлап кына калмаган, әйтерсең лә безнең бүгенге заманны да алдан күрә алган. Йә, шулай түгелмени?!

Монархия институты, миңа калса, зур реаль көчкә-идарә структурасына, бигрәк тә ялланган түрәләргә каршы тору өчен төзелгән булырга тиеш. Ялланган түрә, димәк-вакытлыча гына. Мантыйк бер: «Вакытың барда—урлап кал!» «Урлыйлар»—ди Карамзин. «Канцлердан алып соңгы протоколчыга кадәр һәммәсе дә урлый һәм барысы да сатыла»—монысын Пушкин әйткән. Әлбәттә инде патша, гәрчә төпле акылга, яисә әхлакый сыйфатларга ия булмаса да, ул түрәләр сыман урламаячак, мал-мөлкәтне черетеп, бозып, әрәм-шәрәм итмәячәк. Чөнки бу дәүләт аңа, аның нәселенә мәңгелеккә бирелгән. Шунлыктан, бөтен гаепне бер патшага гына аударырга ярамый. Россиянең бәлаләре өчен төп гаепле көч—бюрократия. Ул Петр I заманында ук үз көчен ныгытып күрсәтә башлады һәм коммунистлар чорында чиксез кодрәткә ирешә. Бу хәзер дә шулай. Чөнки Россиянең бүгенге югары даирәләре дә, гәрчә рәсми рәвештә коммунист булып саналмасалар да, нәкъ менә большевиклар кебек үк, халыкка фәкать тәҗрибә куяннары итеп кенә карыйлар. Бүгенге Россиянең төп проблемасы—халык дәүләттән читләшкән һәм бу вәзгыятьтә яхшы якка бернинди дә социаль-сәяси үзгәрешләр булуы мөмкин түгел. Либераль бюрократка әверелгән урыс дәүләте бүген үз халкына каршы берәзлексез сугыш алып бара. Илнең төп милли байлыгы дәүләт кулында, димәк, бюрократлар кулында. Россиянең һәлак булу-булмавы да алардан тора. Хәер, бюрократизмның да төрлесе була. Хокукый, демократик дәүләтләрдә аңа каршы уңышлы гына көрәшеп киләләр. Әмма боларда да соңгы вакытта бюрократиянең үсеше күзәтелә. Кешене кеше идарә итүгә ихтыяҗ бетми торып, бюрократизмның да тамыры корымаячак. Әмма Россиядә бу көч дәүләтнең асылын билгели бит. Хәтта аңа каршы демократик чаралар куллану да—вакыт әрәм итү генә. Парадокс: штатлар кыскара, бюрократлар саны арта! Нәкъ менә ачлык елны ишәйгән күселәр сыман... Бу паразит сыйныф үз дәүләтенең үсешенә комачаулый, үзе утырган ботакны кимерә. Кайчан егылып төшәр?! Урыс дәүләтендә халык бюрократиягә хезмәт итә. Чаян белән керкә балыгы турындагы анекдотны ишеткәнегез бардыр инде: балык чаянны дәрьяның бер ярыннан икенчесенә чыгарып куярга ризалаша. Елганың уртасына җитәрәк, чаян керкәне чага. «Нишлисең син? Батабыз бит!»—ди балык. «Холкым шундый»—дип җавап бирә чаян. Урыс бюрократиясенең дә «холкы шундый». Аның беренче кланы патша империясен «чакты». Икенчесе—коммунистлар номенклатурасы—

Совет империясен җимерде, өченчесе исә—хәзерге квази либерал-демократик клан—Россияне тар-мар итеп маташа.

Бюрократиянең бар булмыш акылы аның умырып алу, тизрәк эләктереп калу инстинктына тупланган. Агымдагы эшләр, көндәлек ыгы-зыгы, үзеңнән өстә торган түрәгә ялагайлану, һәрдаим үз-үзеңне чикләү интеллект өчен кирәкле иҗади башлангычны яралгы хәлендә юкка чыгара. Үзеннән акыллырак, өстенрәк көндәшен бюрократ дошман итеп күрә.

Урыс дәүләте күп гасырлар дәвамында халык мәнфәгатен, аның хосусый милекчелек хисен басып килде. Бүгенге хәерчелек, эчкечелек, ялкаулык-хөрәсәнлек, өметсезлек, әхлаксызлык кебек бик күп урыс бәлаләре (ни кызганыч, ул татарга да кагыла)—әнә шул сәясәтнең аянычлы нәтиҗәләре. «Работа не волк—в лес не убежит» кебек йомры гыйбарәләр юктан гына бар булмаган лабаса. Европа халыклары арасында Россия халкы бәйрәм көннәренең күплеге буенча беренче урында тора. Аңа киң таралган караклык өчен дә «алтын медаль» биреп булыр иде. Бит дәүләттән, яисә байлардан гына урламыйлар, әбер-берсеннән дә чәләләр. Бүген инде «Ватан» төшенчәсе сукыр бер тиенгә дә тормый, чөнки гражданинның хосусый милек тамырлары төптән өзелгән. Хәерчелеккә төшкән авыл халкы, уңдырышлы туфраклы туган җирен ташлап, бәхет эзләп шәһәргә кача, кала юксыллары сафын ишәйтә. Физик һәм рухи көче сынарга өлгермәгәннәр исә тизрәк чит илгә чыгып китү ягын карый. Туктаусыз барган сугышлар, халык каймагының мөһаҗирлеккә бирелүе милләтнең генофонды бозылуын күрсәтә, милләт буларак юкка чыгу процессы башлануына ишарәли.

Кытайның танылган акыл иясе Мән-Цзы (безнең эрага кадәр III гасырда яшәгән) болай дип язып калдырган: «Хосусый милеккә ия булмаган халык даими хисләр кичерә алмый, ул таркала, аның әхлагы югала, ахыр чиктә ул башына ни килсә, шуны кыла башлый».

Димәк, хосусый милек кешене җаваплы, оешкан, тәртипле, әхлак һәм хокук кысаларын саклый ала торган итеп тәрбияли. Көнбатыш дәүләтләренең узган гасырның икенче яртысында алган тәҗрибәсе шуны күрсәтә: халыкның өчтән ике өлеше төрле формадагы һәм төрле дәрәҗәдәге хосусый милеккә ия икән, димәк бу җәмгыять социаль яктан тотрыклы булып санала.

Ялланып эшләүче халыкның исә бар вөҗүде-тәне пролетариатлыкның «эренле ярасы» белән сырҗып алынган. Бу яралар төзәлми торып, ни тулы канлы эшмәкәрлеккә, ни чын, ирекле базар мөнәсәбәтләренә йөз тотып булмый. Ялчы—демократиядән тыш, ул—кол. Кол исә—диктатураның нигез ташы.

«Урыс халкының фаҗигасе шунда ки, аның беркайчан да тарихи хәтере булмады. Һәр яңа көнне без календарьның чиста битеннән башлыйбыз, шуңа күрә дә безгә гел берүк хаталарны кабатларга язган»—ди Чаадаев. Мең тапкыр хаклы бу акыл иясе! «Сатам-алам», «алам-сатам»га көйләнгән кыргый базарга барып кердекме?—Кердек! Җиде түгел, бер кат та үлчәп тормастан, үзебезнең сыйфатсыз товарыбыз белән дөнья базарына да ыргылдык әле. Хәер, дөньякүләм бердәнбер төп «товарыбыз»—чимал. Анысы да бетмәс-төкәнмәс күләмдә түгел бит. Абруйлы мәгълүмат чыганакларына таянсак, Россиядә бүген нефть—35 елга, табигый газ—81 елга, ташкүмер 60-180 елга, тимер рудасы—42 елга, бакыр—40 елга, никель—40 елга, алтын—12-37 елга гына җитәрлек калган. Башка төрле минераллар белән дә шундый ук хәл. Безнең оныкларыбызга (безгә түгел!) тиешле файдалы казылмаларны да уңга-сулга сатып, таратып бетерсәк, нәрсә исәбенә яшәргә кала соң, дигән урынлы сорау туа. Иртәме, соңмы, бу сорауга җавапны бүгенге «реформатор»лардан таләп итәргә туры киләчәк.

## 2. Нәрсә эшләргә һәм ничек эшләргә?

ЧААДАЕВНЫҢ урысның тарихи хәтерсезлеге хакындагы сүзләрен янә искә төшереп, әлләни ерак булмаган тарихыбызга мөрәҗәгать итик әле. Октябрь инкыйлабыннан соң озак вакыт та үтмәде, яңа хакимият белән халык арасында

тирән упкын хасил булды. Бу вәзгыятьне хезмәт җитештерүчәнлегенең кискен кимүеннән дә күреп була иде. Ленин 1918 елның март-апрель айларында «буржуазия белән көрәшнең яңа фазасына керәбез» дигән булып, яңа экономик сәясәткә (НЭП) юл ачты. Ниһаять, Россия тарихында беренче мәртәбә куәтле урта сыйныф формалаша башлады. Дәүләтне һәм халыкны таламыйча, үз тырышлыгы белән барлыкка килгән яңа көч иде бу! Әмма Ленинның үлеменнән соң бу буржуаз үзгәрешләрне коммунистлар диктатурасының мең потлы чукмары изеп ташлады...

Хосусый милек ияләренең төп-урта сыйныфын булдыру мөмкинлеге узган гасырның 80 нче еллар азагында да туды. Шул рәвешле Тарих Галиҗәнабләре буржуаз реформалар өчен янә бер (бәлки, бу соңгысыдыр?) форсат чыгарды. Мәгълүм булганча, дөньяның бик күп илләрендә капитализмның башлангыч чоры крестьяннарны һәм каланың вак милек ияләрен хәерчелеккә калдырудан гыйбарәт. Әмма бу Россия менталитетына туры килми. Өч урыс революциясе дә моны артыгы белән раслый. Соңгы инкыйлаб, гомумән, бөтен дөньяны тетрәтте һәм аның «канлы шулпасын» кешелек әле хәзергәчә чөмерә. Көнбатыш капитализмының бүгенге демократик стадиясен исә, бик теләсәк тә, җәмгыятьнең социаль һәм матди сәбәпләренә бәйле рәвештә, үзебездә булдыра алмыйбыз.

Бүгенге вәзгыятьтә безгә яңа НЭПка каршы килмәгән дәүләт булдыру зарур. Әмма ничек итеп?

Урыс менталитеты иң беренче чиратта дәүләттән социаль гаделлек мәсьәләсен чишүне таләп итә. Әмма бер генә җәмгыятьтә дә аны тулысынча хәл иткәннәре юк әле. Дөрес, абсолют күпчелекнең яшәү рәвешен коммунистлар тигезләп куйган иде куюын. Моның ни-нәрсә икәнлеген без үз мисалыбызда бик яхшы беләбез. Бу күпчелектән бик азлар—коммунистик номенклатура гына (карьера, махсус хастаханә, махсус кибет, һәм башка бик күп «махсуслар») аерылып торды. Менә кемнәр өчен генә иде ул «социаль гаделлек». Минемчә, бу мәсьәләне болай хәл итәргә дә була: Милли байлыкны тигез итеп бүлеп биреп, һәр гражданнан хосусый милекче ясарга кирәк. Бу аларның социаль тигезлеге өчен үзенә күрә бер старт капиталы булыр иде. Һәркемнең өлеше Үзәк Банкның реаль акчалары белән гарантияләнгән очракта, бу мөмкин эш. Гражданин үз өлешеннән килгән дивиденттан бизнесның теләсә кайсы төре белән шөгыльләнгәндә файдалана ала. Әмма өлеш (милли байлык!) аның кулына бирелми, мирас буларак варисларына да калдырылмый. Миңа калса, кризистан чыгуның бу варианты халыкның авыру психологиясен тернәкләндерү җәһәтеннән дә менә дигән дару-дәрман булыр иде; халык базар мөнәсәбәтләренә үги анасына (Россиягә) кулын сузып килгән ятим кебек түгел, ә бәлки чын хуҗа сыйфатында килеп керер иде... Минем бу концепциям көнбатыш-либераль һәм коммунистик карашлар белән һич тә уртак түгел, әмма монда тәңгәл һәм каршы моментлар да бар. Иң мөһиме: һәркемгә һәм һәммәсенә дә!

### 3. Кемгә эшләргә?

БИЛГЕЛЕ булганча, илдәге-җәмгыятьтәге үзгәртеп коруларны демократиягә йөз тоткан интеллигенция вәкилләре башлап җибәрде. Әмма бу дулкынның башында торучылар оешмаганлык, битарафлык күрсәттеләр, «кайнар күмер»не куллары белән тотасылары килмәде аларның. Нәтиҗәдә, реформалар дилбегәсе финанс акулалары кулына күчте. Йомгаклау өлеше исә көч структураларына насыйп булды.

Инде алда әйтеп үтелгәнчә, Россиянең күп гасырлар буена сузылган кара язмышына «үсеш субъекты»ның, ягъни гаммәви милекчеләр сыйныфының юклыгы сәбәп булып тора. Бүгенге вәзгыятьтә бу урынны, миңа калса, интеллигенция вәкилләре тулыландырырга тиеш. Чөнки халыкның югары интеллектын фәкать алар гына үзенә сеңдергән, саклап калган. Хәзер кешелек дөньясы акыл вә мәгълүмат алмашу дәверендә яши. Илнең,

дәүләтнең, җәмгыятьнең дәрәҗәсе дә, абруе да, яшәү көче дә бары тик «кешенең үсеш-тәрәккыять индексы» белән үлчәнә хәзер. Димәк, алгы сафка, алгы планга интеллигентлар чыгарга тиеш! Әлбәттә, интеллигенциянең тарихи миссиясе аның дәүләткә нинди мөнәсәбәттә булуына карап билгеләнә. Ә ул мөнәсәбәт гомер бакый тәнкыйди рухта булган. Бу рухтан ваз кичкән очракта, ул үз-үзе булудан туктый, хакимлек итүче сыйныфның колына әверелә.

Интеллигенция—халык акылының көзгесе. Аның иң талантлы, иң гыйлемле вәкилләре мең вә меңнәр, миллионнар йөрәгендә ятканны күрә, ишетә алалар, хакимнәр җиде йозакка бикләгән Хакыйкатьне табу да аларның кодрәтеннән килә. Моңа алар, әлбәттә, күп очракта биниһая зур бәһаләр бәрабәренә генә ирешә алалар. Урыс тарихы башыннан азагынача юкка гына зыялылар каны белән сугарылмаган лабаса...

Урысның атаклы тарихи акыл иясе В. Ключевский болай дигән: «Интеллигент-халыкны дәвалаучы табиб түгел, ул фәкать аның авыруын, авыру сәбәпләрен ачыклаучы диагност кына һәм ул аны кичекмәстән ачыкларга тиеш. Аның эше борынгы римлылар әйткәнчә: «консуллар уяу булсыннар, ә халык үз ярасын үзе ялар, үзе тернәкләнер...»

Россия дәүләте гомер-гомергә интеллигенциягә тискәре мөгамәләдә булды. Чөнки зыялы затка буйсынмас, бәйсез холык, үзенчәлекле шәхес башлангычы һәм дә ихтыяр көче хас. Бу сыйфатлар күпчелеккә җитенкерәми. Сәбәбе: халыкта бәйсезлекнең нигезен билгеләүче шарт-хосусый милек юк. Өстәвенә, дәүләтчелек, югары даирәгә буйсыну, түбәннәрне кимсетү фәлсәфәсе канга сеңгән. Бу фәлсәфәне ят итеп, кешенең шәхес буларак үсешен билгеләгән фәлсәфәле милләтләр, сер түгел ки, урысны инде биш былтыр элек үк артта калдырып узып киттеләр.

1917—1920 еллардагы инкыйлаб һәм гражданнар сугышы елларында ил тулаем элитасын югалтты—3 миллионга якын кеше Көнбатыш (өлешчә—Көнчыгыш) илләренә мөһаҗирлеккә китте. Аннан соңгы елларда исә коммунистлар илдә калганнарны тулысынча диярлек кырып бетерделәр. Нәтиҗәдә, буыннар алмашы юкка чыкты. Изге урын буш тормый, әлбәттә. Әмма яңа «элита», яңа «интеллигенция» элгәресен яхшы якка алмаштыра алмады. Чөнки традиция бозылган, идеология үзгәргән иде шул инде.

Интеллигенциянең дә төрлесе була. Мәгълүм август путчыннан соң, мәсәлән, дәүләт белән хакимлек итүче югары даирә үз ягына зыялы элитаның күренекле вәкилләрен аударды. Хакимиятнең арт ягын ялауда аеруча «Демократическая Россия» оешмасы җан-фәрманга тырышты. Бу исә хакимлек итүче режимга гади халыкны көпә-көндез кычкыртып талауга юл ачты. Демократик көчләр дә берничә кисәккә бүленде. Күренә ки, җәмгыять көймәсе—тишек, ул бата бара. Монда сатлык интеллигентларның гаебе аеруча зур.

Сәясәтчеләрне тәрбияләү—интеллигенциянең бурычы. Алар кылган, яисә кылачак хаталарны йөзләренә туры бәреп әйтү дә—аның бурычы.

Бүгенге көндә интеллигенция башкалардан аермалы бер акыл хезмәте белән шөгыльләнүче кешеләрнең шәхес һәм социаль мәнфәгатьләрен яклаган социаль төркем булып формалашырга тиеш. Мәгълүмат, белем һәм акыл үскән саен, җәмгыять камилләшә. Бу аксиома.

Хәзер интеллигенция, әле өстен сыйныфның, әле «гегемон»ның күңелен күреп йөргән хезмәтче кыз роленнән ваз кичеп, үзенең кадерен белә башларга тиеш. «Россиянең төп ресурсы—аның акылы, мие»—дип яшәгән очракта гына бу ил мескенлектән, бөлгенлектән котыла алачак.

Бүгенге көндә җәмгыять үз мәнфәгатьләрен яклый алмый. Ул демократик лидерларга мохтаҗ. Иң беренче чиратта интеллигенция киң колачлы сәяси партия булып оешырга тиеш. Аның сафлары укытучылар, табиблар, инженерлар, юристлар, галимнәр һәм башка зыялы катлау вәкилләре белән тулыланыр иде. Булачак сәяси лидерлар өчен дә менә дигән мәктәп ролен үтәр иде ул. Бүгенге Россиядәге барча партияләр дә түрәләр мәнфәгатен генә

кайгырта. «Демократия» сүзе исә алар тарафыннан битлек буларак кына файдаланыла. Чын, асыл демократик хәрәкәтнең башында интеллигентлар партиясе торырга тиеш.

Ни генә дисәк тә, хәзерге Россия Сталин, яисә Брежнев заманындагы ил түгел инде. Бу ил бүген халыкара демократия чолганышында яши. Европа Советы бар, Халыкара Мәхкәмә бар. Бу институт-мөмкинлекләрдән файдаланмау үзе бер җинаять булыр иде.

«Сәяси упкынга тәгәрәүче халыкның язмышын яхшы якка фәкать даһи гына үзгәртә ала»—дигән Гегель. Кешелек дөньясына бу тәҗрибә таныш: Рузвельт узган гасырның 30 еллар башында АКШны коточкыч икътисади кризис сазлыгыннан тартып чыгарды; колониаль система таркалган чорда, Франция сәяси тупикка килеп терәлгән бер мәлдә бу илне Шарль де Голь коткарды. Россиянең исә үз даһие—Ленины бар иде. Әмма ул үлем сәгате якынлашканда гына шуңа төшенде: дөньяның өстен-аска китермичә дә, җәмгыять үсеше өчен нәрсәдер эшләргә була!

Әмма дә ләкин бер генә сыйныф та шәхесне тәртә арасында тота алмый, ул бары тик мәнфәгатьләре туры килгән шәхес артыннан иярә генә ала. Стратегик мәгънәгә ия мәнфәгатьләр исә милекчеләр сыйныфында гына бар. Бүгенге заманыбызны Россиянең кризис кичергән башка чорлары белән янәшә куеп тәңгәлләштерсәк, хәзерге номенклатура арасыннан «яңа Ленин»ның килеп чыгуы да ихтимал. Халык арасында абруй казанган, төпле, нык хаким исә Россияне һәлакәткә бару юлыннан борып җибәрә алыр иде. «Халык капитализмы»ның урыс вариантына Ленин 20нче елларда нигез салган иде инде. Хәтта ул тормышка да ашырыла башлаган иде. Әмма бу юл—НЭП+Кооперация—озакка бармады. Гомумхалык проблемаларын өстән (ягъни дәүләт тарафыннан) хәл итү Россиядә традициягә әверелгән инде ул. Дәүләтне көчәйтү ностальгиясенең хәзер халыкта бик популяр булуы да шуны раслап тора. Югыйсә бу дәүләтнең бернигә яраксыз, криминаль-коррупция дәүләте икәнлеген дә халык яхшы чамалый. Хәлбуки, бандитлар тәртибе дә үзенә күрә барыбер бер тәртип... Бу җәһәттән шуны искәртәсе килә: хәзер ил җәмәгатьчелегенең төп игътибары Россия президенты В. Путинга юнәлтелгән. Президент үзе дә Федераль җыенга юлламасында мөмкин кадәр (үз статусы кысаларында әлбәттә) ачык итеп болай диде: «Система статус рентасын, турысын әйткәндә—ришвәт алу хокукын якларга тырыша. Хакимиятнең бу рәвешле яшәве дәүләт өчен, җәмгыять өчен куркыныч тудыра». Бу системаны бер Путин гына җиңә алыр микән? Бит бюрократия гаҗәеп дәрәҗәдә яшәүчән, хөкүмәт аны кыскарткан саен, ул үсә генә бара. Госкомстат мәгълүматлары буенча, Россиядә соңгы берничә елда гына да ел саен түрәләр саны 30 меңгә күбәя бара; ил 18 минут саен бер түрәгә арта! Аларның тулаем саны хәзер 1 163 000 кеше исәпләнә (Әле моңа оборона министрлыгы, МВД кебек көч куллану ведомстволарының бихисап түрәләре керми—алары үзләре генә дә бу җиде цифрлы сан кадәрле булмагае). Кыскасы, бер кешенең сыртында—җиде сорыкорт. Хәер, бу вәзгыятьтә дә хакимият нык була ала, әгәр дә аның социаль базасы, үзен асрый алырлык гаммәви милекчеләр сыйныфы булса. Әмма дә андый сыйныф бездә юк шул. Бүгенге Россия вәзгыятендә: «хакимиятне ныгытабыз»,—дигән булып, диктатура урнаштыру ихтималы гаять зур.

## Рифат Сверигин

# ГАСЫРЛАР ЧАТЫНДА

Еллар, гасырлар, хәтта меңъеллык чикләрен үтеп чыгу—ул үзе, әлбәттә, бик шартлы күренеш. Биек баскычларны атлаганда үзенең яна үлчәмнәргә күчкәнлеген адәм баласы бәлки сизеп үк бетерми дә торгандыр. Аннары, иҗтимагый тормыш тәртипләре үзләре дә кинәт кенә үзгәреп китә алмый. Әдәбият-сәнгать дөньясында бигрәк тә шулай: янарыш тизрәк яисә әкренрәк барса да—ул, барыбер, дәвамлы процесс, шуңа күрә, аны хронология кысаларына гына сыйдырып куеп булмый. Шулай да егерме беренче гасырга яки өченче меңъеллыкка күчешне билгеләгән шартлы дата чорның инде артта калган чакрымнарын санарга, үтелгән юлларга ныклабрак әйләнеп карарга һәм яна офыкларга текәлергә унайлы гына бер форсат та бирә.

Иртәгесен юлга чыккач, каршында биек тау-кыялармы, әллә тирән ерганаклармы, яисә төпсез упкын ачылачакмы икәнлеген анык кына белеп житкермәгән килеш, эңгер-меңгер вакытта юллар чатында хәл алырга туктап, арган буыннарны язып, алдагы юл азыкларын хәстәрләп, барлап, аякка басып, кутәрелеп килгән чак бу. Мосафирыбыз—татар әдәбияты, төгәлрәк әйтсәк, прозасы. Юллар ерак. Юллар авыр. Истәлекләр дә гел яктыдан түгел: адашкан сукмакларыбыз... эшкә ашмый калган өмет-хыяллар... бу фажигаләрне күбрәк олы буын әдипләре кичерде. Шул буынның соңгы вәкилләре әле генә фани дөньядан китеп барды. Гомәр Бәширов һәм Әмирхан Еникине, Фатих Хөсни һәм Атилла Расихны, Мөхәммәт Мәһдиев һәм Гариф Ахуновны соңгы юлга озаткач, татар прозасының тулы бер дәвере тәмамланганлыгын, инде ятим әдәбиятның үсеш һәм тәрәккыят мөмкинлекләре фәкать үз кулына, үз жегәренә, үз сәләтенә калганлыгын аңларга өлгердекме икән? Әллә «буыннар шулай алмашынып тора инде ул» дип, һаман да үз-үзебезне юатабызмы? Һәм, гомумән, бармы соң ул алмаш дигәнебез, ягъни, югалткан әдипләребез дәрәжәсендә торырдайлар? «Менә яңа лидерларыбыз, менә әйдәп баручыларыбыз», дип кемнәргә карарбыз, кемнәргә таяныр быз? Милли прозабызның егылган байрагын югары күтәреп китәрдәйләр табылырмы?.. Һәм, югарыда жилферди алса, ул байрак, туып килүче яңа гасырның әлегә сүрән кояшы астында нинди төсләргә, нинди төсмерләргә керер? Ә бәлки шул байракны күтәрерлек көчләр дә, хәтта шуңа омтылучылар да теге гасырда бүленеп калганнардыр? Ә бу яктагылар аны, баскан саен тирәнрәк, пычрак ләмгә, сазга батырып, аяклары астында ни ятканын да белмичә, аның өстеннән таптап йөрүчеләр генәдер бәлки?

Әнә шундый күңелсез уйларга бирелеп, яңа роман, повесть, хикәя битләрен актарам. Аларга бүгенге каләмдәшләремнең фикерләре дә кушыла: «...татар прозасы егерменче гасырда дөнья тирәнлегенең катламнарын ача алмаган әле. Нинди беркатлылык, бер чордарак иҗат ителгән повестьларда уртак сыйфатлар, бигрәк тә рухи сайлык бар. Безнең геройларда рухи бөтенләй юк!..» *(Аяз Гыйләжев. «Казан утлары», 2000 ел, 12 сан).* Язучы Миргазиян Юныс «нәшриятны һәм һәвәскәрлек дөньясын басып киткән уртакуллык һәм халтура» турында ачынып сөйли («Идел», 2000 ел, 8 сан). Әхсән Баянов та дөньяга күзне ачыбрак карарга, традиция дигән булып, бер макталганны, күнегелгән гадәт буенча гел мактап, һәм, киресенчә, бер тәнкыйтьләнгәнне, алга таба инде аның булган яхшысына да күз йомып, хурламаска чакыра *(«Казан утлары», 2000 ел, 12 сан).*

Чыннан да, инде кыйбласын югалта башлаган татар укучысына тормыш һәм әдәбиятның асыл кыйммәтләрен танырга, якты өметләр уятырдай офыкларын, перспективаларын күрергә кем ярдәм итәр? Ә күбебез тик «яфраклар шаулавын гына ишетә... Ә тамырлар шаулавын ишетмибез. Ә бит һәммәсе тамырдан башлана... Маңгайга бәрелеп торган матурлыкны күрү кыен түгел, ә тирәндәгесен күрү өчен күңел күзе кирәк» *(«Идел», 2000 ел, 1 сан).* Ниһаять «Халык шагыйре» дип танылган оста прозачы Фәнис Яруллинның шушы сүзләре аның үзенә һәм, ни өчендер, тәнкыйтьчеләр күзеннән читтә калган проза әсәрләренә дә кагыла сыман. Бу авторның тормышка, кешеләргә карата таләпчәнлеге һәм гадел позициясе бар. Ул әйләнә-тирәдәгеләрне бөек, олы җанлы итеп, һәртөрле тормыш ваклыкларыннан өстен торучы шәхесләр итеп күрергә тели, һәммәбезне дөрес яшәвебез яисә яшәмәвебез хакында уйланырга чакыра. Яңа гына дөнья күргән «Портрет» исемле повесте да әнә шундый уй-фикерләр белән сугарылган. *(«Идел», шул ук сан).*

Вахит Имамовның «Могикан» *(«Идел», 2000 ел, 10 сан)* исемле повесте дә битараф булмаска өнди. Эзләнүчән һәм яңаны тоючан бу әдип гасырыбызның «бөек төзелеше» дип саналган КамАЗның без белмәгән бөтенләй башка якларын ачып сала. Бу төзелеш тыныч һәм тигез генә яшәп яткан халыкның тормышын астын өскә әйләндерә—борынгыдан килгән тәртип, гореф-гадәтләргә, әхлакый яшәешкә, экологиягә афәт ябырыла, табигать, җир-ана, җирле халык һәлакәткә дучар була. Әлегә кадәр нинди зур югалтулар бәрабәренә татар илендә яңа кала, зур заводлар пәйда булганлыгын күрсәткән әсәрнең язылганы юк иде. Бу повестьта гигант төзелеш шушындагы халыкларга үзе белән бозыклык, әшәкелек алып килгән дию пәрие—монстр кебек итеп гәүдәләнә. Үз фикерен, төп идеяне укучыга җиткерү өчен Вахит Имамов шактый ук оригиналь сюжет сайлый.

Алтмышынчы-җитмешенче еллар авылы. Атлар белән мавыгып үсеп килүче татар балалары хыялларында үзләрен ерак Америка далаларында—прерийларда гизүче индианнар итеп күрәләр—шулар булып уйнап, мәш киләләр—яна туган матур колынны да экзотик исем табып, Могикан дип атыйлар. Әсәр барышында аның чыннан да бу тарафлардагы гүзәллекнең соңгы могиканы икәнлеге аңлашыла башлый.

Югарыдан җиткерелгән икътисади сәясәт нигезендә элеккеге авыл-кырлар өстенә салынган автоград чыннан да биредәге җирле халыкны әнә шул чит илләрдәге хокуксыз дип саналган индианнардан да түбәнрәк бер халәткә төшерә. «Могикан» повесте әнә шундый кире ягы беләнрәк әйләндерелгән метафоралы сәнгати детальгә нигезләнгән булып чыга. Димәк, олы прогресс дип аталган сәясәт хакына җирле халык үзенең элеккеге кечкенә хокукларыннан да мәхрүм калган. «Бөек төзелеш» дигәннең шушы ягын нишләп күрми калдык? Ул безгә зыяннан башка әйбер бирмәде бит»,—димәкче була автор. Мәсьәлә, әлбәттә, кыю күтәрелә.

Шулай да мин, бу кыю адымның сәяси-икътисади ягына артык кермичә генә, проблеманың әдәби чагылышы мәсьәләсендә автор белән бәхәсләшмәкче булам. Хикмәт шунда: автор сюжетны әлеге киң мәгънәле деталь тирәсенә туплыйсы, җыясы урынга, аны кирәгеннән артык тармакландыра башлый. Мондый күпкатлылык җыйнак повесть жанрына бөтенләй ятышмый, аның җиңел конструкцияләре моны күтәрә алмый.

Ә бит «Могикан»ның антитезага корылган схемасы һич тә начар түгел иде: әсәрнең беренче өлеше—гүзәллеккә мәдхия, икенчесе—шул матурлыкны мәсхәрә итү, аны өстеннән таптап йөрү. Матурлык—беренчедән, ат һәм колын кыяфәтендә, икенчедән, ул—авыл кешеләренең бер-берен аңлап, тату яшәүләрендә, өченчедән, балаларның өмет-хыялларында, дүртенчедән—саф мәхәббәттә, бишенчедән—искиткеч нарат урманында, алтынчыдан—гаҗәеп уңдырышлы кара туфраклы җирләрдә, җиденчедән—әхлак кагыйдәләре буенча көн итүдә... Һәм менә боларның һәркайсы теге төзелешкә ияреп килгән яисә шул төзелеш үзе тудырган начарлык, пычраклык белән алмашына—тереклек, җан ияләре, урманнар, уңдырышлы җирләр юкка чыгарыла, мәхәббәт мәсхәрәләнә, әйбәт гадәтләр эчкечелек астында күмелеп кала, якты хыяллар сүнә... Менә боларның һәркайсы яисә бер-икесе повестьның

нигезен тәшкил итә алган булыр иде. Кызганычка каршы, автор берьюлы бик күп нәрсә әйтмәкче булган. Югарыда искәртелгәнчә, бер повестьта күпсанлы сюжет сызыкларын барысын да бергә бәйләп, нигезләп, ышандырып, ахыргы ноктасына житкерү—бик авыр, хәтта мөмкин булмаслык эш. Шуна күрә дә, минем үземә әгәр дә авторга чама, пропорция хисе хыянәт итмәгән булса, анын әлеге ижат табышы яктырак балкыган булыр иде кебек тоела.

Ә гомумән алганда, Вахит Имамов яна гасыр бусагасыннан ин кыю һәм актив әдипләребез рәтендә атлап керде. Ул унберенче-уникенче гасырларда булып узган тарихи вакыйгаларны, шул чордагы болгар, магул, урыс хөкемдарларынын сарай һәм гаилә интригаларынын гаять катлаулы һәм мәкерле чәбәләнешләрен кин географик һәм тарихи үлчәмнәрдә әдәбиләштереп чагылдырган күләмле әсәренен беренче китабын тәмамлады. Халыклар тарихы белән якыннанрак кызыксынучылар «Утлы дала» дип исемләнгән бу романнан искиткеч күп һәм бай мәгълүмат алырлар. Элек бозып күрсәтелгән яисә махсус рәвештә карангылыкта тотылган тарихыбызны булганынча яктырту мөнәсәбәтеннән генә бәяләсән дә, Вахит Имамов башкарган титаник хезмәтне танымыйча, билгеләмичә үтү зур хаксызлык булыр иде. Ә инде андагы вакыйгалар, фактларнын ни дәрәжәдә дөреслеккә туры килү яисә килмәвен тарихны махсус өйрәнүчеләр—тарих белгечләре тәгаенләрләр.

Мин, үз нәүбәтемдә, күренешләрне сайлау, аларны сюжет-композиция таләпләре буенча урнаштырып, әдәби эшкәртү, әсәрнен художество бөтенлегенә ирешү юлында бу авторга әлегә үзенен бар булган мөмкинлекләрен файдаланып бетермәве хакында гына дәгъва белдерә алам. Чыннан да, бай фактик материал аны типиклаштыруны, тормыштагыны әсәрнен идея-художество бөтенлегенә зыян китермәстәй итеп, тиешлесен генә сайлап, урнаштыра белүне дә сорый. Әлбәттә, бу очракта әсәрне бераз кыскартырга да туры киләчәк. Романнын алдагы басмаларын хәзерләгәндә Вахит Имамов бу кинәшебезгә колак салыр дигән өметтә калабыз.

Сонгы бернична елда татар прозасынын аеруча кыйммәтле ачышлары милләт жанлыларнын аннарын-күнелләрен кузгатырдай, күптәннән борчыса да, һаман да әйтелә алмаган уй-мәсьәләләрне үткәннәр һәм бүгенге көн сулышы белән кушып, аралаштырып, яктырту юнәлешендә булды. Дөрестән дә, бүгенге тормышнын, замана агышынын милләтебез киләчәге өчен хәвефлерәк тарафка авыша төшүе әдәбиятчыларнын гына түгел, һәр татар кешесенен дә халкыбыз язмышына битараф калмаска тиешлеген сорый. Нурихан Фәттах, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Рабит Батулла, Солтан Шәмси, Ркаил Зәйдулла кебек әдипләрнен сонгы эзләнүләре халкыбызнын еракта калган тарих сәхифәләрен дөресрәк, объективрак яктырту ягыннан да, аларны әдәби-сәнгати рәвешләрендә үзләштерү жәһәтеннән дә, һәм жәмгыять халәтенен бүгенге этабында бик зарури булган мәсьәләләргә игътибарны суытмау ягыннан да әһәмиятле. Язу алымнары, стильләре белән бер-берсенә һич тә охшамаган бу каләм ияләрен үткәннәргә ихтирам, вакыйгаларны һәм шәхесләрне тарихтагыча ачарга омтылу һәм милли тойгыларны олылау идеясе үзара якынайта.

Солтан Шәмси «Корбанбикә» исемле яна повестенда *(«Сөембикә»нен 2000-2001 ел саннары)* күп буыннар күнелендә якты эз калдырып, бүгенге көннәргә кадәр килеп житкән Сөембикә образынын янача укылышын, үз вариациясен бирә алган. Бу әсәр әдәбиятта Мөсәгыйт Хәбибуллин, Рабит Батулла һәм башка авторлар тарафыннан ижат ителгән мәгърур Сөембикә образына яна төсмерләр һәм бизәкләр өсти—болар барысы бергә хәзерге укучыларыбыз күнелендә сөйкемле һәм кешелекле гүзәл ил анасын, легендар ханбикәне ачык итеп жанландыра.

Моннан 15 яисә 5-6 гасыр элек булып үткән тарихи хәлләр-вакыйгалар Мөсәгыйт Хәбибуллин романнарында *(«Атилла», «Хан оныгы Хансөяр», «Аллаһы бүләге»)* гүя бүгенге көнкүрештән алынгандай, анлаешлы, таныш һәм күнелебезгә якын итеп гәүдәләндерелсә, Ркаил Зәйдуллин әсәрләрендә *(«Тәнре кылычы», «Тимер бога», «Хан һәм шагыйрь», «Шаһгали»)* борынгы заманнарнын әдәп-этика, этнография, сөйләм-тел үзенчәлекләренә аеруча игътибарлылык һәм сизгерлек күзгә ташлана, ягъни чор колоритына аеруча нык басым ясала.

Әлбәттә, һәр ике ысулның да әдәбият дөньясында яшәргә тулы хокуклары бар—чөнки һәр ике очракта да тормыш үрнәкләре, гыйбарәләре, тарих сабакларының бүген үзебез өчен дә кыйммәтле һәм зарури булуы уңышлы раслана.

Тарихта якты эз калдырган шәхесләр турында уйланганда күнелдә яна сораулар да туа—бүгенге күзлектән караганда гел-гел үрнәк үк булып бетмәсәләр дә, андыйлар кыюлыклары, эшләгән эшләре, кылган гамәлләре белән тарихның ашкынулы агышын тизгенләп акрынайтырга да, кирәк булса, ашыктырырга да, үзләренчә, ә кайбер очракларда үз тирәлегендә яшәүчеләргә, хәтта халыкка кулай юнәлештә борып җибәрә дә алганнар. Булдыклы һәм нык характерлы илбашларын, хөкемдарларны әллә юксына ук башладыкмы? Шулай булмаса, ни өчен әдәбият андыйларны бүген күбрәк тарихтан эзли?

Ни өчендер олы ил агалары образларын гына түгел, хәтта моннан 30-40 ел элек кенә норматив әдәбиятыбыз бик күпләп «житештергән» һәм бүген дә ихтыяҗыбыз, мохтаҗлыгыбыз кимемәгән үрнәк геройларны заман темасына язылган әдәби әсәрләрдән табу соңгы вакытта шактый ук кыенлашты. Ә тормыш маяклары булырдай, яшь буынны сокландырырлык, шулар кебек яшәсәң иде, дип хыялландырырлык әдәби геройлар бүген дә бик кирәк.

Әмма ничек кенә булмасын, әлеге эзләнүләр дә ахыр чиктә, барыбер, милләт мәсьәләсенә, аның язмышына, киләчәгенә килеп кагылмыйча кала алмый. Ә бу үзе—бик олы әйбер, һәм аны халыкның үткәне, яшәеше, киләчәген фаразлау, традицияләре, тәрбиясе, әхлак кагыйдәләре, дене, иманы, теле кебек бик катлаулы һәм нечкә сфералар белән тыгыз бәйләнештә генә күрсәтеп була. Шулай да матур әдәбиятта төп кыенлык шул мәсьәләләрне кую, күтәрү, чишү тирәсендә түгел, ә боларның бөтенесен сәнгатьчә формага салу, сурәтләү камиллегенә ирешү юлларын үткәндә очрый. Чын әдәби яисә сәнгати сурәт яисә образ бер чык тамчысында җемелдәгән кояш нуры сыман бик кечкенә, бик җыйнак күренештә, нәни генә детальдә дә чагыла ала. Әйтәсе килгәннәренне художестволы призма аша бер ноктага, фокуска җыеп, туплап, әдәби камиллек югарылыгында тасвирлау, күрсәтү сәләте һәркемдә бер дәрәҗәдә була алмый. Бу кыенлыкны берәүләр бөтенләй тоймыйлар да, чөнки андыйларга ул ходайдан иңгән талант рәвешендә тумыштан диярлек бирелгән, ягъни югарыдан «төшкән» була, ә икенче берәүләр ана дистәләгән еллар дәвамында тәҗрибә туплый-туплый ирешәләр—әмма ничек кенә булмасын, әдәби осталык мәсьәләсе көн тәртибеннән төшми, чын иҗат табышларын иҗат дәрьясыннан бөртекләп кенә табып була. Әнә шундый сирәк очрый торган энҗеләрнең берсен 2000 елда Айдар Хәлим бүләк итте. Сүз аның «Казыктагы итальян» исемле новелласы турында бара. Моннан алдарак та бу автор проблемаларының үткенлеге, сюжетының бөтенлеге, эшләнешенең камиллеге белән аерылып торган «Татар вакыты» исемле кечкенә романы белән шатландырган иде. Милләтнең җанын—бу очракта сүз саф, чиста, әхлаклы татар рухы турында бара—аның гүзәллеген, сафлыгын саклап калу идеясен образлы гәүдәләндерү өчен озаклап сөйләп, әсәрне сузайган сюжет дилбегәләренә бәйләп үстерү дә кирәк түгел икән. Айдар Хәлим—олы фикер һәм тойгыларны бер-ике сурәт, берничә деталь тирәсенә җыеп, кыска һәм үтемле итеп әйтеп бирү сәләтенә ия. Димәк, хикмәт, кайберәүләр инанганча, жанр зурлыгында яисә вакыйгалар чиксезлегендә түгел, ә кыска, тыгыз, динамикалы сюжет кысаларында сурәтләнгән конкрет тормыш күренешенә күңелгә нык тәэсир итәрдәй тирән мәгънә сала белүдә икән.

Авылда Бәгърем исемле ятим бала яши. Әтисе, бала дөньяга аваз салганчы ук, фин сугышына китеп, һәлак булган. Әмма ул туачак баласына исем кушарга өлгергән. Әнисе дә җәйге челләдә, кызу печән җыю вакытында, баласын тапкач, күп кан югалтудан үлеп киткән. Бала әбисе—Карт инәе кулында тәрбияләнгән. Яхшы күңелле авыл хатыннары аны күкрәк сөтләрен биреп имезгәннәр. Алга таба да халкыбызның мәрхәмәтлелеген, изге күңеллеген тоеп, инсафлы бала булып тәрбияләнеп үскән. Унике яшеннән урман кисү эшләренә йөреп, үзе тапкан акчага картинәсенә күлмәклек, ә үзенә унике телле, шыңгыр бакалы гармун сатып алган. Хәзер инде ул уналтынчы җәен каршылый, авылдашлары да аны ихтирам итәләр: егет авылның гармунчысы булып танылып килә.

Автор салмак темпта, иплəп һəм жайлап кына безне яшүсмернең эчке дөньясы белəн таныштыра башлый. Һəм бу бик табигый итеп бирелə—жəйге эссе көн уртасында малай Гыймалетдин картка кое казыша, тирлəп-пешеп эшлəгəн чакта башка төрле уйлар да килə. Ə төрле истəлек-уйларның күбесе бергə уйнап-йөреп үскəн күрше кызы Разия белəн бəйлəнгəн булып чыга. Əллə бу Разия безнең егеттəн аз гына олыракмы, əллə бу тарафларда гореф-гадəт дигəнең шундыйракмы—кызыбызны инде туй ясап, күрше авыл кешесенə кияүгə дə биреп жибəрəселəр икəн. Бəгърем бу хəлне үзе дə бигүк аңлап житкерми, аңларга да телəми, бу хəл, əйтергə кирəк, бөтенлəй аның башына сыймый. Житмəсə, аны авылның берданбер гармунчысы буларак, кыз озату мəжлесенə, туйга чакыралар. Шулай итеп, Разиясының үзенə бик кадерле һəм якын икəнлеген аңлый гына башлаган бер мизгелдə, егет, аны гармун уйнап озатып, чит авылның ят бер кешесенə биреп жибəрергə тиеш була.

Туй йоласын башкару—авыл халкы өчен зур вакыйга. Ул жиренə житкереп, матур һəм күңелле итеп үткəрелергə тиеш. Əмма Бəгърем анда күңеле тартканнан түгел, ə авылдашлары сүзен-үтенечен аяк астына салырга ярамаганнан гына килə. Барасы килмəве дə кадерле картинəсеннəн сүз кабатлаттыруы аркылы гына аңлашыла. Бу канəгатьсезлек əңгəмəдə дə сизелə:

«Ул коедан күтəргəн суын читəн буена алып килде. Чабаталарын, оекларын салып какты, кыска жиңле күлмəген дə салып, читəнгə сөйисен сөяп, элəсен элеп куйды да юына башлады.

—Теге Качаган бадарыннан алган күлмəгенне киярсен, яме, канатым.

Бөкресен чыгарып, болдырда кош-кортка болгау болгаткан картинəсе гүя ана үзе белеп эшли торган эшлəрне дə исенə төшереп тору өчен яратылган жан иясе иде...

—Теге Качаган күлмəген киярсен дим, ишетəсенме...

Егет эндəшмəде.

Бəгъремнең кəеф жепселлəре киеренке, кан агышы кызу иде. Үлəн сөтендə яшəреп елкылдап шомарган тырма тешен хəтерлəткəн картинəсе, колакка бераз каткан карчык, бəлəген шапылдаткан арада сүзлəрен өченче мəртəбə кабатлады:

—Качаган күлмəген ки. Чалбарың үтүклəнгəн. Урындык өстендə.

—Белəм.

—Кем баласы дигəндə, шуның баласы диярлəр. Əтиең дə, əниең дə бик ыспай кешелəр иде, мəрхүмкəйлəр. Авыр туфраккайлары жиңел булсын. Яна тəпичеклəренне ки. Спут башындадыр.» *(«Казан утлары», 2000 ел, 9 сан)*

Мондый диалоглар, кайберəүлəр уйлаганча, холыкның, сөйлəмнең колоритын тасвирлау вазифасын гына башкармый—яшүсмернең олы кешедəн сүз кабатлаттырып торуында ук аның барасы килмəве сизелеп тора. Туйда да ул, эчендə буран уйнаса да, карусыз гына тоелгандай, гармунын тартып утыра, əмма кызны атка утыртып алып киткəндə, үзен-үзе белештермəс хəлдə: «Бирмим Разияны! Китмисең!» Кайт, Разия, кайт!» дип илерə, буза куптара, яраткан гармунының күркен аерып, аны читəн казыгына кадап, аерып төшерə...

Кайберəүлəр: «туйда андый хəллəр генə була инде ул», дип əйтер бəлки. Əмма Айдар Хəлим калəме галəти булып тоелган əнə шул вакыйга жирлегендə кечкенə генə могжиза ясый—бу күренеш геройның рухи драматик фажигасенə əверелə. Чыннан да, яшь керсез-тапсыз күңелнең беренче житди жəрəхəте, яралануы бик тəэсирле бирелгəн.

Əсəр һич тə уналты-унсигез яшьлеклəр турында гына түгел. Биредə күңелен кушканча яшəү һəм мəжбүрилек философиялəре үзара бəрелешə, һəм тормышыбызда да əнə шул мəжбүрилек хакимлек иткəнен белə торып, без үзебез дə шул кагыйдəлəр кушуы буенча гына көн итеп күңел кошыбызның канатларына басабыз—очар кошларыбыз күклəргə менə алмый, жирдə ятып кала. Айдар Хəлим—үзенчə яшəү, ирек, мөстəкыйльлек, азатлык идеялəрен күтəреп һəм яклап чыккан шəхес. Шуңа күрə, бу əсəрендə дə аның симпатиялəре гел Бəгърем ягында. Əмма ул тормышның жиңел генə хəл итеп булмаслык яклары да бар икəнлеген дə искəртə. Көмеш телле гармунны казык башына утыртып куйганда да бик ачык күренə бу.

Айдар Хәлим әдәби деталь мәсьәләсендә Шәриф Камал, Әмирхан Еники, Фатих Хөсни, Рафаил Төхфәтуллин традицияләренә таянып, яна ачышлар ясый. Бу хикәясендә дә көмеш телле гармун, сиртмәле кое, эссе көндә эчелгән салкын әйрән, утызменче Айсинның кыланышлары һәм лексиконы, картинәй белән, Гыймалетдин бабай белән әңгәмәләр—берсе дә очраклы гына китерелми—алар барысы да әсәр тукымасына бик табигый, ятышлы үреләләр һәм төп фикергә хезмәт итәләр.

«Казыктагы итальян»—тыгыз сюжетлы, тирән мәгънәле, милли рухыбызны чагылдырган образлы детальләргә бай булган хикәя буларак әдәбият хрестоматияләрендә урын алырдай һәм яшьрәк язучылар өчен тәҗрибә мәктәбе булып хезмәт итәрдәй әсәр.

Фәүзия Бәйрәмованың «Соңгы намаз» исемле романында да яна фикерләрне үтемле чаралар ярдәмендә әйтергә омтылу сизелә. Бүген, бик күпләр замана тәгәрмәченә әшәке ябышкак булып сылана торган алдашу, гаделсезлек, көчсезләрне кимсетү, җәберләү, эчкечелек, наркомания, әхлаксызлык күренешләре белән килешеп, «мина ничек тә ярый, тик үземә генә тимәсеннәр», дип әкәм-төкәм фәлсәфәсен, җайлашу позициясен хуп күргәндә, кинәт кенә трибун әдибәнең гасабилы, ачы авазы яңгырый: «Кешеләр, күрәсезме бу вәхшәт, бу мәсхәрәне?! Ник йоклыйсыз сез барыгыз да!»—дип әйтергә тели ул.

«Соңгы намаз» әсәрен берничә яссылыкта укырга, өйрәнергә, анализларга мөмкин. Биредә авторның милләт һәм дингә карата фикерләре, сәяси карашлары, мөнәсәбәте художестволы, мажаралы әсәр калыбында яктыртыла. Бу хәл авторның уйлап чыгару-фантазия мөмкинлекләренә юл ачып кына калмый, мәсьәлә—проблемаларның куелышын үткенәйтә, идея-мәгънәви функцияләрен көчәйтә төшә.

Кайчандыр бәйсезлек өчен көрәшеп, мәйданнарга чыгып «Азатлык!» дип кычкырдык, телебез чын дәүләт теле булыр, уку йортларында гел ана телебездә сөйләшеп, дәресләр тыңлап, тәрәккыят итәрбез, дип хыялландык. Ләкин бик күп хыялларыбыз тормышка ашмады. Милли хәрәкәт тә сүнә-сүрелә бара. Милли хәрәкәтнең әзме-күпме уңышларыннан файдаланып, яна татар байлары хакимияткә үрмәләде. Ә гади халык хәерчеләнгәннән-хәерчеләнә бара. Газиз балаларыбызны бүген Каф тавы сугышларына алып китеп, гомерләрен кисәләр. Әйләнә-тирәбездә яна афәтләр—эчкечелек, наркомания, башка төрле бозыклыклар, спид үләтләре котырына. Халкым, кая барасын?! Бу хәлләрдән чыгу юлларын эзләп кара! Бөтен күңелең белән Исламга хезмәт итә алсаң, Аллаһы Тәгаләгә калган гомереңне багышлый алсаң гына, бу афәтләрдән котыла алырсың!

Менә шушы фикерләр «Соңгы намаз» романының нигезенә салынган—бу төп идея әдәби һәм публицистик чаралар ярдәмендә кат-кат һәм бик ачык әйтелә. Шулай ук әсәрдә татар мәктәпләре-мәдрәсәләре, аларның кадрлары, информация чараларындагы алдашу, шымчылык шартларында кеше хокуклары, ирекләре чикләнү һәм бүгенге милләт тормышындагы күп төрле башка, күбесенчә тискәре күренешләр дә шактый ук дәлилләнеп күрсәтелә.

Дөресен әйткәндә, Фәүзия Бәйрәмованың бу карашлары артык зур яңалык булып та тоелмый. Үзенең күп санлы чыгышларында һәм мәкаләләрендә болар турында ул инде күп тапкырлар сөйләгән иде. Әмма әлеге очракта автор көннең иң кайнар проблемаларына тагын да якынрак килә алган, һәм соңгысы әдәбиятчылар өчен аеруча кызыклы—ул матур әдәбият чараларын бу очракта турыдан-туры эшкә җигә.

Әлбәттә, «йөзеннән нур чәчеп торган, бөтен килеш-килбәте белән затлы патшабикәләрне хәтерләткән» Мәрьямбану образын үрнәк, унай геройларның бик уңышлысы иканлеген әйтми үтү һич мөмкин түгел. Аны Изге Мәрьям-ананың бер ассоциатив чагылышы дип әйтсәң дә ярый торгандыр. «Мәрьямбану бүлмәгә ак сын кебек килеп керде. Өстенә ак плащын кигән, башында ак берет, кара чәчләре, анда ябылып ятарга теләмәгәндәй, дулкын-дулкын булып җилкәләрен кочып алган... озынча мәрмәр йөзе тагын да агарып киткән» *(«Мирас», 2001 ел, 1 сан).*

Нәкъ шушы сокландыргыч һәм идеал рәвештә формалаштырылган героиня карашларында авторның дөньяны аңлау-аңлату юнәлешендәге үз фәлсәфәсенең

үзеген дә табып була:

«Мәрьямбану, гаҗиз булып, тирә-ягына карады. Менә бу урам тулы исерекләр, яшь-яшь наркоманнар, зиначылар, угрылар, җинаятьчеләр—алар да дөньяның патшасымы? Яки дөньяның патшасы, Аллаһының кадерлесе булып яратылып та, ялгыш юлга кереп китеп, харап булган кешеләрме? Беркем дә, мин ялгыш юлга керәм, дип, махсус адашу, бетү ягына китми бит, хак белән ялгыш арасында чик бик нечкә, кеше күнеле исә аннан да нечкә. Ул Аллаһы Тәгалә тарафыннан бәхеткә, иман белән яшәргә көйләнгән, тәртипле тормыш өчен программалаштырылган. Кан күзәнәкләренә мәңгелек бәхетнең сере, формуласы салынган. Аллаһы үзенең нурыннан кешенең җанына өлеш чыгарган, димәк, кешенең җанында Аллаһының нуры бар. Ул нурга сүнәргә, корым белән капланырга ирек бирергә ярамый, шул нур белән бергә Аллаһының тәэсире, рәхмәте дә киселергә мөмкин» (шунда ук).

Романдагы геройларның һәммәсе дә әнә шул йә кала, йә сүнә торган Изге нурлы чиккә барып теләлгәннәр. Үзен Аллаһы Тәгаләгә, Ислам диненә багышлап кына Мәрьямбану күнелендә рухи яктылыкны саклап кала—әмма бик авыр корбаннар бәрабәренә: Чечняда газиз улын югалткан анага әле тагын сөйгән ире белән дә, яраткан эше белән дә хушлашырга туры килә. Аның ире, заманында милли хәрәкәттә башлап йөргән, кулыннан эш килә торган Тимербулат изге яктылыктан мәхрүм кала—ничектер, көтмәгәндә-уйламаганда, бик җинелдән генә явыз, кара эчле сихерче Римма тозагына килеп каба, шигарь-мәнфәгатьләрен генә түгел, сөйгән хатыны Мәрьямне дә югалта. Күнеле белән гел яктыга тартылган гөлдәй матур кыз Ләйләне «дин юлына керә бу», дип акылын җуйганга санаучылар—эчкечелектән башы чыкмаган, базар юлын таптаудан башканы белмәгән әнисе аны җүләрләр йортына илтеп яптыра. Анда кирәкмәгән көчле уколлар биреп, сәламәт баланы тәмам хәлсезләндерәләр, мингерәүләтәләр. Якты нурлы тормыш өчен яратылган тәрбияле татар егетләренең хәлләре исә тагын да аянычрак: Мәрьямнең улы Әхмәт Чечняда федераль армия солдатлары тарафыннан үтерелә, тик аны «чеченнар үтерде» дип игълан итәләр. Шул вәхшилекне күреп торган дусты Хәйдәрне чын дөреслекне әйтмәслек итеп каты кисәтеп куялар. Караңгылык хәшәрәтләре дә байтак бу әсәрдә: шуларның берсе—Хәррис Фабарисов дигәне—намуслы кешеләрне шик-шөбһәле пәрәвез җепләренә урап, шымчылык итеп йөри. Ә инде Римма һәм аның әллә кемнән табылган малае Вова, спид чире йоктырып, тереләй черергә дучар ителәләр...

Менә болар барысы да җыелып өелгәч, күңелгә шактый авыр юшкын утыргандай була. Бөтен әйләнә-тирәбез мондый пычрак белән тулгач, җүнле итеп, кешеләрчә яшәр өчен бер дә өмет калмый ахрысы. Алай ук түгел шул, бердәнбер юл—Аллаһы Тәгалә юлы бар бит әле. Әсәр ахырында эчендә яшәгән кешеләре белән күп катлы йортның җимерелеп төшүе, әлбәттә, күптән түгел Америкада, Рәсәйдә булган фаҗигаләрне дә искә төшерә, әмма романда ул күбрәк символик мәгънәдә бирелә. Барыбызга да һәлакәт яный, тик котылу чарасы бер генә—ул иман юлына, Аллага табыну юлына басу, дигәнне аңлата бу. ...Әмма күңелгә утырган юшкын никтер юылмый... Без бит, барыбер, шушы гөнаһлы җирнең бәндәләре...

Әсәрдә Дин үзәккә куела, тормышның төп факторы дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Мәрьямбану үз улының үлеме белән дә килешкәндәй була. Тик мөселманны мөселман үтерде, дигән уй белән генә һичничек килешә алмый. Кеше гомере һәм дин альтернативасында өстенлек соңгысына бирелә.

Үзем гомер иткән чорда *(ә мин инде җиде дистәне тутырам)* татар матур әдәбиятында динне бу дәрәҗәдә пропагандалаган, яклаган әсәрне күрергә туры килгәне юк иде әле. Әлегә кадәр татар әдәбиятының, шул исәптән прозасының, магистраль юллары башка иде: ул мона кадәр яшәү чыганакларын, бөеклек һәм гүзәллекне тормыштан, кешенең үзеннән эзләде. Милли әдәбият кына түгел, ә дөнья классикасы да моның шулай икәнен күп мәртәбә раслады.

Озаккарак киткән сүземне йомгаклап, тагын бер генә нәтиҗә ясап куйыйм: «Соңгы намаз» исемле яңа романны мин үземнең принципиаль позицияләреннән

бер карышка да чигенмәгән Фәүзия Бәйрәмованың халыкны, милләтне кисәтүе һәм рухи сафлыкка чакыру юнәлешендәге бер кыю адымы дип аңладым.

Ил һәм җәмгыять тормышында нык тамыр җәйгән һәртөрле тискәре күренешләргә башка татар язучылары да үз мөнәсәбәтләрен белдерергә тырышалар. Тәҗрибәле прозаик Вакыйф Нуруллин «Хыянәтчеләр» исемле повестенда *(ул «Мирас» журналының 1999 һәм 2000 елларда чыккан саннарында басылды)* бюрократия дөньясының гади халык белмәгән, ямьсез, кыңгыр һәм сәер якларын ачып сала. Карьерчы бюрократ үз алдына ачык максатлар куеп яши: үзе өчен җайлы, уңайлы, тыныч шартлар әзерли һәм башкаларны этеп-төртеп, булдыра алганда, тегеләрнең башларына баса-баса югарыдагы җитәкчелек кәнәфиләренә ыргыла. Тик моны битлек кимичә эшләп булмый: халыкны яратучы, аның мәнфәгатен кайгыртучы булып кыланырга кирәк, югыйсә юлыңны тиз бикләрләр, кәнәфиеннән очып төшкәненне сизми дә калырсың!

Авторның үзенә карьерист Шәриф Шәкүровичның чирканчык роленә керергә, аның хамелеон түмгәгенә басып фикер йөртергә дә туры килә. Һәм, әлбәттә, мондый очракларда уртак сөйләм алымы бик активлаша. Нәтиҗәдә, түбән зәвыклы, примитив, әмма үзенә дигәндә, шактый ук елгыр һәм житез бер адәм актыгының җитәкчелеккә омтылу юлындагы уңышлары-уңышсызлыклары, ниһаять, һәлакәте үтемле, аңлаешлы, нәкъ шушы типка туры килә торган алымнар, чаралар ярдәмендә күрсәтелә. Вакыйф Нуруллинның бу әсәре соңгы еллар әдәби җәмәгатьчелегебез инде онытып бетергән «сатирик проза» дип аталган тармагының яшәргә хокукы зур икәнлеген раслады. Әйе, тәнкыйть рухы әлегә сүнеп бетмәгән икән. Әдипләребез аның ахыр чиктә гаделлек, яхшылык, гүзәллек тантанасына алып килергә тиешлеген дә истә тоталар. Тик ни өчендер, безнең тәнкыйть пафосыбыз һәм аның көйдергеч ялкыннары яндырыласы әйберләрне замана агышы үзе тормыш сәхнәсеннән алып куйгач кына көйри башлый һәм ныклап кабынып китә. Фәүзия Бәйрәмова кебек, үз вакытында һәр яманлыкка бармак янап сөрән салучыларыбыз, кызганычка каршы, бүген бездә юк дисәң дә була.

Әмма мәсьәләнең икенче ягын да онытып бетермәскә иде. Илебездә, җәмгыятебездә күптән түгел генә булып узган елларны, шул чор хәлләрен бүгенгедән чыгып каһәрләү прозабызның төп тенденцияләренең берсенә әверелеп килә. Элеккеге совет, партия номенклатурасы кешеләрен, уртакул җитәкчеләрне, колхоз башлыкларын—барысын да бушбугазлар, эшлексезләр, үз кәеф-сафалары өчен генә гомер итүчеләр, пычрак җаннар итеп күрсәтүне, әлбәттә, беръяклылык дип һәм авторларның объективлыкны санга сукмый башлаулары дип кенә бәяләп була. Кызганыч ки, нигездә уңышлы гына эшләнгән әсәрләрдә дә андый типларның катнашулары лазем икән.

Дәлилләү өчен мисалларны озак эзләп йөрисе дә юк, әле генә «табадан төшкән» романнарга, повестьларга гына мөрәҗәгать итегез—сез андыйларны байтак очратырсыз: «Өтелгән мәхәббәт» *(Якуб Зәнкиев)*, «Бәхетсезләр бәхете» *(Фоат Садриев)*, «Саташулы таң» *(Факил Сафин)* һ. б. кайбер әсәрләрдә әлеге зарурилык азмы-күпме дәрәҗәдә сюжет логикасы белән дәлилләнсә, мондый юньсез җитәкчеләрнең бөтенләй башка темага язылган әсәрләргә килеп керүләрен ничек аңлатырга *(мәсәлән, Гөлчәчәк Галиеваның «Тулгак» дигән повестена)*? Кыскасы, инде әйләнеп кайтмаячак заманның тәртипләрен һәм кешеләрен иркенләп һәм рәхәтләнеп тәнкыйть итү бүгенге авторларыбызга һәр тарафтан оттырышсыз, һич кенә дә үзләренә җил-янгыр тидермәячәк кәсеп яисә мода булып тоела башлады. Әйе, һич югында, модасыннан булса да артта калмаска иде... Бу хәл бүре килеп, сарыкларны ботарлаганда, мыштым гына бүрәнә артында посып утырган агайларның, теге явыз урманга кереп югалуга, дәррәү генә, күсәк болгап, сикереп чыгуларын хәтерләтте.

Якуб Зәнкиев һәм Фоат Садриев күләмле яңа әсәрләрендә үзләренең бай тормыш күзәтүләрен, тәҗрибәләрен укучыларга житкерергә телиләр. Аларның әйтәсе сүзләре күп, образлы фикерләү сәләтләре дә, роман кебек олы конструкцияне традицион, ягъни моңа кадәр хуплап кабул ителгән әдәби таләпләргә туры китереп эшләү осталыгы да сизелеп тора. «Өтелгән мәхәббәт»

романында Якуб Зәнкиев Себер якларында гомер итүче милләттәшләребезнең хәлләре-яшәешләре белән таныштыра, шул төбәк халкының гореф-гадәтләре, сөйләм үзенчәлекләре, тормыш итү тәртипләре дә кызыксыну уятырлык итеп тасвирлана. Шул шартларда үсеп формалашкан герое Зиннур образына Якуб ага Зәнкиевнең үзенең олы тормыш юлында күргән-кичергәннәренең байтагы кергәндер, дип уйларга да нигез бар.

«Бәхетсезләр бәхете» дип исемләнгән романның герое Ирек, автор Фоат Садриевның үзе кебек үк, Татарстанның көнчыгышында урнашкан районнарның берсендә яши, читтән торып укып, югары уку йортын тәмамлый, баштарак мәктәптә, аннан соң редакциядә, район партия комитетында эшләп йөри, язучылык белән дә шөгыльләнә, һәм үз тормышының асыл мәгънәсен дә тик иҗат эшендә күрә башлый. Әдип, үзе шундый вакыйгаларда нык кайнагангамы икән, авылдагы, райондагы хуҗалык һәм сәяси механизмның уңай һәм тискәре якларын, яшерен серләрен, хикмәтләрен искиткеч яхшы белә.

Димәк, бу яна әсәрләрнең һәр икесенең дә нигезенә нык өйрәнелгән тормыш материалы салынганлыгы бәхәссез. Җанлы һәм аңлаешлы телдә язылганлыктан, укучыларына тиз барып ирешерләр, дигән өмет тә уяна. Шулай да, тәнкыйтьнең жиз иләгенә салып иләргә керешсән, иләк төбенә утырып калачак ком-ташларның да хәйран күп булачагын тәҗрибәле әдипләр үзләре дә шәйлиләр булыр. Әсәрләрне җыйнаграк итеп эшләү турында да утырып уйларга кирәктер безгә.

Реалистик әдәбият традицияләре никадәр генә көчле булмасын, аның казанышлары һәм алымнары татар прозасында үзләренчәрәк юл салучы әдипләрне канәгатьләндереп үк житкерми. Һәрберебезнең язмышы кайдадыр алдан билгеләнеп, теркәлеп куелганлыгын, Илаһи Бөек зат янсә Табигать-ана каршында фани дөньябыз мәшәкатьләренең чиксез вак һәм әһәмиятсез икәнлеген сизенә башлаган әдипләр шушы юнәлештә әдәби тәҗрибәләр ясарга керештеләр. Барысы да галәми көчләр тәэсиреннән килә, ә без үзебез исә галәм субстанциясенең җанлы кисәкләре-кузәнәкләре дип аңлатучылар да табылды. Алар баштарак үзләренең хыялый иҗат дөньяларына аваздашлык эзләп, аеруча тиз ышанучан катламнарга—балалар һәм яшүсмерләр аудиториясенә мөрәҗәгать иттеләр *(мәсәлән, Җәүдәт Дәрзаман—«Бизмән йолдызлыгы», «Ник кирәсез төшләремә?»)*.

Тора-бара, реаль көнкүреш шартларында хәрәкәт итсәләр дә, акыллары бераз гына «авышкандайрак» тоелган һәм хакимнәргә, һәртөрле боерык-кушуларга баш иеп яшәргә күнеккән гадәти Рәсәй кешеләренә караганда баерак рухи тормыш белән яшәүче, үзләренең иманнарын яклап, бәхетләре, мәхәббәтләре өчен көрәшә белүче каһарманнар, бигрәк тә Нәбирә Гыйматдинова героинялары пәйда булды. Бу кешеләрнең тамырларында нинидер сихри көчләр ага, алар без әлегә аңлап ук житкермәгән серле дөнья тәэсирләрен тоеп яшиләр. Үтә нечкә күңелле бу авторның хисләренә буйсынып тибрәнүче сизгер каләме бүләк иткән «Сихерче», «Кыргый», «Пәри утарында», «Күке төкереге», «Ак торна каргышы» әсәрләрен хыялый романтикага һәвәскәррәк укучылар аеруча яратып кабул итте. Әдәби җәмәгатьчелек бу күренешне талантлы әдибәнең нәкъ үзенә лаеклы табышы, олы казанышы дип билгеләде.

Әмма ни кызганыч, «Икебезгә дә авыр» исемле өр-яңа повестенда үзенчәлекле авторыбыз иҗатының иң күркәм сыйфатларының—укучы күңеленең иң нечкә кылларына сак кагылуның, һәр күренешне жентекләп, тәфсилләп эзерләүнең, геройларның, персонажларның уй-фикер, эш-гамәлләрен ышандырырлык итеп һәм логик дәлилләүнең эзе дә калмаган. Н. Гыйматдинова бу юлы прозабызны иңләп алган чирләргә—ничек тә булса фаҗигале сенсацияләр эзләү һәм табу, күпвакыйгалылык, хәл-вакыйгаларның бик тиз үзгәреп тору ыгы-зыгысын күрсәтү шаукымына бирелгән. Мондый кабаланып, ашыгып язу «Боларның барысын да автор үз күңеле аша үткәрде микән?» дигән сорауны да уята. Кыскасы, болар берсе дә авторның үз «куяннары» түгел.

Хыялый, мистик әдәбият тарафдарлары көннән-көн арта бара. Бүген алар сафына оста язучылар өстәлде: Әхәт Гаффар *(«Богау»)*, Радик Фәизов *(«Тәңре хөкеме», «Гаделлек иясе»)*, Галимжан Гыйльманов *(«Албастылар»)*. Болары инде

балаларның үзләре өчен дип түгел, ә туксанынчы еллар экстрасенслары тарафыннан һәртөрле уйдырмаларга тиз бирешүчән итеп тәрбияләнгән яңа буын укучыларына, ягъни олыгая баруларына карамастан, бала акылы чыгып житмәгәннәргә төбәбрәк язылган әсәрләр. Дөресен әйткәндә, бу хыялый повестьларны үзем дә, шунда сурәтләнгән хәлләргә ышанасым килгәндәй, рәхәтләнеп укыдым. Һәр өч авторның цивилизация кулы тимәгән кыргый һәм кара урманнары әллә нинди серле, шомлы бөеклекләре белән күңелләребезне жәлеп итә. Гап-гади кешеләр янында яисә шуларның аңнарында-уйларында һәртөрле Ияләр, шүрәлеләр, албастылар жанланалар, кеше тормышына тыкшыналар, аны юлдан яздырырга чамалыйлар. Тормыш бертөрлелегеннән вакытлыча гына арынып, хыялланып аласы килгән укучылар мондый әсәрләрдән үзләренә ниндидер рухи жим табып, канәгатьләнә алалар.

Сүзебезне гомумиләштерү ягына күчебрәк әйтсәк: моннан 10-15 ел элегрәк, әдәбият-сәнгать дөньясында һәртөрле чикләүләр алып ташлангач, татар әдәбияты югарыга кинәт күтәрелеп китәр әле дигән өметләребез зурдан иде. Мәгълүм ки, ул өметләр акланмады. Татар прозасы һаман да штамплар кысасыннан, элеккеге әдәби алымнарның эчпошыргыч бертөрлелегеннән арына алмый интегә. Прозаикларыбыздан күбесенең яңа шартларда яңача ижат итәргә әзер түгеллеге анлашылды. Дөрес, бу тәнкыйть сүзләре, классик проза тарафдарларының һәркайсына кагылмый. Бүген Миргазиян Юныс, Аяз Гыйләжев, Айдар Хәлим, Фәнис Яруллин, Мәгъсүм Хужин кебек каләм осталарының элекке классик әдәбият казанышларына таянып, искиткеч камил әсәрләр ижат иткән көннәре. Телгә кинаяле сурәтлелеккә зур игътибар, сюжет жыйнаклыгы кайбер башка әдипләребез ижатында да сизелә *(Марсель Галиев, Флүс Латыйфи һ. б.)*

Әлбәттә, бер мәкаләдә проза дингезенең бар киңлекләре, тармаклары, утраулары хакында сөйләп чыгу мөмкин түгел. Алдыбызга андый бурычны куярга жөрьәт тә итмәдек. Шулай да ижади хыял очышы ихтыярына бирелеп, яңа жанр формалары, яңача әдәби алымнар, кызыклы оригиналь сурәтләр һәм образлар ярдәмендә әдәбиятка жанлы сулыш өреп, аны терелтергә, күтәрергә мөмкин икәнлегенә инанучы әдипләрнең пәйда булулары куандыра. Бу урында мин иң беренче чиратта Зөлфәт Хәким һәм Рафаэль Сибатны күздә тотам. Дөрес, боларын да әдәби форманы төрләндерүдә пионерлар дип атап булмый. Мәсәлән, бу өлкәдәге игелекле эшне тәжрибәле әдип Әхсән Баянов инде күп еллардан бирле алып бара. Аларның һәркайсы, әсәрләрендә заман темаларын киң яктыртып, үзләренең мөстәкыйль һәм кабатланмас ижат сфераларын табарга өлгерде. Бу шәхесләрнең ижади эзләнүләрен бер селтәнү белән ниндидер экзистенциализм, модернизм яки һ. б.—изм дип йөртелүче башка тартмаларга урнаштырып куючылар да табылыр. Әмма бүген бу ижат дөньяларының формаль классификациягә генә түгел, ә конкрет өйрәнүгә һәм махсус тикшерүгә мохтаж икәнлеге дә ачык күренә.

Әйе, яңа гасырга кереп баручы татар прозасының традицион казанышлары да әлегә югалып ук бетмәгән, яңалыкка омтылышы да сүрелмәгән кебек, теләсәләр, жир жимертеп эшләрлек язучыларыбыз да бар. Тик күңелне нидер тырный, нидер шөбһәгә сала.

Яңа туган гасырда һәркайсыбызның үзебезне татар дигән олы милләтнең үсешенә булышырлык затлар итеп күрәсе килә. Әдипләребез дә милләт гамен кайгыртып һәм Кеше булып яшәү өметләренә ышаныч уятырдай әсәрләр бирерләр әле.

Ризван Хәмид

# ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕ МИЛЛИМЕ?

1982 елда Мәскәүнең ин күренекле сәнгать белгечләренең берсе И. Л. Вишневская «Литературная газета»да: «Хәзерге чор СССР драматургиясенең торышын бүгенге татар драматургиясенең биеклеге билгели»,—дип язып чыккан иде. Ә шуның алдыннан гына ул миннән—бу ханым Югары әдәби курсларда безнең белән драматурглар секциясен алып бара иде—«татар драматургиясе ничек алай кинәт кенә зур уңышларга ирешә алды?» дип сорады. Мин моны үземчә болайрак аңлатырга тырыштым: чөнки без моңарчы күбрәк урыс драматургиясенә ияреп килдек—шунлыктан драматургиябез нигездә икенчел әдәбият булып кала бирде, ә хәзер без үз тамырларыбызны эзли башладык, татар менталитетын, татарның милли хисләрен кыюрак файдаланырга күчтек, әсәрләребезне «мәңгелек» сюжетларга корганда да, милли үзенчәлекләребезгә өстенлек бирергә омтылабыз, әмма шул ук вакытта бар халыкларны да тирән борчыган уртак зур проблемаларны да онытмыйбыз. Шушы үзгәрешләр безнең иҗатыбызга карата кызыксыну тудырадыр бәлки? Мөхтәрәм ханым ул чагында минем мондый аңлату белән килешкән кебек тоелды, һәрхәлдә, каршы бәхәс күтәрмәде. Ләкин, еллар үтү белән, ул чакта «миллиләшүне» бик сай аңлаганмын икән, дигән фикерем көчәя бара хәзер...

Шулай да була: илнең бөеклеге, аның халыкара абруе күтәрелү яки икътисадының югары уңышларга ирешүе мәдәниятенең дә чәчәк атуын тәэмин итәргә тиеш шикелле. Ләкин еш кына күзгә ташланып торган тышкы иминлек аның эчке рухиятенең халәтенә туры килми. Бер-ике саллы мисалга игътибар итик.

XVI гасыр башларында Испания дәүләте дөньяда иң куәтле державага әверелә: моңа ике зур тарихи вакыйга этәргеч фактор буларак хезмәт иткән. 1492 елда испаннар көчле илбасарларны—мавырларны—үз җирләреннән куып чыгаралар, гарәпләрнең Пиренеядәге Гранада дип аталган соңгы әмирлекләре яшәүдән туктый. Ә шул ук елның 12 ноябрендә даңлыклы диңгез сәяхәтчесе Христофор Колумбның «Санта-Мария», «Нинья» һәм «Пинта» исемле өч корабтан торган экспедициясе аңарчы дөньяда бар дип тә уйланылмаган Яңа Дөньяны—Американы ача. Үз исеме белән аталырга насыйп булмаса да, бу факт Колумбны мәңгегә үлемсез итә, ә хәерчелектән башы чыкмаган Испаниягә, меңәр тонналап алтын китереп, кинәт бай дәүләткә әйләнергә мөмкинлек бирә. Ана кадәр шыксыз гына бинада тәхеттә утырган король Карл I озакламый, бөтен Ауропаны шаккатырып, берсеннән-берсе бай һәм зиннәтле сарайлар салдыра һәм, күп тә үтмәс, ул үз титулына «герман императоры» дигән дәрәҗәле тагын бер исем өсти! Чөнки, нәфес ашаганда көчәя: Карл I немецләрнең бар җирләрен басып ала һәм аларның зиннәтледән-зиннәтле таҗларын үз башына яраклаштыра. Менә шул чагында испаннар: «безнең империядә беркайчан да кояш баемый», дип шапырына башлыйлар. Чыннан да, Ауропадагы җирләрендә кояш батып өлгергәнче, Америкадагы чиксез колонияләрендә кояш калка бит!

Илнең мәдәнияте чәчәк атсын өчен тагын ни җитми соң?! Юк, ике кояш берьюлы калыкмый икән шул: нәкъ шул чорларда испан культурасы, сазлык тынлыгын хәтерләтеп, йокымсырап ята. Әмма «бәхетләренә», озакламый бер дә батмастай тоелган кояшлары сүрелә башлый: башта, 1588 елда аларның «Җиңелмәс Армада» дип аталган флотилияләрен тулаем диярлек Ирландия янында су төбенә җибәрәләр, ә коры җир гаскәрләре берьюлы дистә-дистә меңәрләп әле французлар белән, әле инглизләр белән булган сугышларда кырылып ташлана... Әнә шул орышлар нәтиҗәсендә империянең йөзек кашы саналган Голландия дә суверенитет яулый (1609). Бу вакыйгаларны бик озак дәвам итәргә мөмкин, әмма безнең максат ул түгел: нәкъ шул чорда испан сәнгате кинәт чәчәк ата башлый! Аеруча, испан драматургиясе һәм театры! Моны күзаллау өчен Сааведра Сервантес (1547-1616), Лопе де Вега (1562-1635) һәм Тирсо де Молина (1583-1635) кебек әдәбият гигантларының исемнәрен атау гына да җитәдер.

Ничек анларга моны? Империя тантана иткәндә испаннарның сәнгатьләре бөтенләй булмаган дияргә ярый, ә империя кояшы батканда—алтын гасыры башлана?! Җавапны империянең төп асылыннан эзләргә кирәк: чөнки аларның корольләре борынгы Эпиктетның «Дөнья—театр, ә кешеләр—анда актерлар» дигән зирәк сентенциясен үз дәүләтләренең төп идеологиясенә әверелдергәннәр икән! Халык—актер гына булгач, режиссер да кирәк бит инде?! Бу рольне корольләр үз кулларына алалар һәм, сез—испаннар—дөньяның кендеге, дип рәхәтләнеп көлә-көлә, аларны дөнья «сәхнәләренә» менәрләп-менәрләп куып йөртәләр. Алар рольләрен әйбәт башкарсалар, ягъни шәп сугышсалар—бүләклиләр, ә инде сәләтсез артистлар булып чыксалар—үзләренә үпкәләсеннәр! Үз «бөеклеген» шиккә алырга башына да китермәгән гади халык үзенең шамакай ролен генә башкаруын сизми дә! Нилектән дигәндә, чын театрдагы кебек афишалар да, тамашачылар да юк (корольләрне һәм аларның иярченнәрен санамаганда, әлбәттә)—спектакльгә бөтен халыклар җәлеп ителгән ич! Сервантеслар иң беренчеләрдән булып менә шушы империя ташы астына тирән яшерелгән хакыйкатьне анлый башлыйлар—алар шуна күрә җуелмас әсәрләр иҗат иткәннәр дә!

Ә әлеге «комедиантлар» империясенә буйсындырылган халыкларның мәдәниятләре, шул исәптән, драматургияләре белән эш ничегрәк торган соң? Колониаль изүгә дучар булган Португалия мәдәниятенең тарихы бу яктан караганда бик гыйбрәтле. Әйтергә кирәк, португалларның драматургиясе испаннарга караганда чагыштырмача алдарак шактый югары дәрәҗәгә ирешкән була инде. Үз театрларына нигез салган Жил Висенте (1470-1536) һәм аннан сонрак килгән Франсиско Са де Миранда (1485-1558), Луиш де Камоэнс (1524-80), Антонио Феррейра (1528-1569) кебек дөньякүләм танылган бөек шагыйрьләр һәм драматурглар испаннар уянганчы ук үз милли театрларының түбәләрен алтын баганалар белән биек итеп күтәреп куйган булалар. Ләкин, бәхетсезлекләренә, комсызланып беткән Испания империясе 1581 елда күршеләрен канга батырып басып ала һәм 60 кына ел (1581-1640) үз кулларында тотып тора алса да, сон була инде. Португалия театрының нигезенә мәнге төзәлмәслек итеп балта чабыла! Империяләрнең барысына хас булган бер уртаклык бар—алар басып алган җирләр хуҗасының мәдәниятен юкка чыгаруны беренче максат итеп куялар! Испания короле Филипп Икенченең шовинистик әмере бераздан гамәлдән чыгарылса да, алтмыш еллык изелүдән сон Португалия сәхнәләрендә бик күп вакытлар буена бары тик испан пьесалары яисә испан телендә язылган португал әсәрләре генә бара әле. Шулай да, португал драматургиясе, испан драматургиясе белән бергә, ике зур милли сәнгать булып бөтен дөнья культурасының алтын фондына мәнгегә кереп кала.

Шушы тарихи экскурстан сон күнелдә бер житди сорау туа: драматургиянең миллилеге нәрсәдә чагыла икән сон? Бу сорауны мин бүгенге көндә драматургиябездә җигелеп иҗат итүче унбишләп язучыга биреп карадым. Аларның җаваплары бер үк диярлек булды—үз телендә яз, үз халкын турында яз, үз халкына бар сәләтенне бир, шул булыр иҗатыннын миллилеге! Юк-бар белән башынны катырма—велосипед уйлап табылган бит инде, янәсе... Дөрес, бер-ике драматург безнен халык әдәби-музыкаль әсәрләрне ныграк ярата—миллилек шулдыр, бәлки, дип тә өстәде. Чыннан да, бәлки шушыларны яхшы белү җитәдер? Әмма... «соцреализм»нын идеологлары бер дә юкка гына «творчество должно быть национальной по форме, социалистической по содержанию» дип уйлап чыгармаганнар ич?! Социалистик сәнгатьнен (драматургияне дә кертеп) «миллилеген» әнә ничек оста конкретлаштырган булганнар! Һәм шушы катгый таләпне аксиома итеп кабул итмәүчеләрнең башлары җилкәләрендә озак йөрмәгән хәтта! Уйландыра торган факт бу. Ә безнең драматургларның күбесе: «юк, уйланганым булмады и уйланмаячакмын да!»—диде...

Ә—зерә!

Бик үк тирәнгә чумып батмас өчен, кыскача гына драматургиянең жанр буларак ничек барлыкка килүен һәм үсүен искә төшерик. «Көнбатыш һәм Көнчыгыш культуралары, нигездә, үз халыкларынын милли уеннарыннан, милли мифларыннан, милли мәзәкләреннән үсеп, бүгенге югары дәрәҗәләргә күтәрелгәннәр. Милли театрлар һәм драматургияләр өчен беренче кирпечләр булып, итальяннарда—ателлана, дель арте; французларда—миракль, фаблио, фарс, соти; немецләрдә—фастнахтшпиль,

шванк; кытайларда—йөз уен, сяошо; японнарда—кегэн, екеку, саругаку; бенгальләрдә—джатра, шом шикелле милли уеннар һәм әсәрләр хезмәт иткән. Бары тик шунын аркасында гына аларнын һәрберсе үзләренен чын милли драматургияләрен һәм театрларын булдырып, бөтен дөнья алдында үз халыкларын борынгы культуралы һәм булдыклы халыклар итеп таныта алганнар!

Сүз башында танылган Мәскәү белгеченен безнен драматургиябезгә бик югары бәя бирүе искәртеп үтелгән иде. Чынбарлыкта безнен татар драматургиясе Көнбатыш һәм Көнчыгыш драматургияләре арасында нинди рәк урын тота икән? Кайсына тартылабыз? Әллә берсенә дә охшамаган мөстәкыйль урын билибезме? Дөньякүләм мәдәнияткә күпме өлеш керткәнбез?

Һәр татар зыялысын кызыксындыра торган бик житди сораулар болар: һәр эштә конкретлык таләп иткән кырыс заман килде—гомуми жаваплар белән генә котылып булмый. Чөнки киләчәк үсешебезнен төгәл кыйбласын да ачыкларга кирәк!

Беренче карашка, мәскәүләр шундый искиткеч бәяләр биреп ятканда, бәхәс кузгатунын ни кирәге бар, дигән гажәпләнү туу мөмкин. Әнә—«үз милли театрын булдыра алган халык—цивилизациянен ин югары ноктасына күтәрелгән милләт ул!»—дип язган ич философлар философы, бөек немес улы Гегель! Ә без менә тиздән милли театрыбызнын йөзьеллыгын тантаналы бәйрәм итәргә әзерләнәбез! Ә инде милли драматургиябез туганга быел хәтта 115 ел тула: татар телендә ин беренче пьесаны Габдрахман Ильяси 1887 елда ук язган һәм «Бичара кыз» дип аталган. Тик анын ижат жимеше чыннан да «бичара кыз» хәлендә яшәргә мәжбүр ителә, чөнки урыс хөкеме белән 1906 елга чаклы татар халкына үз милли театрын ачу катгый тыела. Португалларга әнә бары тик 60 ел гына чит кавем изүе астында яшәргә туры килә—үзләренен дөньякүләм дәрәжәгә күтәрелеп өлгергән милли драматургияләрен чүт кенә югалтмый калалар, дидек бит. Ә без 1906 елга кадәр андый «рәхәтлекне» өч гасыр ярымнан артык гомер татып яшәдек! Шул арада безнен халык тамашаларны тәмам сагынып беткән булган, ахрысы! Ул кинәт буа ташыгандай халәт кичерә—милләтебез 115 ел эчендә драматургиябезгә, минем кара исәп белән, 300 дән артык язучы үстереп бирә! Ә бүгенге көндә жин сызганып эшләп яткан драматургларыбыз саны житмешкә якын!

Белеп тору өчен: узган гасырнын туксан жиденче елында республикабызнын Мәдәният министрлыгы яна пьесалар конкурсы оештырган иде—шунда әле генә «кайнар табадан төшкән» житмешләп әсәр катнашты! Хәзерге вакытта да ел әйләнәсенә шул ук кадәр санда яна пьеса языламыйдыр дип кем кистереп әйтә ала? Дөрес, арабыздан вакытлы-вакытсыз китүчеләр дә, бу жанрдан читләшүчеләр дә юк түгел. Әмма, ничек кенә булмасын, халкыбызга гел-гел яна сәләтләр үстереп торуы өчен рәхмәт! Рәтләребез әле дә тыгыз—республикабыздагы 12 театрга (читтә эшләп ятучылар белән—15) бер алайга торырлык драматурглар сафы бар сәләтләрен биреп жаны-тәне белән ижат итә!

Мин еш кына үз хәлебезне Америка драматургиясенен бүгенге хәле белән чагыштырам. Нишләп дигәндә, алар да үзләренен чын милли театрларын нәкъ без башлаганда төзергә керешәләр, төгәлрәк әйткәндә—бездән дә сонрак, егерменче гасырнын егерменче елларында гына. Ә инде бүгенге көндә аларнын милли драматургиясе дөньякүләм драматургиянен ин алгы сафында атлый! Юджин О, Нил, Артур Миллер, Теннесси Уильямс, Эдвард Олбиларнын исемнәре Жир шарынын бөтен сәхнәләрен менә ничә дистә еллар инде космик кораблар шикелле урап оча... Ә бит Америка театрлары анарчы Аурупа язып биргән пьесалар белән канәгать булып, кайгы-хәсрәт белми эшләп яткан. Хәзер исә Аурупа үзе американнар исәбенә яши. Эш нәрсәдә икән сон?! Эш—үз театрларынын чиренә кырыс сораулар аша дөрес диагноз куеп, нәкъ кирәкле даруын таба белүдә!

Американнар үзләренен милли драматургияләренен чирен дә тапканнар, терелтерлек даруын да! Алай гына да түгел, алар хәтта театрнын аурупалылар уйлап чыгарган кайбер яна төрләрен дә, терелтеп, үзләренен милли горурлыкларына әвереллерәләр: Америка мюзиклы, мисалга—әнә шундыйларнын берсе. Ул башта Англиядә XIX гасыр урталарында мюзик-холл рәвешендә барлыкка килә (ул анда эстрада театры буларак әле дә яши), ә американнар шуны үстереп, драматургиянен өр-яна һәм тәэсирле төренә әйләндерәләр. Чын мюзиклны бүгенгә чаклы

американнарның үзләреннән башка беркем дә иҗат итә алганы юк: ул—эстрада һәм гадәти музыкага драма элементларын, хореография һәм опера сәнгатьләрен оста кушкан, һәм нигездә, комик характердагы музыкаль сәхнә әсәре. Безнең чор—драматургиянең өч төп төреннән (трагедия, драма һәм комедия) драма төре өстенлек алган чор. Американнар нәкъ драмада да хәзер беркемгә дә алны бирмиләр! Әйдәгез без дә, американнар шикелле, милли драматургиябезгә анализ ясап карыйк әле. Берәр төрле кимчелегебез яисә чиребез ачыкланса, төзәтү чараларына керешербез, ә инде аның сау-сәламәт икәнлеген ачыкласак—шатланырбыз гына!

Татар драматургиясе миллиме? Сунын сыйфаты бер тамчысында чагыла—драматургиябезнең анализлау өчен алынган кечкенә бер өлеше дә шуңа җавап бирергә җитәрлек җирлек була ала. Соңгы өч ел эчендә язылган барлык әсәрләрне дә анализлап чыгу кирәкмидер, кайбер коллегаларыбызның әсәрләре күз уңыннан төшеп калса, үпкәләмәсләр, шәт. Безгә монда милли драматургиябезнең магистраль тенденциясен барлап карау мөһим.

Театрларыбызның агымдагы репертуарларын барлап чыксак менә нинди гаҗәеп күренеш ачыла. Безнең театрларыбыз соңгы елларда иҗат ителгән пьесалардан ваз кичкәннәр дә (барысы да түгел, әлбәттә) нигездә классикага таба йөз белән борылганнар, прозаны сәхнәләштерергә тотынганнар яки үз артистлары әштер-өштер әмәлләгән «шедеврларга» урын биргәннәр! Билгеле, мин боларга каршы түгел: классикабызны да онытырга ярамый, прозаны сәхнә теленә күчерү дә матур-матур үрнәкләр бирә, артистларның үзләренең пьеса язып караулары да—мактаулы шөгыль. Иң күренекле классикларыбызның күбесе нәкъ сәхнә осталары да булганнар бит инде: Габдулла Кариев, Кәрим Тинчурин, Тажи Гыйззәтләрне искә төшерү дә шуны раслый! Әмма ләкин тамашачылардан еш кына: «Маташалар шунда, үз вакытларын әрәм итеп, безне, тамашачыларны алдап, акчаларыбызны әрәм иттертеп!»—дип төкеренеп кайтып киткәннәрен дә ишетергә туры килә—сүз әнә шундый фактлар хакында бара.

Бәхеткә, чынбарлык алай ук мөшкел түгел икән ләса: профессионал драматургларыбыз да, элекке еллардан бераз кимрәк куелсалар да, төп урыннарын югалтмаганнар. Гадәттәгечә, йоланы саклап, иң күренекле драматургыбыз Туфан Миңнуллиннан башлыйк. Соңгы елларда ул «Шәҗәрә», «Саташу», «Эзләдем, бәгърем, сине» кебек драмаларын язып, театрларда куйдырды. Шулар арасында «Шәҗәрә» халкыбызның үз тамырларын эзләргә омтылуын оригиналь сюжет аша күрсәтә: бер авыл егете кайчандыр карт бабасы алып торган һәм тули алмый калган бурычын үзе түләргә ниятләп, бабасына миһербанлык күрсәткән кешенең бүгенге торыннарын эзләргә чыга һәм бер-берләрен белмәү дәрәҗәсенә җитеп таралышып беткән туган-тумачаларны кабат таныштыра... Ә инде «Эзләдем, бәгърем, сине»—исеменнән үк күренгәнчә—мәңгелек темага, мәхәббәткә, корылган. Әмма монысы да шактый үзенчәлекле: пьесада ике генә персонаж һәм алар икесе дә инвалид арбачыгына гына утырып йөри алучы гариипләр. Шулай да алар үз мәхәббәтләрен табалар... Ә менә «Саташу» дип аталган өченче пьесасы әйдәп баручы драматургыбызның таланты һәм каләме һаман да тутыкмаган икәнлеген тагын да көчлерәк раслый: бер кыз, үзен якты дөньяга китергәннәре өчен... үз ата-анасын судка бирә!

Өлкәнрәк драматургларыбыздан Илдар Юзеев белән Әхсән Баяновлар да, бүтән жанрларда да иҗатларын дәвам итеп, драматургиябез өчен дә берничә оригиналь әсәр яздылар. Әхсән Баяновның «Кара кош» дигән шигъри трагедиясенең төп герое—Габдулла Тукай, ә Илдар Юзеевның, шулай ук шигырь белән язылган, «Бәгырь» дигән трагедиясе үзәгендә бөек шәхесләребез Салих Сәйдәшев белән Кәрим Тинчуринның дуслыгы, уртак иҗатлары һәм фаҗигаләре ята. Менә аның шушы әсәрен иң беренче булып укырга насыйп булды һәм ул мине тетрәндерде! Утызынчы кара елларда безнең халыкка каршы никадәр вәхшилек эшләнгәнен шушы әсәрне укыгач, бөтен тулылыгы белән аңладым кебек... Илдар аганың бу елларда язылган тагын бер драмасы бар: «Эзләдем, таптым, югалттым» дип атала ул. Бизнес артыннан куып, яшьлеген дә, сөйгән ярын да, баласын да, анасын да һәм үзен дә югалткан кеше драмасы бу. Әле дә бик көчле әсәрләр иҗат итә Ә. Баянов белән И. Юзеев—әмма, ни кызганыч, аларның яңа пьесалары соңгы елларда бер генә театрыбызның да сәхнәсенә менә алганнары юк...

Яшьрәк драматургларыбыздан Зөлфәт Хәким ел саен диярлек яна пьесаларын Камал театрында куйдырып килде, шул әсәрләре арасында «Чапты атым Казанга» дигән комедиясен аның иҗатында иң уңышлысы дип санарга мөмкин. Сюжеты Хәкимчә бик гади, ләкин ул монысында да кызык-кызык детальләр тапкан: бер авыл «неудачнигы»—ул гармунчы, клуб мөдире—гармунын да урлыйлар моның, үзен эшеннән дә сөрәләр, бер тиен акчасыз утыра. Гаделлек эзләп Казанга барыр иде—автобуска түләрлек тә сәмәне юк тегенең. Шуннан ул башкалага атка атланып чыгып китә, әмма бер кирегә китсә китә бит, ГАИ туктаткач, атын да чәлдерәләр! Кыскасы, Казанга кыенлыклар аша барып житкәч, эше унай якка борыла башлый: финалда биш гармунлы була, аты да әйләнеп кайтып керә. Ягъни—«хеппи энд», бәхетле бетүгә корылган җырлы-музыкалы комедия.

Данил Салихов—иң актив иҗат итүчеләрнең берсе: ул ел саен кимендә бер-ике әсәр куйдырып килде. 2001 елда гына да ул Чаллы яшьләр театрында «Мөгезле Мәүлихан», Тинчурин театрында—«Капчыктагы Мәгъфия», Әлмәт театрында—«Пуля» дигән сатирик комедияләрен сәхнәгә мендерде. Салихов әсәрләренең жанрын шоу-тамаша белән сатирик комедия уртасындарак тора, дип билгеләргә мөмкин: мәсәлән, беренче пьесасындагы төп персонаж Мәүлихан, колхоз рәисе, шуннан файдаланып күп хатын-кызлар белән кети-мети уйный, ә көннәрнең (дөресрәге—төннәрнең) берендә ул үзе амбар каравылчысыннан «мөгез» алып куя... «Мәгъфия»дә—ялгыз ханымнарны алдап, кемне төп башына, кемне кәкре каенга терәп, кемне капчыкка салып, тегеләрнең байлыкларын үзләштереп йөргән аферист—үзе корган ятьмәгә үзе эләгә... Өченчесендә «дөньяның бер кендеге», завод директоры китмәгәндә почта аша конверт эченә салып җибәрелгән пуля ала һәм куркып йөри торгач, акылыннан шаша.

Рәдиф Сәгъди: ул да иң актив эшләүчеләрнең берсе. Соңгы елларда куйдырган әсәрләреннән «Сынган беләзек» драмасы, «Яз галәмәте» комедиясе (икесе дә Тинчурин театрында куелды) һәм «Гүзәл Аппаксылу» әкияте тамашачыларның күңелен җәлеп иткән пьесалар. Беренчесендә ирен сугышта югалтып, малаен ялгызы үстереп авырлыклар кичергән хатынның язмышы күрсәтелә. Әмма аның ире исән икән—ул Сталинның «бездә әсирләр юк, сатлык-җаннар гына бар», дип миллионлаган гаепсез солдатларны фаҗигале язмышка дучар итүе аркасында үзенең дөньяда барлыгын яшереп яшәргә карар кылган. Ниһаять, ул авылына кайтырга җөрьәт итә, ләкин соң инде—хәләл җефете якты дөнья белән бәхилләшкән, ул туган авылында «өч аршын җир» генә таба... Икенче әсәр үзәгендә егерме ел элек сөйгән егетен югалткан һәм, комендант буларак, тулай торакны дер селкетеп торучы бер хатын язмышы: югалган егете көтмәгәндә кайтып төшкәч, ир-атларны җен урынына күргән Мәдинә кинәт «сөйкемле сөяккә» әверелә... Сәгъдинең инде театрлар репертуарларына кертелгән һәм куелачак тагын өч яна пьесасы барлыгын да беләбез.

Гафур Каюмов: ул соңгы елларда яза алмады кебек, чөнки бар сәләтен, бар көчен монарчы татарда булмаган камерный театр ачуга сарыф итте—Алла ярдәм итсен аңа!

Яшьләрдән тагын күп кенә исемнәрне санап үтәргә була: Галимҗан Гыйльманов, Аманулла, Фәнәвил Галиев, Рафис Корбан, Хәбир Ибраһимов, Альберт Гаделша, Рөстәм Галиев, Ләбиб Лерон, Зиннур Хөснияр, Шамил Фәрхетдинов, Заһид Мәхмүди, Илсөяр Иксанова... Алар Фәнис Яруллин, Гөлшат Зәйнәшевалардан бер тотам да калышмаска тырышып, драматургиябезгә үз сәләтләрен бирәләр. Иң мөһиме—аларның барысы да милли драматургиябез белән бик житди кызыксына, әмма ләкин аларның үзләре белән театрларыбыз ныграк кызыксына башласын иде, дигән теләктә калырга туры килә әлегә.

Айдар Хәлим, Юныс Сафиулла һәм Эсфирларның исемнәре дә биредә аталырга тиеш иде, ләкин соңгы өч елда алар яңа әсәр яздылармы икән, язган булсалар, кайсын сәхнәгә чыгара алганнар—миндә андый мәгълүматлар юк.

Югарыда санап үтелгән һәм әсәрләренә кыскача күзәтү ясалган авторлар арасына тагын ике драматург кермәде: мин моны махсус шулай эшләдем, чөнки алар хакында җәелебрәк сөйлисем килә. Сәбәбе бик житди—алар икесе дә драматургиябезгә яшен ташыдай атылып килеп керделәр!

Шуларның берсе һәм көтелмәгәнрәге—Ркаил Зәйдулла: ул үз әсәрен дөньяга

тәүге тапкыр күрсәтер өчен, (мишәр егете бит) Камал театры сәхнәсен сайлап алды! Асылынасың килсә, асылын агачның асылына, ди безнең халык—шуны күз алдында тоткандыр инде... Һәм—ялгышмаган булып чыкты. Беренче пьесасын кемнән куйдырды, диген әле—Марсель Сәлимжановның үзеннән! Хәзерге вакытта аның «Саташкан сандугачы», чут-чутларын еракларга ишеттереп, өздереп сайрый. Ркаилнең пьесасы хакында аның яшьтәше Мансур Гыйләжев миңа нәрсәләр язып бирде: «Саташкан сандугач»—ул интеллигенциянең хәзерге заман җәмгыятендә үзен ничек тотарга тиешлеген ачыкларга бер зур омтылыш ясарга тырышу. Бу проблема һәр зыялының тирән борчуы. Иҗат әһелләре, гомумән интеллигенция, бүген ничек яшәргә тиеш? Матди кытлыктан котылыр өчен үз идеалларыннан ваз кичсеннәрме? Әллә бүтән юл сайларга омтылсыннармы? Театр да Ркаил пьесасының шушы версиясен алгы планга чыгарган һәм дөрес хәл иткән.» Мансурның фикере белән мин дә килешәм. Ркаилнең эш өстәле тартмасында башка пьесалары да бар хәзер: «Фидаи», «Хан һәм шагыйрь»—соңгысы күптән түгел «Казан утлары» журналында басылып та чыкты. Сикәлтәлерәк булса да, милли драматургиябез юлына бер кергәнсең икән, ташлама, шагыйрь!

Инде, ниһаять, Мансур Гыйләжев турында сүзем. Мансур татар драматургиясенә моннан дистә еллар элегрәк шаулап килеп кергән автор: аның әсәрләре иң башта Камал театрында ныклы урын алдылар да, республикабызның һәм башка төбәкләрнең төрле-төрле сәхнәләрендә ат уйната башладылар, фестивальләрдә, конкурсларда катнашып, дәрәҗәле бүләкләргә лаек, дип табылдылар. Аннары драматург, әсәрләре триумф белән башкарыла торсалар да, кинәт кенә язудан тукталды! Без ничек тә аңлый алмый аптырадык аның бу сәер адымын... Һәм ниһаять, менә кичә генә (16 февраль) Камал театрында аның яңа премьерасында булып кайттым: «Баскетболчы», дип спектакльне түбәнрәк төшерә торган исем кушылган. Зал шыгрым тулы, хәтта республикабызның зур җитәкчеләре дә хәләл җефетләрен җитәкләп килгәннәр. Һәм өметләребез акланды—чын мәгънәсендә театрның да, әсәр авторының

## «КАЗАН УТЛАРЫ»НА 80 ЕЛ
## «QAZAN UTLARI»NA 80 YIL

**Шамил Закиров,**

*Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры директоры*

## ХӘЗИНӘ ТАПТЫМ!



*«Казан утлары» 1922 елдан алып 1930 елга кадәр гарәп шрифтында «Безнең юл» исеме белән чыккан. Без укыган чорда мәктәп филиалы мәчеттә урнашкан иде. Анда куян фермасы оештырылган һәм мин, яшь натуралистлар түгәрәге әгъзасы буларак, куяннар карый идем. Көннәрдән-беркөнне мәчет чормасына менгәч, нәкъ менә шул «Безнең юл» белән «Совет әдәбияты»ның саргаеп беткән, әмма әле яхшы сакланган төпләмәләренә юлыктым. Хуҗасыз яткан бу хәзинәне мин өйгә ташыдым. Авыл китапханәсе бик ярлы булганлыктан, болар минем өчен чын мәгънәсендә хәзинәгә әверелде. Укып чыгам да, кабат укыйм. Үземне кызыксындырган театр, сәхнә тормышы, артистлар турындагы язмаларны кисеп алам, теркәп барам. Алар әле бүген дә архивымда бик кадерле ядкарьләр булып саклана. Ул чагында белемгә, әдәбиятка, мәгълүматка булган ихтыяҗымны, бушлыкны шушы журнал аша тулыландырдым. Һәм менә шул дәвердән бирле, ягъни 40-50 ел*

да тантанасы булды ул спектакль! Символлар дәрәҗәсенә житкереп, халкыбызның бүгенге авыр язмышын һәм анын киләчәккә өметен югалтмаган гайрәтле милләт икәнен зур сәнгать теле белән тагын бер кат күрсәтте ул безгә. Спектакльгә детальләп анализ ясап тормыйм, бу—тәнкыйтьчеләребезнен бурычы. Шунысы куандыра, Мансур Гыйләжев язудан читләшмәгән икән, ә үргә менгәндә туктап, тирә-ягына күз төшереп алырга булган: соңгы ике елда анын иң актив драматургка әверелүе шул хакта сөйли—без тиздән анын бер-бер артлы яна премьераларына шаһит булачакбыз. Шул исәптән, без анын белән икәү бергә Гаяз Исхакый әсәрләре буенча бер пьеса яздык һәм ул Камал театры репертуарына алынды. (Сүз жаеннан, жәяләр эчендә генә язып үтәм: бу язманың авторы үзе дә драматург бит, нишләп соңгы өч елда үзе ижат иткән әсәрләре хакында бер сүз дә әйтми диюләре мөмкин. Әйе, мин дә, шөкер, шушы вакыт эчендә берничә әсәремне төрле сәхнәләргә чыгардым: Чаллыда «Тигезәкләр» дигән драмам, Минзәләдә «Хан кызы» дигән тарихи трагедиям куелды. Болардан тыш тагын берничә яна пьесам режиссерларын көтә... Тик ятмадым шикелле.)

Шулай итеп, соңгы өч елда язылган әсәрләребезгә кыскача күзәтү ясап уздык кебек... Ә сүз башына куелган сорауга жавап табылдымы соң? Сорауга драматургларыбызнын күпчелеге аңлаган яссылыктан караганда—табылды. Аны Ркаил Зәйдулла, гомумиләштереп, жыйнак кына итеп әйтеп тә бирде: «Милли драматургия—ул дөнья драматургиясе ирешкән бар ысулларны ижади файдаланып, үз драматургиябездә милли традицияләрне дәвам итү. Ә безнен традицияләр исә: музыкальлек, самимилек, хәтта бераз примитивизм, этнографик элементларга артык күп игътибар итү, әйтәсе килгән фикерне әллә ни тирәнгә яшермәү.» Әйе... Ә «национальная по форме» дигән гыйбарә белән нишлибез? «Ирешкән ысулларны куллануыбыз»—Көнбатыш уйлап тапкан «велосипед» ич? Без бит ул ысулны Көнбатыштан урыслар аша алдык... Куян шулпасының шулпасын чөмереп ятабыз булып чыга түгелме?!

Үз милли драматургиябез узган юлга да кечкенә экскурс ясап алыйк. Бездә

*дәвамында яраткан журналымнан аерылганым юк. 60 нчы еллар азагындагы «Казан утлары» аеруча истә! - Тиражы да (100 меннән артык!) үсте, хәзерге заман яшьләре теле белән әйткәндә, бик «крутой» - «текә» журналга әверелде ул. Тоталитар хакимият кыюлыкны өнәмәгән, монын өчен хәтта жәзага тарткан бер дәвердә дә ул кыю, туры сүзле журналга әверелде. Хәзер дә шулай.*

*Журналнын яна авторларны эзләү, аларны дөньяга чыгару буенча кылган гамәлләрен дә хуплыйм һәм мона бик сөенәм. Әмма ни кызганыч, соңгы вакытта ул әдәби мирасны дөньяга чыгарудан бераз читләшкән шикеллерәк, бу вазыйфаны ул башка журналларга (ә алар бу олуг эшне башкарып чыгалырмы-юкмы, анысы шикле) тапшырды сыман. Бәхәс уята торган, кискен-үткен, каршылыклы язмаларны бастырудан тартынмаса, журналнын укучылары да бермә-бер ишәер иде. Хәер, хәзерге көндә «Казан утлары»нын 9 меннән артык даими укучысы бар икән, бу әлбәттә, очраклы хәл түгел.*

*Журналыбыз ел саен берничә яхшы-затлы пьеса бастыра. Театр пьесасын халык та бик яратып укый. Журналда чыгу пьесанын да абруен күтәрә. Соңгы вакытта дөнья күргән язмалардан Щепкинчы актерларыбыз хакындагы һәм Наилә Гәрәева, Илдус Әхмәтжанов турындагы язмаларны бик канәгатьлек хисе кичереп укыдым. Теләгем шул: драматургияне, сәхнә тормышын журнал күбрәк яктыртсын иде. Профессиональ генә түгел, үзешчән халык театрларынын да хәле бүген бик авыр. Бу мәсьәләне дә журнал күз уныннан ычкындырмасын иде.*

*Яраткан журналым «Казан утлары»нын киләчәктә дә бик күпләр өчен хәзинә булып калуын телим.*

чын драматургия XIX йөз ахырларында гына башланганын алда әйтеп үттек, ә инде кайсы «ысул» сайлап алынуга килсәк, ул чакларда талымланып-нәзерекләнеп торырга вакыты да, мөмкинлеге дә булмаган—менә нилектән безгә дә «урыс кулланган ысул» сайлап алынган! Монда классикларыбызны һич гаепләп булмый, берничә ел эчендә урыс әсәрләренә тиңләшүгә якынлашкан пьесалар иҗат итеп калдырган Камалларга, Исхакыйларга, Тинчуриннарыбызга рәхмәтләр генә укыйк. Алар—безнең драматургиябезгә нигез салучылар, алар туып кына килә торган театрларыбызны буш тәрҗемәләр коллыгыннан коткарганнар һәм чын мәгънәдә үз халкыбызга кирәкле әсәрләр бүләк иткәннәр. Халкыбызның трагедиясен җентекләп өйрәнеп, милләтне шуннан коткару чараларын эзли башлаучылар да шулар. Хәзер генә ул татар иле буынсыз буыннар иленә әверелде! Хәтта ки, гел кимчелекле якларыбызны гына төртеп күрсәтә торгач, милли горурлыгыбызны да югалтып бетерә яздык. Ә классикларыбыз ул елларда әкренләп халкыбызның милли холкын өйрәнә башлаган—уналтынчы елда Мирхәйдәр Фәйзинең үлемсез «Галиябану»ы шул ихтыяҗдан чыгып дөньяга килә һәм бер «яше» дә тулмас борын бөтен татар халкының иң яраткан әсәренә әверелә! Ул чакларда моның сәбәбен кайбер олы шәхесләребез дә аңламыйча аптырый, шуна ачулары килепме, әллә үзләренең тагын да түбәнрәк сыйфатлары аркасындамы—алар мәшһүр драматургны примитивизмда, «бездарьлектә» гаепли башлыйлар. Пьесасына җыен чуп-чар җырлар тутырган, янәсе! Ә М. Фәйзи исә халыкның, Данил Салихов язып биргәнчә әйтсәк, «миллилеген—гомер буе изелеп, колониядә яшәп тә, үзенең моң-зарларын күз яшенә әйләндермичә, җыр-биюгә, уен-көлкегә, бәетләргә салып юанырга өйрәнүләрендә» күрә алган. Татар халкы шуна күрә Мирхәйдәр Фәйзинең музыкаль мелодрамасын, һич икеләнмичә, үз әсәре итеп кабул кылган.

Бу җәһәттән, Кәрим Тинчурин бөек музыкаль драмаларын һәм мелодрамаларын иҗат итеп, Салих Сәйдәшев белән берлектә тиңдәшсез каһарманлык эшләп калдырды. Кайбер сәнгать белгечләре аларның иҗатларын татар операсына нигез әзерләү иде, дигән нәтиҗә ясап, боларның фидакарь хезмәтләреннән ролен кечерәйтәләр генә. Юк, андый максатны куймаганнар олы шәхесләребез: операны уйлап чыгарасы юк, ул инде бик күптән бөтен дөнья сәхнәләрендә шаулый, операның милләте дә юк (татарның әлегә кадәр аны кабул итмәве дә шуннан түгел микән?). Ә менә Фәйзиләрнең, Тинчуриннарның драматургиябезгә—Көнбатыш ысулы белән барлыкка килгән драматургиябезгә—беркемнекенә дә охшамаган музыкаль пьесалар алып керүләре—яңа жанр уйлап табулары иде. Алар җиң сызганып иҗат иткән ул елларда татарның илледән артык театры эшләгән! Ләкин... баш очларына балта элеп куелган була шул инде: милли театрларыбыз бик тиз ябыла башлый һәм «үзгәрешләр» чоры килер алдыннан алар нибарысы 4 кенә бөртек яшәп кала! Шундый хәлләрдә иҗатчылар драматургиябезнең милли формасын эзләп карау хакында уйлый да алмыйлар, әлбәттә. Әмма татар театры узган йөз еллык юл милли театрыбызга иң кирәген—драматургик энергияне җитәрлек туплап өлгерде!

Татар театры үткән юл—бөек юл ул! Һәм ул үзе кабул итеп алган «ысулын» да беркайчан да югалтмаячак. Кызганыч, без «яки-яки» дигән принципка күнеккәнбез: яки бу төрлесен генә калдырабыз, яки икенчесен генә, дибез. Ә бит сәнгать дөньясы шулкадәр иркен—анда барысы да сыя!

Язманың кереш өлешендә Көнбатыш һәм Көнчыгыш театрларының ничек барлыкка килүен күздән кичергән идек. Ә безнең, төркиләрнең, аларныкы кебек үк халык өчен табигый булган милли театр сәнгате алданрак туа алган булыр идеме соң? Читләр тапкан ысулларны файдаланмыйча гына? Минемчә, бөтен мөмкинлекләребез җитәрлек булган. «Идел» журналының 2001 елгы 10 санында дөнья күргән «Яртыясаклар иле» дигән язмада мин Әхмәт ибне Фазланның Болгар дәүләтенә килгәч бер могҗиза күрүен искә алып үткән идем. Дөрес, мин анда башта Ф. М. Достоевскийның татарлар хакында, үз күзләре белән күргәненнән чыгып: «Все мусульмане, татары и прочие, как я замечал не один раз, всегда страстные охотники до всяких зрелищ» дигән сүзләрен китергән идем.

Әйе, гарәп илчесенең язуына караганда, татарларның башка беркемнекенә дә охшамаган театр төре булган икән инде. Әлбәттә, болгар бабаларыбыз ул чагында аны «театр» дип атамаганнардыр. Күз алдыгызга китерегез: сез биек булмаган калкулык

итәгендә кичке хозурлыкка сокланып утырасыз. Шулвакыт баш очыгызда биектән, кояш нурларыннан алсулана төшкән болытлар арасыннан, ниндидер акырышулар-бакырышулар ишетелә башлый, әкренләп сез анда атлы сугышчыларны чамалыйсыз—алар үзара ниләрдер бүлешә алмагандай, ыгы-зыгы киләләр, атлар кешни, кылычка кылыч бәрелеп чынлап ала. Менә бермәлне, болар үзара аңлашып, тынычланып өлгергәнче, өсләренә кинәт икенче атлы гаскәр ташлана! Баштарак беренчеләре югалып калалар, ә аннары көчкә-көчкә аннарына киләләр дә көтмәгәндә араларына бәреп кергән чит ил сугышчыларына дәррәү ябырылалар һәм зур кыенлыклар белән чакырылмаган килмешәкләрне куып җибәрәләр. Шушы мәлдә болытлар арасындагы сәер манзара кинәт юкка да чыга...

Сюжетлы һәм мажаралы кичкенә шәүлә спектаклен хәтерләтмиме бу? Экспозиция бар: ниндидер атлы гаскәр үзара тату түгел, якында гына дошман җайдаклары посып торадыр дип башларына да кертмичә, гамьсез рәвештә үзара талашып яталар. Кульминация: өсләренә кинәт илбасарлар гаскәре ташлана, йә тизрәк качарга кирәк, йә каршы торуны оештырырга! Чишелеш мондый: атлы гаскәр, иң дөрес юлны сайлап, дошманнарын куып җибәрә. Авторның һәм куючы режиссерның иң зур максаты—гамьсезлекнең һәм таркаулыкның бик тә аяныч хәлгә төшерү мөмкинлеген халыкка сәнгать чаралары белән күрсәтү!

Шушындый төпле сюжет белән төгәл башкарылу булгач, әлеге тамашаның авторы белән режиссеры да бар диген сүз бит инде! Театр түгелмени бу?! Ә спектакльнең сәхнәсе әллә кайда түгел—баш артындагы калкулыкның кичке кояш ягындагы сөзәк урын ул. Кояш үзе прожектор, ә шәфәкъ алсулаткан болытлар—экран! Болгарларга моннан 1080 ел элек иман нуры алып килгән гарәп кунаклар ни уйларга да белмичә куркып калганнар, ә болгарлар үзләре шушындый спектакльләрнен күптәнге тамашачылары булырга охшаган. Чөнки, Ибне Фазлан сәерсенеп язганча, алар шырык-шырык көлешеп кенә утыралар. Әлеге факт—мондый «шәүлә театры»ның алар өчен яңалык булмавын күрсәтә. Бусы булды—бер!

Икенчесе. Данлыклы Сабан туйларыбыз шулай ук татар милли театрының бөтенләй бүтән төренә әйләнергеч була ала торган татар халык уеннарыннан килеп чыккан түгелме соң?! Алар да сюжетлы һәм анда җыр-бию, музыка, җырчылар һәм атлар ярышы, физик көч һәм мәргәнлек сынашы, җор теллелек бәйгесе, кәләш-кияү сайлау, хатын-кызларның тегү-чигүдә осталыгы, ир-атларның аты белән мактанышуы, төрле сәбәпләрдән чыккан яшерен конфликтлар һәм үзара килешү һ. б., һ. б. синтезы бар бит! Юкка гынамыни хәзерге заман драматурглары еш кына Сабан туйларын төп вакыйга урыны итеп пьесалар язалар!

Сабан туена охшаш уеннар башка халыкларда юк, әгәр дә борынгы бабаларыбызга, шәүлә театрын уйлап тапкан чактагы кебек, Сабан туен да милли театрыбызның бер төре итеп үстерергә ирек биргән булсалар? Кытайларның, японнарның иң үзенчәлекле театрлары нәкъ шундый катлаулы уеннардан үсеп чыккан ич! Ул чакта театр шикелле тамашаларның үсеп китмәвенә төп сәбәп, әлбәттә, ислам дине кабул ителү. Дин әһелләре хәтта иң изге уеныбызны—Сабан туен да тыярга маташканнар. Шундый ук омтылышны совет хакимияте кабатлап карады. Казан ханлыгында да татарның бик үзенчәлекле театры чәчәк аткан, диген кайбер имеш-мимешләр бар... Сабан туйдан ярылган театр булмады микән ул?

Мин—оптимист кеше: галимнәребез әле бу юнәлештә күп нәрсәләр ачарлар, яшь һәм сәләтле, кыю драматургларыбыз да үзенчәлекле чын милли пьесалар язарлар. Бик үк ерак булмаган киләчәктә мин бер күренеш күзаллыйм: ниндидер бер калада (Парижмы ул, Мәскәүме, яисә Әлмәтме—бусы әһәмиятле түгел) халыкара милли театрлар фестивале бара. Әнә шунда японнарның—«Но» театры, кытайларның—«Сяошо», һиндларның—«Джатра», немецләрнен—«Фастнахтшпиль», французларның—«Соти», итальяннарның—«Ателлана» һ. б. халыкларның чын милли йөзен күрсәткән милли театрлары арасында тигез хокуклы булып безнең «Сабан туе» диген чын милли театрыбыз да бөтен дөньяның игътибар үзәгендә... Бирсен Ходай! Бу хыялга чынга ашырга язсын!

Мөдәррис Вәлиев

# СӨЕНСЕННӘР ӘЛЕ САБЫЙЛАР!

## БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ "МӘГАРИФ" НӘШРИЯТЫ

### 1

Әле күптәнме генә теге яки бу шәхес хакында истәлекләр тупланган җыентыкның кибет киштәсендә боегып, алынмыйча яту ихтималы бик зур иде. Ул заманда чыккан шундый басмаларның кайберсе әле дә кайдадыр тузан эчеп ятадыр. Ә менә соңгы бер-ике елда гаҗәп хәл: нәкъ шул рухтагы китаплар, басылып чыгу белән, комга сеңгән су тамчысы кебек тарала да бетә. Татарстан китап нәшрияты, мәсәлән, үткән ел дәвамында гына "Туфан", "Такташ", "Сибгат Хәким" дигән, исеменнән үк эчтәлеге аңлашылып торган бик үзенчәлекле өч том чыгарды. "Мәгариф" нәшриятының Абдулла Алиш һәм Габдрахман Әпсәләмовка багышланган китаплары елның күркәм вакыйгасына әверелде. Бу басмалар уңаеннан үткәрелгән кичәләр, бигрәк тә балалар белән очрашулар укучы күңелен кузгаткан мәгънәле китап бәйрәмнәренә нигез салды.

Гомумән, соңгы елларда күренекле әдипләребезнең гомер һәм иҗат бәйрәмнәре матур, ихлас итеп үткәрелүе күңелне сөендерә. Исәннәренә, ниһаять, күптән әйтеләсе җылы сүзләр килеп ирешә. Хәлбуки, әлеге кадер-хөрмәтнең дәрәҗәсен һич кенә дә киметмәстән, юбилейга мөнәсәбәтле мәҗлесләргә һәм "ияр-камыт баулары"на каршы куймастан, чын каләм әһеле өчен барыбер иң олы бүләк—аның китабы басылып чыгудыр, дип раславга батырчылык итәм. Беренчедән, андый вакыйга (ягъни китабы басылу) юбилей җиткәч кенә булырга тиешлеләрдән түгел. Икенчедән, ни кызганыч, бу кытлык заманында хәтта түгәрәк туган көненә дә һәр әдип үз китабының чыгып җиткәнен күрмидер... Шулай да бәхетлеләрдән көнләшмик. Халык шагыйре Шәүкәт ага Галиев, мәсәлән, үзенең җитмеше тулган көндә, Сабан туе мәйданының уртасына чыккан кебек, Камал театры сәхнәсенә басып, әле генә нәшриятлар "табасыннан төшкән" ике җыентыгын берьюлы кулына алган иде. "Көләч көзге" исемлесен мин, уенын-чынын бергә кушып: "Сезгә Хөкүмәтебез бүләген тапшырабыз, аксакал",— дип бирдем. Һәм бу сүзләрдә шаяртудан бигрәк хаклык күбрәк иде. Бәйрәм табынына "Мәгариф" нәшрияты тырышлыгы белән куелса да, чын мәгънәсендә "хөкүмәт бүләге" булды ул китап.

Яшерен-батырын түгел, моннан берничә ел гына элек "Мәгариф"тә (химаяче-спонсор ярдәмендә яисә махсус заказ белән!) берәр балалар китапчыгы дөнья күрсә, шуннан зур гаеп эзлиләр, ул чактагы мәгариф түрәләре, нәшрият өстеннән шикаять язып, безне генә түгел, ревизорларны да айлар буе тинтерәтә иде.

Хөкүмәттән һәртөрле пособиеләр теләнеп, хәтта кайбер чакта андый "хәер-садака"ны алып та, язучы үзенең хәлен чын-чынлап яхшы якка үзгәртүгә ирешмәячәк. Язучыга иң лаеклы, иң нәтиҗәле һәм иң тотрыклы ярдәм—хезмәтенең таҗы булган яңа китабын (яки сайланма әсәрләрен) дөньяга чыгаруда булышлык күрсәтү рәвешендә булырга тиеш. Әлбәттә, һәр мөмкинлекнең чиге бар, һәм каләм ияләренең күпчелеге хәлне аңлый: иҗатын укучыга җиткерү хәстәрен нәшрият белән бергәләп кайгырта. Гамьле әдип ничек борчылмасын: иҗтиһад итмәгән (әйе, акча җитмәгәннән генә түгел!) авыл һәм мәктәп китапханәләрендә татар әдәбияты—ялан тәпие бозга ябышып каткан Апуш хәлендә... Милли китап сәүдәсе дә, һәр авылда аракы кибете ачуны мәҗбүри итеп куйган кебек, дилбегә какканны көтә...

Әнә шул хәлләрне күздә тотып, берничә ел элек, язучыларыбыз республика җитәкчеләренә махсус мөрәҗәгать кабул иткәннәр иде. "Балалар әдәбияты яклауга мохтаҗ!" дип аталган ул хат әле дә актуальлеген югалтмады. (Күрәсең, мөрәҗәгать кабул иткәч тә, һәрвакыттагыча, ул үзеннән-үзе нәтиҗә китерер дип ышанып, мич

---

Мөдәррис ВӘЛИЕВ (Салих Маннапов)— *"Мәгариф" нәшрияты директоры.*

башына менеп ятканбыздыр.) Ниһаять, соңгы өч-дүрт елда хәл уңай якка үзгәрә башлады. Мөрәҗәгать тәэсиреннән бигрәк, мәсьәлә үзе өлгереп җитте шикелле... Әдип һәм дәүләт эшлеклесе булуны бербөтен олы вазифа итеп аңлаган Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев, Туфан Миңнуллин һәм башка язучы-депутатларыбызның милли китапны, бигрәк тә балалар китабын яклап дәлилле сүз әйтүе "бозны кузгатты". Китап нәшер итү хөкүмәт карары белән башкарыласы мөһим гамәл итеп канунлаштырылды.

Нәшрият өлкәсендә дәүләт сәясәтенең шундый эшлекле һәм эзлекле төс алуы, билгеле, матур нәтиҗәләр бирә башлады.

"Мәгариф" нәшриятының да милли әдәбиятыбыз җәүһәрләрен бала күңеленә түкми-чәчми җиткерергә омтылуы яна көч белән дөрләп китте. Яңа буын дәреслекләр һәм әдәби хрестоматияләр рәвешен дә алды ул, махсус басмалар итеп тә күзалланды. Мәсәлән, "Хәзинә" дигән гомуми исемдә, татар әдәбиятының борынгы дәверләреннән алып бүгенгәчә үткән юлын иңләүче, аның иң асыл үрнәкләрен туплаган 15 томлык сериягә нигез салынды. Әлеге хезмәтнең беренче китабы Әмирхан ага Еники фатихасы белән укучы кулына кергән иде. Аннан соңгы томнарга Р. Фәйзуллин, М. Госманов, Н. Хисамов, М. Хәсәнов һ. б. күренекле шәхесләребез кереш сүз-аңлатма яздылар. Бу сериянең һәр китабын, үзенчәлекле педагог-галим һәм язучы А. Яхин җитәкчелегендә, "Мәгариф" нәшрияты хезмәткәрләре төзи. Г. Ибраһимов исемендәге институтның танылган галимнәре тарафыннан халкыбыз иҗатының барча жанрдагы әсәрләрен сайлап, тәфсилле аңлатмалар белән, яна концепция нигезендә нәшер ителә торган 10 томлык "Энҗе чәчтем—энҗе җыям" сериясе (баш редакторы К. Миңнуллин) балаларга шулай ук игелекле хезмәт күрсәтер дип ышанабыз. "Раушан көзге" һәм "Иң матур сүз" (балалар бакчалары өчен антология-хрестоматияләр)...—шундый тыйнак китапларыбызга күпме хәзинә сыйган. Быел, ниһаять, тагын бер зур хыялыбыз тормышка ашыр—татар әдәбиятын укыту программалары белән бәйләп төзелгән 50 томлык "Мәктәп китапханәсе" сериясеннән китаплар чыгаруга керешәбез.

"Мәгариф" нәшриятының балалар китабын әнә шулай матур һәм зәвыкле гөләндәм-букетларга туплап, эзлекле һәм максатчан эш алып барырга тырышуының сәбәп-омтылышлары аңлашыладыр. Без—бөек халык, дип күкрәк кагу бер хәл, чынлыкта кимлегебезне үзебезнекеләр дә, башка милләт балалары да тарихыбыз, әдәбиятыбыз аша төшенсен һәм кабул итсен дип көч куябыз. "Без тарихта эзлебез!" дигән серия буенча басылып килүче, дәүләтчелегебезнең төрле дәверләрен иңләгән "Кубрат хан" (М. Хәбибуллин), "Хыянәт" (Ф. Латыйфи) һ. б. әдәби әсәрләргә балалар һәм яшүсмерләр зиһенен ачу, аларның күңелләрен агарту вазифасы йөкләнә. Язучы ачып җибәргәнче тирән катламнарда яткан тарихи-эстетик мәгълүмат, шахта субайлары кебек, танылган галимнәрнең фәнни-популяр тәфсире белән ныгытып барыла.

Гасыр башында калган юл башчыбыз—"Мәгариф" нәшриятының "Балалар күңеле" дигән мәшһүр сериясен (Г. Тукайның "Энҗе бөртекләре" белән башлап!) тергезүнең дә максаты—милли тәрбия традицияләрен яңарту. Бу сериянең затлы басмаларын, Шәүкәт ага Галиевкә кушылып: "Сөенсеннәр әле сабыйлар!" дип чыгарабыз. Шуңа күрәдер, Ә. Баянның "Җил яратучы күркә", Т. Миңнуллинның "Авыл эте Акбай", Р. Харисның "Әбәк", И. Юзеевның "Аю сатам, кем ала?", Р. Миңнуллинның "Алма бабай", Э. Шәрифуллинаның "Алтын балык", Р. Вәлиевнең "Кайтаваз кайда яши?", Ж. Дәрзаманның "Серле янчык", М. Фәйзуллинаның "Гаилә әлифбасы" һ. б. ш. китапларын сабыйлар үзләре генә түгел, аларның әти-әниләре, әби-бабайлары һәм тәрбиячеләре дә куанып кабул иттеләр шикелле.

"Бишек җырлары" җыентыгы белән дөньяга аваз салган нәшриятыбыз "Күгәрченем, син дә гөрлә..." кебек балалар җыр китапларын чыгаруны шулай ук изге эш итеп саный. Соңгы елларда бу юнәлештә Мәдәният министрлыгы һәм Президент каршындагы Мәдәниятә булышлык итү фонды белән хезмәттәшлек уңай нәтиҗәләр бирә.

Г. Тукай һәм А. Пушкинның татар һәм рус телләрендәге бүләк басмалары, М. Җәлил, Ф. Кәрим, А. Алиш, Н. Баян һәм Г. Кутуй иҗатыннан бер сәлам-китапчык, Ә. Еники хикәяләре, Л. Толстойның "Хаҗи Морат"ы, А. Сент-Экзюперинең "Нәни принц"ы—болар барысы да "Мәгариф" китапханәсе" сериясеннән. "Нәни принц"ның "Мәгариф" басмасын сорап Франциядән, Канададан хатлар килә... Гомумән, дөнья классикасын туган телебездә "сөйләтү" традициясен тергезү—инде гамәлгә ашырыла

башлаган ниятләребездән. "Том Сойер мажаралары"ннан соң (оригиналдан С. Ибраһимова тәрҗемәсе) яңалары булачак...

"Хәзинә", "Энҗе чәчтем—энҗе җыям", "Балалар күңеле" серияләрендә басылып чыга торган әдәби җыентыклар мәктәп һәм гаилә китапханәләреннән күркенә, яшь буын рухын баетучы кыйммәтле хәзинәгә әверелде. Бу китапларның тирән эчтәлекле, яхшы бизәлешле булуына ирешү өчен, нәшрият хезмәткәрләреннән зур белем, зәвык, һөнәри әзерлек һәм иҗади осталык таләп ителә",—дип, "Мәгариф" нәшриятының хезмәтләренә Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев биргән югары бәя безне фидакарьлеккә рухландыра.

Билгеле, "Мәгариф"нең төп вазифасы уку-укыту әсбаплары әзерләп бастыру булганлыктан, эшебезне хәтта күләм-нисбәт җәһәтеннән дә бәяләү четерекле: бер вагон кәгазьгә, мәсәлән, егермеләп әдәби китап та чыгарып була, шул микъдар ике дәреслеккә дә сыеп бетә... Мәгәр балалар китабын—зиһен һәм күңел үстерүче тормыш дәреслеген нәшер итү, янә дә Шәүкәт ага Галиевнең бер шигырен файдаланып әйткәндә, "төп эштән соң башкарыла торган төп эшебез" булып кала. Әле дә сафтагы иллеләп татар әдибенең әсәрләре безнең нәшриятта нәшер ителгәнен, янә дистәләгән язучының якын араларда безнең белән бергә шундый куанычны кичерәчәген әйтеп үтәргә мөмкин. Алар арасында Роберт Әхмәтҗанов, Т. Галиуллин, Р. Гаташ, З. Мансуров, Р. Мингалим, Р. Мөхәммәдиев, М. Насыйбуллин, Р. Хафизова, А. Хәлим, Ф. Яруллин һәм башкалар бар. Ә. Гаффар, Р. Корбан, Р. Кутуйның ике дәүләт телендә берьюлы басылган җыентыклары, шулай ук татар һәм рус әкиятләреннән төзелгән бик затлы "Куян кучтәнәче—Заюшкина избушка" китабы (рәссамы Нияз Хаҗиәхмәтов) "тел ачкычы" төсендә, гамәли яктан да файдалы бер күренеш булды.

Ихтимал, язучыга, каләм хакы алу җәһәтеннән, әсәрен бүтән нәшриятта бастыру файдалырактыр... Бездә нәшер ителгән хезмәтнең төп өстенлеге—конкрет укучыны күздә тотып, аңа атап чыгарылуы гына: ягъни ул адреслы ("киләчәккә хат") һәм шуңа күрә—нәтиҗәлерәк тә. Без каләм әһелләре белән үзара ихтирамлы мөнәсәбәтне сакларга, үз хисабына китап чыгару җае булса—"йомшаграк" шартлар тудырырга тырышабыз. Хезмәтебезнең асыл мәгънәсен белү, аны башкаларның да күрүе һәм аңлавы—иң зур юанычыбыз. Милләт баласының күңел киштәсендә "Мәгариф" нәшриятының бер генә китабы булса да бар икән,—димәк, безнең көнебез бушка үтми.

## 2

Татарстан Милли китапханәсе үткәрә торган, инде традициягә әйләнеп килүче "Ел китабы" дигән бәйге-ярыш, баштагырак елларда, кайбер журналистлар сүз уйнатканча, "ша-ярыш" кына ахрысы дип, әлләни җитди кабул ителмидер кебек иде. Янәсе, китапның кыйммәтен китапханәчеләр түгел, әдәбият белгечләре бәяләргә тиеш... Шулай да, ахыр чиктә, китапның җәмгыяви әһәмияте укучыга ясаган тәэсире белән, ә инде шул ук "урамның каршы ягына" чыгып караганда—ана укучының мөнәсәбәте белән билгеләнә. Китап сүзенең көндәлек яшәешебездәге урыны әнә шул гап-гади төшенчәдән—"әйләнеш"тән гыйбарәт булып чыга. (Китапханәдәге бер нөсхәне уртача ничә кеше укыганлыгын теркәүче сан икән ул—"китап әйләнеше".) Бу бит үзенә күрә бер "референдум", һичшиксез дикъкатькә лаеклы әдәби-социологик тикшеренү!

"Ел китабы" бәйгесенә минем дә нәшрият манарасыннан гына торып карамавым аңлашыладыр. Чөнки безнең "Мәгариф"нең төп икмәге—дәреслек, сүзлек, фәнни-популяр әдәбият кебек, балаларга бик кирәкле булса да, мондый конкурс кысаларыннан читтә кала торган хезмәтләр. (Иписез аш үтмәсә дә, табынга кунак ризыгы итеп "кызыл билле пәрәннек" куела.) Соңгы бәйгеләрнең берсендә, мәсәлән, татар телендә басылган 63 китап катнашкан булса, шуларның нибары сигезе генә—"Мәгариф"неке иде. Төрле номинацияләр буенча беренче-өченче урыннарга лаек дип табылган басмалар—унберәү. Һәм... әлеге бәхетле китапларның бишесе—"Мәгариф"тә басылган булып чыкты. Ягъни мәйданга чыккан сигез китабыбызның бишесе "батыр калган"!.. Балалар әдәбияты буенча "баш батыр"—халык шагыйре Илдар Юзеевның "Аю сатам, кем ала?" дигән китабы. Хәзер инде бәләкәй генә серне ачарга да була—без Илдар

абыйга бизәлеше алдан әзер китапны биреп, аны шигырь белән "тутыруын" сораган идек... Шул ук елны И.Юзеевның балалар өчен тагын бер матур җыентыгы бүтән нәшриятта да чыкты бит әле... Димәк, автор һәм рәссам хезмәте белән бергә, укучы, мөгаен, үзе дә сизмәстән, китапның нәширен дә аера икән!

Очраклы хәл түгелдер: татар укучысы соңгы елларда балалар әдәбияты китапларыннан нәкъ менә "Мәгариф"тә басылган әсәрләргә өстенлек бирә башлады. 1997 елда ук беренче урынны Ф. Яруллинның "Бию че бака" дигән китабы алган иде. 1998 дә—Ә. Гаффарның "Әкәмәт"е, 1999 да Ш. Галиевнең инде телгә алынган "Көләч көзге"се беренче булды. 2000 ел бәйгесендә А Хәлимнең «Казлар көткәндә» китабы «батыр калды».

"Сан сыйфатка күчә" һәм "Әз булсын—яхшы булсын" дигән, тыштан капма-каршы, әмма асылы уртак ике формула билгеле. Нәшрият хезмәтендә дә, сыйфат өчен көрәшү белән бергә, укучының күптөрле ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен, сан ягын да онытмаска кирәк була. Әйтик, бүген Русия китап чыгару индустриясе Мәскәүдә һәм Питерда тупланган. Рус китап сәясәтен нигездә биш-алты нәшрият-монстр билгели. Шул ук вакытта Русиянең иң зур 25 нәшрияты исәбенә милли "Мәгариф" тә керә икән, бу инде бөтенләй үк әһәмиятсез күрсәткеч түгел.

Беренче карашка, әнә, рус телендәге басмаларга һич кытлык юк кебек тоела. Кибетләрне генә түгел, Казан урамнарын да язгы ташу сыман китап баскан!.. Шул унайдан кәмит тә, гыйбрәтле дә бер хәл искә төшә. Халыкның башын Кашпировскийлар әйләндергәнче үк әле, ниндидер шабашник-күзбуар безнең авыл клубларында гипноз сеансы үткәреп йөри икән. Тамашасының "кендеге" булырлык күренеш—...залны судан бастыру. Моның: "Су баса!"—дию енә, куркаграк ирләр эскәмияләргә менеп кунаклый, хатын-кыз җәмәгате исә, чыланмасын диптер инде, итәк-чабуын күтәрә, имеш... Без күзәтә торган китап "ташуы"—рус телендәге басмаларның әнә шулай "итәк күтәреп маташуы" ул. Күп булып тоелуы шуннан гына: юньлерәк китапларның бәясе "тешли", ә "чүбек тутырган"нарына кызыгу хәзер шактый сүрелде. Асылда, Русия Китап палатасы мәгълүматларына караганда, нәфис әдәбият бастыру, шулай ук балалар китабы чыгару соңгы ун ел эчендә 6—7 тапкыр кимегән, һәм бу тенденция әле дә дәвам итә икән. Бу саннарны искә алуым—Мәскәү нәшриятлары өчен кара кайгыга батуымнан түгел, үзебездәге хәлләрне чамалап-чагыштырып карау өчен кирәк. Бит моннан ун еллар элек, хәлләр шактый мөшкелләнеп, рәхимсез һәм кагыйдәләрсез көрәш мәйданында яклаучысыз калган татар китабы бөтенләй "нокаут" алмасмы дигән шомлы уйлар килә башлаган иде күнелгә... Һәм шундый мәдәни-икътисади-сәяси ситуациядә "Мәгариф" нәшриятын төзү турында махсус карар кабул ителүнең никадәр үз вакытында булуы еллар үткән саен ныграк ачыла, аңлашыла бара.

Яна туган "Мәгариф"не бишеккә салып тирбәтмәсәләр дә, кырыс һәм кысыр заманда нәшрият кадәр нәшрият ачуга батырчылык иткән хөкүмәт безне үз канаты астына алды. Бу гамәлнең иң югары дәрәҗәдәге гаранты бар иде. Кремльдә бер төркем язучылар белән очрашуы вакытында (әле яңа нәшриятта эшкә керешкән генә чорым иде) Минтимер Шәрипович кыска һәм ачык итеп: "Мәгариф" нәшриятын ярдәмнән ташламабыз",—диде. Бу сүзләр менә ничә еллар инде конкрет эш белән расланып килә. Кайгыртучанлыкның нәтиҗәсе дә күз алдында. Статистика буенча, бүген Татарстанда чыгучы китапларның 70 проценты диярлек "Мәгариф"тә басыла, һәм иң мөһиме: без чыгарган һәр ун китапның сигезе—татар телендә. Әлбәттә, бу—ирешелгәннәр белән хозурлану түгел. Беләбез: "әһле китап" буларак, халкыбыз, милләтебез каршында бурычыбыз зур, бик зур әле.

Хәзер, мәсәлән, Русиядә китап чыгаруның 80 нче еллар уртасындагы биек ноктасына кире кайту турында хыялланалар. Бездәге хәлне күзаллау өчен бер генә мисал: "золотой застойный" дәверда басылган дәреслекләребез ел саен 500—600 мең тирәсе булса, хәзер әлеге сан 1 миллион данәдән артык. "Суверенитет безгә ни бирде?" дип сораучыларга, Тукай әйтмешли, "сүздә түгел, басмада" бер җавап инде бу.

Ә ун гына ел элек дөнья бөтенләй башка кебек иде... Билгеле, без дә күктән пилмән яуганын көтеп ятмадык, кытлык чорында дөньяга килүебезне аңлап тырыштык, тырмаштык. Авырлыкларны җиңеп, юлда калыккан киртәләрне ишә баруның файдалы яклары да күп икән. Акчаны кысып тоту зарурлыгы иң элек нәшриятлар темпланыннан беркемгә кирәкмәгән чүп-чарны чыгарып ташлауга булышты. (Дөрес, акчасы табылгач,

"бәйсез" нәшриятларда яисә турыдан-туры типографияләр аша шундый басмалар яңадан чыга башлады. "Табылдык" акча еш кына халык кесәсеннән алына—хәтта хөкүмәт структуралары да "ни өчендер" китап басып "әштер-өштер" китерүчеләр файдасына юмартлана. Заман—кемнен заманы?!.)

Әйе, насыйбына ирешү максатында һәркем үзенчә кәсеп итә. Моннан жиде-сигез еллар элек шактый четерекле хәл туды: Кулланучылар жәмгыяте (потребсоюз) "кинәт кенә", авыл халкына татар китабын сатуга караганда, "урыс" аракысын сату файдалырак икәнен аңлап алды. Мона шул чактагы район башлыкларының гаме китаптан ераклаша башлавы да ярдәм итте... Иң аянычы шунда: әлеге башбаштаклык авыл баласын милли китаптан аерды... Күрәсен, әлегедәй сынауларны да үтәргә кирәк булгандыр. Анын каруы, Татарстан башкаласында татар баласына туган телендә китап сату белән махсус шөгыльләнергә тиешле беренче сәүдә ноктасы—"Мәгариф" нәшриятынын "фирменный кибете" барлыкка килде.

Шул ук дәвердә республикадан читтә яшәүче милләттәшләр белән дә элемтә өзелде. Милләт яңадан уянып, Русия төбәкләрендә татар мәктәпләре һәм класслары ачыла гына башлаганда, бу—кислородны ябып кую белән бер иде. Диаспора исеменнән бик гайрәт чәчеп йөрүче милли оешмаларнын да бу хәлне төзәтүгә әллә дәртләре, әллә дәрманнары житмәде... Турыдан-туры килешүләр төзи башладык,—бигрәк тә Башкортстан, Пермь өлкәсе белән элемтәләр элеккеге елларга караганда да уңышлырак эшләп китте. Мәсәлән, ике ел рәттән, Башкортстан Халык мәгарифе министрлыгы заказы буенча, төбәк үзенчәлекләрен исәпкә алган махсус "Әлифба"ны жәһәт кенә эшләп, 18 мең данә бастырып жибәрдек. Ягъни, бүген чит төбәкләрдә дә милли мәгариф өлкәсендә кул кушырып утыручыларга дәреслек, балалар китабы юк дип аклануы кыенрак. Андый мохтажлыгы булган һәр төбәк, хәтта аерым мәктәп тә нәшриятка турыдан-туры мөрәжәгать итеп, бу мәсьәләне чишә ала. Дөрес, "Мәгариф"нен китап туплау һәм саклау урыны булмаганлыктан, һәр китапны үз вакытында соратып, чыккан берен ала барырга туры килә. Монын уңайсызлыклары аңлашыла, мәгәр шул ягы әйбәт—"складка" эшләмибез, "неликвид" продукция юк, ягъни һәр китап тәгаен ихтыяжны исәпкә алып кына планлаштырыла. Элек андый заказлар ким дигәндә бер ел алдан жыелса һәм аны үзгәртү, киметү яки өстәү мөмкин булмаса, без хәзер ихтыяж үзгәрүгә бик сизгер һәм тиз реакция ясыйбыз. Китап басыла башларга хәтта бер генә көн калганда да, заказ кабул ителә. Кызганыч, балалар китабына ихтыяжны алдан белү, тиражны төгәл билгеләү әле дә бик кыен. Сарыф ителгән көч һәм чыгымнар акланып бетми. Бу игелекле эшкә мәктәп һәм авыл китапханәләре кушыла алса, балалар китабынын иң хажәтен кирәкле санда нәшер итүне жайга сала алыр идек. Әйтик, "Мәгариф" нәшриятынын уникаль китап программалары—алда телгә алынган "Хәзинә", "Энже чәчтем—энже жыям" серияләрен һәр мәктәп һәм авыл китапханәсе берәр генә данә булса да алдырырга тиештер бит инде!

Китапханәләр соңгы ике-өч елда иркенрәк сулыш ала башладылар. Президентыбызнын турыдан-туры ярдәме белән, аларга китап фондын тулыландыру мөмкинлеге тудырылды. Үзенә күрә "тузган китапны яңарту программасы" эшли башлады. Монын өчен китап укучылар бик рәхмәтле. Булган каләресе чынлап та шактый таушалган, яңалары "килеп житми", шунлыктан бүгенге буын авыл балаларына үз заманынын әдәбиятын укудан мәхрүм булып үсү яный башлаган иде...

Соңгы унъеллыкта Татарстан Милли китапханәсе дә укучылар белән яна китапларны "кавыштыру" кебек игелекле вазифаны үз өстенә алды. Әлеге "Ел китабы" конкурсы да—татар китабынын хәлен чагылдыручы көзге сыман: республика китапханәләре хәзинәсенә байтак кына яна басмалар 1000 һәм аннан күбрәк данәдә барып кушылган. Китапханәнен төп укучысы балалар һәм яшүсмерләр булуын искә алсак, дымга сусаган басуга төшкән бәрәкәтле яңгыр кебек булган ул китаплар! Әйтик, татарча бер калын роман китабын ел дәвамында уртача 42 кеше укып өлгергән. Чират торып укыганнар. Моннан берничә ел гына элек кер порошогына торган чиратлар, әнә шулай, күнелне сөендереп, китапханәләрдә һәм китап кибетләрендә генә калсын иде!

Хәтергә төшерик: моннан ун гына ел элек әле Казан урамына чыксан, кеше алдында татарча сөйләшергә ярамый, дип кисәтү ясыйлар иде. Туган телебездәге балалар китабы, милли дәреслек арзанлы ямьсез тышлык кигән, 2 нче сортлы дип

атала торган саргылт кәгазьдә басылган булыр иде. Ул китаплар татар баласына “икенче сортлы халык иканегезне белеп үс!” дип тукып торалар иде сыман.

Бүген исә балаларыбыз кулында—якты чырайлы татар китаплары. Алар яхшы кәгазьгә, сыйфатлы итеп бастырылган.

Юк, бернинди дә могҗиза булмады: шушы еллар эчендә, алда әйтелгән үзгәрешләргә өстәлеп, хөкүмәтебез ярдәме белән, Газета-журналлар нәшриятына заманча китап бастыру техникасы алынды. Инде милли дәреслек һәм балалар китабы бастыруның зур йөген тартып баручы Полиграфкомбинатның да техник куәтен арттырасы иде. Әйтик, “Мәгариф” нәшрияты чыгара торган продукция эчтәлеге белән генә түгел, технологик яктан да шактый катлаулы. Аның һәр “өтере” махсус стандартларга җавап бирергә тиеш, катлаулы формулалар, таблицалар, рәсем-иллюстрацияләр, корректура ягыннан искиткеч җаваплылык таләп итә торган зур күләмле текстлар... Бүген “Мәгариф”нең бөтен китаплары эчәсеннән җебенә кадәр—оригинал-макет дәрәҗәсенә җиткәнче, нәшриятның үз эчендә, үз белгечләре көче белән эшләнә. Күрәсез, соңгы елларда Казан-башкаланың йөзе матурайган кебек, китапларыбызның да тышкы кыяфәте күләчләнде. Баланың зәвыгын тәрбияләүдә китап үзенең килеш-килбәте белән үк катнашырга тиеш, әлбәттә!

Ун ел элек чиратлар һәм китап тышлыклары гына түгел, фикерләвебез дә башка иде шул безнең.

Гомуми тиражы 14 миллион данәгә җиткән 900 китап—әлегәчә башкарылган хезмәтнең нәтиҗәсе әнә шундый. Күпме бу, азмы? Балалар белән очрашканда, шундый чагыштыру китерәбез: әгәр без чыгарган китапларны “гыйлем сукмагы” итеп салсаң, ул сукмакның бер башы Казанда булса, икенче очы... Берлинга барып җитәр иде, дибез. Милли китапка шундый кайгыртучан мөнәсәбәт булганда, “Мәгариф” нәшрияты Берлинны гына “алып” калмас әле, шаять.

Алда әйтелгәнчә, сан артыннан куу үзмаксат булмаса да, узганга карап шөкер итмәсәң, алга карап фикер йөртүе кыен... Ниһаять, без эш һәм иҗат кешесен ымсындырып торучы көч, алга куалаучы “таяк”-стимулга ихтыяҗ барлыгын искә төшерә башладык. Инде искәртеп кителгәнчә, соңгы елларда төрле һөнәр ияләренең уныш бәйрәмнәрен уздыру кебек, язучыларның да хезмәтен зурлау актив төс ала. Әдәбият өлкәсендә бер-ике рәсми премиягә куш булып, төрле конкурслар үткәрелә, бүләкләр бирелә башлады. Кемнеңдер мона эче дә поша шикелле, әмма, минемчә, ул хәтле, премияләр күбәйде, дип кайгырмыйк, аларның гаделлеген, дәрәҗәсен сакларга гына кирәк... Әлбәттә, барыбер язучыга иң олы бүләк—аның китабы дөнья күрү, дибез. Әлеге китабы уңышлы саналып, бүләк тә бирелсә—нур өстенә нур булыр. Тик менә китабы чыкмаса... язучы тегесеннән дә, бусыннан да мәхрүм кала. Бигрәк тә беренче китабын бастыру алдында торган талантлы яшьләр ярдәмгә, яклауга мохтаҗ. Татарстан хөкүмәте вице-премьеры Зилә Рәхимьяновна Вәлиева хуплавы белән, “Мәгариф” нәшрияты яшь авторларга йөз тоткан махсус әдәби бүләк булдырды. Бу бүләк бүтән премияләрдән бөтенләй аерылып торачак. Ул әле китабы басылып чыкмаган, әмма басылып чыгарга лаек дип табылган яшь талантка грант рәвешендә бирелә һәм бәхетле авторның хезмәте шул ук елны “Мәгариф” нәшриятының махсус сериясендә басылып чыга. Бу бүләкнең әнә шундый максатчан булуы әдәбиятыбызны үстерүгә билгеле бер өлеш кертер дип өметләнәбез. Сүз уңаеннан искәртү кирәктер: талантлы яшьләребез инде “Мәгариф”тә чыккан беренче җыентыклары белән Язучылар берлегенә кабул ителә башлады (Л. Әмирханова, С. Гаффарова, Р. Әймәт, Р. Мөхияр...— бу исемлек дәвамлы булыр, иншалла!). Нәкъ менә Яшьләр елында сәләтле яшь каләмнәр иҗатына юл ачкан “Җәйнең җиде төсе” җыентыгы, “Сабантуй” газетасы авторларының “Безнең йолдызлар яктырак” тупланмасы—чын мәгънәсендә яңа гасырга атлаучы бәхетле китаплар!

* * *

Китапка гаять җаваплы вазифа йөкләнә—аны кулына алып укыган баланың зиһенен баету, рухын ныгыту, күңелен үстерү. Китапның үзенең дә бәхете—укучыдан. Балаларыбызның күңел пайтәхетенә күтәрелгән “Мәгариф” китаплары нәкъ шуны раслый.

**Равил Рахмани**

# КЫЙБЛАБЫЗГА ТУГРЫЛЫК

Йөрәкләрне йөзгә һәм менгә телгәләп тагын бер шаулы гасыр, тагын бер серле меңьеллык үтеп китте. Халкыбызның милли дәүләт төзүгә юнәлтелгән хыяллары, күңел түрендә сакланып килгән якты өмет-теләкләре кабат тормышка ашмады.

Әмма ул көтелгән көннең һичшиксез бер киләчәгенә ышанычын җуймаган асыл улкызларыбыз, алда торган юлның юнәлешен тәгаен ачыклау өчен, уй-фикер, идеяләре белән, Сабан туе мәйданына җыелган халык сыман төрле сукмак, төрле тарафлардан килеп, бердәм көрәш үзәгенә туплана. Кичекмәстән элеккеге хата-ялгышлардан арыну, җан-иманның чистарынуы, күңел офыкларының киңәюе сорала.

Милләт язмышы хәл ителгән мондый җаваплы сөйләшүләрдә фикер алышучылар уртасында мин, ни өчендер, һәрвакытта әдип Миргазиян Юнысны күзаллыйм. Бу гаҗәп тә түгел, чөнки бүгенге катлаулы рухи яшәешебездә, милли азатлык көрәше мәйданында ул—һичшиксез, рәсми булмаган лидерларыбызның берсе һәм күренеклесе.

М. Юныс шәхесен гади яшәеш күзлегеннән чыгып аңларга, аның әдәби иҗат колачын гадәти көндәлек тормыш кысаларына кертеп үлчәргә һәм бәя бирергә һич мөмкин түгел. Аның күңел дөньясына үтеп керү өчен, бу феноменның асылына төшенү өчен без матди тормыш, көнкүреш логикасыннан берникадәр фәлсәфи аң югарылыгына күчеп фикер йөртергә тиешбездер, мөгаен.

Холык-фигыле белән—яшьләрчә дәртле, житез, хыялый; кешеләр белән мөнәсәбәтендә—сабыйларча эчкерсез, ихлас, беркатлы; бәхәс-фикердә—үсмерләрчә кызу, тәвәккәл, максималист; иҗатында—аксакалларча тирән, төгәл, саллы булган бу әдип үзен күңеле белән һаман әле яшь-җилкенчәк итеп тойса да, яңып яшәп узып киткән еллар саны инде аз түгел... Бераз туктала төшеп, гомер агышы турында уйланырга да, башкарылган һәм тәмамланасы эшләргә кайбер нәтиҗә-ачыклыклар кертергә дә вакыттыр, югыйсә?! Әмма ул үзе алай уйламый, күрәсең: язганнары кырыкмаса кырык җиргә чәчелгән-сибелгән, аларның санын да, кайларда басылуын да һәм басылмый ятуын да һич хәтерләми. Сәяхәт билетын гомерлеккә транзитлап куйган диярсең, ул һаман юлда... Заман аны каядыр ымсындыра, куа, җилкендерә... Аның башында яна идеяләр, күзәтүләр, ачышлар; яшәешендә—канатлану, очыш, егылу, әрнүләр... Ул әле Татарстанны елга-диңгез державасына әверелдерү турында хыяллана, әле башкалабыз Казанны Рим, Венеция югарылыгына житкереп сәнгатьле кору-бизәү уе белән яна. Ул татар язучыларын дөньякүләм масштабларда эш иткән ПЕН клубы тирәсенә туплау белән мәшгуль, ул фикерле яшьләрне, йә булмаса җәмгыять лабиринтларында адашып калган талантларны, әллә кайдан күреп алып, зур иҗатка, гаделлек, азатлык көрәшенә рухландыра.

Аның телендә—дөньяның мәшһүр философлары, психологлары, әдипләре; бәгырендә—милләт мәнфәгате. Юлдаш дуслары—дан-шөһрәткә эремәгән, затлы кәнәфиләр җылысына оемаган, үз персонын ярату белән авырмаган чын ватанпәрвәрләр. Куралмаганы—томаналык, имансызлык, икейөзлелек. Андыйлар белән аның арба күчәре бик тиз эләгешә. Мондый чакта кайнар темпераментын, үткен зиһенен, аяусыз әче тел хәнҗәрен тоймый калмыйсың... Мондый чакта ул үз курсыннан, үз мәсләгеннән бер генә градуска да тайпылмый очкан рәхимсез торпеда сыман... Күз алдында аяусыз, үз шәхси интересларын тәмам оныткан фидакарь көрәшчегә, халкыбызның иман сакчысына әверелә... Ә кайчакта ул киләчәктән килгән ерак юлчы, изге бер илче-пәйгамбәрне хәтерләтә...

Кем ул Миргазиян Юныс? Кай жир кешесе? Ана гомер биргән, дөньяга күзен ачкан, белемгә, хезмәткә һәм галиләккә мәхәббәт тәрбияләгән туган авылы Исергәпнекеме? Канат чыгарган төбәге Баулыныкымы? Торган жире Әлмәтнекеме? Тормыш корган урыны Мәскәүнекеме? Әллә дөнья сәнгать-культурасын гына түгел, чын татар рухын да сизергә ярдәм иткән, анын канында йокымсырап яткан милли тойгыларын, шигъри хисләрен, психологик анын уятып, беренче ижат эшенә илһамландырган һәм кулына киләчәктә төп көрәш коралына әвереләсе каләмне алырга этәргеч биргән «хөррият символы» Одессаныкымы? Ирекле яшәүнен тәм-ләззәтен бар күзәнәге белән тоеп, һәрчак ашкынып-талпынып кайткан һәм һәр очракта мәгъруур альбатрос сыман кин колачлы канатларын тар, кысан, гамьсез мешан урамында жәрәхәтләп китеп барган, мәнгелек мәхәббәте—татлы газабы булган, йөрәгендә гомерлек көрәш уты кабызган Казанныкымы? Дистә елдан артык канатланып очкан зәнгәр күкнекеме? Жир шарын иңләп дөнья гизгән давыллы дингезнекеме? Әллә кендеге белән туган туфрагына береккән шушы гөнаһлы һәм татлы яшәү бүләк итүче кара жирнекеме? Әллә сон Миргазиян Юныс... кайчак дуслары шаяртып әйткәндәй, гомумән, Жир кешесе түгелме?!.

Кай заман кешесе ул? Үткән ерак гасырлар авазына колак салып, Мисыр пирамидалары, Бабил бакчалары, Артемида гыйбадәтханәләрендә дөньянын «жиде могжизасы» белән серләшеп йөргән чал тарихчы яки фикер иясеме? Тун йөрәкле, гамьсез, битараф жаннарнын тынычлыгын бозган тынгысыз замандашыбызмы? Әллә аллагы көнлә үз халкынын якты язмышын сиземләгән, канында көрәзәчелек сыйфатлары йөрткән киләчәк заман әдибеме?


*Миргазиян Юныс һәм Вахит Юныс әниләре белән*

М. Юныснын әдәби ижат үзенчәлеге һәм ижатынын татар әдәбиятында тоткан урынын ачыклау өчен дә без шактый нечкә нюанслар дөньясы аша үтеп фикер йөртергә тиеш булабыз. Әдәбиятка ул чагыштырмача соң—зур тормыш тәжрибәсе туплап: очучылыктан китеп, Мәскәү университетын калдырып, океан киңлекләрен айкап йөри башлаган бер чорда килеп керә. Хикәяләрен башта урыс телендә яза. Бер әсәре хәтта Одессада дингез хикәяләре конкурсында жинүче дип тә танылa. Әмма авылы белән үсмер чакта ук саубуллашып, читтә—урыс арасында—25 еллап яшәгән һәм татар телен шактый гына оныта башлаган әдип тиздән ижатында үз ана теленә күчә. 1968 елда, ягъни 41 яшендә, анын беренче—«Тимер фил» исемле китабы дөнья күрә. Әдәби жәмәгатьчелек М. Юныснын беренче әсәрләрен үк бик жылы каршылый: әдәбиятыбызга авторнын яна—дингез темасы алып килүе, фикерләвенен сәнгатьлелеге, оригинальлеге билгеләп үтелә.

Кайбер каләмдәшләре һәм анын әсәрләрен «эшкәртергә алынган» редакция хезмәткәрләре арасында ул чакта... һәм, әйтергә кирәк, кайчак хәзер дә әле ишетелгәләп киткән «Миргазиянның теле юк» диган кырыс бәя дә нәкъ шул көннәрдән калган бер мөнәсәбәт булса кирәк. Ни өчендер шома язуны камиллек билгесе итеп күрәсе килгән әдәбиятчыларыбызга һәм әдәбиятыбызга килсәк, шомалыкта алар чыннан да гажәп зур унышларга иреште һәм теллә генә дә түгел... Әдәбиятызны шома образлар, шома фикер, шома идеяләр, шома тәнкыйть басты... Кайчакта күбесенен, гомумән, сәнгать әсәре белән уртаклыгы ук күнелдә шик уята. Әдәби әсәрнен теле—гади сөйләм теле янсә жөмлә кисәкләре дөрес куелган гадәти язма тел генә түгел шул... Матур әдәбият теле ул—сәнгатьле фикерләүне барлыкка китергән материал һәм шартлы чара; тел ул—язмыш, психология; тел ул—фикер, идея, көрәш!

Ә бу яктан кем кем—М. Юныс әдәби сурәтләрне шагыйрьләрчә төгәллек белән коеп куя белә! Анын әсәрләрендәге психологик тирәнлек, фәлсәфи фикернен саллылыгы укучыны һәрчакта сокландырып килә. Хәтта дингезчелек яки очучылык кебек тормышнын тар-специфик өлкәләрен чагылдырган терминнарга да ул табигый татарча янгыраш бирә алды. Шулар булмаганда, әдәби сәнгатьтә көндәлек көнкүрештән ары китә алмаган шома телнен кемгә нинди хаҗәте булыр иде икән?!

М. Юныснын әдәби таланты беренче хикәяләрендә үк ярылып ята. «Тимер фил» (1965) хикәясендәге гарәп малаен тасвирлаган юлларга игътибар итик:

«Бачра—урам малае. Аның йорты—яр буена урнашкан зур шәһәр, бүлмәсе—дингез порты. Түбәтәй урынына киездәй кара бөдрә чәч. Аның мендәре—йомшак коры ком, юрганы—бәрхеттәй кара, йолдызлы төн. Аның сәгате—күктәге кояш, иртәнге акчарлаклар малайны йокыдан уята.

Малайның кечкенә йөрәге талпынып-талпынып аны алга куа. Шуннан бирле көн саен ул Дөнья исемле чиксез зур, калын китапны укып бара. Укый һәм анларга тырыша—нигә Аллаһы Тәгалә берәүләргә ипекәйне күп итеп биргән, икенчеләр аның һәр кабымын көннәр буе арып-алҗып эзләргә тиешләр?»

Күрәбез, бу инде гадәти сөйләп чыгу түгел; шома, «дөрес» телдән күпмедер үзгәрәк бу тасвирда нәни каһарманыбызның тышкы кыяфәте һәм эчке рухи халәте сизеп тоелырлык итеп сурәтләнгән. Аның күңел дөньясына үзе кебек ашыга-ашыга хыял-кичерешләре, уй-фикерләре килеп керә, сурәт тагын да тулылана, образның яшь үзенчәлеге, көнкүреш-яшәештәге социаль йөзе ачылып китә:

«Кайбер юләр бәндәләр өсләренә бер күтәрәм кием киеп йөриләр. Бачра алай киенсә, эсселектән, мөгаен, пешеп үләр иде. Аның бердәнбер киндер галәбәсе штан урынына да, күлмәк урынына да ярый. Бу киемне Бачра үзе текте. Ашлык тутырырга дип биргән капчыкның төбен өч жиреннән уйды да, урта тишеген изү итеп, муенына киде, як-якларындагы кулларын тыкты. Гажәп унайлы, чыдам кием булып чыкты бу капчык».

Аны әнисе әйткәнчә, бәләкәч, ягъни гарәпчә Бачра дип кенә йөртсәләр дә, ул үзен бер дә бәләкәй итеп тоймый—туганыннан бирле сигезме, тугызмы рамазан үткән... Үз тамагын үзе туйдыра. Аның илендә исә «үз тамагын үзе туйдырган кеше өлкән кеше санала, ә тамагын туйдыра алмаган һәр кеше йә бик яшь, йә бик карт була».

Гаиләдә әтисе урынына туендыручы булып калгангадыр, күрәсең, өлкәннәрчә житди фикерли торган бу малай тормышта берьюлы ике психологик катлам яссылыгында хәрәкәт итә. Бер якта—табигый үз сабыйлыгы, аның ихласлыгы, беркатлылыгы, шаянлыгы, хыялыйлыгы... Икенче якны бөтен кырыслыгы белән олы тормыш үзе тудыра. Портка кайткан пневматик ашлык суырткычын да ул әнә башта балаларча сөенеп—чиксез көч-куәткә ия булган озын хортумлы фил итеп кабул итә...

Малайның яшьтәшләренә кушылып чит ил солдатлары артыннан йөгерүе, аларга кызыгып карап калуы, «барысының да киемнәре гел бертөсле»—«алар ничек бер-берсен таный алалар икән? Шулай гел бертөрле киенеп йөрсәң, үз-үзеңне таба алмавың да бар, Алла сакласын!» дип уйлануы, йә булмаса, азрак тамагын ялгап алгач: «Хәзер бер ай ашамыйча йөрергә була!»—дип сөенүендә дә сабыйларча эчкерсезлек ярылып ята. Ә бит ул шактый кырыс дөньяда яши: әтисен югалту, ачлык, гаиләне туендыру вазифасы, кыйналу, гаделсезлек, чит ил баскынчылары тудырган ирексезлек, эшсезлек... «Тимер фил» белән дә нәни Бачра шушы олы «тормыш китабы»нда очраша. Тик ул, аны эшсез калдырып, ачлыкка калдырып, ачлыкка дучар итә... аларга бәхетсезлек, күз яше, әрнү алып килә. Эчке кичерешләре малайны котылгысыз төстә яшәү көрәшенә китереп чыгара.

М. Юнысның бу хикәясе аның «Чолым» пароходына эшкә урнашып, Италиягә йөри башлагач—хыял белән чынбарлыкның бергә кушылып могҗизалы яшәешкә әверелгән көннәрендә барлыкка килә, иң гажәбе шунда—хикәя башта урыс телендә языла һәм ул Одессада К. Паустовскийның 70 еллык юбилеена багышланган конкурста катнашып җиңү яулый.

Язучының сәнгатьле фикерләү һәм психологик сурәт ясау осталыгын без аның «Аяклы реклама» хикәясендә тагын да ачыграк күрәбез:

«Шәһәр стадионы идарәсендә Джейк Питирулга яңа реклама бирделәр.

—Гарольд, кияргә ярдәм ит әле,—диде Джеймс.

Гарольд икесен бергә бәйләгән зур-зур фанер такталарны Джеймсның җилкәсенә асты:

—Менә син хәзер чын сэндвичменгә әверелдең!

Алдагы һәм арттагы тактага матур хәрефләр белән «Бүген кич шәһәр стадионында үтәчәк ярышта данлыклы соры эт Лайтнинг катнаша!»—дип язылган иде. (Лайтнинг (ингл.)—яшен.)

—Бүген Берләшкән корольлекнең бөек этенә хезмәт итәбез, Гарольд,—диде Джеймс.

—Үз вакытында үләргә өлгерә алмаган кешеләр өчен бик әйбәт хезмәт...—диде Гарольд тавышын күтәрә төшеп».

Хикәягә шушы урында элеккеге дингезченең хис-кичерешләре, үзе һәм дөнья турындагы фикер-уйланулары килеп керә:

«Дулкын сыртында дөнья гизә торгач, син җәмгыятьтә төпле урын таба алмый каласың. Язмышны үзягына, файда ягына борырга яр җәмгыяте өйрәтә. Шушы хакыйкатьне Джеймс бик соң, картлык килгәч кенә аңлады. Дингезне аны иртәрәк, көч барында ташларга кирәк. Ярга соңгарак калып чыксаң, сине анда рәхимсез михнәт һәм картлар тәкъдире—өметсезлек көтеп торган була. Соңгы мәртәбә ярга чыкканда, Джеймс бөтенләй таушалып беткән иде инде. Язмыш аның акылыннан да, тәҗрибәсеннән дә көчлерәк булып чыкты. Шуңа күрә

җәмгыять театрында бирелгән аяклы реклама роленә риза булырга туры килде. Башка роль дауларга аның көче җитмәде.

Джеймс ашыкмыйча гына атлавын дәвам итте. Кая ашыгырга? Калган гомер болай да күп түгелдер? Ул һаман кыскара тора. Соңгы нәтиҗә ашыкмасаң да тизрәк килеп җитәчәк... Ал яктагы реклама данлыклы соры этнең кечке чыгышын белгертә. Аркадагысы да нәкъ шул турыда сөйли. Джеймска, бер-бер артлы аякларны гына алыштырып, һаман адымлап торырга кирәк. Адымларга, машина астына эләкмәскә тырышырга. Теге, гарәпләр әйтемендәге, эт гомере килеп җиткән инде...»

Геройлары психологиясенә тирән үтеп кереп, фикри мәгънә салып, нык тәэсирле итеп тасвирлый белүен без әдипнең башка хикәяләрендә дә бик ачык тоябыз. Язучы татар әдәбиятына дингез сәяхәте һәм дингезче хезмәте аша чит илләрдә яшәүче халыкларның тормыш-көнкүрешен, үзенчәлекле гореф-гадәтен, эчке күңел дөньяларын алып керде. Юльязма-очеркларында янар тауларның, зәңгәр су асты киңлекләренең шигъри матурлыгын, без ул чакта исемнәрен генә ишетеп белгән шәрекъ һәм гарәп илләренең кабатланмас тормыш сулышын китереп җиткерде.

М. Юныс, 60-70 елларда беренчеләрдән булып, кыю төстә, чит илләрдә яшәгән милләттәшләребез язмышын яктыртуга алынды. Татар укучысына «Безнең өй өянкеләр астында иде...» (1964), «Энҗе эзләүчеләр» (1971) кебек гаҗәеп тирән кичерешле хикәя-новеллаларын бүләк итте.

«Безнең өй өянкеләр астында иде...» хикәясенең герое дингезче Габдрахман Рахманкулов Генуя портында, атаклы Стальено зиратына баргач, очраклы төстә бер татар карчыгы белән очраша. Көтелмәгән могҗиза алдында калгандай, гаҗәпсенүләрен, тирән дулкынлану һәм шатлыкларын, кайнар күз яшьләрен берьюлы тышка чыгарып, алар бердә үзләренең якташ булуларыннан тыш башка нәрсә турында сөйләшергә дә өлгерә алмый калалар...

Аның каравы, «туган җир туфрагы» эзләп пароходка килгәч, икенче очрашуда, карчыкка иркенләп эчен бушатырга җай чыга.

Әби иренең кайчандыр кибет тотуын, революция шаукымыннан качып башта Кырымга, аннан Төркиягә чыгып китүләрен, тора-бара Грециядә яшәп калганлыкларын... иренең үлүен, балаларының таралуын, туган авылын сагынудан зар елавын сөйли. Картайган саен җирсенгәнрә, ди ул. Хәтереннән җуелудан курыккандай, әледән-әле, безнең өй өянкеләр астында иде... дип кабатлый. Бәлки, туган якта үскәндер, дигәч, ипиен дә ашап тормыйча төйнәп куя. «Өермәгә эләккән тузганаклар шикелле таратып ташлады безне язмыш...—ди әби.—Алып кайт син мине, улым. Карамалымны күрәсем килә. Ык буен, өянкеләрне...»

Аларның өченче очрашулары сүзсез һәм... тагын да кыскарак була: әбинең үле гәүдәсен пароходның трюмыннан табып алып, Феодосия портында туган ил туфрагына җирлиләр.

Мәрхүмә, шулай итеп, соңгы теләгенә ирешә: сөякләре ата-баба яшәгән илгә күмелә.

Әсәр тәмамлана, әмма ул гаҗәп әрнүле сорау куеп калдыра: ни өчен соң татар гел шулай—теләгенә ирешүен ирешә дә, тик нәтиҗәгә нигәдер гомере тикле зур корбаннар исәбенә килеп җитә?..

Хикәя нигезенә алынган карчык фаҗигасе М. Юныснын үз язмышында да шактый тирән эз калдыра.

Әлегәчә урысча сөйләшеп-аралашып яшәгән, көндәлекләрен һәм хатларын, беренче хикәяләрен дә шул телдә язган, профессионал язучылар тарафыннан да шактый гына югары бәяләнергә өлгергән яшь әдип-дингезче әлеге хикәясен кинәт туган телендә иҗат итә. Сәбәбе нәрсәдә? Бу хакта автор әле бүгенгәчә уйлана һәм соравының очына чыгалганы күренми. «Өянкенең гомере кыска» (2000) мәкаләсендә әдип болай яза: «Ялган сөйләү—гөнаһ. Ул чорда, Табташ сүзләре белән әйткәндә, туган тел «калган, югалган» иде. Мин үзем дә инде тәге, чабата киеп, сабан артыннан йомшак буразнага басып йөрүче малай түгел идем. Өстемдә Сингапурда алган хаки, кесәдән кызыл тышлы загранпаспорт күренеп тора. Рестораннарда официанткалар гына түгел, метрутельләр, хәтта шеф-поварлар—минем корефаннар. Белмим, шушы дәрәҗәгә җитеп кылтайган бәндәне Генуя зиратында очраган татар карчыгы ничек уятып, чынбарлыкка кайтара алган икән? Карчыкның әниемә охшаганлыгыдыр, бәлки? Тетрәнү чиктән тыш көчле булган, күрәсең... Бусы аңлашыла, шул тетрәнүдән котылыр өчен бушаныр өчен... ниһаять, карчыкның чыраендагы газапны онытыр өчен язганмын мин ул хикәяне. Бу бәхәссез нәрсә. Ә нишләп мин аны татарча язганмын? Менә нәрсә аңлашылмый миңа! Татарча язылган хикәяне Одессада бастырып буламыни? Казан белән, хәтта Баулыда чыга торган «Колхоз» газетасы белән дә бернинди элемтә юк. Киресенчә, «Моряк» газетасыннан тыш «Водный транспорт» газетасында, «Морской флот» журналында мәкаләләрем басылып тора...»

Әлеге юллар безгә яшь авторның әдәбиятка килгән беренче адымнарын һәм ул чактагы күңел халәтен бик ачык күз алдына китереп бастыра булса кирәк. Димәк, бу вакыйга әдипне, тетрәндереп, хикәя язарга этәреп кенә калмаган... аның табигатьтән һәм милли тәрбия кысаларында салынган, әлегәчә йокымсырап яткан потенциаль фикерләү-иҗат мөмкинлекләрен

дә кузгаткан. Хикәянең әһәмияте татарча язылган беренче әсәре булуында гына да түгел... авторын ул дөнья мәдәнияте шаукымыннан йолкып алып милли җирлек, милли чынбарлыкка кайтарып бастырган. Әсәр татар әдәбиятына Миргазиян Юныс дигән язучыны китергән...

«Бөтен юллар да Римга илтә» әйтеменен нәкъ киресен раслап, әдипнең бу татарча хикәясе үз юлын Римнан Казанга юнәлтә һәм «Совет әдәбияты» журналында басылып та чыга.

Шунысы кызык: бу хикмәтле кульязма тиздән үзе артыннан авторны да тартып Казанга кайтара. 1964 елда М. Юныс беренче тапкыр Казанга килеп төшә. Нәкъ Тукай кебек, нәкъ Такташ, Туфан һәм татар әдәбиятының башка бик күп талантлары кебек үк. Дөрес, монда күпмедер аерма да сизелә: М. Юныс Казанга кайтканчы Рим, Венеция, Марсель, Лондон, Гамбург, Роттердам, Александрия, Каһирә, Стамбул, Барселона, Калькутта, Сингапур, Джакарта кебек дөньяның иң мәшһүр дисталәрчә шәһәрләрендә булырга өлгерә. Аның Казанга ашкынып кайтуы нәкъ Тукайның «Пар ат»ы күтәренкелегендә булса да, шәһәр әдип күңелендә шактый авыр тәэсир калдыра: «Татарстанның башкаласы... колониаль стильдә, урыс колониаль стилендә чекрәеп күз алдыма килеп басты»,—дип яза ул. Әлегәчә күрми генә, ишетеп һәм хыялланып кына яраткан Казаны, шул рәвешчә—дөнья цивилизациясе фонында чекрәеп торган коллык стиле белән, аның бәгыренә кереп кадала, бу тәэссорат әдипкә гомер буена сызланырлык әрнү китерә.

Татар карчыгы белән очрашудан алган кичерешләре дә шактый тирән һәм дәвамлы булып чыга. Мәкаләдә язылганча, бу вакыйга авторга, иң элек, кешеләр язмышына тагын да игътибарлырак булырга этәргеч ясый. Ана нечкә кичерешле язучы каләме бүләк итә, иң зур байлыгы—туган телен кайтарып бирә. Әдәбиятыбызга дөнья меридианнары белән тыгыз үрелгән өр-яңа тема, өр-яңа тормыш катламы алып килә. Чит илләге милләттәшләребезгә үзләренең онытылмаганлыкларын искәртә. Мәкаләдә искә алынган Финляндия татарларының: «Безнең бар икәнлегебезне беләләр икән, дип, күз яшьләренә тыгылып шатландык»,—диюләре әнә шул хакта сөйли. Ниһаять, татар укучысы бу чит илдә адашып калган әби язмышында барыннан да элек үзен танып ала. Күрәсең, хикмәт аның чит илдә булуында гына түгел... хет син ерак йолдызга кит, хет җәннәткә барып кер, хет җәһәннәмгә китеп олак, фаҗиганең механизмы шул бер үк—диненнән яки иленнән яздырылган, теленнән читләштерелгән, кеше бәхете өчен тир һәм кан түккән әче татар язмышы! Менә хикмәт кайда! Инде килеп, бу хикәя авторны урыс телле язучы булып китүдән саклап кала, туган теле аны самими балачагына һәм халык рухының саф сулы чишмә башына алып кайта. «Татар карчыгының каһәрле тәкъдире минем күземне ачты»,—ди әдип. Язучының иҗатына игътибар белән караган кешегә бу «күз ачылу»ның нәрсә аңлатканын чамалау авыр түгел: бу—әдипнең үз-үзен ачуы: милләтенең әче язмышы, яшерелгән бөек тарихы, аның гади һәм кодрәтле табигате белән бер бөтен булып кушылуга ихтыяҗ туу дигән сүз.

Татарның үткәнен һәм киләчәген берьюлы—йөрәгә аша кабул итү исә язучыга гомере буена җитәрлек әрнү-уйлану, димәк, иҗат чыганагы, илһам бирә, көрәшкә этәргән олы вазифа йөкли, аның кыйбласын билгели. М. Юныс менә кырык ел буена шушы иманына тугры калып, нинди генә томан һәм юлсызлыкта да үз мәсләгеннән читкә чыкмыйча, һичбер нинди ялтыравык шайтан вәсвәсәләренә дә бирешмичә, кыю иҗат юлын ерып бара. Сизгер йөрәгенең меңләгән сызланулы язмышлар белән бәйле булуы ана үз маршрутын, үз курсын һәрвакыт төгәл саклап калырга ярдәм итә. Бу яктан М. Юныс яшь әдипләргә генә түгел, үзләрен халык язучысы дип олылап йөргән каләм ияләре алдында да үрнәк итеп куярлык.

Кайсы гына әсәрен алып карасак та алар—әдипнең үз халкы, үз милләте язмышы проблемаларын үзәккә куеп ачыкларга алынган чираттагы бер омтылышы булып кабул ителә.

«Энҗе эзләүчеләр» (1971) хикәясе дә—чит илдәге якташларыбызның әче язмышын чагылдырган нәкъ шундый әсәрләрнең берсе. Татар язмышының географик киңлеген, фәлсәфи яңгырашын ул тагын да киңәйтә. Һәм бу әсәрдәге фаҗига да, мина калса, әчкә, тирәнгәрәк яшерелгән.

Әсәрнең баш каһарманы 22 яшьлек Гыйммран—туган илне үзе күргән кеше түгел. Илдән киткәннәрнең ул—икенче буыны. Бу образда Ватанны әти-әниләре сүзе, алар кичерүе аша гына тоеп үскән яңа буын кешеләре язмышы гәүдәләнә.

Аның әтисе—сугышта немецларга әсир төшкән Идел буе татары. Ватанына кайткан әсирләрне гомерлеккә сөргенгә җибәрәләр икән, дигән сүзгә ышанып, ул сугыш беткәч Бельгиядә кала.

Үләр алдыннан ул Гыймранга, әсир төшүдә гаебе булмаганлыгын, армияләре белән немецларга аларны генерал Власовның сатуын әйтә. Улына: «Сагынуыма чыдый алмыйча үләм. Туган җир туфрагы җиде буынга каләр тарта, диләр. Чит ил сине дә җирсетер. Син дә минем шикелле үк мантый алмассың дип куркам. Җай чыкса, минем туган авылыма кайтырга тырыш. Ул авыл Идел исемле данлыклы елга буенда. Анда минем туганнарым калды. Ата-бабаларыбызның сөякләре шул җирдә ята. Васыятем шул—кабиләгә кушылырга тырыш...»—

дип әйтеп калдыра.

Чыннан да, фашист концлагеренда туып, Бельгия жирендә үскән, биш яшендә әнисез калган малайга үзе яшәгән жирләрнен берсе дә, хәтта әтисенең туган илгә охшаш булмасмы дип күчеп килгән гарәп иле—пәйгамбәрләр иле дә Ватан була алмый. Ватан дигән изге жир анын әтисе сүзләре белән барлыкка килеп хыялында гына яши. Күнеленә ул шунда кайту уен беркетеп куя. Юлга акча ясар өчен зуррак мәржән табу хәстәренә керешә. Әмма нәтиҗә фажигале тәмамлана. Соңгы кат дип чумгач, анын аягын кинлеге метр ярымга житкән гигант дингез кабырчыгы тридакна капкачларын ябып кыстырып ала. Иптәше анын аягын кисеп, су төбе капкынынннан коткара...

һәм Гыймран, үлем хәлендә, үзенен хыялый Ватанына кайта:

«Күзен йому белән Гыймран бушлыкка очып төшә башлады. Кызгылт караңгылык эченнән бик озак очып баргач, тирә-ягында яшел сәхрә җәелеп ятканын күрде. Бу күренеш ана гажәп таныш иде... Менә ул йомшак үләнгә басып мул сулы кин елгага таба бара. Яр буен күе яфраклы бөдрә таллар каплаган. Еракта елга буенча тезелеп утырган зәнгәр тәрәзәле матур ак йортлар күренә. Бу, билгеле, Гыймран әтисе туган авыл... Тирә-якта моңлы итеп кошлар сайрый, елга ягыннан әкрен генә салкынча жил исә. Әнә ташлар арасыннан чаптырып чыккан салкын чишмә... «Күрергә насыйп булган икән, шөкер, әтиемнен васыятен үти алдым...—диде Гыймран сөенеп.—Мәрхүмкәйнен үзенә генә күрергә насыйп булмады...»

Бу анын саташу аша соңгы кат күргән хыялый төше һәм дөньяга соңгы тапкыр елмаеп каравы. Гыймранның нинди телдә сөйләшүен дә, хәтта әтисенең авыл исемен дә без белми калабыз. Бу—бик табигый. «Безнең өй өянкеләр астында иде» хикәясендәге карчык кебек «Карамалым» дип сүз саен кабатлый алмый, читкә китеп эрегәннәрнен ул—тик икенче буыны. Бирелә югалту ан дәрәжәсеннән ан асты катламына төшеп кенә яшәвен дәвам итә.

Гигант кабырчыкның аягын кыстырып алуы да, соңгы тапкыр мәржәненен «гасырга бер генә тапкыр табылган», «мондый байлыкны еш тудырырга дингезнең дә көче житмәгән» энже булуы да, һичшиксез, әсәрдәге өмет һәм кара язмышны гәүдәләндергән символик детальләр генә. Ул энҗенең Гыймран күзе булып карап торуы да тикмәгә генә түгел, анын Зөннүн картка да бәхет китермәве әсәрдә ачык итеп күрсәтелә—күгәрчен йомыркасы зурлыгындагы кыйммәтле гәүһәр энҗе эзләүчедән ике адым читтә балкып ята. «Анын булуы хуҗасына шатлык та, үкенеч тә китерә алмый иде хәзер». Шактый гыйбрәтле фикер һәм нәтиҗәләргә этәрә бу символ. Жир баласына жирдәге эшләрен жирдә һәм үз вакытында эшләп бетерергә кирәклеге турында искәртмимени бу күренеш?

Әсәр шундый тормыш детальләренә таянып, шартлы символларны хәрәкәткә китереп гомумилли фикерле идея-фәлсәфәгә әверелә. Анын эпиграфына тикмәгә генә «Чит жирләрдә югалган якташларыма багышлыйм» дип куелмагандыр... Күпме милләттәшләребез жир шарынын нинди кыйтгаларында адашып һәм ятып калмагандыр... Татар язмышы бу яктан теләсә кемне тетрәтерлек! Авторнын житмешенче еллар башында шушындый «унайсыз» һәм кыю фикерләр күтәреп чыгуы, һичшиксез, анын күнел зирәклеге һәм гражданлык батырлыгы хакында сөйли.

Бу хикәяләрне кат-кат укыганда да әсәрләнмичә калмыйсың. Болай тәэсирле, үтемле булуларынын сере шунда, күрәсен—автор үзе тасвирлаган тормыш материалын каяндыр ишетеп, каяндыр күчереп алган үрнәк, документ, вакыйгаларга кормый һәм бик күпләр кебек аны шул ярымфабрикант дәрәжәсендә калдырмый. Тормыш чынлыгын ул үз яшәешеннән табып, йөрәге, акылы, бәгыре аша үткәреп, сыкрап һәм яратып иҗат итә. М. Юнысның язучы буларак төп талант көче әнә шунда!

Милләт язмышы авторнын «жир әсәрләре»ндә дә үзәк проблемаларнын берсе булып калуында дәвам итә.

«Табу һәм югалту» повестен гаять четерекле темаларнын берсе—милләт, гаилә, кеше рухындагы мең еллык традицияләрнең таркалу һәм югала бару рәвешен анализлау, җәмгыятьтәге бу авыруга диагноз куярга алыну нәтиҗәсе итеп карарга кирәк. Милләт тормышындагы бу зур фажигане әдип анын бер күзәнәге—гаилә тормышы аркылы сурәтләп күрсәтергә омтыла.

Югалту тойгысы әсәрнен баш каһарманы Габдрахман Рахманкуловнын йөрәген берничә кисәккә телгәләп сулкылдый. Барыннан да бигрәк, ул үз-үзеннән канәгать түгел. Чын Табигать баласы булуга карамастан, Габдрахман күп еллар инде шәһәрдә, өстәвенә чын урыс мохитынын үзәге Мәскәүдә яши. Рухи яшәеше белән дә шунда эри башлаган. Авыл белән бәйләнеше исә көннән-көн ерагая бара... һәм бу кайтарып алалмас югалтуын ул әчке күнел сизгерлеге белән интуитив төстә аңлап ала, чөнки ана балачакта жир тәрбиясе, милли тәрбия шундый нечкә тоемлау—йөрәк белән аңлау көче—салып калдырган. Шушы әрнүле тойгы көчәя барып, анын күнелендә кинәт тыелгысыз бер теләккә әверелә, аны туган авылына—бөтен милли традицияләрне бергә төйнәп торган әнисе янына тарта.

Жәйге ялны кайда үткәрергә? дигән беренче карашка һәрбер гаиләдә һәр ел саен хәл ителә торган гадәти сорау Габдрахман гаиләсендә бу юлы, принципиаль төс алып, зур

киеренкелек чыганагына әверелә. Фикер төрлелеген, үзендәге һәм гаиләдәге беренче эчке каршылыкларны җинә-җинә, Габдрахман тормышында әнә шул хәзинәне эзләп ерак юлга чыга.

Анын йөрәген сызып үткән иң әрнүле җәрәхәтләрнең икенчесе—хатыны Мәрьям белән бәйле. Мәрьям милли ан, милли традицияләрне югалтуда Габдрахманга караганда бер-ике баскыч түбәнгәрәк төшкән. Ул инде бу югалтуга акылы белән дә, күңеле белән дә килешкән һәм аны эзләмәс дәрәҗәдә.

Дөрес, Мәрьям әле телен җуймаган. Анын төп әхлакый яшәү принципларында да әле татар традицияләре яшәвен дәвам итә. Әмма тышкы тирәлек, эш мохиты гына түгел, анын көндәлек үз яшәү рәвеше дә күптән шәһәрләшкән һәм урыслаша башлаган. Ире Габдрахман белән дә ул башлыча урыс телендә сөйләшә. Кече яшьтән шәһәр культурасында тәрбияләнеп үскәнгә, Мәрьям үз халкын бөтендөнья халыклары казанышы дәрәҗәсеннән чыгып бәяләргә омтыла. Әмма үзебез бер дип иманган Аллаһы Тәгаләне, газиз әти-әниебезне, беренче мәхәббәтебезне, туган авылыбызны... йөрәгебез өчен бердәнбер, тиңе булмаган башка нәрсәләрне дөнья стандартларыннан чыгып үлчи башлап карыйк инде... алардан ни генә калыр иде микән? Милләт тә шундый ук һичнинди стандартка бирелми торган—алыштыргысыз кыйммәт түгелмени? Кызганыч, Мәрьям моны аңлау һәм тоемлау сәләтен югалткан. Ул үзе «хатын-кызнын иренә хыянәте бер конфет белән сыйланудан башлана», дип бик дөрес фикер йөртә, югыйсә. Әмма милләтенә, үз халкына ясаган хыянәтнең дә нинди сүздән, ниндидер адымнан башланып китү ихтималы булу ни өчендер анын башына да килми. Үсемлек тамырын юк итүнең үсемлеккә үлем китерәчәген аңлаган адәм баласы, ни өчендер, үз ыругынын тамырларыннан аерылуны бер дә фаҗига итеп күрми. Мәрьям татар культурасы һәм традицияләренә чиста бер информацион байлык итеп кенә карый, аны алмаштыру—башка көчлерәк, матуррак, унайрак, җайлырак традицияләр белән алмаштыру ана югалту булып түгел, киресенчә, отту булып тоела.



*Чыңгыз Айтматов һәм Миргазиян Юныс*

Бер-берсен яратып, хөрмәт итеп яшәгән Габдрахман белән Мәрьямнең, бер сәбәпсездән дип әйтерлек, аралары суыну һәм килеп чыккан конфликт та нигездә әнә шунын белән бәйле. «Мәрьям авылны, авыл җиренең табигатен, анда яшәүче кешеләрне ярата иде. Мәрьям авылны шәһәрчә ярата, дачада яшәүче шикелле итеп, ә шул ук вакытта авыл—Габдрахманын иманында, вөҗданында. Менә кайдан туа аларнын бер-берсен аңлый алмыйча газаплануларыi».

Мәрьямнең логикасы көчле: «Анда шундый рәхәт булгач, нигә башкалада интегеп яшисен? Син бит бик тәвәккәл кеше... Авыл тормышы мина шулай ошаса, мин бер минут шәһәрдә тормас идем»,—ди ул иренә.

Анын күнел күзе сукыр түгел, ул кешеләрне үтәли күрә: «Туганнарын әйбәт, кешелекле. Алар шундый табигый—сабый шикелле. Ләкин шәһәр кешесе андый әйбәтлеккә битараф. Мина, мәсәлән, шәһәр кешесенен үзара дикъкатьсезлеге, туганнарына сүлпән караваы ошый»,—ди ул.

Күрәбез, анын җан сукырлыгы—тамырлар өзелүдә. Сүз логикасында хакыйкать, бәлки, чыннан да Мәрьям фикерендәдер... Әмма, шуна карамастан, бу сүзләргә Габдрахманнын хәтере кала. Тышкы формаль логикадан тыш, күнел сизгерлеге, йөрәк логикасы да бар бит әле.

Һәм шул ук Габдрахманнын да югалтулы каршылыклар эчендә яшәвен онытып җибәрмик: «Һаман туган авылын сагынса да, Габдрахман шәһәр тормышынын җиңеллегенә, анын гомуми ваемсызлыгына күнеккән иде инде».

Габдрахманнын гаиләсе белән урысча сөйләшүе, милли каршылыкларны әле башлыча шәһәр—авыл каршылыгында гына күзаллавы һәм анын да гомуми канәгатьсезлек рәвешендә генә чагылышы, бу өлкәдә килеп туган һәр проблеманы әлегәчә аңлы төстә чишәргә алынмавы һ. б. сыйфатлар да алдагы өзектәге фикерне раслап тора. Болар барысы да баш геройнын милли югалтуны җан тоемлавы аша аңлавы хакында сөйли. Шуны сизгән йөрәгә бунт күтәрә... хуҗасын туган җир туфрагына тарта... кызы Кәримәне үзе белән алып Габдрахман авылга китә, һәм анда югалтунын чын исеме табыла.

Кайткач, әбисе Кәримәне «И-и-и бәбкәем!» дип күтәреп ала.

—Әти, нигә безнеңчә сөйләшми ул?

—Юк, кызым, әбиен безнеңчә сөйләшә, без үзебез чит телдә сөйләшәбез».

Бик хикмәтле сүзләр әйтә баш герой. Димәк, нәкъ әшлисе эшләрнең беренчесе—инде төп игътибар үзегенә куела.

Дүрт яшьлек Кәримә исә, милли югалтуның тагын да фаҗигалерәк рәвештә гәүдәләнгән соңгы өченче баскычында яши. Ул туган телен белми, табигатьтән аерылган, халык тәрбиясе анардан ерак. Аның сабый күңеле лакмус кәгазедәй чиста, саф. Бу гөнаһсыз җанга тәрбияви эксперимент ясаудагы кимчелекләр хәттин ашкан. Ул корбан. Шәһәр һәм урыс тәрбиясе алып кына түгел. Авылга кайтып яшел чирәм һәм чишмәне күрә алмаганы һәм әбисе белән рәхәтләнеп сөйләшә алмаганы өчен дә... Әти-әнисенең туктаусыз бәхәсләре уртасында (алар ана икесе дә аңлаешлы һәм аңлаешсыз да) зәгыйфь тирбәлеп торган искиткеч сизгер һәм нечкә бәгырьле җан булганы өчен дә. Әтисе белән әнисе, аны тар бүлмәгә ябып куеп, тәрбия эшен үз кулларына алганнар. Ә әзерме алар бу зур, җаваплы эшкә? Габдрахманның ул әнә йөрәге уртасында ялкынсынган өченче җәрәхәт сызыгы булып тора. Милли тәрбия ана мәктәптә дә эләкмәячәк. Әбисе һәм авыл еракта. Халык тәрбиясе аларга ят. Ә бит әле ул—гомеренең башында гына. Тәрбиядәге хаталарны төзәтергә һәм үзгәртергә дә вакыт әле узмаган кебек.

Шушы зур югалтуны күрү Габдрахманга көрәшер өчен көч, тәвәккәллек бирә. Хатынының ай-ваена карамастан, ул кызын алып авылга кайтып китә.

Бу урында төп каһарман югалтуның тагын да зуррагы—яна объектив чынбарлык алдында торып кала. Шул аңлашыла—ул үзе дә шактый күп нәрсә югалткан икән... Заман үзгәргән, кешеләр үзгәргән, хәтта мәңгелек табигать үзгәргән. Чирәме тапталган урам, суы кипкән чишмәләр алдында ул алдакчы бер әти булып торып кала: «Чишмә менә шушы чокырдан чыга иде инде, әллә нишләп суы беткән аның...»—ди ул кызы һәм дөнья каршында аптырап.

Дөрес, Габдрахман монда, кечкенә генә булса да, кайбер җиңүләргә дә ирешә.

Әнә алар чәчәкле болынга килеп чыгалар. Кызы матур чәчәкләрне өзеп әнисенә җибәрмәкче.

—Өзмә, кызым. Кирәкми, өзмә. Үссен.

—Өзмәгәч минеке булмый бит ул.

—Өзгәч, чәчәк үлә. Синең чәчәкне үтерәсен киләмени? Килми бит, әйеме?

—Өзмәгәч, әнигә биреп булмый бит аны,—мәсьәләнең катлаулыгыннан Кәримә елар хәлгә җиткән иде. Мондый чакларда тәвәккәллек белән иценең берсен сайларга кирәклеген Кәримә белми иде әле...

—Шушы ялангагы чәчәкләрнең барысы да синеке булсын. Теләсән, яланы белән әниеңә бүләк итәрсең, яме.

—Яланны Мәскәүгә җибәреп булмас шул.

—Мондагы килеш әниеңнеке булыр».

Һәм ниһаять, кыз: «Бу чәчәкләрнең барысы да—минеке! Мәскәүдә беркемнең бу кадәр чәчәкләре юк!..—дип шатлана».

Өстәвенә, авылга кайтудан баш тарткан шәһәр килене дә кайтып төшә... Габдрахман һәм әнисенең бәхете шунда—гаилә бәхете түгәрәкләнә. Буыннар чылбыры-бөтенлеге ялгана. Шәһәр-авыл аерымлыгы һәм каршылыгы юкка чыккандай була. Тик болар барысы да бер мизгелгә.

Әсәрнең финалында безне авторның шактый ук төшенке нотапарда әйткән сүзе каршы ала: «Бәхет артына посып Габдрахманны киләчәк хәсрәтләр, бәрелешләр дә... сагалап тора иде,—дип белдерә ул.—Караяр белән Мәскәү тәрбиясе арасында үзара аңлашу, юл бирешү, уртак тел табу мөмкинлеге юклыгын Габдрахман белми иде әле». «Мәскәү күз яшенә ышанмый»,—ди урыс әйтеме. Караярда күз яшенә, аһ-зарга ышана торган кешеләр яши. Бу авылның тарихы аһ-зар белән, күз яшьләре белән, азатлык көрәшендә коелган кан тамчылары белән язылган иде».

Җиңү һәм җиңелүче.

Габдрахманның шундый зур кичерешләр белән җиңеп тапкан зәгыйфь үрентеле бәхете тиздән, тапталган нәфис чәчәк кебек, бөтен табылган гүзәллекне юкка чыгарырга сәләтле замана машинасы һәм империя албастысы табаны астында калып юкка чыгачак.

Габдрахманның фаҗигасе шунда—ул таба һәм мәңгегә югалта. Үзенең гомере кадәр һәм хәтта зуррак та (чөнки ул кызы Кәримә бәхете өчен дә җаваплы) бәхетсезлек тора аның алдында. Бу хәсрәт бер аныкы гына түгел, бу—миллионлаган татар гаиләләренә бердәй янап торган уртак фаҗига. Менә ничә гасыр инде бу афәт, буыннан-буынга күчеп, тоташ бер эпидемия рәвешен алып, милләтне кыра, аның яшәү тамырын корыта.

1970 елда әдипнең яланаяк тәпиле балачагына багышланган «Занзибар зәңгәр болытлар артында» повесте дөнья күрә. Монда без теләсә нинди шартларда да үз милли йөзен җуймаслык итеп тәрбияләнгән егет-кызларыбызның сабый балачагына—аларның рухи чишмә башына юнәләбез. Һәм ул, билгеле, аллагы повесть герое Кәримәне тәрбия итү шартларына һич кенә

дә охшамаган.

Биредә төп герой—Габдрахман үзенең чын бәхетен ерак диңгезләр артындагы серле атауда—Занзибар илендә итеп күзаллый. Һәм ялгышмый. Бу балачак хыялы аны, төгәл компос сыман, тормыш давыллары эченнән үзе эзләгән олы бәхеткә якынайта бара. Әлеге әсәре белән М. Юныс талантлы балалар язучысы икәнлеген күрсәтте. Повесть баштанаяк яшь геройларның хыялый, романтик күңел очышыннан һәм мавыктыргыч маҗаралар тезмәсеннән тора.

Бер-берсе белән гаять тыгыз бәйләнгән бу ике сыйфат нинди җирлектә калыплана соң?

Повесть сугыш чоры авылын тасвирлауга корылган. Бер якта—ачлык, ялангачлык, житешсезлек. Ирләр фронтта, хатын-кызлар кырда, хезмәт фронтында. Кешеләр ниндидер бер зур сынау алдына куелган, вакытлы түзүне сораган заман. Икенче якта тормышның моңдый чикләүле, китек яклары белән һич кенә дә санашып торырга теләмәгән, яшәүгә—киләчәккә, тулы бәхеткә тәбәлгән, авырлыкларның тиздән үтәсенә тирән ышанган көр күңелле, оптимистик омтылыш. Заманның бу ике төрле көчен балалар аеруча нык тоеп тора. Алар да бит шушы кырыс шартлар эчендә, туктаусыз дәвам иткән аяусыз көрәш уртасында, бу олы тормышка кушылып, кайгы-шатлыкларын бергә үреп, әле борчылып, әле сөенеп, әле үз дөньяларына чумып яши. Шушы ике көч арасына аларның яшәешләре яна бер өченче дөнья булып килеп керә. Уен, хыял, өмет, мавыктыргыч маҗаралар эчендә кайнап торган әлеге балачак дөньясы, билгеле инде, көрәш үлчәвенең алга, киләчәккә, яктылыкка, үлемсез оптимизмга илткән ягын куәтли.

Сабыйларның сизгер йөрәге олы тормышның һәр тирбәлешенә, димәк, начарына һәм яхшысына да, гыйбрәте һәм үрнәгенә дә җавап бирми калмаган сизгер барометр сыман. Әнә Габдрахман, әнисе буранда адашып үлгәнлектән (әтисе фронтта), апаларында тора, аларда тәрбияләнә. Көннәрдән бер көнне, Габдрахман балык тотып кайткач, һәм колхоз дүрт калак он биргәч, апасы дүрт бәлеш пешерә... ашарга утырганчы, берсен күрше Минсылуга илтеп кайтырга куша.

«Минем хәтерем калды. Үзенә дә сирәк эләгә торган шушындый затлы ашамлыкны ничек кешегә өләшергә инде?

—Үзебездән калса, илтербез әле. Минсылу түтәй безгә беркем дә түгел бит,—дидем мин, бәлешне кешегә бирергә риза түгел икәнлегемне белгертергә теләп.

—Минсылу түтан—безнең күршебез. Пешергән ашта күрше өлеше була. Таба ашында хаста кеше өлеше дә була әле ул. Инсафетдин хатыны Минзифа аш үтмәү чире белән хасталана. Ана мин үзем илтермен инде.

## «КАЗАН УТЛАРЫ»НА 80 ЕЛ
## «QAZAN UTLARI»NA 80 YIL

### Солтан Гыйлемханов,

*РСФСР ның атказанган укытучысы.*
*Арча районы, Субаш-Аты авылы.*

## УЛ МИНЕ ГОМЕР БУЕ ОЗАТА КИЛДЕ



*Өлкән кешегә күп кирәкмени, кайчак исемемне телгә алып "Арча шагыйре" дип әйтеп куйсалар, күңел тулып китә, шигърият белән җенләнә башлаган яшьлегемне искә төшерәм. Бәндә баласына нинди дә булса шөгыль-гамәлгә тотыну өчен берәр этәргеч кирәк бит. Мин, хәтерем ялгышмаса, 18 яшьләремдә "Совет әдәбияты"н алдыра идем инде. Караңгы бер татар авылына яктылык алып килә иде ул журнал: буй җитмәс кебек тоелган язучылар, шагыйрьләр үз әсәрләре аша өенә килеп керсен әле! Тукай, Такташ шигырьләренә мөкиббән китә идем. Үзем дә шигырьләр язгалый башладым. Игезәк туганым Мөхәммәт белән ярыша-ярыша яза идек без. Кызганыч, ул 1941 елны хәбәрсез югалды. Мөхәммәттән яхшы гына шагыйрь чыккан булыр иде. Сугышка хәтле газеталарда, "Совет әдәбияты"нда шигырьләребез басыла башлаган иде инде. Шул елларда Шәйхи Маннурның "Яшь буыннар үскәндә" дигән мәкаләсе чыкты, анда Мөхәммәт белән мине дә телгә алган иде. Мин армиягә 1939 елны киттем һәм 1940 елны журналның 1 санында, беренче биттә чыккан "Ул үлмәскә туды" дигән шигыремне дуслар*

күбрәк токтан булсан, ятимнәр өлешен дә чыгарып булыр иде, аларныкын башка вакытта үтәрбез».

Менә бу—безнең халыкның тәрбия дәресләре нигезе. Ул алдагы повесть герое Мәрьям логикасыннан шактый үзгә. Аны табигать, мең елга сузылган ислам әхлагы һәм кырыс тормыш үзе тудырган.

Әсәргә сугыш чоры педагогикасының эш стилен күрсәткән кайбер юмористик эпизодлар да килеп керә:

«Гани Ганиевич үзенең беренче дәресендә Җирнең ничек кояш тирәсендә әйләнгәнлеген күрсәтер өчен Рафаэль белән Асияне такта янына чыгарды. Асия Кояш булып бер урында гына әйләнеп торырга тиеш иде, ә Рафаэль, Җир буларак, бер үк вакытта Кояш тирәсендә дә, үз күчәре тирәсендә дә әйләнергә тиеш. «Кояш» үз, ә «Җир» «Кояш» тирәсендә һәм үз күчәре тирәсендә әйләнә башладылар. Без бу хәлгә хәйран калып карап тора башладык. Башта «Җирнең» җиңе өстәлдәге кара шешәсен эләктереп челпәрәмә китерде, аннан соң башы әйләнгән «Кояш» чайкалып китеп кара тактага барып бәрелде дә идәнгә ауды.

Шушы тәҗрибәсеннән соң, Гани Ганиевич, дәрес бирү урынына, китапның укыласы битләрен күрсәткәннән соң, кырык биш минутка сузылган елмаю белән генә чикләнә иде».

М. Юнысның «җир әсәрләре» һәм «дингезче язмалары» белән тыгыз үрелеп барган тагын бер зур темасы бар—бу аның очучылар тормышын чагылдыруы. Гаҗәп түгел, ул әле 1944 елда, сугыш барган чорда, ягъни үзенә 17 яшьтә чакта ук, Армиягә алынып хәрби авиация мәктәбенә укырга җибәрелә. Аннан соң башта—фронт бомбардировщикларында укчы-радист, соңрак штурман булып 11 ел буе оча. Харьков авиация училищесын тәмамлый. Кыскасы, аның дистә елдан артык гомере—канатланып очкан яшьлеге—авиация белән бәйле. Татар әдәбиятына әдип бу өлкәгә караган берничә гүзәл әсәрен, шул исәптән: үзенең «утта янмас, суда батмас, җирдә тапталмас» яшьлеген—курсант чорын чагылдырган «Күктә тургай оча...» хикәясен һәм сугыш чорына багышланган «Шәмдәлләрдә генә утлар яна (Биектә калу)» исемле повестен бүләк итте.

Соңгы әсәрдә эскадрильяның өч батыр очучысына: звено командиры Сәйрин Сәләховка, якут егете штурман Максим Майнагашевка, кырым татары укчы-радист Марсель Ялчинскийга сугыш бетәргә берничә көн кала, гаять четерекле очыш—«нәтиҗәсен Баш ставка үзе тикшереп торачак» бурыч йөкләнә.

Инде кемнәрдер исән калу турында гына түгел, үзләренең сугыштан соңгы киләчәге, дан-дәрәҗә, академиягә укырга керү турында да кайгырта башлаган... Герой Орлов әнә *конвертка салып җибәрделәр. Туган яклардан бик еракта хезмәт иткән солдат өчен бу өйгә кайтып килү, якын дуслар белән күрешү кебек иде. Мина 7 елга якын хәрби хезмәттә булырга туры килде. Сугыш мине әти-әнидән, туган нигездән генә түгел, шигърияттән дә аерды. Кайберәүләр әйтер, алгы сызыкта, ут астында язган шагыйрьләр дә бар бит дияр. Беренчедән, мин профессиональ шагыйрь түгел идем, икенчедән, автомат түтәсенә кәгазь куеп шигырь язуга ышанып җитмим. Ул чакта башта бүтән уйлар, бүтән кайгы иде. Алым саен үлем сагалап торганда күңелгә илһам килүе—ай-һай... Инде сугыштан соң Субаш-Аты мәктәбендә завуч һәм әдәбият укытучысы булып эшли башлагач, баштанаяк шигърияткә чумдым дияргә була.*

*Сугыштан соң журналда басылган беренче шигырем, хәтерем ялгышмаса, "Савыгу җыры" исемле иде:*

*"Больнис тәрәзәсе, башым куеп*
*Түр бакчага карыйм йотылып.*
*Хуш ис бөрки сирень куаклары,*
*Иелеп-иелеп ала тал чыбык...*

*Шулай башланып китә иде ул.*

*Журнал—минем өстәл китабым иде. Әдипләребезнең иҗатын өйрәнгәндә мин укучыларыма дәреслектәге түгел, күбрәк журналда чыккан әсәрләрне укый идем, теге яки бу язучы, шагыйрь турында үзем күргән-белгәннәрне өстәп сөйли идем. Чөнки журнал аша мин татар әдәбиятының умыртка сөяге булып торган каләм ияләре белән таныштым. Хәтерлим, сугыштан соң мина Сибгат Хәкимнән хат та килгән иде. Минем утлы җәһәннәмнән исән калып өйгә кайтуымны ишеткән дә, шунда ук хәбәр дә салган: "Солтан, ник язмыйсың, яза аласың бит..." дигән иде. Казанга барсам, Сибгатне күрми китми идем. Бер мәртәбә: "Сезне Мөршидә сыйлар, егетләр, мин карап утырырмын, әйдәгез",—дип (Сибгат аракы белән дус түгел иде) Нури Арсланов белән икебезне өенә кунакка чакырды. Сабыр гына сөйләп, сабыр гына тыңлап утырыр иде Сибгат, үзенең бераәр яна шигырен дә укыр иде. Хәзер ничектер, ул чакта "Совет әдәбияты" редакциясе Язучылар Союзын хәтерләтә иде. Кемнәр белән генә танышмадым да, кемнәр белән генә дуслашмадым мин анда. Яшерен-*

дивизия командиры кызына өйләнеп җибәргән. Подполковник Павлов тир-кан түкми генә тагын да югарырак үрмәләп, Армия штабы җылысында сыену урыны тапкан...

Бу өч егет исә уфтанмыйча, сукранмыйча үзләренең соңгы сугышчан операцияләренә—дошман тылының үзәгенә—хәтәр очышка җыеналар. Әлбәттә, «җыеналар» дип әйтү генә җиңел, аларның бу ике көндә нервлары соңгы чигенә җитеп тартылган, эчке дөньяларында булган бар каршылыклы уйлар, хис-тойгылар киерелгән җәя сыман «сугышчан» халәт алган. Тик ул кичерешләрнең берсе дә тышкы якка чыкмый, алар гаять сабыр, хәтта үз язмышларына күпмедер битараф та калгандай, эмоцияләрне эчкә яшереп һәм салкын акылны өскә күтәреп, сугышчан бурычларын үтәргә—хәлиткеч көрәшкә әзерләнәләр... Әмма язмыш алар өчен үтә дә кырыс финиш әзерләп куя. Сугыш афәте садә җанлы бу егетләрнең яшь гомерен өзә.

Шунысы үкенечле, аларның үлеменә дәһшәтле сугыш—алар бомбага тотасы бу мөһим объектны саклап, «зенит батареялары һәр квадратны алдан хисаплап, прицелга алып куйган» дошман гына гаепле түгел... Аларны үлемгә үз хәрби башлыкларыбызның профессиональ сукырлыгы һәм әхлакый әшәкелеге китерә! Гаделлекне яраткан эскадрилья командиры Растопчин, югыйсә, монарчы җибәрелгән ике экипажның инде унышсызлыкка очравын, Орлов алып кайткан разведка мәгълүматларының «бәясе сукыр бер тиен» булуын искәртә. Аннан югарырак торган командирлар бу сүзгә ни рәвешле колак салалар соң? Гомумән, аларның егетләргә карата мөнәсәбәтләре нинди рәк? Меннәр язмышы белән идарә иткән әлеге җитәкчеләрнең кәрт уйнап утырганда сөйләшкән сүзләренә колак салыйк:

«—Заданиегә очасы экипаж әгъзалары, дөрес, чаплашкалар. Икесе татар, берсе якут,—диде штаб начальнигы Филимонов та.—Әмма сәләтле егетләр. Сезгә, иптәш подполковник, бер үтенечем бар: командующий белән сөйләшеп карагыз әле. Бәлки, ул заданиене бер-ике көнгә тоткарлый алыр? Ашыкмаска кирәк иде. Хәбәр итеп карагыз әле, яме.

—Аңламыйм мин сезне, иптәш подполковник,—диде Павлов.—Кинәшелтән. Очуның һәр детале уйланылган, хәл ителгән. Ниндидер бала-чагалыкка охшый сезнең бу үтенечегез. Әллә сез өч чүчмәкне кызганасызмы? Алар бит урысларга караганда тизрәк үрчиләр».

Шушы гаделсезлек, әхлаксызлык (күрәбез, монда егетләрнең нацмен булулары да роль уйный) дивизиянең батыр очучыларын күренеп торган үлем кочагына ташлый.

Дөрес, бу гаделсезлек өстәгеләр арасына килеп кергән очраклы бер күренеш түгел. Аста да шул ук хәл, Армиянең бөтен тәнендә

*батырын түгел, рестораннарга да йөрдек, тик анда ашап-эчеп чыгар өчен генә керми идек. Өстәл артында башланган иҗади бәхәс еш кына безгә ияреп шәһәр бакчаларына чыга иде һәм шигырь укый-укый җәйге таңнарны аттыра идек. Яшьлек романтикасы, хыялыйлык диген, ә... Шунысын да әйтим, ул чакта "култыклашып" өйгә кайтыр дәрәҗәгә җиту юк иде. Инде Субаш-Атыда балалар йорты директоры булып эшли башлагач, иң якын фикердәшләремә әйләнгән Фатих Хөсни, Габдрахман Минский, Габдрахман Әпсәләмов, Әхмәт Исхак, Сәхәп Урайский, Әнвәр Давыдов кебек танылган шагыйрьләрне ятим балалар белән очрашуга алып кайта идем.*

*Тагын бер шәхес—Гази Кашшаф турында күңелдә якты истәлек саклыйм. Аның "Совет әдәбияты" мөхәррире булып эшләгән чагы иде. Редакциягә күләмле поэма китердем, 400 юллык...*

*Ялгышмасам, 1956 ел иде бугай бу, дөнья ике лагерьга аерылган, халыкара хәлләр шактый киеренке чак. "Соңгы юл" исемле поэма империализмга каршы язылган иде. Шактый тешләк әсәр тоелган күрәсең, Гази Кашшаф аны бастырырга рөхсәт сорап Мәскәүгә хат язды. Җавап озак көттермәде, поэманы бик хуплаганнар һәм ул журналда басылып та чыкты.*

*Ул чор әсәрләре бүгенге буын өчен, бәлки, артык "партийный", артык кызыл тоелыр. Әмма без киләчәккә ышаныч, яхшылыкка-яктылыкка омтылыш белән яшәдек. Безнең иман бер генә иде—кешелеклелек. Ул чакта язучылар, шагыйрьләр бик абруйлы иде. Тере язучы, тере шагыйрьне күрү зур бәхет санала һәм алар сирәк туа торган кешеләр буларак кабул ителәләр иде.*

*"Совет әдәбияты", бүгенге "Казан утлары" журналы менә әнә шундый "сирәк" кешеләр, чын талант ияләре белән таныштырды, кавыштырды. Кызганыч, алда санап киткән чордашларым инде юк. Журналны гомерлек дус итеп минем яшькә җиткәннәр дә бик сирәктер. Озын гомерле булуыма мин иң элек язмышка рәхмәтле булсам, икенчедән, илһам, яшәү, иҗат дәрте биреп елларымны-көннәремне арттырган журналга бурычлымын.*

бу. Сәйрин очышка чыгып китәр алдыннан лейтенант Кононенконың ашыга-ашыга үзенә характеристика яздырып алуының да бик сәер эчке мәгънәсе ачылып китә. Саләховны бәреп төшергән очракта, урынына билгеләнер өчен «алдан аяк киенеп куюы» икән ләбаса аның... «Тетрәндергеч хәл иде бу. Әйтерсең, звено командиры Сәйрин Саләхов үзенә-үзе үлем хөкеме чыгарды».

Димәк, кеше белән санашмау, үзләренең бәхетләрен башка кешеләр исәбенә табу һәм моны, үзләре уйлап кына калмыйча, әйтүләре дә, ярым ачык итеп эшләүләре дә бу авыруның шактый тирән тамыр җибәрүе хакында сөйли.

Дәһшәтле сугыш тәмамланып килә. Әмма гадел, чиста күңелле кешеләр өчен сугышның тагын да зәһәррәге—мәкерле эчке сугыш, ягъни тышкы дошман битлегеннән оста файдаланырга өйрәнеп житкән эчке дошман белән көрәш әле алда тора.

Шушы тышкы һәм эчке дошман көчләр бергә кушылып, Сәйрин белән Разияның керсез олы мәхәббәтен имгәтеп ташлый.

Әлеге ике катлы дошман көчләрнең бер ноктага—вөҗдансыз кешеләрнең язмышын-бәхетен җимерүгә эшләвен без Разияның Дзержинский урамына—Черек күлгә чакырылу эпизодында бик ачык күрәбез.

Җину көнен, дүрт ел көткән сөйгәненең кайту көнен тизрәк житкерим дип хыялланып, больницадан әле яна гына терелеп чыккан кыз кулына повестка китереп тоттырдылар.

«Рәсми кәгазь татар милләтеннән булган кешегә каршылык күрсәтергә юл калдырмый. Мондый буйсынуга без, гасырлар буе колониаль шартларда яшәгәнлектән, күнегеп беткәнбез. Куркып буйсыну белән генә чикләнеп калмый мескен татар. Аның хакимияттән дер калтырап торуы тарихи тәкъдиргә, Казан ханлыгын югалтканда коелган каннарга, жимерелүләргә, күп гасырга сузылган чукындыруларга, лашманчыларга барып тоташа».


*Белла Әхмәдуллина һәм Миргазиян Юныс*

Разия да, күңеле белән үз-үзенә каршы килеп булса да, шушы йортка бара. Һәм анарга кадәр дә меңләгән язмышларны кара канга батырган бу йортта мәсхәрә ителә.

Әсәрдәге фаҗигаләр бүгенге көн яктылыгында бигрәк тә калку булып күренә. Ул кырыс сугыш елларында гына түгел, һәр чорда да без, азчылыкны тәшкил иткән милләт вәкилләре, беркатланып, чын бәхетебезне гадел хезмәт белән табарга өметләнеп йөргән илдә садә жаннарның язмышы әнә шулай өстә кемнәрдер—кеше диеп әйтелергә лаек булмаган адәмнәр тарафыннан хәл ителүен һаман әле онытып җибәрәбез.

Әсәрдә автор бу фальш дөньяның асыл механизмын бик нечкә, тирән итеп ачып сала. Шунысын да әйтеп үтик, ул хакта кычкырып әйтергә безнең хокукыбыз да юк иде бит әле. Алда китерелгән өзектә чагылган вакыйгалар да кайчандыр цензура тарафыннан сызып ташланган иделәр... Шөкер, укучыларга тәкъдим ителә торган яңа басмаларда инде бу әсәрләр бүген тулы килеш—төшереп калдырылган өстәмәләре белән бергә дөнья күрә.

Повестька шундый әйләнечле юл белән кире кайткан кисәкләрнең тагын берсен—Кырым татарларын, Марсель Ялчинскийның әнисен һәм ике сеңлесен, баржа трюмына төяп алып китеп, диңгезгә батыруны тасвирлаган эпизодны искә төшереп үтик. Чын-чынлап жанны тетрәтә торган битләр алар!

Күренә ки, үз әсәрен автор арзанлы, мавыктыргыч сюжет сызыклары белән бизәп, укучының күзенә төтен җибәрми, тормыш дәреслеген йомып калдырып аны шомартмый, милли язмышының андый такыр, шома юлдан йөрмәгәнлеген ул яхшы белә һәм шуңа да аның үзенчәлекләрен ачканда реаль тормыштан чыгып фикер йөртергә тырыша. Бу очракта да ул иман-кыйбласын җуймаган ышанычлы әдип исемена тугры кала.

Китапның азагында 1945 нең 9 маенда—Җину көне һәм хаты әле кичә генә килеп төшкән улы Сәйрин хөрмәтенә әнисе Миңлезифа апаның авылдагы карчыклар мәҗлесе җыюы бәян ителә. Изге жанлы әбиләребезнең ерак милли традицияләребезне барлап, нахакка рәнҗетелгән миллионнарча корбаннарыбыз рухына багышланган догасы килер көнгә якты яшәү өмете белән үрелгән ин гүзәл симфоник поэма булып ишетелә!

Әсәрне укып чыккач исә, бәгырьләрне өзә-өзә күңелебездә чын табигать балалары булган Саләхов, Яльчинский һәм Майнагашевның жан яктылыгын сибеп, аларның яшәүгә булган омтылышын безгә житкереп, фаҗигале дә, өметле дә, үлемсез дә булган «Гөлҗамал» янгырый

башлый.

М. Юныс иҗатының төп стихиясе, әлбәттә, диңгез! Аның «Тозлы җил», «Теләп алган давыл», «Таңда Босфор аша» исемле өч кисәктән торган роман-трилогиясе «Дөнья гизү» (1977—1984) исеме белән 1987 елда аерым китап булып басылып чыкты. Шуны әйтергә кирәк: бу роман, һичшиксез, татар яшүсмерләр әдәбиятының иң күркәм классик әсәре саналырга хаклы!

Укучылар әсәрнең сюжетын яхшы хәтерли торгандыр. Баш каһарман Габдрахман Рахманкулов—студент егет, үзе укыган мәшһүр Мәскәү университетының өченче курсын ташлап, диңгезче булыр өчен Одессага китеп бара. Зур авырлыклар белән башта күмер ташучы пароходка табак-савыт юучы булып эшкә урнаша, үзенең теләгенә ирешеп, диңгездә йөзәргә керешә, аннан матрос, штурман хезмәтендә чит илләргә чыгып йөри башлый.

Шунысын әйтеп үтәргә кирәк: әсәрдә без алда сүз алып барган милли тема алай ачыктан-ачык күзгә бәрелеп тормый. Киресенчә, әсәр тулаем элеккеге СССР дип аталган илдәге күпмилләтле, интернациональ рухлы халык вәкилләренең уртак тормышын, кырык ата баласының йөзләрчә төрле холык-фигыле аша чагылыш тапкан уртак борчу-шатлыкларын уртага куеп тасвирлауга корылган. Без моны Габдрахманның студент дуслары арасында да (Өметгали, Баграт, Маштаков, Феликс, Валерия һ. б.), бергә хезмәт иткән йөзләгән диңгезчеләр арасында да бик ачык күреп торабыз.

Әлбәттә, баш герой Габдрахманга бәйле төстә (аның характер үзенчәлеге, уйланулары, сюжет сызыгын барлыкка китергән эш-шөгыле, башкаларга мөнәсәбәте; әти-әнисе, балачагы, авылы һәм якташлары турындагы истәлекләре һ. б.) әсәрдә татар тормышына да шактый мул гына урын бирелә. Әмма милли теманың яктыртылуы биредә проблемалы итеп куелмаган, дөресрәге, ачык проблемалы итеп куелмаган. Татар һәм аның язмышы әсәрдә дөнья халыклары язмышы белән беррәттән «эретеп» тәкъдим ителә. Ләкин ул алар арасында эреп юкка чыкмый. Киресенчә, кешелекле мөнәсәбәтләр аша татар (Габдрахман) үзенә башкалар янәшәсеннән тигез урын даулый. Тик бу тышкы даулау түгел, ә бәлки тормыш-яшәешнең үз тирәнлегеннән килеп чыккан эчке ихтыяҗ. Әйе, Милләтче булыр өчен башта Кеше булырга, милләтеннең лаеклы баласы булырга кирәк. Аның тышкы, очраклы бер әгъзасы булмаганда гына, синең билгеле бер Милләт Вәкиле булып сөйләшергә хокукың бар. Бу повестьта да баш герой ачыктан-ачык татар бәхете дип көрәшми, әмма ул биредә үзенең исемен—Гадрахман Бәкерович Рахманкулов икәнлеген, татар баласы булуын, башкалардан һич ким булмавын раслый. Нәтиҗә күз алдында—урыслар телләрен сындыра-сындыра булса да, аның чын үз исемен әйтергә өйрәнәләр, пароходта табак-савыт юучы татар булып та ул, ашап бетермәгән боткаларына икмәк сыныкларын һәм тәмәке төпчекләрен батырып китүче башка «бөек» милләт вәкилләренә аларның үз телендә тәрбия сүзен ишеттерүгә ирешә. Хәер, диңгезчелектәге дневальный һөнәрен үзләштергәндә дә ярдәм итүче... әнисе үрнәге кирәк булып чыга.

Шулай итеп, бу әсәрдә татар проблемасы ирек даулап тышка чыкмый, киресенчә, ул эчкә, эчке өлгерү ягына юнәлтелә. Төп юл—героебыз Габдрахманның шәхси өлгерү юлы. Ул үзенә Милләт Вәкиле булып сүз әйтер хокук даулый. Соң бу хокукны университетта калып, дөнья әдәбиятын тирән үзләштереп һәм шул югарылыкка менеп даулап булмас идемени? Моның өчен укуны ташлап, савыт-саба юуучы дәрәҗәсенә төшеп, диңгезче булу кирәк идеме?

Алдагы әсәрне анализлаганда Мәрьямнең югары дөнья мәдәниятен үзләштерүе генә аны Үзен югалту фаҗигасеннән коткара алмавы турында сүз булган иде инде. Шуңа бу очракта һич икеләнмичә әйтә алабыз: әйе, җиргә чынлап яшәргә дип килгән, иркен күктә чын очышның ни икәнен татып караган Габдрахман (татар) өчен университет стеналары гына кысан. Нафталин исе сеңгән формаль белем алуның корбаны булуын белү белән үк ул, һичшиксез, аннан сыеша алмыйча китәргә тиеш иде. Башта (түбәннән башлап) ул үзен һәм үзенең кем булуын расларга тиеш иде. Чын Милләт Вәкиле булып шушы чын тормыш эченнән күтәрелеп чыгарга тиеш иде! Габдрахман моны эшли алды. Үзенең эшенә һәм әйткән сүзенә ул татар укучысын да ышандыра алды. «Занзибар»дагы яшүсмер Габдрахманга лаеклы калып, диңгезче егеткә һәм Габдрахман Бәкер улы Рахманкуловка әверелә алды. Зур тормыш диңгезенә чыгып, анда үзенең лаеклы урынын тапты. Габдрахманның моннан соң әйткән сүзләренә инде безнең колак салмый чарабыз юк. Авторның моннан соң язылган әсәрләрендәге йөрәк әрнүенә безнең ышанмаска хакыбыз юк. Диңгез ул—ахыр чиктә, безнең диңгез призмасы аша күренгән җир тормышыбыз, аның тынгысыз ирек символы! Геройның әлеге китапта Диңгезгә килүе—ул аның зур Әдәбиятка килүе. Бу хакта әсәрнең соңгы битендә бик ачык ишарә ясала. Ә Әдәбият ул язучы өчен—изге сүз, кыйбла, иман, үз Халкын өчен фидаи көрәш!

Язучы үзенең «Вавилон елгалары. Шәрекъ» (1977—1981), «Европа ат сагына» (1982—1987) һәм «Соңгы сулыш» (1991—1997) дип аталган диңгезче юлъязмаларыннан торган «Юлда

уйланулар» исемле трилогиясен тәмамлады. Ниһаять, авторның егерме ел иҗат вакытын сораган бу «ирекле жанрда» язылган 36 табаклы китабы бүген тулысы белән (аның алдагы ике кисәге 1990 елда дөнья күргән иде) укучысы хөкеменә тапшырылырга әзер.

Авторның «Җиде могҗиза», «Без—коллар» һ. б. әсәрләре дә башлыча шушы диңгез сәяхәте тудырган уйлануларны, татар һәм кешелек дөньясының үткәндәге язмышы, җир тормышының бүгенге кайнар йөрәк пульсын чагылдыра. Аларда күз күрмәгән илләр, гореф-гадәтләр, яна мәдәният һәйкәлләре, яңа бәя, яна кичереш, яна уйлану, яна гомумиләштерүләр... Аларны укып без үзебез дә сизмәстән, географик киңлек һәм Вакыт шкаласы буйлап сәяхәт итәбез, кешелек тарихы турындагы мәгълүматларыбызны киңәйтәбез. Башка цивилизация-халыкларның эчке җан матурлыгын күрергә һәм аңларга өйрәнәбез. Монда автор шәхесенең масштаблылыгына һәм аның күңел дөньясының олылыгына сокланмыйча мөмкин түгел. Юк, хикмәт аның күңел күзенең ерак чакрымнарны һәм чиксез вакыт аралыгын кочаклап алуында гына түгел. Хикмәт шушы чиксез зур материалны йөрәк ялкынында эретеп, милли хис һәм аң белән сугарып, гомумкешелек мәхәббәте белән җылыта-яктырта алуындадыр, мөгаен.

Шул ук сыйфатлар, шул ук хис-тойгылар, тагын да кайнарлана төшеп, тагын да максатчанрак юнәлеш алып, авторның публицистик мәкаләләренә дә үтеп керә. Аларда әдипнең Шәхес зурлыгы һәм Шәхес үзенчәлекләре тагын да ачыграк төсмерләнә.

Соңгы 10-12 ел эчендә М. Юныс каләме үз укучысы алдында тагын да бер каһарманлыкка тиң эш башкарды. Ул гомум күләме ике зур томнан арткан публицистик әсәрләрен матбугатта бастырып чыгарды. Аларның бу катлаулы заманда язылып, меңнәрчә милләттәшләребезнең җан әзләнүләренә турыдан-туры җавап бирүе, адашкан күңелләрне хак юлга чыгарышуда ышанычлы һәм абруйлы киңәшче булуы—әдипнең үз җилкәсенә алган вазифасын йөрәге белән аңлап, акылы белән тоеп, югары кимәлдә үтәве хакында сөйли.

Аларда авторның мәгълүмат байлыгы, тормыш куйган проблемаларны кую рәвеше һәм чишү тирәнлеге, фикерләвенең философларча колачы безне әсир итә. Әдип, үзенең табигатенә тугрылыклы калып, милли бәхетебезне буучылар белән аяусыз көрәшкә ташлана. Әсәрдән әсәргә көчәеп, үрләп килгән милли көрәш очкыны аның публицистик мәкаләләрендә дөрләп янган зур учакка әверелә. Ул мәкаләләрнең һәрберсендә—милләтебез өчен җан ату! Аларның һәрберсе әрнүле мәхәббәт, үз халкының вөҗдан авазы, ныклы иман белән сугарылган! Шушы публицистик рух ана халкыбызның җан авазын хәтерләткән дисталәрчә сыннарын ясарга этәргеч бирә. «Чиста әдәби жанр» язудан бүленеп, кулына утлы публицист каләме алырга мәҗбүр итә. Биредә ул миңа чын мәгънәсендә Шагыйрь һәм халкыбызның илче-пәйгамбәре булып тоела башлый.

Укучылар яхшы белә: соңгы елларда бик күп әдипләребез, үзләре яулап алган дан-дәрәҗәгә сокланып, халык бәгыреннән чыккан сыкрауларны тиешенчә ишетеп бетермәделәр. Кемдер алдашты, кемдер ярашты, кемдер куштанланды, кемдер адашты, кемдер ерак тарихка, кемдер ерак балачакка китте, кемдер акыллылык битлеге киде... Әдәбият та, аның тәнкыйте дә реаль чынбарлыктан тәмам аерылды. Шуның нәтиҗәсе буларак, соңгы 10-15 ел эчендә күпләрнең иҗаты тупикка килеп керде.

М. Юныс иҗатында исә без шушының нәкъ киресен күрәбез. Үзенең активлыгы белән алай бик нык аерылып тормаган бу иҗат нәкъ менә сүз ирегә туганнан соң—1990 еллардан соң—бөтен тулылыгы белән ачылып, активлашып китте. Яман заман каршысында Миргазиян Юныс Үзе булып торып калды.

Кыска гына вакыт эчендә ул тормыш чынбарлыгының иң хәтәр ялганнарын ачып салган, дөнья сәнгатенең чын кыйммәтен аңларга өйрәткән, дөнья әдәбияты белән янәшәдә татар әдәби үсешенең мескенләгән күрсәткән язма-мәкаләләрен бирде.

Аларда барыннан да бигрәк әдипнең эрудициясе, шәхес зурлыгы, җан кыюлыгы чагылыш тапты. Әлеге көрәшче әдип бүгенге әдәбиятыбызның иман-кыйбласын саклап калуда безгә үрнәк күрсәтә алды.

Шушы публицистик көрәш тәҗрибәсе М. Юныска, һичшиксез, матур әдәбият әсәрләре иҗат итүдә дә яна мөмкинлекләр ачты. Әйтерсең лә аның икенче сулышы ачылды. Ул язган соңгы «Без—коллар» романында әлеге публицистика белән баетылган яңа заман әсәренең гүзәл үрнәкләре ярылып ята.

Әсәр Җир шарының иң зур шәһәрләреннән саналган Ташкала һәм шунда яшәүче гап-гади бер гаиләнең тормыш рәвешен һәм язмышын үзәккә куеп тасвирлый. Автор анда империя башкаласы Ташкалага фәлсәфи-публицистик рухлы заман бәясен бирә:

«Җир йөзендәге гөнаһ һәм савап, ялган һәм хакыйкать, изү һәм изелүнең күп өлеше ташу суы китергән чүп-чар шикелле монда туктала. Монда—хөкүмәт, шымчылык һәм хәрбиләр үзәге, илчелекләр, данлыклы зур төрмәләр, мәдәният оешмалары, нәшриятлар, мәшһүр фахишханәләр һәм фәнни-мәркәзләр урнашкан. Җир шарын чолгап алган алыш-биреш җепләре дә шушы калада зур бер төенне тәшкил итә иде. Сәүдә һәм сәяхәт, җенси һәм рухи

омтылышлар, коллык һәм азатлык дәгъвалары да бу калада аеруча көчле. Биредәге яшерен хәрәкәтләр жир йөзен караңгылык каплаганнан соң гына жанланып, астыртын рәвештә эшли башлый. Рәсми вазифасы башкала булганлыктан, Ташкала башка шәһәрләрдән шактый аерылып тора. Сигез ярым гасыр элек барлыкка килгән кала корал һәм куркыту, итәк астыннан ут йөртү юлы белән бер дәүләткә туплана, йөзләгән халыкларның язмыш-тәкъдирләре белән идарә итә, аларның азатлыгын буу белән шөгыльләнә. Башкала вазифасын аклау юлында башкала чит илләргә, Жир шарындагы барлык халыкларга яшәү юнәлеше биреп, аларның эшләренә катнашып, айга, кояшка, күктәге йолдызларга баш булу хакында хыяллана».

Әсәрнең икенче канатында Әмир Шәкүровның гаилә тормышы тасвирлана. Зур жәмгыять тормышы турында фикер йөртүнең бу—конкретлык алган икенче як полюсы. Алга таба әсәр чынбарлыкны нигездә шушы ике төрле спектрдан, ике аспекттан чыгып яктырта. Жәмгыять һәм Гаилә образлары бер тормыш чынбарлыгының ике объекты гына түгел, аларда авторның ике төрле фикерләү рәвеше дә төсмерләнә. Беренчесендә—фәлсәфи-сәяси публицистикага тартым уйланулар, икенчесендә—гаилә жылысын, бала табигатен ачкан сәнгатьле фикерләү. Алар үзара тыгыз керешеп чорның каршылыклы яшәешен күз алдына китереп бастырырга ярдәм итә.

Башкаланың үз дәрәжәсенә, үз тәкәбберлегенә торырлык мондый туры бәяне татар язучыларыннан беркемнең дә әле бирә алганы юк иде шикелле. Бу—яңа заман мөнәсәбәте, яңа чор чәчмә әсәре, монда стереотип фикергә урын юк.

Бу әсәрдә Мәскәүгә лаеклы үз бәясе бирелсә, әдипнең «Соңгы сулыш» әсәрендә без шул империя әгъзаларының көчле сарказм белән сугарылган көлкеле дә, кызганыч та... куркыныч та булган жанлы, реаль образлары белән очрашабыз: әлеге горур совет гражданнарының үзләре гомер буе мәсхәрәләп көлеп килгән Шәрекъ илләре чүплегендә бүген ташланган иске кирәк-ярак эзләп казынулары күп нәрсә турында сөйли булса кирәк.

Бу әсәрләрдә Ташкала нык алга киткән Шәрекъ цивилизациясе Япония, Корея, Сингапур, Ган-Конг белән янәшә куелгач, аның киләчәге тагын да фажигалерәк тоела. Шушы капма-каршы традицияле ике кыйтга арасында безнең көнелебезнең чын үзәге—туган Татарстаныбыз пәйда була. Аның язмышы нинди булыр? Ул кайсы юлдан китәр? Язучы, рәссам, шагыйрь-публицист, фикер иясе М. Юныс безне әнә шул хакта уйланырга чакыра. Бу олы әдипнең металл клапанлы йөрәге, безне бүген, Яңа чор чатында, яратырга һәм нәфрәтләнергә, көрәшергә һәм бирешмәскә дәртләндерә. Бу йөрәк, бу ижат безне һәр чакта, һәр очракта кыйблабызга һәм үз-үзебезгә тугры калырга чакыра.

---

*Безнең календарь*

## Кәшшаф Әмировның тууына 90 ел

Кәшшаф Әмиров драматургиягә зур тормыш мәктәбе үтеп килә. 1922 елның 7 апрелендә хәзерге Ульяновск өлкәсенең Иске Кулатка районы Яңа Зимница авылында туган егетнең үсмер чагы һәм мәктәп еллары Үзбәкстанда уза, Бохара укытучылар институтын тәмамлаганнан соң 1940–1945 елларда Үзбәкстан мәктәпләрендә балаларга белем бирә, Ташкентта юридик курсларны тәмамлый һәм 1950 елга кадәр Тажикстанда тикшерү органнарында эшли. Бу өлкәне яхшы белү нәтижәсе булып ижат эшенә керешкәч «Хөкем алдыннан», «Гаделлек жинә» пьесалары барлыкка килә.

1960 елда Татарстанга кайтып башта Азнакай, аннары Лениногорск шәһәренә килеп төпләнә. Нефтьчеләр тормышына багышланган «Шөгер моннары» пьесасы К. Әмировның шул еллардагы ижат жимеше. Аның шулай ук «Туй алдыннан», «Кодалар», «Упкын» пьесалары да җитмешенче еллар башында Республика татар драма һәм комедия театры сәхнәсендә уңыш белән бара, Үзбәкстан, Оренбург халык театрлары тарафыннан да сәхнәләштерелә. Кәшшаф Әмиров драматургиясенең төп үзенчәлеге дә заманның актуаль проблемаларын, халыклар арасындагы дуслыкны яктырта белүендә. Бу җәһәттән авторга зур уңышлар китергән «Зөлфия» пьесасы мисал була ала. Әлеге пьеса татар һәм рус сәхнәләрендә куела. Әфган халкы белән совет халыклары арасында урнашкан дуслыкка багышланган бу пьеса 1983 елда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә уйнала, рус теленә тәрҗемә ителеп шул ук елны «Театр» журналында басылып чыга. К. Әмиров–1985 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы. 1996 елның 26 сентябрендә вафат була.

*Юмор-сатира*

# Маннур Саттар

## Такмаклар

*(Урам көенә)*

Алмалы гөл чәчәк ата
Майның унбишләрендә.
ВУЗ бетереп чәчәк сата
Минем дус-ишләрем дә.

Кызарып чыккан кояшның
Белмим кайда байганын.
Балконым карый көньякка,
Шунда үтте елларым.

Чәчем сүттем тарыйм дип,
Күзгем сөрттем карыйм дип.
Җырларымны кыркып баскан,
Түрәләргә ярыйм дип.

Абау дия, башын ия,
Башы авыртмаса да,
«Халкым!»—дия, кәпәч кия,
Халкын кайгыртмаса да.

Коттеджының бакчасы,
Тимер икән капкасы.
Тимер булмый нәрсә булсын,
Бар да бюджет акчасы!

Ишегалдым ак балчык,
Ак балчыктан атлап чык.
Кыскартыласың килмәсә,
Башлыгыңны мактап чык.

Өй артында шомыртым,
Яннарында багана.
«Ваучер» дигән кәгазь биреп,
Утырттылар бабага.

Агыйделнең аръягында
Талдин кәрзин үреләр.
Суга салсаң, калкып чыга
Безгә насыйп түрәләр.

Агыйделдә ике сал,
Берсе каен, берсе тал.
Чит илләргә елга булып
Ага безнең капитал.

Уфаларга барам әле
Чана юлы салынгач.
Без сорамый, кем сорансын,
Күпме завод ябылгач?

Сатин кайта пичәтсез,
Сатып алдым кисәксез.
Баеганнар меңгә берәү,
Шәрә калган исәпсез.

Әй бу дөнья хәлләре,
Тотып ташка бәрмәле!
Бәйдән ычкынган бәяләр
Егып талый бәндәне!

Кайтып аудым өйләргә,
Бүрегем элми чөйләргә.
Айга ике получкалар
Калды сагынып сөйләргә.

«Житми,—дисең,—акчабыз»,
Бар бит әле бакчагыз.
Телефон да куйдырырсыз,
Бакчагызны сатсагыз.

Китә казлар, китә казлар,
Без кайтырбыз язлый, дип.
Премиальный бирмәделәр,
Телең озын, абзый, дип.

Буфетчы кыз белен сата,
Язып куйган бөккән дип,
Шул каешны кабып йоттым,
Беткән башым беткән, дип.

*(Сарман көенә)*

Сандугачлар кунып кайда сайрый—
Сарман буйларында тирәктә.
Атна саен яңа бәя белән
Товар кайта безнең төбәккә.

Сарман буйларында яшел алан,
Печәннәре житәр бер заман.
Эш хакларын алу күнелле дә,
Биш ай көтүләре бик яман.

Сарман буйларына чыгарсыңмы,
Кармак асып иртән балыкка.
Күзләреңне тутырып карарсыңмы,
Зәңгәр тауда коттедж калыкка?

## Бәйрәм бүген

*(Тукайча түгел)*

Бар күнелсезлек нидән соң? Юк гадәти ямь бүген.
Нәрсәдән бу? Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Килми хат, котлау, гәҗиттер, һәр кеше хәйран бүген.
Эшләми бер почта да: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Ичмаса, сериал карыйм, дип, ачсаң экранның йөзен,
Анда юк мавыкканың: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Ут бетеп йә тукталып су, житсә чаң сугар көнен,
Юк телефон алгучы: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Күршеләрнең жен туеннан дер килсә панель өен,
Зарланырга юк хакың: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Өч тәүлек бармыш бу мәхшәр, китмәсә бер атнага!
Еш кына кемдер дучар бәла-казага капмага!

Рәхмәт әйт, төгәлләнсә ул шеш яки күңгәк белән,
Бетмәсә бәйрәм кичәсен соңгы кат күрмәк белән!

Типтерергә бертоташтан, шатланырлык нәрсә бар?
Әллә өелгәнме тау-тау ил житештергән товар?

Яртысы елның кызыл көн, бер гажәп-хәйран миңа!
Житсә эш башланган атна, шунда чын бәйрәм миңа!

# Uquçı süze
# Укучы сүзе

* * *

Bu xatnı aptırağannan yazam inde. Xikmət menə nərsədə. Mina xəzer citmeş biş yəş tula. Un yəşemnən birle «Qazan utları»n uqıy idem. Əle ul zamanda jurnal «Sovet ədəbiatı» dip atala ide həm latin xəreflərə belən basıla ide. Uncide yəşemnən xərbi xezmətkə alınıp, utız yıldan artıq şul armiə qamıtın kiep yəşərgə turı kilde.

Şul səbəple ul yıllarda jurnalnı rətləp uqıp bulmadı. Ə inde otstavkağa çıqqaç, 1980 yıldan birle jurnalnı daimi uqıp kilə idem. Əmma 1994—1996 yıllarda uqıp bulmadı—katalogta yuq ide. Ə inde 1997 nçe həm 2000 nçe yılnın berençe yartısına çaqlı yazdırıp alıp buldı—katalogta bar ide. Ə inde 2000 yılnın ikençe yartısınnan birle bu kəngəçə jurnalga yazılıp bulmıy. Rusiə, BDB kataloglarında Qazannan tik «Вечерняя Казань» gəzite genə kertelə. Bu xəlgə zarlanıp qaya ğına yazıp qaramadım—ləm-mim! Jurnalnı uqudan məxrüm itelü minem өçen bik zur qayğı, faciğa.

Sezgə mərəcəğətem həm sorawım şul: Tatarstan matbuğatın Belarus' katalogına kertü kemgə bəyle? Nişləp «Вечерняя Казань» kertelə, ə başqa gəzit-jurnallar, bigrək tə, tatar telendə—yuq?

Sovetlar zamanında kirək nərsəne Qazannan «Книга-почтой»dan aldıra idem. Andıy ğəməl xəzer yuq ikən. Mərəcəğətem şul: jurnal nөsxəsen ay sayın redaksiə mina poçta aşa cibərə almas mikən. Aqçasın poçta perevodı belən cibərer idem.

Üzem Aqtanış rayonınnan (Axun awılınnan). Xəzer Tatarstan xəbərləren «Azatlıq» radiosı tapşıruın tınlap qına xəbərdarmın. Şul unaydan niçek inde Amerika kongressına rəxmət uqımıysın!

Bezne, tatarlarnı, kimsetü, cəberləw yuq monda. Bezdən, sovet çorında kilgən tatarlardan, tış monda 600 yıllar elek kilep urnaşqan tatarlarnın warisları da yəşi. Alar telləren küptən inde yuğaltqannar. Əmma islam dinen totalar. Şular belən bergə beznen ictimağıy oyışma (rəsmi berketelgən) bar. Xөkümət tüləwsez birgən binabız bar. Şunda cıyılabız, ğərəp yazuın, Qər'ənne өyrənü maqsatı belən yəkşəmbe məktəbe eşli. Uraza, Qorban bəyrəmnəre ütkərelə. Mədəni tormışqa kilgəndə, өlkə həm respublika milli-mədəni festival'lərendə qatnaşabız—üzeşçən sənğət kollektivıbız bar. Şunda min də talyan həm saratov (qınğırawlı) garmunnarında uynıym. Sirək-mirək өlkə gəzitlərendə minem məqələlərne bastıralar tatarlar turında. Küp məğlümatnı «Qazan utları»nnan ala idem, ləkin ul mөmkinlek bette xəzer. Aptırağaç «Вечерняя Казань» gəziten aldırabız.

Menə şulay sağınıp-sarğayıp çit cirlərdə qartayabız inde. Aptırağan-yədəgən digən şikelle. «Azatlıq»qa da yazıştıram.

Qatnaş ğailələr monda bixisap küp. Xərbi xezməttə bulğan ir-tatarlar marcağa өylənğənnər. Ə tatar qızları çirəm cirlərne eşkərtkən zamanda urıs, belorus, polyaklarğa kiəwgə çığıp, bu cirlərgə «qaytqannar». Yuğarı uqu yortların beterep eşkə kilgən qızlar da cirle kiəwlərgə tormışqa çığıp urıs ğailəse tөzegənnər. Bar tatarlar da (cirlelər də, «beznekelər» də) uqımışlı zıyalılar—tabiblar, uqıtuçılar, injenerlar. Menə şulay beznen xalıq başqa xalıqqa xezmət itə. Üzem də xərbi xezməttən son ike yıl tөzüçe injener bulıp eşlədem. Barığızğa da səlamətlek wə icadi unışlar teləp, səlam belən

**Saniaf GARDANOV**
Belarus' respublikası

# ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ БАШЛАНДЫ

Хөрмәтле укучыларыбыз!

2002 елның икенче яртыеллыгы өчен вакытлы матбугатка язылу башланды. Ул 26 июньгә кадәр дәвам итәчәк. "Казан утлары"ның индексы—73210, ярты елга язылу бәясе—66 сум.

Журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Әлеге квитанцияне кисеп алып, анда тулы адресыгыз, исем-фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.

Казанлылар исә безнең журналга "Горпечать" киоскларында языла алалар. Бу очракта журналны ай саен шуннан барып аласы була.

80 еллык бай тарихы булган мәдәниятебез елъязмасы "Казан утлары"на язылырга онытмагыз!

Ф.СП-1

Управление почтовой связи
"Татарстан Почтасы"

**АБОНЕМЕНТ на** ~~газету~~ журнал — 73210 (индекс издания)

*Казан утлары*
(наименование издания)

Количество комплектов:

на 2002 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда
(почтовый индекс) (адрес)

Кому
(фамилия, имя, отчество)

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

| ПВ | место | ли-тер |
|---|---|---|

на ~~газету~~ журнал — 73210 (индекс издания)

*Казан утлары*
(наименование издания)

| Стоимость | подписки | ______ руб. ______ коп. | Количество комплектов |
|---|---|---|---|
| | переадресовки | ______ руб. ______ коп. | |

на 200 2 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда
(почтовый индекс) (адрес)

Кому
(фамилия, имя, отчество)

## КОНСТИТУЦИЯДӘГЕ ҮЗГӘРЕШЛӘР

Февраль ахырында Татарстан Дәүләт Советының X пленар сессиясенең чираттагы утырышы үткәрелде. Утырышта каралган «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» закон проектын республикабызда яшәүчеләр, бигрәк тә татар халкы шактый борчу белән каршылады. Конституциянең яңа редакциясендә Татарстанның суверенлыгы ни дәрәҗәдә сакланыр? Конституциябез киләчәктә дәүләтчелегебезне ныгытуга ярдәм итә алырмы?

Сессия утырышында иң башта республиканың бүгенге хәле һәм 2002 елда социаль-икътисади сәясәтнең төп юнәлешләре турында Президент Минтимер Шәймиевнең Дәүләт Советына юлламасы тыңланды.

Аннары «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» закон проекты тикшерелде. Президент житәкчелегендә эшләгән комиссия тарафыннан тәкъдим ителгән үзгәрешләр Конституциянең барлык бүлекләренә кагыла. Тулаем алганда, Конституция шактый үзгәргән һәм югары төшкән. Конституциянең нигезен тәшкил итүче маддәләр федераль хокук белгечләре белән килештерелгән. Сессиядә доклад белән Конституциянең яңа редакциясе проектын әзерләү буенча эшче төркем житәкчесе Марат Галиев чыкты.

Докладта билгеләп үтелгәнчә, Татарстанның элек-электән рейтингы югары, Россия субъектлары арасында һәр өлкәдә алдынгы урыннарда тора. Татарстан Республикасының статусы 1 нче маддәдә ачык чагыла: «Татарстан Республикасы—Россия Федерациясе белән Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында үзара эшләр бүлешү һәм вәкаләтләр алмашу турында» Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсе нигезендә берләшкән һәм Россия Федерациясенең тулы хокуклы субъекты булган демократик, хокукый, социаль дәүләт. Татарстан Республикасы суверенлыгы Россия Федерациясе карамагындагы эшләр чикләреннән һәм Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасының уртак карамагындагы эшләр буенча Россия Федерациясе вәкаләтләреннән тыш, дәүләт хакимиятенең (закон чыгару, башкарма һәм суд) бөтен тулылыгына ия булуда чагыла һәм Татарстан Республикасының аерылгысыз хасияте була.

Татарстан Республикасы статусы Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең үзара килешүеннән башка үзгәртелә алмый. Татарстан Республикасы чикләре аның ризалыгыннан башка үзгәртелә алмый. Татарстан Республикасы үз вәкаләтләре кысаларында халыкара һәм тышкы икътисади мөнәсәбәтләрдә мөстәкыйль катнаша».

Төп канундагы үзгәрешләр депутатлар арасында каршылыклы төрле фикерләр уятты. Депутат язучыларыбыз да бу сессиядә актив булдылар, кискен, әмма гадел үз сүзләрен әйттеләр. Разил Вәлиев, мәсәлән, федераль үзәкнең милли республикаларны бетерү сәясәте алып баруын билгеләде. Туфан Миннуллин Татарстан Конституциясенең референдум юлы белән кабул ителүен, шунлыктан төп маддәләрнең үзгәрешсез калырга тиешлеген искә төшерде.

Парламент «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» закон проектын беренче укылышта кабул итте. Ул рәсми гаммәви мәгълүмат чараларында бастырылачак, халык депутатлары Советлары сессияләрендә тикшереләчәк. Барлык тәкъдимнәр гомумиләштерелгәч, проект Дәүләт Советына икенче укылышка чыгарылачак.

## ДАТАЛАР АЧЫКЛАНДЫ

Февраль азагында Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булып узды. Идарә рәисе Фоат Галимуллин Татарстан язучыларының быел үтәчәк XIV Корылтаена әзерлек мәсьәләләре турында сөйләде. Идарә әгъзалары Корылтайны май ахырында, ягъни 31 майда, җомга көнне уздырырга дигән уртак фикергә килделәр. Утырышта шулай ук «Казан утлары» журналының быел узачак 80 еллык юбилее турында журналның баш мөхәррире Равил Фәйзуллинның белдерүе тыңланды. Журнал юбилее тантаналары август ахырында Бөтендөнья татар конгрессы көннәрендә үтәчәк.

## АКСАКАЛЛАР СҮЗЕ

Татарстан Республикасы Аксакаллар шурасы Бөтенроссия халык санын алу уңаеннан татар халкына мөрәҗәгать белән чыкты.

Өндәмәдән күренгәнчә, «2002 елгы Бөтенроссия халык санын алу материалларын эшкәртү өчен милләтләр исемлеге» һәм «Милләтләрнең һәм телләрнең системалы сүзлеге» аксакалларда борчу һәм хәвеф тудыра.

Бу документлар татар милләтен диалектлар буенча—мишәрләр, дин буенча—керәшеннәр, территория буенча—Себер, Әстерхан һәм башка татарлар, сословие-катлаулар буенча—ногайбәкләргә бүлүне күздә тота. Мондый билгеләү Россия Федерациясенең башка милләтләре арасында татар милләте санын киметү омтылышы булып тора.

Татарстанның Аксакаллар шурасы татар халкын 2002 елгы халык санын алганда үз милләтен «татар» дигән графада билгеләргә өнди.

## КҮПМИЛЛӘТЛЕ ХАЛЫК БУЛМЫЙ

Россия татарларының милли мәдәният мохтәрияте рәисе, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Индус Таһиров Мәскәүдә булып кайтты. Ул анда милли мәдәният мохтәриятләре вәкилләренең Дәүләт Думасы рәисе Геннадий Селезнев белән очрашуында катнашты.

Индус Таһиров үз чыгышында Россиядә булачак халык санын алу белән бәйле мәсьәләләрнең фәнни юл белән чишелергә тиешлегенә басым ясады һәм татарларны берничә милләткә бүләргә тырышуны бик шөбһәле эш дип атады.

## ЖАНГА УЕЛГАН ХӘТЕР

Татарстанның «Сәяси репрессия корбаннары» турындагы «Хәтер китабы»ның 5 нче томы дөнья күрде. Андагы меңләгән фамилия арасында каһарман-шагыйрь Муса Жәлилнең бертуган апасы һәм Россиянең беренче президенты Борис Ельцинның әтисе дә бар. Китапка «Е», «Ж» һәм «З» хәрефләренә башланган барлыгы 3500 гә якын фамилия кергән. Алар «советка каршы эшчәнлек, пропаганда һәм агитация алып барганнары өчен» 1918—1983 елларда кулга алынган, Татарстанда туган һәм яшәгән кешеләр, шулай ук безнең республикада тоткынлыкта атып үтерелгән һәм үлгән кешеләр.

## ЯНӘ БЕР ИСЕМЛЕ БУЛДЫ

Күренекле шагыйрь, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ренат Харисның Чабаксарда иҗат кичәсе үтте. Чуаш һәм татар халыклары арасындагы мәдәни багланышларны ныгытуга керткән хезмәте өчен Р. Хариска «Чуаш республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде. Иҗат кичәсендә чуаш шагыйрьләре Юрий Семендер, Порфирий Афанасьев, Валерий Тургай, Раиса Сарби, Светлана Азамат, Татарстаннан—Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, «Мәдәни жомга» газетасының баш мөхәррире Зиннур Мансуров катнашты.

## КАЮМ НАСЫЙРИ МУЗЕЕ

Күренекле мәгърифәтче Каюм Насыйри—татар тарихына нык уелган шәхес, чын дәрәҗәсендә милли энциклопедик галим. Ул үзеннән соң 40 ка якын басма китап һәм басылып өлгермәгән бик күп кульязма хезмәтләр калдырды, төрле гуманитар фәннәрнең нигезләрен эшкәртте. Мәгърифәтче, хәзерге татар әдәби теленә нигез салучы, татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеген, икетелле сүзлекләрне, фәнни яктан эшкәртелгән беренче татар грамматикасы «Нәхү китабы»н («Синтаксис»), математика, география, табигать белеме буенча татар телендәге беренче дәреслекләрне төзүче, халыкта киң таралыш алган календарьлар нәшер итүче. Аның «Китап әт-тәрбия», «Буш вакыт» хезмәтләре—татар балалар әдәбиятының чишмә башы санала.

К. Насыйриның тормышы һәм иҗади эшчәнлеге Казан белән тыгыз бәйләнгән, 1841 елдан башлап вафатына кадәр (1902) ул биредә яшәгән. Шуңа күрә мәркәзебездә бу олуг шәхеснең музее янадан торгызылмау (ул яшәгән музей-йорт 1979 елда яныл вәйран булган иде) җәмәгатьчелекне борчып килде. Ниһаять, февраль башында К. Насыйриның музее яңадан эшли башлады. Тантананы Татарстанның мәдәният министры И. Тарханов ачты һәм алып барды. Музей ачу церемониясендә Дәүләт Советы депутатлары, язучылар Р. Миннуллин, Р. Вәлиев, галимнәр Х. Миннегулов, Р. Ганиева, Вахитов районы хакимияте башлыгы Р. Борһанов, К. Насыйриның якташлары—Яшел Үзән шәһәре һәм районы хакимияте вәкилләре, К. Насыйри премиясе лауреатлары катнашты. Сонрак музей директоры Р. Хөснетдинова жыелган халыкны музей экспонатлары белән таныштырды.

Музейның адресы: Казан, Париж Коммунасы урамы, 35 йорт.

## КҮЛЛЕ КИМЕ—ШАГЫЙРЬ БИШЕГЕ

Үткән елның декабрендә Татарстанның халык шагыйре Сибгат Хәкимнең 90 еллыгы республикада һәм татарлар яши торган кайбер төбәкләрдә киң билгеләп үтелде. Кыш фасылының соңгы көннәрендә шагыйрьнең туган авылы Күлле Кимедә дә зурлап искә алулар булып узды. Шагыйрьнең туган җиренә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, халык шагыйрьләре Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, язучылар Әхсән Баян, Галимҗан Гыйльманов, шагыйрьләр Харрас Әюп, Бикә Рәхимова белән Фирая Зыятдинова, «Татарстан» радиосы режиссеры Госман Әхмәтҗанов, язучы Әхәт Сафиуллин составындагы төркем дә Сибгат Хәкимне искә алырга, аны юксынып утырган өянкеләренә баш иярга килделәр. Бу тантанага шагыйрьнең

улы—Татарстан Президенты кинәшчесе, Фәннәр академиясенең Тарих институты директоры Рафаил Хәкимов та килгән иде.

Кунаклар ин башта моннан егерме ел элек мәктәптә оештырылган С. Хәким музеенда булдылар. Экспонатлар белән музей мөдире Луиза Шәмсиева таныштырды. Музейны караганнан соң язучылар, Күлле Киме мәктәп укытучылары һәм укучылары коллективы белән очрашып, С. Хәкимне зурлап искә алдылар.

Күлле Кимедән соң кунаклар район үзәгендә—Г. Тукай исемен йөрткән авыл хуҗалыгы техникумында—Сибгат Хәкимгә багышланган кичәдә катнаштылар.

## «САНДУГАЧ КЕРДЕ КҮҢЕЛГӘ»

25 февраль көнне Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында күренекле шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановны (1941—1995) искә алу кичәсе булды. Язучылар берлеге һәм Г. Камал театры инициативасы белән оештырылган бу кичәдә шагыйрьнең шигырьләре, җырлары, үзе исән чакта язып алынган чыгышлары яңгырады. Замандаш каләмдәшләреннән Роберт Әхмәтҗан, М. Әгъләм, Зөлфәт Рәшиткә багышланган шигырьләрен укыдылар, җырчылар К. Хәйретдинова, Р. Ибраһимова, А. Фәйзрахманов шагыйрь сүзләренә язылган җырларны башкардылар. Шагыйрьнең бертуган энесе, Г. Тукай премиясе лауреаты Илдус Әхмәтҗанов башкаруында яңгыраган шигырьләр аеруча тәэсирле булды. Кичәнең сценарий авторы—Р. Батулла, режиссеры И. Хәйруллин.

## «БЕЗ—ИСӘН!»

26 февральдә Тинчурин театрында күренекле шагыйрь, публицист Айдар Хәлимгә 60 яшь тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Милләтпәрвәр юбилярны җырчылар И. Шакиров, Р. Үзбәкова, Р. Баһадур, Р. Маликов котлады, артистлар А. Арсланов, И. Әхмәтҗанов, Х. Җәләй, Ә. Шакиров шагыйрьнең шигырьләрен укыды. Татарстан Президенты М. Шәймиевнең Айдар Хәлимгә юллаган котлау хатын Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин ирештерде.

Айдар Хәлимнең иҗат бәйрәме Мәскәү һәм Чаллы шәһәрләрендә дә зурлап уздырылды.

## МУЗЕЙДА КУНАКТА

М. Җәлилнең квартира-музеенда Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, шагыйрь Әхмәт Гаделнең 60 яшьлек юбилее уңаеннан әдәби-музыкаль кичә булып узды. Шагыйрь иҗаты турында галим язучы Т. Галиуллин сөйләде. Шагыйрь сүзләренә язылган җырларны Э. Җәләлетдинов, М. Галиев, С. Сабирова һ. б. башкарды.

## ЕРАКТАГЫ ЯКЫН ШАГЫЙРӘ

Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Башкортстанның Нариман районында яшәп иҗат итүче шагыйрә Халисә Мөдәррисова Казанда булып китте. Укучыларыбызга ул шигырь китаплары, «Утыртмадың атларына», «Балан», «Сагынам сөйгәнемне» кебек популяр җырлар авторы буларак билгеле. Язучыларның Тукай клубында шагыйрә белән очрашу булды. Кунак шагыйрә үзенең шигырьләрен укыды, Башкортстандагы язучыларыбыз турында сөйләде, сорауларга җавап бирде. Очрашуда шагыйрьләр И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, М. Әгъләмов һ. б. катнашты. Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин да шагыйрә турында җылы сүзләр әйтте. Шагыйрә белән очрашу яшьләрнең «Шәрык» клубында да үткәрелде.

## КЛУБ КАВЫШТЫРДЫ

«Казан утлары» журналы программисты Альбина Әхмәтова белән Касыйм морзаларының нәсел дәвамчысы, Бөтентатар интернет-форумы һәм виртуаль татар тарихи интернет клубы хуҗасы мәскәүле Айнур Сибгатуллинның никахы булды.

«Шәрык» клубы активисты Гамил Гыйбадуллин әйтүенчә, алар җәй көне шушы клубта очрашканнар. Хәзер клуб әлеге матур гадәтне дәвам итеп, төрле шәһәрләрдән ялгыз йөрәкләрне кавыштырырга ниятли. «Шәрык» Санкт-Петербургның берничә клубы белән элемтәдә тора.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Президенты Указы белән Татарстан радиосының әдәбият-сәнгать һәм музыкаль тапшырулар дирекциясе директоры Җәүдәт Харис улы Дәрзамановка «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

Тышлыкның беренче битендә: «Язгы ташу»—*фотоэтюд.*

Тышлыкның дүртенче битендә: шагыйрә Флера Тарханова.

# АВЫР ЮГАЛТУ

Татар әдәбияты зур югалту кичерде: 13 мартта 75 нче яшендә күренекле прозаик һәм драматург Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев вафат булды.

А.М.Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында Татарстан Республикасының Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туган. Балачагы һәм мәктәп еллары Зәй районы, Югары Баграж авылында уза. Сарман урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, берникадәр вакыт колхозда эшли, аннары ике елга якын ВЛКСМның Зәй районы комитетында бүлек мөдире була. 1948—1950 елларда ул - Казан дәүләт университеты студенты. Әмма ана, сәяси репрессиягә дучар булу сәбәпле, укуыннан бүленеп, 1950 елның мартыннан 1955 елның августына кадәр тоткынлыкта газап чигәргә туры килә. Гаделлек тантана итеп, тулысынча аклангач, ул яңадан Казанга әйләнеп кайта һәм университетта укуын дәвам иттерә.

1957 елның мартыннан 1961 елның августына кадәр А.М.Гыйләҗев матбугат эшендә: «Чаян» һәм «Азат хатын» журналлары редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, «Совет әдәбияты» журналында проза бүлеге редакторы вазифаларын үти. 1961—1963 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби курсларда укып кайтканнан соң, Аяз Мирсәет улы калган гомерен, профессиональ язучы буларак, тулысынча әдәби иҗат эшенә багышлый.

Аяз Гыйләҗевнең бай иҗаты, таулар куенынннан ургыган чишмә кебек, 1956 елдан башлана. Аның дистәләрчә хикәяләре, фельетоннары, үткен мәкаләләре бер-бер артлы төрле газета-журналларда дөнья күрә. Татарстан китап нәшриятында беренче хикәяләрен, повестьларын туплаган «Рәтле кешеләр», «Яшьлек юлларында», «Дүртәү» дигән җыентыклары басылып чыга.

Беренче әсәрләреннән үк аның иҗатында кырыс реализм, халыкчан образларга бай җор тел һәм үзенчәлекле сурәтләү алымнары күренде. Ул кайсы чор турында һәм нинди темага язса да, кеше шәхесенең катлаулы рухи дөньясын, эш-гамәлләрен, заманның гуманистик идея-эстетик карашлары югарылыгыннан торып анализларга омтылды. Әдәби осталык, форма өлкәсендә өзлексез эзләнү, кыен тәҗрибәләр—атаклы каләм остасы Аяз Гыйләҗевнең иҗат эшчәнлегенең төп асылын тәшкил итте. Бу сыйфатлар әдипнең соңгы елларда язылган бихисап әсәрләрендә аеруча ачык чагыла. «Өч аршын җир», «Зәй энҗеләре», «Урталыкта», «Язгы кәрваннар», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят», «Мең чакрым юл», «Җомга көн кич белән», «Әтәч менгән читәнгә», «Яра», «Балта кем кулында?», «Йәгез, бер дога!» әсәрләре татар әдәбияты казанышына әверелде.

А.Гыйләҗев өч дистәдән артык драма әсәре авторы да иде. Драматургның пьесалары башкорт, рус, словак, авар, чуаш милли театрлары сәхнәләрендә куелды һәм киң яңгыраш тапты.

Әдәбиятыбызның һәм театр сәнгатен үстерүдәге зур хезмәтләре өчен әдипкә Татарстанның Г. Тукай исемендәге һәм Россия Федерациясенең М.Горький исемендәге Дәүләт премияләре бирелде. Ул шулай ук Татарстанның халык язучысы, Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе иде. Ул—Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге премиясе лауреаты да иде.

Татар әдәбиятының олпат вәкиле, күпкырлы талант иясе, кабатланмас олы шәхес арабыздан китте. Аның бай иҗаты киләчәк буыннарга да хезмәт итәр, якты истәлеге халкыбыз күңелендә мәңге сакланыр.

М.Ш.Шәймиев, Р.Н.Миннеханов, Ф.Х.Мөхәммәтшин, Ә.С.Гобәйдуллин, З.Р.Вәлиева, Р.М.Миннуллин, И.Г.Тарханов, Ф.Г.Галимуллин, К.Ш.Исхаков, Р.С.Хәмәдиев, Р.Ш.Фәрдиев, М.Х.Сәлимҗанов, Р.А.Тажетдинов, А.Я.Славутский, Н.С.Фәттахов, Р.Г.Фәйзуллин, Т.А.Миннуллин, И.Г.Юзеев,А.Л.Литвин, Ш.Г.Галиев.



Аяз Гыйләҗев

1928—2002

Индекс 73210



Флера Тарханова

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)